# КАЗАН УТЛАРЫ

10.1990



## ЖУРНАЛ АЛДЫРУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА!

Журналның брак саны килгән очракта аны газета-журналлар нәшриятының техник контроль бүлегенә җибәрүегезне үтенәбез. Адресы: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2, Типография ГЖИ, ОТК.

Редакция журнал җибәрү белән шөгыльләнми.

Әгәр журналның теге яки бу саны килми калса, «Союзпечать»нең җирле бүлекләренә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бу мәсьәлә редакция вәкаләтенә керми.

Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ЖУРНАЛЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

1990

10

(816)

ТАТАРСТАН ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда:*

Милләтебез килер көнгә ышана! *Котлаулар, теләкләр* . . . 3

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

**М. МАЛИКОВА.** Фидая. *Роман* . . . 5
**Р. НИЗАМИ.** Вакыт җиле. *Шигырьләр* . . . 87
**Ә. МӘХМҮД.** «Матур» исем эзләүчеләргә. *Шигырьләр* . . . 91
**Л. ЗӨЛКАРНӘЙ.** Зең . . . 117
**К. ЛАТЫЙП.** Әминә. *Шигырь* . . . 120
**Н. ШӘМСЕТДИНОВ.** Муса Җәлил истәлегенә. *Шигырь* . . . 122

ХИКӘЯЛӘР ЯРЫШЫ

**М. ЮНЫС.** Каравыл йорты . . . 93
**Р. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН.** Сиртмәле кое . . . 105
**З. ХӘКИМ.** «Контра» . . . 113

ПУБЛИЦИСТИКА

**Р. ФӘИЗОВ.** Илгә бәрәкәт иңәрме? . . . 124

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Т. ӘЙДИ.** Хакыйкатькә яңа адым . . . 131
Тукайлар рухы (*Татарстан халык депутаты, язучы Ф. Бәйрәмова белән әңгәмә*) . . . 141

КОРЪӘН СҮРӘЛӘРЕ

**Ә. ХӘЙРУЛЛИН.** «Укыйм тиз-тиз күңелдән бер гаҗәеп сүрә Коръәндин» . . . 148
Фатиха, Аятел-көрси, Рахман, Ихлас, Фәлакъ, Нас сүрәләре . . . 151

КИТАП КҮЗӘТҮ

**А. ӘХМӘДУЛЛИН.** Рухи мирасыбызны барлаганда . . . 163
**Р. ДАУТОВ.** Фәннилек хәбәрчесе . . . 165

СӘНГАТЬ

**В. ГОРШКОВ.** Дөнья сәхнәсенә сәфәр . . . 166
**Х. ФӘЛӘХЕТДИНОВ.** [illegible]? . . . 168

*Баш мөхәррир*

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН

*Редколлегия*

ГАРИФ АХУНОВ
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ФЛҮС ЛАТЫЙФИ
*(җаваплы сәркәтип)*
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
МАРАТ МӨЛЕКОВ
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РАШАТ НИЗАМИЕВ
*(баш мөхәррир урынбасары)*
ГӘРӘЙ РӘХИМ
КОЯШ ТИМБИКОВА
*(бүлек мөхәррире)*
МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ
*(бүлек мөхәррире)*
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркәтип — 53-07-09.

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

МӘДӘНИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

**Р. ӘМИРХАН.** Иелмәс баш . . . . . . . 172
**А. РАСИХ.** Гаяз Исхакый хаты . . . . . . . 173
**Ф. БАҺАВЕТДИНОВ, А. ӘХМӘДУЛЛИН.** Фәтхи Бурнашның соңгы көннәре . . . . . . . 176
**М. БАКИРОВ.** Сак белән Сок кайлардан килә? 183

ТАТАР ХАЛКЫ ТӨРЛЕ ТӨБӘКЛӘРДӘ, ТӨРЛЕ ИЛЛӘРДӘ

**Р. ӘЛТӘФ.** Маньчжуриядәге милләттәшләребез 187

КИТАПЛАР ДӨНЬЯСЫНДА

**М. ТАҺИР.** Чит илләрдә татар вакытлы матбугаты . . . . . . . . . . . . . . . 189

Мәдәният тормышы көндәлеге . . . . . . . 190

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Народ верит в будущее. Поздравления, пожелания.
«Проза и поэзия»: начало романа М. МАЛИКОВОЙ «Фидая». Стихи Р. НИЗАМИ, А. МАХМУДА, Л. ЗУЛКАРНАЯ, К. ЛАТЫПА, Н. ШАМСУТДИНОВА.
«На конкурс»: рассказы М. ЮНУСА, Р. ГИЗЗАТУЛЛИНА, З. ХАКИМА.
«Публицистика»: статья Р. ФАИЗОВА «Будет ли в стране изобилие?»
«Литературная критика»: статья Т. АЙДИ о современной прозе. Беседа критика М. ВАЛИЕВА с народным депутатом ТССР, писательницей Ф. БАЙРАМОВОЙ об актуальных проблемах жизни и литературы.
Суры из Корана. Предисловие научного сотрудника ИЯЛИ Казанского научного центра А. ХАЙРУЛЛИНА.
«Книжное обозрение»: А. АХМАДУЛЛИН и Р. ДАУТОВ рецензируют книгу «Татарский театр до Октября».
«Искусство»: статьи В. ГОРШКОВА «Путь на сцену» и Х. ФАЛАХУТДИНОВА «Осень печальная».
«К истории культуры»: статья Р. АМИРХАНА об издательской и редакторской деятельности Г. Исхаки; письма Г. Исхаки; статья Ф. БАГАУТДИНОВА и А. АХМАДУЛЛИНА «Последние дни Ф. Бурнаша», статья М. Бакирова о взаимосвязи устного творчества народов мира.
«Татарский народ в различных регионах страны и мира»: Р. АЛТАФ. «Татары в Маньчжурии».
В мире книг.
Хроника культурной жизни.
На наших обложках: фотокопия из Корана, изданного Духовными управлениями мусульман СССР в 1977 году; известный писатель, лауреат государственной премии им. Г. Тукая Х. Камалов.

*Бүлек мөхәррирләре:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин
*Мөхәррирләр:* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Җәүдәт Миңнуллин, Рәшит Әхмәтҗанов
*Хезмәткәрләр:* Р. Вафина, Л. Гатауллина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина

Производствога бирелде 1.08.1990 ел. Басарга кул куелды 9.10.1990 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 83044. Заказ Д-358. Бәясе 90 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе
Казан, Декабристов урамы, 2.

© «Казан утлары», 1990 ел.

# МИЛЛӘТЕБЕЗ КИЛЕР КӨНГӘ ЫШАНА!

Ярты Европа коммунизм
«Төзеп» яшәп яткан мәлендә,
Ничек мөмкин яшәү Мәскәү белән
ничә йөз ел сугыш хәлендә.

Ничек мөмкин ярты Европа
Йөзгән чакта муллык мәлендә
Мәскәү белән ничә йөз ел калу
Туйдыручы — коллык хәлендә.

Көн килде дә... мәйданнарга чыгып,
Бар халыкны әйдәп чаллылар,
КамАЗ салган кебек, Азатлыкка
Һәйбәт итеп нигез салдылар.

Мондый көндә коллар булып калу
Җинаятьтер, әйе, җинаять —
Август ае. 1990. —
Чик куелды моңа, ниһаять.

**Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ**

**Татарстанның дәүләт мөстәкыйльлеге игълан ителү уңаеннан хөкүмәт һәм җәмгыять оешмаларына, республика газета һәм журналлар редакцияләренә, Татар иҗтимагый үзәгенә котлау телеграммалары килү дәвам итә. Түбәндә алардан кайбер өзекләр урнаштырабыз.**

*Борынгы татар халкын Татарстанның дәүләт суверенитеты игълан ителү белән кайнар котлыйбыз. Кардәш халыкка сәясәт, икътисади, социаль һәм мәдәният өлкәләрендә, җөмһүриятне үзгәртеп коруда яңа уңышлар телибез.*

**Сәетбай БАЙДУЛЛАЕВ,**
Төрки халыклар җәмәгать оешмалары
ассоциациясенең оештыру комитеты рәисе.
**Бәһрам ГОИ,**
Төркстан халык хәрәкәте рәисе.
Ташкент.

*Татарстан җөмһүриятенә уңышлар!*

**Надир ДӘҮЛӘТ**
Истанбул.

*Халкыбызның каһарманнарча көрәше гүзәл нәтиҗә бирде — Союздаш Татарстан чынбарлыкка әйләнде. Шулай итеп, Татар иҗтимагый үзәге халык рухын чагылдыручы олы көч икәнен тагын бер кат раслады.*

**Айдар ХӘЛИМ.**
Уфа.

*Суверен Татарстанга бәхет телибез, җөмһүрият чәчәк атсын!*

**ӘХМӘТОВ.**
Магнитогорск.

*Бисмилла иррахман иррахим.*
*Халкыбызның мөхтәрәм җитәкчеләре! Саратов һәм Энгельс мөселманнары исеменнән Сезне һәм Сезнең аша бөтен татар халкын Татарстанның дәүләт мөстәкыйльлеге Декларациясе кабул ителү белән котлыйм. Сез үзгәртеп кору хәрәкәтенең башында тордыгыз һәм күп газаплар чиккән халкыбызны киләчәктә дә алга, яктылыкка әйдәрсез дип ышанабыз, шуның хакына гыйбадәт кылабыз, бөек Аллага сыгынабыз. Халкыбызның күпгасырлык тарихы Хак тәгаләнең бөек тәгълиматы — ислам дине белән бәйле. Ышанам, ислам дине җөмһүрият тормышында лаеклы урынын табар.*

Имам-хатиб **БИБАРСОВ.**
Саратов.

*«Казан утлары» хезмәткәрләрен Татарстан республикасының туган көне белән тәбриклибез.*

*Барчагызга саулык-сәламәтлек, халкыбызга һәм милләтебезгә армый-талмый хезмәт итүегезне теләп калабыз.*

**Нәҗмиевләр** гаиләсе.
Алма-Ата.

*Тарихыбыздагы олы борылыш көнендә Сезгә халкыбыз бәхете хакына игелекле хезмәт телибез.*

Башкортстан татар иҗтимагый үзәге.
Уфа.

*Татар иҗтимагый үзәге эшлеклеләрен Азатлык бәйрәме белән котлыйбыз. Җиңүчеләрне мең-мең кат кочаклап, рәхмәт әйтәбез.*

**Мәүләви СӘЛӘХОВ.**
Яңавыл. БАССР.

*Әзербайҗан ССРның татар җәмәгатьчелеге Союздагы барлык татар халкын тарихи җиңү — суверен Татарстан җөмһүрияте игълан ителү белән котлый. Декларацияне тормышка ашыруга — татар милләтен яңарышка илтүдә көчебезне, осталыгыбызны, белемебезне туплыйк.*

*Әзербайҗанның «Туган тел» җәмгыяте җыелышында кабул ителде.*

**Нияз ЯРУЛЛИН.**
Баку.

*Кырым-татар милли хәрәкәте оешмасының Кырым өлкә советы Идел буендагы кардәшләрен олуг җиңү белән котлый. Милләтнең терелүендә хәлиткеч адым ясалды. Бөтен өметләрегезнең чынга ашуын телибез. Алла къолай кетрсин.*

**Шәүкәт КАЙБУЛЛАЕВ,**
Кырым-татар милли хәрәкәтенең Үзәк
Советы җәмәгать сәркәтибе.
Бакчасарай.

*Удмуртиянең 200 мең татары Фәүзия Бәйрәмовага, барлык депутатларга кайнар рәхмәт юллый. Уңышлар Сезгә, ватандашлар!*

**ГАЗИЗУЛЛИН.**
Удмуртиянең татар иҗтимагый үзәге.
Ижау.

*Киләчәккә өмет белән карыйбыз. Ышанабыз, халкыбыз тагын да үсәр, чәчәк атар. Татарстан парламентына сокланабыз. Без бүген бәхетле, кадерле туганнар!*

Үзбәкстанның татар иҗтимагый үзәге.
Ташкент.

*Кукчәтау өлкәсенең күпмеңле татар халкы мөстәкыйль Татарстан республикасын котлый. Киләчәктә бу көн татар милләтен тергезү көне, бөтен дөнья татарларының гомуммилли бәйрәме көненә әйләнер. Шөкер, бу көннәрне дә күрдек! Афәрин.*

**САЛАХОВ.**
Кукчәтау өлкәсе, Кызыл яр.

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

## Мәдинә Маликова

# ФИДАЯ

РОМАН

### 1



Шомырт чәчәк аткан чак иде. Төн. Тирән ярлар арасыннан аккан елганың ике ягына сузылып утырган авыл, биек-биек тирәкләр, өянкеләр астына ышыкланып, йокыга талган. Агач башларына терәлгән салынкы болыттан, яңгыр дисәң яңгыр түгел, дым коела кебек, ара-тирә йөгереп узган җил генә яфраклардан эре тамчыларны сибеп китә. Ерактан, авыл өстендәге олы юлдан тигез гүләү ишетелеп куя, кайдадыр трактор гөрелди. Тик бу тавышлар авыл йортларын урап алган тынлыкны көчәйтә генә, ә урам баганаларындагы лампочкалар караңгылыкны куерта гына сыман. Мондый төннәрдә авылларда аеруча моңсу була: һәр йорт, башкалардан ерагаеп, бар җиһанда бер ялгызы калгандай тоела.

Шунысы юанычлы: май төннәре тиз үтә. Озакламый таң атар, иртәнге җил болытларны таратыр, яңгыр туктар, тирә-юнь, яшеллеге, чәчәкләре белән балкып, нурга күмелер. Әнә бит, төн карасы аша аксыл томан йомарламнары булып шәйләнгән шомырт агачлары шундый иртәнең килерен хәзердән хәбәр итә сыман. Шуңа күрә, иртәнең хәерле, ямьле килеренә ышанганга, һәммә җан иясе тыныч йоклый, алдагы көнгә көч җыя.

Хәер, барысы да йокламый икән әле. Әнә, олы урамда, мәктәп ихатасына урнашкан бер йортның өч тәрәзәсеннән дә гөлт итеп яктылык сибелде, алар каршында энҗе бөртекләре булып, тамчылар җемелдәште. Караңгылыкны бозган бу тәрәзә артында ниндидер борчу, тынгысызлык, хәтта хәвеф бардыр кебек тоелды. Йокының татлы сәгатендә вакытсыз, урынсыз кебек иде ул.

Бу хисне тагын да көчәйтеп, йортның тышкы ишеге каерылып ачылды, эчтән бөркелгән яктылыкта күлмәкчән генә, яланбаш хатын шәүләсе күренде. Менә ул, озын кунычлы резин итекләрен лаштыр-лоштыр китереп, ашыгып урамга чыкты, биегәйтелгән урта юл буйлап югары очка таба йөгереп китте. Сирәк лампочкалар, пыскак

---

Мәдинә МАЛИКОВА *(1935) — әдип, «Казан каласы таш кала», «Янар таулар яктысында», «Шәфкать» һәм башка әсәрләр авторы, Татарстанның һәм РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

яңгыр күзне алыштыра, хатын бик ашыга иде, шуңамы, әллә артык кабалангангамы, абынды-сөртенде, бер-ике мәртәбә янтаеп китеп, кулы белән таянды, әмма моны сизмәде дә кебек, үзалдына сөйләнә-сөйләнә, сулкылдый-сулкылдый йөгерә бирде. Биегәеп, каралып утырган идарә, клуб биналары турыннан узды; ниһаять, күпергә илткән киң тыкрыкның каршы ягындагы ихатага җиткәч, туктады, пычранган бармагы белән капка баганасындагы төймәгә басты. Якындагы багана башыннан төшкән яктылыкта капка түбәсендәге «Медпункт» дигән язу аермачык укыла иде. Хатын сабырсызланды, төймәгә озак-озак басып торды, аннары йодрыгы белән дөбердәтергә кереште.

Ниһаять, дымнан бүрткән өй ишегенең сыкрангандай шыгырдап ачылганы ишетелде, йокыдан карлыккан, әмма ягымлы хатын-кыз тавышы:

— Ишетәм, ишетәм, хәзер ачам, — диде.

— Мөнирә, мин бу! Киенеп чык тизрәк!

— Хәзер, хәзер. Үзең дә яңгыр астында торма, кер, — дип сөйләнә-сөйләнә, капканы ачты Мөнирә.

Биш минут үткәндерме-юкмы, алар кире әйләнеп тә чыктылар. Мөнирә плащ кигән, юлдашының да иңенә куртка салган иде. Ишек төбендә аларны унбиш яшьләрдәге кыз бала озатып калды.

— Кызым, син дә озаклама, тиз генә киен дә килеп җит, — диде аңа Мөнирә.

Юлдашы бераз тынычлана төшкән иде булса кирәк:

— Аны кузгатмаган булсаң да ярар иде, — диде. — Йокласын иде тыныч кына.

Аның тавышында баягы сулкылдау сизелми иде инде.

— Килеп китсен, — диде Мөнирә гади генә. — Бәлки кирәк булыр.

— Үзең генә ярдәм итә алмассың микәнни? — Хатынның тагын сулышы киселде.

— Кирәге булмаса, әйләнер дә кайтыр. Яшь кешегә нәрсә ул! — диде Мөнирә тыныч, хәтта битараф булырга тырышып.

Алар ашыгып кире түбән очка таба киттеләр. Мөнирәнең сул кулында кечкенә чемодан, уң кулы белән юлдашын култыклап алган, аны егылудан сакларга тырыша иде.

Мәктәп ишегалдына кергәч, хатын:

— Иркә уянмаган иде, — диде.

— Шыпырт кына керербез, аны борчымабыз, — дип пышылдап диярлек җавап бирде Мөнирә.

Алар өйгә кереп озак та тормадылар, хатын янә урамга атылып чыкты, янә югары очка йөгерде. Бу юлы медпунктка түгел, аны узып, күперне дә чыгып, аръякка, куе, шомлы агачлар каршына — рәт булып тезелеп баскан йортларның берсенә. Үрсәләнеп капканы какты. Бөтен урамны аякка бастырырлык иде кебек; күршеләрнең этләре яман өрде, кайдадыр казлар каңгылдашты. Ә эчтә көттерделәр, бик озак көттерделәр сыман тоелды. Ниһаять, ишек шыгырдады, калын, ачулы хатын-кыз тавышы ишетелде:

— Ни кыланасыз ул хәтле? Ут чыктымы әллә?

— Машина кирәк! Машина! Мәгъсүмнең хәле начарайды! — дип җавап бирде хатын, ике кулы белән капкага таянып. Эчтәге хатын, сөйләнә-сөйләнә, ашыкмый гына капка бикләрен ачарга кереште:

— Мин монда машина кочаклап ятаммы әллә? Таптылар, килә-ләр дә куыралар! Көн юк, төн юк!

— Син бит авылның хуҗасы! Председательгә бармый, кая барыйм?

— Хуҗа дигәч тә, алла кодрәте юк ич минем кулда! Мондый төндә яхшы хуҗа этен дә урамга куып чыгармый. Аның шоферын

кузгатасы, машинасын кабызасы... Бар әнә, Уралга әйт үзең, мин кушты диярсең...

Хатын капканың ачылып беткәнен көтеп тормады, кире йөгерде. Тагын бер капканы кагып, аннан чыкканнарын көткәнче, хәлне аңлатканчы, машинаның ватылганын, аны тиз генә кузгатып булмасын төшенгәнче бөтен бер гомер узгандай тоелды. Хатын кире йөгереп кайтканда, аның кызган маңгаена тамган яңгыр чыжлап парга әйләнә кебек иде. Мөнирә аны ишек төбенә чыгып каршы алды, хәлне сүзсез аңлады:

— Бар, Гыйззетдингә йөгер, — диде. — Баштук шуны гына дәшәсе калган.

Гыйззетдин аръякта, председательнең күршесендә... Хатын кире йөгерде. Бу юлның очы-кырые юк иде сыман... Ләкин ниндидер кодрәт белән, ниһаять, саташуга охшаш чабуның да ахыры җитте. Хатын тәбәнәк капканы ачып кергәндә, өй эчендә ут кабынып, ишек ачылды. Озак аңлатырга кирәк булмады, Гыйззетдин шундук ишегалды түрендәге сарайның киң капкасын ачып җибәрде, машинасын кабыза башлады, өйдән аның хатыны йөгереп чыкты, ул да хәлне тиз аңлап, иренең өс киемнәрен алып чыгып бирде. Аңарчы бөтен дөнья тукталып торган кебек иде, кинәт һәммәсе хәрәкәткә килгәндәй булды: берничә минуттан «Нива» машинасы мәктәп турына килеп туктады, фаралары белән түрдәге өй ишеген яктыртты, аннан медсестра Мөнирә озын буйлы ир кешенең беләгеннән нык тотып алып чыгып килә иде инде. Кызы да килеп җиткән икән, ул да чыкмакчы иде, әнисе:

— Зиләйлә, кызым, син монда гына йокла, Иркәгә иптәш булырсың, — диде. Каршына килгән хатынга:

— Менә, Зиләйләнең килүе ярады бит әле, Иркә өчен борчыласы юк, — дип куйды.

Мөнирә алга, Гыйззетдин белән янәшә, ир белән хатын арткы утыргычка утырдылар. Машина, нык гүләп урта юлга күтәрелде.

Гыйззетдин артка борыла төшеп сорады:

— Район больницасынамы?

— Кармашка барабыз, — диде аңа Мөнирә. — Билал абыйга.

— Анысы Билал кебеге район больницасында юк инде, — дип, ничектер бик йомшак кына аның белән килеште Гыйззетдин.

Машина дымлы караңгылыкны фаралары белән ертып, әүмән-тәүмән килеп, авылдан чыгып китте.

Арттагы утыргычта ирен биленнән кочаклап утырган хатынга хәзер инде сулышына кабып каядыр чабарга, кемнәргәдер хәлнең авырлыгын кабаланып аңлатырга, ярдәм көтәргә кирәкми. Хәл-әхвәл башкалар кулына тапшырылган. Башын суза төшеп, күн фуражка астыннан елтыр күзләрен алга төбәгән, вак яңгыр һәм туктаусыз чәчрәгән пычрак белән томаланган пыяла аша юл сикәлтәләрен күрергә азапланган Гыйззетдин, биш чакрым араны күпме вакыттан узды-рып, Кармашка кайчан килеп җиткерер?.. Участок больницасының баш врачы Билал Газимов ни әйтер?.. Аннары авыруны ничек дәвалар?.. Берсенә дә катнашып та, газизеңә ярдәм итеп тә булмый... Бу хәл хатынны шомландыра, шул ук вакытта җегәрен алып, хәлсезләндерә дә иде. Аның зиһене томаланып китте, аннан соңгы вакыйгалар хәтеренә яман төш кебек өзек-төтек булып кына сеңеп калдылар.

Юлның сикәлтәләре хисапсыз иде, һәркайсында йөрәк туктап торгандай булды. Хатын, кесәсеннән кулъяулык алып, иренә сузды. Яулык каралды... Артына әледән-әле борылып карап килгән Мөнирә каяндыр алып мамык кисәге сузды. Ул да тиз каралды, авырайды. Кан... Иң тирән чокырлар Кармаш урамында иде булса кирәк, алары соңгы көчне алды.

Участок больницасына олы урамнан борылып, үргә менәсе иде.

Ниһаять, килеп җиттеләр. Хатынның хәтеренә бик нык уелып калды: болдырда ире басып тора, биленнән больницаның медсестрасы Гөлфия кочып алган. Кара плащ өстеннән, Мәгъсүмнең сынын икегә аергандай итеп, ак халат җиңе сузылган. Ул башын артка каерып, аңа, хатынына карый; суырылган, агарган йөзендә хәлсез елмаю. Юаткан да шикелле ул, шул ук вакытта бәхилләшкән дә кебек. Ишек өстенә беркетелгән олы лампаның көчле яктысында бу караш, бигрәк тә караңгы машина эченнән чыкканнан соң, бик ачык күренде. Лампа яктысы аяусыз иде, ул стеналарның, ишекнең искелеген, тузганлыгын, бинаның кечкенә, шыксыз икәнлеген аеруча ачык итеп күрсәтте. Гүяки ул: «Күрегез, мәңгелек караңгылыкка илтә торган юлның башы шушы була», — дип, аяусыз битарафлык белән кисәтә иде кебек. Кинәт: «Ул моннан чыкмаячак! — дигән уй бәгырьне ярып үтте. — Үз аягы белән чыга алмаячак ул моннан... Кире кайтмаска китергәнмен...»

Ах, үкенечкә булды аның бу уе! Шушы төндә ул кулыннан килгәннең һәммәсен эшләде, кылганнары өчен үкенерлек булмады, ләкин шомлануы, алдан хәсрәтләнә башлавы, әлеге өметсез уе... Шушы ишек төбендә ул аның белән хушлаша башлады, мәңгелеккә араларның өзелгәнен шундук тойды. Һәм моңа иренең бәхилләшкәндәй елмаюы түгел, — һич юк, чөнки Билал да, Гөлфия дә артык борчылырга сәбәп юклыгын сүзләре, йөзләре, хәрәкәтләре белән аңлатып тордылар, — өметсезлеккә шушы хан заманыннан калган бинаның шомлы, битараф, ваемсыз кыяфәте, рәвеше сәбәп булды. Гүяки аның эчендә инде бик күпләрнең соңгы сулышы өзелеп, караңгылыкта, тынлыкта юкка чыккан һәм бу монда бик тә гадәти хәл иде.

...Ике көннән, тагын шул ук «Нива»га утырып больницадан китеп барганда, хатын, артка каерылып, керфек тә какмый, күздән югалганчы шул бинага карады. Дөрес, ихатаны төзекләндерергә тырышканнар, коймаларның эчен сарыга, тышын зәңгәргә буяганнар, өметсезлекне, шомны куарга маташканнар. Тәрәзә кашагалары да акка манылган. Әмма бу буяулар сиксән яшьлек карчык битенә ягылган иннек-кершән кебек кенә. Күпме яңгырлар юып, күпме карлар сыйпап узган бу соры бүрәнәләрне? Күпме күзләр аларга өмет белән текәлгән дә, яннарында күпме яшьләр түгелгән? Кем алган аларның исәбен? Шуларга тагын берәүнең ачы яшьләре кушыла икән, аннан ни үзгәрә?

Хатын тирә-ягын күздән кичерде. Нык ихаталар эчендә, түбәләре хикмәт сырлап ясалган биек капкалар артында, шифер астында, челтәрле кәрнизләр, иркен верандалары белән көязләнеп утырган йортларны, авыл очындагы озын ак ферма биналарын, очарга әзерләнгән зур-зур ракеталардай, борыннарын болытларга төбәп баскан силос манараларын күрде. Бу йортларда, бу биналар тирәсендә җиргә нык-нык басып, ашаганда колагы селкенә һәм эшләгәндә йөрәге җилкенә торган кешеләр яши, алар тагын да шәбрәк өйләр салу, тагын да матуррак киенү, тагын да күбрәк рәхәтләр күрү турында уйлыйлар. Аяк астында җирнең ныклыгын тоймый башлаганнар өчен, йөрәге нечкә җепкә эленеп торгандай көч-хәл тибә башлаганнар өчен, сызланудан сыгылып төшкәннәр өчен, әҗәл белән йөзгә-йөз очрашканнар өчен әнә шул иске, шомлы бина... Кинәт хатынның зиһене ачылып киткәндәй булды. «Ничек мин бу хәлгә төшдем икән? — дип уйлады ул.— Нигә мин бөтен халыкка, «Без нишләп болай ваемсыз, нигә без гомеребезнең иң авыр минутлары киләсен уйламыйбыз, нигә аны кайгыртмыйбыз?!» — дип кычкырмадым икән? Ни өчен мин: «Җанда гайрәт, тәндә көч барда тегенди-мондый җитмәүчелеккә дә түзеп була, кеше кулларына калганда ниләр күрәсебезне уйлыйк!» — димәдем икән?»

Ә бина әле нык тора, аны кузгатып та, үзгәртеп тә булмас кебек,

гүяки аның тирәсендә вакыт үзе туктап калган, баш өстенә ишелердәй булып салынган болытлар да, үзәккә үтеп сибелгән яңгыр да үтмәскә килгән сыман иде...



## 2

Ләкин гомер агышы туктамый, үтмәстәй тоелган җил-яңгырлар да үтә, дөнья үзгәреп тора.

Ул елның маенда күк йөзен атналар буе каплап торган салынкы болытлар да, вакыт җиткәч, таралды, үз нәүбәтендә эссе җәй, иртә кыраулы көз килде. Аннан соң да бер ел узып, көзге болытлар янә яшь коярга кереште.

Иртән күзен ачуга Давыт: «Тагын, — дип уйлады. — Һаман туктамаган, коюын белә». Парланган тәрәзәләр болай да сүрән көн яктысын саран үткәрә, өй кыегыннан тигезле-тигезсез коелган тамчылар гүяки тыштагы салкын күләвеккә түгел, бәгырьгә тама иде.

Аш бүлмәсеннән Фазиләнең савыт-саба шалтыратканы ишетелде. Әнә ул ишектән башын сузып:

— Давыт, ишетәсеңме соң? — дип сорады. — Телефон шылтырый бит, ник алмыйсың?

Әйе шул, шылтырый, тик Давытның тыңлыйсы килми, рәтле сүз әйтмәсләрен күңеле сизә. Әмма кемдер аны бик кирәксенә, ахры, ямьсез зыңгылдау колакны ертып, озак-озак кабатлана. Тыңламый котылып булмас, мөгаен.

— Алло!

Директорның секретаре икән.

— Давыт абый, хәерле иртә! — Тавышы дәртле, сөенче әйтә диярсең. Яшең унҗидедә чакта көзге яңгыр гына кәефне җимерә алмый шул. — Телефонограмма сезгә!

— Йә, укып күрсәт әле, туйга чакыралармы әллә?

— Ю-ук, туйга түгел! Нәрсәгә икәнен әйтмәгәннәр. «Урман хуҗалыгының баш инженеры иптәш Гаяровны сәгать тугызга иптәш Нурханова...»

Бу урында кыз тотлыгып калды. Аннары, гаҗәпләнгәндәй:

— «Үтенеп» дип язылган монда, — диде. — Нурханова сезне үтенеп чакыра!

Телефонограммаларда «үтенеп» сүзен гомер очратмаган Давыт та сәерсенеп куйды.

— Кем ул Нурханова? — дип сорады.

— Соң, шул теге... райбашкарма председателенең яңа урынбасарыдыр инде! — диде кыз. — Әле күптән түгел генә куелган!

Ә, әйе бит әле, берничә ай элек Гайнуллинны Казанга, министрлыкка эшкә алдылар. Аның урынына хатын-кызны куйганнар иде, моңарчы эш төшмәгәч, онытылып киткән.

Пычрак ярып районга барып йөрисе килми иде. Телефоннан гына сөйләшеп алсаң ярамас микән? Әмма Давыт бу уеннан шундук кире кайтты. Беренче юлында бармый калу ярамас. Җитмәсә, башкармада аның үз йомышы да бар иде.

Иренең китәргә җыенганын күргәч, Фазиләнең чырае каралып чыкты:

— Синсез тора алмыйлармы әллә? Инде бер буш көнең булыр, өйне карарсың, дигән идем. Шимбә ләбаса бүген! Тәрәзә бикләре каккан беткән әнә, югач, рәтләп ябып булмады. Абзар ишеген дә карыйсы бар.

Өстәл янында чәй эчеп утырган Давыт дәшмәде, ишек кырыенда сыерга он суы болгатып азапланган хатынының аркасына, кыршыл-

ган бәрхет жакетына гаеп эзләп карады. Икесе дә озын буйлы, озынчарак йөзле, кара чәчле булгангамы, әллә холык-фигыльләрен дә охшатыпмы, аларны кайчакта абыйлы-сеңелле дип беләләр, танышлары да, бигрәк пар килгәнсез, ничек шулай табыштыгыз, дип, кызыгып карый иде. Ләкин менә мондый көннәрне үзенә охшаган хатынының түгел, үз-үзенне күрәсең килмәгән чаклар була. Бигрәк тә каршыңда кирле-мырлы сүз сөйләшеп торсалар...

Фазилә борылып карамады, әмма иренең уйларын аркасы белән үк тоеп торган икән. Чиләген күтәреп ишектән чыгып киткәндә:

— Бар, бар, юлда батып ятканда, әйткән ие бу, диярсең әле, — диде.

Давыт каты пешкән йомыркага төелә язды: «Ир өйрәтеп маташкан була тагын, йомырка пешерә белмәгән башы белән!»

Башка вакытта, «Газиг»ын кабызып юлга чыккач, аның күңеле тынычлана, моторның тигез гөрелтесе гүяки йөрәк тибешен дә бер жайга сала торган иде. Әмма бүген алай булмады. Әллә томан, әллә вак яңгыр пәрдәсе астында каралып яткан шәрә басулар, соры-коңгырт яфракларын инде коеп бетерә язган, шәбәреп мескен кыяфәткә кергән каенлыклар, алгы пыялага туктаусыз чәчрәп сыланган сыек лай әчтәге ачуны отыры кабарта гына барды. «Кайчаннан бирле коя бит инде, очы-кырые һич күренми!» Соңгы атнаның көннәре дә, соры су тулы юл чокырлары кебек, бертөсле, ямьсез, әчпошыргыч тоела иде.

Шушы соры, салкын, юеш, күңелне изә торган сәгатьләрдә аның бөтен яшәешен үзгәртәчәк, язмышын хәл итәчәк вакыйгаларның яралганын, соңыннан үзенең дә нәкъ шушы иртәне күп тапкырлар сагынып һәм сызланып искә алачагын белми иде әле ул.

Хәер, безнең кайсыбыз гына киләчәген алдан күрә ала соң? Күпчелек очракта без, бу дөньяда һәммә нәрсә кабатланып тора, кичә баеган кояш бүген иртән тагын чыга, сүрелгән ай, атна үтүгә, яңадан туа, көз артыннан кыш килә, аннары яз җитә, дип уйлыйбыз. Ә бит бүгенге таң кичәгечә түгел, өченче көндәгечә дә түгел, бәлки өр-яңача ата, җилләр бүтәнчә исә, кошлар башкача сайрый. Шәфәкъ нурлары да, офык сызыгы артыннан, моңарчы күрелмәгән төсләр бөркеп, өянке-тирәк ябалдашларын төсләргә маналар.

Безнең баш очыннан бер мәртәбә агылып узган болытлар беркайчан да кире әйләнеп кайтмыйлар.

Тик безнең күзләргә — җетелек, күңелләргә сизгерлек җитенкерәми шул, таң балкышларын һәм болыт агышларын төсмерләре белән аерып күрә белмибез, язмышыбыздагы борылышларны башында сизми калуыбыз да шуннан киләдер, мөгаен.

Районбашкарманың аксыл-сарыга буялган ике катлы бинасы янына килеп туктагач, Давыт, машинадан төшеп, кызган йөзен күтәреп, бераз вакыт салкын яңгырга куеп торды, тынычланырга, суынырга тырышты. Җитәкче янына кызуланып, кәефсезләнеп барып керү беркайчан да хәерлегә булмый. Ишектән бераз читтәрәк ләмле су тулы озынча калай савыт тора иде. Давыт андагы озын саплы пумала белән ботинкаларын озаклап юды.

Яңа җитәкче янына, бигрәк тә хатын-кыз каршына барасын уйлап, урманчылар формасын кигән иде ул. Әчкә кереп, гардеробка шинеленфуражкасын элеп куйгач, зур көзге каршына басып, кителен тарткалады, бөтен кыяфәтен җентекләп күздән чигерде.

Форма килешә аңа, пөхтә-ыспай, үзенә таманлап махсус тегелгән. Буй-сын да, аллага шөкер, халык арасында югалып кала торган түгел, һәркайда диярлек бер башка биегәеп тора ул — метр да туксан сантиметр! Куе кара чәче артык шома да, килешсез тырпаючан да түгел, жай гына дулкынланып ятып тора. Йөз ак, күзләр тере.

Урынбасарның бүлмәсе икенче катта, коридорның аргы башында үк иде. Ике яктан тезелеп киткән бертөсле ишекләр турыннан узганда,

Давыт ирексездән чыраен сытты: пычкы чүбеннән укмаштырылган бу ишекләрнең өсте фанер булып, имән тактага охшатып майлы буяу белән буялган иде. Мондый ясалмалыкны күңеле кабул итмәгән Давытка бирелдәге бертөсле бүлмәләрдә утырган кешеләрдә дә шундый ук ясалмалык бардыр сыман тоелды.

Аргы баштагы ишек тә — башкаларның игезәк сыңары. Әгәр ул бикле булып чыкса, Давыт сөенәчәк кенә иде. Әмма аның бу яшерен өмете акланмады: йозакта бер бәйләм ачкыч эленеп тора, димәк, хуҗа урынында. Бүлмәнең элекке хуҗасы Гайнуллинны исенә төшереп, Давыт көрсенеп куйды: ул, каршы килеп, ике куллап исәнләшә, өстәл аша түгел, янәшә утырып, ачык итеп сөйләшә торган иде. Дөнья рәтен белә Гайнуллин, ә яши белгән кешегә урман кирәк — ял иткәндә дә, тормыш көткәндә дә...

Эчтән яңгыравык нечкә тавыш ишетелде. Давыт ишекне ачканчы, аңа кадакланган яңа язуны укыды: «Нурханова Фидая Госмановна». Ят исем, телгә дә бик үк җайлы түгел сыман. Давыт, көрсенеп, эчкә атлады.

Иң беренче күзгә ташланганы гөлләр булды. Почмак бүлмә булганга, тәрәзәләр ике якка карый: аларның төпләре тулы бүрек-бүрек кызыл чәчкә аткан яраннар, тамчы гөлләр; мондагы элекке ирләрчә кырыслыкка күнеккән Давытның күзе камашкандай булды.

Түр өстәл артында аягөсте басып, аңа таба уң кулын сузган хатынны күргәч, ул тагын да ныграк сәерсенеп китте. Мондый кабинетларга, дәрәҗәле өстәлләр артына кереп утырган хатыннар, гадәттә, ир кыяфәтлерәк, тупасрак чырайлы һәм бәдәнле була, алар, бу охшашлыкны тагын да көчәйтергә теләгәндәй, коңгырт яисә зәңгәр костюм киеп йөри. Ә бу исә челтәрле изүе күкрәкләренә сыланып торган, нечкә билен кысып алган ачык көрән төстәге бәйләгән күлмәктән иде. Анысы бер хәл, иң гаҗәбе шунда — бу хатын чибәр, чынлап торып бик чибәр иде. Дөрес, Давытның исенә төште, район җыелышларында бу хатынның күзгә чалынып киткәләгәне бар иде, ләкин ул чакта аңа текәлеп каралмаган икән. Хәзер менә, якын ук килгәч, аның чибәрлеге гаҗәпкә калдыра, караган саен карыйсыны китерә. Бөтен җире килешле: сул яктан кыеклап ачылган алтын-сары чәчләре дулкынланып иңнәренә төшкән, ак түгәрәк йөзе тулган ай кебек яктырып тора, зәңгәр күзләренең карашы үткен һәм уйчан, ә бераз эрерәк, әмма тигез ак тешләреннән, тулы иреннәреннән саф күңелле кешеләрдә була торган якты елмаю сирпелә иде.

Фамилияләрен әйтеп танышканда, Давыт каушавыннан аның кулын учында озаграк тотты бугай, нечкә, нык бармаклар кош баласы кебек тыпырчынып куйдылар. Давыт кызарынып чыкты.

Нурханова үз өстәленә терәп куелган өстәл кырыендагы тирән кәнәфигә ишарә ясады — утырырга тәкъдим итте. Давытның фикере чуалганын сизмәмешкә салышмады, гади генә итеп:

— Форма кигән кешене күргәч, үзем дә бераз каушап киттем әле, — дип елмайды. Күренеп тора, үзе ул тамчы да каушамаган, моны фәкать сүзне ипле башлап җибәрү өчен генә әйткән иде. Әмма Давыт бирешмәде, саламга тотынгандай, бу сүзне ялгап китте:

— Безнең эш хәрби хезмәткә тиң, — диде, — белмәгәннәр каушап төшсә дә гаҗәп түгел. Урман сакчыларына форма киемен заманында Петр Беренче керткән. Килегез безгә, бик шәп музеебыз бар, карап китәрсез.

Кәнәфигә утыргач, Давыт кинәт кечерәеп китте, үзенең башы өстәл артындагы биегрәк урындыкта утырган Нурханованың башы белән бертигез икәнен күрде, башкаларга өстән карарга күнеккәнгә, үзен җайсыз хис итте. Ләкин аягөсте басып сөйләшеп булмый бит инде! Ул аякларын сузып җибәргән иде, ботинкалаларының икенче якка ук сузылып чыкканын тойды. Нурханованың да шунда караганын

күреп, тезләрен өстәл аратасына бәреп, аякларын кире тартты. Каһәр суккыры, Гайнуллин заманында да шушы кәнәфидә утыра торган иде ләбаса, аягын нишләтә иде соң әле? Җитмәсә, бүлмә хуҗасына ян белән утырып, муенны борып сөйләшү дә шактый җайсыз икән!

Ә Нурханова аның көйсезлекләрен сизми дә кебек, тыныч кына, нечкә тавыш белән, үзенең инде урман хуҗалыгы музеенда булганын сөйли. Ул Баллыболын мәктәбендә директор булып эшләгән икән, урман хуҗалыгына укучы балаларны алып барган, андагы цехларны да караганнар, бизәкле кашыклар, савытларны ничек эшләгәннәрен күргәннәр, фанер цехында булганнар.

— Агач савыт-саба эшләү цехыгыз бик ошый безгә. Хәл кадәренчә ала идек без аларны. Мәктәп олимпиадаларында җиңеп чыккан балаларга бик матур бүләк бит.

Ә Давытның башында бер генә уй буталды: моңа миннән ни кирәк? Ул бит инде бу пычракта егерме чакрымнан Давытны үзенең кем булып эшләгәнен һәм урман хуҗалыгына ник барганын сөйләр өчен чакырып китермәгәндер. Араларны җайлау-майлау, Давытның күңелен йомшарту максаты белән сөйли ул боларны. Акыллы иржитәкче дә шулай итәр иде, син менә моны бир дә тегене эшлә, дип йомышын сөйләргә керешкәнче, бераз вакыт юк-бар сүз үрчетеп алыр иде.

Ләкин бу чибәр хатынның йомшак, нечкә тавыш белән ирләр сүзе сөйләп утыруын күңел кабул итәргә теләмәде. Урмандагы һәр кош үзенчә сайраган шикелле, адәм балалары да, кыяфәтләренә, утырган урыннарына, ниһаять, җенесләренә карап, үзләренчә сөйләшергә тиешләр. Һәм Давыт, сәерсенүен һәм ризасызлыгын яшерә алмыйча, күке булып кычкырган уткойрыкка тап булгандай, керфек тә какмый, Нурханованың йөзенә текәлде. Ярый ла ул үзе генә шулай сәер сайраса, ягъни сөйләсә! Бу кош үз тавышы белән сайрамый икән, аңа шулай ук үзеңә хас булмаганча итеп җавап бирергә кирәк микән инде? Әгәр бу хатын белән башка җирдә, әйтик, клубта, театрда, кунакта очрашсалар, Давыт белер иде ничек сайрарга, югалып кала торганнардан түгел! Ләкин урыны нинди бит! Шушындый җитди, рәсми урынга шушындый чибәр хатынны кертеп утыртырга кайсы түрәнең акыллы башы җитте икән? Хатын-кызны күтәраләр, имеш... Таптылар гадәт! Хәзер Давыт нишләргә тиеш инде менә? Иң яхшысы шушы минутта өстәл артыннан бу хатынны күтәреп кенә алу булыр иде дә бит.

Давыт буталчык уйларының очына чыга алмады, йөзенә салкын җил бәргәндәй, артка тайчанып куйды: Нурханованың ак йөзеннән, боз кыйпылчыкларына әверелгән зәңгәр күзләреннән котып салкыны бөркелгәндәй иде. Ай-һай, сизгер икән үзе дә. Давытның уйнак уйларын тоеп та алган! Озаграк шулай карап утырса, үпкәң шешәр, алла сакласын!

Хәер, Нурханованың араларны бөтенләй суытасы килми иде әле: ул, бераз җитдиләнеп, тәрәзә төбендәге гөлләргә карап торды, аннары, зур сүз башлаганын сиздереп, көрсенеп куйды, терсәкләрен өстәлгә терәп, кул бармакларын бер-берсенә аралаштырып кысты. Аның сул кулында, атсыз бармагында гади генә нечкә алтын балдак ялтырый иде.

— Сезнең белән киңәшәсе бар иде, — диде ул.

Давыт дәшмәде. «Киңәшәсе булгач, үзең генә килеп китсәң дә зыян булмас иде», — дип уйлады эченнән. Шундук үз сүзенә җавабын да тапты: анда барса, Давыт белән астан карап сөйләшергә туры киләчәк шул аңа.

— Суыклар башланганчы, Кармаш больницасының котельныен көйләп җибәрергә, инфекция бүлеге корпусының түбәсен ябарга кирәк иде, — дип дәвам итте Нурханова. Давыт тагын авыз ачмады.

Кайсыдыр авылдагы участок больницасына аның ни катнашы бар?

Нурханова аңа туп-туры текәлде дә:

— Утыз кубометр такта кирәк, — диде.

Тынлык урнашты. Алар бер-берсенең күзенә шактый озак туры карап тордылар. Ниһаять, Давыт авызын ачты:

— Такта кирәкмәгән кеше юктыр инде ул безнең районда, — дип, көлемсерәде. — Тик нигә аны миннән сорыйсы иттегез? Лесхоз директоры иптәш Мингалимовка кушыгыз гына. Район үз кулыгызда бит.

— Сөйләштем. Бирә алмыйм, ди. Көз. Ел ахырынача тәмамлыйсы төзелешләр күп. Һәр кубометр учетта. Ә бу төзелеш аның планына кертелмәгән.

— Планга кертмәгәнсез, учетка куймагансыз, хәзер инде мин такта урлап китерер дип өметләнәсезме әллә?

Нурханова, аның күзләренә туп-туры карап, өзеп-өзеп:

— Әйе, урлап китерерсез дип өметләнәм, — диде.

Давыт сызгырып җибәрүдән чак тыелып калды. Әйе-е, ишетмәсәң ишет! Ә ул, мондый югары урынга шыр тилеләрне утыртмыйлар, дип ышанып йөри иде моңарчы! Чибәрлек булгач, акыл гел кирәкми икән бит, менә, менеп утырган, хәзер инде Давытны әвәрә итмәкче! Юк инде, апакаем, барып чыкмас! Матур хатыннар күп ул дөньяда, ә Давыт үз-үзенә бер генә!

Ә Нурханова Кармаш больницасы хакында сөйли иде. Районның мәйданы зур, җитмәсә кыяр кебек озынга сузылган, бер башыннан икенче башына туксан биш чакрым. Ә район үзәге Суташ бер кырыйдарак. Уртада, Суташтан утыз чакрымдагы Кармашта «Ашыгыч ярдәм» үзәге ачу, хирургия бүлеге булдыру планлаштырылган. Бу планны тормышка ашыру район халкы өчен бик тә, бик тә мөһим...

Урынбасар сөйли бирде, сүзе Давытның бер колагыннан кереп, икенчесеннән чыга торды. Аның фәкать бер генә сорауга җавап аласы килә иде: моңарчы кара-каршы килеп, ике авыз да сүз сөйләшмәгән килеш, нишләп әле бу Нурханова нәкъ менә Давытка шундый четерекле үтенеч белән мөрәҗәгать итәргә булган?

Бу сорау кычкырып әйтелмәде, әмма урынбасар үзенең шактый озынга сузылган сүзен нәкъ менә шушы аңлату белән тәгаллде.

— Сез яшь кеше, тәвәккәл, уңган, алда торган эшләрнең иң мөһимен аерып ала беләсез. Районда күпме урманнар утыртуны оештырдыгыз. Урман хуҗалыгында күпме яңалык керттегез. Бизәкле савыт-саба цехын ачу да сезнең гайрәт белән эшләнде, диләр. Минемчә, больница торгызу эше дә сезне рухландырырга тиеш. Халык өчен кирәк бит, ә бәлки, агач кашыклардан кирәгрәктер дә әле...

Монысы авырткanrак җиргә тиде. Ул цех артыннан Давытка күп йөрергә, күп мәртәбәләр «агач кашык булмаса, тимере дә ярап тора әле, ашарга гына булсын» дигән сүзләрне ишетергә туры килде. Ә хәзер әнә район җитәкчеләре иркенләп мактаналар шул кашыклар белән!

«Ярый безгә, каткан тезгә буяулы кашык ясау да», — дип уйлады Давыт. Иң мөһимен сез күрерсез инде. Урыныгыз да югары, яшегез дә бездән өлкәнрәк күренә — утызга таба барасыз булса кирәк. Аннары килеп, больница кадәр больницаны тегеннән-моннан йолкыштырып, урлаштырып, коры тәвәккәллек белән генә төзеп була микән әле? Давытка калса, Кармаш үрендәге ул берничә бүлмәле корылманы, тирә-юнендәге сарай-келәтләре белән бергә, бульдозер китертеп, сыдыртып кына ташларга күптән вакыт иде инде. Дөрес, моннан ике-өч ел элек килгән баш врач Газимов, аның тирәсенә агачлар утырттырып, койма-капкаларын, тәрәзә яңакларын буятып куйды куюын. Аннан гына больница рәтләнәме?

Хәер, бу хакта сүз үрчетеп, вакыт уздыруда мәгънә юклыгы күренеп тора иде. Хатын-кыз, кая гына күтәрелсә дә, хатын-кыз

булып кала. Давыт үз-үзен кулга алган, кыюланган иде инде. Ул, кулларын җәеп, ясалма елмайды:

— Бөтенесен аңлыйбыз, Фидая... — каһәр, атасының исеме онытылып китте тагын!

— Госмановна, — дип анның исенә төшерде Нурханова.

— Әйе, Фидая Госмановна. Мөмкин булса, бөтенесен эшләр идек, җае бер дә күренми бит әле. Тора-торып берәр әмәле табылмасмы, истә тотарбыз!

Ләкин истә тотмаячагы, бусагадан чыгуга онытачагы көн кебек ачык иде.

— Безнең һич кичектереп булмый торган зур эшебез бар бит әле. Баллыболынның буасы кырына нарат утыртырга планлаштырылган иде. Үсентеләре дә кайтарылды, кешесе юк. Мәктәп балаларны бирми! Әллә нинди кире беткән директор утыра анда. Сезнең бер сүзегез җитә, әйтегез әле шуңа!

Нурханова, карашын түбән төшереп, өстәлдәге кәгазьләргә төбәлде. Озын алтынсу керфекләреннән ак яңагына күләгә төшкәндәй булды, киң, шома маңгаенда уйлану чагылды. Бу рәвешле, нәкъ кирәкле минутта бөтен дикъкатьне бер ноктага туплап, бер мәсьәлә турында тирәннән уйлану — ир-егетләрнең иң төплеләренә хас сыйфат. Хатын-кыз, кагыйдә буларак, теленә беренче килгәнне әйтеп сала да, соңыннан кайтып уйлагач, үкенә. Әмма ирләргә хас булганча төптән уйлану Нурханованың мөлаемлыгын киметмәде, тик аны серлерәк, аңлаешсызрак итте, ерагайтты кебек. Давытның күңеле йомшый башлаган иде инде, Нурханова башын күтәрде дә:

— Хәзергә булмый, — диде. — Балалар бәрәңгедә.

— Менә күрдегезме? — диде Давыт аягөсте басып һәм, бу юлы инде, гадәтенчә, күзләрен кыса төшеп, өстән аска карады. — Беребез дә ходай тәгалә түгел, кодрәтебез чикләнгән!

Саубуллашканда икесе дә көчәнеп диярлек елмайдылар, ләкин бер-берсенә ошамаганнарын, ризасыз калганнарын һәм киләчәктә бер-берсеннән читтәрәк торырга тырышачакларын икесе дә аңлыйлар иде.

Алай да, ишекне ачып, бусаганы атлар алдыннан, Давыт артына борылып карады. Нурханова, урыныннан торып, тәрәзә янына барып баскан иде инде. Ул, Давытның карашын тоеп, бөдрәләрен сирпеп башын борды һәм боздай салкын күз карашы белән ишекне тышкы ягыннан ябарга әмер биргәндәй итте.

«Әйе-е, — дип уйлады Давыт, коридор буйлап кире киткәндә. — һәркемнең, һәрнәрсәнең үз урыны бар. Ташлы тауда тал үсми, сазламыкта чыршы-нарат мантымый. Биеп торган чаптарларга авыр йөк тарттырмыйлар, бөдрә йонлы әнчекләрне бүрегә өстермиләр. Иптәш Нурханова кебек чибәркәйләрнең дә урыны җитәкче өстәле артында түгел. Әнә, культура йорты урам аша гына! Шунда баш булып алсын иде дә, җырчы-биючеләрне өндәсен иде һәртөрле тәвәккәллекләргә!

Зиһене тәмам таралып төшеп килгән Давыт баскыч борылышында берәүнең кочагына барып кергәнен дә сизми калды. Районның төзүмонтаж идарәсе начальнигы Тавис Мирхуҗин икән. Бик яхшы таныш кеше, чөнки урманда еш була, яши белә! Куе кара кашлары җыерылган, киң борыны салынган чагын күрмәссең. Бу юлы да әнә, болай да кысык кара күзләрен ярык кына калдырып, киң чыраеннан май саркыгандай итеп, шук һәм хәйләкәр елмаеп тора.

— Багана, багана, баскычларда аунама! — ди көйләп. — Кайсы хәерсез начальник өнсез итте?

— Ә, исәнме, син дә килеп ятасыңмыни? — диде Давыт. Аның кемдә булганын әйтәсе килми иде.

— Әллә үзе иртәдән шулай явызланамы?— Мирхуҗинның «үзе»

дигәне райбашкарма рәисе Искәндәрев иде. Давыт сорауга җавап бирми котылып булмасын аңлады.

— Аннан түгел...— диде.— Урынбасары белән сөйләштек.

— Ә-ә, Нурхановада булдыңмыни? Фидая Госмановнада? Син дә ул сукмакны таптый башладыңмыни инде?— Мирхуҗин отыры шукланды.

— Үзе чакырып алды. Агач материаллар кирәк икән.

— Булдымы соң?— Бусы инде хәйләкәр үчекләү аралаш әйтелде.

— Нәрсә?— Давыт аңламамышка салынды.

— Агач материалын бирдеңме соң?

— Бездә каян булсын ул? Бөтен төзү материалы сезнең кулда бит.— Давыт Мирхуҗинны әйләнебрәк үтмәкче иде, тегe, уңга бер адым атлап, каршысына ук басты, башын артка ташлап, аның йөзендәге үзгәрешләрне күзәтте.

— Тәҗрибәсезлеге белән чакыргандыр инде мине, эш рәтен белмәгәнгә...

— Алай димә!— Мирхуҗин иягeн чөеп куйды.— Булыр сиңа тәҗрибәсез! Белә ул егетләрнең кайсын чакырырга! Бөтенесе үз кулында икәнен аңлый. Бик нык үсеп китте бит, бик кинәттән зур кеше булды. Уңган хатыннар шулай инде безнең заманда, ирдән арынуга, мантып-үсеп китәләр...

Мирхуҗинга чын күңелдән кызыгып карады Давыт. Рәхәт тә яши инде кайбер кешеләр бу дөньяда! Ни булса да күңелен төшерми, бөтен көйсезлекләргә көлеп кенә карый, атна буе койган яңгыр да кәефен кырмаган, тулган ай кебек балкып тора. Менә хәзер дә, аны күргәч, сулыш иркенәеп китте, әле генә булган күңелсез сөйләшү бер мәзәк сыман гына тоела башлады. Давытның да иреннәре ихтыярсыздан җәелеп килә, ул инде шунда ук Нурханова белән булган әңгәмәне көлкегә сабыштырып сөйләп тә бирмәкче иде, тик булдерделәр: аскы катның коридорында шау-шу ишетелде, кемнәрдер дөбер-дөбер баскычтан менә башлады. Давыт белән Мирхуҗин, стенага елышыбрак, аларга юл бирделәр. Йөзләре агарынган, талчыккан кыяфәтле биш-алты ир-атның һәм кыска соры пальтосы өстеннән озын кызыл шарф очларын чыгарып салган бер хатын-кызның моңарчы районда күзгә-башка чалынганы юк иде. Киемнәре дә авыл җире өчен ятышлы түгел: замша һәм күн курткалар, джинсы чалбарлар, җитмәсә, ирләрнең икесе сакал җибәргән иде. Алар Мирхуҗиннан Нурханова бүлмәсен сорадылар.

— Күрдеңме?— дип каш сикертте Мирхуҗин Давытка, тегеләр узып киткәч.— Озакламый ул Нурхановага коридор буйлап чират тезелеп торачак әле! Минем юлга аркылы төште бит болар. Соңрак керергә туры килер инде.

Алар сөйләшә-сөйләшә ишектән чыкканда райбашкарма каршына зәңгәр «Жигули» килеп туктады.

— Кара, Баллыболын алашасы килеп ята! — диде Мирхуҗин, елмаю аша пошаман белән.— Әләктерә күрмәсен тагын! Берәр нәрсә сорый башласа, котылам димә!

Һәм, зәңгәр «Жигули» ны ерактанрак әйләнергә тырышып, шыпан-шыпан урамның теге ягына юнәлде. «Газиг»ына утырды да, тиз генә кабызып, китеп тә барды.

«Жигули»ның ишеге ачылып, аннан кырык яшьләрдәге таза гәүдәле бер хатын җайсыз гына хәрәкәт белән килеп чыкты. Бу шул үзе — ирләр үзара сөйләшкәндә «Баллыболын алашасы» дип телгә алынган, «Үзәк» колхозы председателе Ниса Таштимерова иде.

Таштимерова баш кагып кына Давытның сәламен алды да, аңа аркасы белән борылып, аяк киемен юа торган сулы улакка юнәлде. Аркасыннан караганда аны, чыннан да, ирләрдән аерырлык түгел иде: озын кунычлы резин итек кигән аяклар җиргә тезләрен нык

аерып баса, калын кара плащ астында киң җилкәләр уйнаклап тора, кара берет читеннән кыска киселгән чәч очлары гына тырпаеп күренә.

Таштимерова районга гына машина белән килә, авыл арасында ат белән йөри, чыбыркысын кулыннан төшерми, диләр. Ул пәһлеван ирләргә хас калын тавыш белән, командирларча каты итеп сөйләшә, кызып киткән чакларында кире беткәннәргә чыбыркы белән тамызып алырга да күп сорамый, имеш. Бер мәсьәләдә дә ирләрдән калышмаска тырыша, имеш. Таштимерова. Шулай берчак мәҗлестә бәхәсләшеп, бер стакан аракыны тын да алмый эчеп бетергән, дип сөйлиләр. Ничек эчкән диген әле! Ике кулын аркасына чалыштырып куйган, мөлдерәмә тулы стаканны тешләп күтәргән һәм шул килеш чөмергән! Аракысы тегенди-мондый гына түгел, «Посольский» булган, ди.

Моннан алты-җиде ел элек, председатель булып өченчеме-дүртенчеме ел эшләгән чорында, җае чыккан саен мәҗлес кору модада чакта, егетлеген исбат итү өчен кыланган ул моны. Һәм, чыннан да, телгә кереп калган бу «егетлек»! Аны еллар аша үтеп, Давыт кебек яшь кадрларга да килеп ирешә менә. Ирләрнең төрлесе Таштимерова турында төрлечә сөйли: бар сукрanучысы, бар сокланучысы, әмма һәммәсе аны гайре табигый күренеш сыманрак кабул итәләр, шул ук вакытта зур хуҗалык белән җитәкчелек итәргә алынган хатын-кыз шундый булырга тиештер, башкача мөмкин түгелдер, дип исәплиләр.

Әйтик, бүгенге көндә Давыттан такта таптыру уе башына килсә, ягъни шул ук Нурханова урынында булса, нишләр иде икән бу җитәкче? Беренчедән, Баллыбалын алашасы телефон аша, «үтенеп сорыйм», дип хәбәр салып маташмас иде. Аның кебекләр, гомумән, үтенә белми, таләп итә! Зәңгәр «Жигули»ен түбәсеннән сазга батырып, урман хуҗалыгы конторасының каршына килеп туктар иде дә ул, бүлмәгә кереп, гайрәтле тавыш белән:

— Давай, шул хәтле такта бир!— дияр иде.

Бирми кара син аңа, чыбыркысын сызгыртырга да күп сорамас. Кая керер тишек тапмассың, соңгысын биреп котылырсың!

Һәм ул хаклы да: бик тырышса, Давыт бераз такта тапмаслыкмыни? «Алай да Нурхановны тыңламыйча дөрес эшләдем,— дип уйлады ул,— үз урынына утырмаганын белеп торсын!»

Таштимерова, иелә төшеп, озын саплы пумала белән итек куныщын ышкый иде. Плащ итәге тырпаеп күтәрелгән, астан сызылып ап-ак чалтәр күренә. Эчке күлмәк итәге.

Давытка ул кинәт бик кызганыч булып тоелды. «Хатын-кыз хатын-кыз булып кала инде,— диде ул, көрсенеп,—ходай шулай яраткач, әллә кая китә алмый...»

### 3

Ә Нурханова, тәрәзә янына басып, гөл чәчәкләре аша урелеп, тышка, яфаклары тутык төсенә кергән, шәбәргән агачларга, ишегалдының юеш асфальтына, яссы кара түбәле гаражларга карап тора иде. Әнә, андагы киң итеп ачылган капкаларның берсеннән яшел «Газик» килеп чыкты, ишегалды уртасында туктады, аның ишеген ачып, кара мыеклы яшь егет күтәрелеп тәрәзәгә карады. Бу — Балкыш — Нурхановның шоферы иде. Нурханова аңа урам якка чыгарга ым какты.

Үзе авыр сулап куйды. Көне нинди бит, көне! Өстә — соры болыт юрганы, аста — кара боламыкка әверелгән басулар, уртада — теләсә нинди плащ аркылы дым булып саркып керә торган вак яңгыр. Инде икенче атнага сузылган үзгәрешсез күренеш. Йөзләрне сүрелдерә, кулдан эшне төшерә, күңелне изә торган мохит. Хәер, борынгы гадәтләрне искә төшереп, мунча ягып, бәлеш пешереп, самавыр

янында гәп корып утырсаң, көн болай ямьсез күренмәс иде. Тик заманы ул түгел. Фидаяның язмышы андый түгел. Аның гаме — халык гаме, ә халык кырда, бәрәңге алуда. Район җитәкчеләренең һәркайсы аерым колхозларга беркетелгән. Нурханова «Үзәк»кә барырга тиеш. Хәзер ул анда барыр, ләм ерып басу буйлап йөрер, кешеләрнең күңелен күтәрерлек сүзләр табарга тырышыр.

Ләкин ул гына да түгел әле: Нурханованың беркем кушмаган, ләкин үзе өчен иң мөһим дип санаган тагын бер эше бар. Кармаш участок больницасы котельные янына утыз тонналы кран китертеп, егерме дүрт метр озынлыктагы юан торбаны утыртып куярга кирәк. Бернинди оешма планга кертмәгән бу эшне иртәгә, ягъни якшәмбе көнне башкарып кую кулай. Бүтән көнне кранны бирмәячәкләр. Дөрес, тиешле оешма белән кранны китертү хакында сөйләшенгән, баш врач Газимовка кат-кат әйтелгән. Тик шулай да кешегә ышанып торырга ярамый, үзеңә тикшерергә кирәк. Юк аркасында зур эшләр туктап кала кайчакта. Торба утыртасы нигез тиешенчә эшләнгәнме? Кран торыр урын ныкмы? Тросы, ыргагы кирәк булыр, алары яраклымы?

«Минем дә, Газимовның да башы җитәрлек түгел моңа,— дип уйлады Нурханова.— Төзү-монтаж идарәсенә Мирхуҗинга сугылып чыгарга кирәк. Үзе барып карап кайтсын, йә булмаса, берәр ышанычлы кешесен җибәрсен. Менә хәзер, үзем белән үк алып барырга була».

Ул, телефонын алып, Мирхуҗинга шалтыратты. Секретарь кыз җавап бирде: «Кайдадыр шушы тирәдә йөри иде әле»,— диде.

Нурханова, юл уңаеннан сугылып чыгарга ниятләп, ишек янындагы элгечтән көн пальтосын алган иде, коридорда күп һәм тигезсез аяк тавышлары ишетеп, тынып калды. «Ходаем, миңа гына кермәсеннәр иде...» Ләкин теләге кабул булмады, күңеле белеп шомланган икән, адымнар якын ук килеп туктады, ишек шакыдылар.

— Керегез!

Ишек әкрен генә ачыла башлады, анда зур авызлы киң чырай пәйда булды, күшеккән калын иреннәр ачылып, карлыккан тавыш:

— Фидая Госмановна биредәме?— дип сорады.

Аннары бу кешенең киң җилкәсе, нык бәдәне күренде, аның артыннан кыюсыз гына алты-җиде кеше килеп керде.

— Чакырылмаган кунаклар килде,— диде ир кеше елмаеп.— Казаннан без, рәссамнар, күргәзмә белән килдек. Сезнең белән алдан сөйләшү буенча.

Нурханова пальтосын кире чөйгә элде дә, кунакларга кул биреп, танышып чыкты.

— Мин җитәкче булам инде, Тәүзих Әхмәдуллин,— диде кырык яшьләр тирәсендәге киң чырайлы кеше. Килгәннәрнең күбесе яшькә аның чамасындарак, берсе чандыр гәүдәле, какча яңаклы, чал чәчле абзый, ә озын кызыл шарфын кыска пальтосы өстеннән чыгарып салган хатын-кыз арада иң яше, ул егерме бишләр тирәсендә иде.

— Рамилә,— диде ул, салкын, юеш бармакларын Фидаяның учына төртеп.

— Вакытсызрак килеп төштек бугай, гафу итегез инде,— диде Тәүзих.— Коя да коя. Билгеләнгән вакытка килеп булмады, шәһәрдәге бөтен транспортны авылларга бәрәңге алырга җибәрделәр. Менә кинәт кенә бер автобус бирделәр дә, форсатны ычкындырмаска булдык. Ашыгырга туры килде, сезгә шалтыратып әйтергә дә өлгермәдек.

Аның сүзләреннән Нурханова хәлне төшенә башлады. Күрәсең, районда Казан рәссамнарының күргәзмәсен уздыру хакында Гайнуллин белән килешү булгандыр. Әйтәсе дә юк, әйбәт эш, ләкин

иллә дә вакытсыз килеп төштеләр инде!

Алай да сер бирергә ярамый иде. Фидая кунакларга елмаеп, ачык йөз белән карады, стена янындагы урындыкларга утырырга тәкъдим итте.

— Матурлык белән очрашу беркайчан да вакытсыз булмый,— диде.— Хуш килдегез! Хәзер урнашырсыз, чәй хәстәрләрбез!

Ул телефонга тотынды. Ресторанга — табын әзерләсеннәр, кунакханәгә — урын кирәк. Кирәген кирәк, ләкин алар әйткәнче үк урын югын белеп тора Нурханова: кунак йорты читтән килгән шоферлар белән шыгрым тулы. Җаелмә ятаклар куярга, диваннарга урын җәяргә. Ә бу күгәргән чырайлы, зур күзле, кызыл шарфлы Рамиләне Нурханова үзенә генә алып кайтырга булды.

— Курыкмагыз, мин сезне кыерсытмам,— дип, үз итеп күз кысты.

Райбашкарманың культура бүлегенә һәм культура йортына — картиналарны автобустан алып кертеп куйсыннар, әләргә урын җайласыннар, бауларын, кадакларын барласыннар... Үзе телефоннан сөйләште Фидая, үзе килгәннәрне күзәтте. Шактый йончыган, күшеккәннәр, чал чәчле абзый йөткергәләп тә куя... Авырып ятмасыннар тагын, монда килеп, артык мәшәкать ясап... Фидая тагын гостиницаны алды: кечкә кайнар чәй, мәтрүшкә, сөт... Алдан кайгырту арзангарак төшә.

Кунакларны, хөрмәт йөзеннән, чәйгә үзе алып керергә булды. Балкыш машинасын ишек төбендәге чиста асфальт кырыена ук китереп терәгән — хуҗасының матур итекләре пычранмасын дию инде. Шоферлар озак-озак көтәргә өйрәнгән халык, китабын алган да, гамьсез генә укып утыра.

Барасы юл ерак түгел, олы урамга чыгасы да чак кына әчкәрәк кирәсе. Ләкин шул «чак кына» дигәне — тоташ саз. Фидая Рамилә белән чал чәчле абзыйга үз машинасына утырырга тәкъдим итте, башкалар үзләрен алып килгән автобуска утырдылар.

Ресторан залының бер як стенасы тоташ тәрәзә диярлек, биек, иркен, якты. Ләкин шыксыз тоела, чөнки салкын. Хәзерге вакытта бина төзегәндә иңгә-буйга, биеклеккә киң җәелергә тырышалар, пыяланы да кызганмыйлар. Ә менә андый залларны ничек җылытып бетерергә — анысын уйлаган кеше юк.

Зур залның түрендә берничә өстәлне бергә кушып әзерләгән табында, шул хакта сөйләшеп алдылар. Стеналарга майлы буяу белән сүрәтләр ясалган — калфаклы кызлар, баһадир егетләр, башаклар, тракторлар... Рамилә күзләрен зур ачып, аларны җентекләп карады, тулы ирен читләрендә канәгатьсезлек чагылып узгандай булды.

— Ошамыймы әллә?— дип сорады аңа каршы утырган Нурханова.

— Ну, ничек дип әйтим...— Рамилә килү белән хуҗаларның әйберсен хурларга кыенсына иде.— Дәүләт премиясенә үк тәкъдим итәрлек димәс идем...

Башкалар пырхылдашып куйдылар.

— Ә без риза,— диде Фидая, барысына да яхшы ишелтелсен өчен кычкыра төшеп.— Безгә матур тоела, чөнки аннан яхшысын сирәк күрәбез. Зәвыгыбыз шундый. Зәвыкны бит аны тәрбияләргә кирәк. Яхшы әсәрләр белән.

— Шуны уйлап килдек бит инде,— диде Әхмәдуллин өстәлнең аргы башыннан.— Шуңа тырышып йөрү.

— Гомер эченә бер килү — нәрсә ул? Зәвыкны аны даими тәрбияләсәң генә...

— Ничек — даими?— дип сорады Рамилә.

— Үзегезне монда мәҗбүри алып калмабыз, курыкмагыз,— ди-

де Фидая, көлеп.— Әшегез халык күз алдында торсын иде.
— Ну... без... мин сезгә кайбер картиналарымны бүләк итә алам...— диде Рамилә.
Нурханова аның беркатлылыгыннан рәхәтләнеп көлде.
— Ә без бушка алмыйбыз, түләп кенә. Байлыгыбыз җитәрлек. Яңа төзелешләрне бизәргә ярдәм итегез безгә!
— Нинди төзелешләрне?
— Менә хәзер участок больницасы салына. Әгәр шуның стеналары чын зәвык белән бизәлсә, ә? Бөтен район халкына яхшылык булыр иде. Анда бармаган кеше сирәк, килгәне берсе озаклап чиратта утыра.
— Ансыз булмый инде-е,— дип сузды өлкән рәссам.
— Андагы рәсемнәрне кешеләр ашыкмыйча, иркенләп, теләгәнчә, рәхәтләнеп, кат-кат карый ала. Шулай бит?
Рамилә эчә торган чәен, тәмләп ашый башлаган чәкчәген онытып, керфек тә какмый Нурханованың йөзенә текәлде: янәсе, чынлап сөйлиме, әллә көлкегә калдырмакчымы? Больницаны зәвык тәрбияләү урыны итәргә маташу — бу ни дигән сүз?
— Шаярта да беләсез икән сез, Фидая Госмановна,— диде Әхмәдуллин, башын чайкап.— Больницада күргәзмә... Ха-ха-ха!.. Тарихта булганы юк андыйның!
— Ә без менә булдырыйк та, үзебезнең тарихка шундый яңалык язып куйыйк. Тарихка бит аңа, гомумән, яңалыклар гына языла, искелекләр түгел.— Нурханова моны бик җитди итеп әйтте.
— Ә чыннан да,— диде Рамилә, уйланып.— Больницаларда да кеше яши инде...
Барысының да дәррәү көлешкәнен күреп, Рамилә кызарынды, тотлыкты, сүзен төзәтергә азапланды:
— Кеше күп йөри, дигәнем... Әнә, сугыш турында киноларр күрсәтәләр, анда госпитальләрдә артистлар концерт куя торган булганнар бит! Барыбер сәнгать... Кешеләргә тизрәк терелергә ярдәм итkән...
Нурханова аңа бик җитди итеп, текәлеп карады:
— Димәк, сез больница бинасын бизәргә алынасыз?— диде.
Барысы да тынып калдылар. Рамилә каушап китте.
— Карарга кирәк башта,— диде.— Бинасы нинди дир бит.
— Алайса, мин сезгә бүген үк больницаны күрсәтергә алып барам!— диде Нурханова, тик шунда ук үзенең артыгырак кабаланганын сизеп алды: юлдан килгән кешене юлга алып чыгып китү ярыймы? Файдасы булырмы?
— Юк, иртәгә барырбыз,— дип төзәтте ул сүзен. Һәм, нокта куелганга санап, сүзне башкага күчерде.
— Без дә монда артта калмыйбыз, озакламый һәрьяклап шәһәрне куып җитәчәкбез, узып та китәрбез әле! Әйтик, менә бу ресторан шәһәрдәгедән киммени?
Барысы да бертавыштан сый-нигъмәтне мактарга керештеләр, коймак-чәкчәк бик тәмле, итне, каймакны әйткән дә юк...
— Хәзер юллар яхшы, якыннарыгызны алып, бер кич утырырга килеп китсәгез дә була,— диде Нурханова.
— Кичләрен чират тезелмиме соң ишек төбенә?
— Чираттан куркасы юк,— диде Нурханова.— Авыл халкы ресторанда утыруны гаеп саный, килгән-киткән тәзүчеләр, узгынчы шоферлар баштарак киләләр иде. Суташ кызларын сыйларга да дәртләре бар иде, тик караңгы төшкәч бу ишекнең бусагасын кем атлап кергәнгә хәтле бөтен район халкы диярлек белеп тора, айлар буе сүз йөри. Кызларны чакырып булмагач, егетләр дә кызык тапмый башлады, кичләрен буш тора бу зал, көндезләрен гади ашханә кебек. «Ресторан» дигәннән ишеге өстенә кадакланган язу гына калды.

— Әйе, монда аквариумда утыргандай шул,— диде Тәүзих, тәрәзәдән урам якка карап.— Бигрәк тә ут яктысында.

— Алайса, ник төзегәннәр соң аны?— дип сорады Рамилә, гаҗәпләнеп.— Башка төзер бина булмагандыр,— дип үз-үзенә җавап бирде аннары.

Ирләр тагын елмаештылар. Алар, күрәсең, үз араларындагы бу яшь хатынны сабый чутында йөртәләр иде.

Нурханова җитди итеп әйтте:

— Мин үзем дә шул сорауга җавап эзлим, таба алганым юк әле.— Аннары бу хакта сүзне туктатып:

— Мин сезне хәзер өйгә кайтарып куям,— диде.— Ял итә торырсыз. Өйдә хәзер беркем дә юк. Алтыдан соң минем каенанам кызымны бакчадан кайтарып куя. Аңарчы үзем дә кайтып җитәрмен әле.

## 4

Шәһәр кызы Рамилә авылда сирәк була, шунлыктан тирә-юньдәге һәрнәрсә анда зур кызыксыну уята, гаҗәпләндерә иде. Район үзәге Суташтан Кармаш авылына илтә торган утыз чакрымлык юл аңа бик озын булып тоелды. «Газик» машинасының арткы утыргычыннан алга таба муенын сузып, буразналар белән сырланган кара басуларны, томан өртелгән ямансу агачлыкларны, олы юлдан читтәрәк утырган, күзге моңсулыкка уралган авылларны бөтен төсмерләре белән күңеленә сеңдереп куярга тырышкандай, күзләрен зур ачып күзәтеп барды.

Анда-санда тракторлар, Рамилә моңарчы күрмәгән машиналар күзгә чалынып кала, алар тирәсендәге кешеләр хәрәкәтсез, күшеккән, көчсез, хәтта кызганыч булып тоела иде.

— Бәрәңгене алып бетереп булмый бит әле,— диде алгы утыргычтагы Нурханова.— Гаҗизләндек инде. Кинәт суытып җибәрүе бар, аннары җылытса да, өшегән балчыктан алып булмаячак!

Ниһаять, «Газик» чайкала-чайкала, олы юлдан төште дә зур гына авыл урамына кереп, дыңгырдый, моторын эчләрне актарырдай улата башлады. Олы урамнан шактый баргач, сөзәк үргә таба күтәрелгән ян урамга борылдылар. Урамның ике ягына икешәр рәт итеп тупыл утыртылган, машина аллеядан барган кебек тоела, юл да монда төзегрәк иде. Бик матур, уңайлы берәр җиргә илтергә тиеш кебек иде мондый юл.

Чыннан да, урам кыска гына икән: машина төзек койма белән әйләндереп алынган ихата янына килеп туктады. Капка өстенә эре, матур итеп, зәңгәргә сары белән «Кармаш участок больницасы» дип язылган иде. Ихатадан читтә дә вак-төяк корылмалар, өйләр күренгәли. Рамилә гаҗәпләнеп капка артындагы бүрәнә йортка карады. Бик борынгы булырга тиеш, бүрәнәләре нык каралган. Дөрес, төзек үзе, янтаймаган. Элекке заманда алпавытлар мондый йортларны ул заман өчен биек, нык итеп торгызганнар. Әчендә ким дигәндә унлап бүлмәсе бардыр. Ләкин... больницасы кая соң?

Рамилә, борылып, Нурхановадан шуны сорамакчы иде, ләкин председатель урынбасарын машинадан төшүгә эләктереп алдылар. Ак халаты өстеннән плащ кия-кия бина ишегеннән кечерәк кенә, әмма нык бәдәнле, сары чәчле бер ир-ат килеп чыкты. Мондый кешеләр тиз картаймый, аңарга утызны да, кырыкны да биреп була. Аның артыннан ак халат, ак башлык кигән,— медсестрамы, врачмы — утыз бишләр тирәсендәге, сипкелле, мөлаем йөзе борчулы бер хатын-кыз күренде. Алар исәнме-саумы диделәрме, юкмы, кызып-кызып үз сүзләрен сөйли башладылар:

— Килделәр килүен,— диде ир кеше Нурхановага.— Тик кузга-

та алмыйлар әле, майлыйлар да җайлыйлар, ә миңа авыруны карарга туры килде.

— Беләм мин аларның нинди май өмет иткәнен!— диде сипкелле хатын, күк күзләреннән ут чәчеп.— Булнис янына килгән шабашникның борын тишекләре үгез танавыдай киңәйгән була, спирт исен аулый!

— Анысы шулай инде,— дип, кыенсынып кына аның сүзен җөпләгәндәй итте ир кеше. Ул әкрен, сабыр гына, йомшак тавыш белән сөйли, теге хатынга каршы да төшми, аны бик үк хупламый да кебек иде.— Ял көнне эш кузгатканда запассыз булмый да бит, алдан хәстәрен күрә алмадык. Син, Гөлфия, артык кызма, тәртибе шул аның, бездән генә калмаган!

— Шул-шул менә, алар тирәсендә: «Әйдәгез, егетләр, әйдәгез!»— дип, шешә болгап йөгерергә кирәк. Шунда алар торбаңны гына түгел, булнисеңне күтәреп күк гөмбәзенә элеп куялар. Юк инде, бездән андыйны өмет итмәгез!— диде Гөлфия бу юлы Нурхановага туп-туры, керфек тә какмый текәлеп.— Син дә кушма, Фидая, ярамаган эшне, Билал да мәҗбүр итмәсен. Ирем дип тә тормыйм, начальнигым дип тә, күзләренә тамчысын чалындырмыйм. Сейфка бикләп куйдым бөтен запасны, җанымны алсалар да бирмим ачкычны!

Ул ике кулын халат кесәләренә батырды, ак тукыма аша йодрыклар шәйләнде.

Боларны читтән күзәтеп торган Рамилә бөтенесен шундук аңлады — иҗат кешесе буларак, ул башкаларның узара мөнәсәбәтендәге нечкәлекләрне тиз эләктереп ала иде. Билал дигәне — баш врач, Гөлфиясе — аның хатыны һәм өлкән медсестра, сүз нининдер шабашниклардан нидер эшләтү хакында бара.

Төркем, сөйләшә-гәпләшә бинаны әйләнеп, ишегалдына таба юнәлде. Рамилә, арттарак калып, аларга иярде.

Ихата артыннан коймалар алынган, анда төзелеш башланган икән. Иркен ихатаның буеннан-буена сузып, биек итеп, бетоннан нигез салып куелган, аның артында кечерәк ак кирпеч бина калкып тора. Баш врач белән медсестраның кәефен кырган кранчылар шуның артында икән. Анда утыз метрлап озынлыктагы, биниһая юан тутыккан торба ята, янында биек кран, аның сары кабинасы эчендә икәү утыра, җирдән тагын икәү башларын күтәреп алар белән сөйләшеп тора иде. Алар якынаеп килүчеләргә бер дә искитмәгән кыяфәт белән карадылар. Нишләр икән Нурханова? Тик торганнары вакытны әрәм иткәннәре өчен тиргәргә керешерме, әллә ясалма елмаеп, кызыл сүзләр белән дәртләндерергә маташырмы? Рамилә өчен бу кызык иде. Ләкин ул Нурханованың тегеләр белән ни сөйләшкәнен ишетми дә калды, чөнки Рамилә якын килеп җиткәндә, ул инде «Хәзер!» дип кире борылды, ашыгып кире китте. Рамилә тагын аңа иярде. Нурханова капка төбенә чыкты да, машинасында китап укып утырган шоферга:

— Бар, тиз генә кайтып кил әле,— диде. Үзе утыргычтан кара сумкасын алып, егерме бишлек чыгарды.— Менә акча.

— Фидая Госмановна, кибеттә юктыр бүген, якшәмбе бит.

— Зиннәтовның өенә бар. Мин моннан шалтыратып куярмын.

«Аракыга җибәрә инде әллә? — дип шаккатты Рамилә. — Шулай шул. Үз акчасын биреп! Менә сиңа җитәкче!»

Алар кире әйләнеп килгәндә, торбага трос салынган, мотор нык гөрли, кранның озын борыны бик салмак кына борыла да башлаган иде инде. Кабинадагыларның берсе якын килмәскә кушып кул болгады. Рамилә бина почмагы янында торган Гөлфия белән янәшә туктады, шунда ук больницадан ак халат өстеннән иңнәренә пальто салган берничә кыз чыгып бастылар, больница тәрәзәләрендә борын-

нарын пыялага терәгән йөзләр чалынды.

— Вира! Пошел!

Торбаның бер очы җирдән калкына башлады.

«Эх, альбомымны, карандашларымны аласым калган!— дип үкенде Рамилә.— Нурханова да әйтмәде, ичмасам, мондый эш буласын!»

Ул тирә-якны күздән кичерде. Манзарасы ни тора! Алар биектә торганга, офыклар киң, калкулык артында ерым, аннан авыл урамнары, аннары киң басулар, алар артында томанга төренгән урманнар... Сулышны киңәйтә, кешене үстереп җибәрә торган күренеш.

— Әйткәнен эшли безнең Фидая,— диде Гөлфия.— Болар барсы да ул кузгаткан эш бит. Бер җәй эчендә шушы хәтле хикмәтне башкарды. Нигезен дә салдырды, котельныен да торгызды. Казаннан килгән студентларны көн-төн эшләтте. Ут өерделәр! Очына чыга алса гына ярар иде.

— Ә нишләп чыга алмасын?— дип сорады Рамилә.

— Һи, төзү эшенең хикмәтләре! Теләсә кайчан туктый да кала ул! Кирпече булса — комы юк, комы булса — цементы юк, тактасы юк, алары булса — эшчесе юк, эшчесе булса, китерергә машинасы юк! Унар-егермешәр елга сузыла мондый корылышлар! Безнең Билал монда килүгә чаба башлаган иде, кузгата да алмады! Районның үзендә янып-көеп йөрүчесе булмагач, баш врач кына әллә ни кыра алмый шул!

Кран торбаны җирдән аерып алган, ул юан троста салмак кына чайкалып асылынып тора, өч ир кеше аны астан бау белән тартып түбәнге башын тиешле урынга, әзер нигезгә утыртырга тырышалар иде. Нурханова бөтен гәүдәсе белән кылдай тартылган, әйтерсең күз карашы, йөрәк тибеше белән тегеләргә булышырга тырыша иде.

«Юкка калдырдым альбомны...»— дип тагын үкенде Рамилә.

Торбаны, ниһаять, нигезенә утыртып, өч яктан трос белән бәйлиләр иде инде, больница артыннан гаҗәеп кыяфәтле бер ир-ат килеп чыкты. Соңгы мода белән тегелгән өр-яңа ачык коңгырт плащ, ялтыравык кара ботинка кигән, төз ыспай гәүдәле, утызлар тирәсендәге бу кешенең аяк басуларында ук үзенә бер затлык, нәзакәт, үз дәрәҗәсен белү сизелеп тора. Плащы төсендәге эшләпәсе маңгаен каплаган, йөз сызыклары бик камил.

— Кем бу?— дип сорады Рамилә Гөлфиядән пышылдап кына.

— Роберт Албертович бу безнең, Йосыпов.

«Мәскәүдән килгән вәкилдер,— дип уйлады Рамилә.— Йә берәр галимдер, докторлык диссертациясенә материал җыярга килгәндер».

— Безнең гинекологыбыз,— дип өстәде ул арада Гөлфия.

Хатын-кыз врачымы? Рамиләнең ышанасы килмәде: бу кеше белән фәкать халык язмышы, сәнгать хакында гына сөйләшеп буладыр, аңа яшерен, эчке серләреңне чишү мөмкин түгелдер кебек иде.

Хәер, авыл халкы чит итмәгән, күрәсең, үзен. Чибәр кеше әле генә өйләнгән икән, бәлки, авыл кызынадыр. Һәрхәлдә, Нурханова аны башлы-күзле булуы белән котлады.

— Монда тамырланып бик әйбәт иткәнсез,— диде.— Яңа больницада эшне җайлап җибәрергә яшьләр кирәк безгә!

Йосыпов ачык елмаеп, калын, йөрәккә ятышлы тавыш белән, һәр сүзенең тәмен татыгандай ашыкмый гына җавап бирде:

— Минем ниятне беләсез бит инде, Фидая Госмановна.

— Ул уегыздан кире кайтмадыгызмыни әле? Инде гаилә дә корып җибәргәч, башкачарак уйларсыз дигән идем!

Доктор китәргә йөри икән. Күрше районга, туган ягына, олыгайган ата-анасы янына. «Авылда да нинди шәп егетләр үсә, ә?— дип уйлады Рамилә.— Чын зыялы булу өчен атаң-бабаңның да зыялы

булуы шарт диләр тагын!»
Ул арада баш врач та якынрак килеп сүзгә кушылды:
— Мин сиңа әйтәм бит, атаң белән анаңны монда алып кил! Менә дигән йорт салып бирербез!
— Аларны нигезеннән куптарып булмый,— диде Йосыпов йомшак, салмак кына.
— Теләсә нәрсә әйт, мин моны җавапсызлык дип саныйм,— диде Газимов кызып.— Врачлары булмаса, бина салып куюда ни мәгънә? Чирлене таш стена дәвалармый! Кадрлар турында кайгыртырга кирәк, Фидая Госмановна! Аптырадык бит инде! Институт бетереп киләләр, эшкә өйрәтеп кенә җиткерәбез, китәләр дә баралар.
Ә Йосыповның исе дә китми, эшләпәсе астыннан көлемсерәп тора.
Аста, авыл читендәге юлда атлы тарантас күренде; ул, борылып, үргә менә башлады. Менә ул менеп җитте, тарантастан кара беретлы, киң җилкәле кеше сикереп төште. Аның юбкадан икәнен күреп, Рамилә аптырап китте, ул аны ир-ат дип уйлаган иде.
Хатынның җилдән каралган киң бите ачулы иде. Ул кулындагы кыска камчысы белән итәгенә ябышкан үлән сабакларын каккалагандай итте дә, туп-туры Газимовка юнәлде. Коры гына сәлам бирде, басу җилләрендә тупасланган калын тавышы белән:
— Безнең колхозга дигән пар казанын син апкиткәнсең икән, ә?— диде.
Газимов каушап китте, артка чигенде, Таштимерова белән — әбу нәкъ шул иде — кара-каршы Нурханова басып калды.
— Пар казанын монда китерергә мин куштым,— диде Нурханова тыныч кына.
Алар буйга икесе бер чама, күзләренә туп-туры карашып торалар, әмма резин итекле аякларын ерып баскан, киңчә гәүдәле Таштимерова каршында нечкә билле Нурханова көчсез һәм кечкенә булып күренә иде.
— Нишләп алай, безгә дигәнне бүтәннәргә бирәсең?— Таштимерова, сабырсызланып, чыбыркысы белән итек кунычына суккалады.
— Монда кирәгрәк бит, Ниса апа.— Нурханова сабыр иде.— Сезгә дә табарбыз, булыр.
— Шул булыр дигәнен монда китерергә иде! Колхозны таларга түгел! Начальник булдым дигәч тә ферманы суытып катырырга кем хокук биргән сиңа?
Таштимерова, кычкырынган саен, ярсый барды. Әгәр шунда Нурханова чигенмәсә, аны йә күкрәге белән этеп җибәрер, яисә чыбыркысы белән сыптырып кебек иде.
— Әллә син мондый эшләрнең ничек эшләнгәнен белмиләр дисеңме? Ирдән арынуың булды, күтәрелеп тә киттең! Беләбез ник икәнен, белмиләр дип уйлама!
Аның тавышы тырпаеп-калкып торган нигез ташларына, биек кранга, үрә баскан юан торбага, больница стеналарына бәргәләнеп көчәеп, үр астында яткан авыл өйләренә кадәр барып ирешә кебек иде. Газимов куркынган кыяфәт белән Таштимеровага таба атлады.
— Әкренрәк сөйләш!
Нисаның камчысы янтыгы янында уйнаклый иде:
— Краныгыз урыныннан купмасын, шушында торсын! Хәзер машина китертәм дә, казанны урыныннан куптарып алып китәм! Менә күреп торыгыз! Ирләр каршында итәк җилпеп үз дигәннәрен итәргә күнекмәсеннәр әле! Барып чыкмас!
Бөтенесе әсәреп киттеләр. Тик Нурхановaның гына йөзе үзгәрмәде бугай:
— Монда сөйләшә торган сүз түгел, минем кабинетка килерсең.

шунда хәл итербез,— диде ул нык итеп.

— Төкерәм мин синең кабинетыңа! Минем, халыктан качып, бикләнеп эшли торган эшем юк! Әйтәсе сүземне теләсә кем каршында шартлатып әйтәм! Үземә тиешлене алам!

Таштимерова тарантасына сикереп менеп утырды да, чыбыркысын болгап, үр астына төшеп тә китте.

«Нинди сирәк очрый торган тип! — дип аның артыннан сокланып карап калды Рамилә. — Тәмәке тартып, чәч кырдырып, тупас сөйләшеп йөргән кызлар белән генә чагыштырырлыкмыни моны! Чын мужик иткән үзен!»

Нурхановaның шоферы әйләнеп килгән, юлы уңган икән, эшчеләр канәгать кыяфәт белән ишегалдыннан аулаграк урын эзләп чыгып киттеләр. Әле генә шау-гөр килеп торган калкулык өстә тынып калды. Мондагы ыгы-зыгының хатирәсе булып, биек торба күккә ашып тора, аның очына алама болытлар кагылып уза иде.

Барысы да таралыштылар, әле генә булып узган күңелсез сөйләшүдән соң, Нурхановaның ялгызын калдырырга кирәклеген беләләр иде. Бер Рамилә калды читтәрәк. Ләкин Нурханова аны күрмәдеме, әллә инде эчендәгене яшерергә тәкате калмаган идеме, йөзенә хәсрәт ялкыны бәреп чыкты, керфекләре дымланды. Кызганыч, чыннан да кечкенә, ярдәмгә, юатуга мохтаҗ иде ул бу минутта. Көчле кеше дә, җитәкче дә түгел, фәкать хатын-кыз иде. Ул кесәсеннән кулъяулык алып, йөзен каплады, шактый гына шулай басып торды, аннары дымлы күзләрен больница тәрәзәләренең берсенә текәде. Анда ике якка аерылган ак пәрдә шәйләнә иде. Рамилә якынрак килде, тәрәзәгә ымлап:

— Анда нәрсә? — дип сорады.

— Операция бүлмәсе,— дип пышылдап диярлек җавап бирде Фидая. Бина иске, тәбәнәк, тәрәзә кечкенә иде, анда операция бүлмәсе булу Рамилә өчен гаҗәп тоелды.

— Әллә... шунда... сезгә операция ясаганнар идеме?

— Үземә түгел...

Рамилә артыгын сорарга ярамаганын аңлады. Фидая күз карашын биек нигезгә күчерде.

— Бер елдан килгәч танымассың әле,— диде. — Бинасы да, палаталары да шәһәрдән ким булмас. Матур итеп җиһазларбыз, менә дигән аппаратлар куйдырырбыз.

Кинәт ул Рамиләне кулыннан тотып алды да үзе белән ияртеп алып китте. Җиңел итеп нигез аша сикерде.

— Менә монда поликлиника була. Уртада коридор, ике якта бүлмәләр... — Ул, Рамиләнең кулын ычкындырып, арырак китте, әрле-бирле йөренә башлады. — Бу якта ишекләр... Монда чират көтеп утыручылар өчен уңайлы диваннар, урындыклар... Район больницасына бөтен халык иртәнге якта җыела, чиратны бөтенләй бетереп булмас. Стеналарына матур рәсемнәр ясасаң, эч пошулары кимер иде, ә? Юк, әллә башта хатын-кызлар бүлеген бизик микән? Нечкә күңелле халык бит.

Ул Рамиләне үзе белән әле тегендәрәк алып китеп, әле кире кайтып йөртә башлады.

— Икенче катта травматология бүлеге булачак. Андагылар атналар буе кузгалмый ятачак. Аларга да күз юанычы кирәк. Балалар бүлеге аерым. Аларга инде тулы әкиятләрне ясарга була...

Рамилә нәрсәнең кайда буласын аңлап җитми, хәер, юк стеналарга төшереләчәк рәсемнәр хакында уйлый да алмый, аны Нурханова үзе шаккатырган иде. «Саташканмы соң әллә бу хатын?»

— Әйдәгез, без хәзер үк кайсын алдан эшләргә кирәген хәл кылыйк та, договорын төзеп куйыйк,— ди Нурханова.

— Акчагыз күпме соң? — дип көлемсери Рамилә.

— Колхозлар белән сөйләшербез. Берәрсен ризалатырбыз. Йә, ничек, килештекме?

Рамилә сәерсенеп артка чигенде.

— Туктагыз әле... Стеналарны күтәрегез башта!

— Аннары соң була ул. Сез монда кайчан киләсез? Юк инде, хәзер хәл итәбез!

Рамилә салкын нигезгә бармагы белән төртте.

— Мин һавага рәсем ясау турында сөйләшә алмыйм.

— Планын карарсыз. План буенча. Анда бөтен үлчәмнәр күрсәтелгән...

Фидая Рамиләне дуылдатып больницага алып кереп китте.

Эчтә бу бина шактый караңгы, тыштан карагандагыдан да искерәк һәм ямансурак иде. Алгы, шактый иркен һәм гаҗәп биек бүлмәдә — күрәсең, бу төштә түбә ике катлы биеклектә эшләнгән иде — аклы-каралы телевизор тора, аның каршына берничә хатын-кыз һәм ир-ат тезелеп утырган. Арада бер-ике үсмер дә бар. Алар күндәм һәм моңсу караш белән ишеккә текәлделәр.

— Менә! — дип, каршыга, түшәм астына ишарәләде Фидая.

Анда акшарланган стенага зур гына рәсем ясалган иде. Киң сәхрә, аның уртасында юан кәүсәле, киң ябалдашлы ялгыз имән. Даладагы үлән сабаклары да, агач яфраклары да көчле җилдән бер якка авышкан. Сулышларны иркенәйтерлек киңлекне, яшәешнең мәңгелеген һәм җиңелмәс гайрәтен тасвирлый иде бу картина.

— Кем ясаган моны? — дип сорады Рамилә.

— Бер каторжан ясаган.

— Ничек — каторжан?

— Заманында моннан Себер юлы узган бит. Этап больницасы булган монда. Сырхаулаган арестантларны дәвалаганнар. Шуларның берсе ясап калдырган, дип сөйлиләр. Күрәсез, эчендә җаны булган кешеләр шул заманда ук больницаларны бизәргә тырышканнар!

5

Машинага утырып, кайтыр юлга кузгалгач, Фидая ян тәрәзәнең өчпочмаклы кечкенә өлгесен ачып, кызган битен салкын, дымлы җилгә куйды. Артта утырган Рамиләгә аның алтынсу бөдрәләре арасыннан алсуланып нәфис колак яфрагы, тыгыз яңагы күренә иде. Бите кызарып чыккан. Эчке ярсуыннан, мөгаен. Рамилә аның бәгырен көйдергән ялкынның кызуын тойгандай булды. Ничек шулай кузгалмый утыра ала икән әле бу Фидая? Рамилә шундый хәлдә булсамы? «Тукта!» — дияр иде шоферга. Сикереп төшәр иде машинадан, яшел наратлар арасыннан чабып китәр иде дә, мөлдерәп яткан күлнең көзге, көйдергеч, тынны буа торган суына чумар иде!

Алай гына түгел, ул алданрак, больница янында ук, Таштимерованың якасына ябышыр, күзен тырмар иде!..

Һәм... адәм көлкесенә калыр иде... Җиңелер, хур булыр иде. Әйе, сабыр елмаеп дөрес эшләде Фидая. Сабырлыгы белән җиңде. Нинди матур иде ул шул минутта. Һәм нәфрәттән ямьсезләнгән, кадер күрмәгәнлектән тупасланып иртә картайган чырайлы, берет астыннан тигезле-тигезсез тырпайган, керле чәчле Ниса нинди ямьсез иде... Бичара... Үз кадерен белсә, битенә кершән ягып, чәчен әйбәтләп тараса, кешечә киенсә, иң мөһиме, кешечә йөрсә-торса һәм адәмчә сөйләшсә, берәүдән ким булмас иде югыйсә. Кешечә дигәне — үз табигатенә ярашлы, ягъни, хатын-кызларча... Әмма Ниса үз җенесенә хыянәт итеп, башка җенескә күчәргә

тырыша бит... Рамилә, күзен йомып, күңелендә аны ир кеше итеп тасвирларга тырышып карады. Юк, күзалланган портретта ир бәдәнле хатын гәүдәләнде. Ходай бирмәгәнне тартып алып булмый... Шунда кинәт Рамиләнең күзе ачылып киткәндәй булды: бүген Нисаның ярсуы пар казаны аркасында түгел бит! Аның Фидаяга нәфрәте күптәннән киләдер, мөгаен. Ул аны хатын-кызлыгын саклаганы, чибәрлеге өчен, сөекле, бәхетле булганы өчен кураллмый! Аннан сирпелгән нурны сүндерәсе, аны пычратасы, таптыйсы килә!

Һәм Фидая, ничек кенә тырышса да, Нисаның бу теләген, омтылышын бетерә алмаячак. Фидаяга андыйларның нәфрәте эчендә гомер сөрергә туры киләчәк. Рамиләнең аны юатасы килә иде. Ул, алгарак авыша төшеп, Фидаяның алсу колагына диярлек:

— Ул сезне казан өчен тиргәмәде бит, — диде.

Фидая гасабиланып көлеп куйды:

— Бер авылдан бит без. Иңгә-иң эшләдек. Ул — колхоз председателе, мин — мәктәп директоры идем.

— Ничек килешә идегез соң?

— Эт белән мәче кебек. Балкыш, туктат әле.

Фидаяга эчен бушатырга кирәк иде, күрәсең. Берәр кешенең җылысын тоярга кирәк иде. Ул Рамилә белән янәшәгә күчеп утырды.

— Ничек... шундый булган соң ул Ниса? — дип сорады Рамилә.

— Ирдәүкәләнгән, дисеңме? Теләге шул булган, хыялы!

— Ирдәүкәләнергәме?

Фидая көлеп куйды.

— Егетләрчә булырга! Егет булуның иң зур дәрәҗә икәнен белмисеңме әллә? Әллә сиңа берәр егетнең: «Чын егет син, Рамилә!» — дигән мактавын ишетергә туры килгәне юкмы?

Фидая Рамиләгә сынап карады.

— Әгәр беләсең килсә, Нисадан да бәхетле кеше булмаска тиеш бу дөньяда. Чөнки ул иң зур теләгенә — егет булуга ирешкән.

— Бичара!..

— Һәм ул бер аның гына теләге дә түгел. Мин үзем гомер буе егет булу турында хыялландым.

— Ә нигә?..

— Егет булу ул чын кеше булу дигән сүз. Шулай түгелме? Күрше малае Ваккас белән сәкедә уйнаганда ук мин, әти булам, дип тарткалаша торган булганмын.

— Курчак уйнамадыгызмыни бер дә?

— Яшереп кенә уйный идем. Әни гади колхозчы минем. Ә әтием бик абруйлы кеше, тракторчы, хәтта тракторчыларны укытучы. Исемен зурлап әйтәләр, район газетасында мактыйлар. Хезмәте серле, кызыклы тоела. Ничек кызыкмыйсың? Ә менә без алтынчыны бетергәч, әти тракторына ярдәмче итеп Ваккасны алдылар, мине түгел. Аның әтисе тракторга су ташучы гына булып эшли иде югыйсә.

— Эшчән малай булгандыр.

— Мәктәптә мине уздыра алмый иде инде. Гел «биш»ләргә укыдым бит мин, отряд советы председателе булдым. Классны тезеп, линейкаларда айт-двага гына бастырып чыга идем. Ваккас минем командага уртада атлап йөри иде.

— Ничек түзде икән? — дип сорап куйды Рамилә үзе дә сизмәстән. — Гарьләнми идеме?

— Гадәттә, шулай бит ул: мәктәптә иң активы — кызлар. Ә урамга чыксаң? Трактор-комбайн тирәсендә малайлар, ат сыртында малайлар... Ваккас алтынчы класстан сабан туйларында ат чабышып, мәйданнарны әйләнә торган иде инде. Ә без кызларга ни

кала? Авызга кашык кабып йөгерү... Менә кайда ул гарьлек! Чөнки безнең хыял нәрсә? Кемнәр безгә үрнәк? Корчагин, Мересьев, Гагарин... Утлар-сулар кичү, зәңгәр күккә менү, ерак юллар үтү... Малайлар өчен дә, кызлар өчен дә бер үк.

— Нишлисең, бездә балаларны бер көтүгә кушып көтәләр шул,— дип көрсенде Рамилә.— Сарык көтүен кәҗә тәкәсе артыннан йөртәләр, дип укыган идем мин. Без сарыкларга кәҗә тәкәләрен үрнәк итеп куялар шул.

Фидая җиңеләеп көлеп җибәрде.

— Дөрес әйтәсең! Ә минем башка андый чагыштыру килмәгән иде әле.

— Безнең мәктәпләр балаларны кеше итеп үстерә алмый. Табигать үзе җиңсә генә. Әйтик, мәхәббәт килгәч, һәммәсе үз урынына урнаша. Малае-кызы үзенең кемлеген аңлый башлый.

— Мәхәббәт? Мәхәббәт... Ә беләсеңме, мәхәббәт дигән сүзне ишетү белән минем аякларым сызлый башлый.

— Мәхәббәт йөрәкне сызлата! — диде Рамилә.

— Ә минем аякларымны сызландырудан башлады. Бер җәйге кичтә көтү каршыларга бара идем. Карасам, Ваккас кычыткannan себерке ясаган да, кызларның шәрә балтырларына чәпәп йөри. Тегеләр чырылдап чабалар. Шуннан миңа каршы килә башлады бу. Ә мин, аны күрмәгәндәй, туп-туры барам. Менә якынайды, иелде, аякларыма уңлап-суллап бәргәләргә тотынды. Ә мин һаман үз көем белән атлап барам. Күпмедер шулай бардык без урам уртасыннан. Ул — иелеп, мин башны югары күтәреп. Бирешмим, сиздермим, Корчагин кебек чыдыйм!

— Юләр! — дип көлеп җибәрде Рамилә.— Аның сезнең белән шаярасы, куышасы килгән! Яратуын шулай сиздермәкче булган!

— Төн буе аякларым утта янып чыкты. Ярату шундый буламыни? Хәер, ул чакта яратадыр дип башыма килмәде әле. Анысын соңрак аңлаттылар. Шулай ук аякларым аша. Өлкән классларны без өч чакрым йөреп укыдык. Беркөнне шул җәмәгать эше белән мин иптәшләремнән калдым. Кышкы юлдан ялгызым кайтып бара идем, чаңгы таккан Ваккас куып җитте. Куен кесәсеннән карточка чыгарды да миңа күрсәтә: «Таныйсыңмы?» — ди. Карасам, аның учында мин елмаеп ятам. Дус кызыма бүләк иткән карточкам. Җәлт итеп карточканы Ваккас кулыннан тартып алдым да, ак фетр итегемнең куныччына кыстырдым. Аннары башымны югары күтәреп китеп бардым. Ә ул арттан килеп, мине төртеп екты да, итегемне тартып салдырды. Карточка читкә барып төште. Шунысы гарьлек, карточкада мин һаман елмаеп ята идем! Ваккас аны алды да китеп барды, мин оекчан килеш кар өстендә басып калдым.

— Яратуы чын булган икән.

— Бу юлы анысы минем башка да барып җитте инде. Моны аңлавым булды, ярату, мәхәббәт дигән нәрсәгә нәфрәтем кабынуы булды. Шул Ваккаска бәйләнергәме? Алла сакласын! Мересьевлар, Гагариннар кылганнарга тиң бөек эшләргә омтылып яшәргә кирәк! Егет булырга кирәк! Менә шуңа инандым.

Рамилә көлеп җибәрде.

— Ярый әле, морадыгызга ирешмәгәнсез,— диде.— Югыйсә нәкъ шул Ниса кебек булыр идегез!.. Ай, әнә-әнә үрдәкләр түгелме?

Машина күл буеннан үтеп бара иде.

— Карагыз әле, әнә тегесе, шәмәхә муенлысы, әтиләре бит! Әниләре кая соң? Калган һәммәсе бертөсле!

Балкыш, юл читенәрәк чыгып, машинаны туктатты.

Нурханова район үзәге Суташның үзәк урамында, югары очтарак, сул ягы биек тупыллар белән ышыкланган ихатада, яңа йортта яши. Ихата ачык яшел төскә буялган тыгыз койма белән әйләндереп алынган, ишегалдында такта калдыклары, пычкы чүбе, кузла, шифер сыныклары — түзелештә була торган үзенә бер күңелле тәртипсезлек хөкем сөрә, түр як кына әле буяп та өлгермәгән сирәк койма белән бүлеп куелган, анда җир казылып, түтәлләр ясалган, кырыйдарак кура, карлыган сабаклары тырпаеп тора: хуҗа бакча ясый башлаган, димәк, монда ныклап нигезләнергә ниятләгән. Бакчаның уң ягындагы өр-яңа корылмалар — әле түбәсе дә ябылмаган сарай һәм мунча да шул хакта сөйли, биредә яшәүчегә мул тормыш вәгъдә итә сыман иде.

Баскычлары, идән такталары гына түшәлеп, ян-яклары әле ышыкланып өлгермәгән болдырда итекләрен салганда Фидая Рамиләгә:

— Хәзер кайнар чәй эчәбез,— дип, җиңел сулап куйды.— Индийский чәй бар минем, шулпаны да өлгертергә була, иртән пешереп киткәч, җайлы ул. Мин электр самавырын тоташтырам, син карый торырсың. Тиз генә Иркәне алып чыгармын. Әбисе балалар бакчасыннан алырга өлгермәгәндер әле.

Ярты сәгать тә үтмәгәндер, алар кечкенә кухня ягындагы чәчәкле клеенка җәелгән өстәл янында, өчесе түгәрәк бер табын ясап, чәй эчеп утыралар иде инде. Нурханова зәңгәр бизәкле ситсы халаттан, чәчен ак яулык астына җыеп куйган, тыйнак, сабыр, сөйкемле әнигә әверелеп калган иде. Рамиләгә ул тагын бүтәнчә булып күренде, әле күптән түгел генә төзелеш мәйданында кара күн пальтодан, ихтыяр төене булып басып торган хатынның мондый рәвешкә керүенә ышанасы да килми иде. Бу хатынның һәр рәвешен тасвирлау өчен төрле буяулар, төрле стиль таләп ителер кебек иде. Әйтик, гайрәтле ирләр һәм куәтле машиналар белән идарә иткәндә — ачык майлы буяулар һәм кубизмга якын стиль, чәй янында кызы белән сөйләшкәндә — импрессионистларга хас йомшак акварель һәм нурлы да, томанлы да төсмерләр...

— Кызым, бакчада нишләдегез бүген? — дип сорый ул Иркәдән, тавышыннан-рәвешеннән наз бөркелә.

— Менә болай иттек,— дип, ике кулын баш очына күтәреп болгый Иркә,— флаглар белән. Тезелешеп йөрдек.

— Сафка басыпмы?

— Ие, сафка.

— Син кайда идең, кызым, уртадамы, арттаракмы?

— Мин иң алда! — ди Иркә, мактанып.

Кызчык әтисенә охшаган, күрәсең: шома көлсу чәчле, очлырак иякле. Соры күзләре үз яше өчен артык акыллы, җитди, уйчан карыйлар.

Урам якта машина гүләп килеп туктаганы ишетелде, олы капка каерылып ачылып, әрҗәсенә берничә озын торба салган «КамАЗ» әкрен генә керә башлады, аның каршында таза гәүдәле, плащын җилбәгәй җибәргән, эшләпәсен артка шудырган ир уртасы бер кеше, хуҗаларча нык басып: «Уңгарак-сулгарак!» — дип фәрман биреп, артка таба чигенә иде.

Өйдәгеләр барысы да башларын сузып тәрәзәдән карадылар. Нурханованың йөзе үзгәрде: җитдиләнде, күзләре боздай суынып киткәндәй булды, ул борылды да бүлмәгә чыгып китте, ә Иркә уйчан һәм өнәмәгән кыяфәттә тәрәзәгә текәлгән килеш калды. Минут та үтмәде, Нурханова, көрәнсу күлмәген киеп, иңенә пальтосын салды да тышка чыгып китте. Рамилә дә, Иркә дә өсләре-

нә киделәр.

Алар чыкканда, машинадан ике кеше торбаларны бушатып азаплана, ә алдан кергәне, эшләпәлесе, болдыр каршына басып, Нурханова белән сөйләшеп тора иде.

— Мин сезне Кармаштан кайтмаган дип уйлыйм бит әле, болай вакытсыз борчып йөрмәс идек, — диде ул, киң елмаеп.— Суыклар җитә, җир катканчы кертергә кирәк бит инде җылыны, өйгә дә, мунчага да,— дип дәвам итте ир кеше. — Ял көннәрендә эшләргә туры килә, планга кергән нәрсә түгел.

— Рәхмәт инде,— диде Нурханова, бик чишелеп китми генә. Ул бу кешене өенә кертергә җыенмый, ишеккә аркылы баскан иде. Рамиләнең чыкканын күреп:

— Таныш булыгыз,— дип өстәде.

Ир кеше — төзү-монтаж идарәсе җитәкчесе Мирхуҗин икән. Зур, йомшак учы белән Рамиләнең кулын илтифатсыз гына сыпырып алды, күзләре исә Нурхановaның йөзенә текәлгән иде.

— Бу йорт казна квартиры саналса да,— дип дәвам итте ул сүзен,— бөтен көчне аңа гына ташлап булмый, төрле якка тарткалыйлар. Монда торба китергәнне сизсәләр, асып куячаклар.

Һәм Мирхуҗин, шаярган булып, кабартмадай калын кул кыры белән аяк астын сызды да, ничек асачакларын күрсәткәндәй, болытлы күккә ишарәләде.

— Мин ашыктырмыйм, үз чираты белән эшләрсез,— диде Нурханова.

— И һәм дөрес эшләмисең,— диде Мирхуҗин, җанланып.— Ашыктыр син мине, мәҗбүр ит, җитәкче буларак әмер бир! Ул чакта иркенләп эшләр идек! Ә болай читен бит! Мин сезнең икегезне тиң,— ул Рамилә белән янәшә чыгып баскан Иркәгә кулы белән ишарәләде,— икегезне тиң туңдырып үтерә алмыйм бит инде. Мәле, кызым!

Һәм ул, плащы кесәсеннән зур, чәчәкле шоколад алып, Иркәгә сузды. Иркә ике кулын да аркасына яшерде:

— Кирәкми! — дип, Мирхуҗинның елмайган чыраена яратмыйча, чит итеп карады.

— Ал әйдә, ал, биргәннең битенә карама, ди!

— Кирәкми, Илдарга бир!

Илдар дигәне, күрәсең, Мирхуҗинның үз малае иде.

— Ай-яй, анаң кызы булсаң да булырсың икән,— диде Мирхуҗин, тагын да киңрәк елмаеп. Аның күзләре бөтенләй кысылды.

— Ә мин әти кызы.

— Әтиең юк ич синең.

— Бар, бар минем әти! — дип кычкырды Иркә. — Ул больницада гына ята! Кайта ул!

— Бигрәк әйбәт, бирсен ходай,— диде Мирхуҗин, шоколадны болдыр тактасына куйды. Алам дигәнне алмыйча, бирәм дигәнне бирмичә кала торганнардан түгел иде ул, күрәсең.

Нурханова итәгенә капланган кызының шома чәчен, нечкә толымнарын сыйпаштырды. Алар Мирхуҗин белән Кармаш больницасының төзелеше турында сөйләшә башладылар.

— Башыгызны катырмагыз ла шул больница белән!— дип, кул селтәде Мирхуҗин. — Үзегезне уйлагыз башта!

Нурханова аннан пар казаны сорады. Казанның «Үзәк» колхозы өчен икәнен белгәч, Мирхуҗинның йөзендәге елмаю сүнде.

— Ул Ташнисаның бугазы тыгылмады инде. Сорый белеп сораса бер хәл иде, алашасына бакыргандай кычкыра!

— Сез аңа тиешле казанны больницага куйгансыз икән бит,— диде сабыр гына Нурханова.

— Казанга тамга сугылмаган, үз өемә дә кайтарып куйма-

дым,— диде Мирхуҗин. — Колхозлар — сорар өчен яратылган нәрсә алар. Кирпечен, тактасын, бульдозерын, запчастен... Йомшаграк торсаң, алар синең кабинетыңа кереп, муеныңа менеп атлана. Сез аларны күп сөйләндермәгез, үз сүзегезне әйтегез дә, чыгарып җибәрә торган итегез!

Нурханова ничектер шаян елмайды:

— Әле генә әмер бирергә киңәш иткән идегез, ә хәзер тыңламаска маташасыз. Сез моны минем әмер дип кабул итегез. Әллә тагын бер казан таба алмыйсызмы?

Мирхуҗин аңа текәлеп, сынап, нәрсәдер сорарга теләгәндәй карады, аннары карашын Рамиләгә, Иркәгә күчерде, көрсенде.

— Аптыраган, Фидая Госмановна,— диде.— Ирләр белән әйбәт кенә аңлашам, ә менә хатын-кызны аңлап булмый, баш миңгери,—диде.— Сезнең хакка утка керергә риза, югыйсә!

Ике кулын җәеп, оялгандай елмайды, аннары, Нурханованың тагын берәр сүзен көткәндәй тынып торды да, чыгар якка борылды. Ирләр дә торбаларны төшергәннәр, машина чигенә башлаган иде инде. Нәни Иркә Мирхуҗинның киң аркасын нечкә толым очлары белән тишәрдәй итеп карап калды.

— Бик үткен кешегә охшаган,— диде Рамилә, уйланып.

— Аларсыз яшәп булмый бит,— дип җавап бирде аңа шулай ук уйчан гына Нурханова.— Менә бит, миңа йортны да ул җиткерә, больницаны да ул торгыза. Әгәр теләсә...

Алар кире кереп өстәл янына утырганда чәй суынып киткән, ризыкның тәме кимегән, гомумән, өйдә ямансулык көчәйгән, почмаклардан яшеренеп кенә ятимлек карап тора иде шикелле.

## 7

Төн карасының бер хикмәте бар: кешеләрне бер-берсенә якынайта, уйларын бер эзгә сала, серләрен ачтыра. Фидая белән Рамилә дә шулай булдылар.

Рамилә белән Иркә бер бүлмәдә, берсе караватта, берсе диванда, ә Фидая зал ягында яткан иде. Бер көн эчендә күп күреп, күп йөреп талчыккан Рамилә, башы мендәргә тиюгә, йокыга киткән иде, әмма төн уртасында нәрсәдәндер сискәнеп уянды. Әллә урамнан үткән машина тавышы, әллә пәрдәләр аша саркып, шуып узган фаралар яктысы бозды йокыны. Рамиләгә эссе булып китте. Ул, урыныннан торып, алгы бүлмәгә чыкты һәм зал ягының ачык ишегеннән яктылык бөркелгәнне күреп, якынрак килде.

Фидая диванда, җәелгән урыны өстендә, халатын бөркәнеп, аякларын бөкләп утыра иде. Кулында кечкенә генә зәңгәр тышлы китап. Рамилә ни сакланып атласа да, сизде, башын күтәреп, ишеккә карады да:

— Кер, кер,— диде.— Утыр менә минем янга.

Үзе ак җәймәне рәтләштерде.

— Нишләп йокламыйсың? Урын үзгәлисеңме әллә?

— Ә сез ник йокламыйсыз?

— Мин бераз йоклап алдым инде,— диде Фидая.— Гадәт шундый минем — сәгать икеләр тирәсендә йокым кача.

— Күптәннәнме шулай?

Фидая бераз тынып торды.

— Елдан артык.

— Берәр хәлдән соң шулай булгансыздыр инде? — дип бик сакланып кына сорады Рамилә.

Фидая карашын китапның ачык битенә төбәде:

— Менә тыңла әле, ничек яза шагыйрь Хәсән Туфан:

Таллар кистем, баулар иштем,
Саллар салдым суларга.
Китәр ягым — уңга да бит,
Җилләр исә сулларга.
Өстә — дулкын,
Астан упкын
Куллар сала салыма...

— Гаҗәп бит, шундый гади, берничә сүз дияргә була. Ә күз алдында — кешенең язмышы, фаҗигале, ачы язмышы. Ә бәлки берәүнең генә дә түгел, бөтен бер буынның язмышыдыр. Әйе, язмыш кешене дулкыннар арасына, упкыннар өстенә илтеп кертә. Ә менә аларга каршы торырлык салларны кем генә ясый ала икән соң?

— Уңган кеше, кулыннан эш килсә, тәвәккәллеге җитсә...— Рамилә, Фидая янына утырып, аңа иңбашы белән терәлеп, шигырьне укыды: «Өстә — дулкын...»

— Кем ул — уңган, тәвәккәл, көчле? — дип сорады аннан Фидая, көлемсерәп.

Рамилә, күтәрелеп, аңа күзләрен тутырып карады, сорауның мәгънәсен аңламады.

— Андый кеше фәкать ир-егет кенә була ала,— дип җавапны үзе кайтарды Фидая.— Әйе, ир-егет кенә. Таллар кисеп, баулар ишеп, давылга каршы сал белән чыгып китүчене кыз бала итеп күз алдына китереп буламы?

Ул бераз тынып торды.

— Кыз бала ул, чәчен җилдә җилфердәтеп, ерактан йөзеп килгән салларны ярда көтеп алучы итеп кенә күзаллана. Ә бит язмышларда аерма юк безнең: җилләр безгә дә бәрә, без баскан төшләрдә дә упкыннар хасил була! Ә көч, гайрәт тигез түгел! Бу шигъри юллар да егет кеше турында язылган. Кызлар болай сөйли алмый! Без, хатын-кызлар, өермәләрнең уртасына барып керәбез, ә үзебезнең аңа каршы торырга әзер түгеллегебезне уйламыйбыз!

Рамилә аның йөзенә озак кына текәлеп карап торды. Эчтән әрнеп:

— Нигә сез үзегезне болай кимсетәсез? — диде.— Әгәр беләсегез килсә, беркемдә юк хәзинәгә ия бит сез! Кулымнан гына килми, мин сезнең портретыгызны шундый итеп ясар идем! Минем буяуларымның көче җитми сезне тасвирларга! Ә рәссамнар ифрат талымлы, аларны сирәк кеше рухландыра, ышаныгыз миңа. Кайчак урамнан барганда шундый чибәрләр очрый, их, дип куясың, артыннан барасың. Ә текәлебрәк күзәтсәң, гайрәт чигә башлый, йә күз карашы мәгънәсез, йә сүзенең рәте юк... Ә сезгә караган саен күңел берегә бара. Сез бик, бик бәхетле булырга тиеш! Әнә бит, теге кеше әйтте: әмер генә бирегез, диде.

Диван янында торгын сары абажурлы торшер яктысы бу минутта Фидаяны алтынга мангандай, тагын да яктырак, нурлырак итеп күрсәтә, аның бераз тузгып тәртипсезләнгән эре дулкынлы чәчләре дә гадәттәгедән затлырак күренә иде.

Фидаяның йөзендә ачынулы көлемсерәү пәйда булды, ирен читләреннән чак кына өстәрәк сөйкемле, нәни чокырчыклар уелып чыкты, бу — аның йөзенә сабыйларча сафлык, эчкерсезлек өсти иде. «Менә шушы яктылыкта, менә шушылай уйчан һәм моңлы итеп сурәтләргә кирәк аны...» — дип уйлады Рамилә.

— Белсәң икән син бер карауда кешеләрнең дикъкатен җәлеп итүнең ничек начар икәнен...— диде Фидая.

— Чибәрлек, сөйкемлелек начармы? — дип сорады Рамилә, шаккатып.

— Әйе, әгәр син шулай дип атыйсың икән — чибәрлек. Безнең

заманда хатын-кыз өчен чибәр булу, мөгаен, үзе бер бәхетсезлектер...

— Бу... болай әйтү...— Рамилә сүз таба алмый торды.— Гөнаһ! Җинаять! Кешенең матурлыгы мәңге-мәңге зур байлык саналган.

— Әйе, мине чибәр диләр. Ләкин син аны хәзинәгә санап бик каты ялгышасың. Мондый булып туганчы гап-гади малай булып тусам, миңа, бәлки, мең мәртәбә яхшырак булыр иде, шулай түгелме?

Рамилә аңа каршы әйтер сүз тапмады.

— Шулай,— диде Фидая.— Без бит алар белән бер үк төрле тәрбия алабыз, бер омтылышлар белән яшибез, бер өлкәдә эшлибез. Без яшәгән-эшләгән өлкәдә чибәрлек түгел, егетлек кирәк. Шулай бит? Менә мин мәктәпне алтын медаль белән бетердем, хыялларым зурдан булырга бөтен нигезем бар иде. Океаннар, биек таулар, космос турында хыялландым мин. Ләкин диңгез причаллары да, күк капкалары да егетләр өчен генә ачык булып чыкты. Мин анда-монда белешеп йөргәнче, вузга документлар тапшыру вакыты узып та киткән иде инде. Алай да, соңгы көнне булса да тапшыра алмаммы дип, киттем Казанга, университетка. Пароходта бер көнлек юл иде. Көн буе миңа утызлар тирәсендәге бер салмыш адәм, әйдә, миңа кияүгә чык, дип бәйләнеп барды. Шулкадәр гарьләндем, әгәр шунда тиремне сала алсам, бөтен матурлыгымны, кешеләрне җәлеп итә торган сыйфатларымны өстемнән сыдырып алыр идем дә пароход астында болганып, ургылып калган дулкыннарга тондырыр идем. Аннан да бигрәк, әгәр егет булсам, үземә бәйләнгән андый сәрхүшләрнең үзләрен Иделгә мәтәлдерер идем! Ә болай — нишли алам? Карашы сыланып калмасын дип, каткат бит-кулларымны сабынлап юдым, бары шул гына.

Рәсемнәр, открыткалар буенча күптән таныш, күңелгә якын, газиз университет та мине егет булмаганым өчен кабул итмәде. Соң килгәнсең, диделәр миңа. Дөрес, мин чыннан да бер көнгә соңардым, ләкин егетләрнең соңарганнарын да кабул иткәннәрдер дип уйлыйм. Университетның игъланнар тактасында бик эре хәрефләр белән: «Егетләр игътибарына!» дигән белдерү эленгән иде. Һәм беләсеңме, нәрсә диелгән иде анда? — Фидая бераз вакыт мәгънәле итеп тынып торды.— «Унбер балл җыйган егетләрне механика факультетының деканына чакырабыз»,— диелгән. Мин башта моның мәгънәсен аңламый тордым. «Механика факультетында недобор бит, шуңа башка факультетлардан егетләрне чакыралар,— дип аңлатты чалбар кигән кәттә бер кыз, исе китми генә.— Хәзер бөтен вузларга күбрәк егетләрне алырга тырышалар. Начаррак укысалар да».

Димәк, әгәр егет кеше булсам, мине соңарган дип тормаячаклар иде.

Чемоданымны күтәреп, урам буйлап киттем, кая барганымны аңламадым. Кыркылган куаклар белән әйләндереп алынган бер кечкенә бакчага кереп, эскәмиягә утырдым, каршымда кара баганалардан ясалган баһадир егетләр, абзыйлар басып тора. Хәтта алар да миңа үчекләп, кимсетеп карыйдыр сыман тоелды.

Күпме шулай утырганмындыр миңгерәп, берәү миңа:

— Сеңелем! — дип дәште.

Кырык яшьләр тирәсендәге чандыр гына бер абзый читтәнрәк миңа карап тора. Шакмаклы күлмәгенең кыска җиңнәреннән сөякчел, зур куллары тырпаеп күренә, ачык изүеннән җыерчыклы муены сузылып чыккан.

— Баядан бирле караштырып йөрим сиңа, нәүмиз кебек күренәсең,— ди.— Барыр җирең юкмы әллә? Авылдан килгәнгә охшыйсың.

Күңелем тулып китте, ике авыз сүз белән хәлемне аңлатып

бирдем. Ул, эскәмиянең икенче башына утырды да: «Әйе, яшьлектә бер бәргәләнеп аласың шул инде, ансыз булмый»,— диде. Ул да Казанга институтка керәм дип килгән булган икән. Конкурстан үтмәгәч, бик гарьләнгән, әмма хәзер үкенми. Заводта эшли, акчаны инженерлардан күбрәк ала. Заманы шундый хәзер: оста куллар гыйлемле баштан кадерлерәк. «Баш ярылып күз чыкмаган, миңгерәп йөрмә болай,— диде ул.— Кунар җирең булмаса, әйдә безгә. Өй тулы кеше, дөрес, ләкин күп янына әз сыя ул. Бер кичкә кер мичкә, ди халык».

Урамнар буйлап барганда, һаман минем күңелне күтәрергә тырышты абзый. «Хатын-кызга һөнәр сайлау җиңелрәк,— диде.— Алар өчен иң кулае — аш-су тирәсе. Эшләре корыда, җылыда, чистада, дөньяда нинди генә хәлләр булса да, тамаклары ачыкмый... Әнә кара, бу зур тәрәзәләр артында гел хатын-кыз эшли бит! Парикмахерлар дисеңме, сатучылармы, тегүчеләрме — һәммәсе дәрәҗәле эш. Ир-атка хезмәтнең авыррагы эләгә, шулай тиеш тә».

Алар Кабан күле артында, шәһәрнең электән калган иске урамындагы агач өйдә яшиләр икән. «Кала кызына йортка кергән идем бит мин,— дип аңлатты ул.— Ә монда үз йорты булган кешегә квартир бирмиләр. Авыл кешесе квартирны тизрәк ала. Менә син эшкә урнашып калсаң, квартир алырсың да, хатын белән мине парлап өй туена чакырырсың әле».

«Бер кичкә кер мичкә» дигәне сүз өчен генә булмаган, өйләре, чыннан да, кысан булып чыкты. Чаршау белән бүленгән бүлмәнең алгы ягында бер карчык, бер хатын һәм ун яшьләрдәге бер кыз — өч буын кешесе чәй эчеп утыралар иде. Абзый минем хакта: «Авылдан укырга килгән, кунар җире юк»,— дигәч, бик ачылып китми генә табын янына чакырдылар. Ул чакта мин нечкәләп уйлап тормадым, ачыккан-талчыккан идем, соңыннан гына аңладым: абзый ул көнне соңарып һәм береаз салып кайтып килгән дә, ишектән керүгә хатыны тирги башламасын өчен мине иярткән булса кирәк.

Төнне мин идәндә, юка сырма өстендә үткәрдем. Мин кымшанган саен янымдагы сандык өстеннән карчык башын калкыта, күрәсең, шикләнә иде.

Иртүк хатын чиләкләрен шалтыратып суга китте, ә абзый, чаршау артыннан чыгып, сандык актарырга кереште. Аның йөзе сүрән һәм күңелсез иде. Хуҗа хатын кайтты да, өйалдында самавыр куйган арада, миннән нindидер абза-җиңгәләрен сораштыра башлады. Ул мине иренең авылдашы дип аңлаган икән. Чит-ят икәнемне белүгә, иренә ябырылды бу: «Кемне алып кайттың син?» Абзый моның гадәтен белә, җавап та бирми, үз сүзен сөйли: «Мунчага барасы иде, майкамны таба алмыйм»,— ди. «Ә, мунчага барасыңмы? — ди аңа хатыны.— Аруланасың киләме? Алайса, бу кәнтәеңне дә иярт инде, аркаңны ышкырга кирәк булыр!»

Баш түбәмнән пычракка чумдыргандай итте бу мине. Һәм тагын шул — кыз бала булганым өчен. Әгәр шунда абзый берәр егет ияртеп кайткан булса, мондый сүз әйтүче булыр идемени?

Пароходка утырып, кире авылга кайтканда, кеше күзенә чалынмаска тырыштым, өске ятакка менеп, стенага карап яттым. Иртән аяк табанымны кытыклаганга уянып киттем. Башымны күтәреп карасам, пумала башлы бер егет минем аягымны сөямләп үлчәп маташа. «Моны,— ди янындагы иптәшенә,— босоножка белән пычрак ярдырып алып кайтып булмый бит инде, бер пристаньда төшеп, галуш алып кигезермен». Төнлә яңгыр ява башлаган икән, мине кайгырта, янәсе. Үзе белән авылына алып китмәкче бугай. Әллә чынлап сөйли, әллә шулай шаяра... Фидая көрсенеп куйды:

— Авылымнан чыгып китеп, чит кешеләр арасында беренче тап-

кыр айкалуым менә шушындый тәэсирләр калдырды. Кайчакларда беләсеңме, нәрсәгә охшатам мин үземне? Бер төрле чәчкәгә...

— Чәчкәгә булгач, бигрәк әйбәт бит инде,— диде Рамилә.

— Чәчкәсе нинди бит... Берәүләрнең бакчасында әллә каян, ерактан күзгә ташланып торган гөл күргән идем мин. Биек сабаклы, учмаучма сап-сары чәчәкле. Бик ачык, хуш исле. Сокланып якынрак килсәм, ни күрим, аны эре, яшел чебен сарып алган. Чирканып киттем...

— Сез бит үлән түгел,— диде Рамилә.— Чебеннәрне куарлык кына хәлегез бар! Сез зур мәхәббәткә лаек, аны табу сезгә башкалардан мең җиңел, язмышка мең рәхмәтләр укырлык!

Фидая көлемсерәп аның йөзенә туры карады. Нидер әйтергә теләде, ләкин шул минутта күрше бүлмәдән:

— Әни!..— дип еламсыраган тавыш ишетелде.

Иркә уянган иде. Фидая, торып, чыгып китте. Рамилә аны шактый көтте, ләкин Фидая әйләнеп кермәде, ул төнне сүзнең дәвамы булмады. Ә Рамиләнең күбрәкне беләсе килә иде: җиде төн уртасында уянып кемне уйлап моңая бу серле хатын... Шул ук вакытта бүген килгән теге начальникның — Мирхуҗинның да нииндидер катнашы бар иде монда. Чибәрлекнең кыйммәте юклык, Фидаяның үзен чебен сарган гөлгә охшатуы — болар, мөгаен, аның белән сөйләшүдән соң туган хисләр нәтиҗәсе иде.

Рамилә, яшел тышлы кечкенә китапны алып, ачык битендәге соңгы юлларны укыды:

Тынма, дәрья, айка, чайка:
Күнмәгәнмен тынлыкка.
Упкыннарың берни түгел,
Батырма тик моңлыкка...

## 8

Күргәзмәне бөтен шартын туры китереп ачтылар. Картиналар район Культура сараеның бию кичләре үткәрелә торган иркен вестибюленә эленгән, залның уртасында аркылыга киң кызыл тасма сузылган иде.

Күргәзмә ачылды, җыелган халык, картиналардан карап торган таза егетләрне, чибәр кызларны бимазалаудан курыккандай, сагаеп, әкрен генә зал буйлап тарала башлады.

Ул арада ишек турына нык пычранган автобус килеп туктаганы күренде. Автобустан төшкән кешеләрне зур тәрәзә аша күреп, Фидая елмаеп ишеккә юнәлде, аның каршына чәчәкле кызыл шәле бөдрә чәченнән шуып төшкән, утлы күмердәй кара күзле, янып торган битле хатын керде. Фидаяны кочаклап күкрәгенә кысты.

— Таштимерова сезне җибәрмәс дигән идем, шуңа хәбәр дә итмәгән идек...— диде Нурханова, гаепле кешедәй.

— Мондый вакыйгадан кала торган кешеме без, ә? Син ничек безнең хакта алай уйлый алдың? Бугазыннан каерып алдым автобусны Таш Нисадан! Бугазыннан! Өлкән класста укучы бөтен балаларны алып килдем!

— «Биш»ле сиңа, Каләмгөл апа!— диде Фидая, көлеп.— Плюс белән! Шуңа өстәп, Таштимерованы җиңгәнең өчен — медаль!

— Аның өчен медаль бирә торган булсалар, минем түштә эләр урын калмас иде инде! Балалар!— дип, ишектән кереп килгән укучыларга борылды Каләмгөл.— Аяк киемнәрегезне әйбәтләп юдыгызмы? Шыпырт, шауламагыз! Хәзер экскурсовод безгә бөтенесен аңлатыр, җыелыбрак торыгыз!

— Экскурсовод юк бит монда,— диде Фидая.

— Нишләп юк ул? Булырга тиеш! Балаларның кайберләре кур-

гәзмәдә беренче тапкыр. Андыйлар бармы? Кулларыгызны күтәрегез әле?— Егет-кызларның икәү-өчәве генә баш түбәсеннән бармак очларын сузып күрсәтсә дә, Каләмгөл үз сүзен расланганга санады.

— Күргәзмәне рәссамнар үзләре алып килгән,— дип аңлатты Фидая.

Моны белгәч, Каләмгөл шунда ук алар белән таныштыруны таләп итте, рәссамнарның һәркайсы белән кул биреп күреште, аның кыяфәтенә һәм энергиясенә таң калган Тәүзих Әхмәдуллин, карашын Каләмгөлнең йөзеннән ала алмыйча, бармакларын учыннан ычкындыра алмыйча интекте.

Ишек төбендә үзенә күрә бер нәни өермә хасил булды кебек, бөтенесе хәрәкәткә килде, күргәзмәдәге дәрәҗәле тынлык бозылып алды. Һәр рәссам үз әсәрләре хакында балаларга аңлатма бирергә тиеш булды. Укучы балаларның берсенә аларның сөйләгәнен бәйнә-бәйнә язып барырга кушылды. Ә Каләмгөлнең үзе кебек үк ут күзле, алма битле, чәчәкле шәле бөдрә башыннан шуып төшкән кызы Заремага фотога төшерергә боерык бирелде.

— Монда да төшереп ал,— диде аңа Каләмгөл,— соңыннан барыбыз бергә урамга чыгып та төшәрбез. Берсе чыкмаса, берсе чыгар.

Ул булган җирдә эш җиңеләя иде. Һәм Нурханова җиңел сулап, төркемнән читләште, картиналарны ялгызы гына тыныч, ашыкмыйча күздән кичерәсе килә иде аның.

Балаларның да йөзләрендә соклану... Бәхетлеләр, алар сәнгать әсәрләренең җитешсез якларын күрергә өйрәнмәгәннәр, шул ук вакытта сизгер күңелләре белән рәссамнарның ихласлыгын, тырышлыгын, якты омтылышын тоялар һәм шуннан тәм табалар. Фидая исә күпне күрә: төсләрнең күзне ерткаввед да, кеше тәненең туктаусыз хәрәкәтен сизелерлек итеп бирә алмыйча, рәссамның аны курчак кебегрәк тасвирлаганын да... «Күп белгәннең башы авырта», диләр. Күпне белгән саен, көйсезлекләрне дә күбрәк күрәсең, барысына да йөрәк әрни.

Ләкин, тукта... Бусы нәрсә соң? Артык катлаулы картина түгел, фәкать тәрәзә төбенә балчык чүлмәк белән куелган чәчәк бәйләме генә. Менә син алар янына килеп бастың һәм бүрәнә йортның эченнән ачык тәрәзәгә карагандай булдың... Ә тәрәзә төбендә алтынсу, алсу, кызыл роза чәчәкләре. Нәрсәсе белән күңелне кузгатты, аякларны атламас итеп, үзләре каршында бастырып калдырды соң әле алар?

Чәчәкләргә әле күтәрелеп кенә килгән кояш нурлары төшкән. Алар ничектер астанрак яктырталар, күрәсең, бу бүрәнә өй калкулык өстендәдер, бу нурлар яктысында чәчәкләр шундый тере булып тоела ки, бармак белән орынсаң, таҗ яфракларының дымсу, салкынча тыгызлыгы, терелеге сизелер, хуш исе бөркелер шикелле. Күңелдә шигырь юллары уянды:

Баскан эзләреңә мин битемне куям,
Эзләреңнең назын, җылылыгын тоям...

Тукта, нигә мондый сүзләр хәтергә килде соң әле? Таң нурына коенган чәчәкләр бәхет турында сөйли — шуңа. Алар офык артыннан күтәрелеп килгән җәйге кояш яктысында торган саен ныграк, күкрәп ачыла баралар. Гөл керфекләренең бу рәвешле талгын һәм тыелгысыз ачылганын кеше үз гомеренең иң бәхетле минутларында гына тоя ала торгандыр. Фидаяның да андый минутларны кичергәне булды. Әйе, гөлләр белән бергә үз йөрәгенең дә нурга, матурлыкка ачылганын, яшәү тантанасы белән тулганын тойган сәгатьләре бар иде аның да.

— Фидая Госмановна, исәнмесез!

Фидая кинәт айнып киткәндәй булды, борылып карады, кемнеңдер зәңгәр китель кигән түшен күрде, аннары, башын артка ташлап, исәнләшүченең көлемсерәгән йөзенә, кысылган, үчекләү белән тулы

күзләренә карады. Урман хуҗалыгының баш инженеры Гаяров икән.

— Фидая Госмановна, әсез миңа. Баллыболын балалары бәрәңгедә, диган идегез. Басулары мондамы әллә аларның? Тик бәрәңгеләре генә күренми нишләптер,— диган булды ул, як-ягына каранган-дай итенеп.

— Аларга атналар буе басуда ятарга димәгән. Сез дә монда килгәнсез бит әле, агач утыртып йөрмисез.

— Ә мин монда эш белән.— Гаяров Нурхpraванының төкселегенә илтифат итмәде. Һаман елмаюында иде.— Рәссам иптәшләрне күреп сөйләшәсе бар. Безнең бизәкле савыт-саба цехында эшләүче яшь кызларыбызга ярдәм кирәк. Алар рәсемнәрне открыткалардан, китаплардан эзлиләр. Ә безгә өр-яңалары кирәк иде, беркем күрмәгәне! «Ах!» диярлек булсын. Мин менә монда караштырып йөрим әле, кайберләрен кечерәйтеп кашыкларга да, вазаларга да ясап булыр сыман. Менә, мәсәлән, бу чәчәкләр ярыйсы гына бит! Сез ничек уйлыйсыз?

Фидаяның күңелендә ачу кайнады: «Надан! Туң йөрәк! Бу бит... Бу бит... Сандугачтан сыбызгы ясарга маташу белән бер!» Тамакка ачу килеп төелде: Фидая, Гаяровка тупас сүз әйтмәс өчен, аркасы белән борылды.

Ләкин теге аңламады. Фидаяның янына басып, иелә төшеп, йөзенә карады:

— Мине генә тыңламаслар, дип куркам, Фидая Госмановна,— диде, һаман көлемсерәп. Аңлап булмый иде: әллә чынлап сөйли, әллә юри үчекли.— Район җитәкчесе буларак, безнең гозерне аларга сез әйтсәгез иде. Югыйсә бит, кемгә нинди бүләк кирәк, районнан һаман йөгереп безгә киләләр! Килегез, пожалыста, ләкин ярдәм дә кирәк бит! Бездә аның осталары җитәрлек, зур вазалар да ясыйлар, маркатри дигәненә дә өйрәнәләр. Тик үрнәген генә ясый белмиләр. Анысына рәссам булу шарт. Әнә, карагыз әле, теге картинаны маркатри белән рәхәтләнеп ясап була бит! Төсләре дә шундыйга бата, коңгырт, күксел дә карасу! Менә моны әйтәм, моны!

Ул, Фидаяның беләгеннән тотып, ирексезләп диярлек, аргы башкарак әйдәде. Кулы кайнар, нык икән.

Ул күрсәткән картинада күксел, яшькелт, коңгырт төсләр белән атлар тасвирланган иде. Җәйге иртә, томан әле таралып кына килә, уртадагы ак айгыр, арт аякларына баскан да, җир тетрәтеп чабарга әзерләнгәнен белдереп, күкләргә ирешерлек итеп кешнәп җибәргән. Ул хәзер офыкка, күтәреләчәк кояшка таба чабачак, башка атларны җир селкетеп, йөрәк җилкетеп, офыкка ургылырга әйди... Аның артында — учак, ялкын телләренә дә атның ярсуы күчкән диярсең, алар да биеккә күтәрелгән һәм, гүяки атның канатлары булып, аның сырты өстендә җилпенә иде.

Көч, гайрәт, яшәү дәрте, хисләр кайнавы, киләчәк гомернең һәм томырылып чабачак юлларның озынлыгы, ә бәлки, чиксезлеге...

— Теге коңгырт учакны алып ташларга кирәк,— дип сөйләнде Гаяров.— Анысы гел артык. Агачтан ясарга катлаулы да. Ә атлары шәп, алары өчен тырышсаң да була...

Аларның картина янында сөйләшеп торганын күреп, Рамилә килде, кыюсыз гына:

— Фикерегезне миңа да әйтерсез, бәлки?— диде.

— Миңа бик ошый, канатлы атлар, канатлы хыяллар, ашкыну һәм гайрәт,— диде Фидая, ашыгып. Ул, Гаяров авызын ачар да, бу нечкә күңелле яшь рәссамның хәтерен калдырырлык берәр сүз әйтеп ташлар, дип курка иде.

Рамиләнең сагаюы шундук юкка чыкты, йөзе ачылды.

— Беләсезме, кайчакта мин тәҗрибә ясыйм шулай,— диде.— Төрле стильдә сынап карыйм үземне. Әгәр сезгә ошый икән, мин бу

картинаны сезгә бүләк итәрмен!

— Аңа әнә теге картина да бик ошый.— диде Гаяров, көлемсерәп, һәм кулы белән роза гөлләренә ишарә ясады.

Рамиләнең тәкъдименнән, аннан да бигрәк Гаяровның әдәпсезлегеннән аптырап калган Фидая авыз ачканчы, тегеләр килешеп тә өлгерделәр.

— Чынлапмы?— диде Рамилә, тагын да рухланып.— Анысы да минем картина. Алайса, мин сезгә анысын бүләк итәрмен.— диде ул. Фидаяга карап.

— Ә бу атлар минем күңелгә бик хуш килгән иде.— диде Гаяров, кәефе кырылгандай, хәтта көрсенүен эченә яшергәндәй итеп. Һәм, инде хәзер ни әйтерсең, дигәндәй, башын кыңгыр салып, күзләрен кысып, Рамиләнең йөзенә текәлде.

— Сез нәрсә?— диде, ниһаять, Фидая.— Күргәзмәне бөтенләй таркатып бетерергә уйлыйсызмы әллә? Алай шаярырга ярамый! Сәнгать әсәре бит алар, бик кыйммәт торалар!

— Арзанмы, кыйммәтме, һәркем үз әсәренә үзе хуҗа.— диде Гаяров, бер дә исә китмичә.— Әгәр автор бүләк итә икән, ихтыяры. Менә хәзер бик әйбәтләп, үз кулы белән: «Калтай урман хуҗалыгына, чын күңелдән».— дип имза куя да, без аны мең рәхмәтләр укып кабул итеп алабыз. Киләчәктә зур иҗади уңышларга ирешергә язсын!

Ул аяк очларына басты, тагын да биегәеп, шактый югарыдагы кадактан рам эленгән бауны ычкындыра башлады.

— Туктагыз, нишләвегез бу!— дип, аның терсәгенә тотынды Фидая. Гаяровның сүзләрендә, кыланмышларында Фидаяны да, Рамиләне дә баласыту ярылып ята, шунысы бигрәк күңелне яралый иде.— Әйт син аңа нygытып, бирмим, диген,— диде ул Рамиләгә борылып.

Рамилә икеләнеп калды:

— Ә нигә.— диде.— Әгәр минем әсәрем кешенең тормышын бизи икән...— Аннары, бераз тынып торды да: — Күргәзмә ябылганны гына көтегез инде,— дип өстәде.

— Мин эгоист түгел, үзем өчен тырышмыйм.— дип, бауны кулыннан ычкындырды Гаяров.— Иҗтимагый интересларны кайгыртам, әсәрегезне күбрәк кеше күрсен, дим!

Рамилә нидер сорамакчы иде, ләкин өлгермәде, аны Каләмгөл чакырып алды — балаларга аңлатма бирергә.

— Сез теге чәчкәләрдән баш тарта күрмәгез.— диде Фидаяга Гаяров һәм, серебез бер булсын, дигәндәй, күз кысып куйды.— Кулга килеп кергәнне ычкындырсак, гөнаһ булыр!

— Бармагыгыз үзегезгә кәкре сезнең дә.— диде аңа Фидая.— Урман хәтле урманнан бер кечкенә бинага түшәм җәярлек такта бирә алмыйсыз, ә монда — бир дә бир!

— Хуҗалык эше шундый ул, Фидая Госмановна.— диде Гаяров, өйрәткәндәй.— Кулдагыны ычкындырмаска, бармакка эләккәнне тартып алырга! Житәкчеләр шулай өйрәтә! Юкса, безне андый эштә тотмыйсыз да сез!

— Минем дә кулым бар, ул да үзенә кирәк якка тарта.— диде Фидая.— Мөмкин булганны больницага алачакмын, ә сез, бай хуҗалык, хакын түләп, сатып алырсыз!

— Һи, ул сезнең больницагыз аякка басканчы, аның әле картина эләрлек стенасы булганчы... күпме гомерләр үтәр!— диде Гаяров, житдиләнеп.— Аңарчы бу картиналар, әллә кайларда кар-яңгыр асларында аунап, череп бетәчәк, идән юарлык киндере дә калмаячак! Анда әле күпме дәвалау аппаратларын шулай алдан ук алдырып әрәм итәчәкләр!

Монысын ул инде бик житди итеп әйтте.

Бу Суташ районы халкы моңарчы рәссамнарсыз ничек яшәгән-

дер, аптырарсың. Каләмгөл килеп, күргәзмәне берәр айга Баллыбалын клубына куюны таләп итә башлады. Алдынгы колхозчыларның портретларын ясатып булмас микән, дип кызыксынды. Ул эш кыйбат торырмы. Таштимеровадан акчасын ничек алырга, бу рәссамнарның кайсысы кешене үзенә охшатып ясый ала икән... Ник дисәң, күрше Җинүче-гә нинди дер рәссам портретлар ясап киткән икән шулай. Акчаны меңәрләп алган, ди. Ә менә кешеләрне ямьсез ясаган.

9

Соңрак, урамга чыгып, җыелышып карточкага төшкәндә, шактый гына ыгы-зыгы булып алды. Каләмгөл рәссамнарны уртага урнаштырды, тирәли балаларны тезде, егетләргә алгы рәттә чүгәләргә кушты. Нурханова Әхмәдуллин белән Рамилә арасына басты.

— Хатын-кызлар чибәр икән монда,— дип пышылдады аның колагына Әхмәдуллин.

— Әйе шул, безнең район халкы гомумән бик чибәр, берәр кая йөреп кайтсам, мин үзем дә аны нык сизәм,— диде Фидая.

— Кызларны матур итеп киендерергә иде,— диде Рамилә.

— Нишлисең, кибеттән алган курткалар бит инде,— диде Фидая көрсенеп.— Без, гомумән, кешеләрне матур киендерә белмибез шул әле.

— Зиләйлә, Зиләйлә, кил монда!— диде кинәт, кычкырып, кырыйдарак баскан бер кыз.— Кил, менә монда сыясың!

Барысы да борылып карадылар. Озын буйлы, төз сынлы бер кыз, эре, салмак атлап, урамга таба китеп бара иде. Тавышка ул сискәнеп китте, чак кына борыла төшеп, маңгай астыннан төркемгә карады. Хәер, төркемгә түгел, аның борынгы Мисыр рәсемнәрендәге кебек чигәләренә озынчалап үелгән күзләре төркем каршында фотоаппарат җайлаштырып азапланган Каләмгөл белән Заремага ук атты кебек. Теле белән җавап бирмәде, урамга таба китте. Аның капчык кебек турыдан тегелгән, алай да сынының төзлеген яшерә алмаган кызыл курткасы аша да нәфрәт саркып чыга иде сыман.

— Кем ул?— дип сорады Рамилә Фидаядан.

— Укучы, сигезенче класстан.

Карточкага төшү мәшәкате тәгәлләнеп, балалар автобуска утыра башлагач, теге кыз, ишектән башын сузып, тагын кычкырды:

— Зиләйлә! Кил тизрәк, китәбез бит!

Кызыл курткалы кыз клуб почмагы артына гына ышыкланып торган булса кирәк, әкрен генә чыгып килә иде. Ул автобуска таба адымнарын кызулата башлаган иде инде. Шулчак каршыдагы китап кибетеннән кулына юка китаплар — нәниләр өчен булса кирәк — тотып, кыска плащ, күн фуражка кигән утыз бишләр тирәсендәге бер ир кеше килеп чыкты. Аны күрүгә, Зиләйлә барган җирендә сөртенгәндәй булды, тукталып калды. йөзенең бурлаттай кызарынганы еракган ук күренде. Культура йортының ишеге төбендә рәссамнар белән көлә-көлә нидер сөйләшеп, куллар биреп хушлашып торган Каләмгөл, китап тоткан ир кешене күргәч, аңа таба юнәлде:

— Гыйззетдин, без китәбез? Әшеңне тәгәлләгән булсаң, әйдә, утыр!

Зиләйләгә таба атлый башлаган ир кеше тукталып, югалып калды. Алар бер мәл шулай ачыклыкта, күп кешенең күз алдында өчесе өч якта аптырагандай басып тордылар. Машинага таба юнәлгән Фидая белән Рамиләнең юлы алар арасыннан үтә иде: алар да, моны яхшысынмый, туктадылар.

Зиләйлә Гыйззетдингә аркасы белән борылды. Каләмгөл беренче булып хәлне аңлап алды һәм чарасын да тапты:

— Әйдәгез, әйдә, утырасы кешеләр утырыгыз тизрәк!— диде. Бу чакыру Зиләйләгә дә, Гыйззетдингә дә кагыла иде кебек. Кыз бо-

рылмады, кире китте. Гыйззетдин исә аның артыннан карап калды. Ләкин алай озак басып торып булмый: инде балалар автобуска кереп урнашкан. Каләмгөл дә алгы утыргычта утыра, тәрәзә аша Гыйззетдингә кулын болгый иде.

Гыйззетдин китапларны кулына учлап йомарлады, көрсенде. аның киң, туры иңбашлары бераз иңеп китте сыман, башы иелде. Ул кемдер кулыннан тотып мәҗбүр иткәндәй, авыр адымнар белән автобус ишегенә юнәлде.

Ул алгы утыргычка Каләмгөл белән янәшә утырды, автобус борылып китеп барганда, күршесенең чәчәкле шәле аша үрелеп урамга, кызыл курткалы Зиләйләгә карады.

— Алар бер-берсенә шулкадәр охшаган,— диде Рамилә.— Әтиле-кызлы төсле. Алар әтиле-кызлы, шулай бит?

...Зиләйлә, автобуста утырганнарның күз карашыннан котылырга теләп, Нурханованың «Газигы» ышыгынарак барып баскан иде.

— Әй, кызый,— дип дәште аңа машина эченнән башын сузып, Балкыш.— Баллыболыннан бит әле сез?

— Баллыболыннан,— диде Зиләйлә.

— Юл ничегрәк анда? Батып ятмадыгызмы килгәндә?

Зиләйлә, таралган зиһенен җыя алмыйча, аңламыйчарак торды. Бераздан гына:

— Бер җирдә баттык,— диде.

— Этеп чыгардыгызмы?

— Малайлар төшеп этеште.

— Ә сез төшмәдегездәме? Малайлар эткәндә утырып тордыгызмы?

Кыз егеткә бик сынап, хәтта яшерен әрнү белән тутырып карады. Аның тулы иреннәре елагандай җилсенгән, яңакларына эчтән ут бәреп чыккан — гомумән, ул бу минутта бик хәсрәтле дә, ифрат чибәр дә иде.

Машина янына Нурханова белән рәссам хатын килделәр.

— Зиләйлә, әниең нишләп ята анда?— дип сорады Нурханова.

— Эшли.

— Район больницасына килгәлиме?

— Килә. Көн аралаш диярлек.

— Нишләп миңа керми икән соң? Әйт әле, кереп чыксын бер. Сөйләшәсе бар иде.

Кыз дәшмәде.

— Синең Суташта ул-бу йомышың юктыр бит?— дип сорады, машина ишеген ачканда, сүз арасында сөйләгәндәй гади генә итеп Нурханова.

— Юк.

— Алайса, утыр әйдә безнең белән. Балкыш абыең хәзер безне илтеп куяр да, аннары сине юлга чыгарып, берәр машинага утыртып җибәрер.

— Авылына хәтле илтеп куйыйммы әллә?— дип көлемсерәде Балкыш.

— Анысын үзең кара,— диде Нурханова, бер дә исе китмичә, һәм алгы утыргычка кереп утырды.— Мин хәзер сине бөтенләйгә җибәрәм. Шарты шул гына: бу кыз караңгы төшкәнче өенә кайтып җиткән булсын.

Арткы утыргычка Зиләйлә белән Рамилә утырдылар. Нурханова сөйләшә-сөйләшә культура йортыннан урамга таба килгән Гаяров белән Әхмәдуллинны күреп алды. Алар Фидаяга түгел, читкә караганнар, шул ук вакытта йөзләрендә ниндидер ясалмалык сизелә иде. «Минем хакта сөйләшәләр,— дип уйлады Фидая.— Үзләрен өстен куеп, мине кимсетеп фикер йөртәләр, мөгаен. Татар ирләренең шул булыр инде».

Өенә кайтып җиткәнче — ә ара кыска иде — ул бу хакта уйлан-

ды. Әнә бит бер-берсенә бөтенләй охшамаган, ят кешеләр, беренче тапкыр очрашулары. Берсе кырыктан узган, икенчесе утызга да житмәгән: берсе төптән юан, урта буйлы, икенчесе нечкә билле, озын; берсе — шәһәрдән, икенчесе — авылдан, берсе — сәнгать әһеле, икенчесе — жир кешесе. Әгәр шундый ике хатын-кыз очрашсалар, сүз таба алмас иделәр. Ә боларга сүз әзер — Нурхановаиы тикшерү. Шулай итеп җай гына телләрен чишеп җибәрерләр дә, аннары бераздан сүзнең кирәгенә, эшкә күчәрләр.

Фидая үзалдына елмаеп куйды: «Сөйләсеннәр әйдә! Эшләре генә уң булсын!»

...Ә алар, чыннан да, Нурханова хакында сөйләшәләр иде.

— Гаҗәеп хатын бу сезнең урынбасарыгыз,— диде Әхмәдуллин.

— Ә нәрсәсе гаҗәп аның? Зур урынга үрмәләгән чәчбиләр әзмени хәзер?

— Бусы гадәти чәчби түгел. Ул ике кешедән тора кебек. Бер карыйсың, чибәр, ягымлы, йомшак сүзле хатын. Икенче карыйсың — нык куллы, кырыс җитәкче...

— Төрлечә кыланып карый инде, тырыша,— диде Давыт, исе китми генә.— Башына төшкәч, нишләсен, булдыра алмаса да, көчәнә. Бичара,— дип куйды аннары.— Карап торышка да ярты кеше генә бит үзе.

— Акылсыз түгел ул,— дип каршы төште Әхмәдуллин.— Безнең бүтән районнарда да булгалаган бар, әшне Нурханова кебек тиз, җайлы оештыручы, акыллы хәл кылучы сирәк очрый.

— Ошаган инде ул сезнең күңелгә, бик хуш килгән,— дип, кулын селкеде Гаяров.— Ә менә мин мөрәҗәгать иткәч, юк кына мәсьәләне дә хәл кыла алмады. Шунысы кызык: нинди апарада күпереп, шушылай калкып чыга икән моның ише хатыннар? Кем күтәрә икән аларны? Шул чибәрлекләре аркасындадыр инде, бер дә бүтән түгел!

## 10

Сүташ елгасы аша биек күпердән чыккач, зират турыннан узып, үргә менгәч, Балкыш машинаны туктатты. Зиләйлә сүзсез генә ишекне ачты, җиргә төште. Ишетелер-ишетелмәс кенә рәхмәт әйтеп, Балкышны һәм машинаны шундук оныткандай, юл читенә чыгып басты. Балкыш машинасын борды: бассын да торсын шунда, бәби түгел, җиткән кыз, үткән-сүткән машиналарга үзе дә кул күтәрерлек. Мондый кызларга шоферлар да игътибарлы була, саз чәчрәтеп выжылдатып узып китмиләр, аяклары үзләреннән-үзләре тормозга баса.

Ләкин Балкыш җиңел генә китә алмады, тукталды, башын сузып, Зиләйләгә карады, кыз, кызыл курткасы белән кара җир фонында кызыл тап булып басып тора, тик бу тап нигәдер бик ямансу, әйтерсең лә аңа йөрәк ярасының төсе чыккан иде. Балкыш «Газик»ын кире борып китерде, ишеген ачып:

— Утыр,— диде.

— Кирәкми,— диде кыз, киреләнеп. Ул Балкышка түгел, каядыр читкә, зираттагы биек өянкеләрнең әле коелмаган яфракларына караган иде.

— Нәрсә сырланып маташкан буласың?— диде Балкыш, кызып.— Узгынчы шоферлардан кимме әллә мин?

— Синә юл уңае түгел лә.

— Ә син каян беләсең минем юлны? Үзеңне бел. Утыр, әйдә.

Кузгалып киткәч, Балкыш аңлатуны кирәк тапты:

— Минем бер дусны сезнең авылга бәрәңге алырга җибәргәннәр иде. Машинасы белән. Хәлен белеп кайтасы бар. Ватылып ят-

мый микән. Сагындым да...
Ул, сүзенең ярымшаяру икәнен сиздереп, җырлап та куйган булды: «Бик күрәсе килә, күрәсе-е-е...»
Кызның күңелен күтәреп, телен ачасы, сүз үрчетеп, юлны кыскартасы килгән иде. Әмма кыз тешләк булып чыкты, сүзне җәпләмәде. Ул, гомумән, арткы утыргычта тынып калды. Балкыш, каршындагы кечкенә көзгене боргалап, аның йөзен карамакчы иде. Әмма теге утыргыч аркасына таянган да, башын беләгенә салган. Йөзе күренми, тик иңбашлары сулкылдагандай тетрәнеп куйгандай булды. Әллә елый инде? Балкыш чүпрәк алып, тәрәзәләргә сарган парны сөрткәләде. Әллә кыз елаганга парлана инде бу пыялалар.
Кыскасы, юл Балкыш өчен шактый күңелсез булып чыкты һәм озын тоелды. Алар авылга кергәндә, караңгы төшкән иде инде. Урам юлы сикәлтәле, көйсез иде, тизлекне еш алыштыра-алыштыра шактый озак барырга туры килде.
Ниһаять, кыз:
— Мин кайтып җиттем,— диде.
Машина фаралары капка өстенә кагылган «Медпункт» дигән язуны яктырттылар.
— Медпункт ич бу,— диде Балкыш.
— Мин шушында торам.
— Нишләп алай?
— Әнием фельдшер минем.
— Бөтен утларны кабызган, сине көтә инде алайса.
— Аның кабул итү сәгате, кеше күптер. Басуда суык тигерәләр.
Зиләйлә ашыкмый гына машинадан төшә башлады.
— Кайсы-берсе юри дә чирләгәнгә сабышадыр инде,— диде Балкыш.— Справка аласылары киләдер.
— Безнең әнинең андый түгел икәнен беләләр,— диде кыз тыныч кына.
— Нинди түгел икәнен?
— Алдашмаганын.
Ул рәхмәт әйтеп, саубуллашты да, капкага юнәлде. Фара яктысында, урам уртасыннан капкага таба салынган биек юлдан атлап китте.
— Әй, кызый!
Фара яктысында кызның һәр хәрәкәте бик нык күзгә ташлана иде: нинди горур, дәрәҗәсен белеп һәм нәфис хәрәкәт белән борылып карады ул, махсус өйрәнгән диярсең!
— Күздән чүп ала беләсеңме син?
Зиләйлә фара яктысыннан бер адым читкә атлады, аның күзләре йолдыз төшкән күл төсле иде.
— Беләм,— диде ул.
— Нәрсә белән аласың?
— Гадәттәгечә, марля белән.
— Ә минә минем әби теле белән ала. Син дә шулай өйрән, ярме!
— Мин болай да әйбәт алам. Әни өйрәтте.
— Ә син телең белән алырга өйрән. Алай җайлырак. Шуны өйрәнеп куйсаң, күзгә чүп кергән саен синең янга килермен.
Шулай диде дә машинасын кире бора башлады Балкыш. Тизлекне күчергән арада, кызның тавышы ишетелеп калды:
— Әбиеңә сәлам әйт!
Кара син аны, тешле икән! Сөйләштереп булмады чукынганны, тешләрен күреп булмады. Алары ничек икән? Хәер, бераүнең дә бөтен җире килеп бетми, моның, мөгаен, тешләре ямьсездер. Һаман-һаман турсаюы да авызын ачмас өчен түгел микән әле!
Балкыш кайтырга борылгач, машина каршына бала күтәргән ир кеше килеп чыкты. Бала, фара яктысыннан күзләрен йомеп,

этисенең муенына сарылды, ир кеше дә башын читкә борды. Шулай да Балкыш анның йөзендә, кыяфәтендә чагылган тынычлыкны, бала кочаклаганда гына була торган бәхетне күреп алды.

Балкыш аны таныды: район үзәгендә кулына китапчыклар тотып Зиләйләгә каршы килеп чыккан, аны барыр юлыннан туктаткан кеше иде бу.

## 11

Бу кичнең җиткәнен, Фидаяның эше бетеп, Иркәнең йокыга киткәнен көтеп алды Рамилә. Аның тизрәк Нурханова кыйссасының дәвамын ишетәсе килә иде.

Ул зал ишеге янына барып басканда, Фидая нәкъ кичәге кебек диванда утыра, сары абажурлы лампа аны нәкъ кичәгечә серле дә, нәфис тә итеп күрсәтә, кулында шул ук зәңгәр тышлы китап.

Рамилә аның янына барып утырды да, шигырь юлларын исенә төшереп:

— «Өстә дулкын, аста упкын»,— диде.— Мәхәббәт турында язылган сүзләрдер бу...

Фидая дәшмәде. Ачылып серләр сөйләргә күңел кыллары көйләнмәгән иде әле, ахрысы. Әнә бит, китапны ачып укырга да ашыкмый. Менә ул башын артка ташлады да Рамиләгә сынап карады:

— Ә син үзең мәхәббәт турында нәрсә беләсең соң? Кияүгә чыкмагансыңдыр бит әле?

Рамилә, әгәр үзе хакында сөйләмәсә, хуҗаның теле ачылмаячагын сизде.

— Мин иртә кияүгә чыктым,— диде.— Сәнгать училищесында укыганда ук.

— Гыйшкың кайнар булган, димәк?

— Гыйшык хикмәтен аңлап түгел. Казан кызы бит мин. Үги әти белән үстем. Бәләкәйдән кыйналдым. Тизрәк өйдән чыгып китәсе, котыласы килде. Танцыда танышкан бер егет белән күпмедер очрашып йөрдек тә, ул, әйдә өйләнешәбез, дигәч, риза булдым. Үз йортлары белән яшиләр, иркен, безгә аерым бүлмә бирделәр...

— Озак тордыгызмы соң?

— Ә сез... каян белдегез безнең аерылышканны?

Фидая тирән итеп көрсенде.

— Күңелең эремәгән булган синең. Ә таш күңел гыйшык тәмен беләме?

Рамилә карашын яшерде.

— Сигез ай тордык. Аннары аны армиягә алдылар. Инде күнегеп беткән идем, сагынып көтәрмен дип уйлаган идем.

— Әмма тиз оныткансыңдыр,— дип аның сүзен ялгады Фидая.

— Ул кайтканчы аларда яшәдем. Кайтты. Бөтенләй ят кеше булып. Кояшта янып каралган, тазарган. Футбол тубы кебек. Ә мин аны ак, нәфис итеп хәтерли идем. Ят кешене янымa җибәрә алмадым.

— Мөгаен, бүтәнгә күңелең төшкән булгандыр.

Рамилә сискәнеп китте.

— Сезнең белән сөйләшү кыен. Бу хакта мин үзем уйларга да куркам. Ул рәссам. Талантлы... Тагын ни әйтим? Картина итеп ясап бирсәм генә. Сөйли белмим.

— Ә ул беләме синең яратканыңны?

— Юк-юк... Уйламый да.. Бирегә дә аннан качып килдем. Мин әле иремнән законлы аерылышмаган бит. Дөрес, аларда яшәмим инде, фатирга чыктым... Белмим, ничек яшәрмен...

Фидая башын иеп уйланып утырды да:

— Беләсеңме, — диде. — Миңа синең ирең кызганыч. Ул сине яраткандыр бит?.. Шул-шул менә. Әгәр хисләр уртак булмаса, мәхәббәтнең бер кадере дә юк. Әрәм яну, әрәм өзгәләнү, йөрәкнең әрәмгә телгәләнүе. Әйе, кайчакларда хатын-кыз ир-егетләрдән көчлерәк була. Нәкъ менә шул хисләр мәсьәләсендә. Шунда без үзебезнең шәфкатьсезлегебезне, аяусызлыгыбызны күрсәтәбез дә инде. Минем дә бар иде шундый каты бәгырьле чакларым. Егетләрне елаткан вакытларым бар иде...

Һәм ул, ачылып китеп, өзелгән кыйссасын дәвам итте.

— Укырга керә алмыйча кире кайтуга, мин ронога бардым, — дип башлады ул. — Баллыболын мәктәбенә пионервожатый итеп билгеләделәр. Эссе көн иде, мин ак күлмәктән, кулымда сумкафәлән дә юк, акча белән кульъяулыкны бөрмәле җиң эченә генә кыстырып куйган. Ронодан алган направление кәгазен, бөгәрләнмәсен дип, түгәрәкләп тереп тоттым. Юл уңаеннан культмагка кердем: янәсе, пионер эшенә кирәкле әйбер-караны караштырып чыгам. Киштәләргә текәлеп тора идем, кинәт теге кәгазем кулымнан шуып чыгып китте. Кысып тотып булмый, бөгәрләнә. Күтәрелеп карасам, янымда озын буйлы бер егет басып тора. Кәгазьне ачып укыды да бу:

— Карале, сине минем урынга җибәреләр икән бит! — диде. — Узган ел мин эшләдем анда!

Баштан кичкән хәлләрдән соң егетләргә мөнәсәбәтемне аңлыйсыңдыр инде. Кәгаземне кулыннан тартып алдым да, борылып, кибеттән чыгып киттем.

Мин Баллыболында эшли башлауга, мотоциклга утырып Ваккас килеп йөри башлады. Ул тракторчы булып эшли башлаган иде. Элекке үпкәләр онытылды кебек, бик ачылып китмәсәм дә, дорфа кыланмыйм. Чөнки кич клубка ул килеп йөри башлагач, ят авылда, чит кешеләр арасында ничектер дәрәҗәм күтәрелеп китә иде шикелле.

Югыйсә, мәктәптә эшләрем баштарак авырлык белән барды. Балалар миңа тиз генә ияләшеп китә алмадылар, аларның һаман: «Ә Мәгъсүм абый болай итә торган иде», «Ә Мәгъсүм абый белән без...» — дип сөйләнүләре эчне пошыра, кулдан эшне төшерә иде.

Мәгъсүм дигәне теге кибеттә мин кулыннан кәгазьне тартып алган озын буйлы егет иде бит. Бер шимбәдә, дәресләр тәмамлануга, аның велосипедка атланып мәктәп капкасы төбенә килеп туктаганын күргәч, минем кәеф нык кырылды. Укучыларымның, укытучыларның йөгерешеп килеп аны уратып алганнарын күргәч, бигрәк тә. Бөтенесеннән читтә берүзең калу да килешми, мин башкаларга иярдем, ишектән чыгып, капкага таба бер-ике адым атладым.

Шунда ул балалар төркеме аша миңа карап алды. Бик тиз генә керфекләрен сирпеде. Шул арада миңа бер нәрсә аңлашылды: ул монда балаларны сагынып түгел, мине күрер өчен килгән икән.

Мин якын килмәскә, сүз кушмаска карар кылдым, кыяфәтемдә бу чагылды бугай, аның йөзе үзгәрде, моңсуланды. Чыркылдашкан балалар һәм бер-берсен бүлешеп сөйләшкән, хәл-әхвәл сорашкан укытучылар төркеме аша без менә шулай аңлаштык: «Сине күрергә килдем, нихәлләрең бар?» — «Йөрисең калмаган. Синең миңа кирәгең юк!»

Ә башкалар берни сизмәде.

— Мәгъсүм абый, ник баяныңны алып килмәдең?

— И шунда бер җыелып, җырлап-биеп алган булыр идек!

— Син киткәннән бирле күңелле итеп уйнап алганыбыз да юк!

— Магнитофон калай бит ул, синең баянга җитәмени!

Бөтенесе мөкиббән иде аның үзенә, елтыр тәгәрмәчле велосипедына, өендә калдырган баянына. Бөтенесе, ләкин мин түгел. Төркемне

читләтеп әйләнеп үттем дә, фатирыма кайтып киттем. Мин авыл очындарак, Наилә исемле бер апада яши идем. Кайтып чәй эчеп утыра идем, кемдер тәрәзәгә чирттемени, үрелеп урам якка карадым. Нәкъ шулвакыт велосипедына атланып теге Мәгъсүм үтеп бара иде. Турыбызга җиткәч кенә, велосипедына нидер булды, янтаеп китте, ул, төшеп, тәгәрмәчен караштырырга кереште. Мин, пәрдә артына яшеренеп, аңа бик җентекләп карадым. Көлсу, туры чәчләре маңгаена сибелеп тора, ул аларны уң кул аркасы белән еш кына төзәтеп куя. Беләкләре таза, гәүдәсе нык, җилкәләре киң. Ә менә йөзе... Йомры иякле, күперенке иренле йөзендә сабый кыяфәте бар иде аның. «Бөтенләй бала-чага төсле бит бу»,— дип уйладым әле мин ул чакта.

Шуннан соң кичләрен Баллыболын юлында ике яктан ике егет тузан куптара торган булып киттеләр: Үзәнтаудан мотоциклга атланып — Ваккас, Суаштан велосипед белән — Мәгъсүм. Юллар ике тарафтан килеп, авыл очында берләшә, егетләр очраша, очрашулар куанычлы дип әйтеп булмый. Һәрхәлдә, Мәгъсүмнең велосипед тәгәрмәчләре тишелгән чаклар булды, дип сөйлиләр. Тик миңа егетләрнең берсе дә бу хакта әйтмәде.

Миңа исә егетләрнең берсе дә кирәкми кебек, киләчәккә корып куйган зур планнарымда аларга урын юк иде. Ә шулай да... Күңел бит ул һәрчакта да акылга буйсынмый. Минем дә талпынып куйган чакларым булмады түгел. Яшьлек үзенекен итә.

Хәтеремдә: җир каткан, ә кар төшмәгән иде әле, ял кичен мин аңлашылмас бер талпыну, дәрт белән көтеп алдым. Ни утырып, ни басып тора алмыйм, дигәндәй, аяклар үзеннән-үзе тыпырдый. Шулай йөгерә-йөгерә инеш ярындагы чишмәдән су ташыдым. Ул елларда урамда колонкалар юк иде әле. Наилә апа әйтә: «Җитте инде сиңа, мунча савытларын тутырып куймасаң да ярый, төнлә нык суытып, сулар катып, чиләкләрнең төбе төшмәсен тагын», — ди. Ә мин көләм, миңа бәйрәм, яшьлекнең сәбәпсез-вакытсыз бәйрәме...

Клубта да гел уртада бөтерелдем ул кичне. Мәгъсүм түрдә, сәхнә буенда баян уйный, Ваккас ишек төбендә басып тора — ике егет ике яктан күз карашларының яктысын кисештереп, мине яктыртkandай итәләр. Мәгъсүм сабыр, сиздерми, ул монда үз авылындагы кебек, иркенләп утырган, кадерле, кирәк кеше. Ә Ваккасның чырае караңгыланганнан-караңгылана: ул биредә килмешәк, өстәвенә, минем башка егетләр белән биеп йөрүемә ачуы килә моның. Баштарак бу икәүне үртәү-үчекләү миңа кызык сыман тоелган иде. Ләкин тора-бара кәефем кырыла башлады. Әдәпсез, ямьсез тотам шикелле тоелды үземне. Яхшы түгел иде болай кылану...

Кичә беткәнен көтмәдем, алданрак чыгып киттем. Бераз баруга, артымнан Ваккас куып җитте, беләгемнән тотып алды. Мин аның кулы каты дип хәтерли идем, ә бу юлы кыюсыз, йомшак тотынды ул миңа.

Егетләрнең көчсезлеге, кыюсызлыгы кызларны тәкәббер итә. Мин эре-эре атлап барам, ул минем адымнарыма яраша. Кулымны тартып алып, китеп кенә барыр идем, артык дорфаланырга ярамаганын аңлыйм: Ваккас армиягә китә, хушлашырга килгән иде.

Аяк астында боз шытырдап торган, зыңгылдаган кич иде бу. Күктә йолдызлар сибелгән, тулган ай ап-якты да, шул ук вакытта салкын да, җирнең, күңелнең җылысын суыра иде сыман.

Ул нидер әйтте микән, сөйләшкәнебезне хәтерләмим. Болай да хәлләр мәгълүм иде: ул китә, мин калам, ул минем аны сагынып көтүемне тели, шул ук вакытта минем көтмәячәгемне дә белә, үзенең чарасызлыгын аңлый, бу чарасызлык аның йөрәген хәлсезләндерә иде. Моннан соң инде ул минем янга килеп йөргән егетнең велосипед тәгәрмәчен дә тишә алмаячак.

Наилә апалар янәшәсендә урамда бура тора иде. Шул бура күләгәсенә кергәч, Ваккас мине сак кына тартып туктатты.

— Хуш инде, Фидая, — диде. — Мин китәм.

— Исән йөреп, сау кайтырга язсын.

Ул чакта мин, шул чор яшьләренә хас булганча, кешене кызганырга ярамый, кызгану кимсетә, дип исәпли идем. Кешене ихтирам итәргә кирәк, кызганырга түгел! Бу — минем өчен тайпылышсыз кагыйдә булып тора иде. Һәр тайпылышсыз һәм искәрмәсез кагыйдәнең, гәрчә ул бик дөрес булса да, шоферсыз гына, юлдан туры җибәрелгән машинага тиң булуын, очраганнарны изеп китүен белми идем шул әле мин.

Кул биреп саубуллаштым да кереп киттем мин өйгә. Утны яндырып тормыйча, Наилә апаның йокысын бүлмәскә тырышып, мыштым гына өс-башымны алыштырдым: резин итек, куртка кидем, башыма шәл урадым, тәрәзәдән карап тордым бераз: алай-болай Ваккас китә алмыйча тормыймы, очрашмыйк тагын, дип. Ул төнне мин сарык фермасына барырга тиеш идем, сарыклар бәränләр чак җитә, терлекчеләргә ярдәмгә агитаторлар чират буенча фермада төнге дежур тору оештырганнар иде.

Урамда кеше-кара күренмәде. Ләкин Ваккас китеп өлгермәгән булып чыкты. Бура турыннан узганда, күләгәдә күреп алдым мин аны. Бүрәнәләргә капланып елый иде ул. Капка ачылганны, минем адымнарны ишеткәч, нигә китеп бармаган ул, нигә ичмасам тураеп басып, күз яшьләрен сөртмәгән, елаганын ник яшермәгән?

Ә бәлки, ул шуңарчы өмет белән яшәгәндер дә, шул кичтә мин аның бөтен өметләрен җимергәнмендер. Гыйшык хәсрәте — хәсрәтләрнең иң ачысы, диләр бит. Башыннан узганнар гына белә, аны җиңеләйтү чарасы юк, диләр. Шул чарасызлык изгәндер аны, көчсезлеге хәлен алгандыр. Ә бәлки, минем кире чыгасымны күңеле сизгәндер, кызганыр, дип өметләнгәндер...

Кызганмадым. Кулдәвекләр өстенә каткан бозларны шытырдатып вата-вата турыннан узып киттем, дәшмәдем.

Фидая тынып калды, зәңгәр тышлы китапны актарды, гүяки ул шигырьләрдән үзен борчыган бер сорауга: «Шул чакта дөрес эшләдемме мин?» — дигән сорауга җавап эзли иде.

— Шуннан? — дип сорады Рамилә.

Әкрен генә сорады, чөнки үзе дә аңлый: егет юкка еламаган, бу — мәхәббәтнең ахыры булган...

— Мин аның бөтен тормышын җимердем. Аңламыйча, уйламыйча. Ләкин аңламау, уйламау — кешене аклыймыни?

— Мәхәббәткә мәхәббәт белән җавап биреп кенә кешене бәхетле итеп була бит, — диде Рамилә көрсенеп. — Сезнең гаеп юк монда. Ул да бит үз тиңен табып, бәхетле була ала иде.

Фидая тагын дәшмәде.

— Сез дә үз тиңегезне табарга тиеш идегез... — Рамилә кыйссаның дәвамын ишетергә тели, иң кызыгы әйтелмәгәнен аңлый иде.

Кинәт сискәндереп телефон зыңгылдый башлады. Фидая бүлмәдән чыгып, трубканы алды, аның хәвефле тавышы ишетелде:

— Кайда яна? Кайчаннан?

## 12

Суташтан чыгып, зират үрен менүгә, алда, офыкта шомлы кызыллык уйнаганы күренде. Барган саен ул биеккә үрли, салмак кына, әмма эчке куәт белән бер көчәя, бер сүрелебрәк торгандай итә, болытларны эчтән яктырткан кебек тоела иде. Ярты юлны

узгач, алдагы дәһшәтне көчәйтеп, көчле шартлау болытлы күкне тетрәндергәндәй итте.

— Газ баллоны шартлаган, — диде Балкыш теш арасыннан. — Өйләренең көле күккә очты.

Авылның таныш урамы хәвеф-хәтәрле, шунлыктан чит тоелды. Машина аргы очка таба ашыгып барган берничә кешене куып узды. Кайсының кулында чиләк, кайсы балта йә багор тоткан, машинага юл күрсәткәндәй, кулларын болгап калдылар. Болай да әллә каян, өй түбәләре өстеннән балкып күренеп тора: янгын югары очта, аръякта котыра иде. «Гыйззетдиннәр түгелме?» — диде Фидая, чамалап.

Арттан сиреналар улаганы ишетелде: район үзәгеннән янгын сүндерү машиналары килә иде. Фидая Балкышка, юл читенә чыгып, аларны уздырып җибәрергә кушты. Махсус машиналар, түбәләрендәге шәмәхә утларны елкылдатып, күңелдәге шомны тагын да арттырып, шул ук вакытта ниндидер ышаныч та биреп, гөрләп узып киттеләр.

Фидаялар барып җиткәндә, каска кигән ирләр сыгылмалы юан көпшәләрне суза башлаганнар иде инде. Алар көн үзәгендәгедәй якты урамда ыгы-зыгы килгән халыкка каты кычкырындылар:

— Читкәрәк! Якын килмәгез! Ераграк!

Алар кычкырынмаса да, якын килерлек түгел! Кая! Нисаның йорты урынында җәһәннәм уты булып коточкыч зур учак дөрли, ялкынын болытларга сиптерә, тирә-якта утлы кисәүләр оча. Ике якта ике йорт дөрләп яна: берсе Гыйззетдиннеке, икенчесе Фаязлар йорты. Арттарак, кечерәк учаклар булып, каралты-кура яна. Бу дәһшәт янәшәсендә, чиләк, багор, балта тотып, нәрсәдер эшләргә маташучылар бик кечкенә, көчсез булып тоела, табигатьнең аяусыз, шәфкатьсез кодрәте каршында кешеләрнең никадәр чарасыз, хәлсез икәнлеге бу яктылыкта аермачык күренә иде. Кемнәрдер кычкырынган, ярсыган сыерларны, сарыкларны, каңгылдашкан казларны читкә куа, кемнәрдер янәшә өйләрнең ишек-тәрәзәләреннән әйбер-кара ташый, инеш ярындагы тупыллар арасында, өеп куелган мендәр, юрган, тәртипсез ташланган киемнәр өстендә бала-чага утыра, аларның әсәренгән күзләрендә, кызарынган йөзләрендә ут уйнаганы чагыла.

Фидаяга игътибар итүче булмады, ул да бу мәхшәрдә ни чара кылырга белми аптырап калды. Ләкин шунда кемнеңдер, битенбашын бишмәт белән урап, тәрәзәләреннән ут ургыган Фаязлар йортына таба йөгереп киткәнен күреп алды.

— Кая? Кая керәсең?

Яначак! Һәлак булачак! Фидая кычкырып аны туктатмакчы булды, ләкин утның гөрелдәве, машиналарның гүләве, кешеләрнең кычкырышуы кушылган тоташ шау-шуда аның нечкә тавышы ишетелерлек түгел иде. Ул иңеннән күн пальтосын сыдырып алды, аны калкан кебек алгарак сузды, чөнки битнең, кулның пешүенә чыдап булырлык түгел иде. Теге тилене туктатырга, алып чыгарга... Күн пальто кулларны пешерде, эссе һава тынга капты, чәч яна башлады бугай... Ул соңгы көчен җыеп талпынды һәм ишектән керә башлаган теге кешене көч белән күлмәгеннән тотып артка тартты:

— Чиген!

Соңыннан бу мизгелне исенә төшергәндә, Фидая үзенең кылганына үзе ышанмады. Юктыр, алыптай гәүдәле бу кеше ул артка тартканга түгел, ә бәлки, ниһаять, аңына килеп кире чигенгәндер.

Алар, ялкынга уралып, тупыллар арасына йөгереп килделәр. Фидая пальтосын җиргә салып таптарга кереште, ир кеше ятып аунап китте. Фидая шунда гына танып алды: бу Фаяз үзе иде. Алар янына Мөнирә йөгереп килеп җитте, кулындагы чемоданыннан нәрсәләрдер чыгара башлады.

Башта Фидаяның битенә нидер сөртте, аның бармаклары салкынча һәм назлы иде, бу дәһшәтле, акылдан шашкан дөньяда аларның орынуы гаҗәп тоелды, ярсыган күңелне тынычландырып җибәрде. Мөнирә Фаязның кулын ак бинт белән урый башлады, үзе:

— Тукта, сабыр, ашыкма, — дип сөйләнә иде. — Кулың исән булсын, үзең исән бул, калганы табылыр...

Гаҗәп, аның әкрен тавышы тирә-юньдәге шау-шу аркылы да күңелгә үтеп керә, урыныннан купкан дөньяны үз эзенә сала кебек иде.

Фаяз утка карап тора, болай да кызыл йөзе комач кебек булган, маңгай өстендәге җирән чәче көеп каралган. Менә ул башын арткарак ташлады да, ак таза тешләрен елкылдатып, шаркылдап көләргә кереште.

— Ха-ха-ха! Ха-ха-ха!

Фидая аның иңенә орынды:

— Бик кызыкмыни, Фаяз абый?

Фаяз Мөнирәдән кулын тартып алды, бинт сүтелеп, сузылып төште.

— Әнә, күр, карап кал! — диде Фаяз, кулы белән йортына төбәп. Янгынның бер кырына күптәннән су коя башлаганнар, ә бу якта ялкын үз көченә күтәрелә, колач җитмәслек нарат бүрәнәләр кызарып, утә күренмәле төсле булган, текәлебрәк карасаң, эчтәге әйберләрне күреп булыр сыман тоела иде.

— Күреп калыгыз! Мондыен башка күрмәссез! Түшәменең биеклеге ике дә туксан! Егерме ике ишеге генә бар! Бөтенесен үз кулымнан әллә ничә тапкыр үткәрдем. Менә шушы кулларымнан! Карап калыгыз!

Караңгыдан, агачлар арасыннан Наилә апа килеп чыкты.

— Сабыр итәргә кирәк, Фаяз! Дөнья малы — дуңгыз каны, дигәннәр. Утка керәләр димени! Әнә, Нисаны кара, җәһәннәм эчләрендә калды бит! И, ялгызлык хәлләре, шушы мәхшәр купканны күреп, уятучың да булмасын әле!

— Җә-әл! — дип шаркылдады Фаяз. — Җә-әл, янган!

— Җәл булмаган кая ул! — дип аның сүзен җөпләде Наилә. — Гөл кебек кеше, гөрләтеп яшәр чагында утларда янсын әле!

— Әгәр исән калса, мин аны! Мин аны! Үзем, шушы кулым белән, җәһәннәм утының менә шушысына башы белән илтеп тыккан булыр идем! Бу учакка шул гына җитми! Мәңге онытылмаслык булыр иде! Шулай бит, Фидая, ә!

Фаяз, ниһаять, йөзен Фидаяга борды. Аның чыраендагы дәһшәт, нәфрәт каршындагы ялкын телләренә тиң иде.

Ул арада Гыйззетдиннәр йортыннан да, Фаязның йортыннан да ялкынга үрелеп пар күтәрелә башлады. Янгын сүндерүчеләр үз эшләрен беләләр икән: утның куәте күзгә күренеп кими.

Агачлар арасында бу ыгы-зыгыда да күзгә ташланган бер кеше күренде: шушындый мәхшәрдә үзенең чисталыгын, арулыгын саклаган, түгәрәк ак сакаллы, тәкъвә кыяфәтле, кечкенә гәүдәле Фәтхрахман бабай, өр-яңа чиләген җиргә куеп, аннан намазлык алды да, агач төбенә җәеп, тезләнде һәм, ике учын тезенә куеп, Нисаның өе урынында көйрәп яткан күмер өеменә карап, нәрсәдер укырга кереште. Шунда гына Фидаяның аңына бер хакыйкать барып җитте: Ниса үлгән, утта янып һәлак булган, Фәтхрахман бабай аңа ясин чыга... Чын микәнни, хак микәнни? Ниса шушылай кинәт, мәгънәсез, һич көтелмәгән фаҗигале рәвештә дөнья куйды микәнни? Утта янмас, суда батмас кебек иде бит, югыйсә! Йа алла, авылның бөтен ирләрен дер калтыратып торган гайрәтле кеше шушы кисәүләр астында юкка чыкты микәнни? Шунда гомере киселде микәнни? Ә бит ул рәхәтләнеп үзе өчен яшәмәде дә әле! Гел халык

өчен дип тырышты, колхозны күтәрәм дип тырмашты, тарта алмаслык йөккә җигелде. Мена-мена йөкне кузгатыр, кешеләрне бәхетле итәр, аннары үзе дә тын алыр сыман иде... Бер рәхәт тә күрми үлеп тә китте, бичара!

Әгәр болай буласын белсә, Фидая аны яратмый, өнәми йөрер идемени? Әле генә ничек бәрелештеләр бит алар. Уйлап карасаң, бер дә юкка — теге пар казаны өчен. Әйткәләшеп торасы да калмаган, казанны куптарып, тарантасыңа салып кит теләсәң, диясе калган. Күңеле булсын иде мескеннең соңгы көннәрендә.

Фидаяны үкенечләр биләп алды. Бик ямансу булып китте. Тик шунда аның сагышлы уйларын чабып килгән ат тавышы бүлде. Тарантастан сикереп төшкән ике кешегә ир-ат ташланды:

— Эт җаннар, кайда себерелеп йөрисез сез, ә? Сезнең аркада ничә йорт янды, кеше үлде!

— Нәрсә сез! Без ут төрткәнме әллә? Безне Ниса үзе тыкырдатып алып китте! Сугышыйкмы әллә аның белән!

Ызгыш-талаш, сүгенү катыш сөйләшүдән шул аңлашылды: төнлә Таштимерова янгынчыларга — аталы-уллы Шәвәлиевләргә килгән дә, айгырны җиктереп, үзен Кармаш больницасына илтергә кушкан.

— Нишләп сез бер Нисаны икәүләп ташыйсыз?

— Ул Ниса белән төнге юлга үзем генә чыгыймммы, әллә малайны гына җибәримме?

— Малаең әйбәтрәк булыр иде!

— Үзең дә ярап торыр идең әле караңгыда! Караңгының күзе юк, кармаласа сүзе юк!

Фидая җирдән пальтосын алды да, артка, машинасына таба чигенде. Ирләрнең тавышы бөтен урамга яңгырый иде.

— Буксовать иттеме әллә айгырыгыз? Озак йөргәнсез.

— Больницадан баш врач квартирына җибәрделәр. Анысын алып килгән идек, теге хатыннарны карый торган кенәз Юсуповны алып килергә кушты. Әрле-бирле чаптык шунда, — дип аңлатты Гариф.

— Кенәзе ник кирәк булган тагын?

— Ник булсын? Ниса да хатын лабаса!

— Кит аннан? Әллә шуның белән дә чирттерүче булганмы?

— Алай димә! Нисаның да бар җаны!

— Ха-ха-ха!

Фидаяның күңелен чиркану биләп алды. Ул Балкышны китәргә ашыктырды.

## 13

Фидаяга ашыкмаса да була, кызы янында Рамилә йоклап калган иде. Кайтышлый ул Кармаш больницасына сугылып, Нисаның хәлен белеп чыгарга ниятләде.

Больницада утлар сүндерелгән, тик коридорда бер тонык лампочка яна да, дежур медсестра бүлмәсенең ярым ачык ишегеннән яктылык сирпелә иде.

Анда Гөлфия үзе утыра икән.

— Медсестраларыбызның тәҗрибәсе юк әле. Ул-бу булмагае дип, үзем килдем мена, — диде ул Фидаяга һәм Таштимерова яткан палатаны күрсәтте.

Палата зур гына, алты-җиде кешелек. Нисаның караваты ишек янында, тумбочкадагы лампадан төшкән яктылыкта аның йөзе нык суырылган, көйгән кебек күренде. Ул ишектән кергән Фидаяга текәлеп карады, сәламен алмады.

Утырырга урындык юк икән. Караваt тәбәнәк иде, Фидая урә

катып, өстән карап сөйләшергә яхшысынмады, күңеле дә нечкәреп киткән, үзенең Ниса өчен борчылганын, аның хәтерен калдырганы өчен нык үкенгәнен белдерәсе килә иде. Шуңа күрә ул Нисаның аяк очындагы ак җәймәне төзәткәләп, шунда утырды да, аның йөзенә таба, алгарак иелеп, йомшак кына сорады:

— Хәлләрең ничек соң, Ниса апа?

Үзе шундук Нисаның тибенгәнен тойды: ул Фидаяны кысрыклый, аның караватта утыруын теләми иде. Фидая аптырап, каушап урыныннан кузгалды. Таштимерова мендәреннән башын калкытты да, палатаны гына түгел, коридорны яңгыратырлык калын тавыш белән:

— Сестра! Сестра! — дип кычкырды.

Ишектән кергән Гөлфиягә, каты итеп:

— Сездә тәртип бөтенләй юкмыни соң? — диде. — Төн уртасында палаталарда чит кешеләр йөри. Йокларга ирек бирмиләр!

Гарьләнүдән Фидаяның күз аллары караңгыланып китте. Әллә хәзер бөтенесен әйтергәме? Караватлардан калкынып, күзләрен зур ачып, шушы тарафка текәлгән биш-алты хатын алдында, шәрран ярып, Нисага йорты янып киткәнен, аның үзенә Фәтхрахман абзыйның ясин чыкканын, аннары Шәвәлиевләр кайткач, ирләренең хахылдашып ниләр сөйләгәнен... Хак дөресен, чын булганын... Фидая аның монда аунап ятканын күреп, ләззәт алырга килмәде. Һич юк! Киресенчә, ул яман хәбәрне йомшак итеп әйтергә, хәлен белергә, хәтта үзенең элекке дорфалыклары өчен гафу үтенергә килгән иде. Ләкин ачык чыраена шушы рәвешле таш аталар икән, аның тиешле җавап бирергә хакы юкмыни?..

Әмма... егылганны кыйнамыйлар. Фидая үз-үзен тыйды.

— Тавышың бик көр чыга, хәлең яхшы икән, аллага шөкер, — дигән булып елмайды да, Гөлфия артыннан чыгып, ишекне йомшак кына ябып куйды.

Гөлфия, гафу үтенгәндәй, аңа борылып елмайды.

— Хәле яхшырганга куанам, дигән булып син юри генә әйтәсеңдер, бәлки, — диде ул, — ә мин чыннан шатланам. Кара син аны, гайрәт бар икән үзендә дә. Монда китергәндә, тырнаклары күгәрә башлаган иде. Үлә, дип котыбыз очты. Ярый әле Юсупов өйдә иде. Куллары алтын шуның, билләһи! Китсә, бик үкенечле була инде.

— Ничек үзен шул хәлгә җиткергән соң ул? — дип сорады Фидая.

— Өйдә бала төшерү бик куркыныч бит ул! Аннан күп хатыннар үлә.

— Хак сүзмени шул? Ә бәлки егылгандыр, авыр күтәргәндер.

— Нишләгәнен безгә әйтмәде. Тик кешегә сиздерәсе килмәгән инде, анысы хак. Аңларга да була, зур җитәкче, ялгыз хатын. Андый гонаһлары сизелсә, хатыннарны җитәкче эштән хәзер куалар бит. Ужымга чыгу ирләренең генә дәрәҗәсен күтәрә.

Ул ягын Фидая бик үк уйлап җиткермәгән иде әле.

— Мир теленә кермәсен иде инде, — диде. — Гомер буе арына алмас.

Моңа каршы Гөлфия башын чайкап куйды:

— И, безнең больницада сер тора димени? Аны инде монда китергәндә үк озатучылары белде.

— Каян?

— Шуннан. Больницаның дежур машинасы юк бит. Ә авыруның хәле мөшкел. Китергән кешеләрне атлары белән безгә чаптырганнар. Билал белән без килеп карадык та, шул ук атларны хатын-кыз врачын алырга җибәрдек. Сер саклыйм дип кеше үтереп булмый бит инде! Аннары олы палатага кертеп салдык. Андагы хатыннар да сукыр түгел, кемгә ни булганын бик яхшы беләләр.

— Врачлар серне нык сакларга тиеш бит, югыйсә, — диде Фидая көрсенеп. — Гиппократ антында да бар андый сүзләр.

— Гиппократ заманында, бәлки, андый мөмкинлек булгандыр да, бездә кая инде ул! — дип кулын селтәде Гөлфия. — Менә яңа больницаны салып бетергәч, без дә, бәлки, адәм төсле эшли башларбыз. Авырган кешене алырга ашыгыч ярдәм машинасы җибәрербез, врачларны да өеннән шуның белән китертербез. Операциядән соң кешене аерым палатага салырбыз. Анда инде бездән сер чыкмауны да таләп итәргә булыр. Гиппократ антын үтәүне дә. Хәер, больничныйга барыбер диагнозның дөресен язарга кирәк.

Алай да Фидая, сак кына, бу хакта чит-ятларга сөйләп йөрүнең яхшы түгеллеген искәртте. Һәм кайгылы хәбәрне — Нисаның өе янып көл булуын әйтүне Гөлфиягә тапшырып, саубуллашты.

Димәк, Ниса да гөнаһсыз түгел икән. Ә нинди керсез булып кылана, әле кайчан гына Фидаяга, кеше алдында, никадәр ямьсез, пычрак кинаяләр ясаган иде... Ә шулай да кем караган аңа? Кем иркәләгән, назлы сүзләр сөйләгән? Фидая Нисаның ир кешене кочаклап үпкәнен, иркәләгәнен күз алдына китерергә тырышып карады, булдыра алмады. «Тьфу, — диде үз-үзенә. — Минем анда ни эшем бар? Иш-ишен тапкандыр инде...»

...Иртәгесен иртүк райбашкарма председателе Искәндәровка төнге хәлләрне сөйләгәндә, Фидая Таштимерова хакында дөресен әйтергә яхшысынмады. Гайбәтче булып күренәсе килмәде, аннары хатын-кызның дәрәҗәсен төшерергә дә теләмәде.

— Аппендицит, диделәр миңа, — диде.

Искәндәров күзлек пыялалары аша зураеп күренгән күзләре белән Фидаяга текәлеп карады.

— Мин монда колхозлар белән сөйләшәм хәзер, — диде. — Теге янган өч йортны торгызуны өч хуҗалыкка тапшырырмын. Ә син Баллыболынга барып, кешеләр белән сөйләшеп кайт. Тынычландыр. Таштимерова безнең районда бердәнбер хатын-кыз җитәкче дияргә була, безнең горурлыгыбыз, аның дәрәҗәсен сакларга кирәк.

Фидая:

— Әллә соң үзегез барып кайтасызмы? — дип караган иде. Искәндәров кырыс кына:

— Син андагы халыкны яхшы беләсең, кешегә салынырга өйрәнмә, — диде.

Фидая «Үзәк»нең партоешма секретаре Әхсән Вәлишинга үзенең киләсен телефоннан хәбәр итеп куйды да юлга чыкты. Авылда сөйләшүнең җиңел булмасын күңел сизә иде.

Аны көтәләр иде: председательнең бүлмәсенә шыгрым булып халык тулган. Әллә Вәлишин чакырган, әллә үзләре җыелганнар. Кечерәк, чандыр буйлы, йомшак табигатьле Вәлишиннан әллә ни ярдәм көтеп булмый, ә халыкның кәефе бик шәптән түгел иде.

Башта өе янган кешеләрнең хәлен сөйләшеп алдылар. Гыйззетдиннәр клубның бер бүлмәсенә урнашканнар, Фаязларның туганнары бар, ә Таштимерова...

— Аның урыны корыда, җылыда, — диде кемдер астыртын киная белән.

— Әле бүген малайлар кисәү актарып яталар иде, Нисаның ике күлмәген табып алганнар. Ышанасызмы-юкмы, төс тә салмаганнар, бөтен чәчкәләре яктырып ята. Борешкәннәр генә!

— Заман товары шулай ул: утта янмый, суда батмый, биш буын салмый киярлек.

— Андый товар тузмый, адәм баласының гына базары уза.

— Узды инде, узды Нисаның базары!

Шулай итеп, рәсми рәвештә сүз башлаганчы, Фидая авызын ачканчы ук, Нисаның язмышын хәл итеп куйгандай иттеләр болар.

Шаярышып кына, сүз арасында гына диярлек.
Фидая бирешергә теләмәде, тавышын күтәрә төшеп:
— Бәла-каза адәм башыннан йөри. Электр белән саксыз кылланган өчен генә кешене салып таптау килешми, — дип куйды.
— Электр белән генә микән?
Монысына астыртын мәгънә салып, хихылдашып алдылар. Барысы да ирләр, арттарак кына бер-ике хатын-кыз утыра, ата-бабадан килгән йола буенча, әдәп саклыйлар, ирләр сүзенә бик үк катнашмыйлар.
Фидая сүзне үзгәртергә тырышып карады. Таштимерова озакламый кайтачак, үзе юкта кеше турында сөйләү килешми. Отчет-сайлау җыелышына да күп калмаган, шунда барын да ачыктан-ачык сөйләшербез. Ул шуны аңлатырга теләде. Ләкин бүлмәдәгеләр үзара пышылдаша, сөйләшә, ничек тә үзләренең ризасызлыгын сиздерергә тырышалар иде. Ул да булмады, колхозның ревизия комиссиясе председателе Гаделша карт өстәл кырыена чәчрәп килеп басты.
— Ничек кайта ул монда? — дип кычкырып җибәрде ул. — Ни йөзе белән халыкка күренә? Әл дә ярый районнан машиналар килеп утны сүндерә алдылар. Әл дә ярый җил юк иде! Шунда бөтенебез янып көл була идек бит, ә? Шул булдымы җитәкче? Аның йөз каралыгы тагын? Юк инде, мин, мәсәлән, аның кул астында эшләргә теләмим. Ник әллә ни әйтмиләр, мин аны шушы көннән персидәтел итеп санарга риза түгел. Менә шул! Кайсыгыз ризалаша шушы сүзем белән?
Фидая белән Вәлишин аңышмый да калдылар. Гаделша шушы сүзе белән мәсьәләне тавышка куйгандай итте, бүлмәдәгеләр дәррәү кулларын да күтәрделәр.
— Юк инде, булмый инде аннан хәзер!
— Ул үзе китәргә тиеш?
— Барып әйтергә кирәк, монда кайтып, персидәтел дип йөрмәсен үзен!
— Персидәтелсез яшәп карыйк әле бераз! Бәлки, болай ук янмабыз!
— Күптәннән персидәтелсез бит инде без, шуны белми йөрдегезме әллә!
Фидая монда үз сүзен үткәрә алмаячагын аңлады. Хәер, ул бу кешеләрнең күңелен йомшарта алса да, Таштимерованы кире кайтарып, бу бүлмәгә, менә хәзер алар Вәлишин белән икесе янәшә утырган өстәл артына утыртып булыр иде микән? Юктыр, мөгаен. Таштимерова үзе үк моңа риза булмаска тиеш. Халыкка каршы бару мөмкинмени? Бигрәк тә мондый очракта.
Хуҗалыкка яңа җитәкче сайларга кирәк булачак иде.

## 14

Кич ашап-эчеп, Иркәне йоклаткач, Фидая белән Рамилә залдагы диванга янәшә утырдылар. Янгында көйгән күн пальтоны әйләндерә-әйләндерә карадылар.
— Их сез, — диде Рамилә. — Шушындый затлы әйберне яндыраларммыни?
— Алты йөз сумлык! — диде Фидая көрсенеп.
— Таза урыннары бар әле барын. Ательеда пинжәк чыгарырлар иде, бәлки.
— Анда кешеләрнең бөтен йорты-милке көл булды әле.— диде Фидая үз-үзен юатып.— Ә кайберләренең кешелек дәрәҗәсе күккә очты.
Ул уйчанланып Таштимерова кыйссасын сөйләп алды.

— Шунысы акылга сыймый,— дип йомгаклады сүзен.— Ул да яратырга сәләтле микәнни? Аны кем яраткан тагын?

— Һәр йөрәк үзенчә ярата, дип күптән әйтелгән бит инде,— диде Рамилә исе китмәгәндәй. Аның Фидая башыннан кичкән хәлләр, йөрәгенә яра салган хисләр турында тыңлыйсы килә иде.

— Теге классташыгыз... Ваккас, ул да үзенчә яраткан бит? — дип сүзне борып җибәрде ул.— Берсе каты бәгырьле булып кылана, икенчесе елый... Чын ярату күп очракта нәкъ менә шулай башлана.

— Юк шул,— диде Фидая.— Бу очракта күз яшьләре сөешүнең башы булмады. Мин аның армиядән язган хатларына җавап бирмәдем. Әнисе кереп минем әнкәйгә ялынып та караган, кызың иптәшләрчә генә хат язсын инде Ваккаска, күңелен төшермәсен, башкасын ул кайткач үзләре сөйләшерләр тагын, дигән. Ләкин мин әнкәйнең сүзен дә тыңлый алмадым, кулым бармады. Классташым Лилиягә генә кереп әйттем, Ваккасның кызлар белән хат алышасы килә икән, язып җибәр әле, дидем. Ул миңа беләсеңме нәрсә диде? «Егетләр синең аяк астында туфрак булырга әзер, өсләренә үкчәләреңне батырып-батырып үтсәң дә сүз дәшмәсләр иде бугай,— диде ул.— Үз аяк асларында туфрак булган кызларга алар әйләнеп тә карамыйлар».

Ваккас чемоданы эченә тоташ итеп минем елмаеп төшкән фоторәсемемне ябыштырган икән, дип тә сөйләделәр. Армиядән кайткач, урамда очрашкан идек, ул минем кулымнан тотып, көмеш йөзегемне суырып алды. Анысы да халыкка фаш булды, шул йөзек бармагына сыйсын өчен, махсус ач торып ябыккан икән, дигән сүз таралды.

Минем исә андый кыланмышларга ачуым гына килә. Ваккас кына түгел бит, Мәгъсүме дә бар әле. Пионервожатый булып бер кыш эшләгәч, мин педагогия институтына кергән идем. Мәгъсүм дә нәкъ шул елны читтән торып укудан көндезгегә күчкән булып чыкты. «Әллә минем аркада микән?» — дигән шик кергән иде күңелемә, дөрескә чыкты. Һәрхәлдә, ул үзе соңыннан: «Синең янда булыр өчен көндез укуга күчтем»,— диде. Мин исә аны кирәксенмәгәнемне җай килгән саен сиздереп торам, баскычта йә коридорда каршы очраса, киемем аңа орынмасын дип, итәкләремне кулым белән җыеп тотып узып китә идем.

«Әрәм итмә хисләреңне шул тәкәбберbegә! — диләр икән аңа дуслары.— Институтта чибәр кызлар җитәрлек, сиңа теләсә кайсы карый». «Тимәгез күңелемә,— дип җавап биргән ул андыйларга.— Кеше үзгәрми тормый, ул да үзгәрер».

Ә дуслары хаклы иде: оста баянчыга кызлар кызыкмыймы соң. Үзенә күрә җае да килеп тора. Берзаман Мәскәүдән ике журналист килеп төште безгә. Чит илләрдә чыга торган журналлар өчен татар студентлары турында мәкалә әзерләп, фотолар төшерергә. Аерып күрсәтер өчен бер кыз белән бер егетне сайлап алырга кушканнар. Үч иткәндәй шунда Мәгъсүмне сайлаганнар һәм аның янына... юк мине түгел, миндәй сары чәчлеләрнең саф татар милләтеннән булуына башка халыклар ышанып җитми бит... Минем дустым, бүлмәдәшем, төндәй чәчле, йолдыздай күзле, айдай йөзле Флераны пар иттеләр. Атна буе парлаштырып әле китапханәгә, әле театрга, әле чаңгы шуарга йөрттеләр боларны. Төн җиткәч кенә очынып кайта Флера, түбәсе күккә тигән. Ул мактануы, ул талпынуы... Минем дә күңел таш түгел ләбаса!

Берничә айдан журналлар килеп төште боларга. Кайсының тышында, кайсының эчендә Мәгъсүм белән Флера тора парлашып. Берсендә егеткәй, иелеп, Флераның чаңгы бавын рәтли. Димәк, минем каршымда гына иелми икән ул егетнең газиз башкае! Аның бу кыяфәте бик тә күңелемә сеңеп калды.

Кыскасы, кеше үзгәрә, диган сүз хак икән. Сынмас кебек идем, сындым мин берзаман. Яңа ел кичендә булды бу.

Мин бәйрәмгә төн булып киендем. Кара күлмәктә ак елтыравык бизәкләр, йөзем кара челтәр белән капланган. Башта концерт куйдык, магнитофон уйнатып биедек. Аннары Флера Мәгъсүмнең кулына баян китереп тоттырды. Баянга биисебез килә, янәсе. Егетләр кызларны чакыра башлады. Гадәттә, мине беренчеләрдән чакыра торганнар иде, бу юлы исә һич көтелмәгән хәл булды: без, кызлар, стена буенда тезелеп торабыз, менә каршыга егет килә, ул елмаеп кулын миңа сузган кебек, баксаң, янәшәдәге кызның беләгеннән тотып ала да, алар икәүләшеп бөтерелеп китәләр. Әллә ничә тапкыр шулай булды. Андыйны бер кинофильмда да күргән идем мин. Шулай итеп, бөтен кызларны алып киттеләр, стенага терәгән кара багана булып бер мин калдым.

Соңыннан белдем: ул кичне Мәгъсүмнең дусты Мидхәт егетләрне миңа каршы котырткан: «Мәгъсүмнең яраткан кызы янына барасы булмагыз, юкса!..» — дип янаган икән.

Баштарак егетләрнең мине читләтеп узуы көлке тоелган сыман иде, берничә тапкыр кабатлангач, хәл көлүдән узды, үзем адәм көлкесенә калгандай булдым. Нишләргә? Стенага сеңеп югалырдай булдым бит тәки! Барысы да парлы-парлы, мин генә моңлы-зарлы булып калдым лабаса! Әнә, хәтта Мәгъсүм дә ялгыз түгел, аның урындык аркасына таянып Флера басып тора, авызын ерган, теләгенә ирешкән! Йөзенә кулъяулык җилпегән була, ә җилен Мәгъсүмгә табарак җибәрергә тырыша.

Нишләргә миңа? Чыгып китәр идең — җиңелү, хурлык булыр шикелле. Ялгызың басып тору — аннан да читенрәк. Дөрес, Мәгъсүм уйнаудан туктаса, мин бу хәлдән котылыр идем, ә ул мине уйламады, уйнады да уйнады. Көйләрнең дәртләләрен, салмакларын, шаяннарын, моңсуларын... Башка шөгыль булмагач, мин баян тавышын дикъкатьләнрәк тыңлый башладым. Аның моңлы тавышы кешеләрне биетеп кенә калмый, ул хәтта чыршы тирәли бөтерелгән кешеләр өчен дә түгел, ә бәлки аларга юл уңаеннан гына орынып уза кебек иде. Талгын җил булып килеп минем йөрәгемә үтә, бит очларын сыйпап назлый, керфекләрне тибрәтә шикелле иде ул. Гүяки шаярта да, елмаеп юата да иде мине. Кинәт колакларым ачылгандай булды, аңарчы мин гел саңгырау хәлдә яшәгәнмен икән. Көйләрнең серен аңлый алсын өчен, мине шушы рәвешле ак стенага кара терәү итеп ялгызымны бастырып тотарга, көйләрнең төрлесен аралаштырып, алардагы омтылыш-хисне тойганчы тыңлатырга кирәк булгандыр.

Мин Мәгъсүмгә күренмәслек итеп баскан идем, идәннән түшәмгә тоташкан, елтырыйк уенчыклар, төрле төстәге лампочкалар асылган зур чыршы арабызны бүлеп тора, зал тулы егетләр-кызлар әйкәлә, ә көйгә киртә юк, ул аның йөрәгеннән минем йөрәккә килеп ирешә.

Мин, авышыбрак, гармунчыга карадым. Флера һаман әле аның урындыгы аркасына таянып, кулъяулыгы белән җилпенә, йөзендә гамьсез, канәгать елмаю.

Шунда Мәгъсүм, көйне ярты юлда өзеп, уйнавыннан туктады, каешларын иңнәреннән шудырып, баянын урындыкка куйды да торып басты, чыршыны әйләнеп, миңа таба юнәлде. Каршыма килеп, башын иде.

Шулчак магнитофонны тоташтырдылар. Мин аңа кулымны бирдем.

— Шулай итеп, сез аңа гомерлеккә кулыгызны бирдегез, әйеме? — диде Рамилә.— Чын мәхәббәт туң йөрәкләрне дә эретә!

— Әгәр дә шулай гына булса икән? — дип, көлемсерәп башын чайкады Фидая.— Әйе, күңел йомшаган иде минем. Ләкин... хисләремне ул кадәр зурлап мәхәббәт дип үк әйтеп булды микән ул чакта?

Туң йөрәгем эреде, анысы хак, ә менә ялкынланып янугакилсәк,анысы ай-һай!...— Фидая тирән итеп көрсенде.— Хәзер менә үткәннәрне искә төшерәм дә, үз бәхетемнең кадерен белмәдем, дип куям. Әгәр күрәчәгемне алдан белгән булсам, башкачарак яшәр идем, үкенерлек итмәс идем, кинәнеп-куанып яшәгән булыр идем!

Ә минем үкенерлек эшләрем булмады түгел, булды.

Май аенда өйләнештек без.

— Син аны яратмыйсың бит, нигә чыгасың? — дип сорады миннән теге Флера дигән кыз.

— Артык өзелеп сөймәсәң, яшәү җиңелрәк була, көнләшеп интекмисең, диләр бит,— дип шаярып җавап бирдем мин.

— Бергә яши башлагач, төрлесе булыр: көнләшерсез дә, үпкәләшерсез дә,— диде ул.

— Сынап карыйк әле, ничек булыр икән,— дип тагын көлдем.

Алай да Флераның сүзе күңелдә калды, туй мәшәкатьләре арасында да вак-төяк көйсезлекләре булгалап торды. Эчемлекләр алырга баргач, Мәгъсүмнең кулыннан бер шешә төшеп ватылган. Ничектер сөмсере коелып кайтып керде. Алай да сер бирмәскә тырыша: «Сатучы әйтте, кәләшең чибәр, ахрысы, синең,— ди.— Каян белде икән ул сине?» — ди. Мескенкәй, ул мине бөтен кешегә ошый дип уйлый, күз тияр дип курка иде хәтта.

Фидая, урыныннан кузгалып, каршы стенаны биләп торган китап шкафы янына барды да аскы тартмадан кызыл бәрхет тышлы альбом алды.

— Менә, безнең туйда төшкән фотолар. Менә мин, бөрчекле күлмәктән. Ул миңа туй күлмәгемне загска барганда киярга рөхсәт итмәде. Бөтен кеше караячак, янәсе. Анда бер кытыршылык булып узды безнең. Күрәсеңме, менә бу өстәл артында утырган яулыклы апаны? Әнә ничек ачулы итеп акаеп караган миңа? Ачуы килүнең сәбәбе шунда: ул минем гаризамны рәтләп укымаган, загс язуында мине ирем фамилиясенә күчереп куйган булып чыкты. Иң тантаналы минутта, кулыма каләм тотып, кул куярга иелгәч, мин моны күреп алдым да бу ападан: «Ник минем фамилиямне үзгәрттегез?» — дип сорадым. Күзе шар булды моның. Ул чакта мин, бу үз хатасы өчен оялды, дип уйлаган идем. Ә ул минем өчен оялган, күрәсең. Шушы соравымны биреп, мин аның каршында, киявем һәм студент дусларым каршында ифрат зур әдәпсезлек кылганмын.

Фидая көрсенеп куйды.

— Еллар узгач, кына, кайта-кайта искә төшергәндә аңладым мин ул чактагы ямьсез кыланмышымны. Уйласам, кызарып чыгам. Ә ул чакта, кара, ничек җитди карап торам мин ул апага!

Апа башын миңа табарак сузды да, башкалар ишетмәсен дигәндәй, әкрен тавыш белән:

— Бүгенгә шулай торып торсын,— диде.— Иртәгә үзең генә килерсең, төзәтербез.

Ул, күрәсең, бу аңгыра иртәнгә хәтле акылга утырыр, килеп йөрмәс, дип өметләнгәндер. Ләкин ялгышты. Бер кермәгән акыл төн эчендә генә керми икән шул.

Иртәгәсен бардым мин аның янына. Яңгырлы, җилле, күңелсез көн иде. Апа мине шактый озак көттерде, башка килгән-киткәннәрнең йомышларын үтәде. Минем тәмам ачуым чыкты. Ахырда, кереп, өстәлгә загс язуын ташладым да «Акназарова» дигән төшенә бармагым белән төрттем. Апа, бер сүз дәшми, бу сүзне шәмәхә карасы белән сызды һәм өстенә чатлы-батлы хәрефләр белән «Нурханова» дип язып куйды, аскарак «Төзәтмәсе рас»,— дип, имзасын сырлады да, сытарга теләгәндәй нык итеп өстенә пичәтен басты.

Аның бу кыланмышлары нишләптер күңелемә бик авыр тоелды, мин урамга чыккач, язуны ачып карадым: кәгазь таушалып, искереп

киткән иде, өстенә яңгыр тамып, әле генә язган юллары җәелеп ямьсезләнде.

Ә ул, Мәгъсүм, ниләр уйлагандыр, йөзенә дә чыгармады!

Берничә ел узгач, безгә кунакка килгән бер хатын бөтен табын алдында:

— Нишләп сез икегез ике фамилиядә? — дип сораган иде.

— Мин юләр булганга,— дип җавап бирдем.

Шунда Мәгъсүмнең үсеп, яктырып киткәнен күрсәң иде!

Иркә тугач, мин, загска барып, фамилиямне үзгәртмәкче булган идем. Ашыгыч түгел бит әле, дип, һаман суза килдем; ул шулай суза-суза бөтенләй соңарганыңны сизми дә каласың икән. Хәзер минә кызым белән икебез ике фамилиядә яшибез...

Флера әйткән иде миңа, сезнең өйләнешүегез заманча булмады, кадимчә булды, дип. «Мәгъсүмнең дуслары кодалады сезне,— диде ул,— тик син үзең моны аңламый гына калдың. Аннары сез язылыштыгыз, туй ясадыгыз, фәкать шуннан соң гына чынлап кавыштыгыз. Хәзерге яшьләр башта яшәп карыйлар, шуннан соң ошатсалар гына кияүгә чыгалар»,— дигән иде ул. Дөресен генә әйткәндә, кәләш булып загска барганда да туйда парлашып утырганда да мин бу хакта — кавышуның чын мәгънәсе турында ныклап уйламаган идем, күз алдына китерергә курка, ояла идем. Мәхәббәт бар җирдә оят булмый, дигән сүз бар. Ә бәлки, минем мәхәббәтем көчле булмагандыр? Кияү келәтендә парлашып төн үткәрергә күңелем әзер түгел иде минем. Ә «келәт»не безнең студент кызлар бик матур итеп әзерләгән иделәр: бүлмәдәге дүрт караватның өчесен кырыйга этеп, дүртенчесен чыбылдык белән ураганнар, чигүле мендәрләргә, өр-яңа җәймәләргә ислемай сипкәннәр. Мин, бүлмәгә кергәч, аз гына кайтарылган чыбылдык чите аша күпереп торган мендәрләрне күреп, шомланып киттем. Мәгъсүм иңемә кулын салган иде, аны ихтыярсыздан тупас рәвештә алып ташладым. Ул моны да сабыр кабул итте. Ишек янындарак өстәлгә табын әзерләнгән, уртасына кызыл тюльпаннар куелган иде, ул ишарәләп, мине шул табын янына чакырды.

Төнне без шул табын янында кара-каршы утырып уздырдык, дисәм, ышанырсың микән? Чәй эчеп кенә түгел, шигырь укып узды безнең ул сәгатьләр.

Фидая шкафтан бер кечкенә китапчык алып килде. Ул бик затлы итеп, шома ак кәгазьгә басылган, тышына чалмалы егет белән кулына кош тоткан нечкә билле кыз сурәте ясалган иде.— Мәҗнүн шигырьләре бу.

Менә тыңла:

Әйтте дуслар миңа: йоклый аның җаны,
Канат яралмаган кош баласы кебек;
Ә мин җавап бирдем: сөям фәкать аны,
Терелтермен җанын, гыйшкым утын өреп.

— Мин бу шигырьләрне укыйм да, гел безнең хакта язылган,— дип уйлыйм,— диде Фидая.— Гаҗәп. Гүяки Ләйлә белән безнең арада гасырлар да, чүлләр, таулар, елгалар да юк, гүяки ул минем белән янәшә яшәгән, без бер үк язмышны кичергәнбез. Менә, тыңла: чынлап гашыйк булган кеше бүген менә шушылай хис итмимени үзен?

Баскан эзләреңә ятып битем куям,
Эзләреңнең назын, йомшаклыгын тоям...

— Без шигырьләрнең төрлесен укыдык ул чакта,— диде Фидая, дулкынланып.— Нишләптер, менә шушылары аеруча нык истә калган.

Ул, тураеп, Рамиләгә текәлеп карады да өзеп-өзеп:

— Без шулай алты кичебезне шигырь укып уздырдык,— диде. Аннары шактый тынып торды.

— Сине бу гаҗәпләндермиме? — дип сорап куйды тагын.

— Гаҗәпләндерә,— диде Рамилә.
— Ышанасыңмы соң?
— Ышанам. Гаҗәп нәрсә күп бит ул дөньяда. Һәркемнең күңеле үзенчә, мөнәсәбәтләр дә төрле-төрле.
— Ә миңа ышанмыйлар. Теге Флера белән берничә елдан соң очрашкач, мин ничектер бу хакта сөйләп куйган идем, ул күземә карап шаркылдап көлде. «Кеше ышанмаслык сүзне дөрес булса да сөйләмә! — диде.— Загста язылып, туйлар уздырып, кияү келәтенә кереп бикләнгән парның нинди шигырь укыганын без дә бик яхшы беләбез, дөньяга бүген генә тумаган! Әгәр шигырь укудан бүтәнне белмәгәнсез икән, димәк, сез икегез дә нормаль түгел!»
Бәлки, мин, чыннан да, нормаль булмаганмындыр, ул моны аңлагандыр. Кияү келәтенең бусагасын атлап кергәндә, мин аның хатыны булырга әзер түгел идем әле. Ул алты кич буе минем шуңа әзерләде. Үзе булдыра алганча. Кичләрен шигырь укып, көндезләрен баянын уйнап. Ул шулай күңелем бозларын эретте, әкренләп оялу-тарсынуларымны оныттырды. Мин кайсыдыр минутта аннан читләшми башладым, кайсыдыр мизгелдә үзем аның иңенә иңемне терәдем, аның кочагына кердем...
Ә бит монда гайре табигый берни дә юк. Салкын күңелне җылыту өчен күпмени ул — алты төн? Таш сынга җан өрү, аны кайнар канлы адәм баласына әверелдерү өчен озак вакытмыни ул — җәйге кояшның алты тапкыр берничәшәр сәгатькә генә офык сызыгы артына күмелеп торуы? Шул сәгатьләр эчендә миндәге үзгәрешне ясау өчен шигырьмоң тылсымы кирәк булган да инде.
Синең теге роза чәчәкләре бәйләмен күргәч, шул кичләрем искә төште. Алар да нәкъ шушы Мәҗнүн шигырьләре төсле бит.
— Рәхмәт-әт,— дип сузды Рамилә.
— Чынлап, чынлап. Аларны күрүгә, йөрәгем сулкылдап куйды. Югыйсә бит, ул көннәр болытлы-җилле, яңгырлы иде. Шомырт чәчәк аткан чак.
Хәтеремдә, теге загста язылышу кәгаземнең кадерен бетереп кайтып килгәндә дә күшеккән идем. Алай гына да түгел, салкын җил һәм вак яңгыр бәгыремә үтеп кергәндәй булган иде. Күңелдә ниндидер буталчыклык, күңелсезлек. Шулай тулай торакка кайтып килә идем, баян тавышын ишетеп туктап калдым. Башта ул, тамагын сынап караган җырчы шикелле, бөтен авазларын рәттән чыңлатып узды, калыннары көрсенгәндәй итте, нечкәләре сызылып алды. Аннары авазлар, бер-берсенә кушылып, бер-берсен дәвам итеп, көй булып сузыла башладылар. Бу көй гүяки минем генә колакка килеп ирешә, ул гомумән, минем өчен генә ярала иде. Мин аның нинди икәнен әйтә алмыйм хәзер, көйләп тә бирә алмыйм, ләкин ул чакта кайсы аваз артыннан нинди яңгырасын алдан ук тоеп, аны ишетеп ләззәтләнәсемне сизеп тора идем, һәм моң, нәкъ мин көткәнчә, йөрәк очымда тибрәлеп яңгырый иде! Бу моң буталчык хис-тойгыларымны бер тәртипкә китерә, уйларымны рәхәт эзгә сала, мине әйләндереп алган мохиттә һәм минем үземдә камиллек тудыра иде. Шунда мин үземнең бәхетле икәнемне аңладым. Йа алла! Яшәү шундый рәхәт, шундый күңелле иде, бүтәне кирәк тә түгел иде бит!
Мин бүлмәгә тын гына кердем дә, ишек яңагына сөялеп, кыймшанмыйча көйне ахырынача тыңлап бетердем. Ул да миңа күтәрелеп карамады. Безнең күңелләрне моң тоташтырып бербөтен иткән, шуннан да артык уртаклык кирәкми иде.
Ул, соңгы авазны сузып, баянын көрсендергәндәй итеп, мехларын җыеп, тынып калды. Мин аның янына бардым да:
— Бир әле миңа,— дидем. Баянны кулыма алдым. Менә ул баян.
Фидая, торып, телевизор астындагы зур тумбочкадан олы гына кап тартып чыгарды, аннан баян алды. Читләре кара ырмау белән читлән-

гән, ап-ак күрекле, ахак белән бизәлгән затлы баян иде бу. Фидая аның «Стандарт Ройаль» дип сырланган көмеш язуын, биш рәт булып тезелгән аклы-каралы төймәләрен сыйпады.

— Мин аны алдым, теземә куйдым, төймәләренә басып тарттым. Баян сыкранып куйгандай булды. Салкын, каты, авыр тоелды ул миңа.

— Бик яхшы уен коралы бу,— диде Рамилә.— Ләкин көйнең хикмәте коралдан бигрәк уйнаучының бармакларында, аның осталыгында шул. Барыннан да бигрәк, аның йөрәк хисләрендә булгандыр...

— Шул чактан минем күңелдә шигърият белән музыка берләште,— диде Фидая, үзалдына уйлангандай.— Хәзер менә аларга рәсем сәнгате дә килеп кушылды. Алар миндә бер үк хисләр, бер үк талпыну, сагыш уяталар...

...Бу төндә Рамиләгә бик моңлы да, ямансу да төш керде. Иртәгесен ул аны Фидаяга сөйләп бирермен, дип уйлаган иде, ләкин ачык кына исенә төшерә алмады. Ул төштә моңлы җыр, сагышлы сүзләр һәм нурлы төсләр аралашып буталган иде.



## 15

Бу урманчы Гаяровның аягы җиңел түгел икән — көн күңелсез башланды. Иртән райбашкарма коридорында Фидаяга иң беренче булып шул юлыккан иде. Аны күргәч, Баллыболын буасы буена урман утырту мәсьәләсе хәтергә төште.

— Укучылар шушы арада бушар, ярдәм итәрләр сезгә,— диде Фидая Гаяровка.

Гаяров аңа өстән аска мыскыллы көлемсерәп карады:

— Кайгыртуыгыз өчен рәхмәт инде. Без анда парторг Вәлишин белән мәсьәләне хәл кылган идек.

«Кирәгең юк, эшне бутап кына йөрисең»,— дигән сыманрак килеп чыкты бу. Фидая Искәндәров бүлмәсенә кәефсез барып керде. Алай да кәеф кырырлык эшләр алда булып чыкты. Искәндәров аны тыңлап та тормады, чөнки иртүк Баллыболын белән сөйләшкән, «Үзәк»нең председательсез калганлыгын да, кичә Нурхановaның аңа Таштимерова хакында ялган сөйләгәнен дә белгән иде инде. Искәндәров, Фидаяны күргәч, зур башын алга суза төшеп, сул кулы белән күзлеген җыерчыклы маңгаен шудырды да, исәнлек-саулык сорашып та тормыйча:

— Колхозны җитәкчесез калдыру өчен җибәрдекмени без сине анда? — диде.— Хатын-кыз буларак, Таштимерова өчен синең җаның фида булырга тиеш иде! Үзегез, кая карама, хатын-кызга ирләр юл бирми, дип кычкырасыз, үзегез бер-берегезнең башын ашарга гына торасыз!

Төштән соң район җитәкчеләре җыелып, мәсьәләне уртага салып сөйләштеләр. Ап-ак күлмәкләр өстеннән галстуклар таккан, пөхтә кара-көрән костюмнар кигән, салмак адымлы, могтәбәр кыяфәтле, таза гәүдәле, чиста итеп кырынган унбишләп дәрәҗәле ир каршына кереп басты Нурханова. Урындыкларны тутырып тезелешеп утырган бу ирләр янәшәсендә аның нечкә сыны, йомшак тавышы, бөтен кыяфәте урынсыз, көчсез тоела иде. Ирләр аңа, ят җанварга карагандай, кызыксынып та, үзләренең һичшиксез өстенлеген тоеп та, бераз кызганып та карадылар.

Мәсьәләне Искәндәров кыскача гына аңлатып биргәннән соң, тынлык урнашты. Бераздан гына, күзләрен гадәттәгечә кысып, көлемсерәп, төзү-монтаж идарәсе җитәкчесе Тавис Мирхуҗин әйтеп куйды:

— Дүрт аяклы ат та абына, ди. Андагы аҗгырган ирләр, моннан ары Таштимеровага баш биреп яшәмибез, дип аяк терәп тора икән, бер Нурханова нишләсен? — диде.— Көче җитмәгәндер. Тәҗрибә дә әз бит әле. Аннары, хатын-кызга авыр да.

— Монда без кешеләрнең җенес аермалыгын тикшерергә җыелмадык,— диде Искәндәров кырыс кына.— Нурханованың кылганына принципиаль бәя бирергә һәм бу очракта нишләргә икәнен ачыкларга кирәк.

Бүлмәдәгеләрнең чырайлары бердән җитдиләнеп китте. Нурхановага текәлгән карашлардан елмаю юкка чыгып, кырыслык чагылды. Иптәшнең эшенә принципиаль бәя бирү башланды. Әйтергә кирәк, принципиальлек нык сакланды. Нурханова соңыннан хәтерләргә тырышса да, кемнең ни сөйләгәнен исенә төшереп бетерә алмады. Аның йомшаклыгы, тәҗрибәсезлеге турында сөйләделәр. Шуңа карамастан, башкалардан өйрәнергә теләмәвен әйттеләр, кыскасы, бернигә ярар җирен калдырмадылар. Сүзнең очы, әлбәттә, Кармаш больницасы төзелешенә, дөресрәге, әлеге планнарга кертелмәгән һәм акча белән дә, фондлар белән дә тәэмин ителмәгән шушы бер төзелеш белән артык мавыгуына килеп ялганды.

— Мин сезне алдан ук кисәтәм,— диде өндәү билгеседәй катгый, чандыр, муртайган кыяфәтле финанс бүлеге мөдире Хатипов,— сез анда хуҗалыклардан төрле юллар белән акча каерып, кемнәрдәндер төзү материаллары алып, эшне башкарып чыгарга телисез, дип ишеттек. Бу эшләрнең очы кайбер органнарга барып җитсә, сез дә котыла алмассыз, без дә,— диде.— Закон белән эшләргә кирәк андый эшләрне. Башта планга кертергә, проектын раслатырга, аннары тиешле оешмалардан эшләтергә. Дөрес юл шул гына! — диде ул, баласына сабак биргәндәй.

— Сезнең белән без андый эшләрдә каешланып беткән инде,— диде тагын Мирхуҗин, көлеп.— Фидая Госмановна яңача эшләргә омтыла, ударникларча. Киләсе елга больницаны өлгертеп, шунда Билал берәребезнең корсагын ярмагае!

Ирләр, була бит ахмаклар, дигәндәй, башларын чайкап куйдылар.

— Әгәр шунда берәрегезгә төнлә ашыгыч операция ясарга туры килсә? Әгәр шул Газимов кулына барып керсәгез? — диде Фидая. Аның тавышы нечкә, калтыравык, көчсез чыкты.

— Инде ул больница кулына калырга язмасын,— диде кемдер.

— Газимовка хәтле дә яшәдек бит әле. Кармашта, гомумән, операция ясау дигән нәрсә онытылган иде инде...

— Бөтен совет медицинасы бер Газимов кулына сыеп бетмәгән,— диде Искәндәров, Фидаяга карап.— Больницаны төзергә кирәк, анысына сүз юк. Ләкин закон бозып эшләргә ярамый. Син алай халыкның котын алма әле,— диде аннары йомшара төшеп.— Әгәр кирәк икән, без Казаннан санавиация дә чакырта алабыз. Монда райүзәктә дә әйбәт врачлар эшли. Кыскасы безнең сүз читкәрәк китте. Нишлибез бу Таштимерова белән?

Күрше «Җиңүче» колхозының председателе, инде алтмышны тутырып килә торган тәҗрибәле абзый, әкрен-салмак кына әйтеп куйды:

— Дөресен генә әйткәндә, соңгы вакытта халык бик үк хупламый башлаган иде инде Таштимерованы. Узган елны гына да Баллыболыннан унбиш семья чыгып китте. Безгә күчәргә дәртсенүчеләре дә бар. Күрше хакы алла хакы дип яхшысынмаганга гына китермим. Таштимерова тәҗрибәле, сүз юк, ләкин бит тәҗрибә генә җитми. Заман үзгәрешен дә тотып ала белергә кирәк. Хәзерге заман кешесенә ярап бетү бик авыр, да, ярамый да булмый. Бәлки, аның шул якларын уйлап карарга кирәктер.

— Аның шушылай килеп чыгуы хәерлегәдер дә әле,— диде Тавис Мирхуҗин бик җитди итеп. Үзе шунда ук уртадагы өстәл кырыена утырган Фидаяга, башкалар сизмәслек итеп кенә, ым каккандай итте: күрәсеңме, сине яклыйм, мыегыңа чорнап куй, янәсе...

Бераз уйларга, тәнәфес ясап алырга булдылар. Алгы бүлмәгә чыкканда, колакка:

— Хатын-кыз бер-берсен сөйми бит ул,— диган сүзләр чалынды.— Күтәрелә башласалар, бер-берсенең түбәсен чукырга гына торалар. Аның Нисасы да шундый, җене сөймәгәне — хатын-кыз.

— Эштән башы чыкмады инде бичараның.

— Әйе, чыбыркы болгаудан бүтәнне белмәде.

— Нишләп белмәсен! Белгән ич әле!

Хихылдашалар.

— Белеп эшләмәгән шул. Белсә, болай адәм хурына калмас иде!

— Әйе, вакыт табып, кенәз Юсупов янына үз аягы белән бер сугылып чыккан булса шунда...

Тагын көлешү.

Секретарь кыз Фәүзия куе чәй әзерләп куйган икән, берсен алганда Фидаяның кулы дер-дер калтыранды. Ул читкәрәк, почмаккарак авышты, ләкин колагы гадәттән тыш үткенләнгән, стаканнар тотып төркемнәргә бүленгән ирләрнең сүзләре ишетелеп тора, ә сүзләр бер дә җитди түгел. Таштимерова да, Нурханова да шундук онытылдылар. Мәзәктер, көлкедер телләрендә.

— Малай, ул «Үзәк»кә радио хәбәрчесен алып барган идем мин бервакыт,— дип сөйли район газетасы редакторы.— Теге ферма мөдирләре бар бит әле. Газизуллин. Әйдә, дибез, сөйлә, фермада сөт артуга ничек ирешәсез. Бу сөйли башлады: силос бирәбез, салам ашатабыз, диде дә бетерде дә куйды. Хәбәрче әйтә, син, ди, сузыбрак сөйлә. Теге суза башлады: «си-и-илоо-с бирәбез, са-а-ала-а-ам ашатабыз». Соңыннан мине бинават итмәкче теге хәбәрче, син миңа, ди, нинди кеше таптың? Мин әйтәм, син яхшы эшләүчене сорадың бит, шома сөйләүчене түгел!

Хихылдашалар.

Фидая җитәкче итеп сайланган кешеләрнең бу сыйфатына,— җитди сүз сөйләнгән җыелышлардан чыгуга, бөтенесен онытып, уен-көлке, шаяруга күчүенә һич тә күнегеп җитә алмый иде. Әле генә җаннарны актарырлык сүзләр әйтелгән, кемнәрнеңдер язмышы хәл кылынган, кемнәрдер эштән алынган була, ә алар, берни булмагандай, юк-бар гәп сата башлыйлар. Кайчан ихлас алар: җыелышта бәгырьләрен айкагандай кайнарланып нотыклар сөйләгәндәме, менә шушылай ләчтит саткандамы? Һәм ничек тиз үзгәрә ала алар? Эчләрен актарып карыйсы иде!

Кабинетка кире кергәндә, тагын чырайлар җитдиләнде, сыннар турайды, башлар күтәрелде.

— Кемдә нинди тәкъдимнәр бар?

— Нурханова иптәшне тыңлап карыйк соң башта.— Тагын Мирхуҗин тавыш бирде, тагын текәлеп Фидаяга карады.

— Минем кандидатурам бар,— диде Фидая, торып.— Яшь, энергияле, булдыклы. Район халкы яхшы белгән һәм ихтирам итә торган кеше.

— Кем? — дип сорады Искәндәров.

— Гаяров.

Барысы да гаҗәпләнеп аңа текәлделәр.

— Гаяров, урман хуҗалыгыннан.

Дөресен генә әйткәндә, Нурханова әле бу кабинетка кергәндә дә Гаяровны уйламаган иде. Ул, гомумән, председатель итеп кемне куярга икән, дип баш ватмаган, моны башкалар, бигрәк тә Искәндәров үзе әйтер, дип көткән иде. Гаяров фамилиясе уйламыйчарак телгә килде, бәлки, Мирхуҗинның үртәп елмаюына бирешмәскә тырышудандыр, ә бәлки иртән очрашу тәэсире күңелгә кереп калгандыр.

Гаяровны атагач, бөтенесен күздән кичерде, хәзер барысы да дәррәү көлеп җибәрерләр, аннары каршы килерләр, хатын-кызның шул булыр инде, кадрлар сайлый белмәени ул, дигәнне сиздерерләр, дип

көтте. Ләкин ирләр көлмәделәр, карашларын аска төшереп, уйга калдылар. Берәм-берәм, Гаяровның чыннан да районда абруе үсә баргanын, эшне яхшы оештыручы икәнлеген әйттеләр. Дөрес, белеме урман буенча. Ләкин авыл хуҗалыгына якын. Дөрес, яшь әле, утызны да тутырмаган, ләкин яшьлек — үтә торган кимчелек, диләр бит. Ә моның нигезе нык — әнә, районда ул утырткан күпме урман үсә.

— Ярый, уйлашырбыз,— диде Искәндәров, йомгак ясап.— Ничек кенә булса да, бу колхозга сез үзегез шефлык итәрсез, Фидая Госмановна,— дип өстәде.— Яңа җитәкчегә ярдәм итәрсез.аның белән бергә җавабын да тотарсыз кирәк чакта.

Җыелыштан чыкканда, Мирхуҗин Нурхановага ышкылып диярлек узды:

— Егетләрнең асылларын сайлый беләсез икән, Фидая Госмановна,— диде.— Ялгышсагыз да, үкенече зур булмаячак, егылсаң атның яхшысыннан егыл, диләр бит!

## 16

Эшне коры тоттылар: Гаяровны чакырып алып сөйләштеләр дә, Казанга җибәрделәр. Булачак колхоз председателен, авыл халкы күргәнче, иң элек Казандагы зур җитәкчеләр карый әле, аның бу җаваплы эшкә яраү-ярамавын алар тикшерә.

Ул арада Таштимерованы иплэп кенә санаторийга озаттылар. Баллыболынга яңа председательне Нурханова илтергә тиеш булып чыкты.

— Үзең бозган эш, төзәтүен дә үзең төзәт,— диде аңа Искәндәров.

Җыелыш кичке сәгать җидегә билгеләнгән иде. Караңгы төшкәч кенә Нурханова машинасы белән юлга чыктылар. Арада сүз ялганмады.

Культура йорты — соңгы елларда авылда салынган биек, иркен сарайларның берсе иде. Барысы да яхшы, тик бер генә ягы килмәгән: авыл җирендә мондый иркен мәйданнарны тиешенчә җылытып та, яктыртып та бетереп булмый, шунлыктан аларга ямь дә керми иде шикелле. Залдагы халык плащ-пальто төймәләрен ныклап каптырган, ирләр муеннарын яка эченә җыерганнар, хатыннар шәлгә төренгән. Биектән, сәхнәдәге президиумнан караганда, Фидаяга таныш йөзләр дә чит-ят тоелды. Барысы да җитди чырай белән, күзләрен зур ачып, трибунадагы Вәлишинга текәлгәннәр, аның төссез-хиссез сөйләгән шома сүзләрен әллә тыңлыйлар, әллә юк, әллә хуплыйлар, әллә яратмыйлар — күзләрендә, йөзләрендә бер хис тә чагылмый. «Әгәр шунда, житте инде, без үзебез белмәгән кешене җитәкче итеп куймыйбыз, дип Гаяровка да каршы чыксалар?» Бу уйдан Фидая эсселәнеп китте, халык тулы залда, президиум өстәле артында үзен көчсез, ялгыз хис итте. Нишләп болай? Элекке елларда, мәктәп директоры булып эшләгәндә, ул бу сәхнәдә, шушы карасу өстәл артында, нәкъ менә шушы урындыкта күп тапкырлар утырды бит! Һәрвакыт үзен иркен, горур хис итә иде, чыгыш ясаганда да дәртләнеп, ышандырып, йөрәкләргә үткәзеп сөйли торган иде!

Фидая бу сорауга җавап эзләп, карашын алтынчы рәткә, кырыйдагы өченче урындыкка күчерде. Анда ак шәл бәйләгән, медсестра Мөнирә утырган... Мөнирә... Нигә син ул урынга утырдың? Анда... анда Мәгъсүм утырырга тиеш. Ул утыра торган иде. Һәм йөзен күтәреп, чак сизелерлек елмаеп, аңа, Фидаяга күз сирпеп куяр иде... Менә каян килә икән бу салкынлык, шыксызлык, каушау, шом! Таныш урында дәрт-көч биреп утырган кеше юк. Барысы да үз урынында, сәхнәсе дә, урындыклары да, залда тезелешеп утырган кешеләре дә, һичнәрсә үзгәрмәгән, тик ул гына юк. Ул гына юк... Аның

урынында ак шәлле хатын утыра, хәтта биектән, сәхнәдән караганда да, ул хатынның уйлары еракта икәнлеге күренеп тора. «Һәркемнең дә хәсрәте була торгандыр инде...» Ә Мөнирәнең хәсрәте бар, әнә ул, аннан алдагы рәттә, уртадарак... Гыйззетдин. Янында буш урын да бар... Бераздан ян ишектән чәчәкле шәлен төзәтә-төзәтә клуб мөдире Каләмгөл килеп керде һәм, иелә төшеп, рәт арасыннан Гыйззетдин янына юнәлде. Аның шәүләсе Мөнирәнең битен ялкын теле белән ялагандай кызартып үтте...

Ә Вәлишин Таштимерованың колхозга кылган яхшылыклары хакында сөйли иде. «Күп эшләде иптәш Таштимерова. Авыл халкы алдында абруе ифрат зур иде. Ул эшләгәндә хуҗалык бик нык үсте. Ләкин менә тормышта төрлесе була бит... Аның да сәламәтлеге какшады. Хәзергесе вакытта ул санаторийда дәвалануга мохтаҗ булды. Ул үзен бу җаваплы эштән бушатуын сорап, колхозчылар исеменә гариза язды...»

Фидая, уйларыннан арынып, залдагыларның йөзен күздән кичерде. Ничек кабул итәләр алар трибунадан сөйләнгән бу сүзләрне? «Ялган!», «Ташла!» — дип кычкырмасларммы? Шаркылдап көлә башламасларммы?

Юк, керфек тә какмыйлар.

Фидая тынычланып китте. Димәк, яңа председатель сайлау шома узачак. Теге чакта идарәдә кыланулары бер тибенеп алу гына булган, муеннар элекке камытка шома гына кереп утырган.

Шулай булды да. Дөрес, трибунага сикереп менеп, тегене эшләргә кирәк тә, моны карарга кирәк, дигән сүзләр сөйләүчеләр җитәрлек булды. Фермаларда азыкны һаман кул белән ташыйлар... Ферма буйлары тоташ саз... Тракторларга запчастьләр юк... Ягулык җитми... Авылдан яшьләр һаман китә тора, калганнарына гаилә коргач җир юк... Юк, юк, юк... Гаделша карт, трибунага менеп, эчүгә чик куярга кирәк, дип бик кызып сөйләп ташлады.

Эчтә кайнаган пар казанын шул рәвешле зыянсыз гына бушатып, дигәндәй, яңа председатель итеп Гаяровны гаугасыз гына сайлап куйдылар.

Гаяровның сүзе дә нәкъ тиешенчә булды: бергәләп эшләргә кирәк, диде ул.

Җыелыштан соң яңа председательнең торак мәсьәләсен сөйләшеп алдылар. Авылга килгән иң дәрәҗәле кешеләрне генә фатирга кертә торган Наилә апа бар, шуның белән сөйләшергә булдылар. Бүген Гаяров өенә кайтып кунačагын әйтте.

Урамга чыккач, Нурхანованың машинасы юклыгы беленде. Балкыш каядыр китеп барган иде. Ул арада клубның утлары сүнде, иң соңгы булып Гыйззетдин белән Каләмгөл чыктылар да ишекне бикләп алдылар.

— Әйдәгез, безгә кереп чәй эчеп чыгыгыз,— диде Каләмгөл.

— Юк инде, балаларыгыз йоклыйдыр, борчып йөрмибез,— диде Фидая.— Болай да кысандыр.

— И, күңел киң безнең! Әйдәгез! Якты чырай, такта чәй, ул гына җитмәсә, җырлап-биеп бирербез, күңелегезне күрербез! Шоферыгыз кызлар янына киткән булса, дөньясын оныткандыр, тиз генә кайтмас!

Аның тавышында сәбәпсез шатлык сизелә иде.

Менә алар саубуллаштылар да, бина буйлап китеп бардылар: янгыннан соң урнашкан бүлмәләре арырак, икенче ишектән керешле иде. Әнә, Каләмгөл Гыйззетдиннең беләгеннән тотып алды да, елышып нидер сөйли башлады. Иркен тота үзен Каләмгөл! Ә Фидая андый түгел, шушы авылда күпме яшәп, аның урам буйлап ире белән култыклашып узганы булмады. Имеш, мәктәп директоры буларак, үз дәрәҗәсен саклады! Тиле түгел диген! Иренең таза, кайнар беләгенә таянып, ирәеп-ирәеп йөрисе калган! Әнә, Каләмгөл кебек итеп!

Югары очтан машина гүләгәне ишетелде, фаралар белән караңгылыкны кисеп, «Газик» килеп чыкты. Нурханова белән Гаяров аңа кул изәделәр.

## 17

Җыелыш барган арада Балкыш үзе теләгән кешене күреп чыгарга барган иде. Тын калган урамны гүләтеп барды, фараларын медпункт тәрәзәләренә төбәп, машинасын туктатты. Өйнең ике генә тәрәзәсендә ут яна иде. «Үзе генәдер, мөгаен,— дип уйлады Балкыш.— Әнисе җыелыштадыр. Машина тавышыннан ук мин килгәнне чамаларга тиеш».

Ләкин ул көткәнчә булмады: Зиләйлә аңа каршы атылып чыкмады. Ишекне шак-шак шакырга туры килде. Шактый көткәч кенә эчке ишекнең ачылганы ишетелде. Көйле, нечкә тавыш:

— Кем анда? — дип сорады.

— Авыруны кабул итегез! — диде Балкыш таләпчән итеп.

— Медсестра җыелышта.

— Ай-яй, үләм, үләм! Ашыгыч ярдәм кирәк!

Өйалды ишеге шуннан соң гына ачылды.

Балкыш сул күзен учы белән каплады да эчкә атлады. Зиләйлә медпункт ягын ачып, андагы утны кабызды. Аның өстендә шактый искергән, кечерәйгән бумази халат, итәк астыннан йомры тез башлары күренеп тора, кыскарган тар җиңеннән куллары сузылып чыккан иде. Куе, кара чәчен баш артына резинка белән бәйләгән, лампа яктысында колак яфраклары алсуланып, нәфисләнеп күренде. Бу кыяфәттә аның үсмерлектән яңа чыгып килгәнлеге аеруча нык күзгә ташлана иде.

— Кая, карыйк!

Ул егеткә өстәл янындагы артсыз урындыкка утырырга ишарәләде һәм салкынча бармак очлары белән егетнең кулын тотып, күзен ачтырды.

— Ни булды?

— Чүп керде менә.

Кызның нечкә бармаклары егетнең керфекләренә орынды. Балкыш, күземне ныграк ачып карый инде бу, дип торганда, күз кабагы әйләнгән дә иде инде. Ипле икән кызның бармаклары. Кыз өстәлдәге лампаны кабызып, якын ук иелде. Аның татлы сулышы егетнең битенә бәрелде, халат түше ачылып китеп, кечкенә күкрәге күренде...

— Өскә таба кара,— диде Зиләйлә.— Уңга, хәзер сулга...

Үзе мамык кисәге бөтереп, керфекләрне назлагандай сөрткәләде.

— Әйбер-кара күренми. Күз яше белән юылып чыккандыр, бәлки.

— Ә син телең белән кара, телең белән,— диде Балкыш.

— Әбиеңә бар. Күзеңне ул ялар.

Теге сөйләшүне онытмаган икән әле. Зиләйлә стенадагы пыяла шүрлектәге нәни шешәләрнең берсен алды да Балкышның күзенә дару тамызды.

— Күзне чыгарасың бит! Белеп саласыңмы соң?

— Даруларны бутарга монда беренче көнем түгел,— диде Зиләйлә, үзе шешә тышындагы язуны тагын бер тапкыр укып алды.

— Күп эшләгән бутала да инде. Әнә безнең авылның медсестрасы төнлә торып күзенә дару тамызган икән, күз алмасы кайнап бүселеп чыккан. Шешәләрне бутаган, ди.

— Мин тиешлесен тамыздым.

— Кансыз да инде шушы медиклар, ә?

— Җебегән кеше врач була алмый,— диде Зиләйлә.— Хирургларга әнә нинди операцияләр ясарга туры килә. Җебеп төшсәләр ни булыр иде?

— Каты булырга әниеңнән өйрәнәсеңме?

— Кирәк нәрсәгә өйрәнәм. Бетте! Күзегез әйбәт карый әнә. Авыртса, иртәгә район больницасына барырсыз.

Зиләйлә, ишекне ачып, чыгарга ишарәләде. Балкыш торып баскан, әмма чыгарга ашыкмый иде. Кыз утны сүндереп, якты өйалдына чыкты да борылды. Караңгыда калган егет аңа йотылып карады. Аңа Зиләйләнең бөтен йөз сызыклары, буй-сыны шулкадәр камил күренде ки, сулышы киселде. Матурлык алиһәләрен рәссамнар шушындый кызларга карап ясыйлардыр. Тик бер ягы: ничектер җансыз, хиссез кебек иде ул, чыннан да, таш сынга охшаган иде. Сүзләре төртмәле, чырае караңгы. Ә бу яшьтә кызларның күңеле кузгалган була, алар Балкыштай егет белән аулакта ялгыз калганда каушамый түзмиләр. Нишләп мондый дорфа бу Зиләйлә?

— Ягез,— диде,— нишләп торасыз тагын?

— Кая ашыгасың ул хәтле?

— Эшем бар.

— Нинди эш төн уртасында?

— Телевизор карыйм.

— Минем дә икенче серияне карыйсым килә,— диде Балкыш, кичә фильмның беренче сериясен күрсәткәннәрен исенә төшереп. Кыз дәшмәде, өйалды ишегенә барып, биккә кулын сузды. Ул Балкышны озатырга, чыннан да, ашыга иде.

— Бу минем сәламәтлеккә зур зыян китерәчәк,— диде Балкыш, ишек төбендә туктап.— Икенче серияне карамасам, кәефем кырылачак, ул нервыга сугачак. Бөтен чир-чор нервыдан азганны син белергә тиеш. Ә мин, медик булмасам да, кеше хәленә керә беләм, караңгыда, юл чатында ялгыз калдырмыйм.

— Мин телевизор караганда сөйләшергә яратмыйм,— диде кыз. Аның тавышында икеләнү сизелде.

— Мин дә шундый, икенең берсе: йә телевизор гына карыйм, йә кызлар белән генә сөйләшәм.

Зиләйлә өй ишегенә юнәлде. Алар, чыннан да, бер сүз сөйләшмичә, икесе ике ялгыз дигәндәй, кечкенә телевизор экранына карап утырдылар. Зиләйлә өйдә чит кеше барын бөтенләй хәтереннән үк чыгарган иде шикелле.

Мөнирә кайтып керде дә, өйдә чит кеше күреп, гаҗәпләнде. Балкышның күзен янә бер кат карады, чүп кергән иде дигәненә ышандымы-юкмы, һәрхәлдә шактый шикләнде бугай. Кәефе юклыгы йөзенә чыккан иде.

## 18

Суташка кайтканда Гаяров нык дулкынланган иде, теле ачылды, алгы утыргычта утырган Нурхановага таба авыша төшеп, Баллыболын кешеләрен сораштыра башлады. Иртәгә таңнан килеп, аңа бу кешеләр белән бергәләп эшкә керешергә кирәк булачак иде бит.

— Парторг Вәлишинның эчендәге тышында, кем икәнлеге күзгә күренеп тора. Бүре кебек ярылып ята. Зыянсыздыр, мөгаен, тик йомшаграк, ахрысы. Сүзен тыңлата белмидер.

— Шулайрак шул,— диде Нурханова.

Күзгә кылчык кебек керә торган Гаделша карт турында сөйләшеп алдылар.

— Анын белән сак булырга кирәк,— диде Нурханова.— Бер кадалган җиреннән талпанны суырып алып була, моны булмый. Гадәттән тыш намуслы булуы бер хәл, намусын тыя белми.

— Ничек тыя белми? — дип гаҗәпләнебрәк сорады Гаяров.

— Намус бик җайсыз нәрсә бит ул,— дип җавап бирде Нурханова житди итеп.— Кайда нинди гаделсезлек, тәртипсезлек, көйсезлек күренсә, шуңа каршы эчтә ут булып яна башлый. Шул эчендәге утны тыя белмәсәң, бөтенесен җайларга, көйләргә, тәртипкә салырга кирәк. Ә Гаделша абзый тыела белми... йөри башлый тирә-ягына очкын сибеп. Шактыйларны шулай яндырды инде. Таштимерованы төшерүче дә асылда шул булды. Аның: «Саф намуслы ветеран буларак сезгә шуны хәбәр итәргә тиеш табам ки...» — дигән хатлары районлагы бөтен җитәкчеләргә мәгълүм. Сез дә озакламассыз, танышырсыз дип уйлыйм.

— Бар икән күрәселәр,— дип авыр сулады Гаяров.— Ә теге клуб мөдире нинди рәк? Анысын чегән таборыннан алганнармы әллә? Аны да яратмаучылар бар, ахрысы...

— Яратмаслар шул...— диде Нурханова.— Көндәшне кем сөйсен. Медсестрабызның ирен аерып алды бит ул. Авыл хатыннарының кырын каравына түзә алмыйча, баштарак Гыйззетдинне алып китәргә бик тырышып караган үзе. Ул чыгарган такмакларны әле дә сөйләп, көлеп йөриләр:

Өзелеп әйткән сүзләремне тыңласана, Гыйззәтлем,
Шушы авылга ябышып кына тормасана, Гыйззәтлем.
Туган җирдәй булмаса да торган җирләр, Гыйззәтлем,
Чын сөюем ул җирләрне оҗмах итәр, Гыйззәтлем.
Уйнап түгел, уйлап әйтәм, ишетсәнә, Гыйззәтлем,
Тәвәккәлләп, бу авылдан китиксәнә, Гыйззәтлем!

Җырлап та такмаклый икән, имеш, Каләмгөл, елап та, тик тегесе бирешмәгән, имеш. Синсез дә яши алмыйм, илсез дә яши алмыйм, мине дә әйдәмә, үзең дә китмә, гомерлеккә бәхетсез итмә, дигән, имеш, Гыйззетдин.

— Кара аны, такмак белән генә сөйләшәләр микәнни шулай? — диде Гаяров, гаҗәпләнеп.

— Булыр да,— дип, көлеп җибәрде Фидая.— Аларның гыйшкын авылда бер мәзәк итеп тә, гыйбрәт итеп тә сөйлиләр инде. Гел әкәмәт...

Фидая, ачылып китеп, Каләмгөл — Гыйззетдин — Мөнирә кыйссасын сөйли башлады. Барысын да тел белән әйтеп бетереп булмый, бигрәк тә чит кешегә, хәтереннән күпкә тасвирлырак чагылып узды бу өчәүнең язмышы.

...Фидая Баллыболын мәктәбендә пионервожатый булып эшләгән елны Мөнирә белән Гыйззетдин бик матур яшәп яталар иде. Бер-берсенең күзләренә генә карашып торалар, икесе дә бик чибәр, чәчәк кебек кыз үстерәләр. Авыл хатыннары аларның мәхәббәтен кызыгып сөйли иде. Бер класста укыганнар, мәктәптә чакта ук бер-берсенә гашыйк булганнар, егет армия хезмәтен, кыз медицина училищесын тәмамлагач, өйләнешкәннәр. Тормышлары тәртип-әдәп белән, матур итеп көйгә салынган. Алар урамнан узганда, ата-аналар: «Безнең балалар да шушылай бәхет-тәүфикъ лары белән үссеннәр иде»,— дип теләп кала торган булганнар.

Ни гаҗәп, Фидая институтта укыган арада, бу парның бәхете җимерелгән булып чыкты. Ул киткәндә әти-әнисе кулында чәчәк кебек үсеп килгән Зиләйлә, ул кайтуга, өченче класска күчкән иде инде. Фидая аны танымады. Түгәрәккә укучылар җыеп йөргәндә, класска кереп, балалар белән танышканда, рәттән аны да бастырып, исем-фамилиясен сорады. Кыз аңа каш астыннан сөзеп, ничектер сабыйларча түгел, өлкәннәрчә карады. Ул тиз генә җавап

бирмәде, тынлыкта шук малайларның берсе бөтен класска ишетерерлек итеп: «Кыйбатлы кыз ул безнең»,— дип пышылдады. Кызчыкның йөзе кызарып чыкты, башы иелде. Ул фамилиясен дә кат-кат сорагач кына әйтә алды.

Фатирына кайткач, Фидая Наиләдән шуны сорашып белеште: Гыйззетдин яшьли сөеп өйләнгән Мөнирәсен ташлаган, клуб мөдире булып эшкә килгән балалы хатын Каләмгөлгә өйләнгән. Кызы Зиләйләгә күп итеп акча түләп тора, чөнки авылның иң шәп механизаторы, эш хакы зур. Шуңа күрә Зиләйләгә «кыйбатлы кыз» дип кушамат такканнар...

— Авылга кертәсе түгел иде ул мөртәт чегән токымын,— диде Наилә.— Миңа да фатирга кертмәкче булганнар иде, якын да китермәдем. Бер күрүдә таныдым кем икәнен. Сихерләп әллә нишләтеп бетерер, алла сакласын!

«Сихерче», «күз буучы» дигән дан Каләмгөлнең нәселеннән килә булып чыкты. Имештер, аның атасы тирә-юньдә исеме таралган күз буучы булган. Аның кешеләрне саташтырып әвәрә итүе хакында әллә нинди мәзәкләр сөйлиләр. Имеш, бервакыт бу күршесенә кергән, ә анда утырмага килгән кызлар бәйләп-чигеп утыра икән. «Күл ясап, үрдәк йөздереп күрсәтимме, кызлар?» — дигән бу. Кызларга кызык, күрсәт, күрсәт, дигәннәр. Шуннан, ни күрсеннәр, бер заман идәнгә су җәелә башлаган. Күтәрелә икән су, сәке йөзлеген кумган, аннары өстәлне. Кызлар сәке өстенә басып, итәкләрен күтәргәннәр... Ә ишектән тезелешеп үрдәкләр йөзеп керә башлаган. «Әйдәгез, кызлар, берсен суеп бирим әле, пешереп ашарбыз!» — ди икән Baһави. Берне түгел, икене тотып суйган бу. Шуннан ул кызларга үрдәк түшкәләрен биреп, үзе чыгып киткән. Карасалар, су да юк, үрдәк тә, кызлар исә итәкләрен күтәреп, сәкедә басып торалар, икесенең кулында ике галуш, галуш башлары киселгән, ди...

Каләмгөл кечкенәдән гармун уйнарга, мандолина чиртергә өйрәнгән, авылга килгән чегәннәрдән җыр-биюләр отып кала торган булган, имеш. Чегәннәр аны урларга да маташканнар, имеш.

Каләмгөл культпросветучилищеда укыган, соңгы курста чакта, гастрольгә килгән чегән ансамблендәге бер артистка гашыйк булып, аңа ияреп китеп барган. Шул чегәннәр белән җырлап-биеп, концертлар куеп йөргән. Ләкин аларга бөтенләй үк берегеп китә алмаган, күрәсең, иреннән аерылып, алты яшьлек кызын ияртеп, Суташка кайтып төшкән, район культура бүлегеннән аны Баллыболын клубына җибәргәннәр. Ул җәйне Таш Ниса клуб мөдире — Җәмит исемле яшь егетне пыр туздырып: «Гармун шыңгырдатудан бүтәнне белмисең, бөтен кеше чөгендердә чакта клубта бикләнеп ятарга ничек оялмыйсың, гармунны синең хәтле генә мин дә тарткалыйм аны!»— дип, куып чыгарган булган.

Каләмгөлнең авылга килүен халык кыйсса итеп сөйли. Урак өсте икән, халык эштән кайта, бөтенесе клуб турында туктап калган, анда зур төркем җыелган. Ишек төбендә кара чәчен иңнәренә туздырган бер яшь хатын мандолина чиртеп утыра, шундый ук бөдрә чәченә кызыл бант бәйләгән нәни кызчык тузан туздырып биеп ята икән.

— Егетләр-кызлар, абыйлар-апалар, әбиләр-бабайлар, эшегез беткәч, клубка килегез! — дигән чәчбикәнең өлкәне, кечкенәсе биеп туйгач.— Мин сезнең клубка директор булып килдем.

Клубны ачып керүгә, Каләмгөл тәрәзә төбендәге ак чиләккә бармагы белән китереп тарткан:

— Бу ни дигән сүз?

— Коедан су кертеп куям, эчәргә,— ди икән Наилә. Аның клубта җыештыручы булып эшләгән чагы икән.

— Шуннан эчәләрмени?

— Тамагы кипкәне эчә инде. Күтәрә дә эчә.

— Кыр батырларына чиләк белән су бирүне кем уйлап чыгарды? Бу заманда сыерга да суны чиләктән эчермиләр. Махсус эчергеч куялар. Монда самавыр булырга тиеш!

Сәхнә янына баргач, кино экранындагы тишекләргә кулын тыгып караган.

— Бусы ни тагын?

Чегәннәрдән бию-җыру гына түгел, башка һөнәрләргә дә өйрәнгән булгандыр, мөгаен, Каләмгөл, ә бәлки, ата-баба канынннан килгән осталыгы бардыр, һәрхәлдә, ул бер-ике көн эчендә Таштимерованы тыкырдатып, клубка самавыр алдырткан, кино экранын гына түгел, тәрәзә пәрдәләрен дә алыштырткан. Идарә янындагы тактага гына түгел, урам почмакларына да игъланнар элгән:

Шимбә кичне концерт була, гафил булып калмагыз,
Йөгереп килсен өлкәнегез, һәммә бала-чагагыз!

Ике-өч көн эчендә авылга урып-җыюда ярдәмгә килгән студентлар, өлкән класс укучылары белән бергәләп концерт та оештырып өлгергән ул. Бик кызык номерлар булган, дип сөйлиләр. Ул сәхнәдә утлар биешеп торган, ди. Магнитофон бик хикмәтле заман көйләрен уйный, ә сәхнәдә чәчләрен төрле тасмалар белән бәйләгән, сылу студент кызлар, егетләр, гитаралар чыңлатып, җырлагандай итенәләр, ди. Ләкин иң шаккатырганы Каләмгөлнең үзенең өермәдәй бөтерелеп, чәчләрен җилфердәтеп, чутсыз киң, озын кызыл итәген болгандырып ут чәчеп бию булган, диләр. «Яшь ирләрнең, егетләрнең күзләрендә фонарь кабынгандай булды,— дип сөйли Наилә, бер дә өнәмичә.— Авызларын ачтылар да карап каттылар...»

Бу исерүдән башкалар ничек айныгандыр, ә менә Гыйззетдин айный алмаган. Эшеннән кайтканда гел клубка сугыла, ә анда Каләмгөл тегене-моны үзгәртеп, ясап кына тора, оста кулдан ярдәм гел кирәк икән.

Авыл кешесенең күзе аның ишене тиз күрә. «Сихерләгән, сөйдергеч ясап эчергән»,— дигән сүзләр йөри башлый. Моңа чын күңелдән ышанучылар да була, чөнки Гыйззетдиннең тәмам күзе тонган, хатыныннан яшерүне дә, кешедән оялуны да белми, Каләмгөлне күрсә, авызы ерыла, дөньясы онытыла икән.

Каләмгөл, кеше сүзеннән куркып, Гыйззетдинне ялгызын клубка бөтенләй кертми, аның белән сөйләшми башлаган. «Юри кылана, канын кыздыру өчен тырыша,— диләр хатыннар.— Сихерләп сөйдерә дә, яндырып-көйдерә».

Чыннан да, Гыйззетдин бер-ике ай эчендә ябыгып киткән, төс ташлаган, ди, имеш. Бер заман кичкә таба кое янында берничә хатын сөйләшеп торалар икән. Ул чакта авылга колонкалар куелмаган, суны коедан алалар иде. Арада Каләмгөл дә булган. Шунда Гыйззетдин узып барган җирдән туктап, эчәргә су сораган. Бер шаяны әйтә икән шунда: «Кем чиләгеннән эчсәң, килгәнне бик беләбез! — ди икән.— Каләмгөл, ышанма син аның кыланмышларына! Ирләр буш сүз сөйләргә оста алар! Менә син аңа әйт әле, сөюләрең чыннан булса, коега үзең төшеп чиләгемә су алып бир, диген. Төшми, билләһи! Курка! Томау төшәр дип коты оча!» Хатыннар шаркылдап көлә икән. Каләмгөлне җир тишегенә керердәй иткәннәр. Шуннан ни дип беләсез? Гыйззетдин сиртмә бавына тотынган да төшкән коега. Сизми дә калганнар.

Бөтен авыл ду килгән. Ирләрне җыйганнар, Гыйззетдинне тартып чыгарганнар. Хатыннар, суны арусызладың, юньсез, дип аны көянтә белән дөмбәсләргә тотынганнар. Шундук Таштимерова килеп чыгып, Гыйззетдинне районга милициягә озаттырган. Район үзәгеннән янгын сүндерү машинасы чакыртып, коеның суын суырттырганнар —

газартканнар. Гыйззетдинне хулиганлыгы өчен унбиш тәүлеккә утыртып куйганнар.

— Шул юк нәрсә өченме? — дип сорады Гаяров.

— Аның бит үзенең хикмәте бар! Гыйззетдиннең кулыннан килмәгән эш юк. Андый кеше — алтын бәясе. Районның баш врачы белеп алган да моның эләккәнен, срокны күбрәк бирүне сораган, унбиш көн буе больницада эшләткән тегене. Кухняда аның өчен махсус ашның тәмлесен пешереп тордылар, дип сөйлиләр. Ә хатыны Мөнирә — медсестра, больницага эше төшеп тора, барырга кирәк, очрашырга туры килә. Авыл тулы сүз, больница тулы сүз, бөтен карашлар аңа төбәлгән...Аның да эчендә җаны бар бит. Кыскасы, Гыйззетдин әйләнеп кайтканда, Мөнирә, кызын алып, авылдан чыгып киткән булган инде. Урынына медсестра итеп бер яшь кызны җибәргәннәр аннары. Тик ул кыз Мөнирә кебек эшли алмады, диләр. Бер елдан әйләнеп кайткан Мөнирә. Теге кызны шундук Кармаш больницасына күчереп, урынын бушатып биргәннәр. Яңа медпункт төзегәннәр, квартиры-ние белән.

Нурханова боларны Гаяровка сөйли, рульне куллары белән гадәттән тыш киеренке тотып, башын алга сузыбрак юлга текәлгән Балкыш барын уйламый иде. Хәлбуки, егет ул сөйләгәннәрне йотлыгып тыңлады. Яшьлек мәхәббәтеннән яралган бала, сөешеп яшәгән ир белән хатын кулындагы сокландыргыч матур чәчәк... Аннары — «кыйбатлы кыз», этисенең әнисе белән түгел, башка бер чит хатын белән култыклашып-гөрләшеп йөргәнен күреп торучы... Әти-әнисе хакында йөргән сүзләрне ишетеп үсүче кыз...

Ничек бәгыре катыланмасын, яше түгелмәсен Зиләйләнең?

## 19

«Кара син аны,— дип уйлады Давыт Гыйззетдин турында.— Карап торуга әйбәт кенә адәм сыман үзе. Кулыннан эш тә килә икән. Хатын-кыз артыннан миңгерәп йөргән кеше, гадәттә, уңмаган була. Ә бу, шундый ир була торып, итәк артыннан чабып, адәм хурына калган. Ахмак! Бөтен халык күз алдында, мин бу хатынны яратам, дип, коега төшәргә кирәк бит, ә! Мәзәк кеше ул гына микән бу авылда, әллә иләс-миләсләре тагын бар микән? Ничек эшләмәк кирәк андыйлар белән?»

Гашыйк булдым, чыдар хәлем юк, дип мескенләнеп кызлар артыннан сөйрәлеп йөргән егетләрне яшь чакта да аңлый алмады Давыт. Инде ике хатын арасында буталып йөргәннәре, аныңча, бөтенләй адәм түгел иде! Әгәр ир-егетләр хатын-кыз итәгенә дөмегеп йөри икән, бу дөньяны кем тотар, эшен кем эшләр, көйсезлекләрен кем көйләр, җайлар? Әлбәттә, хатын-кызны тора салып җәберләргә ярамый, аларны кайгыртырга, кызганырга, кирәк чакта ярдәм итәргә кирәк. Балаларга ярдәм иткән шикелле. Ләкин ир кешенең аннан башка да мөһим эшләре күп бу җиһанда. Хатын-кыз ул — үз өең шикелле. Өйнең көйле-җайлы, ямьле булуы яхшы, ләкин ир кеше анда гына бикләнеп ята алмый, ул дөньяда — хезмәттә, иҗатта, яуда — зур эшләр майтарып йөргәндә, хатын-кыз өйнең бөтенлеген, иминлеген саклау өчен кирәк...

Дөрес, ул үзе дә Фазиләгә аек акыл белән сайлап, исәп-хисап белән генә өйләнде, дип әйтеп булмый. Ул Фазиләне студент яшьләрнең бию кичәсендә бер күрүдә ошатты. Кыз кичәгә таза гәүдәле, түгәрәк ак йөзле, үз-үзенә бик ышанган кыяфәтле егет белән килгән иде. Давыт читтән генә аларның биегәнен, сөйләшкәнен, елмаешканын күзәтеп торды да, бер җаен туры китереп, яңа көй әле генә башланган, егетнең йомарланган кулъяулыгы белән тирләгән битен сөрткәләп

торган чагын туры китереп, залны әйләнеп, кыз тарафына юнәлде. Озын буйлы, нечкә билле, кара чәчен баш артына бик килешле итеп төйнәп куйган, озынчарак битле кыз бу минутта бөтен язмышын хәл итәчәк егетнең үзенә таба килгәнен белми, шуңа күрә аңа түгел, әче пошканрак кыяфәт белән каядыр читкә карап тора иде. Бер нәрсә ачык: таза егеттән бераз гына вакытка котылыбрак торырга каршы булмаячак иде ул. Һәм бу, чыннан да, шулай булып чыкты. Кыз Давытның баш иеп чакыруына елмая төшеп җавап бирде, алай да егетеннән ризалык сорагандай итеп, аңа күз ташлап алды. Һәм алар зал буйлап бөтерелеп киттеләр, беренче адымнардан ук буй-сыннарының да, адымнарының да бер-берсенә бик туры килгәнен аңлап алдылар. Көй тәмамлангач, кыз егете янына барып басмакчы иде. Давыт аны озатып куймады, юк, ул аны хәтта яныннан да җибәрмәде, озын, салкынча бармакларын учына кысып торткан килеш басып торды, кызның тартылганын сизмәмешкә салышты. Алар икенче, өченче, дүртенче тапкыр биеделәр. Биюләрнең салмагын, кызуын. Ниһаять, кыз:

— Миңа китәргә вакыт,— диде.

— Бергә китәрбез.

— Минем озатып куючым бар.

— Бар, әлбәттә,— диде Давыт, җитди итеп.— Мин ул. Мин озатып куям сине.

Менә шулай, бер күрүдә үзенә буйсындырып та куйды кызны Давыт. Тырпылдатмады да. Һәм дөрес эшләде.

Яшәешнең мөһим мәсьәләләрен үзе хәл итә Давыт, хаталанса, үзен гаепли, хатын сүзен тыңладым, шуның белән хур булдым, дигән сүзне кешегә сөйләү түгел, үз башына да китерми.

Бу юлы да, һич көтмәгәндә, Искәндәров аңа «Үзәк»нең председателе булырга тәкъдим иткәч, ул үз акылы белән бөтен ягын уйларга, яхшысын-яманын бик төгәл үлчәргә тиешлеген һәм бу очракта кабул ителгән карары бөтен киләчәген, язмышын хәл итәчәген аңлап алды. Искәндәров исә ашыктыра иде:

— Иртәгә үк Казанга барырга кирәк булыр.

— Хатын ни әйтер бит әле, аннан сорыйсы бар.— Давыт Искәндәровның күзлек аша зураеп күренгән күзләренә хәйләкәр көлемсерәп карады.

— Үз хатыныгыз белән уртак тел табарсыз анысы,— диде Искәндәров.— «Үзәк»тә йөзләгән хатынны тыңлатасы бар бит әле.

— Чит хатыннарның йөзен дә тыңлатып була, үз хатыныңа сүз үткәрү авыр,— диде Давыт.

Искәндәров, көлемсерәп, башын чайкап куйды.

Шаярып әйткән бу сүздә хаклык та бар иде, әлбәттә. Ни генә димә, Фазилә дә боламык түгел, ире «айт» дигәнгә «тайт» дип кенә тормый. Ул үз дәрәҗәсен яхшы белә, башын югары тота. Давыт, кайтып, аның башына органдай кинәт кенә, Баллыболынга күчәргә туры килмәгәе, диюгә, Фазилә, утырган урыныннан сикереп үк торып, шактый кызып китте. Бу нинди санашмау? Ничек инде ул төбең-тамырың, бөтен гаиләң белән бер урыннан икенче урынга күчеп китү турында сүз барганда, аның белән киңәшмиләр? Мондый чакта хәтта районның иң зур җитәкчеләре, Фазиләне чакырып алып, әйбәтләп сөйләшсәләр дә артык булмас иде!

Давыт каршы дәшмәде, хатынның кычкырасын кычкырып бетергәнен көтте. Аннары:

— Бер дә башың катмасын,— диде.— Әле Казанда нәрсә әйтерләр? Аларга ошыйммы, юкмы, анысын уйларга кирәк.

— Һи, моннан җибәргәнне бракка чыгармыйлар инде анда,— диде Фазилә.— Аларга кем кирәк тагын? Председатель булып та мөгезле кешеләр эшләми!

Ул пыр-пыр килеп ирен зур начальниклар каршына барып басарга әзерли башлады: өр-яңа ак күлмәк, кара костюм, ялтырап торган ботинкалар, затлы одеколон, килешле галстук, хәтта яңа оекбашлар — бөтенесе әзер, бөтенесе пөхтә. Давыт аны эчке бер канәгатьләнү белән күзәтте, бу канәгатьлек хисе аның үзенә карата иде: хатынны сайлый белде бит! Фазилә — аның өчен менә дигән тыл. Әгәр уйлап карасаң, чит ил миллионерларыннан кимме әллә ул? Миллионер булу нәрсә дигән сүз ул? Ул — синең кесәдә миллион акча йөри, дигән сүз түгел. Ул — син чиста күлмәк, әйбәт костюм, кулъяулык, оекбаш турында уйлап башыңны катырмыйсың, алар сиңа әзер килеш китереп бирелә, сине ваклык изми, дигән сүз. Шуңа күрә синең башың югары, кыяфәтең горур, дигән сүз ул. Давыт, урманда яшәсә дә, дөнья хәлләрен белеп тора, Мәскәүгә дә баргалый, анда бик шәп танышлары бар, алардан алып, чит илләрдә чыга торган кайбер журналларны караштыргалый. Ул бүген нindирәк сәгатьләр, радиоалгычлар модада икәнен яхшы белә, тик менә костюмның ипле-килешле булуы ягыннан гына чит ил бизнесменнарыннан калышканын күрә.

Алай да, Казандагы җитәкчеләр каршына Гаяров тегеләрнең үзләреннән кәттәрәк кыяфәттә барып басты. Баллыбolынга җыелышка баргач та, күпләр аны гаҗәпләнеп күздән кичерделәр: авыл җирендә дә бик пөхтә, матур йөрүчеләр бар, әмма Гаяров бик дәрәҗәле артист яисә министр кебек иде. Җыелышта берәү: «Музейга куярлык бу егетнең кыяфәте,— дип куйды.— Татар кешесе менә шундый була, дип башка халыкларга күрсәтә торган. Югыйсә, безне ямьсез дә кыргый дип уйлаучылар бар бит! Хуҗабыз мондый булгач, иншалла безгә дә кыяфәт кермәсме!»

Кыяфәтне сакларга кирәк иде. Беренче көнне ирен эшкә җибәргәндә дә, Фазилә төн уртасында торып, күлмәк-костюмнарын өр-яңадан үтүкләде, ботинкасын көзгедәй ялтыратып кигезде. Идарәдә нәрәтне Вәлишин бирде, Гаяров, үзен күрсәтеп, дигәндәй, читтәрәк тыңлап кына утырды. Аннары Наиләгә киттеләр. Апа аларны табын әзерләп каршы алды. Чәй ясаганда, бераз тегене-моны сөйләшкәч: «Хатының бик әйбәттер, мөгаен, сиңа кер кундырмый икән,— диде.— Безнең авыл халкы андыйны бик тикшерә бит. Үзенә әйбәт хатын сайлый белгән иргә бөтәннең дә ышанычы зур була. Безнең Ниса, бичаракаем, ул якны бер дә карый белмәде шул. Казанга-фәләнгә озатканда, авыл сәвите персидәтеле Нәзифә үз күлмәген кигереп җибәрә торган иде. Матур киенүне дә азгынлыкка саный торган иде безнең Нисабыз, авыр туфрагы җиңел булсын».

— Нишләп алай дисез, үлмәгән бит әле ул,— диде Давыт.

— И-и, безгә шул гыйбрәт итеп сөйләргә генә калды бит инде,— диде Наилә көрсенеп.

Ярый, шулай итеп, яңа председательне пөхтәлеге өчен мактадылар, элеккесен тәнкыйтьләп алдылар. Әмма чәйдән соң Наилә, Давытны тагын бер тапкыр күздән кичерде дә, каяндыр өйалдыннан иске кожанка алып кереп бирде:

— Сыяр микән инде бу,— диде.— Безнең Минневафа, мәрхүмкәем, гәүдәле кеше иде. Җилкәсе киң, кыскарак булыр булуын, астыңа салып утырырга палас бирермен.

Давытның аптырап торганын күреп, аңлатуны кирәк тапты:

— Басулар, фермалар буйлап бу матур бишмәтеңне киеп йөрмәссең бит инде,— диде.— Кичкә элә-танагы калмый аның. Эшләпәңне дә алыштыр, Минневафа мәрхүмнән калган бар бугай әле...

Давыт Минневафадан калган искеләрне киюдән көчкә котылды, алай да олы резин итекләрне машинага салырга рөхсәт итте, чөнки ялтыравык ботинка белән күп җирдә машинадан чыгып булмасын Вәлишин дә кисәтте.

Чыннан да, ферма янына баруга, машинадан шул резин итекләрне

киеп төшәргә туры килде. Тездән саз иде. Тигезле-тигезсез акшарланган тәбәнәк озын ферма бинасының эченә кергәч, Давытка автоэчергечләрне ремонтларга киреклеге, тирес чыгара торган транспортерларның юклыгы мәгълүм булды. Анда-санда түбәдән яктылык төшә, ишекләр какшау иде.

Җәйләүгә баргач, Давыт хатыннарның аркаларына капчык салып йөргәнен күрде дә:

— Ни ташыйлар алар? — дип сорады.

— Үз сыерларына тиешле онны,— дип җавап бирде Вәлишин.

— Нишләп аны скотниклар ат белән таратмый, сыртлары кәҗүнниме әллә?

— Он кулга тигән саен кими бит ул, үз сыерларына тиешлесен тулысынча аласылары килә,— дип аңлатты Вәлишин.

Тышкы яктан «Мул савым алуга ирешик!» дигән кебек лозунглар белән бизәлгән терлекчеләр йортына савымчыларны җыеп сөйләштеләр. Барсы да илледән узган, таушалган чырайлы, калын бәдәнле, моңлы күзле апалар. Өсләрендә иләмсез бишмәт, аякларында пычранган резин итекләр. Кайберләре оек эченнән тезләрен калын итеп урап куйганнар — аяклары сызлый, күрәсең. Ләкин зарлану-уфтануның әсәре дә юк, бик тыйнак, тыныч утыралар. Хәл сорашканга:

— И, хәзер эш җиңел инде, җан рәхәте, элек кул белән сава торган идек, суны көянтә-чиләк белән ташый торган идек,— дип сөйләргә керештеләр. Гүяки, алар яңа председатель каршында үзләрен ни өчендер гаепле саныйлар һәм аны юаталар иде. Бер мизгелгә Давытның күңелендә аларга карата ачу кузгалды: «Сез нәрсә, үзегезнең кайсы заманда яшәгәнегезне оныттыгызмы әллә? Ни рәхәт күрдегез сез, ни кадер? Нишләп мондый кыяфәткә кердегез? Сез дә бу җирдә бер генә тапкыр яшисез, нигә үзегезне бу хәлгә дучар иттегез?» — дип сорыйсы килде. Ул үзенең кыяфәте өчен, ап-ак күлмәк якасы, пөхтә эшләпәсе, галстугына кадаган елтыравык булавкасы өчен оялды. Әгәр шушында кинога төшереп алучы булса, бер феодал булып күренмәс иде микән? Ләкин шундук төрле гамьнәр аның бу хисләрен оныттырды, кызгануын да, ризасызлыгын да юып алды. Сөйләшә торгач, терлекчеләрнең фермада ничә сыер, ничә тана асралганын төгәл белмәве ачыкланды.

— Ничек инде сез үзегез караган малларның баш санын белмисез?

— Көн саен үзгәреп тора бит ул, кайсын группадан группага күчерәләр, кайсын иткә озаталар,— дип сөйләнде Вәлишин. Давыт куен дәфтәрен чыгарып, инде тулып килгән битенә тагын бер җөмлә язып куйды: «Бүген үк терлекләрнең төгәл исәбен алырга!»

Янәшә басуда хатыннар актарылган чөгендерләрнең яфрагын кисеп, өемнәргә өяләр иде. Аларны өйләренә җибәрергә мөмкин түгел. Хәер, бу өлкән апаларның язмышы хәл ителгән, гомере шул тәртип белән яшәп узган бит инде...

Басудан кайтканда, Давытның күзе авыл читендә салына башлаган яңа урамга төште: анда биш таш йорт ерактан ялтырып, күзгә ял биреп торалар иде.

Йортлар яңгырлардан соң куерып күтәрелгән тигез чирәмлеккә салынган, анда илтә торган юл да такыр булып чыкты. Әмма аларның каршында тирән озын канау казыганнар икән, машина белән яннарына ук барып җитеп булмады. Ихата белән дә әйләндерә башлаганнар, тик нигәдер башлаганнар да ташлаганнар, кыйшайган баганалар тырпаеп тора, анда-санда яңгырдан күгәргән такта өемнәре аунап ята.

Өйнең эче тагын да котсызрак булып чыкты. Җимерелгән мич, актарылган идән такталары, тутыккан торбалар. Бүлмә ишегенең тактасын каезлаганнар, ул фанер гына икән, арасыннан пычкы чүбе коелган. И ясап та куялар инде бездә әйберләрне кайчак! Тырнак белән чиртсәң таралырга тора...

— Яшь семьяларны торгызып караган идек тә, чыгып качтылар,— диде Вәлишин.— Балалары чирдән арынмады. Мөнирә әйтә, өй дымлы булганга, ди.

Чыннан да, ачык идән астында су ятканы күренә иде.

— Су чыгасын башта белмәгәннәрмени? — дип сорады Давыт.

— Карарга тиешләр иде. Проект белән эшләнде бит.

— Ә син? — дип сорады Давыт Вәлишинга өстән карап.

— Мин нәрсә, мин ул чакта парторг түгел идем. Мәктәптә укыта идем.

Давытның ризасызлыгын сизеп, тагын аңлатты:

— Монда сугарулы җирләр якын бит. Әнә бу рәтнең,— дип артына ишарәләп күрсәтте,— базларына җәй уртасында су төшә. Кайсыларының бәрәңге бакчаларына камыш үсә башлады. Генеральный план буенча бөтен авылны шушында күчерергә тиешләр иде әле.

— Кемнәр?

Вәлишин бермәлгә югалып калды. Чыннан да, кемнәр? Кемнәр генә булмасын, биредә яшисе кешеләр түгел. Авыл халкының үз чамасы булган, ул әнә йөзме, ике йөзме ел элек, йортларын үргәрәк салган... Ул чакта, күрәсең, читтән килеп, генеральный план сызып бирүчеләр булмагандыр...

— Безнең җирләр кая кадәр соң әле монда? — дип сорады Давыт, чирәмлеккә чыккач.

— Әнә, теге полосадан,— дип офыкка ымлады Вәлишин. Анда, күгелҗемләнеп, шәрәләнгән агачлык шәйләнә иде.

— Бик иртә яфрак койган,— диде Давыт.

— Корыганнар алар,— диде Вәлишин.— Әллә нәрсә ярамый, самолеттан агу койганнан да куркәләр,— дип өстәде аннары. Чирәмлек кырыеннан офыкка кадәр сузылган басуларның күп өлеше сөрелгән, ундарак яшәреп уҗым җәйрәп ята иде. Бу иркенлекнең очы-кырые юк иде кебек.

Боларның һәммәсе хәзер Давытка ышанып тапшырылган микәнни?

Әгәр чыннан да шулай булса, Давытның байлыгы чамасыз иде. Ләкин Давыт үзен бай һәм кодрәтле итеп тоя алмады. Киресенчә, кырларның иркенлеге, малларның исәпсезлеге аның иңнәрен басты кебек.

Кире Наилә апага әйләнеп кайтканда, аның кыяфәте нык үзгәргән, костюмы таушалган, итекләре пычранган, башы иелгән иде.

Кичке якта идарәгә килгәч, ул киң коридорда җыелган алты-җиде ир-ат арасыннан бүлмәсенә узды. Борынына хәмер исе бәрелде, колагына: «Хуҗалар килә тора, китә тора, без һаман монда кала торабыз»,— дигән сүзләр чалынды.

Иң элек шул мәгълүм булды: ит комбинатына дуңгызлар илткән булганнар икән, кабул итмәгәннәр, йөз чакрым араны әйләндереп, малларны кире алып кайтканнар. Һәркайсы кило ярым авырлыгын югалткан, ярый әле үлмәгәннәр.

— Быел җир иртә катырыр, мөгаен,— дип сөйләп утырды Гадельша карт.— Ун ел элек тә шулай булган иде: синтәбердә тотынды коярга, бер туктамады, шул көйдән үктәбр уртасында катырып та куйды. Балта белән ватып җыйдык чөгендерне, балта белән!

Аның уйларын телефон бүлдерде:

— Карале,— диде трубкадан көр тавыш.— Нишләп савым кимеде сездә? Бер көн эчендә ярты килога киметкәнсез. Комиссия җибәрикме әллә?

— Туктагыз әле, баш-күз алырга ирек бирегез! — диде Давыт ачынып.

Фермадан ревкомиссия әйләнеп кайткан икән, сыер-тана баш санының очына чыга алмаганнар. Каршысында кыюсыз гына тезелеп

утырган өч кызга Давыт гаҗәпләнеп карады. Аларның гөнаһсыз чырайлары, беркатлы күз карашлары тәмам ачуны чыгарды.

— Сез нәрсә,— диде Давыт,— сыерны танадан аермыйсызмы әллә?

Кызлар аның тавышыннан өнсез калдылар, сулыш алудан туктадылар кебек.

— Сыер ул, бала тапкан хатын төсле була, ә тана кызлар кебек!

Кызларның күзләре шар ачылды, бит очлары китереп суккандай алланып чыкты. Берсенең түгәрәк бите буйлап мөлдерәп яшь бөртеге тәгәрәп төште, ләкин кызыкай аны сөртеп алырга курыкты.

«Болай булса, бу кызлар да җай туры килү белән авылдан чыгып сызачаклар»,— дип үкенеп уйлап куйды Давыт. Ләкин ни сәбәптәндер гафу үтенә алмады. Нәрсәдер тыелырга мәҗбүр итте. Фәкать тавышын йомшарта төшеп:

— Ярый, үзегез генә булдыра алмасагыз, әнә Гаделша абзый ярдәм итәр,— диде.— Иртән аның белән бергәләп барырсыз.

Соңыннан, бүтәннәр таралып бетеп, Вәлишин белән икәүдән-икәү генә калгач, Давыт:

— Таштимерова халыкны камчы белән ярып эшләткән дигән сүз йөри, хакмы? — дип сорады.

— Мир теленә керсә, берне бишкә әйләндерәләр инде,— диде Вәлишин өнәмичә.— Эшлиселәре килми бит, күңел биреп тырышканы бармак белән санарлык. Ә хуҗа бөтенесе өчен җавап бирә. Сабырлыгы төкәнеп, селтәнеп куйган чагы да булгандыр инде! Үзе өчен тырышмады, хуҗалык өчен! Ярылырдай чаклары була торган иде!

«Ә мин? Мин нишләрмен? Ничек чыдармын! Ничек очына чыгармын! — дип уйлады Давыт.— Әллә күтәрә алмаслык йөккә тотынуыммы бу? Кем китереп йөкләде бу эшне миңа?»

Моңа сәбәпче кешенең Нурханова икәнлеге аның башына да килмәде, билгеле.

## 20

Яшь председатель Гаяровның беренче эш көнендә Нурханова хәл белергә бармады. Гәрчә барырга кирәк иде шикелле. Авылны, андагы кешеләрне яхшы белүче буларак та, шул колхозга беркетелгән район җитәкчесе буларак та. Әмма Нурханова бармаска булды. Әйдә, беренче адымнарыннан ук мөстәкыйль булсын, нинди эшкә тотынганын аңласын, мәсьәләләрне үзе хәл кылсын. Ә Нурхановаың үз эшләре бар иде: ул янә Кармаш больницасына китте. Аннан кичкә таба гына әйләнеп кайтты. Көндез сәнгать мәктәбендә булган Рамилә аның шактый ук кәефсез кайтканын сизеп алды.

Кичен чәй табыны янында сүз ялганмады. Ниһаять, Иркәне көйләп йокларга яткыргач һәм икәүдән-икәү генә калгач, Рамиләнең ничектер кыенсынып карап торганын күреп, аңына килде Фидая, елмая төшеп:

— Эш бармый әле,— дип көрсенеп куйды.— Котельный эшли, җылыны бирдек, анысы ярады. Тик менә яңа бинаның түшәме дә, түбәсе дә юк, такта таба алмыйбыз.— Аннары, каядыр читкә карагандай:— Берәүнең дә эче пошмый бит,— дип өстәде.— Баш врачыбыз да андыйга бик уңган кеше булып чыкмады, мин тапсам була, мин тапмасам юк.

Рамиләнең әлегә йоклыйсы килми, ул өзелгән кыйссаның дәвамын көтә иде. Үзенең больница төзелешендә булганын аермачык күз алдына китерде һәм кинәт кенә, моңарчы яшерен серне ачкандай:

— Ә миңа сезнең баш врачыгыз ошады,— дип куйды.— Аннары

сезгә мөнәсәбәте дә гади генә түгел. Бик сак, сизгер кебек, ул сезнең һәр сүзегезгә, ишарәгезгә зур игътибар бирә, зурлап кабул итә. Юк, гади түгел аның сезгә карашы. Ә сез аңа карата шактый ук кырыс кебек тоелдыгыз. Сез аны күптәннән беләсезме?

Рамилә бераз тынып торды: әйтергәме, юкмы, дип уйлады бугай. Фидая, аңа аркасы белән борылып, залга таба атлады. Рамилә дә аңа иярде:

— Гадәттә, гашыйк кешеләр шулай каушыйлар,— дип өстәп куйды.— Хатыны да сезне күздән ычкындырмаска тырыша. Читтән караганда бу бик сизелә.

Фидая, аңа аркасы белән борылган килеш, диван япмасын алды, аңа ак җәймә җәеп, мендәрен кабартып куйды. Рамилә, ул әллә минем сүзләрне ишетмәмешкә салыша инде, дип уйлаган иде. Диванга утырып, хәлсезләнгәндәй аның аркасына сөялгәч, Фидая Рамиләгә янәшәсенә утырырга тәкъдим итеп кулы белән ишарәләде дә авыр көрсенеп:

— Нихәл итәсең, түзәрләр инде,— дип куйды.— Аларга мәшәкать була дип тә, читен дип тә торып булмый, миңа анда һаман барырга туры килә.— Аннары, ике учы белән маңгаен тотты да, йөзен алтынсу чәчләре астына яшереп:

— Әллә миңа җиңелме?!— диде.— Минем йөрәк алардан ныграк талана да бит, бернишләр хәл юк. Яңадан-яңа яралар ясый-ясый барасың... Бөтенесе шунда җимерелде, барысы да шунда һәлак иттелде. Ә мин барам, барырга тиешмен... Барган, күргән саен үзәк өзелә.

Шактый вакыт тынып тордылар. Бу тынлыкта китап шкафы киштәсендәге түгәрәк кыңгыраулы сәгатьнең текелдәве аермачык ишетелде.

Фидая йөзен читкә, челтәр пәрдә белән генә капланган тәрәзәгә текәлде дә, уйланып:

— Хәсрәт күргән юк иде шул моңарчы,— диде.— Чыныкмаган йөрәккә кайгының иң авыры, иң үкенечлесе килде. Моңарчы мин бакчадагы гөл кебек яшәгәнмен икән. Хәтерлисеңме, Экзюпериның роза чәчәген? Нинди көйсез ул, иркә, талымлы. Мин дә шундый булганмын икән. Ул гел минем көйгә генә тора, мине генә кайгырта иде шикелле. Хәзер генә аңлыйм: асылда, мин ул теләгәнчә яшәгәнмен, ул теләгәнчә үзгәргәнмен. Оста бакчачы гөлләрне, агачларны үзенчә итеп үстерә бит. Күпмедер вакыт бергә яшәгәннән соң, мин үземнең элекке тәкәбберлегемне, күңелемнең катылыгын исемә төшереп: «Син миңа ничек өйләндең, курыкмыйча?»— дип сорадым. Нәрсәдән куркасы икәнен әйтмәдем, ул аңлады. «Ә мин синең яхшы буласыңа ышандым»,— диде ул, башымнан сыйпап. Теге чакта үзенә акыл биргән егетләргә: «Кеше үзгәрми тормый, ул да үзгәрер».— дигәне шул булган икән. Җиде ел бергә яшәгәнебез хәзер бер тын, бер сулыш кына булып тоела. Ул үзе тыйнак, йомшак табигатьле иде, ә шулай да баян моңы белән кешеләрне сихерли, үзенә буйсындыра белә иде. Ә мин кечкенәдән, кайда гына булсам да, баш булырга өйрәнеп үстем. Укытучы булып эшли башлавыма, мәктәп директоры оештыру эшләренең күбесен миңа куша, кирәк әйбер-кара артыннан да мине җибәрә иде. Ике ел элек аны райбашкарма председателе итеп алдылар. Мәгъсүм белән киңәшеп, ул үзе урынына мәктәп директоры итеп мине тәкъдим итте. «Алын, әнисе, син бу эшкә,— диде Мәгъсүм миңа.— Гел тавык кына булып яшәмәссең, әтәч булып кылан бераз».— Һәм, мәгънәле көлемсерәп:— Синең күптәнге хыялың бит ул — башкаларга баш булу!»— дип өстәде. «Нишләп инде үз иремә баш булыйм?— дигән булдым мин.— Мин директор, син укытучы булачакбыз бит!»— «Ир — баш, хатын — муен диләр, ә без киресен кыланып карыйк әле,— диде ул.— Син баш бул, мин — муен. Кызык булсын!» Хәзер менә уйлап карасам, башы да, муены

да ул булган, ә мин — авыз, кул-аяк кына булганмын кебек тоела. Мин президиумнарда утырам, сөйлим, эшлим, кирәк-ярак артыннан чабам. Болай итсәм, ничек булыр да, тегеләй әйтсәм, ни килеп чыгар, дип уйлаган да юк, шул хәтле нык лы ышаныч үземдә. Хәзер менә аңлыйм: ышаныч дигәнем ирем — алтын баганам булган икән.

Фидая бераз тынып торды. Аннары, көрсенеп, өстәде:

— Хәзер менә бу түзелеш белән күпме юкка бәргәләнәм, күпме бушка чабам, соңыннан кирәк кешегә сүз кушмаганымны, тиешле урынга бармаганымны аңлыйм. Янымда ул булса... Әй бит кайчакларда аның миңа сәеп, сокланып каравы, һәрчак игътибарлы булуы туйдыра да иде шикелле. Кадерен белми идем шул, дөньяда барча ир-хатыннар шулай яши, дип уйлый идем. Казан санаториена путевка биргәннәр иде аңа бер җәй башында. Минем мәктәпне ремонтлау артыннан чабасы бар, бер уңайдан квартирны да рәтләтмәкче идем. Ризалаттым мин моның үзен генә китәргә. Ике көн үттеме-юкмы, телеграммасы килеп төште моның: «Иртәгә үк кил, югыйсә, үзем кайтам».— дигән. Эшнең кызу чагы иде, бик нык ачуым кабарды минем. Алай да беләм: үзем барып, көйләмәсәм, билләһи, дәваланмыйча кайтып кирәчәк. Аның ашказаны борчый иде, дәваланмый булмый. Бөтен эшемне ташлап, бик кырыс кыяфәттә барып кердем мин моның янына. «Ни булды? Кем тия?» «Үләм-үләм,— ди, авызын ерып,— монда миңа дәва тапмыйлар». «Мин табар, дисең инде алайса?» «Табасы да юк, син үзең дәва! Чирем — сагыну бит минем!» Шулай диде дә, күтәреп бөтерергә дә кереште. Шуннан соң ничек ачуланып булсын аны! Атна буе янында үткәрдем: төнен гостиницадан куныл киләм дә, көннәр буе бергә йөрибез. Ялга килгән хатыннар артыбыздан: «Ирен сакларга килгән, уҗымга чыгар дип курка»... — дип, гайбәтебезне сатып калалар.

Яшәп калырга, яратып калырга, бәхетле булырга ашыккан икән ул. Әй мин мәңге-мәңге янымда ул булыр дип ышана идем. Юләр! Әй бит ул мине алдан ук кисәткән булган, аңламаганмын гына.

Фидая, урыныннан кузгалып, альбомын алды, беренче биттәге рәсемнәрнең берсен куптарып, артындагы язуны Рамиләгә укытты:

Урал суы бигрәк матур, борма,
Урал тауларыннан чыга ул;
Авырлыклар килсә, түзәрлек бул,
Мәңгелеккә бирәм сиңа кул.—

дип язылган иде анда мәктәп баласының язуына охшаш бераз авышрак, тигез хәрефләр белән.

— «Авырлыклар килсә, түзәрлек бул»,— дип кабатлады Фидая.— Ул мине алдан ук кисәткән, ә мин аңламадым, бәхетемнең кадерен белмәдем, хәсрәтләрне кичерергә әзерләнмәдем. Хәзер үкенеп туя алмыйм: мин күп төннәремне аның белән түгел, башка ятакта, башка бүлмәдә үткәрдем. Кызымны үзем белән йокларга өйрәттем, ә иремә-бәгъремә: «Врачлар бергә йокларга киңәш итми»,— дигән була идем. Их, хәзерге акылларым булса, беләгеннән башларымны кузгатмас идем! Бер төнне ничектер сискәнеп уянып киттем дә: «Үкенмәм микән мин бу аннан аерым үткәргән төннәрем өчен?» — дип уйлап куйдым. Тик кузгалырга, аның янына керергә ирендем. Хәзер менә һәр төнемдә әллә ничә үкенәм дә бит, кайтарып алыплар булмый. Кайчак миңа хатыннар ирләреннән зарланып килә: мин аларга акыл өйрәтәм: пар яшәүнең кадерен белегез, гел бергә булырга, аларга да рәхәт күрсәтеп, үзегез дә тәмен белеп яшәргә тырышыгыз, дип сөйлим. Күзләреннән күреп торам: аңламыйлар, бер-берсенең кадерен күрүне кайгыртмыйлар, сүзләрен өстен чыгарыр өчен җан тырмашалар. Ахмаклар! Хәер, үзем дә ахмак түгел идеммени? Хәзер менә бер генә минут булса да аның хуш исле сулышына коенып, кайнар иңнәренә сыенып торыр өчен әллә ниләр

бирер идем! Бер гамьнәрем калмас иде! Шунысына бигрәк үкенәм: соңгы төнемдә дә мин аннан аерым яткан идем. Кинәт нәрсәдәндер сискәнеп уянып киттем, шактый вакыт сагаеп, тыңланып яттым. Кап-караңгы, тып-тын иде. Кабыргаларыма бәргәләнеп йөрәгем типкәне генә ишетелә. Күпме вакыт узгандыр, мин инде үз-үземне тынычландырып, йокымсырый башлаган идем, күрше бүлмәдән сәер, нечкә өн колагыма килеп иреште. Бәрелгән туп кебек, бусага аша атылдым, өстәл лампасының төймәсен кармаланып таптым...

Ул бөгәрләнеп беткән юрганы өстендә, тезләрен җыерып, кырын ята, учына йомарлаган җәймә башы канга чыланган иде. Маңгаен тотып карасам — манма тир. Безне уятмаска тырышып, бик озак түзеп яткан иде ул.

Ул төнне кичергәннәрем төштә бастырылу төсле булды. Шәһәрдә сезнең хәлләр бездәгедәй авыр түгел, кирәк булса, телефоннан гына шалтыратасы. Ә минем ул төнне кургәнемне дошманыңа да күрсәтмәсен. Хәер, күрсәтми нишләсен? Авыл кешесенең кайсы гына авырып китсә дә, шул инде. Майның унөченче числосы иде, салкын яңгыр коя, урамнар ерып узгысыз пычрак. Больницага шалтыратып машина чакырту монда, гомумән, юк, авыруларны үзең җай табып илтергә кирәк. Авылыбызның урамын, саз ерып, әллә ничә урадым мин ул төнне. Ярый, медсестрабыз бик әйбәт, ярый, аның беренче ире, йөгереп барып әйтүгә, машинасын кабызды. Яңгыр астында пычрак ярып күпме чапсам да, тәнем уттай кызган иде. Мәгъсүмгә оекбашлар кигезгәндә аяклары боздай салкын тоелды, йөрәгем «жу» итте. Шуны да уйладым: ничә ел бергә яшәп, мин аның аякларын сыйпамаган-иркәләмәгән икәнмен. Шул беренче һәм соңгы орынуым булды.

Ах, ул төн, ул төн! Иң якын кешем, газизем янымда, кочагымда, ә арабыз минут саен ерагая, мин кара кайгы эчендә япа-ялгыз калам шикелле, аны тотып калырга бернинди мөмкинлек юк, башларыңны ташка орсаң да бу хәлдән котылып булмый!

Операция алдыннан мин аны соңгы тапкыр исән килеш күрдем. Ул мине юатырга тырышты: «Билалга ышанырга була,— диде, юкарган иреннәре белән елмаеп.— Башыңны кисеп, кире тегәм, дисә дә ереп ятам мин аның өстәленә!» Ә минем йөрәктә шом, шом... Әгәр аның терелүенә ышансам, өметем зур булса, бәлки ул исән калган да булыр иде. Чын сөю, өмет, ышаныч могҗизалар ясый, диләр бит, ә мин кара кайгыга сабыштым. Алдан ук Газраилгә бирдем мин аны, мәңге үземне гафу итәчәгем юк!

Саташу, бастырылу кебек очсыз-кырыйсыз да булды, бик тиз дә үтте ул төн. Ах, әгәр уянып булса икән! Таң атты, ә саташуга тиң хәлләр дәвам итте. Кемдер мине җитәкләп ишегалдыннан эчкә алып керде, Гөлфия, җиңемне сызгандырып, беләгемә укол кадады, «Еласын, еласын, елагач җиңелрәк була ул»,— дигәннәре колакка чалынып узды.

Мәгъсүм бүлмә уртасындагы ятакта, ялтырап торган аппаратлар, көпшәләр арасында ята иде. Йөзе тыныч, йокыга талган кебек. Аягын тотып карадым — кайнар. Шунда аның минем орынуыма җавап бирмәве, борылып та карамавы йөрәгемне пычак белән сызгандай итте. Ул үлгән... Аны һәлак иттеләр! Әле генә, әле генә ул исән иде бит! Бу бинаның ишегеннән үз аягы белән кергән иде бит! «Кайтарыгыз аны!— дип кычкырдым мин Билалга.— Монда ничек килеп кергән булса, шул хәлендә калсын! Кире кайтар аны үз хәленә!» Билалның агарып катып, миңа өнсез карап торуы канымны торатороп кыздыра барды. Бөтен ярсуымны аның өстенә сиптем. Тиргәдем, каргадым. «Үзеңә килсен шундый хәсрәт!»— дип кычкырдым... Әгәр шунда Гөлфия арага килеп кермәсә, ялан кул ботарлап ташларга әзер идем мин аны! Ләкин Гөлфия... Ул минем кызымны

беренче булып кулга алган шәфкать иясе иде бит...

Газаплар моның белән дә бетмәгән иде әле: иртәгесен тикшерү ясарга кирәклеген әйттеләр. Кемнәрдер җыелып, үлемнең сәбәбен ачыклар өчен, аның тәнен актарачаклар икән һәм мин бу эшне берничек тә туктата алмыйм икән. Хәзергәчә башыма сыймый: ничек инде ул алай? Ни өчен бөтенләй чит адәмнәр аның гәүдәсенә тулысынча хуҗа булып алдылар да, нишләп минем — ул үз ихтыяры белән җанына, тәненә хуҗа иткән кешенең — бер хокукы да калмады?

Моның өчен мин Билалны тагын каргадым...

Мәрхүмнең каберен шомырт чәчкәсенә төрделәр. Май уртасы иде бит. Ә уналтысы аның туган көне иде. Иртән ишекне ачып чыгуыма, болдырда чәчәк бәйләмнәре, открыткалар күреп, туктап калдым: укучы балалар Мәгъсүм абыйларын туган көне белән котлаганнар. Мин ничек ышаныйм, аның үлүенә балалар ышанырга теләми иде! Күпмесе безнең өйдә телевизор карап, әңгәмәләр корып утырган, күпмесе шунда репетицияләр ясаган, кулыннан килгәнчә сый әзерләп, чәйләр эчкән!

Бөтенесе-бөтенесе юкка чыкты... Бөтенесе шул бер кешенең нәрсәдәдер ялгышуында, нәрсәнедер эшләп бетермәве аркасында...

Соңрак, бераз баш-күз алгач, мин, кызыксынып, медицина китаплары укыштырдым. Кинәт күзләрем ачылгандай булды: аңарчы мин дөм сукыр яшәгәнмен икән, дидем. Билал Мәгъсүмнең ашказанына операция ясаган. Ләкин кан югарырак — үңәчтән килгән булган. Хирург моны башта аныклый алмаган, чөнки андый очракларда төгәл диагноз кую чаралары юк икән әле. Дөрес, канның кайсы ноктадан килгәнен ачыклый торган аппаратлар күптән уйлап чыгарылган икән инде, моннан дистә еллар элек. Ләкин алар әле район-нарда гына түгел, шәһәр больницаларында да юк, чит илләрдә генә эшләнә икән. Моны белгәннән соң мин хәйран калдым: ничек инде ул, моннан дистә еллар элек күп кешеләрне әҗәлдән йолып алу чарасы мәгълүм булып та, без аны бүгенгә кадәр кулланмыйбыз? Ничек бу хәлгә врачлар түзә, нигә алар моның турында кычкырып халыкка сөйләмиләр, нигә чаң какмыйлар? Әгәр без шундый хәл буласын уйлаган булсак, ул аппаратны алдан ук табу чарасын күрмәс идекмени? Бөтен милкебезне, көчебезне, вакытыбызны шуңа багышламас идекмени? Без ипи-су белән яшәргә, җәен-кышын бер бишмәт киеп йөрергә риза булыр идек, бөтенесен шул аппаратны табу өчен бирер идек. Шаккатам хәзер, ничек без моны уйламаганбыз? Ул больницага ни өчен җентекләп карамаганбыз? Без генә дә түгел икән бит! Медицинадагы бик күп ачышлар дистә еллар буе кулланылмый, алар больницаларга барып җитми, шул сәбәпле һәр елны меңнәрчә кешеләрнең гомере вакытсыз өзелә!

Фидая, башын күтәреп, аңлату көткәндәй, Рамиләгә текәлде.

— Исәннәр яшәү хакында уйлый,— диде Рамилә.

— Яшәү хакында уйласак, без аны бигрәк тә кайгыртырга тиеш бит!

Фидая, хәлсезләнгәндәй, күзләрен йома төшеп, аркасы белән диван артына сөялеп утырды.

— Бигрәк тә бездә, иң кешелекле җәмгыятьтә, иң беренче чиратта больницаларны кайгырту тиеш икән бит!— Ул бераз тынып торды.— Мин районда җитәкче булырмын дип уйлап та карамаган идем. Искәндәров үзенең урынбасары булырга чакыргач та иң беренче килгән уй — баш тарту иде. Шунда больница искә төште. Әгәр мин районда зур кеше була алсам, аны яңадан төзәтүгә көч кертә алам бит! Шуны уйладым да ризалаштым. Баш врач Газимов бинага проект булдыру артыннан бик нык йөри, Искәндәров үзе акча юнәлтергә керешкән иде инде. Сәламәтлек саклау оешмалары ифрат та

ярлы икән алар. Без аларга акчаны тиенләп кенә бүлеп бирәбез икән. Шуңа күрә акчаны читтән, закон бозып алсаң гына...

Рамилә аңа ни дип әйтергә дә белмәде. Шактый вакыт тын утырдылар.

— Ни генә булмасын, мин моны ерып чыгарга тиеш,— диде Фидая.— Шуны ерып чыкмасам, минем хәзер дөньяда яшәвемнең мәгънәсе дә калмый.

Тагын башын диван аркасына салып, күзләрен йомды:

— Әйе,— диде үз-үзен ныклап ышандыргандай.— Шул төзелеш һәм кызым Иркә. Шулар гына көч бирә, шуларга таянып кына яшим мин.

— Беләсезме,— диде Рамилә,— әгәр кулымнан килсә, мин сезгә ярдәм итәр идем. Бөтен көчемне куяр идем. Ләкин мин нишли алам? Шул стеналарны бизәргә булышсам гына инде.

— Анысы да зур эш,— диде Фидая.— Минем кулдан килми торган эш. Их, күп нәрсә килми шул минем кулдан, бик күп нәрсәгә көч җитми, осталык... Ә булдырырга кирәк. Ансыз мөмкин түгел!



## 21

Рамилә сүзендә торды: күргәзмә ябылып, хушлашып киткәндә, Нурхановага үзенең чәчәк бәйләме сурәтләнгән картинасын бүләк итеп калдырды. Урынын да үзе тапты хәтта: коридорда, тышкы ишектән кергәч тә күренә торган итеп һәм залның ачык ишегеннән яктылык төшәрлек итеп. Хәзер анда, әчке стенада, ачык тәрәзә бардыр сыман тоела һәм ул тәрәзәдән беркайчан сүрелми торган таң нурлары бөркелә.

Рамилә Гаяровка биргән вәгъдәсен дә онытмаган икән:

— Зинһар, моны Гаяровка тапшырыгыз инде, үз кулым белән бирә алмаганым өчен гафу итсен,— дигәч, Фидая елмаерга тырышты, Давыт исеменнән рәхмәт әйтте.

Ул картинаны, биләүдә килеш, залның почмагына кайтарып куйды.

Ләкин, берничә көннән, мәшәкать арасында тагын картинага күзе төште, әманәтне тапшырмый яткыру яхшы түгеллеген уйлады, шундук илтеп бирергә булды, бер уңайдан үз йомышы да бар иде.

Көннең иртәсе гадәттәге мәшәкатьләр белән узганга, ул Баллыболынга төш турына гына барып җитә алды. Председатель фатирына кайтып киткән иде. Картина колхозга түгел, шәхсән Гаяровның үзенә бүләк ителгәнгә һәм аның арткы ягына рәссам кулы белән шулай дип язылган да булганга, ул колхоз милке арасында — эш кабинетында түгел, ә бәлки торган җирендә эленеп торырга тиеш иде. Фидая аны Наилә апаның өенә кереп тапшырсаң да ярыйдыр, дип уйлады.

— Сезне чәй эчми җибәрмәсләр инде аннан?— дип куйды Балкыш.

— Белмим шул,— диде Фидая.— Чәйләп торырга туры килер микән?

— Әбәт вакыты бит.

Балкышның медпунктка сугылып чыгасы бар икән. Муен тамыры тарта, дип, учы белән җилкә турын сыпырып, башын боргалап куйды ул. Шулай сөйләштеләр: Нурханова биш минуттан әйләнеп чыкмаса, Бакыш тиз генә медпункттан әйләнеп килә.

...Бусаганы атлап керүгә, Фидаяның йөрәге сулкылдап куйды: монда бернәрсә дә үзгәрмәгән! Барысы да һаман шул килеш, алар күңелле өчпочмак — ир, хатын белән бала — өчәүләшеп гөрләп яшәгән чактагы төсле. Үзгәрмәс ямь, тынычлык, иминлек өчен булды-

рылган куыш. Түр тәрәзә өсләрендә чигүле кашагалар, стеналарда рамга куелган фотолар, идәндә өйдә тукылган паласлар тоташ итеп җәелгән. Аларга әле генә йон оекбашлары белән тавышсыз гына басып Мәгъсүм узгандыр, әле генә Иркә аунагандыр да, торып, әтисенең бармагына ябышып, өйалдына чыккандыр кебек, менә-менә әйләнеп керерләр дә, каз бәпкәләре, тавыклар турында сөйләрләр шикелле. Әйтерсең, аларның моннан күчеп китеп, мәктәп квартирында яшәүләре дә булмаган, аннан соңгы кичергән кайгы-хәсрәтләр дә... Нинди гаҗәп бу дөнья, безнең баштан ниләр генә кичмәсен, һаман шул килеш тора! Бу өй Наилә апа яшь чагында да нәкъ шулай булгандыр, стенадагы рам эченнән, тонык фотолардан карап торган кешеләр — аның ире һәм бердәнбер улы исән чагында таптап йөргән паласлар бит болар! Ә менә хәзер аларга бу йорт өчен бөтенләй ят кеше — яңа председатель Гаяров басып уза.

Әнә ул — өстәл янында, кайнап торган электр самавыры артында утыра. Фидаяны күргәч, йөзендә гаҗәпләнү чагылды, салмак хәрәкәт белән аягөсте басып, өстәл артыннан чыкты — тәбәнәк түшәмгә башы тия яза, ул бу кечкенә йортта бигрәк тә озын буйлы күренә икән. Менә ул урындык аркасыннан костюмын алып киде, галстук төенен төзәткәләп куйды да, Фидаяның сузылган кулын саксыз каты итеп кысты.

— Әманәт тапшырырга килдем,— дип, култык астыннан төргәкне алып сузды аңа Фидая. Ул хатирәләрдән дулкынлануын сиздермәскә тырышып, елмайды. Гаяров, әлбәттә инде, күргәзмәдә рәссам хатын белән сөйләшкән сүзләрне хәтереннән чыгарган, аннан соң күпме үзгәрешләр булды бит. Төргәкне чишкәч, ул битараф караш белән канатлы атны күздән кичерде, бу хатын-кыз юк-барга бигрәк зур әһәмият бирә, вак-төяк белән күп шөгыльләнә, дигәндәй, башын чайкап куйды.

Рамны әйләндереп, соры киндердәге язуны укыды:

— Моңа җавап итеп нишләрбез инде?— дип куйды.— Шәһәр кешесенә бераз ит бирсәң дә ярар иде, бәлки...

Фидая Рамилә өчен үпкәләде, иреннәре тартышып куйды:

— Китте инде ул,— диде.

Наилә апа алар тирәсендә бөтерелеп йөри, өстәлгә яңа чынаяк куя, күкрәгенә терәп, түгәрәк күмәч телә, чәй пешерә иде.

— И-и, Фидая, әллә фәрештәләр колагыңа пышылдадымы, бигрәк вакытында килеп кердең! Бүген генә ипи пешердем, әле син җибәргән индийский чәй дә бар.— Аннары, Гаяровка карап:— Фидая гел тәмле чәйдән өзми мине, рәхмәт төшкере,— дип өстәде.— Бүген генә кереп алган идем Хәмидәдән сөтне дә.

Җиңел гәүдәле, ыспай күлмәкле, ак яулыгын чөеп бәйләгән, чәчәкле алъяпкычы белән билен ныгытып буып куйган Наилә Нурханова белән Гаяров арасында туган уңайсыз тынлыкны юкка чыгарды, аларга сүз башлауны җиңеләйтте.

— Фидая миңа үз туганым кебек бит ул,— дип, Гаяровка, күрәсең, инде кат-кат сөйләгәнне кабатлады.— Миндә начар кешенең торганы юк-югын, квартирга бик сайлап кына кертәм. Алай да арада Фидая белән Мәгъсүм кебеге булганы юк әле. Син менә гаиләңне алып килгәч, ничек яшәрбез, белеп булмый, болар белән бер семья булдык без. Миңа да ягымлы иделәр, инде үзләренең мәхәббәтен хәзер дә бөтен кеше шаккатып сөйли. Капка төбенә машина белән кайтып туктасалар, башта үзе сикереп төшәр иде дә Мәгъсүм мәрхүмкәем, йөгереп килеп, Фидая ягыннан ишеген ачар, аны кулыннан тотып төшерер иде. Күпне күрдек инде без дә, алай зурлап яратуны күргән булмады, гомере кыска икәнен сизде микән әллә күңеле бичараның! Анысы, Фидая үзе дә дөньяда бер инде. Ир күңеле сизә бит кемнең ниндилеген. Саф намуслы, чиста кеше Фидая үзе дә.

Наиләнең күзгә карап мактавы, җитмәсә, аларның мәхәббәте турында сөйләве Фидаяның күңеленә тиде: ул үзен шундый кыен хис итте, әйтерсең лә аны бу ят кеше каршында чишендерә башладылар. Ул кызарынып чыкты, каушады, сүзне икенчегә борырга тырышты:

— Сезнең белән киңәшәсе бар иде,— диде, Гаяровның күзенә туры карарга тырышып. Гүяки шул сүзләре белән Наиләнең тыкылдавын ишетелмәс итәргә, бөтен дикъкатьне үзенә тартырга омтылыш ясады.

— Киңәшкә үзем дә бик мохтаҗ әле,— диде Гаяров.— Яшь җитәкче буларак, миңа шефлыкка куелган кешеләр дә сирәк күренә, ярдәм итәселәре килми,— дип өстәде.

Фидаяның гаепне үз өстенә аласы килмәде.

— Безнең авылда, малайларны йөзәргә өйрәткәндә, тоталар да суга ыргыталар,— дип җавап бирде.— Ә сезнең киңәш бик кирәк иде миңа.

Моны Фидая Гаяровка киная белән әйтте, чөнки больница төзелешенә тегене-моны турыдан-туры сораса, бу кире беткән егетнең кирелләнәсен белә иде, ә инде урынга барып карагач, андагы хәлнең мөшкеллеген белгәч, күңеле йомшамый калмас, анда үзен кодрәтле ир итеп тояр, көчен күрсәтәсе килер, дип өметләнә иде. Наилә апа исә хәйләне аңламады, сүзне турыдан-туры кабул итте, көрсенеп:

— И-и, менә шулай шул инде ялгызлык хәлләре,— дип куйды.— Әгәр ирең исән булса, чит ирләр каршына барып, ярдәм сорап йөрер хатын идеңмени син, Фидая! Әйткән сүзе саф алтын, биргән киңәше көчле корал иде Мәгъсүмнең.Кире кайтарып булмый шул!

Фидая янә йөзен чытты, кирәкмәгәнгә кысыла иде Наилә, йөрәк ярасына тоз сибә иде.

Ләкин апаның сүзләре Гаяровка бөтенләй башкача тәэсир итте, аның ирлегенә, мин-минлегенә тиде. Әллә нинди Мәгъсүм алтын сүз генә сөйләп яшәгән дә, гел акыллы киңәш кенә биргән. Гаяров та ахмак түгел ләбаса! Аның да башы эшли!

Киңәшен биргәнче, әлеге дә баягы шул Кармаш больницасына барып кайтырга кирәк икән. Гаяровның бу сәгатьләргә ниятләп куйган үз эшләре дә җитәрлек иде. Ләкин бу хатыннар каршында теге мәрхүм адәмнән начаррак булып күренәсе килми иде, Гаяров Кармашка барып килергә ризалык бирде.

Табыннан тиз кузгалдылар. Балкыш бу юлы да медпункттан кайтып өлгермәгән икән. Гаяровның идарәгә кереп чыгасы бар иде. Фидая, аның белән янәшә урам буйлап баруны яхшысынмыйча, Наилә белән тегене-моны сөйләшеп калды, аннары, Гаяров чыгып китеп бераз торганнан соң, Балкыш артыннын үзе китте, берочтан Мөнирәнең хәлен дә белешеп чыгарга булды.

Күңел ярасын сүзләре белән тырнап ачты Наилә, соңгы көннәрдәге салкын җилләрдән кибеп киткән, ныгыган юлдан барганда, сирәк кенә очраган танышлар белән очрашып, исәнлек-саулык сорашып узганда, һаман үткәннәр искә төште.

Нинди гади һәм аңлаешлы тоела иде дөньяда яшәү Фидая өчен Наиләдә фатирда яшәгән чакларда! Агы ак, карасы кара, кешенең кылганнарына бәя икс генә төрле була ала: йә яхшы, йә яман. Гыйзәзетдин Мөнирәне ташлаганмы? Бик начар эшләгән. Каләмгөл аны тартып алганмы? Монысы бөтенләй әшәкелек. Дөрес, Каләмгөлнең үзен күргәннән соң, аңа яшьләрнең мөкиббән киткәнен, клубның ул килгәннән бирле гөрләп торганын белгәннән соң, Фидаяның үз күңелендә дә, бу хатынга гашыйк булмый мөмкин түгел бит, дигән уй туган иде, ләкин ул моны куарга тырышты. Ходай биргән чибәрлегеңнән файдаланып, кеше бәхетен җимерү шулай ук кабахәтлек түгелмени? Шулай уйлады һәм баштарак Мәгъсүмне клубка җибәрергә теләмәде. Мәгъсүм исә Фидая белән килешмәде.

— Һәркемнең язмышы үзенчә, кешегә хөкем чыгару ул арифметика мәсьәләсен чишү генә түгел, язмыш математика кагыйдәләренә буйсынмый,— диде, Фидаяның математика укытучысы булуына һәм һәр очракта артык катгый фикер йөртүенә ишарә ясап.

— Алайса, кагыйдәләр булмаса да ярыймы? Кеше бүген бернәрсә тели, иртәгә икенчене, башкалар белән исәпләшмичә теләсә ничек яшәсенме?

— Эткә яраган ишәккә ярамый, дигәнне ишеткәнең бармы синең? Берәүнең эте белән ишәге булган, ди. Хуҗа кайтуга, эт аның каршына чабып бара да, ал тәпиләрен аның күкрәгенә куеп, битен ялый, ә хуҗасы аның башын сыйпый икән. Ишәк моңа карап торган-торган да, нишләп әле мин читтә торам, хуҗа этнеке генә түгел, минеке дә бит, дип уйлаган. Беркөнне ул да хуҗасының каршына чабып барып, тоякларын иңбашына куйган, чыраен яларга маташкан. Моның өчен хуҗа аны чыбыркы белән ярган, ди. Кешеләр дә төрле-төрле, фабрик ясаган курчаклар төсле түгел. Менә мин үзем өчен тормышка әхлакый бер кыса сызып куйдым.

Мәгъсүм, алдына дәфтәр куеп, битенә квадрат сызып күрсәтә.

— Әйтик, минем кысам шушындый. Мин аннан чыкмаска тырышам. Башкаларның да үзләре өчен сызып куйган кысалары бар. Алар ясаган кыса минеке белән тәңгәл килми, йә бер ягы, йә бер почмагы белән читкә чыгып тора. Мин моның өчен аларны гаепләгәнче, аңларга тырышырга тиешмен.

— Әхлак кысалары һәммә кеше өчен бер бит ул,— диде Фидая, аның белән ризалашмыйча.— Берәрсенә күзең төшсә, син дә минем шулай башкага алыштырыр идеңме әллә?

— Мин башка... бүтәнне ярата алмыйм. Инде күңелем алгысып куйса да, сиздермәскә тырышыр идем.

— Миннән яшереп кенә сөяр идеңме?

— Синнән дә, аннан да, үземнән дә яшерергә тырышыр идем. Ләкин башкага, син минемчә эшлә, дип әйтү дөрес микән?

Ул чакта алар үпкәләшеп тә алганнар иде әле. Мәгъсүм Фидаяны тыңламады. Каләмгөл клубта баян уйнарга чакыргач, каршы килмәде. Каләмгөл оештырган спектакльләр, концертлар, сабан туйлары аның баяны тавышына уралып уза торган булды. Әкренләп Фидая да бу эшкә тартылмый булдыра алмады. Гәрчә Каләмгөл белән бергәләп ни дә булса оештырганда, хәтта аның белән каракаршы сөйләшкәндә үзен Мөнирәгә карата начарлык эшләгәндәй тойса да һәм моңа вөҗданы сыкранса да. Вакыт һәрнәрсәне үзгәртә бит ул, айлар-еллар узгач, вөҗданның да тавышы тынды, бөтен авыл халкы кебек үк, Фидая да бу кешеләрнең шулай яшәвенә күнекте. Аннары килеп, Каләмгөлнең бер-бер артлы ике улы да туды бит инде. Әйе, бу кешеләрнең тормышы шулай көйләнде, Мөнирәнең көйсез яшәвенә күз күнекте.

Тик үсеп килгән ике кызның — Зиләйлә белән Зареманың гына бу хәлгә күнегүе мөмкин түгел иде. Киресенчә, вакыт узган саен, йөрәкләре хисләренең зурларын сыйдырырлык булып җитлегә барган саен, алардагы ризасызлык, хәтта нәфрәт көчәя генә барды.

Бу үсеш-үзгәреш Фидаяның күз алдында булды. Алар икесе бер класста укыдылар бит: Каләмгөлнең чегән иреннән туган кызы Зарема белән Гыйззетдиннең Мөнирәдән туган кызы Зиләйлә. Икесе дә Аллаяровалар. Заремага җиңелрәк иде, аның күңеле беркайчан да математика кагыйдәләрен сыйдырмады, әллә кайларда гизде. «Зарема, кабатла әле мин әйткәнне!» Ул торып баса, зур кара күзләрен тутырып, бер гөнаһсыз карап тора, калын иреннәрен ачмый да. «Ни уйлап утырасың син, ә?» Әйтми. Дәрестән соң калдырып сөйләшсәң исә, авызы йомылып тормый үзенең: «Менә, апа, кичә телевизордан шундый бию күрсәттеләр, гел ансат кына сыман, кабатлап булмый

үзен, йокларга ятсам, йә дәрестә утырганда хәзер кабатлый алырмын сыман, торып бассам, булдырып булмый». Сикереп торып биеп тә күрсәтә шунда, коңгырт мәктәп күлмәгенең кыскарган итәген бармак очлары белән тотып җилпегәндәй итенә. Нишләтәсең аны! Барыбер математик чыкмаячак аннан, көрсенеп, намуска каршы килеп, «өч»лене куярга туры килә.

Ул Зиләйләнең көйдергеч карашына да күнеккән, аңа игътибар да итми иде кебек. Моны Наилә үзенчә аңлата иде: «Әртис арасында туып үскән бит аның Заремасы, башыннан сыйпаучысы күп булгандыр да, чын ата кадерен күрмәгән. «Әти» дип Гыйззетдингә дәште ни дә, башкага ни — аңа барыбер. Биергә сәхнә булсын да, чиртергә думбра булсын! Ә Зиләйлә — ата баласы, үз атасын бүтәнгә бирүләре читендер аңа. Ир бирмәк — җан бирмәк, диләр, атаны бирмәк аннан да ачыдыр».

Бишенче класска җиткәч, Зиләйлә фамилиясен Касыймова дип, анасының кыз фамилиясенә алыштырырга тырышып караган иде — Мөнирә рөхсәт итмәде. Шуңа да карамастан, дәресләрдән калып, бәйләнеп йөргән иде әле ул кызчык: «Дәфтәрдә хаталарны төзәтәсез бит, моны да шулай төзәтегез!»

Шул ук елларда ул атасыннан акча алуны да туктатырга тырышып карады, анасына елый-елый: «Минем әти түгел ул, Зареманың атасы!»— дип кычкырган. Әмма Мөнирә алименттан баш тартмады, акчасы өчен түгел, Гыйззетдин белән ике арада элемтәне шул рәвешле генә булса да сакларга теләгәннән.

Медпунктның өйалды ишеге төбендә аяк киемнәрен салып, кырыйдарак тезелеп торган артсыз башмакларның берсен киеп керергә кирәк иде. Итекләрен салгач, Фидая үзен кечерәеп киткәндәй хис кылды. Ул, өйалды аша узып, бүлмәнең ишеген ачуга, ап-ак тукыма җәелгән өстәл янында утырган хатын белән Мөнирә икесе дә аягөсте торып бастылар.

— Әле генә чөгендердән кайттык,— диде Мөнирә, гаепле тавыш белән.— Менә, суык тигезәләр, бик читен булды быел.

Фидая аларга сүзләрен төгәлләргә, ашыкмаска кушты. Балкышны ак чаршау артындагы ятакка яткырып, аркасына ниндидер компресс куйганнар икән — аңа да җил тигән, имеш.

— Бер биш минут кына ятсын инде тагын,— диде Мөнирә, сәгатенә карап.

Хатын чыгып киткәч, Фидая медпункт хәлләрен сорашты: авыручылар күпме, дарулар җитәме, кирәк чакта колхоз машина бирәме?

— Ул якка интекмибез,— диде Мөнирә.— Председательнең бусы мәнле күренә. Кирәк чакта үз машинасын да бирә. Аның иң тилмерткәне — чирләүчеләр үзләре. Больница юлында йөрмәс өчен мең хәйлә табалар. Әле беркөнне көчләп диярлек Наилә апаны алып барган идем. Врач әйтә: «Йөрәгем кага, бавырым авырта, башым сызлый, дисең, нишләп соң элегрәк килмәдең?»— ди. «И, бер чир артыннан шулхәтле еракка йөрисе итмәдем инде,— дип көлде Наилә апа.— Бөтенесен берьюлы җыеп килдем менә!»

— Булыр-булыр Наилә ападан,— диде Фидая, моңсу гына елмаеп.

— Бер ул гына түгел инде, бөтенесе шулай. Күбесе аяктан егылганчы өендә йөри. Башкасына түзәр идең, бәби табасы хатыннар сүзне тыңламый. Исән-сау килеш нишләп шунда хәтле барып йөрик, бушка вакыт уздырып, диләр. Алар бармаганга мин гаепле булып каламын, минем аркага тукмак төшә. Аның бит Йосыповына да, Гөлфиясенә дә бернәрсә аңлатып булмый. Хәзер менә Йосыпов та китеп барса, мондагы хатыннарны районга хәтле йөртәсе була. Анда инде берсе дә вакытында барачак түгел. Бәби тапканда берәр хәл килеп чыкмасмы,

дип һаман ут йотып торасың. Үзең беләсең: өйдә бала табучылар булды бит безнең. Шушы заманда!

Бусы Каләмгөл турында иде. Ул хатын корсагын да җиңел күтәрә — авыл хатыннары аның киң, чуар итәге астында гәүдәсе йомрыланганын сизми дә калалар — баланы да эш арасында гына табып куя. Беренче улын да өйдә тудырган иде, икенчесен дә плитә янында коймак пешереп торган җиреннән тудырган, соңыннан район больницасында улының башына зыян килмәдеме икән, дип тә куркышканнар, дип сөйләделәр. Каләмгөл Мөниранe тыңламый, медсестра үзе дә аның тирәсендә артык чуала алмый инде, билгеле!

Бу сүзләрен сөйләгәндә, Мөнирә тик тормады, шкафындагы ниндидер даруларны тәртипкә китерде, почмакта тумбочкада электр плитәсе өстендә кайнап утырган озынча тимер савыттан шылтыратып шприцларны алды, тиз генә пәрдә артына кереп чыкты. Аның артыннан, ничектер гаепле кеше сыман кызарынып, Балкыш күренде. Ниндидер ярамаган эш өстендә тотылган кешедәй иде аның кыяфәте. Фидая аңа гаҗәпләнеп карады.

— Хәзер идарәгә сугылып чыгабыз да, Кармашка барып кайтабыз,— диде.— Председатель дә бара үз машинасы белән.

Егет мыштым гына чыгып китте.

Фидая, хушлашырга дип, Мөнирәгә таба борылды һәм кинәт тынып калды. Мөнирә урам як тәрәзә янагына ышыкланып, ак җеп белән уеп-уеп чигелгән, читләре тел-тел итеп эшләнгән ак пәрдәнең кырын чак кына кайтарып, тышка караган иде. Аның йөзендә оялчан да, бәхетле дә елмаю балкый, бит очлары алланып чыккан, әгәр күбәләк булса һәм тәрәзә ачылса, очып чыгып китәр иде шикелле. Фидая да үрелеп урамга карады: олы урамнан күпергә илтә торган олы юл уртасыннан, зәңгәр курткасының изүен ачкан, чалбар балакларын резин итек кунычларына батырган Гыйззетдин эре-эре атлап узып бара иде. Тәрәзәгә күз салмый, туп-туры карап бара, ләкин нәрсәдер — адымнарының чак кына тигезсезлегеме, кашларының артыграк җыерылган булуымы — тәрәзәдән күзәтүләрен белгәнен сиздерә иде.

Менә ул биек күпергә барып керде, күздән югалды. Мөнирә, башын борыска терәп, күзләрен йомды. Бераздан, тирән сулыш алып, Фидаяга таба борылды, аның күзләреннән җанны эретә торган җылылык бөркелде. Мөнирә бу минутта бәхетле иде һәм моны яшерә дә алмады. Шунда Фидая барысын да аңлады: пәрдәләрнең бу рәвешле вәземләп, нечкә-нәхтә итеп чигелүе дә, тәрәзә төпләрендәге көзге салкыннарда ак чәчәк ата торган гөлләр дә — һәммәсе Гыйззетдин өчен, һәммәсе Мөниранең мәхәббәте хакына эшләнгән иде.

Фидая аның ун елга яшәреп киткән йөзенә, тураеп киткән сынына карады һәм кызыгып куйды: бу хатын сөйгәнен күреп куана, турларыннан сыны гына чагылып узса да үзен бәхетле сизә һәм моның хакына башка газапларга — гайбәтләргә, кызының көйсезләнүләренә, көндәшенең адым саен очрап торуына — һәммәсенә түзә. Ул сөя, ул сөйгәненең нурлы йөзен күрә ала, аның өчен бәхетнең иң зурысы шушы иде.

Мөнирә ак тәрәзә янагына башын терәп, челтәрле пәрдә читен кайтара төшеп, бәхетле елмаеп басып торганда, Фидая: «Ә ятларның аның хакында гайбәт сөйләргә ни хакы бар?» — дип уйлады. Әйе, бу кешеләр арасында үз йөрәге мәхәббәт утында янмаган күпләр өчен аңлашылмас сер — чын сөю могҗизасы бар иде.

«Нинди бәхетле бит ул!— дип уйлады Фидая, Мөнирәдән көнләшеп.— Ул, сирәк булса да, сөйгәнен күрә. Ә мин андый бәхеттән мәхрүм, мәхрүм... Минем хәлем аныкыннан күпкә аяныч!»

Больницада баш врач Газимов белән колхоз председателе Гаяров бик җиңел сөйләшеп киттеләр, икесе бер рухтагы кешеләр икәнлекләрен ике-өч авыз сүз әйтүгә аңлашып та алдылар. Нурханова кызыгып та куйды: ул үзе башка җитәкчеләр белән болай тиз һәм рәхәт итеп танышып, сөйләшеп китә алмый, җитәкчеләр барысы да ир-ат, ә ир-атның хатын-кызга мөнәсәбәте башкачарак.

Ничек кенә булмасын, бу икәүнең бер-берсенә охшап торуы хәерлегә иде. Участок больницасы һәр мәсьәләдә мөлдерәп күрше колхозларның күзенә карап тора, алар ярдәме белән яши бит.

— Әйдәгез, больницаны күрсәтеп чыгам,— диде Билал.— Бәлки, бераэга булса да үзегез дә кереп ятарга туры килер, кем белә.

— Анысы Гаяров кебекләрне район больницасына илтербез инде,— дигән булды, үртәгәндәй елмаеп, Фидая. Ул моны юри әйтте: һәрхәлдә, андый-мондый имгәнү булганда, Газимовка килүне артыграк күрәләр, район больницасындагы хирурглар аның кебек үк булдыра алмый, дип саныйлар иде. Давыт моны белә иде, шунлыктан ул, үчекләүне аңлагандай, күзләрен кыса төшеп, йомылып беткәндәй тоелган күзләренең карашы белән баш врачның ак башлыгына ятып карап куйды.

Алгы зур гына бүлмәнең биек түшәм астында арыш кыры уртасында җилдә чайкалып утырган ялгыз имәнне тасвирлаган рәсем ясалган иде. Давыт аңа текәлеп карады.

Палаталарда исә искелек, тузганлык нык сизелә, стеналарның штукатуркасы купкан, түшәм почмаклары күгәргән, тынчу ис килә. Хирургия бүлегенең палатасында дүрт-биш ир кешенең аяклары махсус җайланмалар белән өскә күтәртеп бәйләп куелган, алардан гер асылынып тора. Яннарындагы тумбочкада стакан-кашык, бер-ике банка, караватлары астында эмаль савытлар. Давытка күңелсез булып китте: кешегә никадәр аз кирәк, әгәр ныклап уйлап карасаң!

Билал ир-егетләрнең һәркайсына берничәшәр сүз әйтеп чыкты, тегеләр ничектер күзләрен аеруча тутырып карап, нәрсәдер көтеп, өмет итеп, әкрен тавыш белән җавап бирделәр. Аякларында нык басып торган чакта алар, мөгаен, берәү белән дә мондый тыныч, әкрен һәм һәрнәрсә белән килешкән рәвештә сөйләшмәгәннәрдер... Алар бу Газимовтан, Давыттан ниндидер күзгә күренмәс киртә белән аерып куелганнар, аны җимерү дә, юкка чыгару да мөмкин түгел һәм ул киртә артыннан чыгу вакытын төгәл генә белмиләр дә иде шикелле...

Газимов түр почмакта тезен чәнчеп утырган чандыр карт янына барып туктады. Бабай марляга уралган аяк йөзен сыйпаштыра иде.

— Эшләр ничек?

— Рәтләнә кебек инде. Монда кергәндә йодрык сыярлык иде бит, хәзер кечерәйде.

— Трофическая язва,— дип аңлатты Газимов, Давытка карап.— Сугыш ярасы.

— Әйе, Курск дугасының истәлеге,— диде карт.— Әледән-әле ачылып тора. Кайчак ярты чиләк балчык сыяр моңа дип торырсың.

— Бөтен чараларны кулландык инде, алга барыш күренми,— диде Билал, палатадан чыккач, тавышын әкренәйтеп. Аның сүзен гармун тавышы өзде, якында гына кемдер дәртле көй уйнап җибәрде. Бу шул кадәр сәер иде, Давыт, сискәнеп, як-ягына каранды.

— Җиһансылу апа,— диде Газимов.— Әйдәгез, кереп күрик әле үзен!

Гармун тавышы хатын-кызлар ята торган бүлмәдән ишетелгән икән. Бию көен уйнаучы, тальян гармунын күкрәгенә куеп, чалкан ятканга, ишек ачылганын да, бер-бер артлы кешеләр кергәнен дә күрмәде, күрекне киң-киң тартып, өздереп-ярсып уйнавында булды.

Янында яткан бер хатын, сузылып, аның кулына орынмакчы иде, Билал, кагылма, дигәнне аңлатып, кулы белән ишарә ясады.

Алар, уйнаучы туктамасмы дип, бераз басып тордылар, ләкин ул бию көен тәмамлады да, яңа сулыш белән сузып торып авыл көен башлап җибәрде.

Билал әкрен генә караватка таба атлады, гармун өстенә кулын куйды. Ә Давыт гармунга түгел, гармун уйнаучының караватына текәлеп, өнсез калган иде: анда, аяклар булырга тиешле урында берни юк, уртасы иңеп төшкән караватта алсу төстәге больнис одеалы белән ак җәймә генә аралашып, бөгәрләнеп, буталып ята. Нәрсә, әллә соң карават төбе тишек булып, ул кеше аякларын аска төшергәнме? Ләкин бит тез туры да беленми!

— Җиһансылу апа, син монда безнең сырхауларны вакытыннан алда сикертеп торгызып, биетә башлама тагын,— диде Билал. Аның тавышында үзенә бер якынлык, хәтта ярату ишетелә. Гармунның кызыл күреге, тирән сулыш алгандай аваз чыгарып, җыелды, ул читкә авышты, аның артында өлкән яшьтәге апаның ак йөзе күренде: чал чәчләрен ике якка аерып, пөхтә итеп үргән, зәңгәр күзләре бик җетез, үткен һәм сынап карый, сулган йөзе шома, тигез, ирен читләре генә җыерылып тора,— гомумән, бу апаның кайчандыр бик чибәр булганлыгы сизелә, ул әле хәзер дә матур иде. Ул Давытка таләпчән карашын төбәде дә:

— Ә бусы Йосыпов урынына килгән доктормы әллә?— дип сорады.

— Юк, бу важныйрак нәчәлник,— диде Билал.— «Үзәк» колхозының яңа председателе.

— Ә-ә, шулаймыни? Ниса булып эшли башладыңмыни?— диде Җиһансылу. Бу сорау шаярып бирелергә тиеш иде һәм аңа елмаеп җавап бирергә кирәк иде, ләкин апаның йөзе җитди, хәтта кырыс калды. Давыт та аңа елмаеп җавап бирә алмады. Җиһансылу Баллыболында туып-үскән, шуннан фронтка киткән, яраланып шунда кайтып төшкән икән. Ләкин соңрак алар Кармашка күчкәннәр, сеңлесе шушы больницада санитарка булып эшләгән. Ул бик җентекләп колхоз хәлләрен сораша башлады: кемнәр сыер сава, кемнәр кырда эшли, кемнәр читкә китәргә йөри? Бөтен кешене генә түгел, һәркемнең холкын-фигылен белгәнлеге сизелә, Давытның күпләрне танымавы-белмәве аның кәефен кыра иде.

Палатадан чыккан чакта, Давыт нәрсәгәдер абынып егыла язды: дүрт тәгәрмәчле кечкенә арба икән — аяксыз кешеләр утырып, куллары белән җиргә таянып тәгәрәтеп йөри торган арба.

— Нишләп мондый әйберне урынсыз тотасыз?— дип Гөлфиягә ачу белән дәште Билал, аның нервыланганы йөзенә бәреп чыкты.

— Җиһансылу апа бик сорый бит, күз алдымда булса да торсын, күңелемә бер юаныч булыр, ди.

— Җиһансылу апаның янбашындагы яралары төзәлгәнче әле... Үзең беләсең бит...

— Беләм дә соң,— диде Гөлфия, башын иеп.

Караңгы коридорны узып, тышка чыккач, Давыт, күкрәгеен тутырып, салкын, дымлы һаваны сулады да, башын күтәреп, ертылган болытлар арасында аеруча чиста, зәңгәр булып тоелган күккә карады. Йа алла, дөньяның барча мәшәкатьләренә, авырлыкларына, иртән сәгать биштән торып, басуларда саз ерып йөрүләргә, район җитәкчеләре каршында бер гаепсезгә тиргәлеп басып торуларга, сүз тыңламас кире беткән механизаторлар белән әрләшүгә, төн йокламый, бу яңгыр туктамасмы дип тыңлап ятуларга — барысына-барысына түзәргә риза, тик менә шушындый стеналар эченә, тынчу, тәмсез исле палаталарга гына кереп ятарга язмасын!

— Һава авыр сезнең анда,— диде ул.

— Нишләтәсең, айлар буе чыга алмый яталар бит, бөтен эшләре шунда,— диде Билал.— Бинасы да иске. Әнә, операционный алдында ял итә торган бүлмә бар безнең. Анда керсәң әле, бөтенләй аптыраш. Ял итәргә дип диван куйган идек. Тәрәзә ягына башны куеп ятарга рөхсәт итмибез, чөнки анда түшәм яргаланып беткән, хәзер ишелергә тора...

— Больницаның яңасын төзүне ашыктырмасак, врачларның кайберләрен шушында кертеп яткырырга туры килмәгәе.

Давыт борылып карады — ул үзләренә ияреп Нурханова йөргәнен бөтенләй оныткан икән, менә хәзер аның сүзгә кысылуы гаҗәпләндереп җибәрде.

— Анысында үзенә күрә бер уңайлы палата да булдырырга исәп бар,— диде Билал.— Житәкчеләр өчен, дим. Бер кечерәк бүлмәне әйбәт кенә җиһазлап куярбыз, дип торам.

Монысы да Давытны юатмады. Кирәкми аерым бүлмәсе дә, уңайлыклары да, килергә генә язмасын. Больница эченнән тоныграк булып тагын гармун тавышы ишетелә башлады — Җиһансылу бая өзелеп калган моңлы-сагышлы авыл көен сыздырып җибәрде.

— Ә ул апаны, Җиһансылуны әйтәм, чирләмәгәндә кем карый соң?

— Караучысы юк шул әле,— диде Билал.— Сеңлесе үлеп китте бит.

— Инвалидлар йортына озатырсыз инде, алайса.

Билал белән Гөлфия, сискәнеп киткәндәй, икесе берьюлы Давыткa текәлделәр, гүяки ул мәгънәсез, ямьсез, күңелне рәнҗетә торган сүз әйтте.

— Ни җаның белән анда җибәрәсең аны?

Билал исә аңлатуны кирәк тапты:

— Монда гомер сөргән,— диде.— Тере җан иясе бит. Алай гына да түгел, сугышкан. Безнең өчен кан койган. Күңел бармый андый эшкә,— дип өстәде, көрсенеп.— Бездә дә андыйларга шартлар юк инде. Юындырып чыгарырга мунчасы да юк бит аның, ичмасам.

— Мунча? Больницага мунча нәрсәгә?— диде Давыт. Билал Давытка гаҗәпләнеп карады, башын чайкады, көлемсерәде.

— Больница мунчасыз тора алмый! Монда айлар буе ятучылар бар. Ерак авыллардан. Кыш көне мунча кертергә дип кайтарып йөртеп булмый. Мунчасы булса, дәвалау чараларын да кулланып булыр иде. Мунча белән дәвалый торган чирләр дә күп бит...

Баш врачның тавышында өметсезлек ярылып ята иде.

— Мунчаны да проблемага әйләндермик инде, иптәшләр.— Бу нечкә, әмма кырыс тавыш Давыт өчен тагын көтелмәгәнчә яңгырады. Ул, син дә мондамыни әле, дигәндәй Нурхановага тагын гаҗәпләнеп карады.

— Аны теләсә нинди колхоз, атна эчендә үк булмаса да, ай эчендә салып бирә ала. Менә иптәш Гаяров белән сөйләшегез дә, хәл итеп тә куегыз,— диде Нурханова, Билалга таба борылып.

— Мин үземчә аның проектын да әзерләп куйган идем инде,— диде Билал.— Арча районыннан күреп кайттым, үзем дә төзәтмәләр керттем...

Үз җилкәсенә мондый эш өюләрен һич тә көтмәгән Давытның ачуы кабарды. Ләкин ул чәчрәп чыгып каршы килә дә алмады. Чөнки йөз илле ел торган, күгәреп төс җуйган бүрәнәләр аркылы әле һаман гармун моңы сыгылып чыга, ул гүяки шушы бина эченнән иркен дөньяга чыга алмыйча яткан зәңгәр күзле Җиһансылуның җан авазын кешеләрнең йөрәгенә күзгә күренмәс юл аша китереп ирештерә, көйдергеч эссе нур булып иңә иде. Бу дөньяда көн саен безне ыгызыгы китереп йөгертә торган мәшәкатьләрдән өстенрәк нәрсәләр бар. Колхоз бухгалтериясендә кәгазьләргә саф-саф тезелеп барган саннар-

дан, һәр иртәне телгә килә торган рация тартмасыннан мөһимрәк әйберләр бар. Ул менә шушы — аягында һич төзәлмәс яра йөрткән моңсу һәм риясыз карашлы абзый, ул — күңел моңын тар стеналардан ургытып чыгарган Җиһансылу. Әгәр без алар хакында — кешеләр хакында онытабыз икән, ни мәгънә ит-сөтнең күбәюендә, ни мәгънә саннарның зураюында?

— Хәзер үк нигезен билгеләргә кирәк, җир нык катканчы киркәле чокырларын әзерләп куярга. Аннары, авылда эш җиңеләйгәч, кешеләрен табу ансат аның,— дип тәкърарлый иде Нурханова. Аның тиз мавыгып, кабынып китә торган гадәтен сизеп алган иде инде Давыт һәм бер дә ошатмаган иде. Ул үзе алай, «төкерек салдым, сикерептчык» дип, уйламый-нитми, каударланып эшкә тотына торганнардан түгел. Әмма, алай да, каршы торып булмады. Билал, аның нигезе чамаланган инде, үлчәп-нитеп, таяклар кагып куелган, дип, арырак, яңа инфекция бинасыннан читкәрәк әйдәде.

Баш врач аның йомшап китүен сизеп алган, эчен бушата, зарларын түгә иде инде. Кадрлар туплау да җиңел булмаячак.

— Без яшьләрне эшкә өйрәтеп кенә җиткерәбез, китеп баралар,— дип сөйләнде ул.— Әле менә Казанда берсен күреп кайттым. Монда бик әйбәт анестезия сестрасы булып җиткән иде. Китте, яратмады. Хәзер анда телефон станциясенә урнашкан. Акчасы яхшы төшә, эше җиңел, җайлы, ди. Бөтенесе шулай итә башласа, без мәңге кадрларга тиенә алмаячакбыз.

Аннары, бераз тынып торды да, башын чайкап:

— Аңламыйм мин бу халыкны,— дип куйды.— Безнең кулга керми калмый бит, югыйсә, берсе дә. Адәм баласы, дөньяга килүенә, безнең кулларга килеп керә.

Давыт, сәерсенеп, хирургның кулларына карады: алар гадәти ир кеше куллары; күп юылганга аграк һәм тиресе бераз купшакланган, кыска бармаклы, шешенкерәк куллар иде. Баш врач аның тәнендәге генә түгел, күңелендәге үзгәрешләрне дә бик тиз сизеп ала иде булса кирәк, ул әңгәмәне бензин сорау белән төгәлләде.

Давыт монысына да каршы килә алмады. Алар инде больница бинасыннан шактый ераклашканнар, гармун моңы анда килеп ирешергә дә тиеш түгел иде шикелле, әмма Давыт һаман шул яктан искән җилгә колак салып тыңлый һәм тау астындагы юлдан узып барган машина гөрелтесе аша авыл көен ишетә иде сыман.

*Ахыры киләсе санда.*

# Рашат Низами

## ВАКЫТ ҖИЛЕ

### Туфан язмышы

Әйтерсең лә бүтән җилләр исә,
Бүтән карлар күктән агыла:
Теге якта — төрмә коймасының
Карцерлардан азат ягында...

Карлы көннәр бер узар да китәр,
Зарлы көннәр чиксез күренә.
Эндәш, заман! Нинди сугымчылар
Оялаган илнең түренә?

Тәүлек саен төрмә капкалары
Кара китап булып ачыла,—
Язмышларны кемдер яза шулай,
Ә каләме... канга манчылган!

Мөмкинме соң сезнең туфанлыкны
«Таш капчык»ка ябып куярга —
Тукайлардан калган гамь барында,
Җанда әле якты уй барда?

Яза Туфан... Сакчы күзләреннән
Урлый-урлый яза шигырен.
Казанына таба баккан саен
Уйлар азат, уйлар йөгерек.

«Эх, бер йотым ирек!» — дия-дия
Җаны күпме бәргәләнмәсен,
Этапларны узган чакларда да
Югалтмаган асыл мәгънәсен.

Еллар үткәч, карыйм рәсеменә:
Ак чәчләре гүя ак җилкән.
Ирек эзләп киткән олпат иргә
Җырдан һәйкәл салыр чак җиткән.

Дөнья гамен тоя белүчеләр
Тукайлыкны үлчәп карасын:
Ак кәгазь һәм каләм — шагыйрь өчен
Яшәү белән үлем арасы!

### Өч заман

Җирен яклап кулга кылыч алган,
Сөте белән каны кушылып тамган,
Тарихларда бетмәс эзе калган —
шулдыр татарлык көзгесе.

Бу халыкны шундый язмыш көткән:
Тузганактай ул таралып беткән,
Күңелләрдән дога сүзе киткән —
шулдыр татарлык көзгесе.

Оныкларга иман нуры салсак,
Туган телне яңгырата алсак,
Үлемсезлек михрабында калсак —
шулдыр татарлык көзгесе!

---

Рашат НИЗАМИ *(1950) — шагыйрь, прозаик; «Кызыл җәй», «Бөек сер» һәм «Агаклы кешеләр тормышы» сериясеннән Фәрит Яруллин турындагы роман-хроника авторы. Казанда яши.*

## Яшел күзле малай

Җәйне яратканга күрә
Күзләре яшел иде.
Чирәмнәрдә уйный-уйный
Тезләре яшел иде.

Суларга карап бакты ул,
Күкләргә карап бакты.
Җаны чиста булгангамы,
Дөньялар — гаҗәп якты!

Яфрактан яфракка тамган
Түгәрәк тамчы кебек,
Бөреләнде күңелендә
Түгәрәк кенә өмет.

Шул өмете коймалардан
Йолдызга кадәр чөйде,—
Чөнки күршедәге йортка
Кунак кыз килгән иде!

Бантиклап үргән чәчләрен
Тотып карыйсы килде.
Күбәләктәй чәчтасмасын
Сүтеп карыйсы килде.

Әллә ни булды малайга —
Үзгәреп китте кинәт:
Канатлы йолдыз җилләре
Кагылган аңа, димәк.

Койма ярыгыннан кызны
Көн саен күреп алды.
Кунак кызның елмаюын
Курайга төреп салды.

«Яшел» иде мәхәббәте,
Күзләре яшел иде.
Әйтер сүзләре, моң булып,
Курайга яшеренде...

## Ком сәгате

Картлык көне... Бу турыда халык
Әйтә килгән борын-борыннан:
«Нишлисең бит, озак яшәмәстер,
Аның инде комы коелган...»

Ком сәгате! Әллә санавыңмы
Кемнәр югын җирдә, кем барын?
Нечкә билле вакыт улагыннан
Кыштыр-кыштыр ага комнарың.

Карап торам: бушлык арткан саен
Арта бара синдә һәлакәт,—
Соңгы комнар аска сикердеме,
Туктала да кала хәрәкәт.

Һәм йөзтүбән әйләндереп куйсаң,
Комнар тагын аска ташлана!
Вакыт җиле исеп куя кинәт —
Яңабаштан бар да башлана...

Гомер — аста, вакыт өстә кала,
Вакыт каршысында без түбән.
Гомерне дә башлап булса икән
Әйләндереп кенә йөзтүбән!

## Су астында калган болын җыры

Мин кешеләр белән дус яшәдем,
Үзләре дә дус булдылар кебек.
Сөйгән кызын яшел тугайлыкта
Кысып-кысып кочкан иде егет.

Гармун тотып печәнчеләр төшсә,
Алар белән мин дә шаштым, көлдем.
Яшәү көче иде туфрагымда —
Курпы булып кабат күтәрелдем!

Килделәр дә җирне актардылар,
Кешеләргә, белмим, ни кирәктер?
Җаным уяу иде, су астына
Күмде алар тагын бер йөрәкне.

Һәр үләнем, тәнем карышса да,
Көчсез иде минем ялварулар.
Табигатьнең мең ел тудырганын
Бер тәүлектә суга батырдылар.

Хәзер бары төптә, караңгыда
Үле тамыр булып тибә инеш.
Җәйләр җитсә — яңгыр тамчысына
Сусап ятам су астында килеш.

Суларымда — кукнең чагылышы,
Ак болытлар гүя ертык җилкән.
Тояк тавышымы әллә дисәм,
Баш очымда дулкын шавы икән.

Мин төш күрдем... Кара ромашкалар
Каплап киткән, имеш, итәгемне.
Кайтып булыр микән дөньялыкка,
Ни язмышлар көтә иртәгемне?

## Әй, туган җир...

Шушы җирдә канат чыгарганмын,
Туган ягым — Байлар Сабасы.
Безгә монда гомер итәселәр,
Безгә монда ямьнәр табасы.

Авыл-авыл булып сибелгәннәр:
Анда Шәтке, монда Иләбәр.
Иген иккән данлы якташларым
Алтын кисәгенә бәрабәр.

Булган заман, булган көмешчеләр,
Койганнары — балдак, беләзек.
Кая киткән шул борынгы һөнәр?
Үткәннәргә, ахры, юл өзек...

Болын буйлап якты Мишә ага,
Зурдан түгел үзе түгелен.

Балачакның көләч көннәрендә
Шул иде бит нәни Иделем!

Кая киткән теге тирәнлекләр?
Ах, саеккан Мишә, саеккан,—
Бездән калган ярның суларына
Тездән кереп баскан саескан.

Саба яктан саба җиле исә,
Туфрагыма, әйдә, баш идер...
Көмеш балдак кулда яшәгән күк,
Легендалар җанда яшидер.

«Байлар» сүзен һәрчак кушып әйтәм:
Туган ягым — Байлар Сабасы!
Безгә монда гомер итәселәр,
Безгә монда бәхет табасы.

## Әнкәйгә кайту

Мин туганмын. Газиз әнкәй
Бишегемә иелгән.
Күз тимәсен балама, дип
Биткә сөрмә тидергән.

Тагын мең кат иелгәндер
Куанып һәм шатланып.
Көләч йөзе хәтеремдә
Шулай тора сакланып.

...Килде авыр, кайгылы көн —
Тын гына, салмак кына
Дога сүзләрен кабатлап,
Бастым әнкәй каршына.

Ачыну һәм күз яшьләре
Тамагыма төелде...
Бу юлы әнкәй йөзенә
Соң тапкыр мин иелдем.

Шул иде, ахры, әнкәйгә
Бурыч кайтарган көнем.
Мең кат башлар иелсә дә,
Бурычым бетмәс минем!

Юллар озын, юллар ерак,
Тагын кайтып барышым.
Юл йөретә, баш идертә
«Әнкәй» дигән сагышым...

## Югалган төн

Шәм яктысы сеңгән төн иде ул!
Ике йөрәк керде ялкынга.
Бертуктаусыз пышылдады яңгыр
Дога укып тәрәз артында.

Шомырт исе килгән чәчләреңне
Ак мендәргә салдың таратып.
Әкияттәге сөю эчемлеген
Салып бирде безгә кара төн.

Түшәмнәрдә шәүлә калтыранды,
Өй артында яшен уйнады!
Яктыра да шундук сүнә торган
Ялган учак булган ул бары...

Күктәге ай, язмыш китегедәй,
Юл чатында калган суынып.
...Инде ничә еллар
Төнге яңгыр эзәрлекли безне,
Эзәрлекли биткә сугылып!

## Совет солдатының Әфганстан белән саубуллашуы

15 февраль, 1989 ел.

Нигә икәнен дә белмичәрәк
Килгән идек сиңа, Гиндекуш.[1]
Карлы түбәләрдән бөтенләйгә
Китеп барышыбыз... Инде хуш!

Теткәләнеп бетте кыяларың,
Янып-чәчрәп очты ташларың.
Сиңа ни сан! Нәләт төшкән сугыш
Аямады адәм башларын...

Утлар белән һәм табутлар белән
Чикләнсә дә күпме язмышлар,
Без китәбез... Кабатланмасын дип
Автоматлы көннәр, ялгышлар.

Дары исен бүтән татымабыз,
Егерме яшь безгә нибары.
Сөю өчен яратылган күңел
Сугышлардан өстен, югары!

Сукты сәгать! Туганлашсын өчен
Әфган белән әфган баласы.
Күпне күрде халкың. Телим аңа
Килер көннең — зурын, яңасын.

Туганлык һәм дуслык табарбыз ди
Килгән идек сиңа, Гиндекуш.
Уртак фаҗигане аңлый-аңлый
Кайтып килешебез... Инде хуш!

❁

Сыерчыклар төяп
Язлар килгән саен
Шартлап ватылсын инештәге бозлар.

Офык-дәрья тулып
Таңнар аткан чакта
Шартлап ачылсын алсу мәк чәчәге.

Табыннарга, күкрәп,
Шатлык килгән саен
Шартлап ачылсын шампан шәрабләре...

Яшәсен,
Әйдә яшәсен
Ил өстендә тыныч шартлаулар!

---
[1] Гиндекуш — Әфганстандагы тау исеме.

# Әмир Мәхмүд

## «Матур» исем эзләүчеләргә

*Йорты Болгар улса улсын,*
*Йортны болгар улмасын!*

МИФТАХЕТДИН АКМУЛЛА

*Татарлыктан татар һич гарь итәрме,*
*Кеше үз исмене инкяр итәрме.*
*Татарлыкта татар угълы татармын,*
*Татар түгел димә — башың ватармын.*

ДӘРДМӘНД

Болгар йорты — минем туган йортым,
Матур исемем минем — татар ул.
Йортны болгый бүген куркак җаннар,
Татар исемен, телен сатар ул.
Шовинист шат аңа: «Молодец»,— ди.
Каш астыннан гына көлер ул.
Милләтеңнең исемнәрен сату
Илне сату белән бердер ул.
Кара җаннар имеш кырын карый...—
Француз яки инглиз булыгыз.

Башкорт яки немец булыгыз,
Манкорт яки иблис булыгыз,
Яраклашып, данлы булыгыз
Исем сатып, шанлы булыгыз!
Әмма минем матур исемемә
Кагылмасын шакшы кулыгыз!
Татар исеме — иң-иң матур исем,
Әни кебек бердәнбер бит ул...
Исем бетә икән, җисем бетә,—
Башны кисү белән бер бит ул!

## Бәхет

Тормыш бит ул алтын тәхет түгел
Гомер белән бергә куелган.
Тик тәхетен эзләп, мәхәббәтем
Керәм диеп тора куенга.

Тәхетем бар, ләкин бәхетем кайда,
Биеклектә микән торагы?

Гади кеше хуҗа булган аңа:
Бөеклектән тора югары.

Тәхетләрне бизәкләргә күмеп,
Кешедән дә биек итмәгез:
Тәхетемне алып китсәгез дә,
Бәхетемне алып китмәгез!

## Тарих

Җирем минем — кулларымда,
Тиз кузгалам мин старттан.
Җитез сәяхәтче кебек
Тарих атлый минем арттан.
Ашыга-ашыга атлый тарих,
Атлый Тарих минем юлдан.
Тартып алырга уйлыймы
Җиркәемне минем кулдан?

Җирне кулларыма тотып,
Очам гына Кояшыма.
Килеп җитәм, сәлам бирәм
Егетләрчә, оста гына.

— Өлгерсең! — ди миңа Кояш,—
Җиргә килер мәңгелек яз...
Кояш нуры — кулларымда,

---

Әмир МӘХМҮД *(1947) — шагыйрь, әдәбият галиме; «Матурлык тантанасы», «Мәңгелек моң» исемле шигырь китаплары, «Муса Җәлил иҗатында эстетик идеал», «Гүзәллек тантанасы» (Торжество прекрасного) исемле монографияләр авторы. Казанда яши.*

Халык уе — уйларымда.
Шат нурларның җылылыгы
Көчте кинәт җырларыма.

Тарих салкын, минем йөрәк
Кояш кебек кайнар, җылы.
Мин тарихка бүләк итәм
Кояш нурын, гүзәл җырым:

Җырла, Тарих, безнең көйгә,
Чалчәч Тарих, җылын әйдә!

Кояш нуры — күңелемдә,
Кояш нуры — серле Җирдә.
Кояш нуры — дустың булып,
Калсын — Тарих, Изгелекне
Саклый белгән күңелеңдә.

## Үзгәрешләр

Бөтен дөнья актан иде,
Икебез дә ап-актан.
Барысы да актан иде:
Ап-ак чәчәкле июнь күк
Күлмәгең дә ап-актан,
Тешләрең дә ап-аклар.

Күкрәкләрең актан иде...
Аккош канатлары кебек
Кулларың да ап-аклар.
Чәчләрең дә актан иде...
Хисләрең дә ап-актан.
Барысы да актан иде...
Бөтен дөнья ап-актан.

Әйтерсең, синең тәнеңнән
Дөнья аклыгын тапкан.

Мин үзем дә актан идем...
Күңелем дә ап-актан.
Киемнәрем дә ак иде,
Сөюем дә ап-актан.
Гүя миңа ай сылуы
Айның аклыгын япкан.

Аккан елларым ап-аклар,
Без һаман да ап-актан...
Бары ап-ак араларга
Нух заманнарыннан калган
Кара каралык яткан.

## Татар зиратында

Татар зиратында — томан,
Төшкәнме кайгы сыман?..
Бала туган. Ана үлгән.
Кабере җайлы сыман.

Гөлләрдә — чык тамчылары,
Күңел яшьләре сыман.
Тарих җилләре шәфкатьсез...
Кабер ташлары сынган.

Бәхет киткән, кайгы килгән...
Кемдер шатлана сыман.

Кабер ташларын сыйпыйдыр
Томан, карт ана сыман.

Җир җылысын тоя Кеше,
Җиргә сыенып тынган.
Әйтерсең, ул яратылган
Аккошлар канатыннан.

Яңа Тукайларын көтә
Зират, сагынган сыман...
Ак томан булып Сәйдәшнең
Моңы агыла сыман...

## Хыянәт

Йөрәккәең синең — таш, дисең.—
Ишекләрен иркен ач, дисең...
Йөрәгемдә — авыр таш ишек,
Бу ишекне ачыйм соң ничек?

Хыянәтне йөрәк кабул итми,
Мәхәббәткә дәва юк та соң...
Тиз ачылмый йөрәк ишекләре,
Бер мәртәбә сынгач тоткасы...

## Миргазиян Юныс

# КАРАВЫЛ ЙОРТЫ

1



дәм баласының гомере аянычлы кыска. Ялгызлыктан бергәлеккә, бергәлек тоткыныннан кире ялгызлыкка күчеп йөргән арада шул кыска гомер комга сеңгән яңгыр суыдай саркып юкка чыга. Гомернең күп өлешен кысыр теләкләр, гамәлгә аша алмаслык өметләр бушлыгы тутырган. Безгә тиешле бәхет шул бушлык эчендә калып югала тора. Бәхетне без киләчәктән көтәбез. Киләчәкнең бәхет алып килүенә без иманырга тиеш. Ансыз яшәп булмый.

Ялгызлыктан курку безне халык дип аталган илаһи берәмлеккә тоташырга мәҗбүр иткән. Халыкка әверелү бәхетенә ирешкән кешеләрнең уртак телләре, уртак диннәре, ата-баба калдырган изге мираслары бар. Шул мираслар тарихка теркәлгән.

Татар халкының тарихы язылмаган әле. Тарихның язылган өлешен ботарлап, таратып ташлаганнар. Без укыган тарихны яулап алучылар язган. Алар аны үзләренең канлы эзләрен яшерер өчен язганнар.

Телен, динен, туган туфракка булган фидакярлеген саклый алмаган халык үлә, юкка чыга. Нәрсә алып килер безгә киләчәк, үлемме, терелүме? Әбит ярты гына гасыр элек без киләчәктән бары тик бәхет кенә көтә идек...

Колхозлашу чорында Караяр авылының Әтәмби урамында яшәүчеләр өйләренә бикләнеп утырдылар. Берләшкәннән соң биш-алты ел үттеме икән, аларны инде дүртенче бригаданың каравыл йортыннан чыгарып та булмый иде. Нәкъ шушы чорда мәчетләрне җимерделәр. Мәчетләр исән чакта җомга намазыннан соң ирләр, бергә җыелып, эчләре бушаганчы гәпләшәләр иде. Әллә шул бергә җыелып серләшүдән мәхрүм калу куып кертте ирләрне каравыл йортына, әллә инде утызынчы елларда чиксез көчәеп киткән кеше аулау гадәте аларны бер-берсенә сырышырга мәҗбүр итте. Курыкканда сарыклар да бер төркемгә укмашалар.

Каравыл йортында утырганда эчкә кереп оялаган курку бераз басыла төшкәндәй була иде.

Тышкы яктан киез кадакланган авыр имән ишек. Ишектән керү белән, уң җилкәң зур мичкә килеп бәрелә. Сул як стена буена гади фанердан эшләнгән шкаф куйганнар. Шкаф белән аксап беткән такта өстәл арасында артлы урындык — бригадир иптәш Шәйдуллинның тәхете. Гади колхозчылар ул тәхеткә утырырга куркалар. Власть дигән нәрсәне югарыда утыручы җитәкчеләр бирә. Властька кул сузу һәр чорда, бигрәк тә бүгенге көндә, иң зур җинаять санала иде. Гади колхозчыларның урыннары такта сәкедә, мич буена куйган эскәмиядә, мич башында. Аксакаллар урыны — сәке түмич буена куйган эскәмиядә, мич башында. Аксакаллар урыны — сәке тү-

---

Миргазиян ЮНЫС *(1927) — әдип. «Тозлы җил», «Теләп алган давыл», «Энҗе эзләүчеләр», «Европа ат сагына» һәм башка әсәрләр авторы. Мәскәүдә яши.*

рендә. Читтәрәк — еракларда йөреп, дөнья күреп кайткан ирләр утыра. Каравыл йортына яшь-җилбәзәк, малай-шалай да җыела. Алар мич башына кибәргә куйган камыт-ыңгырчаклар өстенә кунаклыйлар.

Мичтә дөрләп каен утыны яна. Ялкын телләре, җилфердәп, мич авызына үреләләр дә, кинәт өскә таба борылып, юллыкка кереп югалалар. Каравыл йортында — төтен исе, әчкелтем ат исе, дегетләгән каеш, тузан һәм тәмәке исе. Тынчу һава тын юлына керә, үпкәгә тулып, канга тарала. Ирләрнең күкрәкләре эчендә ләззәтле әрнү. Канда аңлашылмас тынгысызлык. Атлар үз абзарында чакта теләкләрне аңлап була иде шикелле. Ирләрне атсыз калдырдылар. Канатлар сынды. Төрле яктан ялган чорнап алган. Тормышны курку басты. Кысынкылык. Өнсезлек. Көне-төне колхоз эше, куаныч һәм туклык бирми торган нәтиҗәсез, мәҗбүри эш. Дөньялар үзгәрмәсә, яшәп булырмы икән?

Эчкә җыелганны бушату, уртак тел, уртак юаныч эзләп, Әтәмби ирләре каравыл йортына җыелалар. Билгеле, сыкранган җанны коры сүз белән генә дәвалап булмый. Тынычланыр өчен Әтәмби ирләре чөлем көйрәтәләр. Кичкә таба бу йортта төтен куера. Түшәмдә адашып йөргән тараканнар төтенгә исереп, ләчтит сатып утыручыларның өсләренә коела башлый. Ирләр үзләре дә исерә. Әллә инде бу сүз дигән нәрсәдә, аракыдагы шикелле, кешене исертә торган сихерле көч бар? Сүз дә бит, нәкъ хәмер шикелле, кайгы-хәсрәтләрне бетерә, акылны юып төшереп, эчтәге хисне генә калдыра. Сүз тылсымы аларны чынбарлыктан аерып, әкият дөньясына китереп ташлый. Алар үзләре дә әкияттәге Алып батыр шикелле булып китәләр. Инде караңгы төшеп килә, таралырга вакыт.

Сизеләр-сизелмәс кенә ишек ачылып ябыла.

— Исмә-агый-иль, сиңайтәм. Кайт дим. Кыстыбый пешергәнием... Суынып бетә инде. Кайт, яме.

Кыстыбый. Ул да бар микәнни соң әле бу дөньяда? Әтәмби ирләре иреннәрен ялап алалар. Әйе, бар иде кыстыбыйлар, коймак, тәбикмәк, сумсалар ашап яшәгән чаклар. Умач уарга он табарга интегеп йөргән заманда Шырый Исмәгыйленең хатыны Гөлбостан кыстыбый пешергән. Ялганламый торгандыр. Бай Гайнетдин кызы бит. Гөлбостанның әтисен Себергә озаткач, аларның абзар-курасына колхоз атларын ябып, өйләреннән каравыл йорты ясадылар. Мичкә ягарга утын юк. Сыерга салырга салам бетте. Бер уч онга интегеп йөргән чакта Шырый килене Гөлбостан кыстыбый пешергән. Ил белән бергә күргән михнәтләр — михнәтнең яртысы гына. Әйтмәскә кирәк иде Гөлбостанга нәрсә пешергәнен...

Исмәгыйль хатыны чакыру белән урыныннан сикереп тормады. Киресенчә, хатынының тавышын ишеткәч, йөзенә гамьсезлек чыгарырга тырышты. Ул әле һаман утыра бирә. Чакыру белән чыгып китәргә ярамый. Әнә ничек күзәтеп утыралар. Хатынының тавышын ишетү белән урыныннан сикереп торсаң, «Бу Исмәгыйль катынының чабата олтырагына әйләнеп беткән икән»,— дип көлкегә күтәрүләре бар.

Бу кыстыбый дигән нәрсә ләчтит сатуның тәмен алды бит әле. Әңгәмә аксый, туктала, элеккеге тизлегенә кире кайта алмый. Ниһаять, кыстыбый онытылды. Әңгәмә куера башлады. Исмәгыйль мыштым гына урыныннан торды, иплән кенә ишекне ачты да урамга чыкты. Урамнан бер тын баргач, борылып, каравыл йортына карады. Тәрәзәдән карап торучы юк шикелле. Менә ул, чалбарын күтәреп алды да, өенә таба элдертә башлады.

## 2

Колхоз ындырыннан салам кайтаручылар, атларын туарып, абзарга кертеп җибәрделәр дә камыт-ыңгырчакларны каравыл йортына алып керделәр. Үтереп карын ачкан иде. Салам кайтаручылар бер генә минутка мич каршына барып чүгәләделәр. Бер генә минут тыңлап торырга да, тизрәк өйгә кайтып китәргә. Әкренләп өйгә кайту да, карын ачу да онытылды. Сүз дәрьясында мичкә ягарга утын да, сыерга салырга салам да кирәкми иде. Бу сүз дигән нәрсә ашыйсы килүне дә баса икән...

Авыл башы Фәридун кибеттән кайтышлый урамнан җырлап узды:

Аклы ситса күлмәгемне
Элеп куйдым чөйләргә;

Авылымдагы авыр тормыш
Куды ерак җирләргә.

Аягымдагы итекнең
Бер табаны тишелгән,
Туган үскән илләремдә
Ризыкларым киселгән.

Яшәү әллә ничә төрле. Караярдан өч чакрым Кандыз юлында Тәпеч исемле урыс авылы бар. Ул авылның кешеләре Әби патша заманында Караяр җиренә килеп утырганнар. Шуларның бер бик кызык әйтемнәре бар: «Рыба ищет где глубже, человек — где лучше». Юл йөргәндә төн кунарга туктыйсың бит. Таган асып чәй кайнатасың, арбага урын җәеп, менеп ятасың. Тәпеч кешеләренең тормышлары нәкъ шундый. Читкә китсәләр, сагына белмиләр, авылда яшәгәндә туган җир, туган туфрак дип каннарын бозып маташмыйлар.

Дүрт гасыр буена Караярның җирен кисеп, килмешәкләргә өләшә тордылар. Җирсез калып ачка үләргә дучар ителгән Караяр халкы кайларга гына таралмады. Себер ягы, Урта Азия, Казакъ далалары, Котып ярлары, Донбасс, Ерак Көнчыгыш, Төрек иле. Әле шушы көннәрдә генә Караяр авылыннан чыккан кешеләрнең теге самурайлар иле, ерак Япониягә дә барып җитүләре турында сөйләп утырдылар.

Утыз бишенче елгы ачлыкта Фәридун Донбасска китте. Бер ел эшли алдымы икән, сагынуына түзә алмыйча, туган авылына кайтты. Читтә йөргәндә Фәридун аракы эчәргә өйрәнеп өлгергән иде. Кайткач та тыела алмады, эчүен дәвам итте. Әлек бит Караяр авылында аракы эчкән кеше булмаган. Каян килеп керде икән бу өянәк, дип, каравыл йортында еш кына баш ватып утыралар иде. Кешеләрнең нәрсә эшләгәннәрен күзәтеп торучы авыл советы, колхоз идарәсе бар. Кемнең нәрсә эшләп йөргәнен партия ячейкасы, комсомол, ревкомиссия тикшереп тора. Караярга беркетелгән махсус НКВД кешесе атна саен килеп тикшереп китә. Эчеп, исереп, тәртип бозып йөрүче кимеме, ел саен арта тора. Патша заманында шушы оешмалар алып барган эшне картлар башкарганнар. Авылда талашып, тәртип бозып йөрүче булмаган. Аракы турында сөйләп тә торасы юк. Аның нәрсә икәнен дә белмәгәннәр. Һай дөньялар.

Әйе, тагын бер көн узып китте. Көн туганда утын юк иде — әле дә юк. Көн туганда сыер ач иде — әле дә ач. Килерме икән Әтәмби урамына мул тормыш? Әллә, киресенчә, мохтаҗлыклар тагын да артырмы? Ирләр әкренләп өйләренә тарала башладылар. Өйдә аларны нужа белән көрәшеп каны бозылган зәһәр хатын, ач балалар көтә иде. Төн кунарга башка урын юк, кайтырга кирәк. Каравылчы Габделвәли каравыл йортын аңгәмә вакытында оеп ауган малай-шалайдан әрчергә тотынды. Ул аларны мич башыннан сөйрәп төшерә, башларына бүрекләрен чәпи дә, ишек янына китереп, тезе белән бусаганы атлап үтәргә ярдәм итә.

Яңа көн туганчы Габделвәли ялгыз. Ул ашыкмыйча гына тәмәке төрә, чакма чагып, ут кабыза. Хәләл җефетең пешергән татлы ашлар... Хатын куенында изрәп ятулар. Бар иде җәннәт рәхәтендә яшәгән чаклар. Тәмәке уты авызын пешерә башлагач, Габделвәли төпчектә калган самосадны учына җыеп, янчыгына салды. Иншалла, көн узды. Мич башына менеп ятарга да була. Анда менеп ятар алдыннан салкынга чыгып, бригада мөлкәтен тикшереп, атларны карап керәсе бар. Күк йөзе томаланып торган иде, буран чыгар шикелле.

Каравылчы карт бишмәтенең сәдәфләрен эләктерде, мескен бүреген басыбрак киде. Ишекне ачу белән февраль суыгы картның битенә ябышты, юка бишмәт аша ябык тәненә ташланды. Иясез мал, диде ул ишек алдында яткан чананы күргәч. Чананы лапас астына сөйрәп кертте, тәртәсен өскә күтәреп бәйләде. Абзар капкасына барганда себеркегә абынды. Аны да алып баганага сөяп куйды.

Менә кайда ул дөнья рәхәте, дип уйлады Габделвәли ат абзарына кергәч. Монда җылы һәм тыныч иде. Атлар тыныч кына салам чәйниләр. Төнге абзар дөньяның җанга рәхәтлек бирә торган иң изге урыны кебек тоела. Монда ызгыш юк, көнчелек юк. Атлар комсызлыкны, әләкне белми. Аларга дан да, байлык та кирәкми. Атлар арасында куштан активистлар да, сыйнфый дошман дип аталган бәхетсезләр дә юк. Атлар янында торганда кешелек дөньясының серләре ачыла башлый. Әллә нәрсә булды бу дөньяга, дип уйлады Габделвәли. Әйтерсең, аның астын өскә әйләндереп ташладылар. Ялкау, ялган-

чы Тыңкыш Гәрәйне авылга баш итеп куйдылар. Бөтен авылга үрнәк, гадел, тырыш Гайнетдинне Себергә озаттылар. Ячейка секретаре Тыңкыш Гәрәй тирәсенә аның үзенә охшашлы кешеләр туплана башлады. Корчаңгы Шәйдулла малаен Әтәмби урамына башлык итеп билгеләделәр. Әтәмбидә алардан да ялкау, алардан да мәнсез кем бар иде? Шул гомер буе кеше өлешенә кереп яшәгән Шәйдулла малае, байларны кырып бетереп, миравой коммунизм төзибез, дип мактанып йөри.

Әтәмби ирләре эштән бизә башладылар. Хәзер алар, каравыл йортына җыелып, көннәр буе тел саталар. Тормышның көннән-көн авырая башлавын беркем аңлата алмый. Сүз күбәйде, сүзнең кадере бетте. Габделвәлинең яшьлегендә эш күп, сүз әз иде. Ул чакта эшнең кадере бар иде. Габделвәлине башка нәрсә дә куркыта — атлар әзәя башлады. Элек Әтәмби урамында йөздән артык ат бар иде. Колхоз төзегәнгә бишме ел үтте, шул йөздән артык атның бары егерме җидесе исән калды.

## 3

Колхозчыларны каравыл йортына җыярга дигән фәрман килде. Габделвәли карт, йорттан йортка кереп, Әтәмби кешеләрен чакырып йөрде. Бу юлы каравыл йортында хатыннар да, колхоз эшенә йөри башлаган кызлар да бар. Каравыл йорты шыгырым тулы. Клуб мөдире иптәш Сәетвәккасов лекция сөйли.

Ватаныбызны төрле яктан дошманнар чорнап алган. Капиталистлар, чемберлиннар, социал-демократлар, самурайлар, буржуаз интеллигентлар, тредюниончылар, тагын әллә кемнәр. Шуларның барысын бергә җыеп, бер генә сүз белән әйткәндә, алар тышкы дошманнар дип атала. Шуларга өстәп, эчке дошманнар да бар икән әле. Тышкы дошманнар җибәреп торган шпионнар, диверсантлар, провокаторлар, иске тормыш тәрбияләгән кулаклар, милләтчеләр, дин тотучылар, муллалар, зиновьевчылар, троцкистлар, промпартия агентлары, контрреволюционерлар, вәисовчылар, җидегәнчеләр һәм совет хөкүмәтенә тел тигерүчеләр. Социализмга, пролетар диктатурага, партиягә каршы көрәштә эчке дошманнар, тышкы дошманнар белән берләшеп, бергә эш итәләр икән. Алар халык арасында коткы таратып, завод-фабрикаларны шартлатып, активистларны үтереп, социализм төзүгә аяк чалып торалар икән. Халык дошманнарын башкалада фаш иткәннәр. Алар өлкәләргә таралганнар. Өлкә җирендә фаш итә башлагач, өязләргә, өяздән авылларга таралып беткәннәр. Бүгенге көн өчен иң кирәк, иң кыйммәт нәрсә — уяулык икән. Дошман сине туры юлдан яздырыр өчен иң якын дустың, хатының, күз нурың кебек күргән газиз балаң аша да котыртып тора икән.

Лекция азагында Сәетвәккасов турыдан-туры кисәтте:

— Иптәшләр, шушы йортка җыелып, сезнең дошман тегермәненә су коя торган сүзләр сөйләвегез турында сигнал бар. Мин сезне ячейка исеменнән кисәтеп куям, каравыл йортында ләчтит сату туктарга тиеш. Дүртенче бригадта мин агитатор. Сезнең миннән башка кешене тыңларга хакыгыз юк. Аңлашылдымы? Кемнең нинди соравы бар?

Җитәкче Җәләли кул күтәрде:

— Син, иптәш Сәетвәккасов, агитатор кеше, ягъни мәсәлән, идеология фронтының алгы сафында көрәшеп йөрүче. Син аны, ягъни мәсәлән, теге Кытайга янәшә Тибет дигән дәүләтне беләсең инде, әйеме? Шул дәүләт белән ни сәбәпле ике юлбашчы идарә итә? Аның берсе, син аны беләсең инде, Долой-лама[1], икенчесе — Панчен-лама. Син, агитатор буларак, безгә аңлатырга тиеш, шуларның кайсы баширак, Долой-ламамы, әллә Панчен-ламамы?

— Аларның кайсы баш икәнлеге турында, райкомнан күрсәтмә килгәч, мин сезгә аңлатырмын,— диде агитатор.

Ирләр бер-берсенә карашып алдылар. Әйе, Сәетвәккасов теге ике юлбашчының кайсысы баш икәнен белми. Димәк, ул халыкара хәлләрне дә белми. Белмәгән кешене тыңлауда ни файда. Каравыл йортына җыелып сөйләшеп утыруны туктатмакчы була. Боерык биргәнче син башта халыкара хәлләрне өйрән.

Агитаторның кисәтүе нәтиҗәсез калды.

---

[1] Далай-лама.

## 4

Әңгәмәнең кызып житкән чагы иде. Әтәмби ирләре сөйләшүдән туктап, тыңлап тора башладылар. Әллә нинди сәер тавыш ишетелә. Сөт аерту машинасы кызып әйләнгәндә шундыйрак тавыш чыгара. Герман һәм гражданнар сугышына катнашкан ирләр беләләр, туп снарядлары һавада очып барганда шушы чама сызгыра.

— Яраплан бу,— диде Житәкче Жәләли.— Кыямәт көне алдыннан һавада тимер кошлар очып йөрер диелгән бит Корьәндә.

Председатель булып утырганда Житәкче Жәләли әллә ничә тапкыр Казанга барды, зур урындагы кешеләр белән очрашты. Ул инде ялгышмаска тиеш иде. Чыннан да, бу самолет тавышы булып чыкты.

Караяр тарихында беренче тапкыр самолетны узган җәйдә күрделәр. Башта аның тавышы килеп җитте. Чирек сәгать чамасы шул сәер тавыш ишетелеп торганнан соң, күк йөзендә бар кара тап пәйда булды. Кара тап һаман үсә, зурая. Менә ул чәүкә чаклы булды, торна зурлыгына җитте, әстәгъфирулла, һаман зурая. Үзе очар кош шикелле канат та какмый, егылып та төшми, оча. Бу бит, җәмәгать, теге Корьән шәрифтә әйтелгән ахырзаман кошы. Бөгелмә ягыннан күренгән тимер кош Бәләбәй ягына китеп юкка чыкты. Үзе югалгач та аның гөжләве бик озак ишетелеп торды.

Тимер кош очып узганнан соң карчыклар сандык төбендә муртаеп яткан кәфенлекләрен чыгардылар. Исрафилнең сур өргәнен көтә башладылар. Ахырзаман һаман килми. Шул вакыйгадан соң инде менә ярты ел узды. Атна саен авыл өстеннән яраплан очып уза. Самолетның бу якларга килеп чыгуын башкача аңлатырга туры килде. Дөнья күргән ирләр бу хәлне сугыш чыгу куркынычына бәйләделәр. Герман сугышында плен төшеп, өч ел Австриядә яшәп кайткан Жирән Миргарифжан болай аңлатты:

— Дөрес, яраплан күренгәннән соң сугыш чыкмый калмый. Даһи юлбашчыбыз, халыкларның атасы Иосыф Бисарионывич сугыш чыгасын сизеп алган. Ул үзенең мөлкәтен ярапланга төятеп тынычрак җиргә, Урал ягына ташыта башлаган.

Бу сүз ирләрнең җаннарын өшетеп җибәрде. Ач торырга риза, ялангач йөрергә риза, бар нәрсәгә риза, түлке сугыш кына чыга күрмәсен, дип шаулаштылар алар. Һәм шундук ашык-пошык өйләренә тарала башладылар.

Миргарифжан каравыл йортыннан чыккач, бригада абзарына, атлар янына юнәлде. Абзар эчен җанга шифалы рәхәт тынычлык чорнап алган. Ат бит ул изге хайван, пакь һәм тыныч яши белә, дип уйлады Миргарифжан. Озакламый колхозларга тимер атлар китерергә тиешләр дип сөйлиләр. Алар килсә, бахбайлар, сезнең барыгызны да җыеп ит салымына озатырлармы икән? Сугыш чыкса, безне дә туп азыгына әйләндереп бетерерләр инде. Миргарифжанның кола алашасы абзар почмагында җирдән салам чүпләп йөри иде. Хуҗасын күргәч, тизрәк янына килеп, аның җилкәсенә муенын ышкый башлады.

— Мин сиңа ипи алып килдем,— диде Миргарифжан.— Үз өлешем. Килачәктә сине ипи белән сыйлап булырмы икән? Бу ипине хатын алабута катнаштырып, соңгы оннан пешерде. Мә, авыз итеп кара.

Кола алаша ирене белән ипине электереп алды да ләззәтләнеп чәйнәргә кереште.

— И-и-и бахбаем,— диде Миргарифжан.— Син киткәч, абзар-кура җансыз калды. Без инде ятимнәр шикелле яшибез. Ничек инде игенче атсыз яши алсын? Безнең аерылышканга биш ел тулды. Санап кара әле, бу абзарда ничә ат бар? Узган язны гына да сезнең яртыгыз кырылып бетте. Ирләр дә бит нәкъ сезнең шикелле. Әтәмбидә аларның яртысы калдымы икән? Ирләрнең күбесе төрмәгә эләкте, калганнары, авылны ташлап, бәхет эзләргә киттеләр. Нинди каргыш төште икән безнең Караярга? Халык монда элек тә мантымаган. Мин дә китәр идем, син исән чакта ни җаның белән китмәк кирәк?

Абзар капкасы шыгырдап ачылды:

— Кем бар монда?

— Мин бу, Миргарифжан,— диде кола алашаның хуҗасы.

— Монда керергә сиңа кем рөхсәт итте? — диде бригадир Шәйдуллин.

— Атым янына кергән идем.

— Нинди ат ул? Хосусый ат юк монда. Колхоз атлары янына минем рөхсәттән башка керергә ярамый.

Җирән Миргарифҗан бригадир ачкан капкадан чыгып сызу ягын карады.

5

Бүген каравыл йортында өнсезлек. Әтәмби ирләре сәке читендәге буш урынга күз сирпеп алалар да, көрсенеп куялар. Узган дүшәмбедә Җирән Миргарифҗанны ике коралллы кеше районга алып киткәннәр. Шуннан соң аның хәбәре-хәтере юк ди. Кичә кич белән аның хатынын да кулга алганнар, балаларын үрәчәле чанага төяп Бөгелмәгә озатканнар. Халык дошманы балаларын башка балалар янында тотарга рөхсәт юк икән. Дошманлык тәэсире ата-анадан балаларга бик тиз йога икән.

Бу каһәрле җиргә җыелмаска кирәк иде. Каравыл йорты инде күпме кешенең башына җитте. Монда килмәскә кирәк иде. Нишлисең, сыерга салырга бер шырпы салам, мичкә ягырга бер чеметем утын юк. Әтәмби ирләрен бу йортка мохтаҗлыклар куып китерә. Башка кай җиргә барып борын төртмәк кирәк? Монда килеп нәкъ синең шикелле коллыкта яшәгән кешегә зарларыңны ачып салгач, яшәү җиңеләеп киткәндәй була. Бәлки бардыр ул җиңел тормыш? Бәлки каравыл йортына җыелган ирләрнең берәрсе аның кайда икәнен белә торгандыр?

Идарәдә эшен бетереп, бригадир Шәйдуллин кайтып төште. Председатель яныннан кайтты бит, зур кеше яныннан, шуңа күрә ул гади колхозчылар белән исәнләшеп тормады. Авылда бригадирдан өстен ике кеше бар: колхоз председателе иптәш Хәсиятуллин һәм ячейка секретаре Гәрәй Әпсәләмов. Авыл советы председателе Гыйльфановның бригадирдан өстен буласы килә. Кара халык авыл председателен бригадирдан өстен дип йөри. Гыйльфановның кулында чебен куркытырлык та власть юк.

Шәйдуллин, идәндә утырган үсмер малайлар өстеннән атлап үтеп, тәхетенә барып утырды, җыелган халыкка күз сирпеп алды. Утыралар. Нәрсәдер көтәләр. Мескеннәр бит инде. Бернинди хокуклары, бер тамчы көчләре юк. Кая теләсәң шунда җибәреп, нәрсә теләсәң шуны эшләтеп була. Кызганыч бәндәләр, ләкин аларны кызганырга ярамый. Әйтик, Шәйдуллинны бригадирлыктан төшереп ташладылар ди. Ул кызганган кеше аны шундук таптап китәчәк. Яшәүнең кануны шундый: йә син үзең таптыйсың, йә сине таптыйлар.

Ирләр, күзләрен мөлдерәтеп, бригадирга карап утыралар. Шәйдуллин идарәдән наряд алып кайтты. Ирләр шуны көтә. Әнә ничек куркалар. Әйтерсең, Газраил аларның җаннарын алырга килгән. Шәйдуллин дәшми, юри суза. Власть синең кулыңда икәнлеген күрсәтергә иң кулай чак. Белеп торсыннар иптәш Шәйдуллинның кем икәнлеген. Кай чакта алар онытып җибәрәләр. «Зәйгә урман кисәргә биш кеше»,— дисәң, аларның җаннары шундук үкчәләренә төшеп китәчәк. Аңлыйлар алар февраль аенда урман кисүнең нәрсә икәнлеген. «Балахнага торф чыгарырга өч кеше»,— дип белгертсәң, аларның йөрәкләре ярылачак. Әтәмби ирләре торф чыгарудан ревматизм авыруы ияртеп кайталар. Әшәке чир. Язын-көзен ирләрнең буыннарын кимерә, аннан соң аларның йөрәкләренә тотына. Балахнада торф чыгарып кайткан кешеләр өч-дүрт елдан соң каберге керәләр.

«Кар тотарга үз көрәге белән унике кеше»,— сүзен ишетәселәре килә Әтәмби ирләренең. Бу эшне колхозлашу тудырды. Караяр авылында элек кар тотуның нәрсә икәнлеген белмиләр иде. Идарәдән «нәрәт» килгәч, ирләр, хатын-кызлар агач көрәк күтәреп, кырга чыгалар да, балачага шикелле, кар өеп йөриләр. Алар өеп калдырган карларны буран тигезләп китә. Колхоз эшенең күбесе — кар тотуга охшашлы боерык үтәүгә көйләнгән кирәксез эш.

Бригадир Шәйдуллин һаман көттерә. «Карчыгадан — кан, ябалактан — йон. Кошка-киеккә түмгәк булып күрен...» Бәлки шушы ырым сүзләрен укып утырырга кирәктер, нәрәт тырнагыннан котылыр өчен?

— Ызначыт,— дип башлап җибәрде Шәйдуллин боерыгын. Боерык урысча булырга тиеш. Татарча биргән боерыкны кем санга суга. Бригадир итеп утырткачы Шәйдуллин урысча белми иде. Өйрәнергә туры килде. Колхозлашкан елны ук ул абайлап алды, урысча белмәгән кешене җитәкчелеккә утыртмыйлар. Нинди милләттән булма, син урысча белгән кешегә буйсынырга тиеш. Дөрес, татар авылында яшәп урысчаны үзләштерү

шактый катлаулы иде. Әлеге боерык бирергә киңәшмәләрдә кыстырырга җитәрлек кенә белә ул. Ә инде председатель итеп куйсалар, маржага өйләнеп булса да, җитәкчеләр телен өйрәнергә әзер ул.

— Ызначыт, теге Даулы болындагы печән эскертен начинать итәргә приказ чыкты. Вәт так... Слушай! Син, Исламгали Галәү атын җигәсең, ә син, Инсаф — Гайнан атын. Пнимаете? Вәт так. Ызначыт, сез бригадка ике йөк печән кайтарырга тиешсез. Яснымы?

Мәкерле урын иде ул Даулы болын. Кайсы патша булгандыр ул чакта. Әби патшага кадәрге чор иде. Караяр җирен кисеп алып, урыс алпавытын китереп утырткканнар. Революциядән соң ул җир Тәпеч исемле урыс авылына китте. Ул җир ипигә ягып ашарлык әйбәт иде. Килмешәк алпавытка Ык үзәненнән болын да кисеп биргәннәр. Печән уңа торган иң гүзәл болынны. Нәфесле кеше булган күрәсең урыс алпавыты. Биргән болынга гына риза булмыйча, Караяр өлешеннән тагын алты-җиде дисәтинә өстәгән. Караяр ирләре, сәнәк күтәреп, болыннарын кайтарып алырга алпавыт утарына барганнар. Алпавыт Самарадан гаскәр чакырткан. Шул хәрәкәткә катнашкан ирләрнең маңгайларына мичтә кыздырган утлы кыршау сугып җәзалаганнар һәм, канга батырып камчы белән ярганнан соң, Себергә озатканнар. «Даулы болын» сүзе халыкка шул вакыйганы искә төшерә.

Даулы болынны төрле яктан балан һәм шомырт куаклары чорнап алган, шуңа күрә кышларын анда карны тирән сала. Өстәвенә бүген тышта зәмһәрир суыгы, Оренбург ягыннан салкын җил исә. Һай авыр җылы өйдән февраль суыгына чыгып китүе. Бигрәк тә карын ач, тән ябык чакта кешене суык өркетә. Тамак тук чакта алай ук түгел. Печән кибәне әле башланмаган иде. Билгеле, аңа барырга юл юк. Кибән басылган, өсте бозланып каткан. Һай авыр юлсыз җирдән печән кайтару!!

Каравыл йортында авыр, киеренке тынлык. Ирләр көтәләр. Нәрәт шушы гынамы икән, әллә печән кайтаруга өстәп, «Балахнага торф чыгарырга өч кеше» дә бармы? Озак елларга сузылган хокуксызлык, буйсыну, куркып яшәү ирләрнең фикер йөртү сәләтен бетереп үк ташламаса да, шактый зәгыйфьләндерде. Ирләр көтәләр. Наряд шушы гынамы икән, әллә тагын да бармы? Ирләрнең ми сырлары хәрәкәттә. Шул хәрәкәтнең баш сөяге эчендә кыштырдап торуы ишетелгән кебек тоела.

— Көрт муеннан инде анда, иптәш Шәйдуллин,— ди Исламгали, башын күтәрергә куркып. Ул бригадирга карамаска тырыша.— Ай-һай, кереп булырмы икән?

Юк, Исламгали карга батудан куркып борылып кайта торган ир түгел. Керәчәк ул. Типсә тимер өзә, бәрсә очкын чәчрәтә торган ир ул Исламгали. Ләкин... Их, бу тамак туймау китергән зарарлар! Их, бу мәҗбүрилек! Боерык камчысы астында эшләүнең михнәтләре! Ирләр генә түгел, атлар да интегәләр ачлы-туклы яшәүдән. Алар да шундый кызганыч хәлдә. Яз җиткәч, атларның күбесен өрлеккә асып тоталар.

— Узган атнаны, Турай базарыннан кайтышлый, олы йомыш белән кереп шул печән кибәне төбенә чүгәләгән идем,— дип башлады Инсафетдин сүзен.— Көрт — муеннан. Без, иптәш Шәйдуллин, атларны да батырабыз, үзебез дә шунда күмелеп калабыз. Барсаң, анда кәфенеңне әзерләп барырга кирәк.

— Ызначыт, кар тирән дисез инде? Шулаймы? — Бригадир бармаклары белән өстәл тактасына бәргәләп алды.— Ызначыт, атступать итәбез? Бөек юлбашчыбызның бәлшәвикләр ала алмаган крепость юк дигәнен онытгыгызмыни? Әллә сез бәлшәвик түгелме?

— Бәлшәвек булсак та, ул карны ерып кибән янына барып җитү — ай-һай, иптәш Шәйдуллин?

— Кар тирән булмаса, мин сезгә Галәүкә белән Гайнанканы җиктерер идеммени? Слушай, печәнсез кайту диверсия саналачак. Понятнымы?

«Диверсия» сүзенең мәгънәсен ирләр дә, Шәйдуллин үзе дә аңлап ук бетерми. Соңгы елларда ул еш кулланыла башлады. Кешене куркытырга кирәк булдымы, шушы сүзне кулланалар. «Диверсия» сүзен ишетү белән, печән кайтарырга билгеләнгән ирләр бертүзсез әзерләнә башладылар. Шәйдуллин исә, мәсьәләнең хәл ителгәнен белгертү өчен, эшкә чыкканны теркәп бара торган кызыл тышлы дәфтәрне актарырга керешге.

Исламгали стенага элеп куйган камытларның берсен сайлап алды, учы белән киезен капшап карады, бауларын, чөелдереген җентекләп тикшерде. Камыт өстенә ыңгырчак утыртты, сул беләгенә дилбегә, йөгән, аркан элде.

Аркалык бавы һәм түшлек, гадәттә, тәртәдә саклана иде. Исламгали каравылчыдан запас аркалык сорап алды.

Инсаф каравыл йортына салам сорарга килгән иде. Җаваплы эшкә билгеләнүдән файдаланып, бригадирга әйтте:

— Иптәш Шәйдуллин, ул теге сыер дигән нәрсәнең курмысы беткән иде бит әле. Ышанмасаң, барып кара. Бер учлам печән, бер шырпы салам калмады. Җан иясе бит. Син, иптәш Шәйдуллин, игелегеңне онытмабыз, ат астындагы саламны булса да җыеп алырга рөхсәт ит инде.

Салам бирүнең чиктән тыш җаваплы мәсьәлә икәнлеген күрсәтү өчен бригадир бик озак түшәмгә карап, уйланып утырды.

— Ызначит, бу пронблиманы сез печән алып кайткач ришайт итәрбез. Пока син, Инсаф, кыймылда, приказ бирелгән.

Печәннән кайтканчы бригадирның каравыл өеннән таясы һәркемгә мәгълүм. Наряд бирү белән ул кайтып китә. Әйтмәде бу турыда Инсафетдин, тыелды. Начальник кеше күп сөйләгәнне яратмый. Бигрәк тә аның үзе турында сүз кузгатканны.

Күз бәйләнгәндә Исламгали белән Инсаф Даулы болыннан әйләнеп кайттылар. Печән урынына, Инсафның чанасына күк алашаны яткырып, аркан белән бәйләп салганнар. Арттан Исламгалинең буш чанасы сөйрәлеп кайта. Йомран оясына юлыгып, күк алашаның аягы сынган иде.

## 6

Сәкедә тагын бер буш урын барлыкка килде. Мескен Исламгали. Тәкъдиренә шулай язылган булгандыр инде. Әтәмби урамында аннан тыш эш белүче ирләр җитәрлек. Эш белүгә, тырышлыкка өстәп, Исламгали мәзәк сөйли, моңлы итеп җырлый белә иде. Моңлы бала бәхетсез була, дип юкка гына әйтмәгәннәр икән... Бәла агач башыннан йөрми шул, кеше башыннан йөри. Дөрес, кар астындагы йомран оясын Исламгали үзе казымаган. Дөрес, өч аршын кар астындагы йомран оясын күреп тә булмый. Бригадир Шәйдуллин Әтәмби ирләренә Тыңкыш Гәрәйнең сүзен җиткерде: «Чын бәлшәвик җир астында нәрсә барын да белеп йөрергә тиеш. Безне кругом капиталистлар чорнап алган. Арабызда троцкист-зиновьевчылар, солтангалиевчеләр мыж килеп тора. Бүгенге көндә кампрамис — үлемгә тиң». Ирләр «кампрамис»ның нәрсә икәнлеген аңламадылар. Ячейка секретаре Тыңкыш Гәрәй, тырышып-тырышып, «Кызыл Татарстан» газетасын укый иде. Ул шунда язылган сүзләрне сөйли. Исламгалине төрмәгә утыртыр алдыннан, райкомга шалтыратып, райком секретаре белән киңәшми калмагандыр. Димәк, хөкүмәт карары шундый. Колхозның малынамы, мөлкәтенәме зыян килгән икән — кампрамис, давай, сохарыеңны әзерлә дә хатының, балаларың белән бәхилләш.

Тыңкыш Гәрәй инде күптән Исламгалигә кыҗрап йөри иде. Бәлки хуҗалыгын төзек тоткан колхозчыларны берәмләп төрмәгә озатып бетерергә дигән карары бардыр? Мәскәүдән, Казаннан килгән карарларның күбесен җитәкчеләр генә белә. Исламгали тәрәзә капкачларын зәңгәргә буяп тотты. Челтәрле койма. Бәрәңге бакчасыннан бер чемечем чүп үлән тапмассың. Өстәвенә, теге алпавытлар шикелле, узган ел бакчасына алмагачлар утыртты. Шундый кешегә ничек инде ячейка секретаре каныкмасын. Аларны бит, крәстиян халкын ярлы яшәргә өйрәтергә кирәк, дип өлкәдән дә, Мәскәүдән дә туктаусыз кисәтеп торалар, ди.

Исламгалине кулга алган көнне аның хатыны Зөһрәне зәхмәт суккан. Сул кулы, сул аягы йөрми ди, авызы сул якка кыйшаеп каткан. Үзенең тырышлыгы аркасында Исламгали җиде баласын ятим калдырды...

Каравыл йортында тагын матәм, тагын өнсезлек. Аларга монда җыелмаска кирәк иде дә бит. Өйдә бикләнеп утыру куркыта. Әле бит каравыл йортыннан беркемне дә алганнары юк, киресенчә, теге кораллы кешеләр өйгә килеп алып китәләр.

Дөньялар үзгәрде. Юньлегә микән инде бу үзгәрешләр? Кич утырулар, бер-береңә кунакка йөрүләр бетеп бара. Иң якын дустыңа, бер туган абыеңа сер сөйләргә куркып йөрисең... Ә бит газеталарда бөтенләй башка төрле сүзләр: озакламый бәхетле тормыш, муллык, коммунизм килергә тиеш, әзерләнегез, дигән сүзләр язалар.

Көн кичкә авышканда каравыл йорты эченә сасы ис бөркелде. Челем Хәмидулланың тәмәкесе шулай сасы ис чыгара. Әллә төребкә тартканга, әллә самосад тәмәкесен сазлык җирдә үстергәнгә. Челем Хәмидулланың өстендә җәен дә, кышын да — тула чикмән, башында — ялтыравык күзерикле картуз. Бүген аның тәмәкесе беткән. Шул куып китергән аны каравыл йортына.

— Берне көйрәтеп алмасам, үләм. Тартасы килүдән колакларым шеште, күземә сыңар мөгезле, тәнен йон баскан җеннәр күренә башлады,— ди.

Ирләр, ашыгып, янчыкларын Хәмидуллага суздылар. Ул Исламгали турында ишетмәгән икән. Берничә тапкыр йотлыгып суырганнан соң, Челем Хәмидулланың авызы сүз тотмый башлады:

— Бу дөньяда тартасы килүдән дә авыр газап юк икән. Тәмәке беткән чакларда хатын бермә-бер ямьсезләнә. Дөнья тарая. Искә гел сиңа әшәкелек эшләгән кешеләр генә төшеп тора.

— Брачлар тәмәке төтене тын юлын бетәштерә дип сөйлиләр,— диде Инсафетдин.— Тәмәке исе минем Бибисарага ярамый. Аны аяктан егу өчен шушы каравыл йортында киемгә сеңгән ис тә җитә. Бервакыт шулай, ул сыер савып йөргән арада, өйдә тарткан идем. Керде дә, тагын өйне сасыткансың, дип ачулана башлады. Хан кызы түгелсеңдер әле, дим, юкка чәүчәләкләнмә. Аның өянәге шундый икән. Күз алдымда иреннәре чабырып чыкты, күзләрен кан басты, тын алалмыйча гырылдый башлады. Үлә дип торам. Ярый әле күрше Мөкатдисләргә Яхшай авылыннан бер ырымчы карчык кунакка килгән иде. Шуны чакыртып керттек. Үлән суы эчертте. Аннан соң икенче көнне таш буына утыртты. Шул шифалы ташларны, ел саен килеп, безнең Бакыр таудан җыеп алып китә икән.

— Бакыр тау дигәннән, балдызымның кызы Каргалыдан утырмага килгән иде,— дип башлады Челем Хәмидулла.— Бер Мәскәү татары аларда кунак булып киткән. Шул Мәскәү татары бер бик кызык нәрсә сөйләгән. Ул безнең Бакыр тау бөтен дөньяга мәгълүм икән. Әмерек патшасы Иосыф Бисарионовичка хат җибәргән, ди. Шул хатка, әгәр дә мәгәр Караяр авылы каршындагы Бакыр тауны ярапланга төяп Әмерекә ташырга рөхсәт итсәң, ун ел буена халкыңның тамагын туйдырып торырга ант итеп вәгъдә бирәм, дип язган ди.

— Ун ел! — Әтәмби ирләре телләрен шартлатып алдылар.— Ун ел ботны күтәреп, түшәмгә төкереп ятарга була дигән сүз бит инде бу!

— Бездәге кытлыкны Әмерек тә белә микәнни? — дип сорады Инсафетдин.

— Белмичә,— диде Хәмидулла.— Егерме беренче елдагы ачлыкта кем ярмасыннан ботка пешереп ашадык? Минем Әмерек ситсасыннан теккән ыштаным әле дә исән. Төбе генә тишек. Яма да, тагын рәхәтләнеп ки.

— Ыштаның турында соңыннан сөйләрсең,— диде Исмәгыйль Хәмидуллага.— Иосыф Бисарионович нәрсә дип әйткән ди Әмерек патшасына?

— Туйганчы ашап яшәгән кеше бик тиз симерә, дип әйткән, ди. Симез кешенең йөрәгенә май сава. Андый кеше бик тиз үлә, ә минем совет кешеләрен йөз ел яшәтәсем килә, дип әйтеп әйткән ди.

— Бер Бөгелмә кешесе миңа, ашлыкны чит илгә озатып бетерәбез дә, үзебез ач йөрибез, диде. Аның сүзе дөресме икән? — дип сорады Инсафетдин.

— Бездәге урожай чит илгә озатырга да, үзебезгә дә җитәр иде. Ачлык троцкист-бухаринчылар эше ул,— диде Исмәгыйль, сүзгә катнашып.— Сөембикә заманында татарлар ашлык сатып шулкадәр баеган булганнар, татар хатыннарының комганнарына кадәр гел алтын-көмештән булган.

— Пүчтәк сүз бу, җәмәгать,— диде Җитәкче Җәләли.— Беренчедән, Әмеректә патша юк. Алар үзләренең юлбашчыларын бризент дип йөртәләр. Икенчедән, Бакыр тау астындагы алтынны беркем белә алырга тиеш түгел. Советлар Союзының чикләре йозак белән бикләнеп куелган. Граница на замке, дип язалар гәҗитләргә.

— Әмерек патшасының Иосыф Бисарионович Сталин белән сөйләшкәнен Мәскәү татары үзе тыңлап торган дидеңме әле, Хәмидулла абзый? — дип сорады бригадир Шәйдуллин.

Ирләр сискәнеп киттеләр. Кирәк түгел иде болай ачылып китү бригадир тыңлап торганда. Җитәкче кеше бит. Җитәкчеләр янында чама белү мәслихәт. Ходай безгә тел биргән, тыела белүне бирергә онытткан...

— Мин бит аны тыңлап торган димәдем,— Хәмидулла, ярдәм сорагандай ирләргә карап алды.— Мин сезгә балдызымның кызыннан ишеткәнне генә сөйләдем.

Кинәт сөйләшүнең тәме беткәндәй булып китте. Дөньяда ниләр барын шул кадәр беләсе килә, белү беркайчан да сиңа шатлык китерми...

Хәмидулла балдызының кызын озатырга киткән җиреннән Караярга әйләнеп кайтмады. Аны Каргалыдан алганнар дип сөйләделәр. Ни сәбәптер, аның карчыгына һәм балаларына тимәделәр.

## 7

Җәй айларында караңгы төшкәч, фонарь яндырып, агач ботагына асып куйсаң, ут яктасына төрле бөҗәкләр җыела башлый. Фонарь куыгына күбәләкләр, ярканатлар килеп бәрелә. Кайберләре килеп куналар, үрмәләп эчкә керәләр. Фонарь уты аларның канатларын көйдерә, яналар, пешәләр, мескеннәр. Иртән чыгып, фонарь элгән ботак астын карасаң, җирдә бер өем күбәләк, бал кортлары, шөпшәләр мәетен табасың. Фонарьны төнгә карата тагын чыгарып элсәң, икенче көнне иртән тагын яктылык корбаннарын күрәсең. Соң бит, мескен күбәләкләр үзләреннән алдарак кунган бөҗәкләрнең янганын үз күзләре белән күреп торалар. Аларны үлемнән берничек тә туктатып булмый. Әтәмби ирләренең каравыл йортына җыелып сөйләшкәннән соң турыдан-туры төрмәгә эләгүләре утка пешеп үлгән күбәләкләр язмышын хәтерләтә иде.

Каравыл йортында сөйләшеп утырганнан соң кемнедер алып китәләр. Бу хәл инде күп мәртәбә кабатланды. Ирләр һаман җыела, буш вакытларын һаман шунда үткәрәләр. Йортларында кырык эш кырылып ята. Тотынасы килми. Кәеф юк. Эшнең кадере бетте. Эшләп кем баеган? Көне-төне колхоз эшендә бил бөгеп, кем тамагын туйдыра алган?

Җитәкче Җәләли халыкара хәлләр белән кызыксына иде. Ул «Кызыл Татарстан» газетасын даими укып бара. Дөрес, газетаны баштанаяк укып чыгарга төгәл бер көн вакыт кирәк. Юк, ул аны баштанаяк укымый, аның үз темасы бар: халык дошманнары белән көрәш, Чемберлин турында һәм җир йөзендәге иң көчле, гадел һәм җиңелмәс гаскәр — Кызыл Армия турында.

Бүген Җитәкче Җәләли каравыл йортына йомыш белән килде. Колхоз төзи башлаган елны Җәләли җиде ай председатель булып утырды. Эш анда түгел. Җәләлетдин агай җитәкчелек итү эшен ишетеп кенә түгел, үз тәҗрибәсеннән чыгып белә иде. Шуңа күрә ул, йортының түбәсе тишелеп, өенә яңгыр үтә башласа да, килеп  салам сорамады. Коймалары таралып төшкәч, ул аны сүтеп якты. Караltылар да утынга китеп беттеләр. Утын китерергә колхоздан ат сораганы да булмады, чөнки беренче урында колхоз эше, бары тик шуннан соң гына синең йорт эшең. Абзар-курадан Җәләлинең кечкенә генә бер келәте, мал-туардан соры кәҗәсе калды. Балалар бәхет эзләп читкә китеп беттеләр. Хәзер алар картлы-карчыклы шул соры кәҗә белән куанып яшиләр иде.

Бүген каравыл йортына килгәч, Җитәкче Җәләли бик озак кәҗәсен мактап утырды. Бригадир Шәйдуллин түзмәде:

— Җитәр инде, Җәләлетдин агай, шуны мактап торырга, кәҗә дә булдымы мал,— диде.

— Безнең кәҗәдә, иптәш Шәйдуллин, адәм акылы бар. Бөтен нәрсәне аңлый, бөтен нәрсәне белеп тора, түлке әйтә генә алмый. Шул кәҗәне Шәмәй авылына алып барыр өчен ат сорарга килгән идем.

— Син аны, нәрсә, утырмага илтми торгансыңдыр бит? — диде иптәш Шәйдуллин җитәкчеләр дорфалыгы белән.

— Тәкә сорый. Үлә инде мескен, түзәр хәле калмады.

— Караярда тәкә беткәнмени? — диде бригадир.— Әнә, сарык фермасында ат хәтлесе бар. Чын тәкә, исе биш чакрымнан борыныңа килеп бәрелә.

— Җиңгәчәң әллә ничә тапкыр илтеп карады. Санга сукмый. Өнәми кәҗәбез колхоз тәкәсен. Ул, мөртәт, шундый нәзберек, аңа тәкәнең солтаны булсын, башкага күз дә сирпеп карамый. Шәмәйдәге тәкә әрхәр нәселеннән, дип сөйлиләр. Җиңгәчәңнең шул тәкә янына алып барасы килә.

— Әрхәр дигәннәре поп түгелме соң аның? Патша заманында попларның зурырак урындагысын әрхәрәй дип йөртәләр иде шикелле,— диде Җәләлинең зарын тыңлап утырган Инсафетдин.

— Миңа ни, поп түгел чурт та ярый,— диде Җитәкче Җәләли.— Көне-төне акыра. Карчыгымның төн йокысы качты. Үземнең дә түзәр хәлем калмады. Җәлке бит, шул хәтле өзгәләнә, мескен.

— Юк, Җәләли абзый,— диде бригадир Шәйдуллин.— Колхоз тәкәсеннән борын чөйгән кәҗәне бригат атына утыртып күрше авылга җибәреп булмас. Без колхозчыларны гына түгел, малларны да колхозны уважать итәргә өйрәтергә тиешбез!

## 8

Март башында Әтәмби урамыннан берьюлы өч кешене — Житәкче Җәләлине, Инсафны, Шырый Исмәгыйлен алып киттеләр. Шушы вакыйгадан соң ирләр каравыл йортына җыелудан курка башладылар. Каравыл йорты бушап калды. Йомыш белән килгән чакта да ирләр бу куркыныч урыннан тизрәк чыгып таярга тырышалар иде. Монда сөйләнгән сүзләрне кемдер районга, кешеләрне төрмәгә озатып тору өчен куелган НКВД вәкилләренә җиткереп тора. Шик каравылчы Габделвәлигә төште. Ирләр аның сәламен алмый башладылар. Ирләре төрмәгә эләккәч тол калган хатыннар, урамда очратып, Габделвәлигә бәддога укыйлар, каргыйлар иде. Әйтерсең каравылчы йогышлы чир тарата. Хәзер аны читтән урап уза башладылар.

Габделвәли ялгыз яши иде. Карчыгы ачтан үлде. Бердәнбер малае гражданнар сугышында хәбәрсез югалды. Каравылга билгеләнгәч, Габделвәли йортын ташлап, бригада йортына бөтенләй күчеп килгән иде. Үз тормышы, гаиләсе, җылы оясы булмагач, картның бердәнбер юанычы каравыл йортына җыелган ирләргә сырышып, аларның гәпләшкәннәрен тыңлап утыру иде. Габделвәлине соңгы куанычыннан мәхрүм иттеләр.

Серләшәсе, зарын сөйләп бушанасы килгән чакларда Габделвәли карт атлар янына чыга. Атлар каравылчыдан шикләнмиләр. Бахбайлар аның сөйләгәнен дикъкать белән тыңлыйлар. Атлар да бит каравылчы карт хәлендә диярлек. Атларны, хуҗаларыннан аерып, бригада абзарына китереп яптылар. Мескеннәр, Габделвәли шикелле, алар да җылы сүзгә, кызгануга мохтаҗ.

Бүген дә, каравыл йортындагы ялгызлыктан качып, Габделвәли атлар янына чыкты, зарын сөйләргә кереште:

— Менә шулай. ...Шымчы иттеләр инде мине. Сез бит беләсез минем гөнаһсыз икәнлегемне. Беләсез бит, әйеме? Әллә инде, өрлеккә дилбегә асып, муенны элмәккә тыгаргамы?

Атлар, колакларын торгызып, бер тын тыңлап алалар да, салам чәйнәргә тотыналар. Габделвәли дәвам итә:

— Дөрес, аларга да авыр. Шушы кышны гына Әтәмби урамыннан унсигез ирне алып киттеләр. Кем белә, бәлки аларның инде берсе дә исән түгелдер? Унсигез хатын тол калды. Ә балалар? Аларның ни гөнаһлары бар? Ирләрнең дә гөнаһлары юк. Мин бит аларның нәрсә сөйләгәннәрен гел тыңлап утырдым. Алар бит бер генә тапкыр да хөкүмәткә тел тигермәделәр.

Тышта буран улый, үкерә. Атлар тыңлыйлар. Каравылчыга җавап кирәк. Атлар аңа җавап бирә алмыйлар. Атлар түгел, кешеләр дә җавап таба алмый бу эшләргә. Нәрсә булды бу дөньяга?

Буран аша үтеп, Габделвәли каравыл йортына керде, чишенде, мич башына менеп ятты. Торбада җил улый, тол калган хатыннар шикелле үксеп елый. Әнә җилнең шашынып улавында да нахак яла тавышлары ишетелә. Җил дә минем гөнаһсыз икәнемне белми микәнни, дип уйлады каравылчы.

Инде төн уртасы узып китте. Йокы һаман килми. Йокы да аны гаепле саный микәнни? Инде менә атнага якын аның йокы күргәне юк. Аны шымчы иттеләр. Хәзер аны кешегә дә санамый башладылар. Соң бит аллаһы тәгалә аның гөнаһсыз булуын белергә тиеш. Каравылчы беренче әтәчләргә кадәр буран елаганын тыңлап, шушы хакта уйлап ятты.

— Тукта әле,— диде ул урыныннан күтәрелә төшеп.— Ни йомыш белән иптәш Шәйдуллин районга барып йөрде? Ул бит персидәтел түгел. Алар бит районга персидәтелләрне генә чакыралар. Бригадирның анда ни эше калган? Ул нигә, атын манма тиргә батырып, атна саен Баулыга чаба? Иртәгә сорарга кирәк. Монда килеп керү белән, әйт әле, иптәш Шәйдуллин, син нинди йомыш белән атна саен районга барып йөрисең, дип күзенә туп-туры карап әйтергә кирәк.

Юк, Габделвәли картның иртәгә кадәр түзәр хәле калмаган иде. Таң атканны көтә башласам, шушы хурлыкка, шушы газапларга түзә алмый үләрмен дип курыкты ул. Хәзер үк йокысыннан уятып сорарга кирәк. Хәзер үк. Каравылчы ашыгып мич башыннан төшә башлады.

Каравылга куйган чакта миңа мылтык биргәннәр иде бит, дип уйлады Габделвәли урамга чыккач. Мылтык һәм өч патрон. Малай-шалай кулына эләгүдән куркып, Габделвәли мылтыгын өенә кайтарып, чормага яшергән иде. Ул туры өенә юнәлде. Ишеген кар басып киткән. Каравыл йортына кайтып күрәк алып килергә туры килде. Мылтык урынында иде. Чүпрәккә төргән патроннарны да капшап тапты Габделвәли.

Ярый әле мылтык искә төште, дип куанып куйды каравылчы. Мылтык тотып бармасам, йөрмә кеше көлдереп, дип куып җибәрер иде. Хәзер менә куркытырга була. Мылтык түтәсе белән юлны капшап, буранга каршы Габделвәли бригадирның йортына таба юл тотты.

Габделвәлинең каравыл йортыннан чыкмыйча яшәвенә инде күпме булды икән? Кара әле, Шәйдуллин ихатасын ничек ныгыткан. Такта койма. Урыс капка ясатып җибәргән. Габделвәли капка биген бик озак ача алмыйча азапланды.

Өе суынмасын өчен, бригадир нигезенә калын итеп кар өйгән. Кар өеме аша үрелеп, каравылчы тәрәзә капкачын ачты, йодрыгы белән рамга сугып, тәрәзәгә кагарга тотынды.

— Кем ул? — диде бригадир ачулы тавыш белән.

— Бу мин, каравылчы Габделвәли. Чык әле, әйтәсе сүзем бар.

— Нинди сүз ул төн уртасында? Пашул, ишәк!

Габделвәли тагын тәрәзәгә кагарга кереште:

— Иптәш Шәйдуллин...

— Китмәдеңмени әле, корчаңгы ишәк? Ут капмагандыр бит төн уртасында бимазалап йөрергә?

Габделвәли ялганлый белми иде. Ул бер тын икеләнеп торды. Юк, бу юлы ялгансыз берни эшләп булмас.

— Ут чыкты,— диде каравылчы.

— Дурак! Нигә шундук әйтмәдең аны? Каравыл йорты янамы?

Ялган сүз картны шул кадәр тетрәндерде, ул башка бер сүз дә өсти алмады.

— Утны син үзең чыгардыңмы? — диде Шәйдуллин ишектән чыгу белән.

Каравылчы аны янынннан уздырып җибәрде. Алар икәүләп капкадан чыктылар. Урамга чыгу белән Габделвәли бригадирга мылтык төзәде:

— Иманыңны китер!

— Син... Син нәрсә эшлисең?! — Шәйдуллин каравылчыга таба килә башлады.

— Иманыңны укы, атам! — Габделвәли шатырдатып мылтыгын корды.— Синме җиттең унсигез ирнең башына?

— Син... Син нәрсә?! Бригадирдан сорау алырга сиңа кем хокук бирде?

— Унсигез ирнең башына син җиттең! Күпме баланы ятим калдырдың син, ничә хатынны тол иттең. Атла диләр сиңа, ишетәсеңме?!

Шәйдуллинның буыннары йомшарып китте:

— Син, Габделвәли абзый, белмисең... Без — хөкүмәт кешеләре. Миңа бармак тигерсәң дә, сине аталар. Тияргә ярамый миңа.

— Күпме кешенең башына җиттең син, Иблис! Күпме яшь койдың?

Каравылчының сүзен раслаган шикелле, җил бригадирның өстенә кар томыра иде. Юк, курыкмый бу. Бәлки яхшылык белән әйткәнне аңлар?

— Габделвәли абзый, син мине җибәр. Мин бит үз иркемнән әләкләмәдем. Бригадирлыкка куйганда, колхозчыларның һәр сүзен тиешле җиргә җиткереп торырга тиеш син, дип аңлаттылар. Аның законы шулай, диделәр. Мин ышандым.

— Атла диләр сиңа! Мин сине халык җыелганчы каравыл йортына ябып тотам. Колхозчыларның үзләренә аңлатырсың.

Сыер дуласа аттан яман, диләр. Атачак бу. Качып котылмасам, үтерәчәк, дип уйлады Шәйдуллин. Үтерә бу мине. Йөгерергә кирәк. Бригадир, бар көчен җыеп, буран эченә ташланды. Габделвәли караңгылык йота башлаган шәүләгә төзәп тәтегә басты. Шартламады мылтык. Тукта әле, диде каравылчы, аны бит корырга кирәктер. Кызганычка каршы, Габделвәли мылтык кора белми иде.

Икенче көнне, кичкә таба, ике кораллы кеше Габделвәлине районга алып киттеләр.

*1989 ел. Мәскәү.*

## Рафис Гыйззәтуллин

# СИРТМӘЛЕ КОЕ



Коены... үзебезнең туган нигезебезне барып күрәсем килә...

Урын өстендә яткан карчыгының сүзләрен ишеткәч, үз уйларына чумып утырган Сәләхи сискәнеп куйды. Әрчисе бәрәңгесе кулыннан шуып чыкты да, идәнгә төшеп, сәке астына ук тәгәрәде. Әмма карт моңа игътибар итмәде.

— Барырбыз, анасы... Барырбыз... Тик менә аягыңа гына бас, — дигән юату сүзләре әйтергә ашыкты. — Менә тагын берне генә әрчим дә пешерергә куям. Ашап алгач, хәл дә кереп китәр...

Үзе шулай диде, ә үзе сулы савытка күз төшереп алды.

«Нигез, кое... — дип уйлады ул, карчыгы ягына борылып карый-карый. — Соңгы көннәрдә еш кабатлый башлады әле аларны. Йокы аралаш саташкан кебек...»

Сәләхи карт белә: авылдагы әлеге бердәнбер коены Бәдрикамалның әтисе, аңа бабай булырга тиешле Харис карт казыган. Ләкин ул нигез, ул кое инде күптән, бик күптәннән аларныкы түгел...

Бәдрикамал карчык озаклап, буыла-буыла ютәлләргә кереште, тына төшкәч, гыж-гыж килеп, теге сүзен кабатлады:

— Нигезебезне... үзебезнең туган нигезебезне барып күрәсем килә.

Почмак яктан карчыкның янә шул сүзләре ишетелгәч, Сәләхи карт, ярар җитеп торыр булмаса дип, бәрәңге әрчүеннән туктады, кулындагысын сулы савытка чупылдатып ташлады да корткасының уйларын читкә юнәлтергә теләпме:

— Хәзер, анасы, хәзер пешеп тә чыгар... Ашарбыз утырып... — диде. Аннан соң, бераз уйлап торгач өстәде: — Барырбыз анысы, хәлеңнән килсә, — диде.

Бераздан алар, бер-берсенә тотынышып, җан әсәре сизелмәгән озын, тар урамга чыгып бастылар. Озын-озак уйлап тормыйча, тәвәккәлләп, югары очка таба атлап киттеләр. Бәдрикамалны туган нигезе, әтисе төсе булган кое алга әйдәсә, Сәләхи картны, өйләреннән ераклашкан саен, бер уй талкыды: «Ничекләр генә гомер бакый атлап кермәгән капканы шакырлар да, үзләренең нинди гозер белән йөрүләрен ничек тел әйләндереп әйтерләр?»

Атлый торгач, ниһаять, килеп җиттеләр коелы йортка. Тимер баганалы биек, киң урыс капка янында тукталып, атлап керергә кыймый бераз басып тордылар.

Кемдер урам якка — капкага таба килә, ахрысы. Ялгышмаганнар икән. Келә зыңлап тартылуга, зәңгәргә буялган капканың кече ишеге ачылып китте. Аннан иң әлек ялан аяклы кечкенә малай атылып чыкты. Аның артыннан ук иңнәренә чиләк-коянтә салган яшь хатын күренде. Ул үзләренең капка төпләрендә карачкы кебек басып торучы карт белән карчыкны күреп, бермәлгә аптырап калды. Йөзендә гаҗәпсенү, курку, уңайсызлану катыш билгеләр уйнаклап алды.

Буш чиләкләргә карап өнсез калган карт белән карчык, яхшыга булмас бу дип, кире борылып китмәкче дә иделәр инде, әмма Сәләхи карт теленнән сүзе чыгып очуын сизми калды:

— Без сезгә идек бит, килен...

— Соң алайса... әйдәгез, узыгыз, — диде яшь хатын (чыннан да, ул бу

---

**РАФИС** Гыйззәтуллин *(1955) — прозаик. «Очучы буласым килә», «Урман юлы» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

йортка килен булып төшкән иде). — Әти өйдә, йомышыгыз андадыр, шәт!

Һәм ул, бер читкә тайпылып, көтелмәгән кунакларга юл бирде. Әшне болайга җибәрәсе килмәгән карт гозерен әйтергә ашыкты:

— Килен, әйдә, без өлкәннәрне борчып тормыйк инде, — диде. — Минә карчыгым сүзе белән йөрүебез. Шушы нигезне, коены күрәсе килде аның...

Килен кешенең гаҗәпләнүе бу юлы инде читтән ашты. Ул карт белән карчыкка янә сәерсенеп бер караш ташлады. Моңа каршы Сәләхи карт: «Бәдрикамал әбиеңнең балачагы шушында үткән, кызым», — дип, акланырлык сүзләр тезде.

Килен акыллы бала иде: авызын ачып сүз әйтмәде, төпченеп тормады. Борылды да кире ишегалдына кереп китте, теге юеш борын да әнисе артыннан чабулады. Карт белән карчык алар артыннан иярделәр.

Әйе, бу инде кайчандыр Бәдрикамал яшәгән ихата төсле түгел иде. Әмма барыбер монда алар көн иткән нигезенең ташлары ята.

Карчык ишегалдыннан таныш чалымнар табарга азапланып тирә-юньне күзәтте, ә картның күзләре әлеге дә баягы сиртмәле коега төбәлде. Бәдрикамалы кайта-кайта сөйләгән, соңгы вакытта саташып яши торган кое ишегалдының түрендә — бакча ышыгында бура-муенын кукрайтып утыра.

Килен бөтен ишегалдын карашы белән капшап чыгучы карчыкка, коега мөкиббән китеп торучы картка карап: «Аңламассың бу өлкәннәрне», — дип уйлады һәм, аларның үзләрен генә калдырып, өенә кереп китте.

— Ә без кое суын эчмибез, бабай аны малларга гына бирергә куша,— диде карт янында басып калган малай. Бәдрикамалы ишеттеме-юкмы, Сәләхи карт болдырдан килүче тавыштан сагая калды. Моңа кадәр ничек чыкмый түзеп торгандыр, йорт хуҗасы Хәбиб килененнән сорау ала иде:

— Ни калган аларга монда?

Аңа каршы килененең йомшак тавышы ишетелде:

— Карчыгы авырый икән. Туган нигезе белән бәхилләшик, дип килгәннәр.

— Туган нигез... Һе!.. Кара син аны! Теге ни... китәр вакыты җиткәч кенә... онытмаган, димәк!

Ул да булмады, болдыр ишеген төртеп ачып, җиңелчә киенгән Хәбиб карт үзе дә чыгып басты.

Көтелмәгән кунакларны карашы белән сөзеп егардай, таптап үтәрдәй караучы Хәбибкә беренче булып Сәләхи карт эндәште:

— Син... кем (ул аңа кем дип тә эндәшергә белмәде) безгә рөхсәтеңне бир инде, яме? Ни бит... минә карчыгымның үз нигезләрен, коеларын күрәсе килде. Комачау ясамый гына урап чыксын, кое янында бераз утырып хәл алсын инде. Ни дисәң дә балачагы узган җир бит.

Хәбиб, бу сүзләрне ишетсә дә, җавап кайтармады. Аның кысыла төшкән усал күзләре бетәшкән, ябыгудан кечерәеп калган Бәдрикамал карчыкны бораулый иде. Ул аның сүз башлавын көтте. Менә-менә ничә еллар күңелендә йөрткән каргышын әйтеп бирәчәк кебек тоелды аңа җаны чыгарга җиткән карчык. «Нигез, кое сылтау гына моның өчен. Теге дөньяга китеп барганчы барысын да әйтеп калыйм дип торган бу үлем түшәгеннән»,— дип уйлады.

Әмма, ни гаҗәп, Бәдрикамал карчык ни дә булса әйтергә җыенмый иде. Ничә еллар узып та моңа кадәр бер генә тапкыр да аяк атлап кермәгән бу ишегалдына узгач, аның бөтен күңелен әйтеп тә, сөйләп тә, аңлатып та булмастай сагыш, моң басып алды. Ул томаланган күзләре белән ишегалды түрендә моңаеп утыручы коега карады, аякларын сөйрәп шунда таба атлады.

Тәбәнәк рәшәткә белән әйләндереп алынган кое янына килеп җиткәч, туктады. Карты кармаланып ачкан кечкенә капкадан эчкә узды. Коеның өсте ябулы һәм ул йозакта иде.

— Ачасы иде,— дип эндәште ул хәлсез тавышы белән үзеннән бер адым да калмый атлап йөрүче картына. Тегесе исә үзләренең һәр хәрәкәтен күзәтеп торучы Хәбиб картка борылып, сүз катты:

— Капкачын ачарга иде!

Хәбиб карт урыныннан кузгалмады, бары тавышын күтәрә төшеп кычкырды гына:

— Әй, килен, сиңа әйтәм, китер әле ачкычын!

Авыру карчыкның: «Нигезебезне күрәсем килде»,— дип килүе табигый бер нәрсә анысы. Килен кеше бераздан моны шулай кабул да итте. Итәгеннән тарткалап: «Әни, әни, безнең коега берәр нәрсә булганмы әллә?!.» — дип сораштырган малай да тора-бара соравын кабатлаудан туктады, ишегалдын бер итеп уйнарга керешге. Әмма Хәбиб карт кына... бу хәлгә тыныч карый ал-

мады. Моңа кадәр өендә җай гына картлыгын үткәреп ятучы Хәбибкә шактый тәэсир итте бу. Сәбәбе-сылтавы булмаса да, ул ишегалдында әрле-бирле йөренә башлады. Үзе әледән-әле чакырылмаган кунакларга күз төшереп ала. Ә чынлыкта исә искә төшерер, уйланыр нәрсәләре байтак иде аның. Күбесе еллар узу белән төссезләнеп калган булсалар да, әле исендә калганнары да байтак, алар барысы да, телисеңме-юкмы, барыбер шушы сиртмәле кое тирәсенә килеп укмашалар...

Утызынчы еллар башы иде. Авылда төрле имеш-мимешләр китте. Халык телендә моңа кадәр ишетелмәгән хикмәтле сүзләр йөри башлады. Янәсе, бөтен авыл халкын бергә туплаячаклар да бергә яшәтә башлаячаклар, күмәкләшеп эшләтәчәкләр, шулай яшәү колхоз буласы, ди. Һәркем өендәге бар нәрсәсен җыйнап, шул колхоз буласы урынга илтеп тапшырырга тиеш икән.

Бу хәбәрләр берәүләрне пошаманга салды, кайгыга калдырды. Соң шулай булмыйча, бар карап торганыңны — атыңны үзең җитәкләп колхозга илтеп бир әле син!

Кемнәрнедер кара кайгыга батырган ул хәбәрләр Хәбибнең әтисенә — Вәли картка кагылмады. Ни дисәң дә, аларның абзарында тыпырдап торган ат юк, җирне тартып алырлар дип тә хафаланырга кирәкми. Әллә инде уңдырышлыгы беткән шунда, әллә белеп эшкәртмиләр, менә ничә ел кинәнерлек уңыш ала алмыйлар. «Булуга караганда булмавы хәерле ул дисәтинәнең»,— ди әтисе.

«Колхоз», «күмәк хуҗалык» дигән сүзләр телдә ешрак кабатланган саен, Хәбибнең әтисе сөенә генә. Эчендәге шатлыгын тышка да чыгара, улының ялтыр башыннан, тишек күлмәгеннән күренеп торучы иңбашына кагып: «Колхоз дигәннәре генә булсын, барысы да рәтләнер...» — ди.

Кечкенә Хәбибнең күңеленә колхоз иң элек — өстен-башын бөтенәйтәчәк, ач тамагын туендырачак бер нәрсә булып кергән иде. Кайдандыр читтән килеп колхоз ясап йөрүче агайларга ияргән әтисе белән әле тегеңә, әле моңа кереп-чыгып йөри торгач, малай башкасын да аңлады. Колхоз төзүчеләр кереп-чыккан өйләрдән чыр-чу, елаш-каргыш ишетелгәч төшенде моңа Хәбиб. Колхоз дигәннәре әле сине киендергәнче, тамагыңны тук иткәнче, башта кемнәрнедер чишендерергә тиеш икән...

Колхоз оештыру авылның астын-өскә әйләндереп ташлады. Әллә кайдан килгән, билләренә каеш таккан абыйлар беркемнең дә ай-ваена карамыйча капкадан бәреп керәләр дә абзардагы сыерыңны җитәкләп алып чыгып китәләр, атыңа тышау салалар.

Берчак ул шулай, әтисенә ияреп, түбән оч Мисбахларга барды. Ә кичен генә әтисе Мисбахның атын бирмәскә җан талашуын кайтып сөйләгән иде.

— Алабыз барыбер...— диде кырын ятып тәмәке төтәтүче әтисе.— Күреп торырсыз...

Өч-дүрт хәрбигә ияргән әтисе һәм тагын кемнәрдер бергәләшеп төшкәч, җитәкләп чыктылар шул кашка бияне. Аның артыннан гаиләнең бар кешесе урамга сибелде. Ана кеше елаудан шешенеп беткән, ул бар дөньяны каргый, куркышып итәгенә сарылган эреле-ваклы балаларын күкрәгенә кыса, талаучыларга шуларның күз яшьләре белән ләгънәт укый. Йорт хуҗасы Мисбах агай, чарасыз калып, урынында басып тора. Куллары хәлсезләнеп салынып төшкән. Атын бирмәскә теләп бу юлы да карышкан, атының муенына барып асылынган иде дә... Ишегалдына хуҗа булып алган өч-дүрт кеше алдында көчсез иде ул. Арадан берсе билендәге алтатарын суырып чыгарды да маңгаена терәп кычкырды:

— Син нәрсә, контр, совет влачена каршымы, башыңның зинданда черүен телисеңме?!

Хәбиб карт шуларны уйланып ишегалдында йөренә, җанында — зил-зилә. Ничә еллардан соң хәзер әнә шул эшләрнең бик үк дөрес булмавын сөйләнә башладылар. Дөрес булмаган, имеш. Башта нәрсә уйлаганнар? Күпме еллар әтисе белән горурланып яшәде бит ул. Мәрхүм әтисе Вәли картның сурәте колхоз идарәсе каршында эленеп торды. Колхоз төзүче кеше, дип, җыелыш саен мактап телгә алдылар үзен. Ә хәзер... беркөнне күрде Хәбиб: әтисенең рәсемен кемдер йолкып алган.

Килене каенатаеның кинәт кенә үзгәреп китүенә игътибар итми калмады. Тик моны нәрсәгә юрарга гына белмәде. Бабасының сәерләнеп китүенә оныгы да битараф түгел икән.

— Бабай, нәрсә эзлисең син? Ишегалды буйлап нишләп йөрисең?— диде.

— Аяк астында чуалмале...— диган төксе сүзен ишеткәч, читкә китеп, үз уенына бирелде.

Хәбиб картның ачылып киткән хәтере әле дә булса узган еллар офыгында бөтерелә иде.

Әтисе теге чакны дөрес әйткән булган. Колхоз дигәннәре алар йортына акрынлап җылылык китерә, кот кертә башлады. Моңа кадәр хәерчелектә көн күргән, «Ялкау Вәли» дигән кушаматы чыккан әтисе белән элеккеге кебек сөйләшмиләр иде инде. Күзгә карап авылның абруйлы кешесенә әверелде ул. Аның белән санлашалар, сүзенә колак салалар, тыңлыйлар.

Бер сүтелә башласа, хәтер йомгагын тиз генә йөгәнләрмен димә. Хәбиб карт та, уйларыннан арынырга, үзен тынычлыкта калдырырга теләсә дә, булдыра алмады. Җитмәсә, кара инде — килене баядан бирле Сәләхи карт белән Бәдрикамал карчык янында басып тора.

Каенатаеның тамак кыруын ишетеп, килен сискәнеп куйды. Шушы йортка күрше авылдан төшкәннән бирле белә ул: тамак кырдымы, аның тирәсеннән ераграк кит инде син, юкса... Ул шулай эшләде дә — картларның үзләрен генә калдырып, иңенә чиләк-көянтәсен асып, суга чыгып китте.

Бәдрикамал гына боларның берсенә дә игътибар итмәде. Аның үз уе, үз дөньясы иде. Ул, кое янына җайлап кына урнашты да, мәңге дә кире кайтарып булмаячак бала чагына юл тотты, шушы нигез, шушы кое тирәсенә барып укмашкан хәтер очын сүтә башлады.

...Әнә ул, унбер-унике яшьлек кыз бала, иңенә чиләк-көянтә асып судан кайтып килә. Көянтәсе иңнәрен ярып ук кергән. Авыртуын басар өчен әле тегеләй, әле болай күчереп тә карый, юкса. Атлаган саен, чиләге чайпалып, суы ялан аякларын пешерүче кайнар туфракка түгелә. Их, чишмә ерак шул.

Читән буенда кычыткан урып йөрүче әтисе дә күреп алган икән кызын. Бөгелә-сыгыла кайтып килүче Бәдрикамал каршына килә әнә. Суы яртылаш кына калган чиләкләрен үз кулына ала.

— Әти, әти,— дип сөйләнә-сөйләнә, кыз аның артыннан иярде.— Әйдә, кое казыйбыз, суны шуннан гына алыр идек.

Дөньяларда юктыр мондый яхшы әти. Күр инде син аны, кызының сүзен күтәреп алды:

— Ә нигә казымаска, казыйбыз!— ди бит.

Иртәгәсен уянып, ишегалдына чыкса, ни күрсен, әтисе кое казырга керешкән, әнисе дә аның янында. Бәдрикамал үзе дә аларга булышмакчы иде дә, әнисе эш тапты.

— Энең Халикъны кара, аңа күз-колак бул,— диде.

Күптән түгел генә тәпи йөри башлаган энесен бәләкәй арбага утыртып тартып йөргәндә дә телендә кое булды кызның.

— Беләсеңме, энем, тиздән суга дип еракка бармаячакбыз. Күрәсеңме, әти кое казый әнә, кое! Суны шуннан гына алачакбыз. Күр әнә, кара, әти ничек тирән казыган инде,— дип сөйләнде.

Тирәнрәк төшкән саен, кое казуның авырлаша баруын да күрде кыз. Әтисе астан бауга бәйләнгән чиләккә тутырып үзле балчык биреп тора, әнисе читкә алып китеп бушата да кире аска төшерә.

Ничә көнгә сузылгандыр инде кое казулары, әмма очы да, кырые да күренми әле. Ә бер көнне түбәннән әтисенең шатлыклы тавышы ишетелде.

— Су! Су чыкты! Су!..

Бәдрикамал, аңа ияреп энесе Халикъ, бөтен дөнья ишетерлек итеп шатланып кычкырып җибәрделәр. Бер урында сикергәләп, шул ук сүзләрне кабатладылар:

— Су чыкты! Су! Безнең коебыз бар!

Әтиләренең тирләп-пешеп, кызыл балчыкка буялып коедан чыгып килүләрен күргәч кенә чыр-чу килүдән тукталып калдылар. Кызга уңайсыз да булып китте. Аның сүзен тыңлап интекте ич инде әтиләре. Әмма әтисенең үз эшеннән бик тә канәгать булуын күргәч, ул бу халәтеннән арынды. Әтиләренең йөзендәге елмаю әнисенә, аның тирәсендә бөтерелүче балаларга да күчеп өлгерде.

— Коебызның суы беркайчан да кипмәсен,— диде әтиләре.

Коены кое итү өчен аннан соң да шактый тырышырга туры килде. Бәләкәй арба тартып тау итәгенә күп тапкырлар барырга, аннан ташлар җыйнап, сөйрәп кайтырга кирәк булды. Кое эчен шул ташлар белән әйләндереп алгач, буралап куйганнан соң, сиртмә куйды әтиләре. Шуннан соң гына чын коега әйләнде ул. Ишегалдына үзгә бер ямь биреп, йортка хезмәт итә башлады. Бәд-

рикамал да, энисе дә коянтә асып ерак чишмәгә йөрми хәзер. Өйдән генә чыгасың да, коены ачып, сиртмәгә бәйләнгән озын баулы чиләкне аска төшереп җибәрәсең. Күпме кирәк ал көмеш суын, туйганчы эч, кош-кортлар алдына куй, кояшта җылытып, бакчадагы яшелчәләргә сип. Тора-бара күрше-күләннәргә дә хезмәт итә башлады кое. Кергән бере, мең рәхмәтләр укый-укый, коянтә-коянтә су алып чыгып китә.

Беркөнне ихатага Вәли килеп керде. Аны күргәч, Бәдрикамал курка калды. Яратмый шул бәндәне кыз. Аның кешеләр белән тупас-дорфа сөйләшүен күргәне булгангамы, әллә көпә-көндез, талап дигәндәй, җирән кашкаларын алып чыгып киткәннәре өченме?

Вәли, үзенә өнәмичә карап торган кызга астан гына ачулы караш ташлады да, лаштыр-лоштыр атлап, ишегалдын урап чыкты. Кое янына килеп җиткәч, тукталып калды. Капкачын ачып, беркавым аска карап торды һәм энесен үзенә сыендырып басып торучы кызга дәште:

— Эти-әниең кайда?!

— Басуга киттеләр, кичә үзегез ашлык җыярга барырга куштыгыз бит...— дияргә ашыкты кыз. Ачкүз Вәлинең тизрәк чыгып китүен тели иде ул.

Вәли әллә ишетте аның сүзен, әллә юк, күтәрелеп тә карамады. Ул әле дә булса, коеның тирәнлеген чамаларга теләгәндәй, түбәнгә текәлгән. Байтак торды ул шулай һәм, кинәт, черт иттереп коега төкерде дә, чыгу ягына таба атлады.

Кыз аның бу кыланышыннан хурланып кычкырып ук җибәрмәкче иде дә, иренен тешләп, тукталып калды. Вәли капкадан чыгып күздән югалуга, коелары янына йөгереп килде, ачык калган капкачын шапылдатып ябып куйды.

Кичен, эти-әнисе кырдан кайткач, кыз барысын да сөйләп бирмәкче булган иде дә, аларның арыган-талчыккан йөзләрен күреп, тынып калды. Әмма этисе дә, әнисе дә беләләр иде бугай көндезге хәлләрне. Этисе бигрәк тә. Килә дә баса кое янына, килә дә баса. Нидер уйлана, ахрысы, йодрыгы төйнәлгән үзенең.

Беркөнне кыз, эти-әнисенең сүзләрен ишетеп куркып калды. Гомергә булмаган хәл: этисе чыгырдан чыгардай булып ярсыган, йөзе ачулы. Үзе сөйләнә: «Кара син аны... Үзең колхозда исәпләнсәң дә күңелең анда түгел синең, дип бәйләнә Вәли. Илдә күмәкләшү өчен көрәш барганда мин аерым хуҗалык булып яшәргә омтылам, кое казыганмын, имеш...»

Әнисе аны тынычландырырга тырыша:

— Соң аларча, советча булсын. Күмик коены!— Ул да түгел, ачуын басарга теләпме, күрәген ала да койма буендагы кызыл балчыкка батыра. Әмма умырып алган балчыгын коега ыргытырга өлгерми, этисе аның юлына аркылы төшә:

— Юк, күммибез!

Аңышмыйча аларга карап торган кыз йөгереп килеп араларына керде.

— Юк, күммисез. Тимәгез коега!..— дип кычкырып җибәрде.

Ишегалдындагы шау-шудан куркыпмы, кечкенә Халикъ еларга керешге...

Бәдрикамал карчык, уйларыннан арынып, эчкә баткан күзләрен әрле-бирле йөрүче Хәбибкә төбәде. Теге чакта, шушы Хәбибнең этисе Вәли: «Сез аерым хуҗалык булып яшәргә омтыласыз!» — дип җаннарын ашап яшәгән көннәрдә коены күмеп куйган булсалар, эти-әнисенең язмышы да, Бәдрикамал белән Халикның да гомерләре болай булмас, әби-бабалары гомер иткән нигез дә тузгымас, аңа җиде ят кешеләр хуҗа булмас иде, бәлки. Бу хактагы уйларын Хәбибкә әйтсә дә килгән иде аның. Нинди дер көч аны тотып калды. Моңардан ни файда хәзер?!

Бәдрикамалның саңгыраулана башлаган колагында теге көннәрдә яңгыраган тавышлар аермачык булып янә кабатланды.

Күммәделәр коены. Ул, көмеш суы белән кинәндереп, яшәвен белде.

Һәр иртәдә эти-әнисе колхоз эшенә чыгып китә. Өйдәге бөтен эш Бәдрикамалга кала. Ул, коедан су алып, яшелчәләргә сибә, кош-кортларны ашата, энесен карый.

Эти-әнисе соң гына кайта. Кайталар да кызлары пешереп куйган ашамлыкны җылытып капкалыйлар һәм урын өстенә ауалар. Көнозын ишегалды белән йорт арасында йөреп арыган Бәдрикамал да, башы мендәргә тиюгә, изрәп китә.

Йокы аралаш, этисе белән әнисе сөйләшкәннәрне дә ишетеп ята кайчак.

— Тәмам каныга бит Вәли тәресе,— ди этисе,— кое дип теңкәгә тия...

— Күмик, сиңа әйтәм, коены.

Бер төнне ишек кактылар. Баштарак йодрык белән төйделәр, аннан аяк белән үк тибәргә керештеләр.

Һич нәрсә аңышмаган өйдәгеләр, куркышып, урыннарыннан сикерешеп тордылар. Кечкенә Халикъ кычкырып елап җибәрде.

Әтиләре күлмәк-ыштаннан гына болдырга чыгып китте. Озакламый үз артыннан нәрсәләргәдер абына-сөртенә атлаучы өч кешене ияртеп борылып та керде.

Төнге тынлыкны бозып йөрүчеләрнең берсе әлеге дә баягы шул Вәли мөртәт иде.

Кара шәүлә кебек керүчеләрдән берәү, каккан казык төсле, ишек төбендә басып калды. Икенчесе, күн итекләрен шыгыр-шыгыр китереп, идәнне тап-тап түргә узды, кулындагы яктырткычы белән почмакларны ялмап алды, сәке асларын капшап чыкты. Аннары йомшак тавыш белән:

— Гражданин Харрасов, җәһәт кенә булыгыз, киенегез! Сез безнең белән барасыз, сүзебез бар,— диде.

Моңа кадәр ни-нәрсә әйтергә белми басып торган әнисе йөгереп барып әтисе кочагына сарылды: аннан, җилтерәтеп Бәдрикамал белән Халикъны кулына алды да, ишеккә аркылы килеп басты.

— Тимәгез иремә! Кагылмагыз безгә!— дип җан ачысы белән кычкырып җибәрде.

Хәрбиләр мондый гына хәлләрне күп күргән, моңа күнегеп үк беткәннәр иде, ахрысы, өйдәгеләрнең кыланышына исләре китмәде. Йорт хуҗасын акрын киенүдә гаепләп, ашыктыруларын белделәр.

Вәли генә, аклангандай, сөйләнә бирде:

— Әйттем мин сезгә, әйттем. Бөтен илдә кумәк хуҗалык өчен көрәш барганда, сез аерым хуҗалык булып яшәргә омтыласыз, дидем. Күр инде син боларны. Башкаларга чишмә суы ярый, ә алар ишегалдына кое казыганнар. Яхшы хәл түгел бу. Элекке байларга охшарга тырышу дими ни дисең моны...

Тышта дөм караңгы иде. Барысы да шул караңгылыкка кереп батты. Шул караңгылыкны ертып, әтиләре авыз салды:

— Еламагыз, тиздән кайтырмын...

Таңга кадәр йокламый көттеләр аны. Күренмәде әтиләре, кайтармадылар. Күпме төннәр күз яшенә чыланып узды; таңнар туса, күзләре юлда иде.

— Сусадым бит озак йөреп, бирегез әле кое суы, эчим бер туйганчы!— дип кайтып керер кебек иде әтиләре. Ул төнге караңгылыкка кереп киткән җиреннән кире чыкмады, суга төшкәндәй юк булды.

Әниләре, балаларын ияртеп, ничәмә ничә тапкырлар Вәлиләргә барды.

— Кая куйдыгыз иремне? Кайтарыгыз!— дип тәкърарлады.

Вәлинең генә җавабы бер иде:

— Өстәгеләр үзләре белә. Бик күп йөрсәң, үзеңне дә аның янына алып китәрләр,— дип өркетте.— Бер сүзем җитәр...

Юк, озатуын озатмады Вәли әниләрен әтисе артыннан. Шулай да, бер көнне аның кереп килүен күргәч, куркышып калган иделәр.

— Иртәгә урман кисәргә барырга җыен,— диде Вәли төксе генә һәм, кое ягына карап алды да, нидер мыгырдана-мыгырдана чыгып китте.

Әнисе, хәлсезләнеп, өй баскычына килеп утырды.

— Әти кайта, әти коедан чыга...— дип сөйләнде кечкенә Халикъ. Әйтерсең лә, шулай дип әнисен тынычландырырга тырыша иде ул.

Соңгы көннәрдә, башына мондый уй каян килгәндер, әтисен гел коеда дип сөйләнә малай. Әллә инде Вәлинең коега каныгуын үзенчә аңлаган. Берничә тапкыр ачып та күрсәттеләр аңа коены. Әтисенең анда түгеллеген, каядыр һич белмәгән җиргә алып китүләрен әйттеләр. Юк, барыбер үзенекен итә. Әтисен коедан чыгар дип өмет итә малай...

Әниләре телгә килде.

— Кызым, син инде зур хәзер,— диде ул авыр сулап.— Минем таянычым. Үзең дә ишеттең. Иртәгә урман эшенә, диделәр. Энеңә күз-колак бул, кош-кортларны кара...

Иртәгәсен әниләре, таң беленер-беленмәс, эшкә чыгып китте. Бәдрикамал белән Халикъ ишегалдына аяк басканда кояш инде шактый күтәрелгән иде.

Кыз, әнисенең сүзләрен искә төшереп, ул әйткән эшләрне карарга керешә. Халикъның кулына әтисе ясап биргән уенчыкларны тоттырды. Энесе болдырда уйнап калды. Ул исә йөгерә-атлый тавыкларга җим салды, яшелчәләргә су сипте. Алары беткәч, өйгә кереп, идән-сәке юарга керешә. Инде ял итим дип ишегалдына — энесе янына чыкты.

— Халикъ, син кайда? Әйдә бергә уйныйк әле...

Әмма, ни гаҗәп, энесе урында юк иде. Уенчыклары бар, ә үзе күренми. Шаянланып качкан инде әллә?!

Бәдрикамал карчык ишегалдындагы тавышка сискәнеп китте. Гаҗәпсенеп, башын күтәрде. Бәй, ул әле дә булса чит-ят ишегалдында утыра икән ич. Аны өненә кайтаручы, уйларыннан аеручы кеше Хәбибнең оныгы — җирән чәчле малай икән. Әнә ул шукланып, кош-кортларны куып йөри. Кулында — чыбык. Бабасы туктарга кушып кычкырып та карый, тик кая ул. Бәйдән ычкынган малайның исендә дә юк. Ошамады бу Хәбиб картка, җаен туры китереп, эләктереп алды үзен. Эләктереп тә алды, зур-тупас куллары белән колагына да үрелде. Тагын да зәһәррәк чыелдап җибәрде малай, үрле-кырлы сикереп, бабасы кулыннан ычкынырга тырышты. Тарткалаша торгач, ычкынды да читкә йөгереп китте. Кара син аны, Бәдрикамал әбисе белән Сәләхи карт янына — кое ягына йөгерә бит. Моны күргәч, карчык агарынып китте, торып басмакчы булды, тик хәлсез аякларны аны тыңламады, ул кире урынына чүмәште. Малай исә якынлашып ук килә. Карчык кулларын җәеп җибәрде:

— Кое янына килергә ярамый!..

Моңа кадәр үзалдына уйланып утырган карчыкның әлеге кыланышын ишегалдындагыларның һәркайсы үзенчә аңлады. Бабасы тарафыннан рәнҗетелгән малай, кое янына менә килеп җитәм, менә җитәм дигән җиреннән тукталып, урам капкадан чыгып йөгерде. Оныгына кул селтәгән Хәбиб карт абзар эченә кереп китте. Янәшәсендәге карты исә Бәдрикамалының иңенә кагылды: «Әйдә, кайтыйк инде, өзлегерсең!» — дияргә ашыкты.

— Хәзер, хәзер...— диде карчык.

Теле шулай дисә дә, уе башкада иде аның. Ә күзләре... күзләре әле генә малай йөгереп чыгып киткән ачык капкада иде.

Теге чакта, эндәшеп-эндәшеп тә энесе Халикъ җавап бирмәгәч, ишегалдында да, бакчада да күренмәгәч, йөгереп урамга чыккан иде Бәдрикамал. Халикъ анда да юк. Коелып төшкән кыз йөгереп кире кереп китмәкче булган иде инде. Шулчак тыкрыктан җигүле ат чыгып килүен күреп, тукталып калды. Әтисе кайтмыймы икән?! Арбада кәпрәеп утырган Вәлине күреп, капыл гына тукталып калды. Йөзе агарган, чәчләре тузгыган кыз яныннан гына шыгыр-шыгыр килеп, арба узып китте. Вәли янәшәсендә аның улы Хәбиб утыра. Дилбегә аның кулында. Алар, кызга бер генә караш ташладылар да, гамьсез йөзләрен читкә бордылар.

Шул мәлдә кызның җанында нәрсәдер актарылып алды.

— Кое!— дип уйлады ул, үз-үзен белештермичә, атыла-бәрелә ишегалдына таба йөгерде.

Коега карагач, кыз акылдан шашар дәрәҗәгә җиткән иде. Аста — тирәндә — уч төбе кадәр генә күренгән кое төбендә аяк-кулларын җәеп җибәргән энесе ята. Ул йөзе белән өскә — апасына таба караган, күзләре ачык, авызы ачык.

Малай, әйтерсең лә, апасының куркудан ап-ак булган йөзен күреп, гаҗәпләнеп ята... «Эти, чыннан да, монда түгел икән»,— дип әйтер кебек үзе.

Кыз әлеге җансыз караштан өшәнеп китте һәм кычкыра-елый кире урамга ташланды. Анда бу юлы да җан әсәре күренмәде. Бары Вәлиләр утырган арба гына дыңгыр-дыңгыр килеп тәгәри бирә. Кыз, үз-үзен белештермичә, җанфәрман алар артыннан йөгерде. Кулларын бутый-бутый кычкырды:

— Анда... коеда... Халикъ энем! Туктагыз!?

Арбадагылар үзләре артыннан куа килүче сәер кызга карап-карап алдылар. Юк, тыңларга теләмәделәр. Вәли, янәшәсендә утырып баручы Хәбиб кулындагы дилбегәне болгап алды да, ат сыртына тамызды. Йокымсырап барган ат сискәнеп китте һәм куш аяклап чабарга кереште.

Сулуы капкан, хәлдән тайган кыз урам туфрагына капланды. Җирне тырный-тырный күпме үксегән булыр иде икән, иңендә кемнеңдер җылы кулын тоеп башын күтәрде Бәдрикамал. Һәм ул үзен уратып алган авыл картларын, карчыкларын, бала-чагаларны күрде. Кыз, сулык-сулык килеп, үзен юатырга омтылучыларга көч хәл белән энесенең коега егылып төшүен аңлата алды. Моны ишеткәч, авылдашлары дәррәү килеп ишегалдына йөгерделәр. Кемдер озын аркан табып китерде. Кайсысыдыр шуңа тотынып аска төшеп китте...

Уйларының очы да, кырые да күренми иде Бәдрикамал карчыкның. Тынычлыгын югалта башлаган картының:

— Әйдә инде, кайтыйк,— дигән сүзеннән торырга талпынды. Карты да ярдәм иткәч, аягына басты. Атлап китәр алдыннан да ул ишегалдында йөре-

нүче Хәбибкә дә, өй тәрәзәсеннән карап торучы киленгә дә игътибар итмәде. Ачык калган капкадан чыкты да, картының беләгенә тотынып, авыр адымнар белән килгән сукмагыннан өйләренә таба атлады. Юлда очраган авылдашларының кайсы гаҗәпләнеп, кайсы авыр көрсенеп калды. Инде аларның күбесе Бәдрикамал карчыкның нинди гозер белән йөргуен белеп тә өлгергән иде. Авырып урын өстендә яткан, үлемен көтеп яшәүче карчыкның кире торып үз туган нигезе белән хушлашырга баруын табигый бер нәрсә дип карыйлар. Бәдрикамалга, аның әти-әнисенә, әнисенә язмышның бик авыры, ачысы, катлаулысы эләкте. Әнисе Халикъ коега төшеп үлгән көнне үк икенче бер авыр кайгы көтеп торган иде Бәдрикамалны. Шул кичне әнисен кабык арбага салып алып кайттылар. Улының фаҗигасен дә белми-ишетми җан бирде ул. Соңыннан сөйләделәр Бәдрикамалга. Теге чакны, малае Хәбибне утыртып урамнан узган көнне, Вәли урман кисүчеләр янына барган. Юк-бар сәбәп табып бәйләнгән ул әнисенә. Аннан:

— Иреңне халык дошманы дип тапканнар әнә. Син үзең дә шуның сыңары...— дип җикеренгән.

Шул сүзләрдән күзләре караңгыланып, зиһене таралып киткәнме, ыжгырып ауган юан нарат агачы астына барып кергән, мескенкәй...

Әтисез дә, әнисез дә, әнесез дә калгач, кызны читтәге туганнары үзләренә алганнар иде. Озак та үтмәде, аларның нигезенә авылны кулында тотып яшәүче Вәли күченеп килде. Дистә еллар узып, Бәдрикамал ирен ияртеп авылга кайткач, югалган тынычлыклары әрәмгә булган иде: авылга кайтуга, җир алып, яңа нигез торгызган иде алар. Бөтен авыл булышкан иде үзләренә.

Дөрес, авылдашларының коелы йортта яшәүчеләргә нәфрәт белән каравын гел-гел сизә килде Вәлинекеләр. Кич булып урын өстенә яткач та шулар хакында уйланып ятты Хәбиб.

Хәер, бер үк йолдызлы күк астында ятучыларның һәркайсы үз уенда иде. Калган бәрәңгене җылытып ашаганнан соң мендәргә баш терткән Бәдрикамал карчык белән Сәләхи карт, тынычлана төшеп, көндезге хәлләрне уйларыннан үткәрделәр. Бабасы борып кызарткан колагын угалап чоланда ятучы теге шук-шаян малай Нәсих та үзенчә баш вата иде бу минутларда.

Әтисе дә, әнисе дә кое янына бармаска кушалар аңа. Бабасы бигрәк тә. Өстен гел бикләп тотарга куша. Онытылып ябылмый калган чакларда өйдә кара тавыш чыгара. Аякларын көч хәл белән сөйрәп килгән чит әби дә кое яныннан куды. Ә үзе аның янында күпме утырды. Нинди сере бар икән соң ишегалдындагы коеларының?

Шуларны уйлагач, тәмам йокысы качты малайның. Ул шым гына өй эченә колак салды: йокладылар микән әле? Тавыш-тын ишетелмәде. Бары бабасының гына ара-тирә көрсенгәне ишетелеп куйгалый.

Нәсих урыныннан торды, тавыш-тын чыгармаска тырышып, аяк очларына басып кына ишек янына килде. Ишегалдына чыгу, коеның серен белү теләге бөтен җанын биләп алды. Келәне сак кына күтәрүгә, ишек ачылып та китте. Җәйге төн тыныч, якты иде. Күк йөзе бихисап йолдызлар белән бизәлгән, алар уртасында, сиртмәле коега менеп кунаклаган сыман, ялгыз ай нурлана. Малай кое янына килеп басты, коеның капкачына үрелде. Көндезге шау-шу белән бикләргә онытканнармы, ул йозакта түгел иде. Малай сөенә-сөенә, аның капкачын күтәрде. Ни гаҗәп, әле генә күктә җемелдәшкән йолдызлар да, ай да коеда утыра. Моңа исе киткән малай, кое авызына тыккан башын югары күтәрмәкче иде дә, шулчак көтелмәгән хәл булды. Аягы таеп китте, башы очлы ташка бәрелде, күзеннән бөркелеп очкыннар чәчрәде. Ул нигә дә булса тотынып калмакчы булып кулларын бутады һәм, җан ачысы белән кычкыра-кычкыра, очы да кырые да юк сыман тоелган бушлыкка таба очты. Аның тавышына су чупылдаган авазлар килеп кушылды. Тик төнге тынлыкны ярып ишетелүче бу тавышның каян килүен тәгаен генә чамалап булмый: күктәнме ул, әллә җир астыннанмы? Озак та үтмәде, барысы да тынып калды. Күккә сибелгән эрелеваклы йолдызлар да, ай да, кара болытлар арасына кереп качкандай, эреп юкка чыкты...

## Зөлфәт Хәким

# «КОНТРА»

САТИРИК ХИКӘЯ




елны Җир шарында ике әһәмиятле вакыйга булды. Германиядә рейхстагка сайлаулар барган көннәрдә Чатырлы авылында юләр Сәлимҗан колхоздан чыкты. Бу ике сәяси акциядә, һичшиксез, ниндидер бәйләнеш барлыгын сизенгән ГПУ Чатырлы авылына контрреволюционерларны һәм шпионнарны ачыклауда каешланып беткән чекист Галәмшинне җибәрергә булды. Иң элек колхоз председателе Шәйхине чакыртып бик озак сөйләштеләр. Чатырлыга баргач, Галәмшин үзен яңа авыл, колхозлар һәм акты киләчәк турында роман язучы дип атарга тиеш була, ә Шәйхи аны юләр Сәлимҗанга фатирга кертә. Шулай итеп Галәмшин, Сәлимҗанда яшәп, аның Германия разведкасының Чатырлы авылында совет властена каршы көрәшеп ятучы агенты түгелме икәнен ачыклау эшенә керешә.

Хуҗа белән ул бик тиз уртак тел таба. Сәлимҗанга да кунак үзенең ягымлылыгы, акыллылыгы белән күңеленә бик хуш килә.

Әртилдән чыкканда Сәлимҗанга бердәнбер кәҗәсен кире бирмәскә булдылар. Шул ачудан ул берничә көн, сүгенеп, арлы-бирле кәрә-чыга йөрде. «Эһә, фашист партиясенең сайлауларда социал-демократларга караганда азрак тавыш җыюына эче поша моның, шуңа күрә үзен кая куярга белми,— дип уйлады Галәмшин.— Аңлыйм, бик аңлыйм хәлеңне, бандит...»

Ул, Сәлимҗанның бер хәреф тә танымавыннан файдаланып, романны яза башлыйм дигән булып, гаепләү материалларын тупларга кереште.

Кәҗәсен кызганып колхоз рәисе Шәйхине каргау Галәмшиннең кәгазьләрендә совет властен каһәрләү булып сурәтләнде. Урамда аерым хуҗалык иясе Зәйдулла белән тәмәке тартып, җыен юк-барны сөйләшеп торучы Сәлимҗанны үз ишләрен бер оешмага туплап, колхозларга каршы агитацияләүдә гаепләргә бик җайлы булып чыкты.

Ә беркөнне сәкедә юа ашап утырганда: «Әй, чукынсын сана кәҗәсе, ачтан үлмәм әле»,— дип ачы өзгәләнеп әйтүе — «Колхоз мал-туарының тизрәк үлеп, кырылып бетүен теле», дип, монысы да «романга» теркәлде.

Утыз яшьлек, тәбәнәк буйлы, чатан аяклы, җәенке борын һәм кысык күзле, чыраеннан миңгерәүлек катыш беркатлылык кычкырып торган, алла һәм НКВД колы булган Сәлимҗанның юри генә юләр булып кылануында Галәмшиннең иманы камил иде. Бик күпләрнең башына җиткән гпушникның баш миендә: «Бигрәк тәҗрибәле разведчик булып чыкты бу, кара ничек оста итеп юләргә сабыша, күр әле син аның осталыгын... Сволочь!.. Контра!..» — дигән уйлар көннән-көн тирәнрәк уелып килә иде. «Ничего, тиздән эләгерсең кармакка»,— дип, йорт хуҗасын төрле баш бутагыч сораулар белән «капшап» интектерә башлады. Ә тегесе исә, аны-моны уйламыйча, сөйләшеп утырырга кеше булган сөенечтән, дөньясын да, хәтта кәҗәсен дә онытып, теленә ни килде шуны сөйләп утырды.

Ләкин беркөнне аллаһы тәгалә ГПУ агенты Галәмшиннең мескен Сәлимҗанга каршы башлаган бу хәтәр эшен туктатырга исәп итте.

Сәлимҗан тозга һәм керосинга дип калага киткәч, Галәмшин ашыгаашыга өйне, каралты-кураны тентергә кереште. Сәлимҗанның бәхетсезлегенә каршы, утны-суны кичкән ГПУ агенты кар базына төшәргә маташканда, аягы баскычтан таеп китеп, башы белән баз төбенә төшә һәм шунда аның муены шартлап сына.

Дөньяда халыкара хәлләр кискенләшә барганда, илдә рәхимсез сыйн-

фый көрәш кайнаганда, халык дошманы Сәлимҗан бер куркусыз, рәхәтләнеп, калада йөргән чагында, җаны-тәне белән шул Сәлимҗан эше бандитларга каршы сугыш алып барган Галәмшин дөм караңгы, сасы кар базында геройларча һәлак була. Мәңгелек дан аңа!..

Ходай шуны белмәде микәнни: Галәмшиннең тормышына нокта кую — бичара Сәлимҗанны Кояш тирәли әйләнгән Җир шарына утырып йөрүче адәмнәр исемлегеннән сызып ташлау белән бер иде ләбаса... Моны тәңре генә түгел, хәтта Сәлимҗанның колхоз абзарында шыр сөяккә калган кәҗәсе дә аңларга тиеш иде. Чөнки сыйнфый көрәш бара!.. Коточкыч көрәш!..

Сәлимҗан өч көн үткәч кайтты. Авылда бер кеше дә юк — халык колхоз болынында печән чаба. Аның күңелен авылга кергәндә үк ниндидер шом баскан иде. Хәвеф-хәтәр киләсен ничектер сизенгән иде ул. Күршесе кылый Нуруллаңың эте дә бу юлы өреп-нитеп тормады, бер чинап алды да капка астыннан шуып кереп китте.

Сәлимҗан, күзләрен акайтып, арыш саламына охшаган чәчләрен үрә торгызып, болынга чапты. Тиргә баткан ертык күлмәгенең итәген бөгәрли-бөгәрли «язучы»ның базга егылып үлүен тотлыга-тотлыга аңлатып бирде.

Авылдашлары аңа ат җигеп бирделәр дә: «Бар, агайне, мәетне калага үзең илтеп тапшыр инде, милициягә илт»,— диделәр.

Сәлимҗан мәрхүм «язучы»ның башланган «роман»ын, шунда бергә милициягә тапшырырмын дип, бик әйбәтләп чүпрәккә төреп куенына тыкты да, мәет өстендә йөргән чебеннәрне куалап, атны калага чаптырды.

Аны озатып калган Шәйхи: «Халык дошманы булса да, начар кеше түгел иде инде бу Сәлимҗан»,— дип уйлап, авыр сулап куйды. Сәлимҗан белән кыямәт көненә кадәр бүтән очрашмасына шиге юк иде аның.

Председатель Шәйхи, Сәлимҗанның кәҗәсеннән шикләнеп, аны колхоз абзарыннан чыгарып җибәрергә булды. «Хуҗасын бик ярата иде... халык дошманы кәҗәсен колхоз маллары арасында тоту ярамас»,— дип уйлады ул.

Бер атнадан Чатырлыга хәбәр килде: юләр Сәлимҗанны төрмәгә утыртканнар.

Тик.көтмәгәндә, бер өч айдан соң Сәлимҗан, тешсез авызын ерып, бик зур эш майтарган кеше шикелле, чатан аяклары белән җил-җил атлап, Чатырлыга кайтып керде.

Тикшерү барышында (врачларга рәхмәт яусын инде) Сәлимҗанның диваналыгы шыр ярып кычкырып торганга күрә, эшне туктатырга мәҗбүр булдылар. Тумыштан ук бер җан иясен дә сөймәгән тикшерүче, бер килгәч буш кайтмасын инде дигән шикелле, Сәлимҗанның алгы тешләрен сугып койды да, «Бар, чүпрәк баш, күземә күренмә бүтән»,— дип аны кабинетыннан чыгарып ыргытты.

Сәлимҗан, урамга чыккач, тротуарда җыелып торган яңгыр суы белән авызын чайкады да, котылуына чиксез куанып, следовательгә эченнән генә рәхмәтләр укый-укый, туган авылына юл тотты.

Капкасы төбендә дөньядан ваз кичеп яткан газиз кәҗәсен күргәч, ул үзен иң бәхетле кеше итеп тойды.

Авылдашлары гына читләште Сәлимҗаннан. Аерым хуҗалык Зәйдулла да аның белән тәмәке тартып, дөнья хәлләрен сөйләшеп утырудан баш тартты. Бердәнбер иптәше, сердәше булып кәҗәсе генә калды. Өч ай төрмәдә ятып ниләр күргәнен, тикшерүченең ничек сорау алганнарын — барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирә иде үзенең бердәнбер якын җан иясенә. Тик кәҗә генә, коточкыч заманда яшәвен аңлап булса кирәк, хуҗасы сөйләгәндә, сакалын селкетә-селкетә, башын читкә бора иде. Ишетмәмешкә салына янәсе, политикага тыгылмый.

Кыш көне кәҗә вафат булды. Карт та түгел иде югыйсә. Колхоз абзарында бер-бер чир эләктергән булды микән, әллә инде хуҗасы «халык дошманы» булудан гарьләнеп, протест белдерүе булды микән — аның шулай кинәт үлеп китүенең сәбәбе турында тарих архивларында бер мәгълүмат та сакланмаган.

Гомерендә беренче тапкыр шулай ачы итеп елады Сәлимҗан. Базында ГПУ агентының мәетен тапкач та бу кадәре кызгану хисе кабынмаган иде аның күңелендә.

Шул ук көнне каладагы ГПУ бүлегенә председатель Шәйхи тарафыннан менә мондый кәгазь җибәрелде:

«Юләр дип төрмәдән азат ителгән Гыйләҗев Сәлимҗан Мотыйк улы

Совет властена каршы көрәшен дәвам итә. 24 декабрь көнне, 5 ай колхоз абзарында яшәгәне өчен, Совет властена ачу итеп, кәҗәсен үтерде».

Сәлимҗан кәҗәсен бакча артында күмеп йөргән вакытта бу донос теге теш коярга ярата торган тикшерүчегә барып эләгә. Тик, күрәсең, ходайның кәефе күтәренке вакыт булгандыр инде — следователь исемен йөртүче бәндә шул көнне кулга алына һәм, халык дошманы дип, планетаның Лена елгасы Төньяк Боз океанына тоташкан районына олактырыла. Ә Сәлимҗан өстеннән килгән кәгазь иксез-чиксез доносләр, жалобалар, протоколлар арасында югала. Бүгенге көнгә кадәр ул документның күзгә чалынганы юк әле.

Сәлимҗан гына тормыш ыгы-зыгысында, җирнең миллиардлаган халкы арасында һич тә югалмый,— политик вакыйгаларның үзәгенә эләгеп, күзәтү астында кала.

Туры килеп торуын кара әле син аның... 1938 елны, Троцкий эмиграциядә IV Интернационалны оештырып маташкан көннәрдә, Сәлимҗан өч көн рәттән Мукшы күленнән беләк буе сазаннар тотып алып кайта. Кәеф яхшы, авыз ерык, сөенә-сөенә кайта да, балыкларын киптерергә элеп куя.

Председатель Шәйхинең төн йокылары качты. «Нәрсәгә сөенә икән бу, нәрсәгә әзерләнә икән?» — дигән уй аның җанын ашады.

Кипкән балыкларын Кала базарына сатарга дип барганда, урманны чыккач, Сәлимҗанны кулга алдылар.

Таныш бүлмә... Следователь генә икенче. Монысы яшьрәк, тик тегесеннән дә явызрак күренә. Сорау алу алай бик озакка сузылмады.

— Бу балыкларыңны кая алып бара идең?..

Табигатьтән йомшак булган Сәлимҗанны көтмәгәндә балыксыз калу бик тә рәнҗеткән иде. Кинәт ул, җәенке борынының тишекләрен тагын да киңәйтебрәк, утырган урындыгыннан сикереп торды да, ярсудан акайган күзләрен тикшерүченең итләч чыраена кадап, мәрхүм кәҗәсенең кычкыруына охшаган тавыш белән акырып җибәрде:

— Кая алып барсам да бер түгелмени?.. Анда синең ни эшең бар?.. Минем балык бит ул!..

Тикшерүчегә барысы да аңлашылды, аның башка сораулары булмады. Сәлимҗан кычкырганда чәчрәгән селәгәйләрен күлмәк җиңе белән сөрткәләгән арада өстәлдә тиз генә «Троцкийга балык киптереп, посылка белән җибәрмәкче булган»,— дигән документ туды.

Сәлимҗан, алты елга хөкем ителеп, лагерьга җибәрелде, ә тикшерүче Шурин, ял алып, бераз какшаган сәламәтлеген ныгытырга дип, Сочига китте.

Судта Сәлимҗан, аптырагач, үзенең аңгыра икәнен искә төшереп, «Карале,.. ни... өтерменгә утыртмагыз инде мине... мин бит җүләр»,— дип тә карады. «Инде акылланырга вакыт»,— дип җавап бирделәр аңа.

Бер ел тайгада урман кискәннән соң, Сәлимҗанга язмыш тагын елмаеп куйды. Эчке эшләр комиссариатында җитәкчеләр алышу уңаеннан амнистия игълан ителде.

Лагерьданиләр генә күрмәде дә, кемнәр белән генә очрашмады Сәлимҗан. Политтоткыннар, кеше үтерүчеләр, караклар, тагын әллә кемнәр белән... Акылы иләс-миләс булганга күрә, статьясы политика белән бәйле булса да, ул политтоткыннар белән аралаша алмады, ә уголовниклар исә аны үзләре янына якын да китермәделәр. Шуңа күрә ул, үзе шикелле үк аңга туеп җитмәгән Субай авылы керәшене белән бер кечкенә генә, ике кешелек аерым «төркем» тәшкил итеп яшәде.

Микайла (иптәшенең исеме шулай иде) амнистиягә эләкмәде. Чөнки ул дәүләт өчен, халык өчен, гомумән, социализм өчен иң куркыныч элементларның берсе иде.

Ул үзенең ата дуңгызына (белмим, кайлардан тапкандыр, кемнәрдән ишеткән булгандыр андый сүзне) Лаза дип исем куша. Бер көнне моның урамда «Лаза! Лаза!» дип дуңгызын чакырганын ишетәләр. Икенче көнне бөтен тирә-якта диваналыгы белән танылган «көрпә Микайла» авылдан юк була һәм, Лазарь Кагановичны мыскыллауда гаепләнеп, ун елга ирегеннән мәхрүм ителә.

Аерылышканда ике дус Микайланың срогы беткәч, очрашырга вәгъдәләшәләр. Ләкин аларга инде кабат күрешергә насыйп булмый.

Беркөнне баракта, йоклар алдыннан бушлатында мыж килеп йөргән

бетләрне сытып утырганда, Микайла үз гомерендә соңгы политик җыная-
тен кыла.

— Рәхмәт әйтсеннәр әле, шундый пычрак кешенең исемен бер гөнаһ-
сыз дуңгызыма биргән өчен,— ди ул. Бу сүзләрдән соң Субай авылының
ат караучысы «көрпә Микайла» Җир йөзеннән юк була.

Ә бу вакытта инде Сәлимҗан Мукшы күленнән балык тотып, авыз
эчендәрәк исән калган берничә теше белән юа күшәп, урманнан чыбык-
чабык ташып, бәхетсез язмышыннан берсүзсез канәгать булып, беркемгә дә
ачу тотмыйча яшәп ята иде.

Тик, лагерьдан кайткач, авылдашлары аның белән сөйләшмәү генә
түгел, хәтта аңардан кача торган булдылар. «Ристан», «түримщик», «кәтер-
җән», «контра»— Сәлимҗан белән әти-әниләр балаларын куркыта башла-
дылар.

Еллар үткән саен кушаматлар берәм-берәм онытыла барды, тик менә
«контра» дигәне генә бик ябышкак һәм озын гомерле булып чыкты. Сәлим-
җан ул сүзнең мәгънәсен тирәннән үк аңлап бетермәсә дә, аның начар
кешегә, дошманга әйтелә торган сүз икәнен белә иде. Шуңа күрә, бөтен
кеше аңа «контра» дигәч, ул үзенең контра икәненә шикләнми иде. «Күрә-
сең, мин шундый начар кеше инде»,— дигән уй-нәтиҗә белән килешеп
яшәде ул. Бөтен авыл дошман дигәч, дошмандыр инде...

Тик аның үз гомерендә бу дөньяда бер генә дошманы да булмады. Үз
хәле, язмышы белән килешеп, һәр кояшлы таңны куанып каршы алып, бу
вәхши дөньяга булган чиксез мәхәббәтенә хыянәт итмичә яши бирде ул.

Сталин үлгәч, аңа сарык көтүен көтәргә рөхсәт иттеләр. Бу сөенечтән
аның яшәешкә мәхәббәте икеләтә артты. Шулай да авылдашлары аңардан
читтәрәк булу ягын карадылар.

Җилкәсенә көтүче сумкасы белән бергә тормыш йөген асып, чыбыркы-
сы белән бергә «контра» кушаматын сөйрәп, Сәлимҗан гомер сукмагыннан
картлыгына таба атлавын дәвам итте.

Аның белән сиксәненче елларда гына сөйләшә башладылар. Яшьрәк-
ләр: «Сәлимҗан бабай, син халык дошманы дип исәпләнеп төрмәләрдә
утырдыңмыни?..» «Контра» дигән кушамат шул еллардан калдымыни?..» —
дип сорагач, Сәлимҗан: «Әй, булды инде андый гөнаһлар... җәш чак бит,
палитиканы аңлап бетермәгәнмендер инде»,— дигән була иде.

Соңгы вакытта авылдашларының якты чырай күрсәтүеннән, үзенә
игътибар итүләреннән Сәлимҗанга гүя канатлар үсеп чыкты. Исерек кеше
шикелле авыл урамнарыннан көненә әллә ничә тапкыр үтеп, очраган бер
кеше белән кычкырып исәнләшүдән җан рәхәте таба башлады.

Ә беркөнне көтү көткән болыннарына чыгып керергә булды. Бераз
дөньяның матурлыгына, яшәүнең рәхәтлегенә сокланып йөргәч, аның кинәт
кешеләргә рәхмәтен һәм мәхәббәтен ничек булса да белгертәсе килеп, авы-
лына таба йөгерде. Ул үзен беренче тапкыр акыллы һәм зирәк кеше итеп
хис иткән иде.

Тик, әллә артык шатланудан, әллә йөгерүдән, авылга җиткәндә аның
сулышы буылды, аяклары тотмый башлады. Шулчак ул әҗәле килгәнен
аермачык тойды.

Басу капкасы төбендәге чирәмгә егылгач, Сәлимҗан торырга ниятләп
карады, ләкин булдыра алмады. Аның томанлы күзләре күктә ашыга-ашы-
га аккан болытларга ялварып карады... Тик, аны, гомере буе кешеләр сан-
га сукмаган кебек, болытлар да бер адәмнең җиһан белән хушлашып
ятуына исләре китмичә, бер-бер артлы офыкка таба актылар...

Контра-Сәлимҗан дөньядан китте, инде менә дүрт ел хәбәр-хәтере юк...

# ШИГЪРИЯТ

## Ләис Зөлкарнәй

### Зең

1

Иннек сөрткән кояш.
Кершән яккан ай.
— Исәнмесез, туташ!
Мин — сукбай.

Муенымда — каеш,
Ат җуйган шөлдер.
— Шикләнмәгез, туташ,
Мин — шулдыр...

Чәч кистерә яңгыр.
Кешеләр — гөмбә.
— Куагыма сыен
Зонтиксыз көндә.

Көзнең көне черек.
Куак тутыккан.
— Тубыктан ук яңгыр...
— Дөнья тубыктан.

Көзнең чергән көне,
Эчергән төне.
Кигән киемем —
Тәмәке төтене.

Шәһәр чите — үзәк.
Үзәктә — куыш.
— Урамнардан, туташ,
Яфраклар куыш.

Яфрак — миңа ястык.
Теләсә — аңа.
— Туташ, туташ, нигә
Бит алмаң яна?

Кырынмаган кояш.
Юынмаган ай.
— Сукбай, күзеңне ач,
Мин — югалган тай.

2

Эңгер-меңгер...
Куышта безнең
Ат җуйган шөлдер —
Зең-зең дә зең-зең,
Зең-зең дә зең-зең.

Йөземдә — йө-
Зең-зең.
Күземдә — кү-
Зең-зең.
Теземдә — те-
Зең-зең
Сүземдә — сү-
Зең-зең.
Үземдә — ү-
Зең-зең.

Эңгер-меңгер?
Эңгер-зеңгер!
Аң җуйган шөлдер...

3

8—
Ике зонтик очрашса.
8—
Күзем сине кочып алса —
8.

Иренеңә чәчәк игез.
Үп әле, үп чәчәгемне,
Кулда — сыңар,
Үпсәң —
8.

8—
Дивардагы җәпле мөгез
Баш киемен бергә элсә.

---

*Ләис* ЗӨЛКАРНӘЙ *(1962) — шагыйрь, «Балачак күге», «Кар өстендә алмалар» исемле ике шигырь китабы авторы. Казанда яши.*

8—
Беләүләнгән каешымны
Беләзегең үбә белсә.

Ике касә,
Кәсебегез:
Кулыбызда ярты бәхет —
Чәкештерсәк,
Зең-зең
8.

8—
Маңгаеңнан маңгай үтсә.
8—
Бөдрәңнән бөдрәм үпсә —
8.

Сез,
Сәгатьләр,
Гафу итегез.
Сез ничәне суксагыз да,
Безнең вакыт —
Зең-зең
8.

4

Әйдәле, бие әле,
Көйләрен табам үзем —
Төшсен әле түшәмгә,
Түшәлсен табан эзең.

Дошман — тугыз,
Без — сигез,
Китмәс ләкин
Исебез:
Без бит сигез
Икебез.
Икебез —
Сигез, сигез.

Тугызлыны бииләр.
Сигезлене биик без.
Безне түбән дигәннәр,
Сездән генә биек без.

Без, без, без әле,
Без дә үзебез әле.
Сезнең сүзгә без түздек,
Сез дә түзегез әле.

Дошман — тугыз, тугыз, тугыз.
Төн — тыгыз, тыгыз, тыгыз.
Безне тотам дигәннәр,
Куып таңны тотыгыз!

Сүз, сүз, сүз әле,
Мин җибәрәм тезмәне:
Түз, түз, түз әле,
Булмаса да түзмәле.

Безне түбән дигәнгә
Ишетелсен безнең зең —
Кем дә бии идәндә,
Син түшәмдә биисең.

5

Минем кулым түгел,
Гайшә Батман кулы.
Им-томнан.

I

Гайшә Батман кулы түгел,
Батман кулым йөри синнән —
Юатып сүз әйтер идем,
Тапмам.

Йөрәк сеңгән сүзләр
Синдәй йөрәксенгән.

II

Бетерен-бетеренмә,
Без — төркем.
Без — төрмә.

Чыгып кара үз-үзеңнән.

Тутык рәшәткә эзедәй,
Көршәнең ага йөзеңнән,..

III

Тугыз —
Тузгыт!
Җиде —
Җилгәр! —
Инкыйлап-имче ысулы.

Мәйданнардан юл күрсәтә
Безгә Гайшә Батман кулы...

IV

Өч —
Оч!
Киләчәк офык үрендә.

Ун —
Ур!
Ур-р-ра!
Коммунизм,
Кырың күренә.

Биш —
Иш!
Бәхет тавы түрендә.

Шик шикләнә,
Ике икеләнә
Шикелле әнә...

Гайшә Батман кулы
Шәкелләнә:

Күрмәгәнне күрсәтә
Ул,
Күрмәгәнне күрсәтә —
Икеләнмәскә мәҗбүр ике,
Шик — шикләнмәскә...

V

Башка сугып имлиләр дә,
Илтеп чыгармаса юлы,
Минем кулым түгел, диләр,
Гайшә Батман кулы...

Ә сәдака —
Кесә тулы!

VI

Юньсезләрнең
Юне бар көн.

Юньлеләрнең
Юк көн юне.

Җан биргәнгә
Юнь бирмәгәч,
Сәдакадай
Өләшәсең
Сөюеңне.

VII

Киләчәкне көтәчәк бар.
Киләчәк юк.
Китәчәк бар.

Киләчәк ул килмәячәк.

Җирдән килдең, җиргә кит дип,
Безне Әҗәл
Әҗәткә дә имләячәк.
...Һәм киләчәк килмәячәк...

VIII

Бетерен-бетеренмә,
Без — тере.
Без — төрбә.
Чыгып кара үз-үзеңнән.

Тутык рәшәткә эзедәй,
Сөрмәң ага йөзеңнән...

IX

Көтәчәкләр. Көтәчәкләр.
Безнең кебек көтәчәкләр.

Киләчәксез бу дөньядан,
Ярый әле,
Китәчәк бар.

6

Чык төн белән бергә төшә,
Түбәләрдән тама чык.
Чык чыгарга куша аңа —
Син җибәрмә, алачык.

Шәрран ачык ишегендә
Яткан гәүдәм — бусага.
«Түшәмең күк түгел,— ди чык,—
Идәнең җир булса да.
Чык!»

Чык чыгарга куша шулай.
Җанга куша...
Җибәрмә.
Ул килмәсен мин сукбайны
Җир идәнгә җирләргә.
Ул килгәнче җибәрмә!

Ул килер дә шәм кабызыр.
Дер-дер килсә шәмнәре —
Идәннәрең күк булыр да,
Җир булыр түшәмнәрең.

Ат югалткан өнсез шөлдер
Зеңгелдәр һәр сүзеннән:
«Дәрвишем син, минем ишем,
Яшәмә үзең генә...»

Чык чыгарга кушар аңа.
Җибәрә күр, алачык.
Күзем әйтер сөйгәнемә:
— Җанымны да... ала... чык...

# Кави Латыйп

## Әминә

*Чуваш халкының унтугызынчы гасырда яшәгән шагыйрәсе Әминәгә.*

Яңа туган ай шикелле
Әминәнең кашлары.
Хушпу[1]ында җем-җем итә
кыйммәтле күп ташлары.
Бик сагышлы чакларында
Уйный моңлы шыбырда.
Багышлап яры Алимгә
чыгара җыр-шигырь дә...
Алимне «Себер сөргәннәр» —
аерганнар гомергә...
Авылда хәбәр таралган —
кыз китә дип, Себергә.
— Бармыйсың! — дип каршы тора
кызга әтисе Азан.—
Теләп «сөргенгә китә»сең,
акылдандыр син язган?
Онып тизрәк хәерчеңне,
таптым сиңа бай кияү.
Йөз баш куе, җиде аты,—
беркайчан йөрмәс җәяү.
Колмагы ун десятинә,
үзе тагын алманчы
«Атып кал», диләр татарлар,
кызым, «ятып калганчы».

Килеп җитәр димчеләр дә
куа-куа пар атны.
Акыш-макыш[3] туй ясарбыз,
шаулатып тирә-якны.
Таралыр менә, күрерсең,
еракка Азан даны.
Туйны көтеп, куй көтеп мин
каршы алам һәр таңны...

Себер якларыннан кызга
Сәлам хаты килмәде.
«Бирмәсләр микән хәбәр?» — дип,
тыңлады ул җилләрне.
— Ник хат язмый сөйгән ярым,
җилләр, җилләр, сөйләгез.
Сагыш җырын минем белән
бергәләшеп көйләгез!..
Ләкин җилләр телсез иде,
әйтмәделәр бер сүз дә.

— Йолдызлар,— диде шагыйрә,—
эндәшәм инде сезгә!
Ник хат язмый сөйгән ярым,
зинһар, шуны сөйләгез.
Минем белән сагыш җырын
бергә, әйдә, көйләгез!..
Ә йолдызлар, дәшми генә,
берәм-берәм сүнделәр.
Әйтерсең, күбәләкләрнең
канатлары көйделәр
(Балачакта үлгән иде
күбәләкләре шулай)...
Кемгә тормыш бик кулай да,
Әминәгә ник болай?..
Раштуада диләр туйны,
килеп җитәр кулагай...[4]
— Ник хат язмый сөйгән кешем,
белмисеңме, тулган ай?
Сүзсез генә ай югалды
болыт артына кереп.
Әминәкәй басып тора,
йөзе әнә көл кебек.
Иң соңыннан Әминәкәй
күке белән киңәшә.
Күңелендәге төенен
чишкәнче, ул сөйләшә...

Китәргә дип карар кыла
кыз сөйгәне янына.
Юлына ул әтисеннән
акча сорап ялына.
«Себер!» дигәнне ишеткәч,
шашарга җитә Азан...
(Кар сорасаң, кар бирмәстәй
була ул бик тә саран.)
Авыллардан авылларга
кыз йөри шигырь сөйләп.
Ул сүзләрне карт имәннәр
әле дә шаулый көйләп:
«Күке оча «кәк-күк» диеп,—
син язын кайталмыйсың.
Сандугач оча «чут-чут» дип,—
син тагын кайталмыйсың.
Таң ата, дөнья яктыра,—
яктырып кайталмыйсың.

---

Кави ЛАТЫЙП *(1927) — шагыйрь, прозаик; татар, рус, чуваш телләрендә дөнья күргән дистәгә якын китап авторы. Казанда яши.*

Көн туа, дөнья нурлана,—
нурланып кайталмыйсың.
Сулар ага, дөнья шаулый,—
син шаулап кайталмыйсың...»

Авыл халкы шагыйрәгә
бирә соңгы акчасын:
«Әминәкәй, куштаннардан
ничек кенә качарсың?..»
Акча җыйгач, шагыйрә кыз
авылын ташлап китә.
Карлы елгасы буйлап ул
Тымбайга килеп җитә.
Әминәне карт куштаннар
тотып алалар шунда.
Һәм әйтәләр: «Әйдә, сөйлә,
ни кирәк сиңа монда?»
Котыртамы синең әллә
күңелеңне кирәмәт?[5]
Мондый җырлар ник язасың,
тавай кала — сөйлә, әйт!..
Ни генә сорасалар да,
Әминәкәй дәшмәде.
Берәү әйтте: — Озын икән
толымнары — чәчләре!
Бәлки, шуңа Азан кызы
җыр-шигырьләр язадыр? —
Халык әйтә: «Озын чәчле
хатын-кызлар азадыр».
Акылга кыз утырмасмы,
әйдә, кисик чәчләрен.
Инде, чәчен саклыйм дисә,
бирсен шигырь дәфтәрен.
— Чәч ул нәрсә,— диде кемдер,—
башсыз калмасын иде.
Башны әйтәм, берәүнең дә
булмый бит инде ике!?.

Эзли торгач кесәсеннән
җыр-шигырьләр таптылар.
Инде күке кычкырмас дип,
көлә-көлә яктылар.
Әйтерсең, кызның йөрәге
яна иде учакта.
«Кәк-күк!» дип, күкеле сәгать
тавыш бирде шул чакта.
Уклар сымак мич эченнән
атылдылар чаткылар...
Карт куштаннар Әминәне
сихерче дип таптылар...

«Ник болай мәсхәрәлисез,
әйтегезче, йә нигә?..»
Төн ката ут яктысында
шигырь язды Әминә.
«Кыргый усак җил белән
шауласын — селкенсен.
Заманасы — чуваш өчен
чын тәрмә, кара төн.
Күздән яшьләр түктерде
дошманнар ни кадәр!
Еракта — сөйгән егетем,
үзем көтәм хәбәр...
Урладылар сөйгәнемне
һәм минем бәхетемне...—
Караклар сарып алган
Питерда тәхетне...»
Язды да яңа шигырь, кыз
яндырды ут-учакта.
Тора иде карт куштаннар
капка төбендә сакта.

Шагыйрәнең бу шигырен
ишетмәде берәү дә.
Тымбайга әтисе килде,
килгән икән кияү дә.
Алимы түгел, әлбәттә,—
җыючы акча-салым.
Әтисе әзер тора бит
алырга бүген калым.
Азан пиччә[6] кәйнең бик тә
затлы буласы килә.
Әллә шуңа кыш көне дә
шпорлы итек кия.
Атлаганда менә хәзер
ул биеп китәр төсле.
Шатлыгыннан борыны белән
бозны да тишәр төсле.
Кунаклары — Чабаксардан,
Алатырдан булачак.
Мировой белән урядник
хәтта, килеп, куначак!..

Берсекөнгә туй дип, кызны
өйгә алып кайттылар.
Җылына торсын дипме,
мунчасын да яктылар.
Ул якларда шундый йола,
туй лаүкәдән башлана.
Мунча кергәч, имештер, бик
җиңел була ташларга...[7]
Булмады туй... Мунчаны да
юкка гына яктылар.
Таң белән мунча эчендә
кыз гәүдәсен таптылар.
Үлем юлын үзе эзләп
Әминә тапкан, диләр:

---

[1] Хушпу (чув.) — хатын-кызларның баш киеме.
[2] Алманчы (чув.) — салым җыючы.
[3] Акыш-макыш (чув.) — искитмәле.
[4] Кулагай (чув.) — башкода.
[5] Кирәмәт (чув.) — җен-пәри.
[6] Пиччә (чув.) — агай.
[7] Ташларга (чув.) — биергә, җилкенергә.

Янып торган мичнең төнлә
морҗасын япкан, диләр.—
Шагыйрә кыз Әминәнең
сөрем тигән башына...
Халык елый, күз яшьләре
тама кабер ташына.
Җырын дәвам иткән кебек
ялгыз күке кычкыра.
Әминә — чуваш күкесе,
йокла син тыныч кына...

Туган якларыма кайтсам,
кәккүк җырын ишетәм.
Кәккүк җырын тыңлап үсә
сабыйкайлар бишектә.
Кәккүк җырын тыңлый-тыңлый
егетләр урман кисә,
Кәккүк җырын көйли-көйли,
әйтерсең, җилләр исә:
«Оч, кәккүк, оч, кәккүк,
Себерләргә җиткәнче.
Кычкыр, кәккүк, кычкыр син
бәгырьләргә үткәнче!..»

# Николай Шәмсетдинов

## Муса Җәлил истәлегенә

Казан суы ярында мин басып торам,
Гранит җәелгән буш чүлдәй бер үрдә.
Челләдә һәм буранда Җәлил җылысын
Саклый туган җир һаман, суытмый бер дә.

Туган җир, син безне күпме сакладың,
Тояклар челпәрәмә килгән чордан ук.
Сугыш янгыннары сиңа күлмәк булды,
Хәзер яныймы сиңа «тыныч» атом-ук[1]?..

Җәлил улыңның кып-кыска гомерендә
Язмышын эзәрлекләп килде гел гранит —
Каһәрле Моабит, рәхимсез таш капчык...
Граниттан төзелгән иде бит Моабит.

Диварга, әйтерсең, мең таш чөй кагылган,—
Батырлык каерып чыкмаска таш чөйне.
Үлем тынлыгына баткан бу төрмәгә
Мөлдерәмә тулган сагыну илне, өйне.

Дәшмәскә!.. Дошманга бер сүз дә әйтмәскә!..
Куркаклар түгел, бу — батырлар тынлыгы!
Уч төбе кадәрле гади бер дәфтәрдән[2]
Бар дөнья ишетте бөек бу чынлыкны.

---

Николай ШӘМСЕТДИНОВ — *Төмәндә яши. Шигырьләрен рус телендә яза. Тәрҗемәләре журналыбызда да басылып килде.*

Маобит ул — дәшмәүче шагыйрьләр иле.
Ә шагыйрьнең дәшмәве — атака, «Ура!»
Монда эшли йөрәк һәм урланган каләм,
Монда чукраклыктан үч, ант, нәфрәт туа!..

...Төрмә — ярты гектар әрнү полигоны.
Монда Вакыт төс югалта... Аннан үлә...
Сукыр коридорлар... Эт ырлавы... Аннан
Синең өскә төссез, шыксыз үлем килә...

Төрмә — җир тәмугы. Синең бугазыңнан
Буып ала гасабилык, чарасызлык...
Без, шагыйрьләр, нәкъ шушындый төрмәләрдә
Күпме кан-яшь түктек, күпме сыздык?!.

Ә бит анда төнге пычрак почмакларга
Поскан була безне саткан мескен җаннар.
Тышкы яктан язмышлары нәкъ Җәлилдәй,
Ә чынлыкта алар сарык кебек маллар!..

Ә шагыйрь ул — биниһая тере мишень,
Авырта дип, бетәм, үләм дип уйламый,—
Ул үзенә кабул итеп тора һаман
Гомум илгә багышланган һәр пуляны!

Русчадан Гәрәй **РӘХИМ** тәрҗемәсе.

[1] ТатАЭС күздә тотыла.
[2] М. Җәлилнең «Моабит дәфтәре».

# ПУБЛИЦИСТИКА

**Радик Фәизов**

## ИЛГӘ БӘРӘКӘТ ИҢӘРМЕ?

Соңгы вакытта без тормыштан бик еш зарлана башладык. Кая барсаң, шул тарафта «аһ» та «ваһ» килү, лаф ору, офтану. Ашарыбызга такы-токы, өстебезгә затлы кием юк, тегесе дә, монысы да җитми, янәсе. Хәерчеләрчә яшибез, имеш... Һәм башкалар, һәм башкалар. Моныңише моң-зарны әле тагын дилбегә буе сузып булыр иде.

Тик, җәмәгать, бер тирән сулыш алып, бераз тынычланыйк, уй-фикерләребезне тәртипкә китерик әле! Әгәр тормышка, яшәешебезгә, көндәлек мәшәкатьләрдән һәм уйлардан югарырак күтәрелеп, фәлсәфи карый алсак, минемчә, бик урынлы түгел бу зарланулар. Чынлап та. Иң әүвәл, гафу итегез, кайда әле ул «хәерче»? Безме ул — хәерче?! Ярый, әйдәгез, болай итик. Бүгенге көндә намус белән эшләп торган, сәрхүшлеккә төшмәгән, ялкаулыкка чыкмаган теләсә кайсыбызның йортына барып керик. Анда без нәрсәләр күрербез? Кагыйдә буларак, бар яктан җитешле тормышны. Залны балкытып торган «стенка», кием-салым тулудан бүселергә җитешкән шкаф, төсле телевизор, транзистор, магнитофон... Күп кешеләрдә бай гына шәхси китапханә бар. Кайберәүләр хәзер үзенең капкасыннан, элекке байлар яхшы атларда чыккандай, машинага утырып кына чыга.

Шулай итеп, җәмәгать, матди ярлылык турында сүз — төптән уйлап әйтелгән сүз түгел. Һәрхәлдә, ул хакыйкатькә туры килми.

Алыйк торак белән, өйләр, квартирлар белән тәэмин ителешне. Сүз дә юк, бу яктан кытлык сизелә. Әмма, бу очракта да... Һәркем үз җирлегеннән чыгып хөкем итә. Мин Арча эшчеләр поселогын алам. Соңгы елларда гына да безнең Арчада әллә никадәр кеше яңа квартирга күчте, яңа йортлы булды. Белмим, кайда ничектер, Арчада төрле предприятиеләр, оешмалар һәм хәтта кечкенә генә учреждениеләрнең дә үз эшче-хезмәткәрләренә йорт салып бирүе гадәткә кереп бара. Хәзер инде Арчадан Балтачка чыга торган очта шундый йортлардан зур бер шәһәрчек үсте. «Восточный» дип атала. Анда махсус барып, тамаша кылып кайту ярый. Бүрәнәдән, ак кирпечтән, төрле плиталәрдән салынган пулатлар. Бер генә йорт та икенчесенә охшамаган. Иркен ишегаллары, бакча-куралар. Шунда ук ак кирпечтән дәү итеп кибет тә салып җибәрделәр. Монда килсәң, туктаусыз сокланып йөрисең.

Менә мондый чынбарлык фонында нииндидер ярлылык турында сөйләнеп тору, дөресен генә әйткәндә, гөнаһ булыр ул, җәмәгать.

Хуш, китик чыгып Арчадан. «Октябрь» колхозының үзәге Наласа авылына, «Чулпан»ның — Олы Мәңгәргә, «Игенче»нең — Куәмгә, «Искра» колхозы үзәге Түбән Шашы авылына барып керик. Анда нинди йортлар, каралтылар күрәбез! Инглизләр әйткәнчә, минем йортым — минем кирмәнем. Монда исә яңа салынып куелган күпме йорт, яшь гаиләләр яралганны көтеп, буш тора! Колхоз авылларында гасырлардан килгән зур бер мәшәкать бетеп бара. Өйләрне җылытырга зәңгәр ягулык — газ керә. Сүз уңаенда әйтим, торак белән тәэмин ителешкә килгәндә, авыл кешесенең хәле, шәһәрләрдәгеләргә караганда, күпкә яхшы хәзер. Авыл җирендә җитмешәр, туксанышар квадрат метрлы йортларда өч-дүрт, күп булса, биш кеше тора. Шәһәр кешесенә мондый иркенлек кайда әле?!

Ярый, инде йортларга кергәч, табыннарыбызга да күз салыйк. Мин үзем, шәхсән, мондый нәтиҗәгә килдем: бу яктан да адәм баласының нәфесенә ик-чик юк икән. Күпме генә мул һәм тәмле булмасын, без беркайчан да тулысынча канәгатьләнә белмибез икән. Хәер, моның өчен беркемне дә гаепләп тә булмый. Бу бит — табигый күренеш, җәмгыятьнең үсеш законнарыннан берсе.

Алай да хәлне чагыштырып карарга кирәк. Һәм, болай итсәң, бу яктан да без соңгы елларда алга китешләр күрәбез. Ит, колбаса аз, дип зарланабыз. Уйлап карасаң, ничек кенә сәер ишетелмәсен, бу ризыклардан кибет киштәләренең сыгылып тормавы үзе бер уңай күренеш. Әйе! Чөнки без аларны хәзер күпләп кулланабыз, шуңа күрә күпләп алырга да телибез.
Авыл хезмәтчәннәренә әле дә рәхмәт, алар безне ел тәүлеге буена иттән һәм сөттән өзмиләр. Безнең Арчада, мәсәлән, сөт, эремчек, кефир, каймак, атлан май ел буе кибеттә булып тора. Ит тә кибеттә, даими диярлек, бар, сыйфаты да ярыйсы.
Чагыштыру, дидек бит әле. Элекке елларны искә төшерик! Хәзерге яшьләр белми, әмма олылар яхшы хәтерли: моннан утыз-кырык еллар элек халык җәй көне ит ашауны, кыш көне сөт һәм атлан май ашауны белми дә иде. Җәй көне авыл халкының бар сые — сөтле аш та бәрәңге, кышын көненә бер итле аш та тагын шул бәрәңге иде. Ул заманнарда яшелчәләр (җитмәсә, хәзергә кебек, ел тәүлеге буена) безнең татар халкында, гомумән, күрелмәгән нәрсәләр иде. Суганны искә алмаганда.
Безнең хәзерге туклануны ул заманнардагы белән янәшә кую да мөмкин түгел. Әлбәттә, сүз дә юк, табыннарыбызны тагын да баетсаң, бер дә зыян итмәс иде. Әмма монда шунысын да искә төшерик, хәзер безнең кайберләребез ризык җитмәүдән түгел, киресенчә, артык күп ашаудан интегә. Бер уйласаң, көлке дә. Врачлар әйтүенчә, безне җәфалаган күп кенә авырулар — нәкъ менә чамасыз ашау нәтиҗәсе икән.
Монда мин тормышыбызны бизәп күрсәтергә омтылмыйм. Алай уйламагыз. Мин бары тик хакыйкатьне генә искә төшерәм: арабызда симерүдән интегүчеләр булганда ашау-эчү кытлыгыннан зарлану сәеррәк тоела.
Инде өстебездәге киемнәребезгә күз салсак, бу уңайдан без үзенә күрә чын бер революция кичердек. Һәм монда бер дә арттыру юк. Мин — хәзер алтмышка җитеп килгән кеше, бала чагымда аягыма — ыштыр белән чабата, өстемә киндер күлмәк кидем. Кышын да аякта — шул ук чабата, өстә сатин тышлы бишмәт иде. Хәзерге туннарга, йон шарфларга, тире бүрекләргә төренгән бер кешене ул замандагыча бер кат киндер чалбар, юка бишмәт һәм чүпрәк бүректән киендереп куйсаң, ул үзен ялангач калгандай хис итәр. Кышкы салкыннарда, мөгаен, катып та үләр иде.
Мин инде хәзерге яшьләрнең, хатын-кызларның күз күрмәгән, колак ишетмәгән модалы асыл кием-салымнарын әйтеп тә тормыйм.
Җыеп кына әйткәндә, җәмәгать безгә артык төшенкелеккә бирелер урын юк. Бәлки, без көткән һәм теләгәнчә үк түгелдер, әмма безнең тормыш-көнкүрешебез ару гына. Һәм ул, акрынлап кына булса да, гел әйбәтләнүгә бара. Моны беркем дә инкарь итә алмас.
Әлбәттә, киң селтәнү белән төртеп күрсәтүчеләр табылыр: әнә Көнбатыш Европа илләре, әнә Америка! Алар кая барып җиткән, алар нинди биеклеккә күтәрелгән, аларда нинди могҗизалар тулып ята. Бүгенге көндә без нигә шулай яши алмыйбыз?
Менә монда инде, җәмәгать, сөйләшерлек урын бар. Безнең эчке һәм тышкы тәртип һәм халәтебез, бездәге җаваплылык хисенең ни дәрәҗәдә булуы, үзебезгә ышанып тапшырылган эшкә мөнәсәбәтебез һәм башка шундый нәрсәләр турында. Хәтерлисездер, атаклы Остап Бендер: «Җитәр үз-үзеңдә казыну, үз-үзеңне битәрләү»,— дигән. Безгә болай дип әйтү иртәрәк әле. Үзебезне бик җентекләп тикшерергә, үзебезгә бәя бирергә кирәк әле безгә.
Мәгълүм ки, хәзер безнең илебезгә капиталистик ил гражданнарына да ишек ачылды. Аларның берсе — Америка кызы Сюзанна Скляр Свердловскида, педагогия институтында инглиз теленнән дәресләр бирә. Һәм менә шул Сюзаннаны безнең ташка үлчим юллар да, промышленность шәһәрен үзәгендә җимерелә башлаган агач йортлар булу да, хәтта шикәр талоннары да әллә ни гаҗәпкә калдырмый икән. Аны безнең тормыш дәрәҗәбезне шведлар, финнар янсә шул ук американнарныкы белән тиңләп карарга омтылуыбыз гаҗәпкә калдыра икән. «Балтыйк буйларыннан алып Тын океанга кадәр җәелгән илне баету өчен бик күп һәм бик яхшы эшләргә кирәк,— ди ул.— Һәр өйдә, ишегалдында, һәр мәктәптә тәртип урнаштырырга кирәк. Американнар һәм финнар эшләгәнчә... Сездә бит кешеләр барысын да властьлардан таләп итәргә янсә үзеннән-үзе байый торган нинди дер бер хыялый дәүләт моделе уйлап чыгарырга күнеккән...» Бу америкалыга каршы төшеп ни әйтәсең? Дөрес бит.
Әйе, Европа һәм Американың күпчелек илләре белән янәшә куеп карасаң, без алардан начар яшибез. Сорау туа: ә без бүген ничек итеп алар дәрәҗәсендә яши алыйк әле? Без — бөтен дөньяны тетрәткән революция, канкойгыч сугышлар кичергән ил халкы. Бөтен илне, промышленность һәм авыл хуҗалыгын яңа җайга салып, хәзерге дәрәҗәсенә күтәрә алган халык. Һәм аның аянычлысы, шәхес культы афәтен, крестьян әби-бабаларыбызны, җирдән тобе-тамыры белән кубарып алып, Себердә черетү фаҗигасен күтәргән, дистәләрчә еллар буена, бөтенләй диярлек, бушка эшләп, колларча фикерләргә тәмам күнеккән, хокукый дәүләт дигән төшенчәне бөтенләй белмәгән кешеләр без.

Шәхесне мәсхәрәләү һәм имансызлык безда дистәләгән еллар буена дәүләт политикасы булган. Моны хәзерге өлкәннәр бик яхшы белә. Балачагымны хәтерлим. Безнең авылда Корбан агай бар иде. Болай юаш кына, бик тә эшчән кеше иде. Колхозчы — ударник иде, сугыш алдыннан гына лотереяга автомашина отты һәм ул машинаны илебезнең оборона фондына тапшырды. Тәбәнәк кенә, елмаеп кына сөйләшә торган бер авыл агае... Һәм менә шушы агай авыр сугыш елларында авыл халкына үзенең тагын бер холкын күрсәтте.

Әниләр басуда урак ура. Хәзерге кебек комбайн белән түгел, урак белән. Кояш кыздыра, эссе, әниләр көнозын азапланып эшлиләр. Алар ач та бит әле. Әйе, әйе: басу тутырып икмәк үстергән кешеләр... ач. Ашарга каралып беткән вак бәрәңгедән кала берни дә юк. Менә алар, бераз башак уып, бодайны табага салалар. Исәпләре — бодай куырып ашау. Арадан берәү ызанда сакта тора. Корбан агай килеп чыга күрмәсен. Әмма ул бөтенләй көтмәгән яктан килеп чыга. Килеп тә чыга, табаны тартып та ала... Көнозын бил бөгеп урак урган әниләр, ач калу өстенә әр-хур да ишетәләр...

Шул ук агай бервакыт инде игеннәре урып алынган басуда башак җыючы кыз балаларны тотып алып кайтты. Турыдан-туры колхоз идарәсенә. Ат каракларын тоткандай итеп. Бичара кызларның кесәләреннән бер уч башак чыкты. Берәр уч башак! Шуның өчен район үзәгеннән милиция чакырылды, кызларның әниләре һәм әбиләре алдында акт төзелде. Һәм шунда күпме ялыну-ялвару, күпме күз яшьләре түгелде. Колхозда намус белән эшләгән апалар, инде чәчләре агарган әбиләр нинди түбәнчелекләргә төшәргә мәҗбүр булдылар. Хәзер шуларны уйласаң, чәчләрең чалара. Теге кызларны төрмәдән, Сталин лагерьларында черүдән бары тик аларның яше җитмәве, әле укырга да кермәгән булулары гына саклап калды.

Үткәннәребез бик авыр. Әлбәттә, ул заманда ныклы тәртип тә, кырыслык та кирәк булгандыр. Әмма ул чордагы власть ияләренең һәм аларның тугрылыклы хезмәтчесе Корбан абзый кебекләрнең мондый таләпләре тәртип идеме икән? Ай-һай... Имансызлык булгандыр ул.

Имансызлык бит ул — мең төрле. Арчада минем бик яхшы таныш бер картым бар иде. Яшьлегендә шушы Арчада Совет властен урнаштыру өчен көрәшкән. Мин аның ул елларда актив комсомоллар белән бергәләп төшкән фоторәсемен күрдем. Ул гомере буе элемтәдә эшләде, намуслы хезмәте өчен илебезнең олы бүләге — Ленин орденына лаек булды. Пенсия яшендә дә байтак еллар эшләп йөрде.

Менә берзаман баһадир буйлы шушы кеше тәмам картайды. Инде бөтенләй яраксызга чыкты, бар көчен һәм сәламәтлеген илгә хезмәт итүгә биреп, ялга чыкты. Өстәвенә гомер иткән карчыгы вафат булды... Менә шунда инде карт күрмәгәннәрен күрде. Хезмәт хакы түбән булгандыр күрәсең, пенсия акчасы аңа нибары илле сум чыкты. Һәм кайчандыр Ленин орденына лаек кеше, калтыранган куллары белән аулак почмаклардан, елга-ерымты буйларыннан буш шешәләр, банкалар җыеп йөрде. Айга илле сум ничек җитсен?!

Карт үзе гомер буена эшләп чыккан район элемтә челтәренең, анда рәт чыкмагач, район Советы башкарма комитетының бусагасын күп таптады. Үзенең пенсия акчасын арттыру юлларын эзләп карады. Үтенде, гаризаларын кат-кат язды. Әмма яклау тапмады.

Үләренә күп калмастан, ул минем янга район газетасы редакциясенә кереп утырды, күз яше белән елап: «Бу дөньяда дөреслек юк икән, инде Ленин ордены да ярдәм итмәгәч...» — диде. Пенсияне әз алучылар күп бит алар. Андый кешеләрнең пенсияләрен арттырып хөкүмәтебез, ниһаять, бик игелекле гамәл кылды.

Мондый күңелсез хәлләрне искә төшереп тору хәзер кирәкме? Минемчә, кирәк. Чөнки без үткән заманда үз-үзебезнең кем булганыбызны тирәннән аңлап белергә тиеш. Дөрес, кеше үз-үзенә беркайчан да тулы бәяне бирә алмый. Үткәндә безгә дистәләгән еллар буена коллык психологиясе тукылган. Бик ныклап һәм рәхимсез рәвештә. Һәм бу коллык психологиясе безгә кереп оялаган. Безнең һәркайсыбыз моны аңларга, рухи коллык богауларыннан арынырга тиеш. Шул тәкъдирдә генә һәркайсыбыз алга атлый алачак. Һәркайсыбыз алга атлаганда гына, бөтен җәмгыять тә алга атлый. Әмма әлеге бу коллык психологиясе безне үз кочагыннан җибәрергә һич кенә дә ашыкмый. Бик иркенләп, аяк бөкләп утыра ул безнең күңелләр түрендә.

Менә мин күп еллар буена район газетасы редакциясендә җаваплы секретарь булып эшлим. Моннан, әйтик, егерме еллар элек без газета битләрендә хезмәт алдынгыларының рәсемнәрен урнаштыра идек. «Бу иптәш — социалистик ярыш алдынгысы. Ул һәр сыердан бер пот сөт савып ала. Янсә «җир сөрүдә көнлек нормасын 120 процентка үти». Кыскасы кешенең рәсеме янына, кагыйдә буларак, аның күпме эш башкарганын теркәп куя идек. Һәм бу «иҗади» эштә, әле дә булса, берничди үзгәреш юк. Ул нәкъ шушы калыпка салынган хәлендә дәвам итә. Республика газеталарында да

Никадәр гаҗәп ишетелмәсен, һаман да шул каһәр төшкере коллык психологиясенең бер үрнәге бу. Әле колхозчы-крестьяннар киң басуларыбызда, бөтенләй диярлек, бушка эшләгән заманнарда аларны хезмәткә туплау, кызыксындыру чарасы булган бу. «Син эшлә! Эш хакы сорама! Җиң сызганып тырышуыңны гына бел! Һәм синең күңелең төшмәсен! Шул буш хезмәтнең бәрабәренә без сине әнә ничек мактыйбыз! Сурәтеңне газета битләренә куябыз». Менә нинди фәлсәфә яшерелгән газеталардагы сурәтләргә.

«Әһә! Хезмәт кешесен югары күтәреп күрсәтүгә, алдынгылар тәҗрибәсен газета битләрендә яктыртуга каршы икән бу»,— дип уйлаучылар табылыр. Һич тә алай түгел. Хезмәт алдынгыларына урын газета битләрендә түрдән булырга тиеш. Алар турында бөтен кешелек сыйфатларын, эчке дөньясын һәм фидакарьлеген сурәтләгән зур-зур очерклар, зарисовкалар язарга һәм шул тәкъдирдә генә рәсемнәрен урнаштырырга кирәк. Анда да портрет рәвешендә түгел, хезмәт вакытында яисә гаиләсендә төшереп алынган рәсемнәрен.

Һәркайсыбыз белә: әле күптән түгел генә кешене эш урынына карап ихтирам итү бездә тайпылышсыз бер кагыйдә иде. Гәрчә әлеге эшем кешесенең төп сыйфатлары ташка үлчим икәнен бик яхшы белеп торсак та. Бервакыт мин шундый хәлгә тап булдым. Бер танышым җитәкләгән предприятиегә искәрмәстән генә районның зур җитәкчесе килеп керде. Шунда үз бәясен бик белә торган, эшчеләргә карата кырыс, ифрат тәкәббер кыланучы әлеге директорның кинәттән ничек үзгәреп киткәнен күрсәгез иде! Аны, әйтерсең, бөтенләй алмаштырып куйдылар: йөзенә түбәнчелекле, ялварулы елмаю чыкты. Ул, гайре табигый битлекне кигән килеш, җитәкченең һәр сүзен хуплый барды, аны цехлар буйлап озатып йөрде. Моны читтән күзәтеп тору кызык та, кызганыч та иде.

Һәм мин, бу мисалдан чыгып, әлеге бер директорны гына гаепләргә җыенмыйм. Әллә бер ул гына шундыймы? Башкаларыбыз да теләсә кайсы җитәкче янәшәсендә кинәттән кечерәеп, чүгеп, бер башка түбәнсенеп кала. Фикерен юньләп аңлата алмый, тәмам югалып, бер мескенгә әйләнә. Моны, коллык халәте, димичә, ни дисең?! Һәм бу халәт әле безнең беребездән дә, беркая да китмәгән.

Ә бит, җәмәгать, ничә ел инде, илебездә тамырдан революцион үзгәртеп кору бара. Һәркайсыбызга инде иңнәрне, сыннарны турайтып үсә төшергә, үзебезнең кешелек дәрәҗәбезне югары һәм горур тотарга вакыт җиткән. Үзеңне теләсә кем янәшәсендә тигез итеп тоярга, теләсә кемнең күзенә карап, дөресен әйтергә, төгәл җавап таләп итәргә! Берниндн битлекләр кимичә.

Кешелек абруебызны тиешле югарылыгында тота белү безгә хәзер, һичшиксез, зарури. Чөнки бу рухи бөтенләй кенә түгел, экономикага да кагыла. Әйе! Һәркем белә: үзен бәйсез, кыю һәм горур тота белгән кеше генә эшендә тәвәккәл һәм өлгер була ала.

Мин бу мәкаләне язган көннәрдә безнең газета хәбәрчеләренең район слеты булды. Шунда, бүтәннәр белән беррәттән, безнең күптән пенсиядәге элекке редакторыбыз да сүз алды. Ул стена газеталарының эшен яхшырту һәм аларның редакторларын ай саен җыйнап укыту, агитколлективлар эшен яхшырту кирәклеге турында сөйләде.

Бу уңайдан миндә кайбер фикерләр бар. Минемчә, хәзер стена газеталары чыгарып торуның хаҗәте бетте. Уйлап карагыз: телевидение, радио, күпме газета-журналлар, район газетасы һәм... шулар өстенә тагын стена газетасы. Егерме биш еллык тәҗрибәмнән чыгып әйтәм, бу стена газеталары ифрат дәрәҗәдә ашык-пошык, эчтәлекләре берничә тормый торган итеп чыгарылалар. Аларга үзәк газеталарның мәкаләсен дә күчереп язалар. Нәтиҗәдә, алар совет матбугатын мыскыл иткән кебек әлеге тора.

Шуннан килеп, алыйк агитаторларны. Авыл җирендә бу вазифа, кагыйдә буларак, укытучыга йөкләнә. Үз эше болай да муеннан ашкан авыл укытучысына. Ул аны гомер буена, котылгысыз бер җәфа урынына күреп, ничек кирәк алай, аннан-моннан башкарып килә.

Язгы-көзге кыр эшләре башланды исә, төрле җыелышларда телдән дә, матбугат аша да: «Инде эш башлануга кайчан, агитаторлар исә әле дә басуларга, механизаторлар янына чыгып та карамаган!» — дип тиргиләр. Баксаң, бу агитатор дөрес иткән, чөнки аларның басуда һич кирәге юк. Хәзер теләсә кайсы механизатор дөньяга карашының киңлеге, һәм белем дәрәҗәсе белән дә, теләсә кайсы агитатордан һич ким түгел. Ул мәгълүматны җитәрлек җыя. Аның өенә берничә исемдәге газета-журнал килә. Түрендә телевизор утыра. Шулар өстенә ул еш кына үзе белән радиоалгыч йөртә. Безнең хөрмәтле агитаторыбыз исә аны эшеннән вакытсыз бүләргә, ачуын китереп кенә йөрергә тиеш була бит.

Механизаторны: «Яхшырак эшлә!» — дип өндәү дә кирәкми, чөнки хәзер ул эшенә карата акча ала.

Фикерне үстереп әйтсәк, һич кирәкмәгән мәшәкатьләр «табып» без күп вакыт исраф итәбез, гаять зур чыгымнар тотабыз. Әйтик, бүген район ничәдер мең гектар мәйданда чәчү үткәрде, ди. Механизаторлар тир түгеп эшкәрткән шушы гектарлар тагын әллә никадәр кешенең һич кирәкмәгәнгә тир түгүенә китерә әле. Иртәгесен, кара таңнан район үзәгендәге телефоннар шалтырый башлый. Район үзәгенә шушы гектарлар хакында мәгълүмат җыялар. Һәр колхозга һәм совхозга шалтыратып, теләс-ә нинди сөйләшүләрне өздереп торып. Бу гектарлар берничә дистә сводкага төшерелә. Ул сводкалар район җитәкчеләренә таратыла. Янәсе, алар районның ничә гектар чәчкәнен белеп торсын!

Нәкъ шушындый ук тәртиптә, шушы ук мәгълүматларны икенче төркем «эш кешеләре» Казан каласына да җыя. Шундый ук сводкалар ясала. Инде республика буенча. Республика җитәкчеләре белеп торсын өчен.

Хәзер әйтегез: түрәләрнең бу мәгълүматны белү-белмәвеннән нәрсә үзгәрә соң? Уңыш артамы? Тормыш алга китәме? Юк. Юк. Юк. Әле, җитмәсә, ул сводкалар төгәл дә булмый, чөнки, бердән, хуҗалык җитәкчесенең үзе тоткан юлы, үз хәйләсе бар, икенчедән, басуларда хәл сәгать саен зур темплар белән үзгәреп тора.

Бүгенге игенчедән берниндн темп та, гектарлар да таләп итү кирәкми. Үзләренә тапшырылган җаваплылыкны игенчеләр үзләре дә яхшы белә. Бу четерекле хезмәтнең нечкәлегеен белмичә бирелгән күрсәтмәләрнең исә уңышка зыян салуы гына ихтимал.

Һәр район үзәгендә авыл хуҗалыгы белән идарә итә торган зур команда-административлык аппараты бар. Анда агрономнар, зоотехниклар, ветеринарлар, инженер-механиклар — барысы да авыл хуҗалыгы белгечләре. Аларны, маңгай тире түкмичә, җиңел генә тамак туйдыралар, дип, һич кенә дә битәрләп булмый. Кайда ул: ничә керсәң, яннарына килерлек түгел — баш күтәрми эшлиләр, вакытлары тар. Һәм шуннан тагын бер гаҗәп хәл килеп туа. Нәкъ шундый ук аппарат, тик бераз кечкенә күләмдә, һәр колхозның үзендә дә бар. Шул ук ветеринар, зоотехник, агроном, бухгалтер, инженер, механик. Белемнәре дә нәкъ бер дәрәҗәдә, бер үк институтта укыганнар. Гади генә әйткәндә, бу ике аппарат берсен-берсе кабатлап утыра.

Санап карый белмибез шул без, җәмәгать. Болай, аппарат өстенә аппарат утыртып ничек алга киткән илләргә тиңләшә алыйк?! Өем-өем кәгазь белән азык-төлек артмый бит ул. Инде бу турыда сүзләр дә күптән бара, тик үзгәреш кенә юк.

Исәпли башласаң, мондый бер-береңне кабатлау күренешләре бездә бик киң таралган. Бик югары күтәрелмичә, районга гына күз салыйк. Район җитәкчеләренең, кагыйдә буларак, ике, хәтта өч урынбасарлары бар. Биләгән бүлмәсе, персональ машинасы, шоферы, түгәрәк кенә эш хакы...

Әлбәттә, урынбасарлар да бүлмәләрендә эш юклыктан аптырап утырмыйдыр, әмма җитәкчедән узып, бер генә мәсьәләне дә хәл дә итә алмый алар. Урынбасар никадәр тырышмасын, соңгы сүзне һәрвакытта да җитәкче әйтә. Нәрсә килеп чыга? Шул ук гап-гади кабатлау. Бу — әлеге дә баягы, байлыкны җилгә очыру, акланмаган чыгымнар. Менә монысы анык — җентекләп өйрәнелергә тиешле мәсьәлә.

Хәзерге көндә исә урынбасарлар үз урыннарында, кем әйткәндәй, чәчәк атып утыралар. Исәпли китсәң, безнең илебездә алар — зур бер армия. Асылда алар җитәкченең киң аркасына ышыкланганнар. Дөньяның бер чите җимерелеп төшкәндә дә, ахыр чиктә, җавабын алар тотмый, җитәкче тота. Җитәкчеләр алмашынып, гаепләнеп, тагын әллә ниләр эшләп бетә, урынбасарларга берни дә булмый.

Алар — үзенә аерым бер катлам. Алар, кагыйдә буларак, барысы да, үзләренә тиешле булган мөмкинлекләрдән тулысынча файдалана. Кайберләре хәтта җитәкчеләреннән дә уздырып җибәрә. Барысы да дәүләт исәбенә салынган аерым йортларда тора, бу йортларны аулак, тыныч урыннарга салдыра. Кибетләргә дә арткы ишектән генә йөри. Безнең җәмгыятебез үз җилкәсендә шундый зур төркемне асрый.

Моннан егерме биш еллар элек мин Уралда, зур бер төзү трестының тимер юл транспортында эшләдем. Шунда минем белән бергә эшләгән машинист паровоз будкасы стенасына ниндидер сызыклар сыза башлады. Үзе авыз эченнән генә нидер исәпли. Мин аннан бу сәер гамәлен аңлатып бирүен сорадым.

— Безнең трестта эшләгән бер кешегә команда биреп торучы ничә зат туры килә икәнен исәплим мин. Өч эш кешесенә бер әрәмтамак чыга икән,— диде ул.

Күбрәк бит инде бу, җәмәгать! Һәм мин ул заманнардан бирле хәлнең үзгәргәнен дә күрмим әле. Тормыш дәрәҗәсен күтәрергә әнә шушындый нәрсәләрне берәмтекләп исәпләп тотынмаска микән?!

Әйе, без үткән юл нәкъ кытырлы бәләк кебек: Төрле сынап караулар, гаять аянычлы ялгышлар, шәхес культы имансызлыклары, коллык хәле, әчүчелек дигән афәтнең чәчәк атуы... Барысы да — муеннан. Менә хәзер инде, ходайга шөкер, без боларның барысын да аңлап белдек. Үзеңнең үткән юлыңа азмы-күпме дөрес бәя бирә алу — бу инде шактый зур нәрсә. Моннан инде тиешле нәтиҗә ясарга, үзеңне азрак үзгәртә, яхшы якка борылыш ясый башларга да мөмкин.

Менә шушында килеп җиткәч исә, безнең көймәләр тагын комга терәлә. Ник дигәндә, үзгәрешебез бер дә күренми шул әле. Турысын гына әйткәндә, яхшы якка үзгәрә башлый да башламадык. Соңгы ике елда тәртип ягыбыз йомшый гына төште безнең.

Һәм моның конкрет сәбәбе бар. Ничәмә еллар буена безнең өстә йодрык б... янап, безне өркетеп, үзебез аңлап та бетермәгән бер көч торды. Һәм менә шушы куркыныч бастырык, кинәт дип әйтерлек, юкка чыкты. Без ниндидер бер тар кыршау кысуыннан котылгандай булдык, бердән иркенәеп киттек. Без теләсә нинди хәл турында дөресен сөйли ала башладык. Безгә чын ирек килде!

Бәла шунда ки, без шушы иректән файдалана белмибез. Берәүләр ирекка чыктык, дип, бер чиктән икенче чиккә авыша, икенчеләр, аны тәртип йомшаруы, дип кабул итә, үзенең тискәре максатларында файдалана. Өченчеләр исә... битараф. Арабызда хәтта элеккеге чыбыркылы заманнарны сагынучылар да бар.

Барыбыз бер фикергә килеп, барыбыз тәртипкә, намуслы хезмәткә омтылсак, хәл дә тизрәк яхшырыр иде. Һәркайсыбыз үзгәрергә тиеш икәнне, һәркайсыбыз ихластан тырышып эшләсә генә, адәм рәтле яши башлаячагыбызны аңлап бетерә алмыйбыз.

Тәртип, димәктән, нәкъ менә шушы тәртип, дөресрәге аның булмавы, әллә никадәр зыяннар китерә безгә. Тракторчының үзе сукалаган җиргә, аның нинди уңыш бирәсенә битараф булуыннан, хезмәт тәртибенең гади таләпләрен дә үтәмәвеннән басулар начарая. Агрономның үз вазифаларына салкын каравыннан әлеге начар эшкәртелгән басуларга начар орлык чәчелә. Шуннан инде, билгеле, уңыш түбәнәя. Әле ул барлыюклы уңышның да күпмесе, амбарга кермичә, әрәм-шәрәм булып бетә.

Техника җитәрлек. Игеннәрне җыйнап алуга, басуларны кабаттан сукалап та куялар. Шунда, яңгырлар да явып үткәч, басуларга бер күз салсагыз иде сез. Аларны ямь-яшел уҗым каплаган була. Нәкъ яңадан да бер чәчү үткәргән кебек. Исең китәр. Ашлыкны урып алганда шулкадәр күп орлык коелып калган...

Инде терлекчелеккә игътибар итеп карыйк. Колхоз һәм совхозларда ел тәүлегенә үлгән терлекләрнең бәясе меңнәрчә сумнар белән исәпләнә. Крестьянның үз хуҗалыгында исә терлек үлү очрагы — гадәттән тыш сирәк хәл. Колхоз терлекләре бары тик аларны карауичыларның битарафлыгыннан, җитәрлек ашатмавыннан, вакытында сугармавыннан кырыла.

Һәр фермада эчке тәртип кагыйдәләре бар. Алар буенча, терлекләр билгеле сәгатьләрдә ашатылырга һәм савылырга тиеш. Чынында исә сыерларның вакытында ашатылмавы, кайбер көннәрдә бөтенләй савылмый да калуы еш очрый торган хәл. Моңа беркем дә, хәтта җитәкчеләр дә артык борчылмый.

Сөт саву аппаратлары, савытлар юньләп юылмый. Алар чиста түгел. Тирес вакытында чыгарылмый. Сыерлар тирес өстенә яталар, пычраналар. Дуңгыз фермаларында яшь үрчемнең үлү очраклары — муеннан.

Бу — нәрсә? Бу бит — терлекчелекнең үз вазифаларына чиктән тыш ваемсыз каравы, үзебезнең байлыкка вәхшиләрчә карау бу. Бәс, шулай икән без ничек иттереп алга киткән илләрдәгечә мул яшик инде?!

Күзен берәр колхозга килеп төшсәң, мондый хәлгә шаһит булуың ихтимал. Комбайнчы агай үзенең комбайнын алып кайтып, машина-трактор паркына куйган. Алабута һәм әрем баскан бер урынга. Комбайнның ургычы — җирдә, каешлары салынмаган, барабаннары, иләкләре, башка механизмнары ашлык калдыкларыннан чистартылмаган. Тәгәрмәчләр бушаган, шиннары бүселеп чыккан. Комбайн — җил һәм яңгыр хөкемендә. Кыскасы, уннарча мең тәңкәлек машинаны комбайнчы агаебыз ташлап киткән. Рәхимсез рәвештә. Күгәрергә, черергә, исрафлыкка.

Кыш көне, чаңгыда йөргәндә, колхоз басуларында яртылаш карга баткан чәчү машинасына, культиваторга яисә тырма агрегатына юлыгасың икән, бу — бер дә гаҗәп хәл түгел.

Менә шулай шул. Без шведлар яисә финнарның әйбәт яшәвенә гаҗәпләнәбез. Ә үзебездә меңнәрчә сумлык байлыкның әрәм булуына исебез дә китми. Күнеккәнбез

Юк, җәмәгать. Үзебездә чын хуҗа хисе тәрбияләми торып без бер вакытта да алга киткәннәргә тиңләшә алмаячакбыз.

Безнең хәтта бер-беребезгә мөнәсәбәтебез дә коточкыч бит. Урамга чыксаң, тирә-якта кешелегеңне кимсетә, мәсхәрәли торган сүгенү сүзләре, кычкыру-акыру гына ишетәсең. Автобусларда, трамвайларда этеш-төртеш. Кибетләрдә, мунчаларда, ашханә-рестораннарда тоташ дорфалык. Нәтиҗәдә — кәефебез кырыла. Кәефнең нинди булуы — бу бит экономик күрсәткеч тә әле. Әйе! Син күңеле төшенке, ачулы кешенең эшен кара да, күтәренке, хөр күңелле, шәп кәефле кешенең эшен кара. Алар башкарган эштә һәрвакыт зур аерма була. Күтәренке күңел белән башкарылган эш әллә кайдан көлеп тора кебек.

Безнең тормыш — көнкүреш рәвешебез дә мактанырлык түгел. Күбәүләр мондый

фикердә тора: аның ничек яшәве, тәмәке тартуы, аракы эчүе, сырхавы — аның үз эше. Ай-һай алай гына түгел икән шул. Безнең һәрберебезнең яшәү рәвеше җәмгыятькә тәэсир итә. Алга киткән илләрдә тәмәке тартмаган эшчеләргә, мәсәлән, эш хакына өстәмә түлиләр икән. Хәзер кайбер илләрдә тартмаучыларга хәтта өстәмә ял бирелүе турында да хәбәрләр бар. Аракы эчүченең җәмгыятькә зур зыян салуы һәммәбезгә билгеле. Эчкече кеше тиз арада авыруга сабыша, хезмәткә яраксыз хәлгә килә. Ахырында җәмгыять җилкәсендә яшәргә мәҗбүр була.

Инде икенче яктан фикер йөртик: без үз-үзебезне ныгыту белән шөгыльләнәбезме? Физик күнегүләр ясыйбызмы? Безнең Арчада мәсәлән, иртән йөгерүчеләр, паркта гимнастика ясаучылар берән-сәрән күренгәли. Берән-сәрән, уныч меңле Арчадан шулкадәр аз! Саный китсәң, безнең поселок халкының 0,1 проценты гына физкультура белән шөгыльләнә торгандыр. Бу яктан да культурабыз бик түбән булып чыга бит.

Үзебез шундый икән, безгә алга киткән илләр тормышына кызыгып яшәргә генә кала инде. Менә бит, шайтан алгыры, уйлый башласаң, фикер әллә кайларга китә. Без — тәртипсез, без — уңмаган, оешмаган, без яшәргә өйрәнмәгән, өйрәтүчесе, күрсәтүчесе дә булмаган...

Минем күп еллардан бирле бергә эшләгән хезмәттәшем бар. Ул Арча педагогия училищесын тәмамлаган, аннан югары партия мәктәбендә укыган. Күп еллар буе райком аппаратында эшләгән. Дистә елга якын бездә редактор булды.

Әгәр, дөньяда бер могҗиза булып, без иртәгә барыбыз да үзебезнең культура дәрәҗәбез, әхлак, этика кагыйдәләрен үтәвебез белән минем шушы хезмәттәшемә тиңләшә алсак, иртәгә үк ил күләмендә зур үзгәрешләр ясарга мөмкин булыр иде.

Беренчедән, милиция, суд, прокуратураның бөтенләй дә кирәге калмаячак. Чөнки минем хезмәттәшем һич тә җинаять ясардай кеше түгел. Ул тәмәке тартуны, аракы эчүне гомере буена белмәде. Хезмәт урыныннан бер генә тапкыр да үзе өчен файдаланмады. Мөмкинчелеге бар иде. Ул үз вазифаларына безнең беребез дә булдыра алмаган дәрәҗәдә намуслы карады. Ун ел бергә эшләү дәверендә мин аның кемгәдер тупаслык күрсәткәнен, кемне дә булса уңайсыз хәлгә куйганын да хәтерләмим. Ул һәркемгә ихтирамлы. Ул — чын мәгънәсендә кеше.

Әмма... минем әлеге хезмәттәшем кебек башка берәүне безнең Арчада башка белмим. Һәм моны күпләр әйтә: «Бөтенебез дә андый булса, без әллә кайчан инде коммунизмда яшәр идек»,— диләр.

Менә бит, күп тә кирәкми кебек.

Ә алай да без, җәмәгать, киләчәккә өмет белән карыйк әле! Без Сталин культы еллары, торгынлык еллары итәккә тегеп куйган иске-москыдан, әшәке гадәтләрдән, ялкаулык һәм битарафлыктан котылырбыз. Ихлас күңелдән тырышсак, без, чын мәгънәсендә, хуҗалар булырбыз. Уңган һәм бай хуҗалар. Илгә, һичшиксез, бәрәкәт иңәр. Шуңа ышанып тырышыйк!

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Тәүфикъ Әйди

## ХАКЫЙКАТЬКӘ ЯҢА АДЫМ

Менә тагын бер әдәби ел узып китте. Без шул вакыт эчендә замандашларыбыз күңелен дулкынландырырлык яңа әсәрләр барлыкка китердекме? Нинди хакыйкатьләрне ачуга, тарихи үткәнебезгә ни дәрәҗәдә тирән тамыр җибәрүгә, киләчәгебезгә ни дәрәҗәдә ерак күз ташлауга ирештек? Яңа әдәби хәзинәбез узганны тулырак танып-белүгә, аннан гыйбрәт алуга, киләчәкне иреклерәк һәм матуррак коруга булышырлыкмы? Фикер йөртүдә һәм гамәл кылуда ачылган хөрриятне без ни дәрәҗәдә файдаланабыз? Милләтебезнең сәламәтлеген ныгыту, аның тормыш офыгын киңәйтү, яшәү дәртен үстерү, мәңгелеген тәэмин итү, кеше рухының бөеклеген раслау өчен без нәрсәләр эшләдек соң?

Бу сорауларга җавап бирү өчен 1989 елгы прозабызның кайбер үрнәкләрен — уңышларыбызны һәм җитешсезлекләребезне калку күрсәтә торган әсәрләрне күздән үткәрик.

«Ата-бабадан калган эзләрне югалту адашуга дучар итә. Тарихның артта калган юллары никадәр җете күренсә, алдагы офыклар да шулкадәр киңәйгән, киләчәккә юнәлгән була. Үткән заман тәҗрибәсе белән коралланмыйча, сәламәт киләчәккә барып булмый»,— ди М. Юныс «Европа ат сагына» повестенда.

Мондый фикерләрне М. Юныска кадәр Геродот, Плутарх, Цицерон, аларга кадәр һәм алардан соң яшәгән тагын бик күп без белмәгән һәм белгән акыл ияләре дә әйткәнлектән, матур әдәбиятта тарихи жанрның үсеше бик әһәмиятле булуына ышанырга туры килә. Шуңа да карамастан, бу жанр татарда бик соң туды. Туганнан соң да әле уңайлы шартка очрамады: «Әтил суы ага торыр» романын язган Н. Фәттахны әдәбият чиновниклары һәм аларның койрыклары хан заманыннан безнең көннәргә кайтырга кызып-кызып өнди башладылар. Дәртен шулай сүндерү аркасындамы, ул үзенең нәүбәттәге тарихи романын унике елдан соң гына тәмамлый алды. Шөкер, үзгәртеп кору җилләре бу тармакка да үтеп керде: халкыбызның үткәнен гәүдәләндерергә керешкән М. Хәбибуллинны ниятеннән сүтәргә омтылу күзгә-башка чалынмады, «Кубрат хан»ны тәгәлләвенә биш ел тулганда, автор үз укучыларына «Илчегә үлем юк» тарихи романын тәкъдим итте.

«Тамырсызлык — искиткеч куркыныч рухсызлыкка алып бара торган нәрсә... Рухсызлык — хайванлыкка кире әйләнеп кайту өчен салынган шома һәм туры юл»,— ди М. Юныс.

Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Илчегә үлем юк» романы тамырларыбызны ача, ата-бабаларыбызның 1177—1186 еллардагы тормышын гәүдәләндерә, безне татарның бәхетле вакыты — тәхетле вакыты белән таныштыра. Димәк, ул эчтәлеге белән күтәп алынган бик тансык әсәр. Дөрес, борынгы дәверебезне яктырткан башка романнарыбыз кебек, «Илчегә үлем юк»ны да «тарихи» дип билгеләү читенрәк, чөнки татар В. Скоттлары, Л. Фейхтвангерлары файдаланырлык ханлык дәвере архивларыбыз сакланмаган, фән тарафыннан ни Казан, ни Болгар дәвере җитәрлек күләмдә өйрәнелмәгән. Мондый шартларда әдипләребез ата-бабаларыбыз тормышын якынча сурәттә генә «тарихи» гәүдәләндерә ала. Әмма алар шул заманның асыл вакыйгаларын, типик характерларын дөрес, сәнгатьчә оста ачып салса, безгә, һичшиксез, тамырларыбызны күзалларга булышачак. Ул очракта инде туган халкыңа береккән шул тамыр аша безгә М. Юныс әйткән «рухи ашлама, җан азыгы» киләчәк.

Бөек Болгар дәүләте без гасырлар буе горурланачак ике зур казанышка ия була — ул Көнбатыш Европа илләреннән ике йөз ел элек югары сыйфатлы чуен коя, Рейн, Сена елгалары үзәнлегендә вәхшәт, каннибализм хөкем сөргәндә, кеше рухының мактанычы булырлык гүзәл «Кыйссаи Йосыф» әсәрен иҗат итә. Ата-бабаларыбыз менә шушы ике бөек казанышка XII йөз ахыры — XIII йөз башында ирешә. Тарихыбызның алтын дәвере бу. М. Хәбибуллин яңа романында менә шушы шанлы заманыбызны сурәтли. Авторның бай хыялы тарихи мәгълүматларга, риваятьләргә таянып, тимерче Әхмәт һәм аның улы Бәкерне,

алардан чуен кою серен урларга маташкан Владимир кенәзлеге һәм Хәрәзем ханлыгы шымчыларын, читкә кол итеп сатылган хан оныгы Галине, баһадир Бачман, Җик Мәргәннәрне бер сюжет җебенә үреп сурәтли. Романда ханлыкның дәүләт мәнфәгатьләрен, рухи мирасын саклаучы кәтип Хафиз, Болгарның мөселманлык, Шәрык мәмләкәтләре белән дуслык нигезендә үсүен кайгыртучы шәех Игәнәй, туган иленең бәйсезлеген ныгытырга омтылган вәзир Исхак тасвирлана.

Кыскасы, «Илчегә үлем юк» романы Болгар дәүләтенең уникенче йөз азагындагы төп сәяси, мәдәни, матди үзгәрешләрен, ул җәмгыятьтә төрле катлам, төркемнәр арасында барган көрәшләрне үзәккә алып сурәтли, болгар халкының сәламәт нигездә яшәвен, аның киләчәккә хакы барлыгын дәлилли, тарихи-милли аңны Атилла, Көлтәгин, Кубратлар эшчәнлеге белән бәйли, онытылган тамырларыбызны, ата-бабаларыбызның йолаларын, гореф-гадәтләрен җанландырып күрсәтә. М. Хәбибуллин бу әсәрендә дә үзенең сюжет кору остасы, художник икәнлеген раслый — әйтергә теләгән фикерләрен укучыны ялыктырмыйча, көчләмичә, каһарманнары гамәле һәм уе рәвешендә бәян итә. Әсәрнең төп реалистик канвасын халык иҗатына хас шигърилек, рыцарьлык романына хас авантюр мажаралар баетып җибәрә. М. Хәбибуллинның яңа романы тарихи тамырларны тоюга, киләчәгебезне озынайтуга уңышлы хезмәт итәчәк. Әмма «Илчегә үлем юк» романын авторның «Кубрат хан»нан соң иҗади үсеше дип әйтү кыен. М. Хәбибуллин беренче тарихи романын язганда бай катламга юлыга, шуннан алтын кантары табып ала. Икенче романында ул таныш катламны эшкәртә, аннан асылташлар килеп чыккаласа да, беренче табылдыктан кайтышрак була.

«Кубрат хан»да Рум иленә бару кызыклы һәм истә калырлык матур тасвирланса, «Илчегә үлем юк»та урыс кенәзлегенә сәяхәт, андагы сәяси ыгы-зыгы шулай ук уңышлы гәүдәләндерелгән дип әйтеп булмый. Монысында ялыктыргыч итеп исемнәр санала, вакыйгаларга ит кундырып җиткерелмәгән, романның ул өезе елъязмадан механик рәвештә күчереп алынган өлеш тәэсирен калдыра. Автор романтик күренешләрне, вакыйгаларны тасвирлау белән артык мавыгып, тәхет тирәге булган би-морзаларны, илнең алтын баганалары — һөнәрчеләрне, игенчеләрне реалистик рухта киңрәк гәүдәләндерү мөмкинлеген кулдан ычкындыра.

Романның теле дә дәгъвалар уята. Дөрес, әдәби телебезнең берьяклырак үсеше, «урам» шивәсенең югары стильне кысрыклавы, татар мәктәбе юкка чыга барган шартларда төрле тармак атамаларын булдыруга, телнең тарихи катламнарын саклауга игътибар бирелмәү нәтиҗәсе дә бу. Шулай да, Н. Фәттахның кыю һәм батыр, ипле рәвештә сүзлек хәзинәбезне баету эшчәнлеген күрмәмешкә тырышуны, аның табышларын файдаланудан качуны аңлавы читен. Әдәби традицияләргә ныграк таянганда, хан белән морзалар, шәех, вәзир һәм башка аксөякләр бүгенге шоферлар кебек, артык гади һәм тупас сөйләшмәс, шул заман буяуларын ачыграк чагылдырыр, әсәрнең ышандыру көче артыр иде.

«Илчегә үлем юк» романы, мәгълүм кимчелекләре күзгә ташланса да, үткәнебезнең «уникенче гасыр» дип аталган томанлы бушлыгын юкка чыгара, чын тарихыбызга кызыксыну уята торган әсәр.

Исеме алдарак кат-кат телгә алынган Миргазиян Юныс 1989 елда «Европа ат сагына» повестен бастырды. Бу әсәр аваздашлыгы белән дә, капма-каршылыгы белән дә М. Хәбибуллин романына бик табигый килеп ялгана. Жанры ягыннан ул повесть-эссе, повесть-репортаж. Әсәрнең мәгънә йөген автор үзе болай билгели: «Мин читтә йөреп, туган җиремнең, туган халкым татарларның югалган, җиргә күмелгән тарихларын эзлим. Ераккарак китеп читтәнрәк карасам, бәлки ерак бабаларым күмелгән курганнарның барысын да күрә алырмын? Бәлки халкымның яшәешен чит халыклар тормышы белән чагыштырып карасам, милләтемнең хәлен дөрес аңлый, аңлата алырмын?»— ди ул.

Шушы ниятен гамәлгә ашырып, ул борынгы бабаларыбыз кыпчакларның 1223 елда Калка елгасы буенда монгол яуларына каршы сугышуын, Киев шәһәре мәйданындагы төрки балбалларны, тамырында 75 процент кыпчак каны аккан кенәз Андрей Боголюбскийны, Петр I, Грозный, Бабыр патша дәверләрен, борынгы мәчетләрне һәм чиркәүләрне, диннәрне, төрле кавемнәрнең ышанулары, гореф-гадәтләре, йолаларын, матди казанышларын телгә ала, аларның әһәмияте, мәдәниятләр язмышы, татарларның үткәне һәм бүгенгесе турында фикер йөртә. «Татар милләтенә бүтәннәр белән тиң һәм бәхетле яшәр өчен ни җитми?»— дип баш вата.

М. Хәбибуллин прозабыз җегәрен вертикаль буенча ерак үткәннәргә юнәлтсә, М. Юныс аны горизонталь буенча ерак киңлекләргә җәя. Диңгезче әдип тынгысыз хәрәкәттә, без аның ярдәмендә яңадан-яңа илләргә аяк басабыз, яңадан-яңа вакыйгалар, типлар белән танышабыз. Татар укучысы М. Юныс повесте аша дөньяның, заманыбызның йөрәк тибешен планетар масштабта тоя, зиһенен, хисләрен баета. Хемингуэй каһарманнары эчләрен ни белән юа? Фән кандидатын нинди гәп белән кызыксындырырга мөмкин? Инглизләр Һиндстанны ничек кулга төшергән? «Европа ат сагына» повесте әнә шундый әкәмәт серләрне дә ача, укучыны көтелмәгән күзәтүләре, ачы гыйбрәтләре белән әсир итә.

Повестьның үзәгендә игътибарны тарткан ике каһарман бар: берсе — моторчы Сус-

ликов, икенчесе — лирик герой, автор үзе. Тискәре һәм уңай башлангычларны шушы ике зат үзенә туплаган. Сусликов икейөзле нахал, тупас ялганчы, затсыз бушбугаз. Аның ышануынча, кешеләрне «уртак наданлык берләштерә». Пикуль китапларын уку, күн куртка, джинсы чалбар кию, сыра эчүдән дә яхшырак, затлырак эш юк, дип саный ул. Чиркәү — әйбәт, мәчет — начар, мөселманлык — хорафат, христианлык — культура, кешене алдау — чаялык билгесе, музейларга йөрү — юкка баш катыру, аныңча.

Лирик герой исә һәр нәрсәдән гыйбрәт ала, акыл җыя. «Яулап алган халык мантымый», дигән икән борынгы Рим шагыйре Луцилий. Югославиянең Сарай шәһәре тирәсендә «татар тәкъдирендәге шикелле упкыннар» бар, имеш. «Бала-чагасыз бәйрәм тозсыз ашка охшый», «кыйбласызлар алласы — аракы, урлашу, үйнаш»...

М. Юнысның повесте әнә шундый күзәтүләр, гыйбрәтләр белән тулы. Күз алдыннан кораб капитаннары, механиклары, штурманнары, матрослары, порт хезмәткәрләре үзә, аларның байтагына шулай ук шәхси холык-фигыль, сыйфатлар бирелгән, шуның аркасында истә калырлык каһарманнар әсәрдә байтак.

«Европа ат сагына» повестен — үткән белән бүгенгене берләштерә, күңелгә күп ваем, уйлар сала, татар прозасын яңа тирәлек, яңа геройлар белән баета торган кызыклы фәлсәфи әсәр, Сусликов образын исә прозабызда яңа бер каһарман дип санарга кирәк.

Табигатьне, аерым алганда, туган телебезне, гореф-гадәтләребезне, матди һәм рухи мәдәниятебезне, димәк, тулаем милләтебезне саклау бүген безне иң нык борчыган мәсьәлә булып кала. Мөхәммәт Мәһдиевнең «Бәхилләшү» повесте менә шушы теманы ачуга багышланган.

Язучы гомере буе бер китап иҗат итә — яңа әсәре саен ул аның яңа бүлекләрен, яңа вариантларын гына барлыкка китерә, диләр. «Бәхилләшү»не укыганда, бу фикернең Мәһдиев иҗаты белән дә раслануын күрәбез. Ул әсәрдән-әсәргә утызынчы-кырыгынчы-илленче еллар татар авылын, аның яңадан-яңа күренешләрен, каһарманнарын сурәтли. Нәүбәттәге әсәрен укыгач, Казан артында ул телгә алмаган авыл, урам, елга-күл, кыр-ялан, абзар-кура, йорт-җир, сәлам эскертләре, ул сурәтләмәгән бала-чага, карт-карчык, игенче-терлекче калмагандыр инде, дип уйлыйсың. Менә әдип яңа әсәрен тәкъдим итә — «Бәхилләшү»дә ул тагын шул ук Гөберчәк авылы, Кесмәс елгасы тирәсенең табигатен, кешеләрен, анда аккан тормышны тасвирлый, күпләр аның бу әсәрен дә яратып укый, сурәтләнгән вакыйгалардан, каһарманнардан тую кайда, әсәрне бер утырганда йота — шул чакта елмаеп, көлеп җибәрә яки, күз төбен дымландырып, Мәһдиев гәүдәләндергән язмышларны кабаткабат күңеленнән кичереп, уйланып күңелен йомшарта.

Автор әсәрнең жанрын «моңсу повесть» дип билгеләгән. Хикәяләү мәгънәсендә шулай атарга да була, анда, чыннан да, моң күп. Шул ук вакытта бу әсәрне этнографик очерк, истәлек, эссе дип танытырга да мөмкин.

Повесть эчендә 300 юл шигъри цитата китерелә — «Бәхилләшү»дән дөнья әдәбияты буенча шактый тулы мәгълүмат алырга була. Чалгы саплау, бәрәңге пәрәмәче пешерү, мунча ягу, төш күрү һәм төш юрау, сәлам эскерте исе, көрәш, сайлау уены, бию кичәсе, велосипед җене, кошлар гадәте, тагын-тагын әллә нәрсәләр тасвирлана бу әсәрдә. Нигә матур әдәбият санала ул, нигә аны олы да, кече дә егылып укый? Саташып та куя ич әле автор — әйтик, кыярны бездә сентябрь уртасында тозламыйлар, алдаша Мәһдиев! Исламгалинең борчак сибүе дә яңалык түгел, Г. Афзал андый егетне әллә кайчан сурәтләде инде. Шулай икән, «Бәхилләшү»нең нинди тылсымы әсир итә соң укучыны?

Япун Яһүдин. Туган телен оныткан Фәләхетдин. Көтүче Мөбәрәкша. Капъйот Хәмдүнәләр — повестьта бер-берсенә охшамаган күпме кеше гәүдәләндерелә, укучыны шулар көлдерә, шулар сызландыра. Затлы гадәтләргә ия кошлар — әхлаксыз кешеләр. Кичке уеннарда җырлап-биеп, яңгыр шыбырдавына, таң сызылуына сокланып яшәүче утызынчы ел яшьләре һәм аларның матай тырылдатуга, магнитофон үкертүгә күчкән дәвамы. Әүвәлге тәзек йорт-җирле, мал-туарлы, эшле бала-чагалар, мәчетле авыл һәм аның тузанлы, иманы кимегән бүгене. Иген-тару тулы ындырлар, бер телем ипигә тилмертүче түрәләр, туган нигезеннән нахак сөрелгән ир-егетләр. Атасыз калу сагышы, юаш малайны газаплау... Кемнәр генә, нинди генә вакыйгалар тасвирланмый «Бәхилләшү» повестенда.

Әсәрнең уңышы, беренчедән, халыкчан образлы телдә язылуында. Икенчедән, каһарманнар һәм вакыйгалар сәнгатьчә детальләр аша оста гәүдәләндерелә. Билгеле, М. Мәһдиевкә хас кыланчыклык, үз-үзенә соклану һ. б. сыйфатлар лирик геройга да күчкән. Тормышта авторны әнәмәүгә генә хезмәт иткән бу сыйфатлар әсәргә үзенчәлекле ямь, киеренкелек өстәгән һәм аның укылышын көчәйткән. Повестьның фикергә, уйлануларга бай булуында да уңыш сере. Чынлыкта, менә шушы өченче сыйфат Мәһдиевнең иң әһәмиятле казанышы да, кимчелеге дә булса кирәк. Чөнки ул, фикер йөртү белән мавыгып, образларны еш кына шул фикерне әйтү яки раслату өчен генә тартып-сузып барлыкка китерә кебек.

«Бәхилләшү» — милләтебезнең нигезе булган татар авылын бөтен рухын, исен-төсен, тарихи канвасын, моңын-авазын саклап, талантлы каләм тарафыннан гәүдәләндерелгән повесть. Шушы нигезнең таркалуы, тузуы, гореф-гадәт, йолаларның юкка чыгуы, бер-ике

буын тормышы дәвамында гасырлар буе яшәгән мохитнең бозылуы, халкыбызның, ул яшәгән тирәлекнең дә фәкыйрьләнүе турында мәрсия.

Мәһдиевнең башка әсәрләре кебек, «Бәхилләшү» повесте да, әйткәнемчә, яратып укыла, күңелдә бай тәэсирләр уята. Ләкин аның хакында хәтердә тулаем матур фикер саклanса да, повестьның конкрет каһарманнары һәм аларның кылган гамәлләре бер атна эчендә үк истән чыгып бетә. Яхшы әсәр эзенең күңелдән болай тиз эрүе бик сәер. Нигә шулай икән ул?

Минемчә, бу хәл М. Мәһдиевнең татар прозасында ялгызына хас импрессионистик алымда язуына бәйләнгәндер. Ул искиткеч хәтергә, телбизәкләр, детальләр байлыгына ия, ләкин шуларны бер кечкенә повестьта да йөзләгән каһарманга сибеп ташлый. Повестенең һәр бите, Сорочи базары кебек, халык белән кайнап, мыжгып тора. Ул җан ияләренең берсе керә, икенчесе чыга, өченчесе ишек кага — әсәрнең буеннан-буена өзлексез дәвам иткән бер вакыйга, күз алдыннан бер дә югалып тормаган бер персонаж юк. Салават күпередәй буяулар төрлелеге күзне камаштыра, чыр-чуы колакны тондыра, еш-еш алышынулар хәтерне йончыта, игътибарны чәчә. Мәһдиевнең фикер әйтергә, уйлануга комарлыгы башка прозаикларыбыз янәшәсендә мактауга лаек булса да, фикер әйтү яки раслату өчен кертелгән образлары рупор итеп кенә файдаланылганлыктан, алар камил һәм калку гәүдәләндерелми. Күбәләк гомере генә яшәгән ул геройлар, нинди генә күз явын алырлык кыяфәттә, сокландыргыч хәрәкәттә сурәтләнмәсен, бик тиз хәтердән җуела.

Сюжет чынбарлыкны шартлы рәвештә оештырып гәүдәләндерә, һәрвакыт мәгълүм дәрәҗәдә ясалмалыкка юл ача. Шул ук вакытта ул каһарманнарны эзлекле бәйләнешләргә кертә һәм аларның холкы ачылуга, әлеге бәйләнешләр кысасында укучы хәтерендә тирәнрәк эз калдыруга сәбәп була. М. Мәһдиев сюжет корудан ваз кичеп, укучы тойгыларына, аңына тагын да көчлерәк тәэсир итү тылсымыннан коры кала, минемчә. Бу югалтуны таң калырлык чичәнлек, әсәренең һәр битенә мәзәкләр, җырлар, мәкальләр, маҗаралы кыйссалар — төрле энҗе-мәрҗәннәр сибү генә тутырып җиткерер микән? Сюжетлы әсәрләр яза, каһарманнарны тирән, дәвамлы сурәтли, басылып эшли торган әдип, әгәр Мәһдиевтәй күзәтүчәнлеккә, нык хәтергә, йөгрек уйлау, юмарт тасвирлау сәләтенә һәм тирән белемгә ия булса, «Бәхилләшү»дән, мөгаен, берничә роман яки дүрт-биш повесть иҗат итәр иде. Әнә шундый прозаик сыйфатларына да ия булса, Мәһдиев үзе әдәбиятыбызны Европаның киң мәйданына алып чыгып, дөнья күләмендә танытыр иде. Ләкин чынбарлыкта хәл башкача шул. Шуңа да карамастан, без бүген булган Мәһдиевкә шатланырга, «Бәхилләшү» өчен аңа рәхмәт әйтергә тиеш.

Күренекле прозаигыбыз Аяз Гыйләҗев, берничә ел «күмәк хуҗалык»та эшләгәннән соң, быелтыр «шәхси биләмә»сенә әйләнеп кайтты һәм «Казан утлары»нда «Яра» повестен бастырды. Повесть жанры аның яратып эшкәртә һәм мул уңыш ала торган басуы. Автор бу басуны, ата-бабадан килгән тәҗрибәле игенче кебек, җиренә җиткереп сукалый, тырмалый, ашлый, сайланган әйбәт орлыклар чәчә, чүп үләннәре шытып чыгуга юл куймый.

«Яра» повесте халкыбыз тәненә, рухына сугыш салган җәрәхәтләрне гәүдәләндерә, ул җәрәхәтләрне сталинчылык җәбере тагын да тирәнәйтүен сурәтли. Шәкүр солдатның фронт, әсирлек, партизанлык гарасатларын исән-имин узуын, рухын төшермәвен, ватанына кайткач фашистларныкыннан да дәһшәтлерәк Сталин лагерьларына сөрелүен, анда мең үлеп, мең терелүен, һаман яшәргә тырмашуын, ләкин шул зәгыйфьләнгән, хәлсезләнгән дәверендә кабат НКВД ятьмәсенә эләгүен һәм шунда күздән югалуын тасвирлый автор. Танкист Габдулла язмышы да үтә авыр.

Сугыштагы, госпитальдәге солдатларны матур гына тасвирласа да, минемчә, А. Гыйләҗевнең төп уңышы фронт, госпиталь фаҗигаләрен, каһарманнарының анда татыганкичергәннәрен сурәтләүдә түгел, кешенең теләсә кайчан һәм теләсә нинди шартта гаделлек, вөҗданлылык, сабырлык, чыдамлык, шәфкатьлелек, ярдәмчеллек, хезмәт сөючәнлек кебек төп күркәм сыйфатларын тирән ачуда, әнә шул асыл сыйфатларны үзенә туплаган Сөләйман картны һәм Зөләйха корткaны, яшьлеге кырыс заманга туры килгән Зәйтүнә белән Габдулланы күзләргә яшь китерерлек итеп гәүдәләндерүдә, аларга сокландыруда, аларны кызгандыруда. Габдулланың туган нигезенә кайтып керүе, ата-анасы танымагач, аннан кире чыгып китүе, Зәйтүнәнең сөйгәне Габдулланы шулай ук танымавы һәм тагын кайбер күренешләр безнең нервларны ифрат киеренке хәлгә китерә, күңелебезне әчеттереп-әчеттереп чеметә — чын сәнгатьчә язу менә шулай буладыр инде ул, күрәсең.

«Яра» — халкыбызның фаҗигале язмышын, аның яшәүгә булган мәңге сүнмәс омтылышын, әхлакый сафлыгын, рухи ныклыгын бер фокуска матур итеп туплап күрсәткән җитди әсәр. Сөләйманның нәселен дәвам итү кайгысы, аның эчтән көюе, горурлык һәм тотрыклылык саклавы, Зөләйха корткaның сабырлыгы, үзен хәвефкә дучар кылып, бүтәннәр гомерен, иминлеген саклап калырга омтылуы, шушы мөнәсәбәтләрнең кычкырып, чекрәеп бәрелми торган рәвештә сурәтләнүе, әмма укучы күңеленә нык сеңәрлек төстә язылуы А. Гыйләҗевнең татар тормышын, каһарманнарын милли холкы-халәте, сыйфатлары һәм буяулары белән җанландырып күрсәтә алуы хакында сөйли. Автор моңа ирешер өчен туган җиребез табигатен, гореф-гадәтләребезне, ырым-сынамышларыбызны, җырларыбызны

оста эшкә җигә. «Яра»да татар хәяте, тереклегебез тамырлары, киләчәгебез, шуларга бәйле сагышыбыз, өметләребезне гәүдәләндереп, укучыларны уйландыра, үткәненә һәм иртәгәсенә күз салырга, баш ватарга этәрә, үкендерә һәм рухландыра. Тискәре каһарманнарына да җан өрә, аларның гамәлләренә, омтылышларына җете карарга, тормышларыннан гыйбрәт алырга оеткы сала.

«Яра» — гуманистик әсәр, халкыбызның киләчәге булуга ышаныч уята, иманны ныгыта торган повесть. Тәүбәгә чакыра, сафлыкка өнди торган куәте бар аның.

Повесть бик кызык һәм сәер җөмлә белән тәмамлана. Габдулласы белән кавышкач, Зәйтүнәнең елак бәбие елаудан туктый. Тормышта болай булуы икеле. Ләкин шушы хәбәрнең сәнгатьчә хакыйкатькә кирәклеге бәхәссез. Сөләйман, Зөләйха, Габдулла, Зәйтүнәләрнең җаннары елаган дәвернең тәгәлләнүен, аларның имин, тыныч тормышы башланырга тиешлеген куәтли торган, шуны символик төстә раслый торган ишарә бу. Чын сәнгатьнең, һичшиксез, әнә шундый икенче, өченче планнары да булырга тиеш.

Повестьта авторның үз исеменнән уйлануларын биргән бер нәни бүләк бар. Монысы инде, минемчә, әйбәт әсәрнең төзек, табигый тукымасыннан читкә бүселеп чыга. Укучыга турыдан-туры болай мөрәҗәгать итүнең ихтыяҗы юк, «Яра» болай да фәлсәфи уйлануларга бай. Сәнгатьчә детальләр җитешлеге, халыкчан теленең моңы һәм башка күркәм хасиятләре аңа шуннан тыш та озын гомер вәгъдә итә.

Тормышыбызны агулаган сталинчылык дәвере, шул дәвер алып килгән фаҗигалар, ниһаять, әдәбиятыбызда да тирән һәм тулы чагылдырыла башлады. И. Салаховның «Тайгак кичү», М. Хәсәновның «Язгы аҗаган» романнары бу җәһәттән аеруча җитди казанышыбыз. Миллионнарны иленнән-йортыннан сөрү, шәфкатьсез рәвештә юк итү хас булмаса да, торгынлык еллары җәмгыятебезгә шулай ук зур бәлаләр китерде. Әмма бу заман хакында кырыс хакыйкатьне сәнгатьчә тирәнлек һәм осталык белән гәүдәләндерү әле һаман алдыбыздагы бурыч булып тора. Ринат Мөхәммәдиевнең «Кенәри — читлек кошы» романы нәкъ менә шушы юнәлештә ясалган җитди адым санала ала.

Романның баш каһарманы Асия ниләр күреп, тоеп үсә соң? Мәктәптә сабагын юньләп үзләштермәгән Юлия серле рәвештә бишле билгеләре ала, ә чын белемле, зиһенле балага лаеклы бәя бирелми. Намуслы һәм тырыш булсалар да, Асиянең ата-анасы бердәнбер кызларын асылга төрендерә алмый, ә менә шул ук Юлиянең түрә әнисе «маде ин Уса»ларны базадан гына юнәтә, кызын дәрескә генә түгел, тегендә-монда да казна машинасында гына илтеп куйдыра. Абруйлы әнисе аркасында Юлия мәктәпнең комсомол секретаре итеп сайлана һәм шешә сатып көн күрергә мәҗбүр классташы Аликны шул «затсыз» шөгыле өчен оялтырга әзерләнә. Кайбер иптәшләре генә түгел, хәтта укытучылар да әтисе төрмәгә эләккән, әнисе эчкечелеккә сабышкан Аликны кызганасы, аңа булышасы урында, мактанчык, тәкәббер Юлиягә яхшатлана. Кайда монда гаделлек, тигезлек принциплары? Бертөрле уйлау, икенче төрле сөйләү, өченче төрлене эшләү хөкем сөргән заманда, кануннар гына түгел, әхлак нормалары да җиргә салып тапталганда, рухи кыйммәтләрнең бәясе төшә, кешелеклелек югала, бозыклык чәчәк ата. Җәмгыятьнең матди нигезе зәгыйфьләнә, ганлә таркала, намус, вөҗдан, хакыйкать, тугрылык һәм башка шундый төшенчәләрне адәм баласы гомумән оныта башлый. Асия менә шундый шартларда формалаша. Җәмгыятьне череткән чирләр әкренләп аңа да йога, укучы күз алдында ул алдашучы, кешегә салынучы, тормышында җиңел юллар эзләүче йөгәнсез һәм хыянәтче хатынга әйләнә, башта ата-анасына, аннары иренә кайгы-хәсрәт китерә, баласын да язмыш иркенә ташлауга барып җитә.

Романда Асия кебек, тормышта рәхәт күрергә генә омтылган, аның шикелле рухи фәкыйрь, әхлакый йөгәнсез «кенәри»ләр, административ-әмер системасының дәрәҗәле, төшемле урындыкларына менеп утырган, үзләрен кануннан һәм әхлактан өстен санаган «арыслан»нар сурәтләнә. Торгынлык дәвере каһарманы Куштан Зариф, шундыйлар корбаны Җантимер, сталинчылык дәвере җәберен татыган Гыйрфановлар язмышы ачыла әсәрдә. Нинди генә авыр шартларда да гаделлеккә, намуслы яшәешкә ышанычын җуймаган, хакыйкатькә, сафлыкка ашкынган тегүче Сания, укытучы Мәхмүт, шофер Фидаилләрне гәүдәләндерә автор.

«Кенәри — читлек кошы» романы торгынлык дәверенә хас тискәре күренешләрне, әхлакый черү, таркалуның җирәнгеч шартларын һәм сәбәпләрен, паразитларча яшәүнең киләчәге булмавын уңышлы фаш итә, тормыш хакыйкатен яхшы ук тирән һәм оста чагылдыра торган җыйнак әсәр. Романның төзек сюжеты һәм композициясе, шаккатризм кебек төрле аксау-туксаулардан азат, матур аһәңле, ритмлы теле, автор концепциясенең ачыклыгы, аның әсәрдә эзлекле саклануы, образларның вакыйгалар агышына ачылуы Ринат Мөхәммәдиевнең прозаик буларак тагын да үсүе хакында сөйли. Ф. Миңнуллин бик дөрес искәрткәнчә, иркен сулыш белән көчәнмичә язу аның бу әсәрендә дә бик ачык күренә. Сурәтләргә алынган каһарманнарын, аларның гамәлләрен шактый яхшы белүче итеп таныта ул үзен романында. Геройларын гәүдәләндергәндә ирония, шарж, мыскыл элементларын урынлы кулланып, чын бестселлер иҗат итә.

Шулай да «Кенәри — читлек кошы» романына дәгъва белдерерлек мөмкинлекләр

хәтсез. Мисалга, гаскәрдән кайткан Фидаилнең Куштан Зарифны йомшак җирене тибеп өеннән куып чыгаруы өчен генә (моңа шаһитлар юк!) унбиш тәүлеккә утыртылуы ышандырмый. Утыз бишенче бүлектә Асиянең үкенүе, иренә ихтирамы һәм мәхәббәте артуын тасвирлау да чама хисенә туры килми сыман. Аның болай җитди үзгәрүе өчен Асиянең ата-анасы һәм сөяркәсе белән кискенрәк бәрелешүе, нәфрәткә дучар булуы, хурлану ачысын татуы кирәк иде. Автор исә каһарманын андый үткен ситуацияләргә кертеп сурәтләмәгән, димәк, Асиядәге үзгәрешне дә җитәрлек дәлилләмәгән. Бик каты үкенгән, тәзәләргә йөз тоткан хатынның роман азагында тагын сөяркәсе кочагына ташлануы утыз бишенче бүлектә кырыс хакыйкатьне гәүдәләндерү җитмәвен генә раслый. Әсәрдә Асиянең ана буларак сурәтләнүе дә төссезрәк чыккан.

Кенәриләрнең рухи бушлыгы, җавапсызлыгы, ике тамчы судай бер-берсенә охшавы ниндидер дәрәҗәдә акланса һәм тормыш хакыйкатенә зыян китермәсә, «арыслан»нарның да шундый примитив бәндәләр итеп тасвирлануы бездә ризасызлык уята, сәнгать хакыйкате моны инде бигрәк тә күтәрә алмый. Арысланнарны йомыкый, аз сүзле, серле итеп бирүгә караганда, алардагы ихтыяр көчен, интрига-мәкер, тапкырлыкны һәм циникльны тирәнрәк ачу әсәрне күпкә кызыклырак, җанлырак һәм, бигрәк тә әһәмиятлесе, аларны тормышчанрак итәр иде. Югыйсә арысланнар, романның башында гаярь шәхес кебек күренсә дә, уртасында алар куркагә, ахырында исә куянга охшый башлыйлар. Реалистик романны бу инде шактый фәкыйрьләндерә.

Авторның әйтергә теләгән фикерләре беренче планда сурәтләүгә сыеп беткән. Әсәрдән-әсәргә үсеп, прозаик буларак танылып килүче, укучыда зур өметләр уятучы Ринат Мөхәммәдиевтән без икенче, өченче планнарны — ишарәләрне, тирәндәрәк җемелдәп торган фикер чаткыларын бирүне дә көтәргә хаклы. А. Гыйләҗев, М. Юныслар үрнәге безгә менә шуны да йөкли!

Былтыр Р. Мөхәммәдиевнең яшьтәше Әхәт Гаффар укучыларга икенче романын — «Олы юлның тузаны»н тәкъдим итте. Табигать һәм кеше бәйләнешләре, аларның саклануп калу һәм яши алу шартлары тикшерелә бу әсәрдә. Автор монда кешене барлык бүтән тереклек ияләре — үсемлекләр, кошлар, балыклар һәм хайваннар белән бергә янәшә сурәтли. Әмма ул, М. Мәһдиевтән аермалы буларак, кешенең һәм бүтән тереклек ияләренең яшәү көчен, гомер итәргә омтылышын, аларның моңа ни дәрәҗәдә лаек булуын яки булмавын, хәвефнең кайдан янавын калкурак күрсәтер өчен, каһарманнарын гадәттән тыш шартларга куеп сурәтли. Ниндидер милли буяулар төссезләнә, үлә баруына, татар диган «мамонт»ның җаны чыга башлауга ул артык ачыргаланмый. Ә. Гаффар зуррак, колачлырак мәсьәләләр, гомумкешелек һәм галәм язмышы хакында баш вата, тереклекнең тулаем сүнүгә, зәгыйфьләнүгә, галәмнең шөкәтсезләнүгә, кешеләрнең әхлагы таркалуга игътибарны юнәлтә, укучыларын түбәнлеккә, мәгънәсезлеккә тәгәрәүдән, афәткә чумудан коткарырга ашкына. Африкадан кайтучы сандугачлар туган җирләрен танымый — әрәмәләр киселгән, тапталган, җирне тимер-томыр, бетон, химикатлар каплаган. Балыклар күнегелгән урыннарында уылдык чәчә алмый — елгаларны биек буалар киртәләгән, суны ашлама калдыклары, җир мае пычраткан. Кешеләр, югарыдан килгән әмерләргә буйсынып, ата-баба һәм оныклар каршындагы җаваплылыгын онытып, табигатьне туный, умыра, кабер дигән изге урынны тузгыта, өлкәннәргә колак салу, вәгъдәне тоту дигән төшенчәләр, гадәтләр барлыгын уйлап та карамый, җиде ят халыкның азчылыгын күпчелегеннән яклар өчен корал күтәреп бара да, уңга-сулга үлем чәчә башлый. Кешеләр, нинди вәхшәткә баттыгыз сез? Табигать, сине адәм балалары һәлакәткә илтә ләбаса! Кояш астындагы елга җир асты елгасы тарафыннан йотылды, сандугач кабер эчендә томаланып калды, кырпы балыгы умарта базына килеп эләкте дә капъйот бәндәләр һөҗүменә дучар булды. Сусыз, елга барлыкка китергән электрсыз, сандугачсыз, димәк, көйсез-моңсыз калып, ничек яшәрсез, кешеләр? Иртәгә табигатьнең калган өлешен дә корытсагыз, сезне алда нәрсә көтә? Аңыгызны томалап, ихтыярыгызны богаулап торган «Ноль бөтен» исемле һәм аларның яраннарын өстегездән алып атып, сәламәт тормыш кора башларга вакыт җитмәдеме сезгә?

Ә. Гаффар «Олы юлның тузаны» әсәрендә әнә шундый сорауларны куеп, җанлы һәм җансыз табигатьне телгә китереп, катлаулы заманыбызны полифоник рухта гәүдәләндерә, татар романын фикер һәм стиль ягыннан баета, укучыны дөнья, яшәеш хакында күнегелмәгәнчә уйларга этәрә. Моны бары тик уңай яктан гына бәяләргә мөмкин.

Яңа юлдан атлау, язучылык техникасын баету иҗади кыюлык һәм тәвәккәллек сорый, еш кына абындыра, сөртендерә дә. Әгәр эзләнү үз җирлегенә таянып алып барылмаса, иҗат җимешен миллэтенең рухи җирлегенә, үсешенә ипле килеп ялганмый. «Олы юлның тузаны» романы татар әдәбиятының мәңгелек традицияләре, казанышларыннан шытып чыкмавы, ят культураларның архитектурасын гына түгел, фикри хәзинәсен дә артык үзгәртмичә яңа мәйданга күчереп утыртуы һәм аны шул нигездә үстерүе белән күңелне кыра. Әсәргә концепция бөтенлеге, сюжет тыгызлыгы җитми. Аның аерым өлешләре фаҗигa, шарж, сатира алымында язылган, төрле-төрле физик һәм химик катнашма рәве-

шендә калган, роман буеннан-буена бердәй составлы тоташ эремә хәленә килеп җитмәгән. Аның начар тәрҗемә ителгән бүлекләре дә, бөтенләй тәрҗемә кылынмаган өлешләре дә бар. Тәмамланган әсәр тәэсирен калдырыр өчен, аның әле язылып бетмәгән урыннары барлыгы да сизелә. Көчәнеп әйтелгән фикерләр, татарча төзелмәгән җөмләләр укуны бик нык кыенлаштыра. Образларны бирүдә эзлеклелек аксау, фантастик вакыйгалар, детальләрнең чамадан тыш күп урын алуы кызыксынуны кимета. Романның композицион яктан да шактый дәгъва уятуын, таныш геройларның озак-озак югалып торуын, аларның рухи үзгәреше күз алдында җитәрлек сурәтләнмәвен, мисалга, Степанның каберне туздыруы дәлилләнеп бетмәвен, Солтанның дустына иярүе исә аның яшәеш кануннарына, логикасына сыймавын һ. б. якларны да искәртмичә ярамый. «Казан утлары» редколлегиясе утырышында тикшергәндә М. Галиев «Олы юлның тузаны»н Т. Манн әсәрләре белән тиңләп, «аның бөтен ямен-тәмен бәяләр өчен ике-өч тапкыр укырга кирәк», — диде. Томас Маннга тиң татар язучысы пәйда булуга без барыбыз да куаначакбыз, әмма башта бәлки бу романны автор үзе тагын ике-өч тапкыр карап чыгар һәм укылышын тоткарлый торган җирләрен ипкә китерер, җитешсезлекләрен киметер? Кино-телевидение заманында безнең әсәрләрне бер мәртәбә укыту да авыр, шуңа күрә «Олы юлның тузаны»на динамика өстәү бер дә зыян китермәс иде! Әсәргә эчталегеннән чыгып муафыйграк исем бирү дә акланыр иде.

Тулаем алганда, автор сан артыннан кумыйча, сыйфатка күбрәк игътибар бирсә, әсәренең журнал вариантын камилләштерүне, тулыландыруны тырышып дәвам итсә, әдәбиятыбызга чыннан да кызыклы, әһәмиятле роман өстәлүенә шатланыр идек.

Былтыр прозабыз хәзинәсен Фоат Садриев «Шаһзаманов эше» дигән әйбәт повесте белән баетты. Бу әсәр төрле яктан тансык саналырга хаклы: беренчедән, татар укучыларының күпчелеге авылда яши, аңа үз тирәлеген, үз эше, көнкүреше хасиятләрен, каршылыкларын, шундагы тормыш куйган үткен мәсьәләләрне заманча ачкан әсәрләр тәкъдим итүебез хәерле. «Шаһзаманов эше» нәкъ менә шушы социаль заказны канәгатьләндерә алуы белән әһәмиятле. Икенчедән, повестьның баш каһарманы Илһам Шаһзаманов — тракторчы, димәк, илне шулкадәр борчыган, чыгырыннан чыгарган азык-төлек мәсьәләсен хәл итүдә төп йөкне тартучы. Повестьта Шаһзамановның административ-әмер системасына каршы баш күтәрүе сурәтләнә — автор заман мәсьәләләрен яктыртуга бик сүлпән һәм соңга калып алынган прозабызның шулай итеп бер бушлыгын, җитешсезлеген тутыра. Әлбәттә, әсәрнең тормышчанлыгы, сәнгатьчә эшләнеше тиешле югарылыкта булмаса, «Шаһзаманов эше» повестен алда телгә алынган әлеге ике үзенчәлеге өчен генә һич тә мактый алмас идек. Матур әдәбиятка темасы, бүгенге көнне яктыртуы өчен генә югары бәя бирү практикасы котылгысыз рәвештә гамәлдән чыга бара. Без сәнгатьне чамасыз идеологияләштерү афәтеннән әкренләп арына киләбез, мондый шартларда тормышны тулы, тирән чагылдыру, вакыйгаларны реаль конфликтка нигезләү, шул конфликтлар, бәрелешләр аша үзганда образларның төрле яктан ачылуы, язучылык техникасының камиллеге, автор һәм персонажлар теленең төзеклеге, байлыгы беренче планга чыга.

Фоат Садриев саф татар районнарыннан саналган Мөслимдә, үзе яратып һәм яхшы белеп гәүдәләндерә торган каһарманнары арасында яши, шактый вакыт район газетасы редакторы булып эшләгәнгәме, үз төбәгенең хәлен, сулышын тоеп, күреп тора.

Административ-әмер системасы әле һаман үзен иркен хис иткәндә, күп җирдә, шул исәптән, Үрмәш, Үрнәк авылларында да күз буяучылык, эш рәтен белмәгән, әмма боерык бирергә яраткан һәм күнеккән түрәләргә яраклашу киң урын ала. Колхозның баш агрономы Яхъя чәчүлекне район лабораториясенә җибәргәнче, бухгалтерия кызларыннан чүпләтеп чистарттыра, шулай үзен җитәкчеләрдән мактатуга ирешә, әмма колхоз кырына чүп үләне орлыгы аралашкан, сыйфаты түбән бөртекләрне чәчтерә. Язгы кыр эшләрен районда беренче тәмамлавы турында хәбәр итәр өчен, агротехника кагыйдәләрен бозa, шуның аркасында борчак басуын солыча каплый. Бу чатаклыгын Казан түрәләре күрүеннән куркып, Яхъя тракторчы Илһамга инде бер атнадан яшел азык итеп файдаланырга өлгерәчәк борчакны сукалап күмәргә боера. Җаны-тәне белән игенче Илһам, терлекләр коры улак кимергән чакта, колхоз җитәкчеләренең шушы мәгънәсез әмерен аңлый да, ачуыннан — агроном Яхъяны сугып ега. Автор Илһам белән Яхъяның кискен бәрелешкә ничек килеп җитүләрен бик матур һәм ышандыручан итеп тасвирлый, конфликтны алар арасында гына калдырмый, әмер бирүчеләр һәм аларга ярaклашучыларның, үз акылы белән эшләргә һәм яшәргә теләп, административ-әмер системасына каршы баш күтәрүчеләрнең авыл һәм район күләмендәге вәкилләрен дә күрсәтә. Җыйнак күләмле повестьта каһарманнар саны егермедән артык, әмма әсәрнең сюжеты, композициясе оста корылганлыктан, образларның һәркайсы төп конфликтка бәйле рәвештә шәхси сыйфатлары белән ачылганлыктан, «Шаһзаманов эше» повесте мавыгып укыла һәм хәтердә кала. Татар авылына үзгәртеп кору җиле үтеп керү, сәламәт тәнле, сәламәт рухлы, әмма дистә еллар буе иҗади омтылышы, ирегә кысылып, буылып килгән игенченең

күндәм рәвештә әмер үтәүчедән күп газаплар аша үзен хуҗа итеп тоючы шәхескә әверелә башлавы Ф. Садриев тарафыннан матур гәүдәләндерүен күпләр ошаткандыр.

Җәмгыятьне үзгәртеп кору дәвере язучылардан аеруча кыюлык, гайрәт, яңача фикер йөртүне таләп итә. Әмма без як-якка каранып, «алгарак чыксам, башыма сукмагайлары», дип өркебрәк яшәүгә, иҗат итүгә шулкадәр күнеккәнбез ки, дөрес уйларыбызны укучыга җиткерергә, каршылыкларны тирәнрәк ачарга һаман әле сүлпән һәм юаш алынабыз. Шушы кимчелек Ф. Садриевта да саклана. Нәкъ менә шушы нәрсә аңа «Шаһзаманов эше»н тулысынча яңа рухта тасвирларга комачаулый. Мин моны Илһам кичерешләрен партбилетсыз калу хәвефенә бәйләүдә, әсәр сюжетының төеннәрен партаппарат кысасында сурәтләүдә күрәм. Партбилетсыз калу түрәләргә, аппарат хезмәткәрләренә, ахыр чиктә, булдыксыз кешеләргә куркыныч. Чөнки партбилет аларга баткан чакта ябыша торган сәлам гына түгел, социаль комфортка ирешү чарасы да. Ә гади тракторчы, гомере буе буразнадан аерылмаган тырыш колхозчы, партиядән чыгарылганда нәрсәсен югалта соң? Ул партиягә түгел, партия үзе Илһам кебек булдыклы һөнәр ияләренә күбрәк мохтаҗ чакта, баш каһарманның, «партбилетсыз калсам», дип аһ оруы бүгенге укучыны һич тә ышандырып җиткерми. Кыскасы, Илһамның партиядән куылу хәвефен әсәрнең сюжет пружинасына әйләндерү авторның элекке фикер калыпларыннан арынып бетмәвен, шуның белән повестеның ышандыру көчен шактый ук киметүен раслый.

Матур әдәбиятның төп эчтәлеген, аның фикри байлыгын яхшылык белән яманлык көрәше, яхшылыкның яманлыкны җиңүен сурәтләү тәшкил итә. Күп кенә әсәрләрдә бу аермачык ярылып ятмый, витамин конфет тышчасы белән капланган шикелле, авторның укучыга җиткерергә теләгән уйлары да мавыктыргыч вакыйгалар, образлар, аларның үзара катлаулы бәйләнешләре, гамәлләре аша урап-урап сеңдерелә. Гадәттә, нәкъ менә шундый әсәрләр сәнгатьчә тирән тәэсир итү көченә ия була. Әмма яхшылык белән яманлык көрәше турыдан-туры публицистик пафос белән ачылган, ялангачландырыбрак күрсәтелгән әсәрләр дә иҗат ителә. Образлары автор ихтыяры буенча әзер фикер калыбы хәлендә генә калмыйча, катлаулы һәм җанлы шәхес дәрәҗәсенә җиткерелсә, вакыйгалары тормыш хакыйкатенә хилафлык китермәсә, соңгы типтагы әсәрләр дә укучы күңелен били, аны сызландыра, шатландыра яки нәфрәтләндерә. Газиз Кашаповның «Убырут» повесте исеме белән дә, бөтен эчке рухы белән дә нәкъ менә шундыйлар исәбенә керә.

Һәр кешегә яхшылык һәм яманлык орлыгы салынган, аларның кайсысы мулрак шытым бирүе без яши торган мохиткә, иҗтимагый-сәяси шартларга да бәйләнгән. Авыл егете Мәүләвинең убыруткa, ягъни, шайтан таягына, тигәнәккә, убыр үсемлегенә әйләнә башлавы колхозлашу елларына туры килүен автор бик уңышлы тотып алган. Чөнки менә шушы дәвердә дәһшәтле сталинчылык тамам ныгып җитә, аек акыл, гомумкешелек кыйммәтләре, гадел кануннар аяк астына салып таптала, бер шәхескә, бер формага, бер карашка сукырларча табыну тамыр җибәрә, әхлаксыз «халыклар атасы»ның республика, район, авыл күләмендәге күләгәләре барлыкка килә, сәламәт тәнгә ябышкан сөлек кебек, алар күпчелек өчен тормышның тәмен дә, ямен дә бетерергә керешә. Мәүләви әле кайчан гына үз иманa җиренә, үз мал-туарына, димәк, чагыштырмача шактый киң иреккә дә ия булган авылдашларын мескен крепостнойга, телсез-тешсез эш атына, аның җирәнгеч хайваный нәфесен үтәүче мәхлукка әйләндерә бара. Билгеле инде, мондый әверелеш шома гына гамәлгә ашмый, карышу уята, бәрелешләр китереп чыгара, бу исә яңа бәхетсезлекләргә юл ача.

«Убырут» Г. Кашаповның мин укыган әсәрләре арасында иң уңышлысы. Повесть җыйнак, сыйдырышлы, тыгыз язылган.

Повестьның нинди җитешсезлекләре бар соң? Минемчә, табигатьне, портретларны М. Мәһдиевчә юмарт сурәтләү әсәрне тагын да көчәйтә төшкән булыр иде. Мәүләвинең өметсез юлга басу сәбәпләрен балачак вакыйгалары аша ук күрсәтү ихтыяҗы да сизелә. Аның уйнаш маҗаралары артык коры, ипсез тасвирлануы да канәгатьсезлек уята. Әсәрнең азагында Мәүләвине сасы, шомлы үләт базы буена алып килү бик отышлы, әмма повестьны, торгынлык еллары гадәтенчә, якты, нурлы табигать күренеше белән төчеләндереп тәмамлау яраклы түгел... тәмамлау «кланмый. Йомгак ясап шуны әйтергә мөмкин: «Убырут» повесте Г. Кашаповның җитди казанышы, былтыргы прозабызның уңышы саналырлык әсәр.

Барлас Камаловның «Узган гомер бигрәк җәл» повесте дә, «Убырут» шикелле, лирик герой, шулай ук тискәре каһарман исеменнән сөйләнә. Әсәр тәҗрибәле каләм иясе тарафыннан язылган. Җегәрле теле, төзек сюжет-композициясе, тормышчан вакыйгалары, әсәрнең баш каһарманы Рамазан Лотфиевның ышандырырлык итеп гәүдәләндерелүе әйбәт тәэсир калдыра. Повестьта тормыш хакыйкате бар, шуңа күрә ул кызыксынып укыла. Әмма соңыннан күңелне ниндидер канәгатьсезлек хисе били. Нилектән бу?

Минемчә, «Узган гомер бигрәк җәл»нең сәнгатьчә хакыйкать, яңалык, ачыш алып килмәвендә, аңа тирәнлек җитмәүдә.

Лотфиев кебек эчкечелеккә бирелгән, гомерен мәгънәсез юлга кертеп җибәргән кешеләр тирә-ягыбызда тулып тора. Автор бу фаҗиганең сәбәбе — кайберәүләрдә ихтыяр көче җитмәүдә, дип раслый. Тагын бер сәбәбе — тирәлекнең тискәре йогынтысында. Авылда никрутлар, театрда Гали Донской, шәһәрдә сабакташы Зариф, дача танышы Диналәр

әгъвалый Рамазанны. Хәтта эчкечелектән дәвалый торган махсус шифаханәдә дә тынгы юк — аракы тәрәзәдән агылып керә. Яшәп карагыз сез мондый шартларда юлдан язмыйча! Дөрес, хатыны Назирә, адаш абыйсы, эшендәге түрә, хәрби комиссар аны «ир булырга, яңадан сафка басарга» үгетлиләр, әмма бу үгет Рамазанның бер колагыннан керә, икенчесеннән чыга. Авторның миһербанлыгы аркасында, Лотфиев, әйтерсең, «Эскимо» тундырмасы ашап, лимонад эчеп кенә яши, аңа бераү дә бик каты бәрелми, аның белән егерме ел чиләнгән хатыны, аерылганнан соң, елмаеп кына сөйләшә, улы белән кызы да аны нинди яратулары һәм хөрмәт итүләре турында телеграммалар гына яудырып яталар. Тормышта бәлки шулай да буладыр, ләкин сәнгатьтә эчкечегә карата мондый стериль, ак-пакь мөнәсәбәтләрне уйлап чыгаруның мәгънәсе юк.

Б. Камаловның уңай геройлары зәгыйфь фон, күләгә хәлендә генә сурәтләнгән, эчкече гаиләсендәге балалар рухи халәтенең имгәнүе, алар протесты, күз яшьләренең аталары Рамазанга тәэсире автор игътибарыннан читтә калган. Шәхес һәм җәмгыять бәйләнешләрен ачуда күбрәкне вәгъдә иткән, кызыклы типлар буларак төсмерләнгән Гали Донской, Динә Мәсәгутоваларның саран, икенче планда гына чагылдырылуы да укучыны ымсындыру, әмма аның өметен акламауга мисал. Б. Камалов шикелле инде тормыш һәм иҗат тәҗрибәсен мул туплаган прозаикның нәүбәттәге повестенда мөмкинлекләрен тулы файдалана алмавы, әлбәттә, көенечле.

Татар әдипләре милләтебез тормышын яңадан сафландыру, сәламәтләндерү һәм тергезү, киләчәк гомерен тәэмин итү өчен афәтле елларның җирәнгеч чирләрен, пычрак гадәтләрен, җан өшеткеч вакыйгаларын җанландырып күрсәтү, шуларга анализ ясау, шул хәвефле дәвердән гыйбрәт алу зарурлыгын яхшы төшенеп, 1989 елда ике повесть бастырдылар. «Сталинга хат» михнәтле гомер кичергән, әмма сугышчан рухын, яшәү дәртен җуймаган өлкән каләмдәшебез Н. Дәүлинең укучыларга соңгы сәламе булса, «Кыңгырау» — көрәш омтылышы кайнап торган Ф.Бәйрәмованың укучы һәм заман белән аяк терәп сөйләшүе рәвешендә хәтердә кала.

Бу повестьларның икесен дә язмышларны, вакыйгаларны тирән һәм киеренке гәүдәләндерү, сәнгатьчә ачыш ясау җәһәтеннән И. Салахов романыннан соң тагын ды алга китеш дип бәяли алмыйм. Ләкин алар тормышның бүтән тармакларын, шул заманның башка типларын, күренешләрен шактый калку сурәтләп, халкыбыз яшәешенең катлаулы бер заманын тулырак күзалларга булышалар. Н. Дәүли сталинчылык демагогиясенең сәламәт акылны баса баруын Кадрия, Гыйльфан образлары аша кызыклы һәм ышандыручан тасвирласа, Ф. Бәйрәмова культ сөременең тотрыксыз Кыяметдин белән иманы нык Айсылу тормышын ничек чыгырыннан чыгаруын исбатлы рәвештә ачып бирә.

Язучының осталыгы, әдәбиятның камиллеге укучы хисләренә тәэсир итү дәрәҗәсе белән үлчәнә. «Кыңгырау» повестен укыганда Фәүзия өчен шатланасың: ул хатын-кыз әдипләребез арасында гына түгел, байтак ир-ат каләмдәшләребез янәшәсендә дә тойгыларны тирән, куе һәм юмарт гәүдәләндерүе, әсәрнең хисләр җирлеген төгел, ятышлы бирә алуы белән аерылып тора. Аның Айсылуы кышкы суыкта товар вагонында ач-ялангач Себергә олактырыла, коры сөяк белән сеңергә калган хәлендә шахта хезмәтенә җигелә. Ун ел буе шунда кагылу-сугылулардан соң аны туган авылында күзәтү астында яшәү, урман кисү, колхоз эшләрен үтәү көтеп тора. Шул җәфа-михнәтләрне чыдам, сабыр күтәргәндә ире белән улын югалта, карт анасын җирли һәм, бигрәк тә әһәмиятлесе, өметен дә җуя, ләкин шул шартларда да үзендә өч үги баланы тәрбияләрлек, явызлыкка каршы торырлык көч таба. Бу инде сезгә олау-олау кием-салым, азык-төлек һәм хезмәтче лакейларын да алып, станцияләрдә җылына-җылына ирләре янына барган һәм Себердә дә назланып яшәүдән мәхрүм булмаган декабрист хатыны гына түгел. Айсылу яшәешнең бөтен авырлыкларын татыган, әмма кешелеген югалтмаган чын батыр, чын каһарман. Аның иренә, баласына тугрылыгы матур тасвирлануын, сөргеннән кайткач әнисе, аннары ире Галимҗан белән очрашуы аеруча тәэсирле сурәтләнүен дә әйтергә кирәк. Әсәрдә гәүдәләндерелгән Галимҗанның Айсылудан бәхиллек соравы, аларның улы Газизҗанның йөз чакрымлап юлны поезд артыннан җәяү кайтуы һәм Кыяметдингә очрап харап булу күренешләре дә укучыны дулкынландырмый калмый.

Ф. Бәйрәмова бу әсәрендә язучылык техникасын профессиональ дәрәҗәдә оста эшкә җигә, шунлыктан, сөрген һәм төрмә хәлләрен ишетеп һәм укып кына белсә дә, әсәренең кызуын сүндермәс өчен, үткән белән бүгенгене даими аралаштырып, повестен публицистик уйланулар белән баетып, кыенлыкларны җиңүгә ирешә. Ләкин, шулай да, күңел публицистик агымны җанлы тормыш вакыйгалары, сәнгатьчә детальләр алыштыруын тели. Айсылуны авыл халкыннан артыграк аерып кую, аңа теләктәш кешеләрне күрсәтмәү дә чынбарлык бөтенлегенә күләгә төшерә, повестьны фәкыйрьләндерә. Әмма «Кыңгырау» кырык еллар хакыйкате, татар хатын-кызларының фаҗигале сынауларны горур узуын, аларның рухи байлыгын һәм ныклыгын, әхлакый сафлыгын нигездә уңышлы күз алдына бастыра.

Ф. Бәйрәмова былтыр тагын бер яңа повестен бастырды. К. Тимбикова, М. Насыйбуллин, Н. Гыйматдинова, З. Хөснияр лар да укучыларга күләмле әсәрләрен тәкъдим иттеләр. «Казан утлары» белән «Идел» журналында гына да җәмгысе өч роман, унике

повесть, егермеләп хикәя дөнья күрде. Аларның һәммәсен гадел бәяләү безнең күмәк эшебездер, дип уйлыйм.

Елдан-ел кабатлана килгән бер хакыйкатьне тагын әйтергә туры килә: бездә хикәя жанры аксый. Тәҗрибәле өлкәннәр аны язып «вакланмый», яшьләрнең исә күзгә төшәрлек җыйнак әсәр бирергә осталыклары җитешми. Авторларны дәртләндерү, яшь әдипләр тәрбияләү максатында «Казан утлары» журналы өйрәнчек хикәяләрне дә басарга мәҗбүр. Редакциянең хикәяләр ярышы игълан итүе, җиңүчеләргә шактый бәһале бүләк билгеләве әлегә сөенечле нәтиҗәсен биргәне юк.

Андрей Битов: «Унтугызынчы гасыр урыс әдәбияты безгә өч роман бирде»,— дип белдергән иде. Санап карасак, без дә былтыр өч яңа роман бастырдык. Әллә соң урыс язучылары йөз ел тырышканны без шулай тиз арада иҗат итәргә өйрәндекме? XIX йөз урыс романчылары арасында Лермонтов, Гоголь, Тургенев, Гончаров, Достоевский, Толстой кебек беренче зурлыктагы йолдызлар балкый, алардан башка да роман язучылар йөзләгән була. Әмма А. Битов нин дидер өч әсәр турында гына сүз алып бара. Ул өч роман заманның һәм милләтнең әхвәлен тирән чагылдырырга, образларны калку гәүдәләндерергә һәм шул телдә укучыларның гомерлек юлдашы булырга, кайсы телгә тәрҗемә итсәң дә, тәэсир итү көчен җуймаска, халыкара стандартның югары таләпләренә җавап бирергә тиештер.

Әгәр шулай таләпчән тикшерсәк, 1989 елгы татар романнары хакында: «Андый югары бәягә лаегы булмады»,— дияргә туры килә. Повестьларыбыздан тормыш хакыйкате, миллилеге, сәнгатьчә камиллеге ягыннан А. Гыйләҗевнең «Яра»сын мактап телгә алырга; аңа Г. Кашаповның «Убырут»ын, М. Мәһдиевнең «Бәхилләшү»ен теркәргә мөмкин. Зурдан кубып сөйләшкәндә, күп түгел бу. Әмма татар әдипләренең хәзер иң четерекле мәсьәләләрне яктыртудан да курыкмавы, кырыс хакыйкатьне тулы һәм калку сурәтләргә омтылуы, илебездә әдәбият-сәнгатьнең үсеше өчен шартларның яхшыруы гасыр романы яки повестеның туксанынчы елларда язылачагына өмет уята. Моның өчен дөнья әдәбияты казанышларын яхшы белүебез, туктаусыз эзләнүебез, халкыбыз киләчәгенә нык ышаныч белән каравыбыз һәм иҗат утында армый-талмый януыбыз кирәк.

# ТУКАЙЛАР РУХЫ

# ХАЛКЫҢНЫҢ ХОЛКЫ БОЗЫЛСА

ЯЗУЧЫ ФӘҮЗИЯ БӘЙРӘМОВА БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ



*— «Тукайлар рухы» сериясеннән бу инде беренче әңгәмә түгел. Моңа кадәр без журнал укучыларга Салих ага Баттал, Нурихан ага Фәттах, Роберт Батулла һәм Мөдәррис Әгъләмовлар белән булган сөйләшүләрне тәкъдим иткән идек. Менә хәзер инде Сезгә кайбер сораулар бирәсе килә.*

*Торгынлык чорында безнең татар язучылары төрле мактаулы исемнәрне, орден-медальләрне күпләп алдылар. Ул чорда бездә «батырлар», «данлы кешеләр» бик тә күп иде. Ләкин Яңарыш чоры килеп, милләт өчен көрәшергә мөмкинлекләр ачылгач — әлеге батырлар түгел, ә бөтенләй бүтән җаннар күтәрелеп чыкты. Бөтенләй бүтән кешеләр үзләренең фидакарь көрәшләре белән халык игътибарын яулап алдылар. Әнә шундый и к е т ө р л е бат ы р л а р турында Сез ни уйлыйсыз?*

*— Үземнең каләмдәшләремә бәя бирү минем өчен шактый кыен. Һәркемнең үзе теләгәнчә яшәргә хакы бар. Гыйбрәт өчен кайбер нәрсәләр турында әйтмичә дә калып булмый.*

Торгынлык, алдау һәм алдану чоры язучылар дөньясында да булды бит. Тиз генә язучы булу өчен, китап чыгару, нәшрият-журнал тирәсенә эшкә урнашу өчен таныш-белешлек, ни дәрәҗәдәдер куштанлык, телсезлек кирәк иде. Язучы, шәхес булып өлгергәнче үк, шул алдавычка каба, кемнәргәдер бурычлы була, үзенең бәйсезлеге бәрабәренә, җәмгыятьтә җылы, җайлы урын ала. Авылдан килеп, тырыша-тырыша кеше арасына кергән яшь язучының теле икеләтә йозакта була. Аларның күбесе үзләрен ризыклы иткән хөкүмәткә, системага дан җырлары җырлап, идеягә тугрылыкларын раслап торырга тиешләр. Хөкүмәт тә үз чиратында җаваплы булып калмый, ышанычлы кешеләрен тиз таный, аларны баштан сыйпап үстерә, төрле исем-дәрәҗәләр бирә, аларга таяна, бәйсезләрне, сәерләрне, «сәрхүш»ләрне казна казанына якын җибәрми. Ярый, хуш, Сез әйткәнчә, Яңа заман житте, ди. Бу дан-дәрәҗәле, хөкүмәткә һәм идеягә тугрылыклы язучылар баррикаданың кайсы ягына басарлар? Үзен ашатып асраган консерватор система ягынамы, әллә шул тук түрәләргә тискәре караган халык ягынамы? Әллә, дәшмичә, төпкә китеп торырмы? Татар язучыларының күбесе хәзергә дәшми. Милли азатлык өчен хәрәкәтнең башында да татар язучылары юк дәрәҗәсендә, ә бит Балтыйк буе республикарында, Урта Азиядә, Кавказ халыклары арасында милли бәйсезлек өчен көрәшкә иң беренче булып язучылар күтәрелде, халык аларга иярде. Бездә исә милли хәрәкәт башында һаман шәхесләр юк. Дөрес, көрәшчеләр бар, фидакарьләр бар, ләкин милли каһарманнар күренми.

*— Фәүзия Бәйрәмованың милли каһарманга әверелүе өчен н и н д и ш а р т л а р һәм үз шәхесегезнең н и н д и с ы й ф а т л а р ы ярдәм итте дип саныйсыз?*

— Фәүзия Бәйрәмова да милли каһарман түгел. Тарихта милли каһарман исемен алу өчен милләтең өчен тиңсез батырлыклар эшләү кирәк. Шул бәхет насыйп

булса икән! Хәзергә мин дә нидер эшлим, бу халыкның тормышын ничек җиңеләйтим икән, дип газап чигәм. Максатыма төрле юллар белән киләм — Татарстан халык депутаты буларак, парламентта законнар кабул итү, митинг һәм пикетлар оештыру, башка халыклар арасында татарларны пропагандалау, дисталәгән мәкаләләр, аңлату эшләре... Сез, милләт өчен көрәшче булу өчен нинди шартлар ярдәм итте, дисез. Шарт түгел, шартсызлык ярдәм итте. Чарасызлык. Татар милләтенең соң чиккә килеп җитүе. Шунысын да әйтергә кирәк, мин әдәбиятка да, сәясәткә дә авыл йөге белән генә түгел, бераз дөнья күреп, өлгереп, тулып килдем. Кечкенә мисал. Миңа өч ел гаиләм белән Монголия Халык Республикасында яшәргә туры килде. Анда ипилек-тәэлык монголча өйрәндем, башка татар хатыннары да тырыша-тырыша монголча сөйләшәләр иде. Бездәге табигый сәләтне, тырышлыкны күрәселәре килмичә, рус хатыннары безгә: «Сез үзегез монгол нәселеннән, шуңа күрә монголча беләсез!» — диләр иде. (Ә бит татар, кайда барса, кем арасында яшәсә дә, иң беренче тел өйрәнә!) Татар булганым өчен миңа соңыннан да шактый ишетергә туры килде. Газетада эшләгән елларымда татар халкын махсус рәвештә, мәкерле рәвештә талауларын сизенә башладым. Соңра моның төрки халыкларга, бигрәк тә мөселманнарга каршы алып барылган яшерен көрәшнең бер чагылышы икәнен аңладым. Ул арада илдә, республикада төрле политик оешмалар барлыкка килә башлады. Халык фронты, «Мемориал», Татар иҗтимагый үзәге, төрле фиркаләр. Мин аларның барысына да йөреп, өйрәнеп чыктым. Татар иҗтимагый үзәгенә тукталдым. Татар иҗтимагый үзәге миңа зур сәясәткә кереп китү өчен бер ишек булды. Ул арада сайлаулар кампаниясе башланды. Мин башта ук СССР халык депутатлыгына тәвәккәлләп карадым. Менә шушындый тиңсез көрәшләрдә кыйнала-кыйнала, җиңелеп һәм җиңеп, азмы-күпме политик көрәшче булып формалаштым. Бу чор — искедән яңага күчү чоры — минем шәхси тормышымда, холкымда да күчеш чорына туры килде. Сәяси аң белән бергә миңа ышаныч һәм кыюлык килде. Сыктау, зарлану, өметсезлекне һәм билгесезлекне максатлы, планлы көрәш алыштырды.

*— Бүген үзен интеллигент санап йөргән күп кенә татар зыялылары хәзерге чорда, милләт өчен конкрет эшләү чорында, һаман да сүз белән генә мавыгалар. Сүз сөйләүне төп максат итеп куялар. Практик эшкә якынаерга теләмиләр. Нәтиҗәдә, милли хәрәкәт шактый акрын бара, без башка милләтләргә караганда арттарак кыймылдыйбыз... Сез бу фикер белән килешәсезме?*

— Сүз сөйләү татар зыялыларының гына түгел, совет системасының чире. Безнең арттан килеп, күп милләтләр шул чирдән арап була яздылар. Хәтта монголлар да өчәр көн җыелышта утырып, сүз сөйләп, далада мал көтәргә кешеләре калмый иде, төп эшләрен башка илләрдән китереп, соңгы байлыкларын биреп эшләтәләр иде. Хәзер акылга утыра башладылар бугай. Шуны ачык аңларга кирәк — зарлану, елау чоры үтте. Сорау, ялвару чоры да үтте. Урамнарны шаулатып, тетрәтеп, нык басып үтәр, даулар чаклар җитте. Җиребез каны — татар нефтенә, урманнарыбызга, балаларыбыз авызларына кабып өлгермәгән ризыкка кул сузучы үзәк ведомстволарның, Мәскәүнең комсыз, әрсез кулын туктатыр вакыт җитте. Ач, хуҗасыз Рәсәйне без туйдырырга тиеш түгел! Моның юлы — парламентта көрәш, алай да барып чыкмаса — забастовкалар, блокада һәм бойкотлар. Күп милләтләр инде бу юлны үтеп, азмы-күпме ирек яуладылар. Без, авызыбызга сукканда да, бәрәкалла, дип торабыз. Нәрсә бу — татарлыкмы, әллә ахмаклыкмы?

*— Чын каһарманнар бездә нишләп бик тә, бик тә аз икән?*

— Чын каһарман, көчле шәхес булу өчен милләтеңнең дә көчле булуы кирәктер шул. 438 ел буе килгән буйсыну, җиңгән халыкка (русларга) баш иеп яшәү безне буйсыз иткән, холкыбызны бозган. Изүчедән ала алмаган үчне татар бер-берсен кыйнап, бер-берсен «ашап» ала. Беребез күтәрелә башласа, икенчеләребез аны тизрәк өстерәп төшерергә ашыга, әле «олкән абый»га — Мәскәүгә әләкләргә дә оятыбыз җитә. Нинди хурлык! Ике татар сугышканны өченчеләр өстән көлеп карап тора. Татарда «сынган кеше» психологиясе, җиңелүче (кол) холкы һаман нык саклана. Дастаныбызда: «Ком җыелып таш булмас, кол җыелып баш булмас»,— диелә. Әллә шул хак юрау-әйтем бүгенгә дә туры килә инде? Һаман безгә кемдер баш, һаман без газета-журнал битләрендә үзебезне 4 гасыр элек җиңгән халыкка каршында реверанслар ясыйбыз, чүгеп-чүгеп алабыз, шыр сөяккә калган тар күкрәгебезне төеп, тугрылыкка ант итәбез. Йә, кемгә кирәк бу кәмит? Көчле көчлене генә ярата, көчлене генә санлый. Чын каһарманнар югарыда саналган менә шул яман сыйфатлардан азат булырга тиешләр. Чын каһарманнар үсеп чыгу өчен җирлек, үрнәк кирәк, үзеңнән алдагыларның ялкыны кирәк, бәлки, җан тетрәндергеч хәлләр, корбаннар да кирәктер.

*— Үзегезнең көрәш һәм иҗат юлыгыз — сәнгать, журналистика, әдәбият аша политик көрәш сферасына аяк басуыгыз хакында ниләр уйлыйсыз? Шул уңайдан яшь көрәшчеләр белән тәҗрибә уртаклашсагыз иде.*

— Сез берсен дә онытмагансыз. Әйе, сәнгать тә булды — Казан театр училищесы һәм Казан телевидениесе студиясендә эшләү; журналистика — «Азат хатын» журналы, «Татарстан яшьләре», «Социалистик Татарстан» газеталарында эшләү; әдәбият — «Болын», «Чакрым баганалары», «Битлек», «Кем?», «Күл байлыгы», «Канатсыз акчарлаклар», «Кыңгырау», «Сәнгать дөньясына сәяхәт» әсәрләре, дисталәгән пьесалар. Һәм шуларның барысын да калдырып, иң авыры, язылачак әсәрләрнең өлешенә кереп — сәясәт. Кырык яшьтә зур сәясәткә килү. Сүз көче белән үзгәртә, эшли алмаганны сәяси көрәш юлы белән хәл итәргә тырышу. Яхшымы бу, начармы — вакыт әйтер, кешеләр әйтер. Моңа хәтле булган тормыш тәҗрибәм — ун балалы гаиләдә үсү, кечкенәдән көтү көтүләрем, ун сум акча белән, укырга дип авылдан чыгып китүләрем, татар булганым өчен генә хыялыма ирешә алмавым, яшьтән акчасызлык, фатирсызлык, үземнән шактый өлкән кеше белән (11 яшь ара) тормыш алып бару, тулай торак, барак, вагоннарда тору, сусыз монгол чүлләре, авыр, кара эш, олыгаеп беткәч, 33 яшемдә, Казан дәүләт университетына укырга барып керү, ике баламны карый-карый, аена 100 сумга эшли-эшли 6 ел уку, төннәрен әдәби әсәрләр язу, читкә тибәрелүләрем — сәясәтне, халык тормышын аңлауда соңыннан барысының да ярдәме булды.

Тәҗрибә уртаклашуга килгәндә, безнең тәҗрибә яшьләргә ярамаска мөмкин. Илдә политик ситуация тиз үзгәрә, политик көрәштә кичәге алым бүгенгә ярамаска мөмкин. Бүгенге политик халык тормышын да, экономиканы да, динне дә, тарихны да яхшы белергә тиеш. Һәм бик сизгер булырга. Һаман-һаман тәнкыйтьләү белән дә мавыгырга ярамый, һәрнәрсәнең чиге бар, куштанлык, төчелек гайрәтне чигергән кебек, һаман тәнкыйтьләп, өйрәтеп йөрү дә халыкны тиз туйдыра. Политикны политик иткән нәрсә — ул гайре табигый булмаган, кыю, конкрет эшләр, шул ук вакытта чама хисен дә югалтмау. Зур принципларга, кыйблага хыянәт итмәү, шул ук вакытта зур эш, максат өчен кечкенә корбаннарга, ташламаларга да бара белү. Янында таянырдай кешеләр әзерләү һәм аларны сакларга тырышу. Яшь көрәшчеләргә менә бу киңәшләр файдалы булыр, дип уйлыйм. Иң мөһиме — үз милләттәшең белән сугышып ятудан сакланырга кирәк. Безнең инде, читләр котыртуы белән, сыйныфларга бүленеп сугышкан чаклар үтеп бара, хәзер, киресенчә, татарның аппаратчысына да, милләтчесенә дә бер нәрсә — Мәскәүдән, рустан бәйсезлек өчен көрәшер вакыт җитте.

*— Бүгенге татар язучысына ни җитми? Ни өчен ул Тукай кебек түгел, Г. Ибраһимов һәм Такташ кебек түгел?*

— Яхшы әсәр җитми. Тукай, Ибраһимов, Такташлар язмышы җитми. Зурлык җитми. Сазлыкта төз нарат үсә алмаган кебек, безнең әхлакый черек мохит тә мәһабәт язучыларын үстереп чыгара алмады. Язучы дип йөргән күбебезнең хәле җиһан югарылыгыннан караганда шактый мескен, аяныч. Күбебездә сәләт бар, ләкин ходай биргән талант җитенкерәми. Юкны бер нишләтеп булмый, булган сәләтләрне сакларга кирәк.

*— Сезнең ихтыярыгызда булса, бүген СССР тормышында нинди үзгәрешләр ясар идегез? Аларны ясау өчен реаль мөмкинлек мәсьәләсе ничек?*

— СССР тормышында кисәк кенә үзгәреш кертү — 17 нче елны яңадан кабатлау булыр иде. Без инде халык хәтле халыкны, муенын аяк астына китереп, арка миен өздек, нәтиҗәдә, 70 ел эчендә, бөтен гәүдәсен паралич суккан ярымдебил кыяфәтле бер масса әзерләп чыгардык. Аны хәзер кашыктан ашатырга, астына савыт куярга, аның өчен уйларга тиешбез. Без, 70 ел вакыт эчендә, «бир!» дип кычкырып торган 240 миллионлы масса әзерләдек. Хәзер шуның холкын, сәламәтлеген кисәк кенә ничек үзгәртергә?

Халыкның холкы бозык, холкы бозыкка, тормыш көйсез. Эшне башта кайсын сәламәтләндерүдән башларга? Мөгаен, кешеләрдән. Аның да инде арка мие, җилкәсе корыганын түгел, яңа туып, әле бозылып өлгермәгәнен. Мәктәпләрне тоталитар партия идеологиясеннән коткарырга кирәк, мәктәпләр тәрбия түгел, бары тик дөньяви һәм дини белем генә бирергә тиешләр. Балага тәрбияне ата-анасы, нәселе бирер. Мәктәпләрдә бүгеннән дин сабаклары бирер вакыт җитте. Ләкин моның бер куркыныч ягы бар; безнең илдә, укытулар, нигездә рус теленда барганга, һәр мәктәпкә, тәре тотып, христиан вәгазьчеләре керергә мөмкин. Димәк, Татарстаннан читтә яшәгән 5 миллион татарның баласы, чиркәүгә барып чукынмыйча, мәктәптә үк, христиан дине кабул итә, ягъни, чиркәү үзе мәктәпкә килә. Димәк, рус һәм татар мәктәпләрен аеру, балаларны аерым укыту, иртәме-соңмы, ата-аналар каршына да килеп басачак. Юкса, ата-аналар арасында әлегә пошмаслык, сансызлык бик көчле. Алар, үз ризалыклары

белән, балаларының телләрен урыска саттылар инде, хәзер эчтәге соңгы иман нурын сату турында сүз барачак. Ата-аналар ни теләр икән?

Мәктәп, милли һәм дини тәрбия — үзгәрешне әнә шулардан башларга кирәк. Һәр халык үзенчә яшәсен, үз эзенә төшсен, башкаларга зыянын салмасын. Минем ирекгә булса, руслар арасында аңлату-тәрбия эшләрен зурдан алып баруны куяр идем. Югыйсә, «Сез зур халык, сез гөнаһсыз халык», — дип аларның да холкын шактый боздылар. Зур һәм кечкенә халыклар юк. Минем өчен чукча белән рус — икесе бер дәрәҗәдә. Рус язучылары һәм галимнәре шуны һәрдаим үз халкына аңлатып торырга тиешләр, югыйсә, безнең язмыш, яһүдләрнеке кебек, русларның «Память» оешмалары кулында калырга мөмкин. Рус халкын тәрбияләми, холкын сәламәтләндерми торып, без бу илдә бернинди үзгәрешкә дә ирешә алмабыз ахры, дип уйлыйм.

Ә инде экономик хәлгә килгәндә, акылы, холкы сәламәтләнгән кеше белән нәрсә дә эшләргә була. Беренче чиратта, хәрби промышленностьны, армияне яртылаш кыскартыр вакыт җитте, югыйсә, бу көчләрне безнең үзебезгә каршы куллана башладылар. Минем ирекгә булса, артта калган илләргә ярдәмне туктатып торыр идем, чөнки үзебез хәзер иң артта калганнардан хисапланабыз. Илгә чит илләрнең капиталы, ярдәме бик кирәк! Әгәр матбугатны күзәтеп барсагыз, чит илләрнең ярдәменә, нигездә, руслар каршы, янәсе, Советлар илен ваклап дошманнарга сатабыз! Алай икән, Рәсәй (руслар) бу ярдәмнән баш тартсын, ә башкаларын өйрәтмәсен инде, без кемнән нинди ярдәм алырга, кемгә ничек ярдәм итәргә үзебез белербез.

Шулар нәтиҗәсендә җыйналган байлыкның бер өлешен (зур өлешен) авылларны торгызуга, бер өлешен шәһәр халкын торак белән тәэмин итүгә бирергә мөмкин. Әгәр инде сүз Татарстан республикасы турында барса, минем ирекгә булса, аны мөстәкыйль татар дәүләте итүгә бөтен көчемне куяр идем. Иртәме-соңмы, чик мәсьәләләре турында да сүз кузгалачак. Чөнки Себер дә, Урал да, Пенза, Сарытау (Саратов), Самара (Куйбышев), Хаҗитархан (Астрахань), Ырынбур да — тарихи татар җирләре. Без бүген, тәүфикъсыз песи балалары кебек, «союздаш», «союздаш», дип шыңшыйбыз, юкса бит, ярты Рәсәй — безнең җир! Андагы татар мәктәпләре, уку йортлары, татар газета-журналлары, мәчет-мәдрәсәләре юк ителде, бүген андагы чиста татар авылларында балалар рус телендә тәрбия кылына, укытыла. Рас, Рәсәй хөкүмәте татарларга үз ана телләрендә тәрбия алырга, үсәргә мөмкинлекләр тудырмый, ирек бирми икән, без, иртәме-соңмы, татарлар яшәгән ул татар җирләрен яңадан Татарстан дәүләте составына кушуны күтәреп чыгарга мөмкинбез. Мин шуны яхшы аңладым — бары тик көчле үз дәүләтең булганда гына милләтне саклап калырга, яшәтергә мөмкин. Ә инде шушыны тормышка ашырырга реаль мөмкинлекләргә килгәндә, татар халкының күпчелеге шушылай уйларга һәм шушылар өчен көне-төне көрәшергә тиеш.

*— СССРдагы төрки милләтләрнең үзара бәйләнешен ныгыту мәсьәләсе хәзер бик тә актуальләште. Сез бу эштә актив катнашасыз. Әлеге юнәлештә ниләр эшләнде, тагын нәрсәләр алда тора?*

— Кем өчен актуальләште? Төрки халыкларның үзләре өченме? Аларның күбесе үзенең төрки халыктан икәнен белми дә. Татарларга төркиләр турында нәрсә аңлатканыбыз бар — мәктәпләрдә махсус төрки халыкларның тарихы, әдәбияты укытыламы? Нindидер бәйләнешләр бармы? Һични юк, төрки сүзе, кемнеңдер яшерен, көчле кулы белән тарихтан сызылды һәм без анда да ризалашып калдык. Бәлки, Мәскәүдә утырган империя вассаллары өчен безнең үзара бәйләнеш кирәктер? Ай-һай... Дөнья төрки халыкларның үзара бәйләнешеннән, бердәмлегеннән уттан курыккандай курка! Дөнья хәтерендә — төрки каганатлар тарихы, госманлы империясе, туранчылар күтәрелеше. Элек-электән төрки халыклар кыю, сәламәт, тәңреле-аллалы халык булган. Аларны заман юкка чыгара алмаган. Менә шул яшәүчәнлекләре, тәртипләре белән алар күпләрне өркетә дә инде. Төрки халыкларның үзара бәйләнеше бүген бары тик безгә — милли көрәшчеләргә кирәк. Шушы фикергә башлап Әзербайҗан халык фронтында килделәр, шушы фикер төрекләрнең Көнбатыш Германиядә оешкан «Төрек-Ислам берлеге» җәмгыятендә күтәрелеп, дөньяга таралды, шушы фикер бүген Татарстанда, Татар иҗтимагый үзәге, «Иттифак» партиясе җитәкчеләре арасында ныгып килә. Әйе, безгә бәйләнеш кирәк, безгә, авыр вакытта сыенырга аркадашлар кирәк. Шушы унайдан чыгып, бу тотрыксыз илдә милләт буларак исән калу өчен, без, төрки халыклар, үзара берләшә башладык. Бу хәл узган ел башланды. Баку шәһәрендә төрки халыкларның милли хәрәкәтләреннән — үзбәк, татар, казах, кыргыз, гагауз, төрекләрдән — ике тапкыр вәкилләр җыелды. СССРдагы төрки халыкларның уртак мәдәнимәгариф оешмаларын төзү буенча конференцияләр булды, мин үзем дә аларда катнаштым. Булачак оешмабызны «Берлек» дип атадык, аның Уставын һәм Программасын эшләдек. Быелның апрель-маенда СССРда яшәүче төрки халыкларның 1 нче корылтае булырга тиеш иде, без шуңа хәзерлек эшләре дә башлаган идек. Ләкин сугыш башланды. Бакуга танклар керде. Төрки халыклар тагын берләшә алмыйча калдылар. Ләкин безнең хезмәт эзсез калмады. Әзербайҗан һәм татар халыклары арасына без күпер салып калдырдык. Әлбәттә, бу күперне яндырырга, шартлатырга тырышучылар табылачак, төрки халыклар һәм мөселманнарның үзара сугышып торуы кемнәр өчендер бик кирәк, ләкин хәзергә ул күпер нык тора. Әзербайҗанга танклар керткәч, армиянең бу акциясенә каршы, Татар иҗтимагый үзәге һәм «Иттифак» партиясе әгъзалары

урамнарга чыгып, пикетлар, митинглар уздырдык. Мәскәүгә протест телеграммалары җибәрдек, шулай итеп, без Татарстаннан Әзербайҗанга татар сугышчы-резервистларын җибәрүне өздек.

Месхетия төрекләре авыр хәлдә калгач, Әзербайҗанга күчеп кайткан төрекләр өчен Казаннан бер самолет әйбер җыеп илтеп бирдек. Мәрҗани мәчетендә мин үзем ул әйберләрне ай буе тупладым. Кырым татарларының хәле авырайгач, Кырымга барып, партия һәм совет органнарында булдык, Мәскәүгә протест телеграммалары җибәрдек, күп санда русча һәм татарча м ә к а л ә л ә р бастырып чыгардык. Җәен безнең студент яшьләребез Кырымга барып, татарлар өчен йортлар салышты.

Төрки халыклар белән бәйләнешләр менә шушылай башланып китте. Ләкин болар гына аз. Безгә бер программа белән, бер якка хәрәкәт итәргә кирәк. Славян халыклар һәр ел саен үзләренең мәдәният һәм язмачылык көннәрен билгеләп үтәләр. Горбачев, аларны котлап, телеграммалар бирә. Ә төрки халыклар берләшә башласа, инде аларга каршы ярлыклар (пантюркист, туранчы) һәм танклар әзер. Әле безнең үзбәк, казах, кыргызлар белән дә уртак тел табып бетерә алганыбыз юк. Бу безне бик борчый. Без берләшергә өлгермәдек, ә безгә каршы көчләр тиз берләште, безнең арада кечкенә генә яра-низаг булса, алар анда килеп балта чаптылар, пыскып яткан ризасызлык учагын бензин сибеп ярсыттылар, шулай итеп, үзбәк — месхетия төрекләре, үзбәк — кыргыз фаҗигаләре туды. Ә болар бит борынгы төрки бабаның ике бертуган балалары. Илне тутырып, төрки каны ага. Аны кем туктатыр? Бары тик төрки халыклар үзләре, милли хәрәкәт башында торган акыл ияләре.

Быел декабрь аенда Татар иҗтимагый үзәгенең 2 нче съезды була. Без аңа бөтен төрки халыклардан да вәкилләр чакырырга һәм үзебезне борчыган бу мәсьәләләр турында бергәләп киңәшләшергә, сөйләшергә уйлыйбыз. Ул съезд төрки халыклар корылтаена да әйләнеп китәргә мөмкин. Димәк, тарих безне сайлады: Әзербайҗаннан башланган изге эшне без — татарлар дәвам итәргә тиеш булабыз. Безгә, милли сәясәтчеләргә, татар зыялыларының, татар язучыларының ярдәме бик кирәк!

*— Германия Федератив республикасы Сездә нинди тәэсирләр тудырды? Безнең өчен гыйбрәт алырдай ниләр күрдегез, кичердегез?*

— Германия Федератив республикасындагы тормышны күреп, мин әллә ни гаҗәпләнмәдем, чөнки ул илнең шулай бай булуын күрергә мин инде әзер идем. Ә менә шул илдә, без фашистик, капиталистик, тагы әллә нәрсәләр дип атаган илдә төрекләрнең ни дәрәҗәдә яшәвен күреп, мин шактый гаҗәпләндем. Татар, мәсәлән, үз илендә дә шулай иркенләп яши алмый. Әгәр сезгә: «Мәскәү радиосы татарлар өчен һәр көн 20 минут татарча тапшыру эшли»,— дисәләр, бу могҗиза булып ишетелер иде. Ә менә алман радиосы төрекләр өчен һәр көн 20 минут төрекчә тапшыру ясый — һәм бу гадәти хәл. Мәскәү телевидениесе татарлар өчен ике атнага бер тапкыр сәгать ярымлык тапшыру эшләп барса, күпләр өчен гаҗәп тоелыр иде. Ә Көнбатыш Германиядә бу нәкъ шулай — төрекләр өчен телевидение тапшырулары да эшләнә. Советлар Союзында татар балалары укыган кайсы шәһәр мәктәпләрендә м ә җ б ү р и р ә в е ш т ә татар теле укытыла? Ә немец мәктәпләрендә атнага ике тапкыр, мәҗбүри рәвештә, төрек балаларына төрекчә сабаклар бирәләр, аннан имтиханнар билгелиләр. Кечкенә генә Көнбатыш Германиядә төрекләрнең 700 мәчете эшли, манараларыннан азан әйтеп яталар, беркем куып төшерми. Немецлар төрекләрне шулай яраталармы? Юк, бу — хокукый дәүләт, һәм хөкүмәт башында торучы немец милләте үзендә яшәүче башка милләт вәкилләре хакында да кайгыртырга мәҗбүр. Руслар да безгә карата шулай булса, ә? Әкият...

Гомумән, андагы төрек милләте миңа ошады. Мин алар турында бик аз белә идем. Без монда елгаларны корытып, бер-беребезне төрмәләргә утыртып, әллә кемнәр белән кан катнаштырып, иманны югалтып яткан заманда, төрекләр бер якка цивилизацияне, икенче якка куәтле ислам динен канат итеп алып, үзләренә инде әллә кайчан күркәм дөнья төзеп куйганнар. Аларның эчләрендә дә, тышларында да җәннәт, ягъни алар бик иманлы, дини, әдәпле дә, бик бай, матур тормышлы да халык. Минем халкым кайчан шуларга ирешер — җавабым да юк.

*— Бездә хәзер төрле җәмгыятьләр, оешмалар шактый күп. Ләкин татар милләте өчен иң кирәкле нәрсәләр белән (мәсәлән, милли мәктәп белән) конкрет шөгыльләнүче юк диярлек. Ә бит бу иң авырткан, иң хәлиткеч нәрсә...*

— Милли мәктәп мәсьәләсе белән милли дәүләт шөгыльләнергә тиеш. Хәзергә әле безнең милли дәүләтебез дә, милли мәктәпләребез дә юк. Бүгенге катнаш рус мәктәпләрендә без балаларыбызны харап кына итәбез. Безнең укыту системасы да, программа да, дәреслекләр дә бөтенләй икенче — үзебезнеке, татарныкы булырга тиеш. Бары тик милли дәүләтнең генә моны эшләп чыгарга көче җитәчәк. Ә инде төрле җәмгыятьләргә, оешмаларга килгәндә, алар бары тик иҗтимагый аңга тәэсир итү вазифасын гына башкара алалар, чөнки алар кулында власть та, акча да, кадрлар да юк.

*— Читтәге татарларның киләчәген Сез ничек күзаллыйсыз?*

— Өметле итеп түгел шул. Аларның күбесенең исемнәре генә татар инде. Мәктәплә-

ре юк, газета-журнал, театрлары юк, мәчетләре юк. Исәпкә бар, санга юк, кебегрәк. Андагы татарларга татар булып калу өчен ике юл бар, беренчесе — ни хәлгә килеп җитүләрен аңлап, милли азатлыклары өчен үзләренә көрәшкә күтәрелү, яңадан телләрен, диннәрен яулап алып, кире кайтару. Казаннан килеп эшләгәннәрен көтеп тормыйча. Ләкин татар, ай-һай, моңа күтәрелерме икән? Татар куркаграк бит ул, тынычны ярата. Үз ишегалдында исән калырмын, дип уйлый, җанына үрмәләп барганнарын күрми. Милли бәйсезлек өчен көрәш юлы — электән татар җирләрендә яшәп тә, хәзер үз илендә килмешәк хәлендә калганнары өчен бердәнбер юл.

Ә башка милләтләр арасына, алар җиренә барып урнашкан татарларга, исән калу өчен, иң дөрес юл, минемчә, яңадан илгә кайту. Әлбәттә, бу һәммәсенә дә кагылмый. Ләкин үзен татар дип исәпләгән, балаларының татарча белем-тәрбия алуларын теләгән, милләтен сакларга һәм аның өчен эшләргә җан атып торучылар өчен илгә кайту — иң дөрес юл. Бигрәк тә ут чыккан урыннардан татарларга тизрәк китәргә кирәктер, дип уйлыйм. Бүген месхет төрекләре, үзбәк, кыргыз йортлары янса, иртәгә татар йортына да ут кабарга мөмкин.

*— Сез бит әле безнең халкыбызның иң яратып укыла торган язучыларыннан берсе дә. Шул уңайдан берничә сорау. «Күл балыгы»на икенче тормыш бирергә уйламыйсызмы? Ул әсәр зуррак игътибарга, сәхнәдә һәм экранда яшәүгә бик тә лаек бит...*

— «Күл балыгы»... Сәер һәм серле әсәр... Минем, шул күл балыгы кебек, телсез, чарасыз, бәхетсез чагым, әйләнә-тирә мохитем дә — ясалма, тынчу күл... Тормыш — яшәлгән, әсәр язылган инде. Аларга кире әйләнеп кайтып булмый. Бәлки, кемнәрдер бу әсәргә әйләнеп кайтырлар, кемнәрдер аны өр-яңадан ачар... Бәлки, аңа композиторлар һәм кинематографлар игътибар итәр. Мин үзем аны сүзсез фильм итеп күрәм. Фильм бары тик музыкадан һәм хәрәкәттән генә тора. Ләкин бу балет түгел. Бу — җанның җиһанга тартылуы турында өмет һәм фаҗигадән торган сүзсез җыр. Мин аны җырладым инде...

*— Әдәби иҗат белән политик көрәш бер-берсенә ничек тәэсир итә?*

— Политик көрәш әдәбиятка дигән вакытны ала һәм моңга, нечкә хискә урын калдырмый диярлек. Ләкин политик көрәш язучы өчен бик зур тормыш материалы бирә ала, акыл һәм мәкернең яхшылык һәм явызлыкның, искелек һәм яңалыкның көрәш серләрен өйрәтә. Патшалар тормышын да күрәсең, иң авыр хәлле кешеләрнең дә хәсрәтенә кереп батасың. Әдәбият минем күңел күземне ачса, сәясәт исә акыл күземне ачты. Аларның һәр икесе дә миңа бик кирәк. Политик көрәш тәҗрибәсенә таянып, политик, тарихи һәм публицистик романнар тудырырга мөмкин. Чит илләрдә бу шулай эшләнә дә.

*— Хәзерге милли һәм политик көрәштән читтә торучы татар язучыларына Сез ничек карыйсыз?*

— Әгәр яхшы әсәр бирә алса, барысын да кичерергә мөмкин. Бөтен кеше дә политика артыннан йөри алмый. Союздашлык һәм тел мәсьәләсендә татар язучыларының да ярдәме булды бит. Дөрес, татар язучыларына политикада системалы итеп эшләү осталыгы җитми, алар күп көчләрен эчке сәясәткә — төрле төркемнәр арасындагы көрәшкә исраф итәләр. Яки ул бернәрсәгә дә катнашмый, ягъни «даһи» була. Һәркемнең үз эше. Ләкин бер нәрсә күңелне борчый — әнә шул «милли һәм политик көрәштән читтә торучы татар язучылары» тел көрәшендә бик шәп «эшлиләр» шул. Без, милли көрәштә катнашучылар, татар язучыларының сүлпәнлегенә борчылсак та, халык алдында аларга таш атарга җыенмыйбыз, ә нәкъ шул язучылар безгә шактый еш һөҗүм итәләр, янәсе, без бушбугазлар, сүздән уза алмыйбыз, кирәкле эшне эшләмибез, хәтта җитәкчеләр белән халык арасын бутыйбыз! Монда да татарлык инде! Үзе дә эшләми, башка берәү эшләүне дә килештерми. Әллә нинди вак, усал, астыртын көнчеллек, арттан китереп тибәргә ярату. Язучыга һич килешә торган нәрсә түгел. Бәлки, андый кешеләрнең милли хәрәкәткә килмәве дә яхшыдыр.

*— Якын арада укучыларга нинди әдәби әсәрләр бүләк итәргә җыенасыз?*

— Мөгаен, милли азатлык өчен барган шушы көрәш, шушы көннәр турында, үземнең бу юлда нилә күргәннәрем турында бер документаль әсәр язармын. Мин аны әдәби әсәрләрем югарылыгына күтәрергә тырышырмын. Материал инде әзер.

*— Сезнең республика Югары Советы депутаты булып сайлануыгызга бик күп фикердәшләрегез чын күңелдән сөенде. Инде менә хәзер байтак кына вакыт та узды. Яңа вазифа Сезне нинди яңа каршылыклар белән очраштырды? Депутат Бәйрәмованың көрәше турында сөйләп үтсәгез иде.*

— Депутат Бәйрәмованың көрәше Татарстан Югары Советының беренче сессиясендә власть өчен көрәштән башланды. Бу сүзгә һич гаҗәпләнмәгез — кулда реаль власть, көч булмыйча, югарыда сөйләгәннәрнең чиреген дә хәл итеп булмаячак. Ләкин, үзегез беләсез, Татарстан Югары Советы рәисе өчен барган көрәштә мин җиңелдем һәм вакытлыча бу максатымнан читенеп торырга мәҗбүр булдым. Депутат буларак, нинди каршылыкларга очрыйм? Конкрет мәсьәләләрне, сайлаучыларның наказын

утәгәндә, кулда власть, көч юк. Халык миннән бары тик с о р а п кына килә, ә минем кулымда бирер әйберем юк. Җитәкчеләр исә халык алдында да, депутатлар алдында да җаваплылык тоймыйлар. Төп каршылык — иске системаны үзгәртеп булмый. Икенчедән, парламентта таяныр кешеләр, тарафдарлар азрак. Мин милли һәм мәдәни мәсьәләләр буенча комиссиядә эшлим. Татар милләтенә караган һәр мәсьәләне, законнарның һәр пунктын без бик зур авырлык белән, «кан коеп» уздырабыз. Руслар һәм рус телле татарлар тарафыннан шулкадәр каршылык! Тел турында Закон проектын тикшерү буенча дүрт тапкыр җыелып, талашып таралдык. Татар гимназияләре ачу буенча өч тапкыр кычкырышып таралдык. Җанга иң авыры — рус телле (татарча белми торган) татарларның кыланышы. Рус каршы әйтергә икеләнеп торганда да, болар татарга өздереп «юк!» диләр. Нинди авыр хәл! Нинди фаҗига! Татар үз татарын юк итәргә хөкем, законнар чыгара! Бозылды халыкның холкы, ай, бозылды... Шуны терелтергә кайдан көч-куәтләр аласы...

— *Бүген татар халкына булган иң зур теләгегез нинди?*

— Иң зур теләгем — милли бәйсезлек. Аны яулау өчен татар куркак һәм мескен булмасын; үз бәхете өчен үзе көрәшергә өйрәнсен; милли горурлыгын югалтмасын; бөек тарихын онытмасын; киләчәген уйласын.

— *Яшь каләм ияләреннән кемнәр Сезнең игътибарыгызны җәлеп итә алды? Алар иҗатында Сезгә нәрсәләр ошый, ә кайсы яклары борчый, уйландыра?*

— Инде әйткәнемчә, яшьләр арасында да сәләтлеләр бар, талантларны күрмим. Шәхесләр күрмим. Яңа нәрсә күрмим. Әдәбияттагы кечкенә нәрсәләр турында зурлап сөйләп торасым килми. Хәзергә күз туктатырлык кеше күрмим. Аннан «яшь каләм иясе» булып әдәбиятка килүчеләр дә миннән карт инде. Үземнең чордашлардан Нурия Измайлованың прозасын яратып кабул иттем.

— *Язучы Фәүзия Бәйрәмова иҗатында нинди кимчелекләр, җитешсезлекләр күрә аласыз?*

— Язучы өчен дә, сәясәтче өчен дә шактый куркыныч нәрсә — кабатлану. Фикер сөрешенең үсмәве. 6-7 повестемнан соң, язучы буларак мин үземдә бераз кабатлану сизә башладым кебек. Кем белә, бәлки бу кабатлану да түгелдер, беренче әсәрләремдә башланган фикернең яңа формада, башкаларына күчә барып үсешедер? Тәнкыйтьчеләр минем әсәрләремә җыеп бер анализ ясый алмадылар, мин яздым да яздым. Минем моңа хәтле язган әсәрләрем хәсрәтле булып бетте. «Болын»ның гына, мәҗбүри рәвештә, ахырын «бәхетле» итеп тәмамлаттылар. Әсәрләремдә аллә нинди бетмәс-төкәнмәс хәсрәт, әйбәт кенә барганы да шул якка кереп китә. Кешегә мондый әсәрләрне уку бик авырдыр. Бу — нәрсә, минем кимчелегемме — белмим. Ләкин мин башкача яза да алмыйм. Табигатьтән миңа күпме һәм ни бирелгән — мин шуны гына бирә алам.

— *Бер 50 елдан татар милләтен ни рәвешле итеп күз алдына китерәсез?*

— Әгәр милли үзаңы уянса, ислам динен туры юлдаш итеп алса, татар халкы 50 елда нык алга китәргә мөмкин. Чөнки халык тырыш, эшчән, ул яктан теләсә кем белән бил алышырлык. Ләкин бүгенге кебек уяныр-уянмас ятса, берсе күтәрелгәндә, икенчесе бәреп төшерсә, милләте түгел, үз карыны турында гына уйласа, татар өстеннән тарих арбасы дөбердәп узып китәчәк. Татар тузан булыр, башкаларны җигелеп тартыр өчен эш аты, мәңгелек исемсез кол булыр. Мондый киләчәктән ходай үзе сакласын!

— *Татар матбугатының бүгенге эшеннән Сез канәгатьме? Аңа нәрсәләр җитми?*

— Шунысы сөендерә — яхшымы-яманмы, татар матбугаты күтәрелергә азаплана. Үзгәреш чоры килеп, башкалар колбаса һәм фатир даулый башлаганда, зыялы татарлар мәктәп, газета, мәчет сорый башлады. Нинди сөенечле хәл — күпме яңа татар газеталары чыга бит! «Таң йолдызы», «Аваз», «Нур», «Өмет», «Дуслык»... «Социалистик Татарстан» газетасындагы «Әллүки» кушымтасы... Болар — сөендерердәйләре. Көендердәе — бездә милли журналистика мәктәбе юк. Агач тел белән генә түгел, агач баш һәм агач йөрәк белән журналистикага килүчеләр һәм шунда мәңгегә топланеп калучылар күп. Татар журналистлары һаман илдә барган политик хәлгә анализ ясарга куркалар. Әлбәттә, аларның бу яклары миңа ошап бетми инде.

— *«Казан утлары»на нинди теләкләрегез бар? Ул Яңарыш рухына җавап бирәме?*

— Яхшы проза аз. Ләкин Сез язучылар ни бирә, шуны чыгарасыз инде. Шулай да бик йомшакларын, күреп торып искергәннәрен бәлки чыгармаска да кирәктер? Начар әйберне чыгармау да Яңарыш бит инде ул, шулаймы? Төрки халыклар иҗатын күбрәк яктыртырга иде, бераз кан алмаштыру, яңа мәктәп булыр иде. Журналга эшкә күбрәк шәхесләрне тартырга кирәк. Бәлки, редакция коллективында да, әдәбияттагы кебек, буыннар алмашыр чак җиткәндер? Катырак әйтсәм, кичерегез, ләкин журналны көчле һәм кыю көрәшче итеп күрәсе килә шул.

Әңгәмәне **Мансур ВӘЛИЕВ** алып барды

# КОРЪӘН СҮРӘЛӘРЕ

## «Укыйм тиз-тиз күңелдән бер гаҗәеп сүрә Коръәндин»

Илебездә барган үзгәртеп кору һәм яңарыш хәрәкәте хәятебезнең барлык якларына да шифалы йогынты ясап, яңача яшәү һәм яңача фикерләү өчен ныклы җирлек булып тора. Кешеләр өстән кушканны гына эшләргә түгел, ә мөстәкыйль фикер йөртергә дә сәләтле икәнлекләрен күрсәтә башладылар. Яңа хөррият һәм фикер азатлыгы моңарчы эчтән генә борчылып, сыкранып, сызланып та авыз тутырып сөйләргә ярамаган нәрсәләр турында бергәләп киңәшеп, аларны уңай хәл итү өчен шартлар тудырды. Үзебез белә торып та онытылырга мәҗбүр ителгән, исемнәрен телгә алу да зур гөнаһ саналган затлар һәм әсәрләр халыкка яңадан кайтарыла башлады, йөз аклыгыбыз булган шәхесләребез аклана һәм мәгълүм кешеләр тарафыннан махсус барлыкка китерелгән тарихның «ак таплар»ын бетерү эше алып барыла. Бу юнәлештә халкыбызның рухи мирасын барлау, өйрәнү һәм аны халыкка кайтарып бирү бурычын башкаручы, республика күләмендә оештырылган Рухи мирас комиссиясе үзенең эшен җитди итеп башлап җибәрде. Әлеге оешма ифрат кирәкле, файдалы эшләр белән шөгыльләнә һәм аның уңай нәтиҗәләре дә күренә башлады инде. Җөмләдән Г. Исхакый әсәрләрен һәм «Идегәй» эпосын яңадан халыкка кайтаруда Рухи мирас комиссиясенең күп көч куйганлыгын әйтеп үтәргә мөмкин.

Комиссия тагын бер мөһим һәм бик җитди мәсьәлә күтәрде — ул да булса Коръәнне татар теленә тәрҗемә итеп бастыру. Бу мәсьәләне күптән хәл итәргә кирәк иде дә бит... Әлеге дә баягы, үткән еллардагы «ярамый» дигән сүз, бу җитди мәсьәләгә өркеп карау, яки мәсхәрәләү рухында язып, Коръәннең «серләрен ачып» бирергә маташу кебек, аңа берьяклы гына, бик тар итеп карау нәтиҗәсендә нәрсә дә булса эшләү мөмкинлеге булмады.

Безнең халыкта, Коръән — ул дини-схоластик бер китап, аның кирәге дә руханилар өчен генә, безнең җәмгыять кешесенә аны белү һәм аның белән эш итү зарарлы, дигән караш тәрбияләнде, һәм, аннан килеп, язучы Гариф Гобәй «Коръән серләре» дигән китап та язган иде. Аның бу китабын күпләр Коръәннең тәрҗемәсе дип аңлыйлар. Ләкин бу алай түгел. Әле дә хәтеремдә, 1972 елның җәендә (мин ул вакытта Татарстан дәүләт музееның борынгы кулъязмалар бүлегендә фәнни хезмәткәр булып эшли идем) минем янга язучы Гариф ага Гобәй килде һәм музей директоры В. М. Дьяконовның кушуы буенча ике томлык «Тәфсире Ногмани» дип аталган Коръән тәфсирен бирүемне үтенде. «Ул китап Сезгә нигә кирәк, Коръәнне Сез турыдан-туры тәрҗемә итеп эшләмисезмени?» — дигән сорауга ул: «Мин китабымның икенче басмасын әзерлим, Коръәнне турыдан-туры тәрҗемә итә алмыйм, шуңа күрә тәфсирдән файдаланам һәм минем максатым да — тәрҗемә итү түгел, ә башка...» — дип җавап бирде. Китабының икенче басмасын әзерләгәндә аңа гарәп теле укытучысы Мәхмүт ага Рәхимов та бик күп булышкан иде.

Коръәнгә булган әлеге тискәре һәм берьяклы гына караш безнең ил мөселманнары арасында гына түгел, ә бөтен мөселман дөньясында да зур ризасызлык тудырды. Моның сәбәбе, әлбәттә, мондый җитди һәм четерекле мәсьәләгә, йомшак итеп кенә әйткәндә, җавапсыз карау, һәр нәрсәдән гаеп-кыек эзләү, сай мәгълүматлылык һәм кул астындагы чыганактан үз максатыңны, үз мәнфәгатеңне генә күздә тотып файдалану (ә бит бер үк фикерне төрле төсмерләргә манып, төрлечә аңлатып була). Китабын яндырып, авторның үзенә килен җибәргән кайбер чит илләрдән килгән хатлар турында бер очрашуда Гариф Гобәй горурланып «Коръән серләре»нең нинди «эффектлы» булып чыгуы турында сөйләгән иде.

Коръәнне укып карагач, башта төрле сораулар туа: ни өчен соң әле кайберәүләр тарафыннан соңгы заманнарда шулкадәр «зарарлы» дип тиргәлгән, мәсхәрәләп килен-

гән Коръәннән бөтен мөселман дөньясы йөз чөереп ваз кичми? Ни өчен соң аның идеяләре шундый «зарарлы» булгач, мең ярым елга якын яшәп сүнми дә, сүрелми дә, ә киресенчә яшәү көчен арттыра бара? Ни өчен соң без берьяклы гына карап, Коръәннең борынгы бабаларыбыз өчен тәрбияви-әхлакый кануннар мәҗмугасы булуын да, халыкның гореф-гадәтләрен, тормыш-көнкүрешен, зур тарихи вакыйгаларны тасвирлаган, хокук кануннарын, фәлсәфәсен, халыкның якты киләчәккә булган өметләрен һәм уй-хыялларын, әдәби ядкярләрен, сәнгатен эченә алган тупланма булуын да, гомумән, халкыбызның һәм бөтен мөселман дөньясы мәдәниятенең нигез ташы булуын да, һәм кешелек дөньясы барлыкка китергән иң бөек әсәрләрнең берсе икәнлеген дә сукырларча күрмәмешкә салынабыз? Әдәбиятыбызның чишмә башы булган «Кыйссаи Иосыф» әсәре дә шул ук Коръәндәге сюжетка корылган лабаса! Ни өчен соң шундый «зарарлы» дип саналган Коръән барлыкка килгән шәрык дөньясы мәдәнияте үз чорында Европа мәдәнияте үсешенә зур йогынты ясаган? Ни өчен соң Коръәннең бүгенгә кадәр татар телендә тулы, фәнни тәрҗемәсе эшләнмәгән һәм аның мәгънәсен белергә ярамый? Ә мондый тәрҗемә кирәк иде. Аның асыл мәгънәсен ачып бирергә иде бит!

Коръәннең мәгънәсе, аның эчтәлеге белән бик борынгы заманнарда ук кызыксынганнар. Һәркем үзенең фикерләү сәләтенчә аңлатып, бик күп тәфсирләр язганнар. Беренче тәфсирләр, ягъни Коръәннең аңлатмалары, әлбәттә, гарәп телендә язылган һәм калын-калын бик күп китаплар тәшкил иткән. Тәфсирләр VIII гасырда һәм аннан соң да эшләнгәннәр. Мәсәлән, мәшһүр тарихчы һәм Коръәнгә аңлатмалар язучы, 838—923 елларда яшәгән Әбү Җәгъфәр Мөхәммәд бине Җәзир әт-Табари тарафыннан зур-зур 28 том тәфсир язылуы мәгълүм. Ул 1872—1881 елларда Мисырда басылган. Моннан башка, шулай ук гарәп телендә, әл-Бәйзави, әл-Багдади, әд-Димәшкый, Ибне Гарәби, Ибне Хәзин, әл-Бохари кебек тәфсирчеләр язган күп томлы тәфсирләр һәм «Тәфсире Җәләләйн» дигән китаплар дөнья күрә һәм бу эш гасырлар буенча дәвам итә.

Коръәннең мәгънәсе һәм эчтәлеге белән шәрыкта гына түгел, ә гарәбтә (көнбатышта) да кызыксыналар. Биредә XII гасырга кадәр Коръәннең эчтәлеге һәм ислам дине турында берниндн мәгълүмат булмаган. XII гасыр башында Толедо шәһәрендә Коръәнне беренче тапкыр латин теленә тәрҗемә итәләр һәм ул 1543 елда Швейцариянең Базель шәһәрендә басылып чыга. Ә XVII—XIX гасырларда Коръән инглиз, алман, француз, голланд һәм башка телләргә тәрҗемә ителеп тарала. Шәрык һәм ислам дине буенча танылган белгеч профессор Л. И. Климович мәгълүматларына караганда, Коръәннең Джордж Сэйл тарафыннан инглиз теленә тәрҗемәсе 1734 елда Лондонда басыла һәм ул соңыннан, 1792 елда Георгий Колмаков тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителеп, Санкт-Петербург шәһәрендә басыла. Аннары Коръән 1775 елда Һалле шәһәрендә Ф. Е. Бойзен тарафыннан немец теленә тәрҗемә ителә. 1790 елда исә Коръән, Андрей дю-Рюэр-де-ла-Гард-Малезер тарафыннан француз теленә тәрҗемә ителгән нөсхәдән күренекле драматург һәм тәрҗемәче, Россия академиясе әгъзасы М. И. Веревкин тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителеп, Санкт-Петербург шәһәрендә басыла.

XIX гасырда да Коръән көнбатыш телләренә тәрҗемә ителә. Ирандагы француз илчелеге тәрҗемәчесе Альбин де Биберштейн-Казимирский тарафыннан ул француз теленә тәрҗемә ителә һәм шул нөсхәдән рус теленә К. Николаев тарафыннан тәрҗемә ителеп Россиядә 1864, 1865, 1876, 1880 һәм 1901 елларда басыла. Күргәнебезчә, Коръәннең рус теленә тәрҗемәсе көнбатыш телләрдәге тәрҗемәләрдән генә эшләнгән.

Россиядә Коръәннең тәрҗемәләре XVIII гасырда басыла башлый. Аларның иң беренчесе — А. дю Рие тарафыннан француз теленә тәрҗемә ителгән нөсхәдән рус теленә П. Постников тарафыннан тәрҗемә кылынып, Петр I фәрманы белән, 1716 елда Петербургта басыла. Соңрак, татарлар арасында «Әби патша» дип танылган Екатерина II биргән акчага, Госман Исмәгыйль дигән мулла тарафыннан әзерләнгән һәм аңлатмалар белән тулыландырылган Коръәннең гарәпчәсе 1787 елда Петербургта нәшер ителә.

Коръәннең беренче тапкыр турыдан-туры гарәп теленнән рус теленә тәрҗемәсе Казандагы Духовная академия профессоры Г. С. Саблуков тарафыннан эшләнә һәм ул 1879, 1898 һәм 1907 елларда Казанда басыла. Соңгы басмасы — Коръәннең уң як битендә гарәпчәсе, ә сул як битендә юлы-юлга русча тәрҗемәсе итеп эшләнә.

Коръәннең Мәккә сүрәләре, көнчыгышны өйрәнүче күренекле галим А. Е. Крымский тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителеп, 1902 елда Мәскәүдә басылып чыга.

Совет чорында гарәпчә Коръән рус теленә академик И. Ю. Крачковский тарафыннан тәрҗемә ителде һәм ул 1963, 1986 елларда Мәскәүдә басылды. Ләкин академик И. Ю. Крачковскийның вафаты сәбәпле бу тәрҗемә тулысынча эшләнелмәгән

Югарыда китерелгән мисаллардан соң: «Коръәннең татар телендә тәфсир[1] — аңлатмалары, тәрҗемәләре булганмы соң?» — дигән урынлы сорау туа. Коръәннең татар телендә тулы фәнни тәрҗемәсе әлегә кадәр юк, әмма ләкин тәфсирләре шактый күп булган. Бу эшне, татарлардан беренче буларак, татар иҗтимагый фикерендә рационалистик агымга нигез салучыларның берсе, мәгърифәтче галим, философ Габденнасыйр Курсави (1776—1812) башлап җибәрә һәм шул чорның татар телендә Коръәннең җидедән бер өлешенең «Һәфтияк тәфсире» исемле аңлатмасын яза. Бу китап Казанда беренче тапкыр 1861 елда басылып чыга.

1876, 1881 елларда Казанда, Таҗетдин Ялчыгол тарафыннан эшләнеп, шулай ук Коръәннең җидедән бер өлешенең татар теленә тәфсире басыла һәм ул «Китабе шәрәфел-мааб һәфтияк тәфсире» дип атала.

Татар әдәбияты классигы Фатих Әмирханның бабасы, тарихчы галим һәм рухани Хөсәен Әмирханов тарафыннан Коръәннең татар теленә тәфсире эшләнеп «Фаваид» исеме белән зур-зур ике китап булып басылып чыга.

Һәфтияк тәфсире Казанда төрле елларда, төрле исемнәрдә, төрле күләмдә басылуын дәвам итә. Шундыйлардан «Һәфтияк шәриф» исемендә 1840, 1871, 1873, 1874 елларда һәм «Яңа тәфсир, һәфтияккә тәфсир бәян» дип аталып 1914, 1915 елларда басыла.

Болардан тыш Коръәннең аерым сүрәләренең татар теленә тәфсирләре дә басылып килә. 1880 елда «Тәфсир сүрәтел-кәһаф», 1882 елда «Ясин шәриф тәфсире», 1915 елда «Ясин тәфсире, ясин шәриф мәгънәсе белән» дип аталган тәфсирләр дөнья күрә.

XX гасыр башында да Коръәнгә татар телендә аңлатмалар эшләп бастыру эше дәвам итә. Шәйхелислам Хәмиди тарафыннан эшләнеп, 2 кисәктән торган «Әл-иткан» тәфсире, 1912 елда «Коръән тәфсире», 1914 елда Ногман тарафыннан эшләнгән ике зур-зур китап булып «Коръән тәфсире», 1914 елда Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин тарафыннан эшләнгән «Татарча Коръәни тәфсир» нәшер ителә.

1912 елда Муса Бигиев һәм Зыяэддин Камали тарафыннан Коръәннең беренче тапкыр татарчага тәрҗемәсе эшләнә. Ләкин руханилар, моңа каршы чыгып, Диния Нәзарәтенә шикаять язалар һәм Казанның «Өмид» матбагасында басыла башлаган әлеге тәрҗемәнең киләчәге туктатыла. Безнең көннәрдә, ягъни 1985 елда Коръәннең 1907 елда Казанда Шәйхелислам Хәмиди тарафыннан шул чор татар теленә эшләп бастырылган 2 томлык «Әл-иткан фи тәрҗемәтил-Коръән» тәфсиренең күчермәсе зур тираж белән Катар дәүләтендә бастырылды һәм ул бөтен мөселман дөньясына таралды.

Укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган Коръән сүрәләре әлеге тәфсирдән алынды. Мәгълүм булганча, XX йөз башындагы һәм аңа кадәр булган халкыбызның язма һәм сөйләм теле бүгенге телебездән шактый аерылып тора. Ул чордагы телдә, заманына хас булган бик күп гарәп, фарсы, төрек телләреннән кергән сүзләр һәм үз телебезнең борынгыдан сакланып калган сүзләре кулланылганлыктан, табигый ки, аны бүгенге укучыларга аңлавы бик читен. Шуны күздә тотып, әлеге тәфсир бүгенге укучыбыз аңларлык итеп, җиңеләйтеп, гадиләштереп, шул ук вакытта төп мәгънәне саклаган хәлдә хәзерге телебезгә күчерелде. Кайбер урыннарда, мәгънә тулырак ачылсын өчен, сүзләр өстәп тә аңлатылды. Тоташ аңлашылмый торган сүзләрдән соң җөмлә азагында бер-ике төрки телдәге фигыль кулланып кына төзелгән җөмләләр дә, мәгънәсе сакланып, хәзерге телгә тәрҗемә итеп бирeләләр. Бу тәфсирдә сүрәләрдәге аятьләр саны куелмаган иде, ә журнал өчен әзерләнгәндә, укучы Коръәннең төп нөсхәсе белән чагыштырып укый алсын өчен, җәяләр эчендә аятьләр саны да куелды. Тәкъдим ителә торган сүрәләрне хәзерге хәрефләр белән гарәп телендә укыр өчен аларның транскрипциясе[2] эшләнде, тәҗвид кагыйдәләре дә күздә тотылды. Сузык авазлар өстендә куелган басым билгесе — шул сузык авазларның озынрак итеп, сузыбрак укылуын аңлата. Шуңа күрә, Коръәннең төп нөсхәсе белән транскрипциясен чагыштырып укыганда, бәгъзе бер сүзләрдәге кушымчаларның төрлелегенә, яисә туры килмәвенә укучы гаҗәпләнмәсен иде.

Коръәннең 1977 елда Мәскәүдә Каһирә басмасының күчермәсе булып басылган нөсхәсе файдаланылды.

**Әнвәр ХӘЙРУЛЛИН,**
Г. Ибраһимов исемендәге Тел,
әдәбият һәм тарих институты
фәнни хезмәткәре

---

[1] Тәфсир — Коръән сүзләренең мәгънәсен сүзгә-сүз итеп кенә түгел, ә тулырак итеп аңлатып биру.
[2] Транскрипция — нинди дә булса берәр тел яки җирле сөйләм авазларын, бу телнең язу системасыннан үзгәрак булган хәрефләр, шартлы билгеләр белән биру, шундый билгеләр системасы.

سُورَةُ الفَاتِحَةِ

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ﴿١﴾

ٱلْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ ٱلْعَٰلَمِينَ ﴿٢﴾ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ ﴿٣﴾ مَٰلِكِ يَوْمِ
ٱلدِّينِ ﴿٤﴾ إِيَّاكَ نَعْبُدُ وَإِيَّاكَ نَسْتَعِينُ ﴿٥﴾ ٱهْدِنَا ٱلصِّرَٰطَ
ٱلْمُسْتَقِيمَ ﴿٦﴾ صِرَٰطَ ٱلَّذِينَ أَنْعَمْتَ عَلَيْهِمْ غَيْرِ ٱلْمَغْضُوبِ
عَلَيْهِمْ وَلَا ٱلضَّآلِّينَ ﴿٧﴾

ТРАНСКРИПЦИЯ

*(1) Бисмилла́һир-рахма́нир-рахи́м. Әл-хә́мдү лил-ла́һи раббил-галәми́н. (2) Әр-рахма́нир-рахи́м. (3) Мәлики йә́үмид-ди́н. (4) Иййә́кә нә́гъбүдү вә иййә́кә нәстәгы́йн. (5) Иһди́нә́с-сыйра́таль-мустәкы́йм. (6) Сыйра́таль-ләзи́нә әнга́мтә галәйһим гайрил-мәгъдү́би галәйһим вәләд-да́лли́н. (7)*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

«Фатиха» сүрәсе,
Мәккәдә иңгән җиде аять
Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына

Һәрбер чын мактау — Аллаһы тәгаләгә генә. Әмма Аллаһы тәгаләдән башкаларда булган мактау — тыштан гына вә ул тыштан гына булган мактауның кире кайта торган заты да Аллаһы тәгалә. Ул — үзеннән башка һәрбер бар булган нәрсәләрне — адәмнәрне, хайваннарны һәм үсемлекләрне тәрбия итүче, ике доньяның да хуҗасы. Ул — изгелек һәм рәхмәт иясе булган кешегә изгелекле һәм мәрхәмәтле зат. Ул — җәза (кыямәт) көненең хуҗасы. Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм Синнән генә ярдәм эстибез. Син безне шундый адәмнәрнең тугры юлына күндерсәң иде; Син Үзең яхшылык һәм изгелек иткән адәмнәргә пәйгамбәрләрнең күрсәткән юлына, аларга ачуланмаган юлга күндерсәң иде, ягъни яһүдләр кебек Аллаһы тәгаләнең ачуына тиешле булган адәмнәр юлына күндермә! Һәм, тагын, азгын булмаган адәмнәрнең юлына күндер, ягъни христианнар кебек тугры юлдан азганнарның юлына күндермә! (Амин) кабул кылсаң иде! Фатихадан соң «Амин!» дию сөннәт, ягъни кирәк[1]

[1] Бу «Фатиха» сүрәсе — ислам диненең нигезе булган өч олуг мәсьәләгә шарт. Берсе — Аллаһы тәгалә — бөтен галәмнең барлыкка китерүчесе һәм тәрбия итүчесе дип

белү; икенчесе — кыямәт көненә һәм кыяматтә яхшылык һәм яманлыкка җәза булуына ышану; өченчесе — дөнья һәм ахирәттә сәгадәт иясе булу өчен һәм туры юлны табу өчен Аллаһы тәгаләгә ялваруның җитәрлек булуы (Шулай булгач, дин галимнәренә тапшырылу тиеш дигән кешеләрнең сүзләре — хата бер сүз булырга кирәк). Ислам диненең нигезе булган өч олуг мәсьәләнең кыскача бәяны — бу сүрәдән булганлыгы өчен бу сүрәне рәсүл әкрам, ягъни хөрмәтле пәйгамбәр «өммел-Коръән» — «Коръән анасы» дип атаган. Бу сүрә Коръәннең башында булганы өчен «Фатихәтел-китап» — «Коръән башы» дип атаган. Бу сүрә җиде аять булып фарыз, ягъни үтәлергә тиешле намазда икешәр мәртәбә укылганлыгы өчен «сәбгыль-мәсани» — «икешәр укыла торган» дип аталган. Ш. Хәмиди искәрмәсе.

## *«Аятел-Көрси»*

آيَةُ ٱلْكُرْسِيِّ

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

ٱللَّهُ لَآ إِلَٰهَ إِلَّا هُوَ ٱلْحَىُّ ٱلْقَيُّومُ لَا تَأْخُذُهُۥ سِنَةٌ وَلَا
نَوْمٌ لَّهُۥ مَا فِى ٱلسَّمَٰوَٰتِ وَمَا فِى ٱلْأَرْضِ مَن ذَا ٱلَّذِى
يَشْفَعُ عِندَهُۥٓ إِلَّا بِإِذْنِهِۦ يَعْلَمُ مَا بَيْنَ أَيْدِيهِمْ وَمَا
خَلْفَهُمْ وَلَا يُحِيطُونَ بِشَىْءٍ مِّنْ عِلْمِهِۦٓ إِلَّا بِمَا شَآءَ
وَسِعَ كُرْسِيُّهُ ٱلسَّمَٰوَٰتِ وَٱلْأَرْضَ وَلَا يَـُٔودُهُۥ حِفْظُهُمَا
وَهُوَ ٱلْعَلِىُّ ٱلْعَظِيمُ ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмиллаһир-рахманир-рахим.*

*(254) Аллаһү лә иләһә иллә һүвәл-хаййүл-каййум, лә тәәхузүһү синәтүн вә лә нәүм, ләһү ма фис-сәмавати вә ма фил-ард, мән зәлләзи йәшфәгу гыйндәһу иллә би изниһ, йагъләмү ма бәйнә әйдиһим вә ма хальфәһүм вә лә йухыйтунә би-шәйэим-мин гыйльмиһи иллә бима шаә, вәсига күрсиййүһүс-сәмавати вәл-ард, вә лә йәәүдүһү хифзуһүма вә һүвәл-галиййил-газыйм.*

### «Бәкарә» («Сыер») сүрәсе, икенче сүрә, 254 нче аять
### Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына

Аллаһы тәгалә бер генә Аллаһыга ышану һәм Аның сыйфатлары мәсьәләсендә «Аятел-көрси»не, ягъни «Тәхет аяте»н иңдерде.

**Аятел-көрси.** Аллаһы — ул һәрбер күркәм сыйфатны үзенә җыйган зат. Аннан башка гыйбадәт кылырга лаеклы башка аллаһы юк, Ул — һәрбер күркәм сыйфатны җыйган Аллаһы тәгалә, Ул — һәрвакыт терек, Ул — мәңгелек; Аны йокымсырау да һәм йокы да биләми; җирдә һәм күкләрдә булган нәрсәләр — Аның милкенә керәләр. Аның рөхсәтеннән башка, Аның каршысында башка берәүне яклаучы кем бар? (ягъни һичкем яклый алмас). Аллаһы тәгалә адәмнәргә кадәр ни булганын да, алардан соң ни булачагын да белә, ә бәндәләр, әгәр Аллаһы тәгалә — Үзе белүләрен теләмәсә, Аның белгән нәрсәсеннән һич нәрсәне белә алмыйлар. Аның тәхете күкләрне һәм җирне иңли һәм аларны саклау Аны авырсындырмый һәм Ул — чыннан да Үзенә тиңе булмаган югары, бөек зат![1]

[1] Бу «Тәхет аяте» — Аллаһы тәгаләнең берлегенә ышануны, Аны олылауны һәм Аның сыйфатларын эченә алганлыгы җәһәтеннән Коръән сүрәләре һәм аятьләре арасында кадерле һәм хөрмәтле аять була. Шуның өчен дә Рәсүлулла (Аллаһының илчесе — Мөхәммәд) әйтте: «Аятел-көрси»не һәр үтәлергә тиешле намаздан соң укысалар, ул кеше шунда ук оҗмахка керер иде. Ләкин оҗмахка керүдән үлем тыеп тора, һәм ул «аятел-көрси»не укуны дәвам иттермәс, мәгәр Аллаһы тәгаләнең дусты гына һәм Аңа гыйбадәт кылучы гына дәвам итәр. Әгәр бер кеше йокларга яткач «Аятел-көрси»не укыса, Аллаһы тәгалә бу укучыга һәм күршеләренә иминлек бирер»,— диде. Аллаһының кадерле илчесе — Мөхәммәд икенче хәдисендә, ягъни әңгәмәсендә әйтте: «Адәмнең, ягъни кешенең хуҗасы — Адәм (Аңа Аллаһының сәламе булсын!); гарәбләрнең хуҗасы — мин (бу сүземне мактанып әйтмим), фарсыларның хуҗасы — Сәлман; Византиянең хуҗасы — Саһил; тауларның хуҗасы — Тур тавы; көннәрнең хуҗасы җомга көн; сүзләрнең хуҗасы — Коръән; Коръәннең хуҗасы — «Бәкарә», ягъни «Сыер» сүрәсе; «Бәкарә» сүрәсенең хуҗасы — «Аятел-көрси», диде. Моннан башка да «Аятел-көрси»нең өстенлеге хакында күп хәдисләр бар. *Ш. Хәмиди искәрмәсе.*

## Сүрәтүр-Рахман

سُورَةُ الرَّحْمَٰنِ

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

ٱلرَّحْمَٰنُ ﴿١﴾ عَلَّمَ ٱلْقُرْءَانَ ﴿٢﴾ خَلَقَ ٱلْإِنسَٰنَ ﴿٣﴾ عَلَّمَهُ ٱلْبَيَانَ ﴿٤﴾

ٱلشَّمْسُ وَٱلْقَمَرُ بِحُسْبَانٍ ﴿٥﴾ وَٱلنَّجْمُ وَٱلشَّجَرُ يَسْجُدَانِ ﴿٦﴾

وَٱلسَّمَآءَ رَفَعَهَا وَوَضَعَ ٱلْمِيزَانَ ﴿٧﴾ أَلَّا تَطْغَوْا۟ فِى ٱلْمِيزَانِ

﴿٨﴾ وَأَقِيمُوا الْوَزْنَ بِالْقِسْطِ وَلَا تُخْسِرُوا الْمِيزَانَ ﴿٩﴾ وَالْأَرْضَ
وَضَعَهَا لِلْأَنَامِ ﴿١٠﴾ فِيهَا فَاكِهَةٌ وَالنَّخْلُ ذَاتُ الْأَكْمَامِ ﴿١١﴾ وَالْحَبُّ
ذُو الْعَصْفِ وَالرَّيْحَانُ ﴿١٢﴾ فَبِأَيِّ آلَاءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿١٣﴾ خَلَقَ
الْإِنسَانَ مِن صَلْصَالٍ كَالْفَخَّارِ ﴿١٤﴾ وَخَلَقَ الْجَانَّ مِن مَّارِجٍ
مِّن نَّارٍ ﴿١٥﴾ فَبِأَيِّ آلَاءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿١٦﴾ رَبُّ الْمَشْرِقَيْنِ وَ
رَبُّ الْمَغْرِبَيْنِ ﴿١٧﴾ فَبِأَيِّ آلَاءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿١٨﴾ مَرَجَ الْبَحْرَيْنِ
يَلْتَقِيَانِ ﴿١٩﴾ بَيْنَهُمَا بَرْزَخٌ لَّا يَبْغِيَانِ ﴿٢٠﴾ فَبِأَيِّ آلَاءِ رَبِّكُمَا
تُكَذِّبَانِ ﴿٢١﴾ يَخْرُجُ مِنْهُمَا اللُّؤْلُؤُ وَالْمَرْجَانُ ﴿٢٢﴾ فَبِأَيِّ آلَاءِ
رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٢٣﴾ وَلَهُ الْجَوَارِ الْمُنشَآتُ فِي الْبَحْرِ كَالْأَعْلَامِ ﴿٢٤﴾
فَبِأَيِّ آلَاءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٢٥﴾ كُلُّ مَنْ عَلَيْهَا فَانٍ ﴿٢٦﴾ وَيَبْقَىٰ
وَجْهُ رَبِّكَ ذُو الْجَلَالِ وَالْإِكْرَامِ ﴿٢٧﴾ فَبِأَيِّ آلَاءِ رَبِّكُمَا
تُكَذِّبَانِ ﴿٢٨﴾ يَسْأَلُهُ مَن فِي السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ كُلَّ يَوْمٍ هُوَ
فِي شَأْنٍ ﴿٢٩﴾ فَبِأَيِّ آلَاءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٣٠﴾ سَنَفْرُغُ لَكُمْ أَيُّهَ
الثَّقَلَانِ ﴿٣١﴾ فَبِأَيِّ آلَاءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٣٢﴾ يَا مَعْشَرَ الْجِنِّ وَ
الْإِنسِ إِنِ اسْتَطَعْتُمْ أَن تَنفُذُوا مِنْ أَقْطَارِ السَّمَاوَاتِ

وَٱلْأَرْضِ فَٱنفُذُوا۟ ۚ لَا تَنفُذُونَ إِلَّا بِسُلْطَٰنٍ ﴿٣٣﴾ فَبِأَىِّ ءَالَآءِ
رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٣٤﴾ يُرْسَلُ عَلَيْكُمَا شُوَاظٌ مِّن نَّارٍ وَنُحَاسٌ
فَلَا تَنتَصِرَانِ ﴿٣٥﴾ فَبِأَىِّ ءَالَآءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٣٦﴾ فَإِذَا
ٱنشَقَّتِ ٱلسَّمَآءُ فَكَانَتْ وَرْدَةً كَٱلدِّهَانِ ﴿٣٧﴾ فَبِأَىِّ ءَالَآءِ
رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٣٨﴾ فَيَوْمَئِذٍ لَّا يُسْـَٔلُ عَن ذَنۢبِهِۦٓ إِنسٌ وَ
لَا جَآنٌّ ﴿٣٩﴾ فَبِأَىِّ ءَالَآءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٤٠﴾ يُعْرَفُ ٱلْمُجْرِمُونَ
بِسِيمَٰهُمْ فَيُؤْخَذُ بِٱلنَّوَٰصِى وَٱلْأَقْدَامِ ﴿٤١﴾ فَبِأَىِّ
ءَالَآءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٤٢﴾ هَٰذِهِۦ جَهَنَّمُ ٱلَّتِى يُكَذِّبُ بِهَا
ٱلْمُجْرِمُونَ ﴿٤٣﴾ يَطُوفُونَ بَيْنَهَا وَبَيْنَ حَمِيمٍ ءَانٍ ﴿٤٤﴾ فَبِأَىِّ
ءَالَآءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٤٥﴾ وَلِمَنْ خَافَ مَقَامَ رَبِّهِۦ جَنَّتَانِ ﴿٤٦﴾
فَبِأَىِّ ءَالَآءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٤٧﴾ ذَوَاتَآ أَفْنَانٍ ﴿٤٨﴾ فَبِأَىِّ
ءَالَآءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٤٩﴾ فِيهِمَا عَيْنَانِ تَجْرِيَانِ ﴿٥٠﴾ فَبِأَىِّ ءَالَآءِ
رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٥١﴾ فِيهِمَا مِن كُلِّ فَٰكِهَةٍ زَوْجَانِ ﴿٥٢﴾ فَبِأَىِّ
ءَالَآءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٥٣﴾ مُتَّكِـِٔينَ عَلَىٰ فُرُشٍۭ بَطَآئِنُهَا مِنْ
إِسْتَبْرَقٍ ۚ وَجَنَى ٱلْجَنَّتَيْنِ دَانٍ ﴿٥٤﴾ فَبِأَىِّ ءَالَآءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ

بَانِ ﴿٥٥﴾ فِيهِنَّ قَاصِرَاتُ الطَّرْفِ لَمْ يَطْمِثْهُنَّ إِنْسٌ قَبْلَهُمْ
وَلَا جَانٌّ ﴿٥٦﴾ فَبِأَيِّ آلَاءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٥٧﴾ كَأَنَّهُنَّ الْيَاقُوتُ
وَالْمَرْجَانُ ﴿٥٨﴾ فَبِأَيِّ آلَاءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٥٩﴾ هَلْ جَزَاءُ
الْإِحْسَانِ إِلَّا الْإِحْسَانُ ﴿٦٠﴾ فَبِأَيِّ آلَاءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٦١﴾
وَمِنْ دُونِهِمَا جَنَّتَانِ ﴿٦٢﴾ فَبِأَيِّ آلَاءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٦٣﴾
مُدْهَامَّتَانِ ﴿٦٤﴾ فَبِأَيِّ آلَاءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٦٥﴾ فِيهِمَا عَيْنَانِ
نَضَّاخَتَانِ ﴿٦٦﴾ فَبِأَيِّ آلَاءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٦٧﴾ فِيهِمَا فَاكِهَةٌ
وَنَخْلٌ وَرُمَّانٌ ﴿٦٨﴾ فَبِأَيِّ آلَاءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٦٩﴾ فِيهِنَّ
خَيْرَاتٌ حِسَانٌ ﴿٧٠﴾ فَبِأَيِّ آلَاءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٧١﴾ حُورٌ
مَقْصُورَاتٌ فِي الْخِيَامِ ﴿٧٢﴾ فَبِأَيِّ آلَاءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٧٣﴾ لَمْ
يَطْمِثْهُنَّ إِنْسٌ قَبْلَهُمْ وَلَا جَانٌّ ﴿٧٤﴾ فَبِأَيِّ آلَاءِ رَبِّكُمَا
تُكَذِّبَانِ ﴿٧٥﴾ مُتَّكِئِينَ عَلَى رَفْرَفٍ خُضْرٍ وَعَبْقَرِيٍّ حِسَانٍ
﴿٧٦﴾ فَبِأَيِّ آلَاءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ ﴿٧٧﴾ تَبَارَكَ اسْمُ رَبِّكَ ذِي الْجَلَالِ
وَالْإِكْرَامِ ﴿٧٨﴾

*Бисмиллаһир-рахманир-рахим.*

*Әр-Рахману. (1) Галләмәл-Коръән (2) Халәкаль-инсанә. (3) Галләмәһүл-бәйан. (4) Әш-шәмсү вәл-камәрү би-хусбан. (5) Вән-нәҗму вәш-шәҗәрү йәсҗүдан. (6) Вәс-сәма' ә рәфәгаһа вә вадагаль-мизанә. (7) Әллә татгау фил-мизан. (8) Вә әкыймул-вәзнә бил-кыйсти вә лә тухсирүл-мизан. (9) Вәл-ардә вадагаһа лил-әнами. (10) Фиһа факиһәтүн вән-нәхлү затүл-әкмам. (11) Вәл-хәббү зүлгасфи вәр-рәйхан. (12) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (13) Халәкаль-инсанә мин салсалин кәл-фәххари. (14) Вә халәкаль-җәаннә мим-марижим-мин-нарин. (15) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (16) Раббүл-мәшрикайни вә раббүл-мәгърибәйни. (17) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (18) Мәрәҗәл-бәхрәйни йәлтәкыйан. (19) Бәйнәһүма бәрзәхуллә йәбгыйани. (20) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (21) Йәхрүҗү минһүмәл-луәлуәү вәл-мәрҗан. (22) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (23) Вә ләһүл-җәварил-мүншәатү фил-бәхри кәл-әгълам. (24) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (25) Күллү мән галәйһа фанин. (26) Вә йәбка вәҗһү раббикә зүл-җәлали вәл-икрам. (27) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (28) Йәсьәлүһү мән фис-сәмавати вәл-ард күллә йәүмин һүүә фишан. (29) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (30) Сәнәфрүгу ләкүм әййүһәс-сәкалани. (31) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (32) Йа мәгъшәрәл-җинни вәл-инси инистәтагътүм ән тәнфүзу мин әкътарис-сәмавати вәл-арди фәнфүзу, лә тәнфүзунә иллә би султанин. (33) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (34) Йүрсәлү галәйкүма шувазум-мин-нарин вә нухасүн фә-лә тәнтәсыйран. (35) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (36) Фә-изән шаккатис-сәмаү фә-кәнәт вәрдәтүн кәд-дихан. (37) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (38) Фә-йәүме изил-лә йүсьәлү ган зәнбиһи инсүн вә лә җан. (39) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (40) Йәгърәфүл-мүҗримүнә би-симаһүм фә йүәхәзү бин-нәвасый вәл-акъдам. (41) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (42) Һазиһи җәһәннәмүл-ләти йүкәззибү биһәл-мүҗримүнә. (43) Йәтуфунә бәйнәһа вә бәйнә хамимин-ан. (44) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (45) Вә ли-мән хафа мәкамә раббиһи җәннәтан. (46) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (47) Зәвата әфнанин. (48) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (49) Фиһима гайнани тәҗрийан. (50) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (51) Фиһима мин күлли факиһәтин зәуҗан. (52) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (53) Мүттәки-йинә гәлә фүрүшим батаинүһа мин истәбракъ, вә җәнәл-җәннәтәйни дани. (54) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (55) Фи-һиннә касыйратүт-тарфи ләм йатмисһүннә инсүн кабләһүм вә лә җәннүн. (56) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (57) Кә-әннә-һүннәл-йакутү вәл-мәрҗан. (58) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (59) Һәл җәзаүл-ихсани илләл-ихсан. (60) Фә-би-әййи ала'и раббиккүма түкәззибан. (61) Вә мин дуниһима җәннәтан. (62) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (63) Мүд һаамматан. (64) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (65) Фиһима гайнани наддахатан. (66) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (67) Фиһима факиһәтүн вә нахлүн вә румман. (68) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (69) Фиһиннә хайратүн хисан. (70) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (71) Хурум-макъсуратүн фил-хыйам. (72) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (73) Ләм йатмисһүннә инсүн кабләһүм вә лә җан. (74) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (75) Мүттәки-йинә галә рәфрәфин худрин вә габкариййин хисан. (76) Фә-би-әййи ала'и раббикүма түкәззибан. (77) Тәбарәкәсму раббикә зил-җәлали вәл-икрам. (78)*

«Әр-рәхман» («Мәрхәмәт итүче») сүрәсе.
Иңүе турында бәгъзеләр Мәккәдә,
бәгъзеләр Мәдинәдә иңде дигән
каршылыклы фикердә торалар.
Илле бишенче сүрә,
җәмгысе җитмеш сигез аять.
Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына.

1. Дөньяда вә ахирәттә мәрхәмәт итүче Аллаһы тәгалә Үзе теләгән кешесенә Коръәнне өйрәтте, белдерде. Дөньядагы һәм ахирәттәге нигъмәтләрне телгә алу чикләнгән заманда Аллаһы тәгалә бу сүрәне «әр-рәхман» дигән сүз белән башлады һәм дин нигъмәтенең асылы вә олысы булган Коръән нигъмәтен (иңдерүне вә белдерүне) элек искә алды. Чөнки Коръән — диннең нигезе, шәригатьнең башы, вәхинең, ягъни берәр фикерне Аллаһы тәгалә тарафыннан пәйгамбәрнең күңеленә салуның иң олысы вә күктән иңдерелгән китапларның иң газизе. (2) Аллаһы тәгалә адәмне яратты, ягъни барлыкка китерде һәм (3) адәмгә күңелендә булган нәрсәдән тәгъбир (белдерү) рәвешен өйрәтте. (4) Кояш һәм Ай чикләнгән, мәгълүм хисап белән йөриләр, (5) һәм җирдән яңа чыккан сапсыз үлән һәм саплы үләннәр, ягъни агачлар Аллаһыга буйсыналар. (6) Дәхи, Аллаһы тәгалә күкне урында вә мәртәбәдә биек итеп яратты һәм гаделлекне куйды, ягъни һәрбер сәләтле адәмгә тиешле нәрсәне бирде вә һәрбер хак иясенә хакны бирде. Шуның сәбәпле дә галимнең эше дөрес вә тугъры булды. Рәсүл әкрәм әйтә: гаделлек белән күкләр вә җирләр торды», дип. Мизаннан, ягъни үлчәүдән әйберләрнең микъдарлары — күләмнәре беленә торган нәрсә аңлашыла, ягъни мизане горфи — «яхшылык үлчәве» дигән сүз. (7) Гаделлектә чиктән үтмәсеннәр өчен, ягъни инсафтан читкә китмәсеннәр өчен. (8) Дәхи, мизанны тугърылык белән үтәсез, ягъни тугъры, дөрес үлчәгез вә үлчәүне киметмәгез! (9) Дәхи, Аллаһы тәгалә җирне мәхлукъләр, ягъни җан ияләре өчен түбән итеп түшәде. (10) Ул җирдә ләззәтләнү өчен ашый торган төрле җимешләр, дәхи хөрмә савытлары ның иясе булган хөрмә агачлары бар. (11) Дәхи яфрак (салам) иясе булган орлыклар (бодай, арпа, арыш, солы кебиләр) һәм хуш исле җимешләр, яки ризыклар бар. (12) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (13) Аллаһы тәгалә адәмне ут белән яндырылган балчык кеби булган коры балчыктан яратты. (14) Дәхи, җенне, яки җеннәр атасын уттан булган саф төтеннән яратты. (15) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (16) Ул Раббегез — кышның кояш чыгышы тарафы белән җәйнең кояш чыгышы тарафының һәм кышның кояш батышы тарафы белән җәйнең кояш батышы тарафының раббесе. (17) Әй, адәм белән җен! Раббегезнең нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (18) Ул раббегез — суы тозлы диңгез белән суы татлы диңгезне берсе-берсенә күрше булганнары хәлдә җибәрде, ягъни өсләре берсе-берсенә бәхре мохыйтта — океанда юлыгышырлар. (19) Ул ике диңгез арасында Аллаһының кодрәтеннән, яки җирдән бер пәрдә бар. Катышу вә хасиятен бозу сәбәпле, берсе икенчесенә золым кылмас, ягъни берсенең суы икенчесенең суына катнашмас. (20) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (21) Бу ике диңгездән олугъ энҗе илә кечек энҗеләр чыга. Әгәр тозлы сулы диңгездән генә чыгуы шиксез булса — ул вакытта икенчесеннән чыга дигәне — икенчесенең җыелган урыннарыннан чыкканы өчен булыр, яки икесе бергә җыелганлыктан. Гүя ки ике диңгез бер диңгез хөкемендә булса да, берсеннән чыккан нәрсә — гүя ки икенчесеннән дә чыккан нәрсә хөкемендә була. (22) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (23) Диңгездә тәрәкләре югары күтәрелгән, олугълыкта таулар кеби булган агучы (йөрүче) көймәләр — ул Раббенеке. (24) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (25) Һәрбер җирдә булган җан иясе, ягъни адәм белән җеннәрдән булган җан ияләре — һәлак булучы һәм бетүчеләр (26) Әй, Мөхәммәд (галәйһиссәлам)! Олугълык вә хөрмәт иясе булган Раббеңнең заты гына һәлак булмый

калыр. (27) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (28) Күкләрдә вә җирләрдә булган гакыл ияләренең һәрберсе — Аллаһыдан кирәк булган нәрсәләрен сорыйлар. Һәр көнне ул Аллаһы эштәдер, ягъни һәрвакыт Аллаһы тәгалә мәңгелек хөкеменә муафыйкъ төрле затлар пәйда кылыр, ягъни барлыкка китерер вә төрле хәлләр яңартыр. Рәсүлулла, ягъни Аллаһының илчесе — Мөхәммәд пәйгамбәр әйтә: «Аллаһының һәрвакытта мөһим эше — гөнаһларны ярлыкау, кайгыларны бетерү, бер кауемне бөек дәрәҗәгә күтәрү, икенче кауемне түбән дәрәҗәгә төшерү», ди һәм бу аятьтә яһүдләрнең «Аллаһы тәгалә шимбә көн хөкем кылмый», диган сүзләрен кире кагу була. (29) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (30) Әй, адәм белән җен! Кыямәт көнендә (ягъни дөнья беткән көндә) сезнең хисабыгыз һәм җәзагыз өчен бушанырбыз, ягъни ялгыз сезнең хисабыгыз вә газабыгыз белән мәшгуль булырбыз. Чөнки кыямәт көнендә Аллаһы тәгалә хисап белән җәзадан башка эшне кыйлмый. (31) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (32) Әй, адәмнәр белән җеннәр горуһысы (төркеме)! Әгәр күкләрнең вә җирләрнең читләреннән Аллаһының казасыннан качканыгыз хәлдә чыгарга көчегез җитсә — качып чыгыгыз! Качып чыгарга көчегез җитмәс, мәгәр куәт белән генә җитәр, ул куәт сездә юк. Яки: күкләрдә вә җирләрдә булган нәрсәләрне белүегез өчен күкләрнең вә җирләрнең читләреннән чыгуга көчегез җитсә — чыгыгыз! Ләкин чыга алмассыз һәм күкләрдә вә җирләрдә булган нәрсәләрне белә алмассыз. Мәгәр Аллаһы тәгалә билгеләп куйган дәлил белән чыгарсыз вә белерсез. Шулай итеп, фикерләрегез белән күкләргә ашарсыз, чөнки Аллаһы тәгалә күкләргә аша торган гаклый вә нәкъли, (ягъни гакылга бәйле һәм күчерелмә хәбәрләргә таянып эш итә торган) баскычлар билгеләп куйды. Шулай итеп, ул баскычлар белән җиде кат күкнең өстенә ашуыгыз мөмкин. Икенче мәгънәгә таянып, бу аятьтә гыйлемгә ни кадәр кызыктыру була. (33) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (34) Әй, адәм белән җен! Сезнең үзегезгә уттан — ялкын, дәхи, ялкынсыз төтен җибәрелер, шулай итеп, ул ялкын белән төтеннән сезне мәхшәргә, ягъни кыямәт көнендә яңадан терелгән кешеләрнең җыелу урынына сөрер. (35) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (36) Кайчан кыямәт алдыннан күк ярылса, шулай итеп, күк — эрегән зәйтүн мае, яки кызыл сәхтиян кеби, кызыл гөл кеби булып әверелсә. (37) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (38) Күк ярылган көнне гөнаһсы турында һичбер адәмнәр, дәхи җеннәр соралмаслар, чөнки гөнаһлы булулары — тамгалары белән беленә. Бу сорауның юклыгы — каберләреннән чыгып мәхшәргә барган вакытта беленә. Әмма мәхшәрдә хисап вакытында гөнаһлары турында соралулары — икенче аять белән ачык аңлатыла. (39) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (40) Кяферләрне, ягъни алласызларны кыямәт көнендә тамгалары (кайгылы булулары, яки йөзләренең кара булулары) белән белеп булыр һәм кяферләрне тәмугъка илткәндә маңгай чәчләреннән, дәхи аякларыннан тотарлар (сөйрәрләр). (41) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (42) Кяферләргә әйтелер: «Бу шундый җәһәннәмдер — бу җәһәннәмне кяферләр ялганга санаганнар иде. (43) Кяферләр тәмугъ белән эсселектә чигенә җиткән эссе су арасында әйләнерләр, ягъни тәмугъта яндырылырлар вә өсләренә гаять эссе су сибелер, яки, сусап су сорасалар — гаять эссе су белән сугарылырлар. (44) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (45) Дәхи, Раббесе хозурында бәндәләр хисап бирер өчен туктап тора торган урында торудан курыккан кеше өчен ике оҗмах булыр. Берсе — адәмнән булган куркучыга вә берсе җеннән булган куркучыга, яки һәрберсенә ике булыр. Берсе — инануы өчен, икенчесе — гамәле өчен, яки берсе — гыйбадәтләрне кылуы өчен, икенчесе — гөнаһларны куюы өчен, ягъни берсе — рухани оҗмах, икенчесе — матди, җисмани оҗмах булыр. (46) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (47) Ул ике оҗмах — төрле агачлар вә җимешләр ияләре. (48) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (49) Ул ике оҗмахта ага торган ике чишмә бар. (50) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (51) Ул ике оҗмахта һәрбер җимештән ике төрлесе бар. Берсе — хуш исле кеби, берсе — [illegible], яки берсе — коры вә берсе — чи. (52) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (53) Оҗмах әһелләре оҗмахта эчләре калын

ефәктән булган түшәкләргә таянганнары хәлдә нигъмәтләнерләр, вә бу ике оҗмахның җимешләре якын, утырган хәлдә дә, яткан хәлдә дә алырга мөмкин булыр. (54) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (55) Ул оҗмахларда күзләре ирләренә генә кыскартылган (ягъни мәхәббәтләре ялгыз ирләрендә генә булган) хур кызлары бар. Ул хур кызлары ирләреннән элек, адәмнәр өчен булганнарын — адәмнәр, җеннәр өчен булганнарын — җеннәр тотмадылар. Бу аятьтән җеннәр өчен дә хур кызлары булу беленә. (56) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (57) Ул кызлар — йөзләре кызыллыгы белән вә тәннәре аклыгы һәм сафлыгы белән гүя ки якут һәм мәрҗән кебиләр. (58) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (59) Гамәлдә, ягъни кылган эшеңдә изгелекнең җәзасы түгел, ә савапта изгелек, ягъни оҗмах. (60) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (61) Дәхи, бу ике оҗмахтан башка халык хисап өчен туктый торган урында Аллаһының хозурында туктаудан куркучылар өчен ике оҗмах бар. (62) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (63) Ул ике оҗмах гаять яшелләр, гаять яшеллекләреннән күзгә кара кеби күренәләр. (64) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (65) Ул ике оҗмахта сулары кайнап чыга торган ике чишмә бар. (66) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (67) Ул ике оҗмахта ләззәтләнер өчен ашала торган төрле җимешләр, хөрмә һәм анар җимеше бар. Имам әгъзам, ягъни бөек имам Әбү Хәнифә бу аять белән хөрмә белән анарның җимешләр булмавына дәлилләр китергән. Чөнки хөрмә белән анарны Аллаһы тәгалә җимешләргә әйләндергән. Әйләндерү — башка булуны тели. Шуның өчен дә имам әгъзам каршында җимешләр ашамам дип ант иткән адәм хөрмә һәм анар ашау белән антын бозучы булмый. Ләкин ике имам һәм имам Шафигый хөрмә белән анарны җимешләргә әйләндерү — хөрмә белән анарның артыклыкларын бәян итәр өчен дигәннәр. Шулай итеп, гүя ки хөрмә белән анар — артыклыклары өчен җимешләрдән икенче җенес хөкемендә булалар. Шуның өчен дә җимешләр ашамам дип ант иткән кеше — болар каршында хөрмә һәм анар ашау белән антын бозучы була. (68) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (69) Дәхи, ул оҗмахларда сурәтләре вә холыклары күркәм булган изге хатыннар бар. (70) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (71) Ул — сурәтләре вә холыклары күркәм булган изге хатыннар чатырларга ябылган вә өртелгән, ягъни капланган хур кызлары. (72) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (73) Ул хур кызларын оҗмах әһелләреннән элек адәм дә, җен дә тотмады. (74) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (75) Оҗмах әһелләре оҗмахта яшел урындыклар вә гаҗәеп күркәм сәкеләр, калын паласларга таянганнары хәлдә нигъмәтләнерләр. (76) Әй, адәм белән җен! Раббегез нигъмәтләренең инде кайсын ялганга чыгарасыз? (Бу сүз — бу сүрәдә утыз бер мәртәбә телгә алынган). (77) Әй, Мөхәммәд (галәйһис-сәлам)! Олугълык вә хөрмәт иясе булган Раббеңнең исеме мөбарәк, ягъни кадерле булды!

## Сүрәтүл-Ихлас

سُورَةُ الإِخْلَاصِ

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

قُلْ هُوَ ٱللَّهُ أَحَدٌ ۝ ٱللَّهُ ٱلصَّمَدُ ۝ لَمْ يَلِدْ وَلَمْ

يُولَدْ ۝٣ وَلَمْ يَكُن لَّهُۥ كُفُوًا أَحَدٌۢ ۝٤

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахйм.*
*Куль һүал-ләһү эхад. (1) Аллаһүс-самэд. (2) Ләм йәлид вә ләм йүләд. (3) Вә ләм йәкүл-ләһү куфүүән эхәд. (4)*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

«Ихлас» сүрәсе.
Йөз дә уникенче сүрә, дүрт аять
Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына

Бер заманда мөшрикләр, ягъни мәҗүсиләр Аллаһының илчесе Мөхәммәд пәйгамбәрдән сорадылар: «Синең Раббең алтынданмы, көмештәнме, тимердәнме?» дип. Шуларга җавап өчен бу сүрә инде. Мәгънәсе: (1) Әй, Мөхәммәд! Әйт син кяферләргә: «Минем Аллаһым бер, (2) Ул — һичнәрсәгә мохтаҗ түгел, (3) Ул һичкемне тудырмады һәм һичкемнән тудырылмады, (4) һәм дә Аңа һичбер зат тиң булмады»,— дип.

## Сүрәтүл-Фәлакъ

سُورَةُ الفَلَقِ

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ ٱلْفَلَقِ ۝١ مِن شَرِّ مَا خَلَقَ ۝٢ وَمِن
شَرِّ غَاسِقٍ إِذَا وَقَبَ ۝٣ وَمِن شَرِّ ٱلنَّفَّٰثَٰتِ فِى
ٱلْعُقَدِ ۝٤ وَمِن شَرِّ حَاسِدٍ إِذَا حَسَدَ ۝٥

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахйм.*
*Куль әгузү би-раббил-фәлакый. (1) Мин шәрри мә халака. (2) Вә мин шәрри гәсикыйн изә вәкаб. (3) Вә мин шәррин-нәффәсәти фил-гукади. (4) Вә мин шәрри хәсидин изә хасәд. (5)*

«Фәләкъ» («Таң») сүрәсе.
Иөз дә унөченче сүрә, биш аять
Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына

(1) Әй, Мөхәммәд! Әйт син: «Таңны тудыручы Раббемә, (2) Аның яраткан, ягъни барлыкка китергән нәрсәләренең зарарыннан сыенам, (3) Һәм дә, караңгылыгы һәрнәрсәне каплаучы караңгы кичтән сыенам, (4) Һәм дә төеннәргә сихер теләп өрүче хатыннарның зарарларыннан, (5) шулай ук көнчеләрнең көнләшүләреннән Раббемә сыенам.

## Сүрәтүн-Нас

سُورَةُ النَّاسِ

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ ٱلنَّاسِ ۝١ مَلِكِ ٱلنَّاسِ ۝٢ إِلَٰهِ ٱلنَّاسِ ۝٣ مِن
شَرِّ ٱلْوَسْوَاسِ ٱلْخَنَّاسِ ۝٤ ٱلَّذِى يُوَسْوِسُ فِى صُدُورِ
ٱلنَّاسِ ۝٥ مِنَ ٱلْجِنَّةِ وَٱلنَّاسِ ۝٦

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилла́һир-рахма́нир-рахи́м.*
*Куль әгузү би-раббин-наси. (1) Мәликин-на́си. (2) Илаһин-на́си. (3) Мин шәррил-вәсва́сил-ханна́с. (4) Әлләзи йүвәсвисү фи судурин-наси. (5) Минәл-җиннәти вән-на́с. (6)*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

«Ән-нас» («Кешеләр») сүрәсе.
Иөз дә ундүртенче сүрә, алты аять.
Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына

(1) Әй, Мөхәммәд! Әйт син: «Мин адәмнәрнең Раббесе, (2) адәмнәрнең Алласы булган Раббемә сыенам, (4) васвәсә кылып, ягъни күңел аздырып изге гамәлләрне кичектерүче заттан, ягъни шайтаннан, (5) җеннәрдән һәм адәмнәрдән дә булып, адәмнәрнең күңелләрендә васвәсә кылучы заттан сакланам.

Бу — соңгы ике сүрә — рәсүлебезне бер яһүди сихерләп хәстә кылганнан соң иңгән, дип риваять кылына. *Ш. Хәмиди искәрмәсе.*

**Китап күзәту**

# РУХИ МИРАСЫБЫЗНЫ БАРЛАГАНДА

Октябрьгә кадәрге татар театры» китабы[1] басылып чыгып, тиз арада таралып та бетте. Татар театры тарихына, драматургиягә караган хезмәтләр бездә моңарчы да аз түгел иде. Биредә беренчеләрдән дә беренчеләре итеп милли театрның 20 еллыгына багышлап Казанда чыгарылган «Татар театры (1906—1926)» исемле, заманы өчен шактый зур күләмле хезмәтне, В. Мортазин-Иманский белән Т. Ченәкәй шул ук елны Мәскәүдә чыгарган «Татар театры тарихыннан» дигән китапны һәм Ташкентта басылган «Татар сәхнәсенең 20 еллыгына» дигән җыентыкны күрсәтергә була. Боларда Бөек Октябрьгә кадәрле һәм Совет властенең беренче елларындагы театр хәрәкәте турында бай фактик материал бар. Драматургиягә һәм театрга багышланган Б. Гыйззәт хезмәтләре төрле коллектив монографияләрдә һәм тарих китапларында күп басылды. Б. Гыйззәт 1966—1971 елларда Мәскәүдә рус телендә чыккан «Совет драма театры тарихы» дигән алты томлыкта да катнашты. 1975 елда басылган «Татар совет театры» дигән коллектив хезмәт сәхнә сәнгатебезне өйрәнүдә җитди адым булды. Болардан тыш М. Гайнуллин, И. Нуруллин кебек әдәбият галимнәренең монографияләрендә драматургия турындагы бүлекләрне, минем Мәскәүдә русча чыккан «Татар драматургиясе» дигән китапны, Х. Хисматуллин, А. Яхин, Р. Игъламов, Н. Ханзафаров һ. б. ларның драматургларга багышланган аерым тикшеренүләрен дә күрсәтергә була. Театр белгечләре Х. Гобәйдуллин, И. Илялова, һ. Мәхмүтов, Х. Кумысников, Д. Гыймранова, Г. Арсланов һ. б. ларның хезмәтләрендә театр тарихыбызның төрле яклары, аерым режиссерлар һәм артистлар иҗатлары яктыртылды.

Шулай итеп, «Октябрьгә кадәрге татар театры» дигән китап буш урында тумады. Ул үзенә кадәр язылган һәм басылганнар җирлегендә мәйданга килде, тегеләр җилкәсенә таянып күтәрелде. Шуңа да карамастан, без бу китапны үз өлкәсендә беренче җитди сүз дип кабул итәбез. Ни өчен шулай? Бу рухтагы хезмәтләр арасында аның яңалыгы нидә?

Бу китапның төп үзенчәлеге һәм яңалыгы шунда: ул бездәге сәхнә сәнгате тарихын моңарчы булмаганча тулы итеп, төрле яклап яктырта. Үзенә кадәр язылганнарны асылда атлап үтмәгән хәлдә, ул моңарчы тупланган мәгълүматларны дистәләрчә матбугат органнары, архивлар, истәлекләр, фәнни әдәбият һәм агымдагы әдәбият чыганакларында сакланып һәм яшеренеп яткан материаллар белән тулыландыру рәвешендә иҗат ителгән. Китап яңа фактик материалга шулкадәр бай ки, бу байлык вакыт-вакыт хәтта фәнни проблематиканы басып та киткәли. Ләкин моны хезмәтнең кимчелеге дип карарга ашыкмыйк. Хәзерге этапта, бәлкем, материалны шулай тулы итеп туплап чыгару, милли сәхнәнең туу һәм үсеш картинасын күзалларлык итеп бер җепкә тезү мөһимрәктер дә. Чөнки вакытлар узу белән бу материалның бер өлеше юкка чыгу куркынычы бар һәм авторлар моны, күрәсең, бик истә тотканнар. Китапны укып чыккач, ул чор буенча хәзер инде фәнни әйләнешкә керми калган материал күп та түгелдер, дигән фикер туа. Ә моның, ягъни материалны иңләп алуның ни дәрәҗәдә мөһим икәнен, инде шактый ерак чордагы фактларны табып алуның, эшкә җигүнең ни дәрәҗәдә авыр икәнлеген мондый эшне үзе башкарып караган кеше генә тулы бәяли ала.

Китапның тагын бер уңай ягы шунда: революциягә кадәр яшәп килгән «Сәйяр», «Нур», «Ширкәт», дистәгә якын һ. б. труппаларның туу, оешу һәм үсү тарихы анда эзлекле итеп күрсәтелә. Бу труппаларның репертуары, хәтта ае һәм көне белән нинди спектакльләр әзерләүләре һәм тамашачыга җиткерүләре, актерлар составы, режиссерлары, җитәкчеләре һәм ярдәмче хезмәткәрләре турында бәйнә-бәйнә сөйләнелә. Аерым труппаларда кайчан һәм кайсы жанр төрләре нинди дәрәҗәдә булган, кемнәр нинди рольдә һәм ничек уйнаган, кемнәр нинди рецензияләр язган, театр хәрәкәтен кемнәр күзәтеп һәм теоретик яктан ничек нигезләп барганнар — боларның һәммәсе турында кызыклы, моңарчы әле фәнни әдәбиятта яктыртылмаган мәгълүматлар китерелә.

Китапта яңача яктыртылган тагын берни-

1. Мәхмүтов һәнүз, Илялова Ильтани, Гыйззәт Бәян. Октябрьгә кадәрге татар театры — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1988. 400 бит, 32 бит иллюстрацияләр. Фәнни редакторы Н. Ханзафаров, нәшрият редакторы Р. Даутов.

чә мәсьәләне мисалга китерергә була. Әйтик, театрыбызның туу датасы турында. Без моңарчы беренче публичный, рәсми спектакль куелган вакыт дип 1906 елның 22 декабрен саный идек. Монда ышандырырлык итеп инде 1906 елның 21 апрелендә Уфада һәм 5 майда Казанда махсус театр бинасында ачык спектакльләрнең куелган булуы раслана. Ул кичләрдә сәхнәдә уйнелган пьесаларның исемнәре, авторлары, уйнаучылар составы, оештыручылар атап әйтелә. Димәк, безгә милли театрыбызның рәсми рәвештә туу датасын тагын да төгәлрәк билгеләп, аны 8 айга алгарак күчерү мөмкинлеге туа.

Татар театрының социалистик революциягә кадәрге тарихы тагын да тулырак, фәнни яктан нигезләрәк чыгуына моңарчы тыелу яки башка сәбәпләр аркасында аз кулланылышта булган иҗатларның рухи мирасыбызда үз урынын алуы да зур ярдәм итә. Шундыйлардан берсе — Г. Исхакый, аның революциягә кадәрге драматургик эшчәнлеге. Югыйсә, гаҗәеп хәлләр килеп чыга иде. Бу исемне, аның әсәрләрен телгә дә алырга ярамаган вакытларда аерым актерларның яисә режиссерларның иҗаты башланып киткән әсәрләр буташтырыла, белә торып вакыты үзгәртелә иде. Мәсәлән, Г. Кариевның да, С. Гыйззәтуллина-Волжскаяның да сәхнәгә беренче аяк басулары «Өч хатын белән тормыш» спектаклендә була. Ә Гаяз Исхакый тыелган чакта, без ул тарихи адымны «Кызганыч бала» спектакле белән — төрекчәдән тәрҗемә әсәр белән бәйли идек, ягъни күрәләтә тарихны боза идек. Болар, шөкер, китапта төзәтелгән.

Октябрьгә кадәрге татар театрының Г. Кәрам, К. Бәкер, С. Шәрәфетдинев кебек үз тәнкыйтьчеләре булган; Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, С. Рәмиев кебек язучылар да рецензияләр, мәкаләләр белән аның үсешен күзәтеп һәм юнәлтеп торганнар. Шулай да барлык спектакльнең ничек куелышы, режиссерлык чишелеше, художество бизәлеше (сценография) турында әтрафлы рецензияләр күп түгел. Аерым авторларның уен үзенчәлекләре хакында махсус язылган мәкаләләр юк дәрәҗәсендә. Шулай булгач, бүгенге галим театр процессының бу мәҗбүри компонентлары турында мәгълүматларны каян ала? Труппаларның иҗат йөзе, аерым спектакльләрнең художество дәрәҗәсе, актерлык осталыгы, режиссерлык мәктәбенең үзенчәлекләре бу хезмәттә ничек ачылган? — дигән сораулар туа.

Әлбәттә, барлык бу компонентлар китапта без бүген теләгән дәрәҗәдә чагылыш тапкан, һәрьяктан тулы картина туган дип әйтсәк, дөреслеккә бигүк туры килмәс. Үз чорының театр тәнкыйте һәрнәрсәне иңләп алып бара алмау, ягъни җитешмәү аркасында, китап авторларына тарихи-теоретик мәсьәләләрнең барысын да бердәй югары дәрәҗәдә хәл итү мөмкинлеге аз. Бу яктан китапның төрле бүлекләре төрле югарылыкта. Мәсәлән, «Сәйяр» труппасы турындагы бүлектә, — ә бу бүлек хезмәтнең төп өлешен тәшкил итә, — сүз күбрәк труппа репертуары турында, оештыру мәсьәләләре хакында бара, күренекле спектакльләргә анализ һәр урында да җитеп бетми. «Нур» труппасы бүлегендә исә, киресенчә, актерлык осталыгы, уйнау үзенчәлекләре ярыйсы гына яктыртыла, ә репертуар, труппаның эчке үсеш мәсьәләләре беркадәр аксый. Тик шунысына басым ясап әйтергә кирәк: авторлар архив чыганаклары, басма материаллар аз булган очракта истәлекләргә мул мөрәҗәгать итәләр, җитешмәгәнне шулай тутырырга тырышалар. Дөрес, истәлекләрдән файдалану тарих китабы стилен чуарлатып, публицистикага сөйрәп кертүкән очраклар да бар. Мәсәлән, «Нур» труппасы турындагы бүлектә шулай. Ләкин моны киләчәктә төзәтүе авыр булмас. Иң мөһиме — истәлекләрнең булуы, өлкән буын артистлар исән-имин вакытта аларны күбрәк туплау һәм фәнни кулланылышка кертү.

Инде авторларның үзләре турында да берничә сүз әйтик. Тәҗрибәле театр белгече Б. Гыйззәт «Татар театрының барлыкка килүе» дигән беренче бүлекнең яртысын язган. Монда ул татар драматургиясенең тәүге адымнарын һәм сәхнә сәнгатенең беренче омтылышларын тикшерә, мондагы үзенчәлекләрдән берсе итеп мәгърифәтчелек әдәбиятына тартымлыкны күрсәтә. И. Илялова «Нур» труппасы турындагы бүлекне язган. Монда, алда инде әйтелгәнчә, артистларның уены әйбәт кенә яктыртыла. «Нур»да өстенлек иткән романтик уен стиле хакындагы фикерләр дә кызыклы һәм дәлилле. Калган бүлекләрнең авторы — һ. Мәхмүтов. Болар түбәндәгеләр: «Сәйяр» труппасы», «Оренбургта татар театры», «Төрле төбәкләрдәге театр хәрәкәте», «Сәйяр» репертуары», «Кереш» һәм «Йомгак», исемнәр күрсәткече һәм цензура материаллары. Күрәбез, китапның төп һәм күп өлеше бер кеше каләме белән язылган. Алдагы ике авторның хезмәтләрен дә тиешенчә тәкъдир иткән хәлдә, мин: һ. Мәхмүтов — китапның шундый җитлеккән булып чыгуына иң күп көч куйган автор, дияр идем. Әйе, мондый хезмәт — фәнни батырлык. Бу кадәр бай фактик материалны туплау, бөртекләп җыйнау, бер тәртипкә салу, фәнни нигезләргә утырту һ. Мәхмүтовтан дистәләрчә елга сузылган фидакарь хезмәт таләп иткән.

Югарыда әйтелгәннәргә тагын китапның фәнни редакторы Н. Ханзафаров һәм нәшрият редакторы Р. Даутов тырышлыгы да кушылып, уртак нәтиҗәгә ирешелгән.

Гомумән, бу хезмәт театр тарихыбызны, мәдәни мирасыбызны яңача, бүгенге яңарыш рухында яктырту буенча беренче җитди адым буларак бәяләнергә хаклы.

**Азат ӘХМӘДУЛЛИН**,
филология фәннәре докторы.

«Октябрьгә кадәрге татар театры» дигән хезмәт турында әүвәл шуны искәртәсем килә: аның кулъязмасы Татарстан китап нәшриятында минем кулга 1986 елда килеп кергән иде. Инде бу вакытта тормышыбызның һәр өлкәсендә үзгәртеп коруга бәйле демократик хәрәкәт, хәбәрдарлык шактый киң җәелә башлаган, матбугатта җәмгыятьнең бүгенге яшәешенә һәм үткән тарихына караган яңа рухлы, аек фикерле байтак материаллар чыккан иде.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты басмага әзерләгән әлеге хезмәтнең кулъязмасы, нәшрият планына кертелеп, редактор буларак, минем кулга тапшырылгач, беренче чиратта мине әнә шул мәсьәләләр кызыксындырды. Хезмәттә заманның хәбәрдарлык рухы ничек чагыла? Хәбәрдарлык — ул тарихи дөреслекне белү дигән сүз. Димәк, бу очракта театр сәнгатебезнең туу, формалашу процессы, аны тудыруда һәм үстерүдә катнашкан иҗат көчләре — драматург, актер, режиссерларның конкрет тарихи шартлардагы эшчәнлеге һәммәсе хезмәттә бөтен тулылыгы һәм катлаулылыгы белән ачыламы? Мин театр сәнгатебезне махсус өйрәнгән профессиональ белгеч түгел, шуңадыр, бәлки, кулъязма белән беренче мәртәбә танышып чыккач ук, үземне яңа бер дөнья ачкандай сиздем. Фактик материалга байлыгы һәм документальлеге белән сокландырды ул мине. Монда ул хакта артык җәелеп торуның кирәге юк — китап басылып чыкты, кызыксынган кеше үзе таныша ала. Тик кулъязма нөсхәдә мине бер нәрсә сәерсендерде: язу машинкасында күчереп басылган кулъязманың аерым битләре юллап-юллап яки абзацлап-абзацлап өстән ак кәгазь белән ябыштырылган иде. Битләрне яктыга куеп карагач аңлашылды: бу — Г. Исхакыйның исеме телгә алынган яки аның сәхнә әсәрләре турында фикер йөрткән урыннар икән.

Берничә ел элек булса, бу хәл мине артык гаҗәпләндермәгән дә булыр иде. Редакторлык тәҗрибәмнән яхшы беләм: торгынлык елларында әдәбият һәм иҗтимагый тарихыбызда «ак таплар» дип йөртелә торган ачык хакыйкатьләр еш кына нәшрият кулъязмалары битләреннән әнә шулай ак кәгазь ябыштырып кына чыгарыла иде. Мәсәлән, Г. Ибраһимов томнарын чыгарганда күп булды андый кыскартулар. Хәтта бөек Тукайның да кайбер шигырьләре аңардан котыла алмады.

Ләкин үзгәртеп кору процессы барган чорда мондый хәл, чыннан да, гаҗәпләндерде. Монда, әлбәттә, хезмәтнең авторлары гаепле түгел иде. Шулай да, ни генә булмасын, ахырда фәнни караш җиңде. Чөнки фәнни күзлектән чыгып фикер йөрткәндә, татар профессиональ театр сәнгате тарихын Г. Исхакый иҗатыннан башка, аның сәхнә әсәрләренә тукталмыйча дөрес итеп язарга мөмкин түгел.

Татар профессиональ театры туунын беренче айларыннан башлап Г. Исхакыйның драма, фаҗига һәм комедияләре еллар буе сәхнәдән төшмичә, зур уңыш белән уйналып килгән. Октябрьгә чаклы аның 9 пьесасы татар сәхнәсенә менә. Бу — татар театрының атасы Г. Камалның Октябрьгә кадәрге сәхнәдә уйналган әсәрләре санынча ук. Әгәр Г. Камал драматург, артист һәм режиссер буларак шәхси катнашы, конкрет ярдәме белән татар театры туууына һәм формалашуына төрле яклап зур иҗади өлеш керткән булса, Г. Исхакый театр репертуарын милли азатлык проблемаларын кискен чагылдырган киң колачлы пьесалар белән баетуда аерылып торган. Башкалар белән беррәттән, аның әсәрләре нигезендә дә беренче буын татар артистлары үзләренең профессиональ осталыкларын чарлап, театрны яңа баскычка күтәргәннәр.

Кыскасы, әлеге тарихи фактларны истә тотып, авторлар редакцияләү процессында хезмәтне тагын да тулыландыра төштеләр. Инде ул китап укучылар кулында. Шик юк, алар анда үзләрен кызыксындырган күп кенә мәгълүматларны табарлар, Октябрьгә кадәрге татар сәхнәсенең һәвәскәрлек чорыннан югары профессиональ театр дәрәҗәсенә күтәрелү юлын җанлы рәвештә күз алдына китереп бастырырлар. Россиянең төрле төбәкләрендә бер-бер артлы барлыкка килгән беренче татар театр труппаларының шул заманның иҗтимагый проблемалары белән тыгыз бәйләнештә камилләшә баруы, халыкка кыю идеяләр, демократик фикерләр таратуы, репертуар, режиссер эше, артист уены, сәхнә бизәлеше, театр тәнкыйте, иҗат методы мәсьәләләре — болар барысы да китапта көндәлек матбугат, архив, цензура материаллары, шәхси истәлекләр нигезендә фәнни дәлилләп яктыртыла.

Тагын бер уңай сыйфатны әйтеп үтәргә кирәктер: хезмәт, бигрәк тә һ. Махмутов каләменнән чыккан өлеше (ә ул өлеш 400 битле китапның 340 битен тәшкил итә!), саф татарча, сыгылмалы, үтемле тел белән язылган. Һәрхәлдә, миңа нәшрият редакторы буларак, ул өлешләргә каләм тидерергә туры килмәде диярлек.

# ФӘННИЛЕК ХӘБӘРЧЕСЕ

Йомгак сүзем шул: хәзерге үзгәртеп кору чоры таләпләре югарылыгында язылып, мәдәниятебезнең зур бер өлкәсе булган татар милли театрының революциягә кадәрге катлаулы үсеш юлын чын мәгънәсендә дәлилләп яктырткан бу хезмәт татар хәбәрдарлык матбугатының җитди бер уңышы буларак кабул ителер, дип уйлыйм.

**Рәис ДАУТОВ,**
китапның редакторы.

# ДӨНЬЯ СӘХНӘСЕНӘ СӘФӘР



1941 елның июль башлары...

Көнбатышка китүче хәрби эшелоннарны үткәрә-үткәрә, эреле-ваклы станцияләрдә туктала-туктала, Урал тарафына пассажир поезды бара... Ленинградтан Уфа шәһәренә инде атна буена «шуышучы» бу поездда бөтен дөньяга исеме мәгълүм Ленинград академик хореография училищесының милли бүлеген тәмамлап кайтып килүче берничә укучы да бар. Аларның берсе — унбиш яшьлек Нинель Юлтыева.

Сугыш еллары балаларны да өлкәннәр белән бер сафка бастырды. Еш кына аларга мәктәп парталарын эш станокларына алыштырырга туры килде. Менә шундый авыр вакытларда Нинель дә балет «станогы» янында урын алды. 1941 елның 9 июлендә ул Башкорт опера һәм балет театрының артисткасы булып эшли башлады.

Профессиональ сәхнәдә беренче адымнарын ясаучы яшь кызның иҗат биографиясе башка коллега-яшьтәшләренекеннән берни белән дә аерылмый диярлек: хореографик репертуарны үзләштерү, гомум күренешләрдәге биюләрдә катнашу һәм кайвакытларда соло башкару.

Тырыш хезмәт нәтиҗәсез булмый. Үз эшенә җаны-тәне белән бирелгән, бертуктаусыз иҗади эзләнүләр алып барган Н. Юлтыева тиздән балет солистлары рәтенә чыга. Ул «Коппелия», «Торналар җыры», «Бакчасарай фонтаны» балетларында әһәмиятле партияләрне башкара башлый.

Нинель Юлтыеваның Татарстан балет сәхнәсендәге эшчәнлегенең башы 1946 елның 26 октябрендә Н. Җиһановның «Зөһрә» балетында төп рольдә уйнавына бәйле. Шул вакыттан башлап, бөтен гомерен ул — балерина, балетмейстер һәм педагог буларак — татар балетына багышлады.

Зөһрә ролен театрда беренчеләрдән башкаручы Анна Гацулина була. Талантлы бу актриса алдында имтихан тоту җиңел түгел, ләкин, Нинельнең дебюты бик уңышлы үтә.

Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балеты белән Н. Юлтыева, башкаручы буларак, 1952 елда таныша. Спектакльнең яңа хореографик вариантын А. В. Луначарский исемендәге театр сәнгате институтының балетмейстер факультеты дипломчысы Янина Брунак куя. Яшь балетмейстерның бу диплом эше, уңай яклар белән бергә, кытыршылыклардан да азат булмый әле. Чөнки режиссерлык мәсьәләләрен хәл итү бер булса, икенчесе — милли балетны классик биюгә нигезләргә кирәк. Ә бу җаваплы эш шактый тәҗрибә булуны таләп итә. Брунак академик биюләрне чагыштырмача җиңел һәм уңышлы куйса да, хореографиянең милли үзенчәлекләре, хәрәкәтләре аның өчен еш кына табышмак булып кала. Мондый читен хәлләрдә Н. Юлтыева яшь талантка бик теләп ярдәм кулы суза. Ул аңа киңәшләре белән дә, үзенең көндәлек эше белән дә булыша.

1940 еллар азагы — 50 еллар башында балет театрының репертуары әллә ни бай булмый. Биюләрне икенче урында калдырып, сәхнәдә пантомима өстенлек ала башлый. Хәтта А. Горский куйган «Аккош күле»ндә дә кирәгеннән артык, кайвакыт тамашачыга аңлашылып бетмәгән хәрәкәтләр шактый зур урын ала. «Шүрәле» дә биюләрнең беренче планга куелуы исә спектакльнең дәрәҗәсен бермә-бер күтәреп җибәрә. Н. Юлтыева ул биюләрне биегәндә барлык мөмкинлекләрдән дә файдаланырга тырыша һәм моның белән тамашачылар күңелен яулый.

1957 елда Л. Бордзиловская һәм Ш. Байдәүләтовлар тарафыннан куелган «Шүрәле»

балетының чираттагы хореографик вариантында Нинель Юлтыева инде житлеккән бию остасы сыйфатында чыгыш ясый. Бу балет шул ук елның июнь аенда Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында да күрсәтелә һәм зур уңышлар белән үтә. Нәкъ шул вакытларда, РСФСР Югары Советының 1957 ел, 12 июнь Указы нигезендә, совет сәнгатен үстерүдәге хезмәте өчен Нинель Даут кызы Юлтыевага РСФСРның халык артисткасы дигән мактаулы исем бирелә.

Н. Юлтыева 1958 елда Р. Гобәйдуллинның «Кисекбаш» балетында Зифа партиясен башкара, ә 1959 елда А. Ключаревның «Тау әкияте»ндә Зарифа ролен уйный. Бу лирик образларны «Шүрәле»дәге кыз-кош характеры линиясенең дәвамы дип әйтергә мөмкин, ләкин инде аларда кешеләргә хас мәхәббәт чагылыш таба.

1961 елда З. Хәбибуллинның Е. Дорофеев тарафыннан куелган «Раушан» балетында Нинель Юлтыева башкарган Раушан башка милли образлар арасында үзенчәлекле урын алып тора. Хәрәкәтчән яшь кыз ролен, гаҗәпкә каршы, ул пенсия яше якынлашып килгән елларда уйный. Раушан җитез уеннарны, чәчәкләрне ярата, әнисен сөя, явызлыкны, намуссызлыкны күрә алмый. Ул, кыюлык һәм тапкырлык күрсәтеп, энесен Убырлы карчык кулыннан коткара. Спектакль балалар тарафыннан бик хуплап каршы алына. Алар, күңелләренә хуш килгән Раушанны күрергә дип, спектакльдән соң хәтта сәхнә артына күтәреләләр.

Милли балет классик биюләрдән тыш яши алмый. Чөнки ул фольклорны тулыландыра, балетмейстер фантазиясенә киңлекләр ача. Фольклорның классик бию белән бердәмлеге — милли балет репертуарының үсеше өчен бердәнбер юл. Татар балет сәхнәсендә милли тематикалы спектакльләр нәкъ менә шушы нигездә дөнья күрде. Классика — балет труппасының үзенчәлекле нигезе һәм ул артистларга хәзерге хореографик мәсьәләләрне уңышлы чишәргә ярдәм итә. Шуңа күрә дә һәр опера һәм балет театры репертуарында «Аккош күле», «Йокыга талган гүзәл», «Жизель», «Баядерка» кебекләрнең булуы табигый күренеш.

Һәрбер биюче үзенә классик партия тапшыру белән горурлана. Нинель Юлтыева репертуарында андый рольләр аз түгел. Бөтен сәхнә тормышында диярлек аңа «Аккош күле»ндәге саф күңелле Одетта образы «юлдаш» булды. Ул бу рольне 1947 елдан бирле башкара, аны спектакльдән-спектакльгә камилләштерә, үзләштерә. Дәрес, оста итеп бию серләренә ирешү тиз һәм җиңел генә бирелмәгәндер. әкин артистка, рольләрне яулау белән бергә, тамаша залларын да яулады. Тагын берничә мисал китереп үтү дә урынлы булыр. Әйтик, П. И. Чайковскийның «Йокыга талган гүзәл»ендә Юлтыева — Аврора тамашачыны бу балетны каткат карарга мәҗбүр итте. Ә инде Л. Минкусның «Баядерка»сындагы Никия образы? Икенче күренеш азагында Никиянең хушлашу биюендә чагылыш тапкан кайгы-сагыш, борчылуларның гаять дә зур осталык белән башкарылуы йөрәкләрне тетрәндерә, ирексездән күзләрне яшьләндерә.

1953 елда Казанга күренекле совет хореографы Константин Боярский килә. Аның максаты — А. Крейнның В. Чабукиани редакциясендәге «Лауренсия» балетын кую. Киң эрудицияле, тәҗрибәле һәм бик таләпчән хореограф кыска вакыт эчендә бөтен театрны яңа тормышка алып кереп китә. Ял көннәрендә дә эш бара, бию күнекмәләре сигезәр сәгатькә сузыла. Ә инде киемнәр җитешмәү сәбәпле премьераның вакытында куелмау куркынычы килеп тугач, артистлар үзләре теләп костюмнар тегәргә алыналар. Спектакль билгеләнгән вакытта куела һәм үзенең ялкынлы биюләре белән тамашачыларны таң калдыра. Бу балетта төп партияне Н. Юлтыева башкаруы күпләр өчен шатлыклы була. Балерина лирик-романтик планнан кинәт героик-романтик рольгә күчә һәм ул аны уңышлы уйный. Спектакль азагында Лауренсия-Юлтыеваның, күренекле француз художнигы Эжен Делакруаның «Баррикалардагы азатлык» сурәтендәге героиняга охшашлы рәвештә халыкны азатлыкка чакырып әйдәве шулкадәр тәэсирле була ки, хәтта тамаша залы бу минутта ирексездән аягүрә торып баса!

Нинель Юлтыева М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә тагын да бик күп төп партияләрне башкарды. Мәсәлән, алар арасында А. Аданның «Жизель»ендә — Жизель, С. Прокофьевның «Таш чәчәк» балетында — Катерина, Л. Минкусның «Дон Кихот»ында — Китри, Э. Григның «Пер Гюнт»ында Сольвейг кебек рольләрне әйтеп үтәргә мөмкин.

Күренекле артистка спектакльләрне сәхнәләштерүче буларак, 1969—73 елларда «Йокыга талган гүзәл», «Шопениана», «Франческа да Римини», «Болеро», «Тереләтелгән риваять», «Шәһрезадә», «Бакчасарай фонтаны» кебек балетларга үзе уйлаганча сәхнә тормышы бирде. Әйтергә кирәк, әлеге спектакльләр театр һәм балет театры тарихында һәм ул вакытта уйнаган артистлар биографиясендә җуелмас эз калдырды.

Нинель Юлтыеваның исеме үзебездә генә түгел, чит илләрдә дә яхшы мәгълүм. 1974 елда ул Мисырга өч еллык иҗади командировкага җибәрелә. Анда башта бию буенча дәресләр бирә, аннан соң Каһирә балет труппасының баш балетмейстеры һәм сәнгать җитәкчесе булып эшли. Зәлекле күнекмәләр, иҗади тырыш эзләнүләр тиздән үзенең нәтиҗәләрен дә бирә башлый — Мисыр балеты турында Варна, Токио, Мәскәү һәм башка шәһәрләрдә үткәрелгән халыкара конкурсларда уңай бәя әйтелә.

Каһирәдәге иң яхшы балет осталары Соня Саркис белән Хәсән Шитов ватандашлары-

ның һәм чит ил тамашачыларының ихтирамын казануда үзләренең укытучысы — татар балеринасына бурычлы булуларын онытмыйлар.

1985 елның июнь аенда балет артистларының Мәскәүдә үткәрелгән Бишенче Халыкара конкурсында Нинель Юлтыева үзенең элекке укучысы, хәзерге көндә Мисырның Югары балет институты ректоры Магда Салехны күреп янә бер сөенә. «Жизель» балетыннан вариацияләрне нәкъ менә Н. Юлтыева өйрәткәнчә бөтен төгәллекләре белән башкарып, Салех конкурста җиңеп чыкты. Шулай ук конкурста Н. Юлтыеваның тагын бер укучысы — аргентиналы Хулио Бокка да бар иде. Ул беренче урынны яулады һәм алтын медальгә лаек булды. Бу югары бүләктә остазының да шактый зур өлеше барлыгын әйтеп, балерина аңа рәхмәт хисләрен белдерде. 1981—1983 елларда Венесуэла хөкүмәте чакыруы буенча Нинель Юлтыева Каракас шәһәренә командировкага килгәч, Хулио Бокка аның җитәкчелегендә шөгыльләнде. Дөресен әйтергә кирәк, бер‍едә эшне юктан башларга туры килә. Шулай булуга карамастан, кыска гына вакыт эченчә аның тарафыннан «Аккош күле»нең икенче һәм өченче актлары, «Шопениана», «Жизель», А. Бородинның «Князь Игорь» операсыннан «Кыпчак биюләре» куела. «Гаяне» балетыннан А. Хачатурянның «Кылычлар белән бию»е дә венесуэлалылар тарафыннан хуплап каршы алына.

Чит илләрдә эшләү дәверендә Нинель Юлтыева үзенең дә иҗади репертуарын баетты һәм тулыландырды. Мәсәлән, Каракастан ул халык көйләренә эшләнгән «Венесуэла вальс»ын алып кайтты һәм Казан дәүләт культура институтында хореография бүлеге студентлары өчен куйды. Шуны да әйтеп үтү урынлы булыр, ул 1972 елдан шушы бүлектә кафедра мөдире булып эшли.

Бүгенге көндә Нинель Юлтыевага илебезнең төрле төбәкләреннән, чит илләрдән бихисап хатлар килә. Инде хәзер күпләре танылган сәнгать осталары булып әверелгән аның элекке укучылары остазларына чын күңелдән рәхмәт әйтәләр.

*Рәсемдә: Н. Юлтыева һәм Ә. Нарыков Н. Җиһановның «Зөһрә» балетында биилэр.*

**Владимир ГОРШКОВ.**

# КӨЗЛӘР НИГӘ МОҢСУ?

Көзнең урталары җитсә дә, ул елны көннәр җылы, ягымлы, кояшлы торды. Авылга кайтып төшкәч тә иң әүвәл әнинең кыз чагындагы якын дусты Гарифә апа янына кердем. Ул, күчтәнәчләремне мактый-мактый өстәлгә куеп, тиз генә самавырын яңартып җибәрде, хәл-әхвәл сорашты. Монда төбәп керүем юкка түгел иде, чәй янына утыргач та мин:

— Гарифә апа, сөйлә әле әнием турында, нинди иде ул? — дип, сораулар йомгагын сүтә башладым. Гарифә апа, нәни балага хас матурлык белән елмаеп куйды да сөйләп китте:

— Бервакыт шулай әниең белән уеннан кайтып килəбез... Бер тапкыр шулай уракка төшкән чак... Бер кичне шулай Сөләй белән Фәләхи безне озата кайталар...

Мин йотлыгып тыңлыйм, дулкынланам, мин белеп тә бетермәгән әллә ничаклы хатирәләр йөрәгемә тула. Байтак сөйләшеп утырганнан соң: «Улларыңнан хәбәр бармы, Гарифә апа?» — дип сорап куйдым.

— Юк шул, энем җаныем, юк. Менә сигез елдан артып китте инде, ни үзләре, ни хатлары юк... Таза-саулар, эшлиләр, дип Урал ягыннан кайтучылар ишеттерәләр үземә. Югыйсә, иң авыр елларда да ач-ялангач итмәдем бит үзләрен, әтисез үстердем, актык сыныкны һәрчак икесенә тиң бүлеп бирә идем... Ярар, кайтмасыннар, язмасыннар, хәзер көтмим дә инде... Исләренә төшәр төшүен, тик соң булыр. Миңа берни дә кирәкми алардан, хөкүмәтебез биргәне җитә, аллага шөкер. Әзме-күпме тавыгын асрыйм, кәҗәм бар сөткә, саламына-утынына да калхуз аптыратмый, алланың биргәненә шөкер. Тик Сөләйманемне генә һаман көтәм әле... Инде сугыш беткәнгә байтак булса да: «Гарифә, мин кайттым!» — дип Сөләйманем капкадан ук аваз бирер шикелле...

...Тагын бер көз хәтеремдә. Урамда вак кына яңгыр сибәли, тәрәзәне чылата. Радионы ачып җибәрүгә, өй эченә искиткеч моң агылды. Җырның актык сүзләрен генә отып калдым:



*Маликовлар гаиләсе ял вакытында да җыр-моңнан аерылмый.*

Көзләр килде, карлар яуды.
Кавышырга вакыт безгә...

Үтә матур, үтә көчле тавыш. Күңелләрне сагышларга, тирән хисләргә салырлык күркәм тавыш. Сүзләре белән көе нинди аһәңлек, аваздашлык тапкан! Минем өчен моңарчы бер дә таныш тавыш түгел бу. Кем җырлады шулай йөрәкка үтеп керерлек иттереп, кем ул?.. Шушы җырның тылсымлы, серле көче мине бар куәтенә әләктереп алды, бу тавышны тагын да ишетәсем, алай гына да түгел, җырчының үзен күрәсем килеп йөри башладым.

Язмыш миңа, җырчы белән очрашу, аның үткәннәре белән танышу мөмкинлеген әзерләп куйган икән.

Малай чакта Рөстәм радио аша тапшырылган һәр концертны хыялга чумып тыңлый, барысын да күңеленә сеңдерә бара. Халыкның озын җырлары аеруча җилкетә аның йөрәген. Урта мәктәпне тәмамлагач, ерак Байкал буенда армия сафларында хезмәт итеп кайта. Әмма кайда гына йөрсә дә, Рөстәмнең күңел түрендә җырчы булу хыялы сүрелми һәм сихри җыр дөньясы аны Казан музыка училищесына алып килә. Чиста, саф тавышлы, тырыш егеткә укуы җиңел булмый, әлбәттә. Торыр урыны юк, кайчакны вокзалларда йокларга да туры килә. Тора-бара милиция хезмәткәрләре аны таный башлый, вокзалдан куарга тырыша...

Ләкин нык рухлы, максатыннан чигенмәүче Рөстәм бөтен авырлыкларны җиңеп чыга. Училищены уңышлы гына тәмамлый һәм, шул ук елны консерваториягә имтиханнар биреп, биш ел дәверендә танылган җырчы һәм укытучы Зөләйха Хисмәтуллина классында җыр сәнгате серләрен камилләштерүен дәвам итә.

Консерваторияне уңышлы тәмамлаганнан соң Рөстәм бер-ике ай Казанда эшләп ала. Аннары... Үз тормышында беренче мәртәбә Уфага гастрольгә баргач, филармония җитәкчеләре бик үтенеп аның үзләрендә калуын сорыйлар, торакны озак көтәргә туры килмәс, диләр... Башкортстанда ун ел буе диярлек эшләгән чорда Рөстәм Маликов халыкның иң яраткан, иң популяр җырчысына әверелә. Дүрт ел дигәндә «Башкортстанның атказанган артисты» дигән мактаулы исемгә лаек була. Бу зур вакыйга яңа үрләргә күтәрелергә этәргеч, илһам бирә, иҗатына көч өсти. Әледән-әле яңа пластинкалары дөньяга чыгып тора. Шушы елларда Рөстәм берничә тапкыр чит илләргә бару бәхетенә дә ирешә. Һиндстан, Шри Ланка, Дания, Перу, Монголия тамашачыларына үзебезнең милли җырларыбызны, моңнарыбызны бүләк итә. Аның кабат-кабат җырлавын сорыйлар, җырчы һич кыстатмыйча тамашачының күңеле булганчы җырчәчәкләргә күмәләр. Җырчы һич кыстатмыйча тамашачының күңеле булганчы җырлый, тагын сәхнәгә чыга, тагын татар һәм башкорт моңнары агыла, тагын көчле алкышлар кабатлана.

Германия Демократик Республикасында исә Рөстәмгә ике мәртәбә булырга туры килә. Шуларның берсендә ул опера җырчылары фестивалендә катнаша. Анда төрле ил вәкилләре җыелган, һәрберсе үз телендә җырлый. Гадәттәгечә, опералардан өзек-

ләр, арияләр башкарырга туры килә аңа. Рөстәм монысында да сынатмый, талантлы татар җырчысын көчле алкышка күмәләр, вокаль осталыгына сокланалар.

Кыскасы, Башкортстанда җырчы үзе әйтмешли, эшләре гөрләп бара... Әмма аны — Минзәлә районының Бикбау авылы егетен — туган яклары һәрвакыт үзенә тарта, туган теле, туган як авазы, туып үскән Ык буйлары үзенә чакыра. Һаман шулай сагынып яшәүләргә ничек түзәсең? Һәм Маликовлар гаиләсе Казанга күчеп кайта.

...Карлар ява. Энжеләрне
Күрәсеңме, әй сөйгән яр?
Һәрбер энже бөртегендә
«Сөям» дигән сүзләрем бар...

Фирзәр Мортазинның шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов сүзләренә язылган «Көзге моң» дигән җыры бу. Тембр ягыннан үзенчәлекле сокландыргыч лирик-драматик тенорга — күңел кылларын тибрәтеп, дулкынландырып торган гүзәл тавышка ия булган Рөстәм җырның төп серен, асыл мәгънәсен ачып сала. Һәр аваз бөтенләй яңача яңгырый, җырны тыңлаганда тамашачыга рәхәт тә, моңсу да булып китә.

Әнә сәхнәдән, Рөстәм Маликов башкаруында, халкыбызның «Герман көе» агыла. Монда инде түзеп булмый, җырчы беренче юлларны башкаргач та күңелләр тула, керфекләргә дым куна. Бабаларыбызның беренче бөтендөнья сугышына китүләре, әтиләребезнең Бөек Ватан сугышына к[illegible] тотулары, әбиләр һәм әниләребезнең аларны озата барулары күз алдына килә дә баса...

Без барасы юлларның ла
Ике ягы канаулы...

Авылыма кайткан чакта әтием сугышка киткән юлдан атлыйм. Аның ике ягында да канау. Өлкәннәр әйтүе буенча, сугышка кадәр дә шулай булган.

...Герман җире кара үлән,
Әллә кайтам, әллә үләм...

Җәй саен печән чапкан иркен болыннарын ташлап китүе дә, герман җирендә үлеп калуы да әтиемне әллә ни борчымагандыр. Әле яңа гына туып калган улы (җитмәсә әнкәсе дә чирләп тора иче...), исән каламы бу бала, юкмы — менә нинди уйлар аның йөрәген тырнаган. Шушы авыр уйлар белән ул ут эченә барып кергән... Шәхсән минем өчен «Герман көе» — җыр мирасыбызның гүзәл, якты бер йолдызы, халыкның тарихи хәтере, сагыш белән сугарылган татлы бер хәзинәсе, шуларга өстәп тагын әткәм истәлеге...

Рөстәм тиргә батып эшли торган сәләте, милли җыр сәнгатенә гашыйк булуы, тамашачыны чын күңелдән олылау, аңа игътибар итә белүе, вөҗданлылык кебек сыйфатлары белән аерылып тора. Сәхнәдә үз-үзен тотышы, тыйнаклыгы, сөйкемлелеге, җыр сөючеләр белән һәрбер очрашуга зур җаваплылык тоеп әзерләнүе дә аның иҗат йөзен күркәмләп тора.

Кеше сусыз яши алмаган кебек, җырсыз да яши алмый, җыр ул — чын мәгънәсендә күңелгә, йөрәккә бәһасез дару. Моны исбатлап тору кирәкмидер.

Минем әнкәй гөл ярата иде,
Матур иде аның күңеле.
Тормыш тәрәзәсен бизәп торды
Йөрәк хисе булып һәр гөле...

Монысы инде газиз әниләр турында. Композитор Афарим Акчурин Расих Ханнанов сүзләренә иҗат иткән. Әниләр, әниләр... Күпме язылган, күпме җырланган, күпме әйтелгән алар хакында. Һәм, җирдә тормыш булганда, күпме җырланачак, күпме әйтеләчәк, күпме язылачак әле... Шунысын да әйтеп китәргә кирәк, бәхетле аналар арасында, дөнья булгач, бәхетсезләре дә җитәрлек. Ана кадерен белмәүче, хат-хәбәр язмаучы, исән вакытында кайтып та карамаучылар йөрәген аңлап та, аклап та булмый. Бәхетсез аналар — җәмгыятьнең дә бәхетсезлеге, әхлакый югалтуы.

Моннан алты ел элек Рөстәм Маликовның әнисе вафат булды. Бик авырдан кичерде ул иң якын кешесез калуын. Әнисенә истәлек итеп репертуарына «Минем әнкәй гөл ярата иде» дигән җырны кертте... Залда тынлык, залның бөтен игътибары җырчыда. Менә сәхнәдән җыр агыла, әниләр турындагы сагышлы-якты җыр. Әниләр күбебез өчен кадерле шул, шуңа күрә дә җырчыны бик озак сәхнәдән җибәрмиләр.

Бүгенге көндә Татарстанда Рөстәм Маликовны ишетмәгән, аның киң, иркен, кабатланмас тавышына сокланмаган кеше, мөгаен, сирәктер. Аның дисталәгән җырларын үз

итеп, яратып өлгерделәр инде. Шулар арасыннан берничәсен генә әйтеп китик: «Күңелемне аңла», «Миләүшә», «Мин ышанам синең сөюеңә», «Урманнарда йөрдем», «Әдрән диңгез», «Ай эзләдем, ел эзләдем» һәм башкалар.

Рөстәм Маликов концертын тыңлаганнан соң чистарынып киткәндәй буласың, кешеләргә игътибарың үсә, яшәгән җиребезгә мәхәббәтең арта, уйланасың, горурланасың...

Рөстәмнең хатыны Гүзәл дә сәнгать кешесе. Ул вакытында музыка училищесы тәмамлаган. Туган шәһәренә әйләнеп кайтканнан бирле мәдәният йортында «Сәрвиназ» исемен йөрткән хатын-кызлар ансамблен җитәкли, гаиләсе белән концертларда катнаша. Ата-анасының «чире» улларына да күчми каламы соң! Сәхнәгә аяк басып килүче җиде яшьлек Муса гаҗәп матур итеп татарча сөйләшә, оста итеп төрле гармуннарда уйный, яңгыравык тавышы белән хәйран калдырырлык җыр суза. Мин беләм һәм ышанам: үсеп җиткәч тә Муса әнә шулай сәнгатькәр җанлы булыр, остара һәм ирләрчә уйлана гына төшәр. Димәк, сәнгатебез, тарихыбыз беркайчан да онытылмас, халкыбызның моң чишмәсе, җәүһәрләре буыннан-буынга күчә барыр.

Тагын көз иде... Төзүчеләр әзерли торган профессиональ-техник училищесы директоры булып эшләгән чагым. Үзебезнең Балтач районы мәктәп балалары белән очрашу билгеләнгән иде. Туган авылыма да сугылдым. Гарифә апа яшәгән йорт янына якынлаша төшкәч, аптырап калдым: тәрәзәләр черек такта кисәкләре белән кадакланган, ишегалдында тавыклар да, кәҗә дә күренми, бары тик иске бер чиләк кенә аунап ята, рәшәткә башында китек чүлмәк кисәге эленеп тора... Кинәттән: «Уллары кайтып алып киткән икән Гарифә апаны»,— дип уйладым. Янымa күрше Ибраһим абый килеп туктады.

— Үлде ул, юк инде Гарифә апаң... Күрше-күлән җыелышып җирләдек, әле күптән түгел кырыгын уздырдык. Актык сулышына чаклы тәрәзәдән күзен алмады бичаракай, улларын түгел, Сөләйман абыйны көтте ул. Улларына аның бәгъре каткан иде инде...

Мин үземнең тагын бер мәртәбә ятим калуымны сиздем. «Әнием нинди кеше иде ул?» — дип сорарга минем беркемем дә калмады. Мин зиратка таба атладым. Әнием белән очрашырга, әниемнең кыз чагындагы якын дусты Гарифә апа белән хушлашырга... Минем аларга күпме әйтәсе, күпме сөйлисе сүзләрем бар иде.

Һавада кар тавы хәтле болыт кисәкләре очып йөри, сары, кызгылт яфраклар агачларыннан өзелеп төшеп чардуган өсләренә килеп куна, берән-сәрән каргалар кычкырып куя. Зиратта тынлык, зиратта тарих, зиратта моңсулык. Көзге моң. Үтә әче, үтә моңлы була икән көзге моң...

**Хәниф ФӘЛӘХЕТДИНОВ.**

# ИЕЛМӘС БАШ

Гаяз Исхакый... Бу исемне ишетү белән күз алдына курку белмәс инкыйлабчы, үткен телле публицист, киң колачлы әдип, тынгысыз җәмәгать эшлеклесе килеп баса. Ләкин Исхакый киң әтрафлы нашир, баш имәс мөхәррир дә бит әле. Чигенү һәм тайпылуны белмәс характерлы, бәреп торган темпераменты, иманына тугрылыгы әдипкә яшь вакытыннан ук эреле-ваклы афәтләр алып килгән. Ул төрмәләргә ябылган, сөргеннәргә сөрелгән. Цензура инициативасы белән салынган штрафларны түләү исә аның өчен, гомумән, гадәти күренешкә әверелгән.

1913-1915 елларда әдип Петербургта һәм Мәскәүдә чыккан «Ил» газетасын нашир һәм мөхәррир буларак җитәкли. Бу матбугат органында эшләү Исхакыйның тәрҗемәи хәлендәге иң бәрәкәтле сәхифәләренең берсе. Аның «Ил»дә басылган дистәләгән мәкалә һәм хикәяләренә тукталып тормыйбыз, аларның һәммәсе дә диярлек татар публицистикасы һәм әдәбияты тарихында күренекле бер вакыйга. Биредә сүз Г. Исхакыйны мөхәррир буларак кына түгел, принципиаль шәхес буларак та бәяләргә ярдәм итә торган бер факт турында бара.

1913 елның 6 декабрь санында «Ил» газетасында «М. Мәннаф Троицкий» имзасы белән бер шигырь басыла. Ул түбәндәге юллардан гыйбарәт:

### ТАТАРГА

И татар, мескен, бичара, кайда китте ул шаның?
Дөньяны дер селкетеп йөргән батыр Чыңгыз ханың?
Кайда синең чиген үзең белмәгән киң йирләрең?
Дөньяда мисле күрелмәгән фидаи ирләрең?
Күзге агач яфрагыдай дошманың саргайтканың?
Кайда итсәң дә һөҗүм син, шунда җиңеп кайтканың?
Кайда инде ул көчең, ул байлыгың, ул шаннарың,
Тик тарих битендә калган ялтыраган намнарың.
Син хәтергә алмыйсың ник? Әй, татар углы татар!
Син электә бай идең бит, син хәзер ярлы, татар!
Син элек хаким идең бит, син хәзер кем, и татар!
Син хәзер куркак, йөрәксез, син хәзер кол! И татар!
Кычкырам бит, торсаңыз ла йокыңыздан уйганып,
Нинди хәлләр үтте баштан, бер караңыз уйланып.

Цензура реакциясе үзен озак көттерми. Газета чыгып җиту белән үк шигырьнең юнәлеше «җинаятьчел» дип табыла. С. Петербургның матбугат эшләре буенча комитеты үзенең 9 декабрьдәге утырышында мәсьәләне болай хәл итә: газетаның мөхәррире Гаяз Исхакый һәм шигырь авторы Троицкийга каршы хөкем эше кузгатырга, ә «Ил»нең 6 декабрь санына арест салырга. Бу карар тормышка ашырылып, газета саны конфискацияләнә, ә Исхакый судка бирелә. Хөкем әдиптән катгый төстә шигырь авторы турында мәгълүмат таләп итә. Әмма Г. Исхакый шагыйрь турында күрсәтмә бирүдән баш тарта, бөтен җаваплылыкны үз өстенә ала. Аның бу адымы әдипнең гаҗәеп ихтыяр көченә ия булуы турында да сөйли. Шулай да М. Мәннаф Троицкийның кем булуы безнең өчен әлегә һаман сер булып кала. Кем белә, бәлки ул «Ил» газетасында актив катнашкан, М. Гафури, Н. Думави, С. Сүнчәләй яисә башка берәр мәшһүр шагыйрьнең тәхәллүседер? Ничек кенә булмасын, үзенең каләмдәш дустын хөкем кулыннан йолып калу өчен патша сөргеннәрен һәм төрмәләрен җитәрлек татыган Исхакый иелмәс горур башын яңадан суд карамагына тапшыра.

Ләкин бу юлы тәкъдир әдипнең гражданлык каһарманлыгына ничектер мәрхәмәт белән җавап бирә. 1914 елның 12 маендагы утырышында Суд палатасы шигырьдә законга хилаф «җинаять» тапмый һәм эшне ябу турында карар кабул итә. 6 декабрь санынннан арест кире алына һәм газетаның мөхәррире Г. Исхакый гаепсез дип табыла. Әмма олы йөрәкле әдипнең олуг гамәле буыннар күңелендә ихлас соклану хисе уята.

Равил ӘМИРХАН.

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ХАТЫ

*« Гаяз Исхакыйның әнимә язган бер хатын журнал укучыларына тәкъдим итүне кирәк табам. Архивымда сакланган бу хатта, минемчә, Исхакыйның бөек шагыйребез Тукайга булган мөнәсәбәте дә, кешелек сыйфатлары да җитәрлек чагылыш таба.*

*Бу хатның тарихы турында мәрхүмә әнием, Тукайның яраткан кызы Зәйтүнә Мәүлүдованың сөйләгәннәрен искә төшереп, мин түбәндәгеләрне хәбәр итә алам.*

*Габдулла Тукай үлгәч, Троицкида яшәгәндә, әниемә бәйләнеп йөрүче егетләр аз булмый. Шулар арасында берсе аерата тырышлык күрсәтә, мәгәр әнием кискен рәвештә аннан йөз чөерә һәм үзе артыннан бүтәнчә йөрмәслек хәлгә куя.*

*Күрәсең, бу эш тәкәббер һәм кинә саклаучан егетне чыгырыннан чыгара, ул әниемнән үч алу өчен, аның турында һич булмаган уйдырмалар язып, матбугатка чыга. Бу яла, әлбәттә, минем булачак әниемне бик рәнҗетә һәм ул, ярдәм сорап, ул вакытта «Ил» газетасының мөхәррире булган Гаяз Исхакыйга хат яза.*

*Түбәндә тәкъдим ителә торган хат — Гаяз Исхакыйның әниемә җавабы. Ул 1914 елда язылган булса кирәк.*

**Атилла РАСИХ.**

## Зәйтүнә Мәүлүдова хаты

Хөрмәтле Гаяз[1] абыем!

Бән тагы Сезгә канлы, җәрәхәтле яшь калеп илә хат язарга керештем. Моны укыгач «Фу, шул Зәйтүнәнең зарлануы бетмәс», диярсез микән. Гаяз абый, нихәл итим, кемгә әйтим бән хәлемне, кем аңлар? Сездән башка серемне, хәлемне сөйләр һичкемем юк. Чын ышанычлы, мәрхәмәтле дин кардәшем Сез.

Мин Сездән аз гына да үзем хәл кылып бетерә алмаган мәсьәләләремне сорыйм. Сезгә киңәш итәм.

21 июньдә «Сөембикә»[2] журналында «Яшерен мәхәббәт сәрләүхәсе» (мәкаләсендә) Җамалетдин Юмаев имзасы илә бәне чын вөҗдансыз, Тукаевны үлтерүенә шатланып, аны һич уена китерми, матди, булган малларга, матур егеткә алданып, шулар илә ләззәт табып йөрүче бер аңсыз тупас кыз дип исмем белән әйтеп тәхкыйрь кыла...

Ах, Гаяз абыем, бән шулаймени? Хәзер бән (аны) исемә дә кертми рәхәтләнеп чәчәкләр арасында торам, имеш. Ходаем миндә булган, алар рәхәт диеп уйлаган матди вә мәгънәви булган хәлләрне һәр каюсын аларга бирсә иде дә, бәнем хәлне аларга аңлатса иде...

Ул әйтә: шәһәрдән китүен аермачык язып карады, аңсыз, тупас кыз аңламады яки белсә дә исе китмәде, ди. Дөрес, ул язуны укыгач та миңа һәм Тукаев[3] язган диеп тә белмәдем, ул имзасын Ялкын дип куйган. Без Чистайга кайткач та (ул шигырьне) укыдык. Аны миңа гына дип уйларга мөмкин дә түгел. Без Габдулла әфәнде белән аҗам белән бергә таныштык, һәрвакыт бергә очраштык. Җәмалетдин әфәндинең теләр-теләмәс кенә баш иеп китә, дигән сүзе дә хата. Бүгенге кебек хәтеремдә, бер көнне мин ике апам белән (урамда) барганда безнең яннан вагон үтеп китте, минем ян-янга каранып йөрү гадәтем булмагач, бер дә вагонга күтәрелеп карамадым. Бераз киткәч, олы апам: вагон тәрәзәсеннән бер рус башын тыккан да баядан бирле башын селкеп бара, аллә инде сезгә, диюгә кече апам карады да, Габдулла Тукаев, диде, мин дә карадым, (аннан) икебез дә баш идек, ул да баш ия-ия китте. Икенче вакыт без «Әл-Ислах»[4] редакциясе янында урамда очраштык. Ул күрешимме, юкмы дигәндәй (икеләнеп) күреште. Мин никадәр сөйләшергә теләсәм дә, ул күп сөйләшмәде.

Гаяз абый! Ул мине сөя, шуңа шулай салкын сөйләшә дип уйлый алыйммы мин — ул вакыт ундүрт яшьлек кыз. Ул вакыт Солтан Рахманколыйлар мине үртәп, мишәр баласы, дип кенә йөриләр иде...

(Хәер) шул ук елны Казанда бик шәп әдәбият кичәсе булды, шунда Габдулла әфәнде «Утырышу» (шигырен) укыганда һаман миңа караган кебек тоелды. Шуннан кайтуга Фатих абыйның якын кардәше Фатыйма Апаковаларга, Габдулла әфәнде шигырен укыганда гел миңа карады, дидем, мин бик оялдым, дидем. Алар: «Бик карагандыр инде сиңа, исе киткәндер»,— дип үземнән көлделәр, мине мактанчыкка хисап кылдылар. Мин апам алдында бик оялдым, кызардым вә шулвакыт: «Әйе шул, Габдулла әфәнде минем ише кечкенә генә ярлы мишәр баласына исе китеп карамас, аның карыйсы килсә миннән рәтле кызлар да монда бетмәгән, караса, күзе төшкә дә

күңеле миндә булмагандыр, мин, тиле, кешеләрне үземнән көлдерәм» дип, үземне орышып, борчылып йөрдем. «Сөембикә»дәге мәктүбне укыгач, хәйран калдым. Минем, начар йөрәкле кешенең тәмам хәле бетте. Яткан килеш журнал тотып укый идем, Кадыйр, анда синең турыда да бар, диде. Укыгач, һич өмидем калмады, дөньяда хәзер бер көн торасым килми. Бу кадәр газаплардан, нахак булган һөҗүмнәрдән тизрәк котыласым килә башлады. Мин үземне Габдулла әфәнде янына җибәрергә уйласам да, өстемдәге бурычым искә төшү генә бу уйдан кайтарды. Агаларым бәне юклы-барлы (акчаларны) үзләренә калдырмыйча, Зәйтүнә укысын да милләткә хезмәт күрсәтсен, үзебезгә уку тимәде, ул кеше булып хезмәт кылганны карап рәхәт табыйк, дип укыттылар. Шушы бурычны әда кылмый үлсәм, мәңге рәхим мәгъзүб булырмын, дидем. Барыбер мин озак гомер сөрә алмам, бу кадәр газап, бу кадәр борчуларга кибәрмен, корырмын, ниһаять, дөньядан китәрмен, тик үз кулым белән (үземне) үлтерү кебек эшкә бармам, дидем.

Гаяз абый, минем хәлне күп кеше аңламый, журналга карап һәркем бәне вөҗдансыз, таш калебле, юкка алданучан бер кыз диеп ләгънәт укыйдыр. Гаяз абый! Хатыгызда, матбугатка сез чыкмагыз, дигәнгә күрә тагын Сезгә хат язарга керештем. Үткән хатта үзегез (матбугатта) чыгарга вәгъдә бирмеш идегез. Хәзер ни итәсез, чыгасызмы? Мин тын гына торыйммы? Сездән инсаният наменә бер киңәш көтәм. Бәнем саф вә вөҗданлы икәнемне үзегез яхшы беләсегез, матбугат алдында да бу нәхакләрне бәндән китәреп бәне пакьлавыгызны вә бәне тынычландыруыгызны күз яшем илә вә сабырсызлык илә сорыйм.

Сездән мәктүп килеп тынычландырганчы җәһәннәм газабында, каты газап эчендә янып калган милләтдәшегез.

## Гаяз Исхакый хаты

Хөрмәтле Зәйтүнә ханым!

Сезнең хатыгызны алып күп-күп уйга чумдым. Мин үзем һичбер төрле сезне гаепләмим. Сезне һичкемнең гаепләргә хакы юк. Бу мәсьәләдә сез ак, сез баласыз. Бер кешенең сөюендә, икенче кешенең һичбер төрле тәэсире булмаган кебек, сөелмеш кеше шул матур хискә сөю берлә җавап бирмәсә дә һичбер төрле гаеп булмый. Чөнки сөю гакыл берлә мотлак бергә йөри торган эш булмаенча, фәкать йөрәкнең ихтыяры берлә генә идарә ителә торган илаһи бер куәтдер. Сез бердән белмәгәнсез, белгән булсагыз да сез үзегез сөймәгәндә белмәгәнгә тырышырга (?) тиеш (?) иде, монда җинаять юк, монда начарлык юк. Сөю мәсьәләсендә хаклы, хаксыз юк. Сөю бар, сөймәү бар. Басынкы акыл белән чыгарылган үлчәүләрнең сөюгә һичбер төрле мөнәсәбәте юк.

Әгәр сез Габдулланың сөйгәнен белә торып аны мыскыл иткән булса идегез, аның мөкатдәс хиссиятеннән көлгән булса идегез, аның ачылган йөрәгенә төкергән булса идегез, сез гаепле булыр идегез. Сездә ул булмаган, булмаган гына түгел, сез Габдулланың шул хисене белгән булсагыз, үзегез Габдулланы «Габдулла» дип сөймәсәгез дә аңарга ихтирамән, аның талантына ихтирамән үз тормышыгызне анықы берлән бәйләрлек кадәр каһарманлык та булган. Бу бик зур эш, бик зур олуглык. Сезнең хатыгыздагы шул җирләрне укыганда галиҗәнабыгызга исем китте. Хатыгызның чын күңелдән язылган булуы минем алдымда сезгә карата зур ышаныч, бөек ихтирам тудырды. Хәзер сез һичбер төрле вөҗдан газабы берлән газапланмагыз. Сез пакьсез. Габдулланың сезне сөюе, шагыйрәнә сөюе сезнең өчен булып узган бер сыйфаттыр. Сез Габдуллада нечкә пакь хисләр уяткансыз. Габдулланың йөрәгене чарлагансыз, аны матур нечкә шигырьләр әйтергә мәҗбүр иткәнсез. Габдулланың шигырь тудыруында үз ихтыярыгыздан башка ярдәмдәш булгансыз. Моның өчен һаваланырлык, мактанырлык хакыгыз бар. Мин язганда да хәзер дә сезгә каршы һичбер төрле битәрләү ташламадым һәм дә ташларга хакым да юк. Сез Габдуллага каршы вә татар әдәбиятының бер баганасына каршы һичбер төрле хыянәт кылмадыгыз. Икенче мәсьәлә, «Мәктәп»нең Тукай номерында «Җан Шәрәф» имзалы бер мәкалә укыгансыздыр, укымаган булсагыз, укыгыз. Анда сезнең хакта шактый ачык язганнар. Минемчә, алар әйтергә тиеш түгел иде. Ләкин журнал безнең кулда булмаганга, алда шундый мәсьәлә чыгуын күреп җитә алмаганга ясалган бер хата. Ләкин үзегез һичбер вакыт үзегезне якларга дип матбугатка чыкмагыз. Шундый мәкаләләр бәлки киләчәктә дә булгалар. Анда да салкын канлыгыгызны югалтмагыз. Шундый сезне ача торган мәкаләләр чыкмасын өчен мин Фатихка[7] хат язам. «Мәктәп»кә дә әйтеп үтәрмен. Казанга баргандa башка журнал даирәләре берлән дә сөйләшеп алырмын. Ләкин бит, Зәйтүнә ханым, татар дөньясында бик күп былчырак кешеләр бар, алар бер җирдә пакь, матур зат күрсәләр, күзләре кыза, шуны былчыратырга керешәләр. Бу эшнең ахырын белмиләр, кешегә хөрмәт күзе белән

карый алмыйлар, һәр нәрсәнең былчырак ягын өстерәп чыгарга тырышалар. Менә шундыйларның берсе К. Бәкер [8] «Вакыт»[9]ның апрель 13 ндә чыккан номерында Тукайга каршы зур бер былчырак ыргыта. Тукайны хөрмәтләвебезне мыскыл итә. Тукайның үлемен эчүенең сәбәпләрен (?) бик кабәхәт бер авыру иттереп танытырга тырыша. Бу мәкаләнең миңа биргән тәэсире әйтеп бетерерлек булмады. Укыгач та Петербургда Тукайны караган докторга киттем. Ул катгый тарызда [10], Тукайда шундый авыру юк иде, диде. Киләчәк номерыбызда шул хакта озын мәкалә язам. Тукайның симасы[11] хакында сездә шул мәсьәләдә һичбер төрле шөбһә уянмасын.

Җитте түгелме?

Сезне туегыз белән котлыйм. Мин бит Габделкадыйрны бик беләм. Шуның өчен туйга чакырмауга үпкәләргә дә хакым юк түгел. Ярар инде, Троицкига баргач бер бик сыйларсыз яисә бик сынап бер кыз табып бирерсез. Мин дә бит һаман әле егет.

Мәскәүгә барып кайттым. Хәтимә туташны күрдем. Сәламәтләнгән. Гөлсем яшь хатын булды, берни язмый-сызмый, газета да алмый. Безнең газетада хас «Хатын-кызлар тавышы» дигән бүлек ачылды. Шунда язарга тырышыгыз әле, тагы сез ишан киленe булгач, безнең газетәне таратуда ярдәм итегез әле. Хатын-кызлар арасында таратырга җае булса, мин июньдә дәфтәрен җибәрермен. Әлегә хушыгыз. Гаяз.

Андый-мондый матбугатта сезгә һөҗүм булса, үзем каршы чыгарга вәгъдә бирәм. 18 апрель.

Хат кырында: әйтергә яраса Габделкадыйрга сәлам әйтерсез, ярамаса бурычлы калмагыз.

**Искәрмәләр.**

1. Гаяз — Гаяз Исхакый (1878-1954), язучы, прозаик, драмматург һәм җәмәгать эшлеклесе.
2. «Сөембикә»— 1913 нче елның ноябреннән 1918 ел башына кадәр татар телендә хатын-кызлар өчен Казанда чыккан беренче журнал.
3. Тукаев — татар халык шагыйре Габдулла Тукай (1886-1913).
4. «Әл-Ислах»— 1907-1909 елларда Казанда чыккан газета.
5. Солтан Рахманколый (1886-1916)— язучы, журналист, тәрҗемәче һәм сүзлекче.
6. «Мәктәп»— 1913-1914 елларда Казанда чыккан педагогия журналы.
7. Фатих (?)— Фатих Әмирхан (1886-1926) татар әдәбияты классигы.
8. К. Бәкер — Бәкер Кәбир (Бакиров, 1880-1941), язучы, журналист.
9. «Вакыт»— 1906-1918 елларда Оренбургта нәшер ителгән газета.
10. Катгый тарызда — катгый рәвештә.
11. Сима — төс, чырай. Биредә «Г. Тукайның яшәү рәвеше, үзен тотышы» мәгънәсендә

# ФӘТХИ БУРНАШНЫҢ СОҢГЫ ЕЛЛАРЫ

Фәтхи, җаны әрнеп, үзенең Уфа төрмәсендә уздырган вакытын искә төшерде, ул вакытларны бүгенге хәле белән чагыштырды. 1918 ел иде. Ак чехларның котырган, контрреволюциянең иң көчле чагы. Аны, Сембердә чыга башлаган большевистик «Көн» газетасының яшь редакторын, ул вакытта байларга һәм революциянең һәр төрле дошманнарына каршы язганнары: шигырьләре, эпиграммалары, хикәяләр, мәкаләләре, ялкынлы чыгышлары өчен төрмәгә япканнар иде. Анда да ул каһәрләү-кыерсытуларны аз татымады. Үлем әлмәге ул чакта да аның баш очында өч ай буе эленеп торды. Ләкин яшь күңелдә якты өмет көчле иде, шул аның тоткынлык көннәрен бизәде. Иртәгеге көнгә, сыйнфый азатлыкка ышаныч аның бөтен барлыгын биләгән, шуңа күрә халыкның бәхетле киләчәге өчен көрәш рухы аның аклар төрмәсендәге газапларын җиңеләйтә иде.

Ә бүген?.. Ни өчен бу газаплар? Үзенең барлык көч-сәләтен ул яңа җәмгыять төзү эшенә сарыф итмәдемени?! Хезмәт иясе бәхете, аның киләчәге өчен дип көрәшмәдемени?! Ни өчен аны «халык дошманы» ясадылар? Бөтен илне чолгап алган бу әзәрлекләүләр, бер-береңә яла ягып котырынулар, дошманга карата гына түгел, дус-ишләргә карата да шик-шөбһә томанын куертулар, «кара карга» арҗасенә кереп югалулар һәм инде кире кайтмаулар... Нәрсә бу? Нидән бу? Кемнән бу? Әллә бөтен органнарга дошман кереп оялаганмы? Шулай булмаганда, мин һәм минем кебекләр ничек дошман була ди инде? Нинди мәгънәсез гаепләр, уйдырмалар... Ни өчен үзеңнең бер гаепсез, партия һәм халык алдында бер гөнаһсыз икәнлегеңне раслап булмый? Нигә берәү дә синең аклануларыңны тыңларга да исәпләшергә дә теләми?..

Менә инде күпме вакытлар акылын талкыган, бәгырен телгәләгән, күздән яшь китерер дәрәҗәдә гарьләндергән һәм җанын кыйнаган мондый сораулар Фәтхине бүген дә йончыттылар. Ул хурлык, билгесезлек һәм мәгънәсезлек белән тулы хәленә китергән юлны мең дә беренче кат хәтереннән үткәреп, аларга янә дә бер кат җавап эзләде...

## Кулга алыну нигә озаклады?

1940 елның 24 август көне ниндирәк булды соң әле? Күктә кояш балкый идеме соң, әллә күкне болытлар каплаган идеме? Ничек кенә булмасын, нәкъ менә шушы көн аның өчен иң караңгы, иң фаҗигале көн булды да инде. Фәтхи Бурнаш бу көнне Иделнең аръягында, Югары Ослапдагы бакчасында иде: ул монда җиң сызганып иҗат итә, яңа планнар кора. Ә планнар бик тә мавыктыргыч: якындагы ике елда Некрасовның «Кому на Руси жить хорошо» поэмасын тәрҗемә итәргә, «Ялгыз Ярулла» пьесасын Татар дәүләт академия театрында куярга әзерләп бирергә, «Таң» тарихи драмасын яңадан үзгәртеп эшләргә... «Лачыннар»ны алар композитор Мансур Мозаффаров белән бергә опера итеп эшли башладылар. Җәүдәт Фәйзи аның балалар өчен шигырь белән язылган «Кызыл чәчәк» исемле пьесасын опера итәргә ниятләнә. Күңелдә яңа интеллигенциянең тормышына, иске заман калдыклары белән көрәшенә багышланган пьесаның яралгылары туып килә. Планнар зур, барысына да өлгерергә генә кирәк...

Менә шул көнне бакчага чакырылмаган «кунаклар» килеп керә һәм, бөтен җирне айкап тентегәч, бакча хуҗасын кулга алалар...

Кулга алыну Ф. Бурнаш өчен бөтенләй дә көтелмәгән нәрсә була дип әйтә алмыйбыз, ул аны көтеп яшәгән. Ни өчен дигәндә, аның баш очында болытлар инде күптән куерып килә. Репрессия машинасы иҗат әһелләре арасында иң соңгы корбаннардан берсе итеп нәкъ менә Фәтхи Бурнашны сайлаган булса да, инде 1937 елда эвәләнгән җинаять эшләре битләрендә үк аның фамилиясе очрый. Ул анда «советларга каршы киң колач җәеп хәрәкәт иткән милләтчел оешманың актив вәкиле» тесендә күрсәтелә. Аның белән бергә иҗат иткән язучылар, шагыйрь һәм драматурглар бер-бер артлы кулга алынып, хәбәрсез югалалар: Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин, Фатих Сәйфи-Казанлы, Кави Нәҗми, Мирсәй Әмир, Шамил Усманов...

Бу еллар Ф. Бурнаш өчен бигрәк тә авыр була. 20 елларның ахырларында ук башланган эзәрлекләү дәвам итә. Газета һәм журналларда бу елларда еш басыла торган сүгенү рухындагы мәкалә-чыгышларда Ф. Бурнашның әсәрләрендә төрле кимчелекләр күрсәтелә, аны милләтчелектә, буржуа идеологиясен әдәбиятка сөйрәп кертүдә гаепләргә тырышалар. «Таһир-Зөһрә» трагедиясе реакцион дип игълан ителә. Аны ни-

гезсез тәнкыйтьләгән бер мәкаләсенә Ф. Сәйфи-Казанлы хәтта «Сарайлар, ханнар, князьләр, мәчетләр шагыйре» («Яңалиф», 1929, 15 сан) дигән исем дә куя.

Мондый катлаулы шартларда Ф. Бурнаш өйдә дә күңел тынычлыгы таба алмый. Хатыны Фатыйма Ильская белән мөнәсәбәтләре көннән-көн начарлана бара. Сәхнәдә бөек актриса булган, татар театры тарихында күренекле эз калдырган бу хатын тормышта дорфа һәм тәкәббер, үз-үзен генә яратучы һәм вакчыл була. Нәтиҗәдә алар аерылышалар...

Тик шулай да «халык дошманнарына каршы кискен һәм оператив көрәшкән данлыклы НКВД» Ф. Бурнашны нишләп 1940 елның уртасына кадәр иректә калдыра соң әле? Моның, күрәсең, сәбәбе берничә булган һәм алар турында без гөман кыла гына алабыз.

Беренче фикер һәм, күрәсең, дөреслеккә иң якын фикер. Мәгълүм булганча, Ф. Бурнаш совет чорында тәнкыйть өлкәсендә гаять актив эшли, принципиаль, үз фикере булган тәнкыйтьче буларак таныла. Аның тәнкыйть уклары шактый күп кешегә, шул исәптән шиксез әдәби авторитет саналган язучыларга да эләгә. Мәсәлән, Тукай мирасын өйрәнүгә, аның иҗатын пропагандалауга күп көч сарыф иткән Ф. Бурнаш шушы уңайдан бөек Галимҗан Ибраһимов белән бәхәскә керүдән дә курыкмый. Революциягә кадәр язган «Татар шагыйрьләре» исемле китабында Г. Ибраһимовның халык шагыйренә биргән бәясе белән килешмичә, ул Г. Ибраһимовны кискен һәм каты тәнкыйтьли. «Г. Тукай хакында тәнкыйтьчеләр» («Безнең юл», 1923, 8—9 сан) исемле зур күләмле мәкаләсендә Г. Ибраһимовтан хата фикерләреннән баш тартуны, шул хакта әйтеп матбугатта чыгуын таләп итә.

Ә Кави Нәҗми, Гадел Кутуй кебек яшьләр белән матбугат битләрендә шактый озак барган бәхәс-полемика? Ул яңа әдәбият һәм сәнгать турында, аның үзенчәлекләре хакында, аны аңлау һәм аңлату турында. Әдәби иҗатның принципиаль мәсьәләләре турында бәхәсләшкәндә авторлар бер-берсе адресына каты-каты сүзләр дә әйтәләр.

Мондый мисалларны тагын да китерергә мөмкин. Алар асылда Ф. Бурнашның үз фикере һәм карашы булган, нык иманлы, авторитетлар алдында җебеп калмый торган кеше итеп характерлыйлар. Шунысын да әйтергә кирәк, мондый бәхәсләрдә Ф. Бурнашның тәнкыйте, нигездә, дөрес була. Гомумән, иҗади бәхәсләр ике якны да баета, дөрес юлны табарга булыша, татар әдәбиятын алга этәрә, яшь талантларны тәрбияли.

Утыз җиденче елны исә Г. Ибраһимов, Ф. Сәйфи-Казанлы, К. Нәҗми һәм башкалар халык дошманнары итеп игълан ителәләр, кулга алыналар... Күрәсең, Ф. Бурнашның бу язучыларга карата кайчандыр тәнкыйть белән чыкканлыгы билгеле бер рәвештә аның репрессияләрнең иң кызган вакытында иректә калуын озайткан.

Тагын да бер фараз. Монысын язучының бертуган энесе Вафа кызы, бүгенге көндә язучының шәхси архивын үзендә саклаучы Йолдыз Бурнашева әйтә. Абыйсының башкалардан шактый соңарып кулга алынуының сәбәбен ул бөек рус язучысы Максим Горький белән Фәтхи Бурнаш арасындагы мөнәсәбәтләрдә, дуслыкта күрә. Бу фаразның да кайбер нигезләре юк түгелдер. Бурнашның тырышлыгы белән нәкъ шул елларда «Ана» романы геройлары татарча сөйли башлыйлар. Бурнаш моннан тыш бөек пролетар язучының кайбер башка хикәяләрен дә татарчага тәрҗемә итеп бастыра. Шул уңайдан ул М. Горький белән тыгыз бәйләнештә тора, еш очраша.

## Нахак гаепләр

Фәтхи Бурнашның җинаять эшендәге документлар арасында бер сорау алу беркетмәсе аерылып, үзенә җәлеп итеп тора. Аны гаепләнүче үз кулы белән язган. Беркетмәнең башында: «Минем иҗади әсәрләремдә булган идеологик хаталар турында» дип куелган. Язучы үз иҗатында нинди хаталар тапкан соң? Шуларның берничәсен китерик.

«Бер поэмада мин малае сугышка киткән карт ана образын бирәм. Ул ана улының исән-сау кайтуын теләп дога кыла. Әлбәттә, әгәр дә ул ана дога белән түгел, ә башка ысул белән безне халык дошманнарына каршы сугышка чакырса, яхшырак булыр иде...»

Ачыклап үтик, бу поэма Бурнашның Октябрьга кадәрге поэмалары рухында язылган, 1919 елда, ягъни авторына 21 яшь вакытта басылып чыккан.

Яки әнә «Ике дус» сатирасында (1919 ел), «Адашкан кыз» пьесасында (1926 ел) автор ул вакытта зур хәрби постларда булган Троцкийның фамилиясен искә алган икән. «Миңлекәй белән Данбулат поэмасы»нда да (1933 ел) Татарстан республикасы җитәкчеләре Байчурин һәм Абрамов фамилияләре очрый. Әлбәттә, инде хәзер, ягъни Троцкий читләре Байчурин һәм Абрамов ... Байчурин белән Абрамов кулга алынгач, болар барысы да «политик» илгә качкач.

яктан уяулыкны югалту» дип бәяләнә.

Һичшиксез, бу беркетмәне тутыруда Ф. Бурнашка НКВД тикшерүчеләре нык кына «ярдәм» күрсәткәннәр булыр һәм үзеннән тартып-сузып гаеп табарга тырышуы өчен Бурнашка бер сүз дә әйтеп булмый. Тикшерү ахырына таба язучы сорауларга җавап бирүдән баш тарта башлый. Берсендә, сорау алырга чакырылгач, ул тикшерүчегә каты-каты сүзләр әйтә, сорауларга җавап бирми (ягъни, сорау алучы теләгән җавапларны бирми, дип аңларга кирәк!). Моның өчен аны ун көнгә карцерга утырталар...

Ә менә инде төп гаепләрнең берсе. 1929 елда «Чаян» журналының 10 санында «Шанлы дәүләт» дип исемләнгән шигырь басылып чыга. Без аны тулысынча китерәбез:

## Шанлы дәүләт

*(«Шәрекъ гөлләре» поэмасыннан кыйтга)*

Тузды Болгар иле, сынды ханлык,
Килде читләр Казан тәхтенә.
Тынды тыштан, әчтән янды халык
Тәкъдир биргән ачы бәхтенә.
И ходаем, безне читкә ташлама,
Бирмә көч ислам диненнән башкага.
Большевиклардан бушансын таш кала,
Бирмә көч ислам диненнән башкага.
Рус җирендә данлы Чыңгыз әүләде,
Урнашып ятырларны читкә кауладьı.
Большевиклар әйләнеп төште кире,
Селкетә бар җир йөзен Чыңгыз иле.
Һәрбере куркып Туранчадан тулды («шылды» булыр — *авторлар*)
Мал белән кәрван йөридер көн-төне.

Шактый ук мәгънәсез булган бу шигырьнең астына Фәтхи Бурнаш имзасы куелган була...

Тикшерү барышында һәм суд вакытында Ф. Бурнаш бу шигырьгә авторлыктан катгый рәвештә баш тарта, аның бары тик пародия яисә шарж буларак язылуын аңлатырга тырыша. Чыннан да, шигырь Бурнаш стиленә туры килә, аерым сүзләр куллану рәвеше анык. Ләкин, бердән, шигырь күрәләтә торып логикага сыймый торган эчтәлекле: монда ук ханлык чоры да, шунда ук большевиклар да... Бу кыйтга, ягъни поэманың өлеше, кисәге кемгә карый: моны кем әйтә? дусмы, дошманмы? революционермы, контрреволюционермы? Һәм, соңгысы, мондый эчтәлекле шигырь сатирик-шаян журналда басылыр идемени, моның өчен бит аның мәгънәсе туры килергә тиеш. Гомумән, 1919 елдан партия члены булган язучының мондый шигырьне үз исеменнән яза алмаслыгы мәнди анасына да билгеле. Бурнаш менә шуларны аңлатырга тырыша да инде, «шигырь — минем өстән пародия» дип әйтеп карый. Шигырь өчен гонорарны кем алганын белү юлы белән аның авторлыгын ачыклауларын үтенә, шул вакытта «Чаян»да эшләүче Гадел Кутуйны чакырып ачыклауларын сорый. Ләкин боларның берсе дә эшләнми, суд җиңел юл белән генә бара, гаепләнүченең аклануларын гаҗәеп «оригинальлек» белән юкка чыгара. Суд карарында болай дип нәтиҗә ясала: «Бурнаш, шигыренең контрреволюцион эчтәлегенә дәгъва белдермичә, үзенең авторлыгын гына бәхәсли һәм шигырьнең аңа карата шарж буларак урнаштырылганын аңлата. Ләкин Бурнашның бу шигырьгә бернинди реакция ясамавы аның шигырьдәге эчтәлек белән ризалашуын раслый». Вәссәлам!

Тикшерү барышында Ф. Бурнашның барлык әсәрләре дә суд экспертизасы аша уздырыла. Эксперт комиссиясенә Татарстан китап нәшрияты хезмәткәрләре Н. Терентьев, И. Гази, А. Камалетдинов керә. Соңрак, гаепләнүченең үтенече буенча, комиссиягә өстәмә рәвештә Хәсән Хәйрине һәм Т. Имаметдиновны да кертәләр. Комиссия: «Художество, тарихи һәм хәтта политик яктан байтак җитди кимчелекләре булуга карамастан, Ф. Бурнашның югарыда санап кителгән әсәрләрендә, «Шанлы дәүләт»не исәпкә алмаганда, Советка каршы тенденцияләр юк»,— дип таба.

Ул «житди хаталар»ның никадәр җитди булуын ачыклау, дөресрәге, бернинди хата юклыгын раслау күп урын алыр иде. Шулай да, аларның характерын күрсәтү өчен, берсенә тукталып китәбез. Ф. Бурнаш аны әле бүген дә сәхнәдән төшми уйнала торган «Яшь йөрәкләр» пьесасында «җибәрә». Әлеге пьеса буенча комиссиянең бәяләмәсе мондый:

«...пьесаның менә шушы моменты уйланырга мәҗбүр итә — пьеса герое Сәрби кинаяле рәвештә пьеса герое Хәйретдиннән нинди дә булса бүләк алырга бик тә теләвен белдерә.

«Х ә й р е т д и н. ...Нәрсә китерим соң, җаным?
С ә р б и. Нәрсә булса да...
Х ә й р е т д и н. Нәрсә? Күлмәкме, яулык, шәл?..
С ә р б и. Нигә алар булсын...
Х ә й р е т д и н. Ә нәрсә соң?
С ә р б и. Нәрсә булсын, вак-төяк!.. Нигә андый зур нәрсәләр?..
Х ә й р е т д и н. Ә нәрсә соң, нәрсә?
С ә р б и. Беләсең инде... вак-төяк... прәннек, йөзем, җимеш...
Х ә й р е т д и н. Тагын?
С ә р б и. Тагын нәрсә булсын — теләсәң, конфет, чикләвек...
Х ә й р е т д и н (шатланып). Шулар гынамы? (итәген тотып). Бүген кич үк бер итәк төяп китерәм. Беләсеңме, бер итәк...»

Хәйретдиннең ярлы булуын исәпкә алганда, болар бөтенләй үк вак-төяк түгел. Биредә авыл яшьләренең: революциягә кадәр ярлыларга да бер итәк «вак-төяк» табу бернигә дә тормаган, дип уйлавы мөмкин. Һәм пьесада бу сюжет ахырынача җиткерелә — Хәйретдин чынлап та китерә бу әйберләрне...

Күрәсез, монда аңлатма кирәкми.

Сүз җаеннан шунысын да әйтик. Комиссия Ф. Бурнаш әсәрләрендәге «җитешсезлекләр»не, нигездә, шул вакытларда хөкем сөргән вульгар социологизм ноктасыннан торып тапкан булса да, асылда язучыны аклый торган нәтиҗә чыгарган. Комиссия членнарыннан берсе — Т. Имаметдинов судта да шул фикерне яклый. Фәтхи Бурнаш әсәрләрендә бернинди дә контрреволюцион нәрсәләр тапмадым, ди ул. Һәм тагын: матбугатта Ф. Бурнашка каршы чыккан тәнкыйтьчеләр аның иҗатына объектив карамадылар, дип әйтергә дә батырчылык итә.

Ф. Бурнашны гаепләү пунктларыннан тагын да берсе аның 1924 елда ук «39 кеше белдерүе» дип аталган чыгышка кул кую факты була. Тикшерү һәм суд органнары тарафыннан бу белдерү «уң буржуаз милләтчеләрнең ВКП(б) һәм Совет власте милли политикасына каршы юнәлдерелгән платформасы» дип бәяләнә.

Җинаять эше материалларында теркәлгән бу белдерү текстларгы кайбер урыннары ассызыклап һәм аерып күрсәтүләр белән, текстының кырыйлары өндәү, сорау һәм башка билгеләр белән чуарланып беткән. Өндәү билгеләренең берсе белдерүне төзүчеләрнең түбәндәге сүзләре янына куелган: «Иптәш Зиновьев Татарстан республикасында партия дискуссиясе өчен кыенлыклар булуын, чөнки башка моментлар белән бергә, биредә бәхәс нәкъ менә милли момент белән бик көчле дәрәҗәдә кискенләштерелгән булуын шактый гадел күрсәткән...» Өндәү билгесе һәм Зиновьев фамилиясен ассызыклап күрсәтүнең максаты ачык: бу вакытта инде ул гаепләнгән һәм атып үтерелгән.

Партия Үзәк Комитеты Политбюросына — Сталин аша Бухаринга, Молотовка, Рыковка, Рудзутак һәм Куйбышевка адресланган «39 кеше белдерүе»нең эчтәлегенә җентекләп тукталып тормыйбыз. Шунысын гына әйтергә кирәк, республикадагы хәлне анализлау нигезендә җаваплы хезмәткәрләр Үзәк Комитетның игътибарын Татарстанда милли мәсьәләне практик хәл итү буенча чаралар күрү кирәклегенә юнәлтәләр. Белдерүгә Татарстан Халык Комиссарлары Советы председателе Мохтаров, Үзәк Башкарма Комитеты председателе Сабиров, халык комиссарлары, республика прокуроры Бахаветдинов, аның урынбасары Мәхмүт Бәдәйли һ. б. кул куйган. Унынчы булып «Ф. Бурнашев — әдип-шагыйрь, Всеработпрос каршындагы эшчеләр матбугаты үзәк комитеты членлыгына кандидат» дигән имза тора. Тагын да бер фамилия: «М. Борындыков — Мәгариф халык комиссары». Бу исемлектәге фамилияләрнең күпчелеге янында карандаш белән «ос» (осужден — ителгән) дигән билге куелган.

Белдерүгә кул кую факты 1929—1930 елларда Татарстан республикасында партия сафларын чистарту вакытында, күпләргә карата гаепләү булып әверелгән кебек үк, Ф. Бурнашка карата да гаепләү төсен ала. Ул чакта аңар түбәндәге планнар тагыла:
а) әдәби хезмәт белән шөгыльләнеп, Фәтхи Бурнаш үз әсәрләре пролетариатка бөтенләй ят һәм дошман идеологияне, милли буржуазия һәм солтангалиевчелек идеологиясенә туры килә торган идеологияне чагылдырган (ханнарны, кинязьләрне, сарай һәм мәчетләрне мактап җырлаган);
б) уң группировкада торган солтангалиевчелек оешмасын ахыргача актив яклаган, солтангалиевчелеккә материаль ярдәм күрсәткән;
в) тикшерү вакытында үз аңлатмаларында эчкерсезлек күрсәтмәде.

Карар бирелә — ВКП(б) сафларыннан чыгарырга.

Лэкин Ф. Бурнаш карар белән килешми, тагын да югарыга ВКП(б)ның Үзәк Контроль Комиссиясенә апелляция бирә. 1930 елның 12 ноябрендә Петерс, Мильчаков, Муранов составындагы партия «өчлеге», кисәтү белән каты шелтә бирдереп, Ф. Бурнашны партия сафларына кире кайтара.

Күренә ки, мәсьәлә инде ул вакытта ук тәмам хәл ителгән кебек булса да, ун елдан соң аңар яңадан әйләнеп кайталар, бу юлы инде җинаять җаваплылыгына тарталар. Әйе, мәгънәсезлек, элементар логикага каршы эш бу. Әмма Ф. Бурнаш эшендә (хәер, ул чордагы башкалар эшендә дә) андый мәгънәсезлекләр һәм каршылыклар тулып ята.

Шулай итеп, озак вакытлар буена — тормыш юлы дәвамында тупланып килгән таркау, күпчелеге вак-төяк булган фактларга нигезләнгән, теге яки бу «халык дошманы» белән вакытлы һәм очраклы очрашуларга, бәйләнешләргә таянып әвәләнгән эш була ул — Ф. Бурнашны гаепләү. Ул фактларның берсе җинаять булып тормый, тора да алмый. Әмма алар өчен бөтен катгыйлыгы белән түләтәләр: «ун елга лагерьга җибәрергә». Мондый карар, никадәр генә үкенечле һәм нахак булмасын, Ф. Бурнашка әле өмет бирә... Хәзер аңа 42 яшь, ун елдан ирек килсә, әле ул иҗат дөньясына әйләнеп кайта ала...

Лэкин язмыш аңа икенче төрле юл әзерләгән икән...

## Вакытсыз киселгән гомер

1941 елның мартында язучы Куйбышев шәһәр янындагы «Безымянлаг» (Безымянный лагерь — исемсез лагерь) дип аталган лагерьга җибәрелә. Аңа бу исемне биргәндә, әйтерсең лә лагерьның тоткыннары да мәңгелеккә билгесез булып калырлар дип уйлап куелган...

Үзенә билгеләнгән ун еллык срогын тутыру Бурнашка насыйп булмый. Ул монда икенче мәртәбә хөкем ителә.

Икенче эшнең сорау алу беркетмәләре сакланган һәм алар язучыларның төрмәдәге тормышы, язмышы турындагы бердәнбер материаллар. Әлеге беркетмәләр лагерьда аның якташлары Солтан Галимов һәм Харис Сабиров белән якын мөнәсәбәттә булганлыгы турында сөйлиләр. Бер ел буе ул туганнары белән хат язышып, элемтәдә тора. Сорау алу вакытында язучы хатлар алышып торган кыз туганнары Бакиева һәм Фәсхетдинова исемнәрен атый, энесе Вафадан хат алуын, ерак туганы Мөнәвәрә Бурнашевадан еш кына хәбәрләр килеп торуын әйтә. Ф. Бурнаш үзе хат алышкан тагын бер хатын-кыз исемен атый, бу — Куйбышев шәһәрендә яшәүче Татьяна Александровна Матвеева. Бәлкем ул бүген дә исән-саудыр, бәлкем ул Бурнашның язмышына нәрсә дә булса ачыклык кертә алыр... Соңгы көннәре турында...

Бөек Ватан сугышы башлангач, Ф. Бурнашның эзләре югала. Ун ел да, артыгракы да уза, ләкин ул кире әйләнеп кайтмый. Бары тик 1956 елда гына, реабилитация турында туганнары гариза биргәч, аларга шундый рәсми җавап килә: «Ф. Бурнаш 1942 елны кабат хөкемгә тартылды һәм 10 елга ирегеннән мәхрүм ителде. Ул 1946 елның 1 августында үпкә авыруыннан үлде».

Туганнары бу җавапка ышаналар, аларның ышанмаска хаклары булмый. Һәм Бурнаш турындагы китапларга, башка төрле хезмәтләргә шушы дата кереп китә.

Лэкин әле күптән түгел генә моның ялган икәне ачыкланды. Дөресендә, Фәтхи Бурнашның гомере нәкъ дүрт ел алданрак, 1942 елның 1 августында өзелгән. Һәм ул үз үлеме белән, авырып үлмәгән, ә бәлки «сугыш вакытында советларга каршы агитация һәм пропаганда алып барганы өчен» атылган...

Бу соңгы җинаять эшендә, әйткәнебезчә, документлар аз, алар мәгълүматларга бик тә ярлы. Сорау алуның кыска-кыска, бик тә таркау беркетмәләре, шул ук гаепләүләр... Шулай да алар буенча Бурнашның соңгы айлары турында кайбер әйберләрне ачыкларга, ә кайберләрен чамалап белергә мөмкин.

Лагерьда Ф. Бурнаш Ильенков фамилияле бер тоткын белән якынаеп китә. Бу кеше Кызыл Армиядә озак вакытлар хезмәт иткән, ВКП(б) члены булган, 1940 елда контрреволюцион эшчәнлеге өчен 8 елга ирегеннән мәхрүм ителә. Бу ике кешене үзара нәрсә якынайткан — хәзер әйтүе читен. Алар бергә ашыйлар, бергәләп йоклыйлар, төрле темаларга гәп коралар. Ачыктан-ачык, әчкерсез сөйләшүләр дә аз булмый. Политик характердагы мәсьәләләрне тикшергәндә шулай ук Ватан сугышы фронтларындагы хәлләр турында сөйләшкәндә Ф. Бурнаш үзенең кайбер кыю, саксызрак ычкындырган сүзләрен Ильенковның хәтеренә сеңдереп калдырачагы һәм җае чыкканда «кирәкле төшкә» хәбәр итәчәге турында башына да китермәгән, әлбәттә.

Тиздән Ильенковны хезмәттә «күтәрәләр», төзү эшләре десятнигы итеп куялар.

Ф. Бурнаш фикеренчә, бу Ильенковка файдага булмый: дус кинәт дошманга әйләнә, алар арасындагы мөнәсәбәтләр бозыла һәм бераздан бөтенләй дә өзелә.

1942 елның 12 гыйнварында Ф. Бурнаш белән икенче бер тоткын — Свиридов арасында җәнҗал туа. Сакланган документларда бу бәрелеш турында каршылыклы мәгълүматлар китерелә. Кем хаклы, кем гаепле? Ләкин шунысы хак: эш вак-төяктән оеша, пүчтәктән генә киләкмәгән зур нәтиҗә чыгарыла... Ф. Бурнашның саксызлыгы аркасында котелоктан Свиридовның ашы түгелә. Шунда алар бер-берсенә ябышалар. Башка тоткыннар арага керә, Ильенков та килеп катыша. Шушы гадәти җәнҗалның нәтиҗәсе Ф. Бурнаш өчен бик үкенечле булып бетә.

Шул ук көнне Ф. Бурнаш отряд начальнигы урынбасарына Ильенковның һәм Свиридовның үзен кыйнаулары турында, бу эшне тикшерү хакында гариза язып бирә: аларны җавапка тартуны сорый.

Ни өчендер бу гаризаны җуйганнар, җинаять эшендә ул юк. Ф. Бурнашның үтенече буенча, аның хәтере нигезендә яңартылган гаризаның текстын тикшерү документларының азагына гына теркәп куялар.

Шулай итеп, Бурнашның гаризасы югалган. Аның каравы, икенче гариза барлыкка килә — монысын инде тоткын Ильенков язган. Язган вакыты — 1941 елның 24 сентябре. Әйтеп үтик, җинаять эше шушы гариза буенча 1942 елның 16 гыйнварында, ягъни Ильенков гариза биргәннән соң 4 ай узгач кузгатыла.

Документлар бик саран шул, монда сорау артыннан сорау туа. Ильенковның гаризасы кайчан язылган — чыннан да 1941 елның сентябрендәме, әллә 1942 елның гыйнварындамы? Әгәр дә ул 1941 елда язылган булса, ул кайда яткан, ни өчен аны үз вакытында ук тикшермәгәннәр? Гаризаның кайчан керүе турында бернинди билге юк. Шунысы да шик уята: җинаять эшенең иң соңгы битләренә генә теркәп куелган ул. Ф. Бурнашның тән җәрәхәте алуы турында да бернинди медицина документы юк.

Ф. Бурнаш гаризасы җавапсыз калдырыла, аның белән беркем дә шөгыльләнми. Аның каравы Ильенков гаризасына юл ачыла. Тикшерү тиз бара. Сорау алулар, йөзгә-йөз очраштырулар көн саен диярлек оештырыла. 12 көннән тикшерү тәгәлләнә. Гаепләү түбәндәгечә рәсмиләштерелгән: «Ф. Бурнашев, контрреволюцион эшчәнлек өчен хөкем ителгән һәм лагерьда җәза срогын үтеп яткан халдә, тоткыннар арасында үзенең буржуаз-милләтчелек карашларын үткәрде, патша заманнарындагы тормышны мактады, эшчеләр һәм колхозчылар тормышы турында ялган таратты, СССРга карата дөрес булмаган фикерләр әйтте, провокацион имеш-мимешләр таратты һәм совет матбугатына яла якты».






Үзенә сылтанган «советка каршы фикерләр»не әйткәндерме, юкмыдыр, хәзер моны белеп булмый. Хәер, моның әллә ни әһәмияте дә юк. Чөнки бүгенге көн югарылыгыннан торып, плюрализм ноктасыннан торып караганда алар барыбер кешенең җаныкыерлык дәрәҗәдә була алмас иде. Бер генә мисал китерик. Тоткын Верховский дәлилләрен алыйк. Ул, имеш, Бурнаш «халыклар юлбашчысы» исеменә Чехословакия премьер-министры җибәргән, Гитлерга каршы берләшеп көрәшергә әзер торуын белдергән телеграмма Америкадан сугылган, дип раслады, ди. Ф. Бурнаш үзе моны судта гади генә итеп аңлата: «Чехословакия күптән инде немецлар кул астында булганлыктан, мин андый телеграмманың булуына шик белдердем һәм аның бары тик башка илдән генә җибәрелә алуын әйттем». Шундый ук логик әлеклелек белән ул башка гаепләүләрне дә кире кага.

Карар алдан ул билгеләп куелган була инде. Гаепләү нәтиҗәсен раслаган кешеләр аны түбәндәгечә формалаштырып куялар: «Гаепләнүче Бурнашевка карата иң югары җәза чарасы — ату куллануны тиеш табабыз».

Судны көтеп Ф. Бурнаш ярты елдан артык камерада интегә. Үзенә үлем карары

чыгарылачагын ул, һичшиксез, сизгән. 1942 елның 15 июлендә — Фәтхелислам Закирович Бурнашевны атарга» дигән хөкем карары чыгарыла һәм, әйткәнебезчә, ул 1 август көнне үтәлә...

Ике җинаять эшендә дә Ф. Бурнашның фотолары теркәлгән. Аның беренчесе язучы кулга алынгач ук төшерелгән. Икенче фото, күрәсең, җәза алдыннан төшерелгән. Алар җир белән күк сыман бер-берсеннән аерылып торалар. 1940 елгы рәсемдә Ф. Бурнаш чигелгән чәчкәле ак күлмәктән, аны бик тиз танып була. Бөтен мәһабәт гәүдәсендә, йөз сызыкларында ниндидер сәер тынычлык: әйтерсең лә ул үзенә ташланган мәгънәсез гаепләрнең тиздән кире кагылачагына ышана. Ә 1942 елда төшерелгән фотода язучыны тануы бик авыр. Каткан телогрейкадагы, баш киемсез, битен сакалмыек баскан бу кеше — кайчандыр танылган драматург һәм шагыйрь Фәтхи Бурнашмы соң?! Ләкин бу чынлап та ул: кайчандыр чибәр булган кеше бөтенләй беткән, йончыган, шешенгән күзләрдә тормыш нуры сүнеп килә, бөтен кыяфәтендә ниндидер битарафлык... Болар — физик һәм мораль яктан кыйналулар нәтиҗәсе.

Хәзер Фәтхи Бурнашның соңгы елларын каплап торган кара пәрдә алып ташланды. Ләкин сораулар тагын да кала әле. Бурнаш кебек кеше лагерьда да, төрмәдә дә язмыйча кала алмас. Һич югында, аның кыска-кыска шигырьләре булырга тиеш. Кайда алар?

Бүген шунысы ачык: Ф. Бурнаш беркайчан да ханнар, сарайлар шагыйре булмады, ул бөтен иҗатын аларга түгел, ә туган халкына багышлады. Халкыннан күпме генә аерырга тырышсалар да, ул аңа кире әйләнеп кайтты. Бүген кат-кат басыла торган әсәрләре, күп томлы китаплары булып, сәхнәләрдә уйнала торган пьесалары булып, дәреслекләргә кергән шигырьләре булып әйләнеп кайтты ул...

Флүр БАҺАВЕТДИНОВ,
Татарстан Прокуратурасының аеруча мөһим эшләрне тикшерүчесе,

Азат ӘХМӘДУЛЛИН,
Казан университеты профессоры.

# САК БЕЛӘН СОК КАЙЛАРДАН КИЛӘ?

Халык иҗатында киң таралган «Сак-Сок» әсәрен, гадәттә, XVII-XVIII йөзләрдә иҗат ителгән бәет дип аңлаталар. Шул ук вакытта аны Болгар чорының иҗаты дип карау да бар. Аерым алганда, археолог А. Халиков «Сак-Сокны» борынгы «саксин» — «саклаб» кабиләләре белән бәйли һәм бәеттә, бер-береннән VIII йөздә аерылган шул кабиләләрнең туганлыгы чагылмады микән, дип исәпли.[1]

Без әлбәттә «Сак-Сок»ны Болгар кабиләләренең реаль тормышы һәм шуларның исеменә хас булган «сак» тамыры белән генә бәйләүдән ерак торабыз (игътибар итегез: «саксин», «саклаб»). Чөнки тарих барышында болгарларның бер-береннән аерылган кабиләләре бу кабиләләр белән генә чикләнми. Җитмәсә, угыз-кыпчак ыруглары берләшмәсе булган саксиннар һәм төрки-фин катнашмасыннан торган саклаблар монгол һөҗүме вакытында яңадан бергә кушылганнар. Һәм, икенчедән, баллада характерындагы әлеге бәетнең драматик эчтәлегендә дә болгарлар тормышындагы тарихи вакыйгалар, ягъни конкрет тарихилык белән бәйләнеш булуына берниндн дә ишарә юк.

Әмма әсәрнең мифологик сюжеты һәм образлары, чыннан да, бик борынгы булырга охшый. Алар гасырлар тирәнлегеннән килгән магия-ырым һәм мифологик фикерләү белән сугарылган. Иң характерлысы — аларда сүз-каргышның гадәттән тыш кодрәткә ия булуына ышану һәм хәтта балаларның бөтенләй башка затка — кошларга әверелүенә булган хәл дип карау ярылып ята. Димәк, «Сак-Сок» әсәренең нигезенә салынган ышануларга һич тә, дөньяви әсәрләрдәге кебек, сәнгатьчә шартлылык, ягъни аңлы рәвештә художество чарасы итеп кенә файдалану хас түгел, ә бәлки табигыйлек, мифлардагыча чын инанганлык хас. Болар бар да безне, теләсәк-теләмәсәк тә, бабаларыбызның әле мифларга чын күңелдән ышанган кадими дәверләренә, халкыбыз һәм, гомумән, борынгы төркиләрнең балалык чорына алып китә.

Тарихи чыганаклар әйтүенчә, Үзәк Азиядә һәм Алтайда яшәгән борынгы төркиләр, кеше үлгәч, аның җаны кош булып очып китә, дип ышанганнар. Шул ук вакытта кешенең җаны күбәләккә әверелә, йә булмаса күктән йолдыз булып атыла, дип ышанулар да булган. Моннан тыш, археологлар тарафыннан Болгар дәүләте биләмәсендә түшләренә кеше йөзе ясалган һәм канатларын як-якка җәеп торган бер яки икешәр башлы бронза кош сыннары табылганлыгы да мәгълүм.[2] Бу архаик мәгълүматлардан, әлбәттә, ерак заманнарда яшәгән бабаларыбызның кеше җанының төрле нәрсәгә, шул исәптән кошка да әверелүенә ышанганнарын абайлау кыен түгел.

Ләкин үлгән кеше җанының төрле әверелешкә дучар булуына ышану бер нәрсә, ә исән чакта ук адәм баласының бүтән затка әйләнә алуына ышану бөтенләй башка нәрсә бит. Боларның икенчесе асылда мифология үсешенең тагын да ераграк чордагы баскычына, ыруглык дәверенә үк барып тоташа. Борынгыларның рухи мирасында шундый ышануларның эзләрен саклаган мәгълүматлар да юкмы соң?

Менә монда инде без гомумшәрык культурасы орбитасына чыгабыз, ерак бабаларыбыз булган сөнни-һуннарны һәм борынгы төркиләрне дә азыкландырган рухи ядкарьләр дөньясына юл салабыз. (Шәрык төшенчәсен без, әлбәттә, бу очракта киң мәгънәдә кулланабыз һәм аның эченә, һичшиксез, Греция дәүләтен үз эченә алучы Якын Көнчыгышны да кертәбез.)

Сак-Сок кебек образлар тууына китергән культура мирасының иң борынгы катламы, безнең карашыбызча, аеруча калку, булып һинд-европа халыклары мифологиясендә сакланып калган. Без бу очракта, барыннан да элек, символик характердагы борынгы парлы төркемләү ысулын, ягъни капма-каршы ике башлангычка нигезләп классификацияләү системасын күздә тотабыз. Бу система ыруглык җәмгыятендә бөтен җанлы һәм җансыз нәрсәләрне ир-ат һәм хатын-кыз әйберләренә аерып караудан үсеп чыккан

---

[1] Халиков А. Х. Татар халкының килеп чыгышы. Казан, 1974, 28,34 б6.

[2] Теплоухов Ф. А. Древности в виде баснословных людей и животных. Пермский край, т. II, Пермь, 1893, 18 б.

(аның эзләре, мәсәлән, аерым телләрдәге «род»ларда сакланган), шулай ук ул борынгы кабиләләрнең бер-берсенә кызларын кияүгә бирүче ике ыругка (фратрияга) аерып йөртелүеннән һәм тирә-яктагы әйберләрнең дә шуларга нисбәтләп төркемләнә башлавыннан хасыйл булган.[3] Соңрак инде шушы ук система нигезендә кайсыдыр сыйфатлары белән бер-берсенә капма-каршы торучы игезәкләр культы формалашкан һәм үзара бәхәсләшүче-көрәшүче, диалекталь каршылыкларны гәүдәләндерүче төрле дуалистик парлар — мифик антиподлар барлыкка килгән.[4] Мәҗүси аллалар, ыруг-фратрия башлыклары, агалы-энеле туганнар — әнә шундый образлардан.

Мисалларны төрле халыклардан китерергә мөмкин. Борынгы һинд мифологиясендә, мәсәлән, Митра белән Варуна, ираннарда Ахурамазда белән Ангро-Майнью, төркиләрдә Үлген (Ульгень) белән Ирлек (Эрлик) исемле яхшылык-изгелек һәм начарлык-явызлыкны гәүдәләндерүче һәм һәрвакыт үзара көрәшүче игезәк аллалар булган. Аларның уңайлары яктылык — көн хуҗасы итеп, киреләре исә караңгылык — төн яки җир асты патшалыгының хуҗасы итеп фараз ителгән. Шулай ук мифларда аерым халыкның яки нәселнең нигез салучылары итеп тасвирланган яисә ике башлангычны гәүдәләндерүче үлемсез игезәкләр дә юк түгел. Итальяннардагы, дөресрәге этруслардагы Ромул белән Рем, һиндлардагы Яма белән Ями, германнардагы Балдур белән Гедур, төрки халыклардагы Хозыр белән Ильяс моңа характерлы мисал була ала (Сүз Хозыр-Ильясның борынгы көнчыгыш варианты турында бара).

Тагын шунсы характерлы: үзара капма-каршы парлар һәм игезәкләр кеше кыяфәтендә генә түгел, ә төрле нәрсәләр — хайван һәм кош-корт кыяфәтендә дә күз алдына китерелгән. Алар йә баштан ук шундый кыяфәттә булганнар һәм соңыннан гына кешегә әйләнгәннәр, йә булмаса, киресенчә, кешедән бүтән нәрсәгә әверелгәннәр.

Димәк, дуалистик парларда һәм игезәк образларында борынгы парлы төркемләү ысулы белән мифик әверелүчәнлек сыйфаты бергә килеп кушылган һәм үзара үрелгән. Аннары шунысы кызыклы: борынгырак чорга киткән саен, әверелүнең объекты да күбәя һәм төрләнә бара, ягъни бер үк пар бер-беренә охшамаган бернилә кыяфәттә гәүдәләндерелә. Бу инде күп катлы әверелүләр борынгылар тарафыннан табигый хәл итеп, ягъни мифик парларның табигый яшәү формасы итеп кабул ителгән дигән сүз. Һиндстанда игезәк Ашвиннар, мәсәлән, борынгы чорларда ике ят яки кошлар кыяфәтендә дә, шулай ук иртән һәм кич калка торган йолдызлар итеп тә күз алдына китерелгәннәр. Грециядә исә Диоскурлар ак атлар, йә булмаса парлы йолдыз («Игезәкләр») рәвешендә дә, яисә аккошлар яки кыр казлары сыйфатында да фараз ителгәннәр. Моннан тыш, шушы ук геройлар соңрак, һичшиксез, кеше итеп тә, әйтик, ат яки кош уллары итеп тә тасвирланган һәм изгеләштерелгән.

Мифология үсешенең соңрак баскычында исә, табигый инде, әверелү логикасына, дөресрәге — бер үк объектларның күп төрле нәрсәләргә әйләнә алуына һәм моның табигый хәл итеп каралуына ышаныч кимегән. Дуалистик парларның һәм игезәкләрнең кыяфәте дә, кагыйдә буларак, бары бер үзгәрешкә генә дучар була башлаган. Яңадан инде алар, димәк, башка нәрсәгә дә, шулай ук кире үз хәлләренә дә әверелә алмаганнар. Бу гына да түгел, мондый бер катлы әверелү формасы акрынлап нинди дә булса драматик ситуациянең, фаҗигале конфликтның зарури нәтиҗәсе, ягъни үзенчәлекле һәм гадәттән тыш хәл ителүе рәвешен дә алган. Башкача әйткәндә, ул инде геройларның язмышында үзләре көтмәгәндә килгән җәза яки зур бәла-каза итеп карала башлаган. Шул рәвешле, әверелүгә, кыяфәт үзгәртү логикасына корылган мифлар эволюциясендә яңа форма һәм яңа эчтәлек барлыкка килгән.

Менә Шәрык халыклары мифологиясеннән конкрет мисаллар. Борынгы һинд эпосы «Махабхарата»дагы бер мифологик легендада мирас бүлешкәндә бәхәскә кергән игезәк туган тасвирлана. Бәхәсләренең очына чыга алмыйча, болар каргашуга кадәр барып җитәләр һәм, нәтиҗәдә, берсе — филгә, икенчесе ташбакага әйләнә.[5] «Тутыйнамә»нең һинд версиясендәге мифологик хикәяттә исә ир белән хатын, Будда алласыннан көлгәннәре өчен, кошларга әвереләләр.

Көтелмәгәндә башка кыяфәткә керүнең җәза һәм бәла рәвешендә килүе акрынлап фаҗигале һәм гыйбрәтле язмышлы ялгыз геройлар даирәсен үз эченә алган. Мәсәлән, иран һәм төрки мифологиясендә Сириус йолдызы азгынлыгы аркасында күккә ашкан хатынның үзгәргән кыяфәте итеп аңлатыла. Алтайларда һәм телеутларда төннәрен тау елгасы буйларында «юзаак-юзаак» дип кычкырып очып йөри торган кош «Өксез-ул» дип атала, ягъни ятим калган бала язмышы белән бәйләп карала.[6] Шул ук алтайларның мифологиясендә күрсенгән-уфылдаган тавыш чыгарып кычкыручы икенче бер кош исә кайчандыр бай кызы булган дип фараз ителә һәм, туе вакытында этисенең са-

[3] Золотарев А. М. Родовой строй и первобытная мифология. М., 1964.
[4] Штернберг Л. Я. Античный культ близнецов при свете этнографии /Сборн. музея антропологии и этнографии, т. III, Пг., 1916, 133-184 бб.
[5] Штенберг Л. Я. Первобытная религия в свете этнография.— Л., 1936, 133 б.
[6] Потанин Г. Н. Очерки северо-западной Монголии. Вып. IV, Спб., 1883, 183 б.

ранлыгына түзә алмыйча, гарьләнеп суга ташланган да шундый кыяфәткә кергән дип исәпләнелә.[7]

Димәк, ниндидер гаепләре, килеп туган каршылыктан чыга алмаулары аркасында икенче кыяфәткә кергән мифик геройлар мәңгелек фаҗигага, газап чигүгә дучар ителгәннәр. Чөнки алар инде башка төрле объектларга да, яңадан кешегә дә әверелә алмаганнар. Иң мөһиме — аларның кыяфәте инде, борынгы чор мифологиясендәге кебек, аллалар яки изгеләштерелгән игезәкләр өчен хас булган табигый яшәү формасы итеп тә карала алмаган. Шуңа күрә дә мондый мифларда нәкъ менә гадәттән тыш-лык һәм котылгысыз трагизм беренче планга чыккан. Икенче төрле әйткәндә, борын-гыларның, халыкның аңында элекке мифологик ышанулар яңабаштан каралган һәм яңа мәгънә, яңа бәя алган.

Мифологиядә, халык иҗатында табылган бу яңа форма соңыннан хәтта борын-гы язма әдәбиятка үтеп кергән һәм аерым әдипләр иҗатында махсус вә аңлы рәвештә трагизм тудыру чарасы итеп файдаланылган. Борынгы грек шагыйре Овидийның эвере-лү алымына һәм үз чорындагы мифологик ышануларга, легендаларга нигезләнеп ме-таморфоза жанры иҗат итүе моңа ачык мисал була ала (метаморфоза — грек сүзе, эвере-лү мәгънәсендә). Бер метаморфозасында, мәсәлән, шагыйрь Исак исемле Троя героеның фаҗигасен тасвирлый. Урманда йөргәндә бу егет Геспeрия исемле нимфага — алиһәгә гашыйк була һәм, тотмакчы булып, тегене куа башлый. Алиһә кыз, куркып йөгергәндә, аягын ялгыш еланга чактыра һәм шунда ук егылып үлә. Тетрәнеп, шашып калган егет, гаебен үлеме бәрабәренә булса да йолмакчы булып, текә ярдан диңгезгә ташлана.[8] Ләкин Су алласы моны шулчак кошка әверелдерә һәм мәңге ялгызлыкка, үкенеп-каңгы-рап яшәргә дучар итә. Скила, Алкиона исемле геройларын да Овидий драматик ситуа-цияләрдә кошларга әйләндерә.

Инде яңадан фольклор мифологиясенә әйләнеп кайтыйк. Һәм бу юлы «Сак-Сок» сюжетына һәм образларына аеруча якын торган мифик ышануларга мөрәҗәгать итик. Безнең эзләнүләргә караганда, шундый ядкарьләрнең берсе борынгы кытай мифоло-гиясендә сакланып калган. Анда ярымалла, ярымкеше итеп күз алдына китерелү-че Ди-ку исемле император һәм аның ике улы Яньбо белән Шичәнь турында сүз бара.[9] Бу малайлар көннәр буе бертуктаусыз сугышалар, «мине кыйнамасаң, мин сине үтерәм» дия-дия, бер-берсен тукмыйлар. Әтиләре исә нишләргә дә белми. Ахыр чиктә ата кеше бер-берсен газаплаучы балаларыннан котылырга була: Шичәньны Шәнь йолдызына, Яньбоны исә Шан йолдызына идарәчеләр итеп озата. Шул рәвешле, ике туган бер-берен-нән аерылырга мәҗбүр ителә һәм моннан соң инде беркайчан да үзара күрешмиләр. Чөн-ки алар идарә итә торган йолдызлар да мәңге очрашмый: бер йолдыз көнчыгышта ка-лыккан чакта икенчесе көнбатышта батып өлгерә. Менә шуңа күрә дә Кытайда бер-берсе белән тату тормаган туганнарны яки озак күрешмичә яшәүчеләрне, әлеге йолдыз-ларга тиңләп, «Шәнь-Шан» дип йөртәләр.

Яки менә турыдан-туры парлы кош образлары белән бәйләнешле һинд мифы. Анда ир белән хатынга, егет белән кызга тиңләштереп йөртелә торган Чаква-Чакви кошлары фаҗигасе турында сүз бара.[10] Берсе ана, икенчесе ата булган бу кошлар караңгы төшкәч бер-берсеннән аерылалар һәм, төн буена өзгәләнеп кычкыра-кычкыра, бер-берен эз-ләп чыгалар. Сак белән Сокның күзләренә кояш яктысында кан сауса, Чаква белән Чак-ви ай яктысында күрмәс булалар. Бу миф киң билгеле булганлыктан, һинд поэзиясендә бер-берен күрмичә сагынып-сагышланып яшәгән парларның еш кына Чаква-Чаквига тиңләштерүләре бер дә гаҗәп түгел.

Сак-Сок белән гаҗәеп дәрәҗәдә охшаш-авазадаш булган мисалларны без шулай ук төрки халыкларының үз мифологиясендә дә очраттык. Алтайларның бер мифында, мә-сәлән, бер-берене өйләнергә җыенган егет белән кызның фаҗигале язмышы сурәтләнә.[11] Зур елга аша чыкканда болар баталар һәм дулкын егетне бер ярга кызны исә икенче яр-га чыгарып ташлый. Болар төн буена, бер-берен өзгәләнеп чакыра-чакыра, икесе-ике якта йөриләр, ә таң аткач, кошларга әвереләләр. Икенче миф Кырым татарларыны-кы[12] һәм анда да геройлар — егет белән кыз, димәк, игезәкләр кебек үк, парлы образлар. Алар өйләнешергә сүз куешкан булалар. Ләкин кызның әтисе яшьләрнең никахлашуына кискен каршы төшә һәм аларны көчләп бер-берсеннән аера. Шуннан соң инде егет белән кыз, «исак-исак» дип үрсәләнеп кычкыра-кычкыра, һәр төнне бер-берсен эзләп үткәрүче кошларга әвереләләр. Төннәрен «исак-исак» дип моңлы

---

[7] Шунда ук, 184 б.
[8] Овидий. Метаморфозы.— М., 1977, 286 б.
[9] Юань Кэ. Мифы древнего Китая.— М., 1987, 122-123 бб.
[10] Баранников А. П. Образность в индийской литературе //Известия АН СССР. Отд. лит-ры и языка, т. VI, вып. 4.— М., 1947, 291 б.
[11] Потанин Г. Н. Алда күрсәтелгән хезмәт, 183 б.
[12] Шунда ук, 768 б.

тавыш белән кычкыручы кошларны Кырымда «Исак» дип атап йөртәләр дә.

Мисаллар җитәрлек булды булса кирәк. Без анализлаган мифлар, шулай итеп, «Сак-Сок» сюжетының һәм образларының килеп чыгышын, шулай ук аларның борынгы эволюциясен Шәрык культура мирасы белән бәйлиләр. Аерым алганда, ул мифлар көнчыгыш халыкларының рухи мирасында Сак-Сок белән чын мәгънәсендә аваздаш образлар һәм мотив-сюжетлар булуын раслап торалар. Безнеңчә, бу һич тә бер-береннән бәйсез мөстәкыйль рәвештә туган типологик уртаклык кына түгел, ә нәкъ менә үзара кардәшлеккә нигезләнгән генетик уртаклык та. Бу уртаклык бабаларыбызның көнчыгыш халыклары белән тыгыз аралашып яшәүләре һәм культура элементләре нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Әмма парлы образлар һәм шуларга нигезләнгән сюжет үзебезнең милли җирлектә, һичшиксез, эшкәртелгән, ягъни милли фараз, аерым вариант төсен алган. «Сак-Сок» әсәренең ана белән балалар арасындагы мөнәсәбәтне дә гәүдәләндерүе, парлар арасындагы конфликтны мораль-әхлакый планда тасвирлавы әнә шул хакта сөйли.

Сак-Сок кошларының исемнәре дә, безнеңчә төрки-татарларның үз җирлегенә, үз сүзләренә барып тоташа. Кайберәүләр бу исемнәрне борынгы «сыктау» (елау) һәм «сакинч» (сагыну) дигән сүзләрдән чыгарырга тырышалар. Әлеге сүзләр кошларның (балаларның) драматик табигатенә шактый тәңгәл килеп торса да, без шәхсән Сак-Сокка этимологик нигез итеп борынгы сак (уң) һәм сок-согъ (сул) дигән сүзләрне алу ягында. Чөнки «сак» (уң) — «сок» (сул) дию борынгыларның дуалистик карашларына аеруча тәңгәл килеп тора. Ул асылда бер-берсе белән беркайчан да кушыла алмый торган ике антиподның, ике оппозициянең исемнәрен атау белән бер. Уң белән сул үзара кушыла алмаган кебек, капма-каршы образлар булган Сак-Сок та бер-бере белән очраша алмыйлар.

*Өйгән кибәнне җилләр тарата,*
*Каушабыз дигәч, хәзер таң ата.*

*Кояш туганда кан тула күзгә,*
*Кыямәт көнсез кавышу юк безгә.*

«Сак-Сок»ның Рязань өлкәсе Касыйм районында табылган бер вариантында хәтта әлеге образлар, турыдан-туры капма-каршы яклар белән бәйләп, ягъни нәкъ без раслаган мәгънәдә бирелгәннәр.

*Бермез сактамыз, бермез сoктамыз,*
*Без икевемез ике яктамыз.*

Тормышта кулланыла торган аерым атамаларда, әйтик, кайбер елга исемнәрендә дә без сак-сок оппозицияләре белән очрашабыз булса кирәк. Мәсәлән, хәзерге Куйбышев һәм Оренбург өлкәләрендә капма-каршы юнәлештә агып ятучы ике елганың исеме Сак белән Сок. Һәм өстәп әйтергә кирәк: соңгы елганың исеме Ибн-Фадлан сәяхәте вакытында, ягъни IX йөздә үк инде билгеле булган.

Инде килеп, Сак-Сок атамаларына бәйләнешле соңгы момент турында. Безнең фәнни әдәбиятта Сак-Сокны тулысынча мифик-фантастик кошлар итеп кенә карау гадәткә кергән. Ләкин кайбер төбәкләрдә әлеге кошларны, Кырым татарлары һәм алтайларда, аерым мифик кошлар чын кошлар белән тиңләштерелгән кебек,ниндидер реаль кошлар белән бәйләү очраклары да бар. М. Гафури, мәсәлән, үзенең истәлекләрендә («Тәрҗемәи хәлем») Урал таулары арасындагы урманнарда төннәрен моңлы итеп Сак-Сок кошларының кычкыруы турында яза.[13] Яки менә элекке Буа кантонының Чүпрәле волостеннан укытучы Габделхәй Хәмзин тарафыннан 1927 елда Гыйльми Үзәккә җибәрелгән бер хаттан өзек: «Ышланга авылы янындагы Сер урманында Сак-Сок кошлары бар. Таң атканда берсе сызгырган тавыш белән «сак-сак» дип кычкыра. Аңа каршы икенче «сок-сок» дип җавап бирә. Сак Сoктан күбрәк кычкыра. Сак кычкырганда башка кошлар тыныбрак торалар. Сак-Сок кошлары, башка кошлар шикелле үк, 15 майдан 1 июльгә кадәр кычкыралар. Күчмә кошлар булырга охшыйлар. Безнең якта бу кошларны Сак-Сок дип йөртәләр».[14]

Шулай итеп, «Сак-Сок» әсәрендә гасырлар чоңгылыннан килүче Шәрык мифологиясе башлангычы иң борынгы катламны тәшкил итә икән. Әмма бу башлангыч безнең үз җирлегебездә туган яки эшкәртелгән элементлар белән бергә кушылган һәм, алда әйтелгәнчә, милли версия төсен алган. Бу инде, димәк, «Сак-Сок» сюжеты һәм образлары көнчыгыш культура казанышларын үзләштерү һәм үзебезнең милли фольклорда үзенчәлекле дәвам итү нәтиҗәсендә барлыкка килгән дигән сүз. Драматизмга һәм дуалистик конфликтка нигезләнгән борынгы мифик әчтәлекнең — миф-легенданың — әсәрдә, сәнгатьчә фикерләүгә буйсынып, романтик һәм лиро-эпик яңгыраш алуы һәм ярымбаллада, ярымбәет формасында корылуы әнә шул хакта сөйли.

**Марсель БАКИРОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

[13] Гафури М. Әсәрләр. Дүрт томда. 4 том. Казан, 1981, 420 б.
[14] Казан университеты фәнни китапханәсенең көнчыгыш кульязмалары бүлеге, Т. 953.

# МАНЬЧЖУРИЯДӘГЕ МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕБЕЗ

Ерак Шәрыкта, аерым алганда Маньчжуриядә, үз вакытында гомер кичергән милләттәшләребезнең хәяте тарихын өйрәнү бик зарури эш. Чөнки чит мәмләкәтләрдә яшәүче татарларның тарихы — бербөтен тарихыбызның аерылгысыз бер өлеше.

Татар мөһаҗирләренең «беренче дулкыны» Маньчжуриягә килеп чыгуы 1897 елда Көнчыгыш Кытай тимер юлы (КВЖД) төзелә башлау белән бәйле. Бирегә килүчеләр, башлыча, сәүдә белән шөгыльләнәләр. «Икенче дулкын» килү Октябрь революциясеннән соң башлана. Яңа дәүләт корылышына ризасызлык белдерүче хәрбиләр, төрле катлау вәкилләре бирегә күпләп күчәләр һәм төрле эшләргә урнашалар. «Өченче дулкын», әйтергә кирәк, баштагы икесенә караганда күләм ягыннан азрак, илебездәге күмәк хуҗалык төзүнең авыр һәм фаҗигале елларына туры килә.

Аянычлы язмыш җилләре кая гына илтеп ташласа да, татарлар үзләренең хезмәт сөючән, тырыш булулары аркасында һич тә югалып калмыйлар. Маньчжуриядәге мөһаҗир милләттәшләребез әкренләп сәүдә өлкәсендә шактый гына уңышларга ирешә башлыйлар. Алар хәтта яшәгән даирәләрендә кытайлы коммерсантларның да көндәшләренә әвереләләр. Мәсәлән, Япониягә барып япон телен өйрәнеп кайткан Бәдретдин Агафуров зур гына сәүдә ширкәте әгъзасы булып китә. Заһидулла Агишев исә үзе Харбинда яшәп, Тухунда каласында кибет тота. Сәүдәгәр Айдаровның Харбинда әзер күлмәкләр сата торган кибет хуҗасы булуы мәгълүм. Берадәрән Сатылгановларның «Лихо» дип аталган тире-күн эшкәртү заводы, Акчуриннарның «Чурин һәм К°» сәүдә фирмасы заманында киң танылган була.

Татарлар Маньчжурия калаларында мәхәлләләргә тупланып яшиләр. Шундый зур мәхәлләләрнең берсе 1904 елда Харбин шәһәрендә барлыкка килә. Соңрак моңа охшашлы мәхәлләләр Хайлар, Бухэду, Мукден, Хунгульди, Чаньчун, Якэши, Гирин кебек калаларда да оеша. Болай бергәләп яшәү аларга телләрен, гореф-гадәтләрен, йолаларын сакларга ярдәм итә. Зур мәхәлләләрдә уку-укыту, дини йолаларны үтәү, милли традицияләрне саклауга юнәтелгән махсус биналар да салына. Мәсәлән, 1906 елда Харбинда «Гинаят» (химанчесе ахун Гиниятулла Салиәхмәтовка нисбәтән) беренче татар мәктәбе төзелә. 1920 елда бу мәктәпнең директоры булып Габдулла Газизов эшли, ә мөгаллимнәре Рабига Деушева, Зәйнәб Шәмсетдинова була. Башка фәннәр белән бергәттән, мәктәптә төрек-татар тарихы, Коръән дә укытыла, 1930 елдан япон теле өйрәтелә.

Татарлар яшәгән мәхәлләләрдә дини тәрбия кылуга да зур игътибар бирелә. Әйтергә кирәк, Кытайда ислам динен дунганнар, уйгырлар, казакълар, кыргызлар һәм башка милләтләр дә тоталар. Аларның төп өлеше сөннилөр мәзһәбендә. Шактый еллар Ерак Көнчыгышта мөфти булып Кобэ шәһәрендә яшәүче Шамгони Маҗар тора. Аның вафатыннан соң бу вазыйфаны чират тәртибендә Харбин имамы Мөнир Хәсбуллин, Кореяда яшәүче Габделкәрим Рәхимов башкара. Шулай ук үз вакытында Токиода яшәүче Габдрәшит Ибраһимов та дини хезмәттә күренекле урыннарның берсен алып тора.

Бабаларыбызның ислам динен үз ихтыярлары белән кабул итүнең 1000 еллыгы уңае белән 1923 елда Маньчжуриядә яңа мәчеткә нигез салалар. Ул мәчет 1937 елда төзелеп бетә.

Татар яшьләренең күпчелеге мәктәпләрдән соң белем алуны югары уку йортларында дәвам иттерәләр. Әйтик, Габдулла Әхтәмов, Төньяк Маньчжурия университетының политехник факультетын тәмамлап, «Чурин һәм К°» фирмасының үзәк конторасында

эшли. Харбиндагы татар мәхәлләсенең яшьләр түгәрәге идарәсе сәркатибе Фатыйх Бәдретдинов та университет белеме ала.

1908 елда Харбин мәхәлләсендә бушлай файдалана торган китапханә ачыла. Аның уку залы да була. 1918 елда пристань төбәгендәге Артиллерия һәм Биржа урамнары кисешкән почмакта театр, спорт залы булган ике катлы таш бина өлгертәләр. Анда шулай ук канцелярия, мәктәп, китапханә, уку залы, яшьләр өчен күңел ачу бүлмәсе дә эшли. Бирегә лекцияләр уку оештырыла, әдәби-музыкаль кичәләр үткәрелә. Болардан килгән керем мәхәллә ихтыяҗларына сарыф ителә.

Харбин радиосы, «Маньчжурия мөхбире», «Харбин вакыты», Япониядә чыгучы «Яңа япон мөхбире» газеталары татарлар тормышын тасвирлаган хәбәрләр тапшыралар, мәкаләләр бастыралар. 1935 елда Мукденда татар телендә «Милли байрак» исемле газета чыгарыла башлый. Аның нашире — «Стелла» кибете хуҗасы Сәлмән Аитов, ә редакторы Дәүләткилде Ибраһим була.

1919 елда барлыкка килгән татар театр түгәрәге яшьләрдә сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләүдә зур роль уйный. Бирегә, башка татар драматургларының әсәрләре белән беррәттән, Г. Исхакый пьесалары да еш уйнала.

Шул вакытларда Маньчжуриядә яшәүче татар хатын-кызлары турында да әйтеп үтәргә кирәк. Алар да милләттәшләребез хәятендә тирән эз калдырганнар. Хатын-кызлар милли, дини бәйрәмнәрне оештыру һәм үткәрүдә бик актив катнашалар. Мәсәлән, шундыйлардан Хәнифә Айдарова, Газизә Байчурина, Гарифә Шаһимәрданова, Маһисәрвәр Шакироваларның исемнәрен әйтергә мөмкин. Мәктәпләрдә укытучы булып эшләүчеләрдән янә Мукден шәһәрендәге татар мөгаллимнәре курсында эшләүче Фәридә Агеева, Маньчжурия шәһәрендәге татар мәктәбе директоры Мәйсара Нәбиуллина исемнәре дә билгеле. Әшрәф Акчурина, аның сеңелесе Халидә коммерция өлкәсендә, Хәнифә Гайнетдинова «Фудосан Синтаку» фирмасында, Маһинур Байчурина Харбинда врач булып эшлиләр.

Маньчжуриядәге татарлар бүтән кыйтгалардагы милләттәшләребез белән дә бик тыгыз элемтәдә булалар. Ләкин Икенче Бөтендөнья сугышы башлану алар тормышында да кискен үзгәрешләр ясый. Ерак Көнчыгышта иҗтимагый-сәяси хәлләрнең катлауланучы нәтиҗәсендә Маньчжуриядәге татарлар Америка, Төркия һәм башка мәмләкәтләргә күплән күчеп китә башлыйлар.

Р. ӘЛТӘФ.

# ЧИТ ИЛЛӘРДӘ ТАТАР ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТЫ

XIX йөз ахыры — XX йөз башында туган җирләрендә фәкыйрьлектән интеккән татарлар Кытай, Корея һәм Япониягә килеп урнаша башлый. Кытайда алар әүвәл Маньчжурия, Хайлар, Харбин шәһәрләрендә тамыр җибәрә. Вакытлы татар матбугаты пәйда булгач, милли газеталарыбызны һәм журналларыбызны туган якларыннан алдырып торуны юлга салалар.

Октябрь революциясе милләттәшләребезнең яңа дулкыны читкә китүгә сәбәп була. Әлеге шәһәрләрдә татарлар саны бик күпкә арта, Корея һәм Япония шәһәрләрендә аларның яңа колонияләре барлыкка килә. Шуның белән бергә, Россиядән татар матбугаты алдыру кимегәннән-кими, аннары тәмам туктала. Рухи ихтыяҗны канәгатьләндерү, милли бердәмлекне саклау омтылышы чит илләргә сибелгән татарларны әнә шулай үз вакытлы матбугатын нигезләргә этәрә.

Татар көндәлек матбугаты Ерак Шәрыкта иң әүвәл Кытайның Харбин шәһәрендә шытып чыга. Башта гарәп хәрефләре белән кульязма журналлар һәм газеталар пәйда була, аннары шуларны мимеография һәм литография ысулында күбәйтергә керешәләр. Теләкләре кабынса да, заманча типография корырга мал-мөлкәтсез мөһаҗирләрнең хәтсез вакыт көче җитми.

1927 елда Төркия латин әлифбасына күчә, шунлыктан монда гарәп хәрефләренә ихтыяҗ калмый. Аларның бәясе арзанаюын Япония, бигрәк тә Токиодагы татар җәмгыяте, беренче белеп ала һәм милләттәшләребез арасында иганә җыюны оештыра. Аннары тупланган акчага, Япония хакимнәренең теләктәшлек күрсәтүе шартларында, Төркиядән гарәп шрифте кайтарыла һәм, кайбер япон зыялылары ярдәмендә, татар типографиясе оештырыла. 1930 елда милли басмаханәбез эшкә керешә, шулай, итеп, чит илләрдә вакытлы матбугатыбызны чыгару яңа югарылыкка күтәрелә.

Ерак Шәрыкта татарларның Үзәк идарәсе оешкач, Токио басмаханәсенең әһәмияте әкренләп кими, милли китапларыбыз һәм вакытлы матбугатыбызның яңа мәркәзе рәвешендә Кытайның Мукден (Шәнйән) шәһәре санала башлый.

Түбәндә Ерак Шәрык илләрендә басылган татар вакытлы матбугаты исемлеге тәкъдим ителә.

**Бәйрәм нуры.** Харбиндагы татар җәмгыятенең бер көнлек бәйрәм газетасы. 1934 елның 23 июнендә Харбинда чыга.

**Берлек мәҗмугасы.** Токио шәһәрендә 1940 елда Камал Йосыф бастыра.

**Ерак шәрык.** Харбин татар җәмгыяте журналы. Редакторлары Г. Әхмәди, Х. Габдүш, Р. Рәхмәти. 1920-1922 елларда Харбинда басыла.

**Ерак шәрык.** Татар яшьләре түгәрәге газетасы. Редакция коллегиясе Харбинда 1924-1925 елларда бастыра.

**Игълан-хакыйкать.** Токиода 1936 елда комиссия бастырган газета.

**Йолдыз.** Тйанцзиндә 1928 елда чыгарылган газета.

**Мең ел.** Харбинда Идел буе болгарларының ислам дине кабул итүләренә мең ел тулуга багышлап чыгарылган бер көнлек газета.

**Милли байрак.** Гаяз Исхакый нигез салган газета. Нашире С. Анти. Баш редакторы И. Дәүләткилде. Мукденда 1936—1945 елларда басыла.

**Пилмән.** Сатирик листовка. Харбинда Хөсәен Үтеш 1920 елларда бастыра.

**Чаткы.** Харбинда Хөсәен Габдүш 1932 елда чыгарган газета.

**Шагыйрь.** Г. Тукай үлеменең 20 еллыгына багышлап чыгарылган бер көнлек газета. Харбинда 1933 елның 15 апрелендә юбилей комиссиясе бастыра.

**Шәрык авазы.** Тйанцзин шәһәрендә С. Караев тарафыннан 1940—1944 елларда чыгарылган журнал.

**Шәкертләр таңы.** Мукден шәһәрендә татар мәктәбе укучылары чыгарган журнал. 1934, 1939—1940 елларда дөньяга килә.

**Япон мөхбире.** 1931 елда Токио татарлары чыгарган журнал.

**Яңа япон мөхбире.** 1932—1938 елларда Токиода комиссия тарафыннан нәшер ителгән журнал.

**Ялкын.** Харбинда урыс мәктәпләрендә укучы татар яшьләре 1923—1924 елларда чыгарган журнал.

Токио һәм Мукден шәһәрләрендә еллык татар календарьлары да нәшер ителә.

Чыганаклар: Таһир М. Ерак Шәрыкта нәшрият фагыйлиятләребез //«Казан» журналы. 1971, № 5. Истанбул; Таһир М. Токиода «Матбагаи исламия»// «Казан» журналы, 1975, № 16. Истанбул; «Милли байрак», 1938, № 117. Мукден. («Казан» журналының башка саннарында да милли көндәлек матбугатыбыз хакында кайбер мәгълүматлар бар).

**Мәхмүт ТАҺИР,**
Истанбул шәһәре, Төркия.

## ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

16 августта Татарстан Язучылар берлегенең ачык партия җыелышы булып узды. КПССның XXVIII съезды йомгакларына багышланган беренче көн тәртибендә коммунист язучылар бүген КПССта килеп туган аңлашылмый торган бер күренешкә игътибар юнәлттеләр. Залдан президиумга шундый сораулар яуды: «Без хәзер кайсы партия әгъзалары — КПССныкымы, әллә РКПныкымы?» «Без хәзер кайсы съезд карарларын тормышка ашыру өчен тырышырга тиеш — КПССның XXVIII съезды карарларынмы, әллә РКПныкыларынмы?» Әш шунда ки, Татарстан язучылары, КПССның XXVIII съезды карарларында азмы-күпме алга китеш, җәмгыятебез тормышында теге яки бу үзгәрешләр ясарга омтылыш булса, РКПның оешу съезды консерватив шартларда үтте, дип саныйлар. Коммунист язучыларның күбесе РКП съезды йомгакларыннан, бигрәк тә аның беренче секретаре И. Полозковның сәяси карашларыннан риза түгел. Әйтик, алар И. Полозковның «Правда» газетасына биргән интервьюсы бүгенге үзгәртеп коруга, демократия һәм хәбәрдарлыкка, экономикадагы радикаль үзгәрешләргә һөҗүм дип бәялиләр. Бу уңайдан Татарстан Язучылар берлеге партия җыелышы И. Полозковның әлеге интервьюсына сәяси протест акты белдерергә карар кылды. Шушы протест йөзеннән язучы-коммунистларның өч айлык взнослары, партия кассасына тапшырылмыйча, картлар йортына күчереләчәк.

Шушы җыелышта драматург Ризван Хәмид, тәнкыйтьче Мансур Вәлиев, прозаик һәм шагыйрь Марсель Галиев, прозаик Нәбирә Гыйматдинова, рус телендә язучы Әхәт Мушинский, балалар язучысы Рафис Корбановның төрле сәяси сәбәпләр белән КПСС сафларыннан чыгулары турындагы гаризалары каралды һәм үтенечләре канәгатьләндерелде.

Драматург һәм публицист Диас Вәлиевнең гаризасы буенча фикер алышу катлаулы бер бәхәскә әверелде. Д. Вәлиев, бүгенге партия һәм дәүләт җитәкчеләре социалистик җәмгыять төзү принципларыннан читләшәләр, дип саный һәм шул сәбәп аркасында үзенең бүгенге КПСС сафларында булуын туктатырга карар кыла. Әмма язучы үзен бәйсез коммунист дип саный, партия взносы түләүдән баш тарта. Әдип, партия яңадан социалистик җәмгыять төзү позицияләренә басса, мин КПСС сафларында булуымны дәвам итәчәкмен, дип белдерде.

Шушы ук җыелышта республика язучылары, Татарстан Югары Советы сессиясендә каралачак дәүләтчелек Декларациясе проектына үз мөнәсәбәтләрен белдерү өчен, барлык иҗат союзларының берләштерелгән гадәттән тыш пленумын чакыру башлангычы белән чыктылар.

## ТАТАРСТАН ИҖАТЧЫЛАРЫНЫҢ БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘН ПЛЕНУМЫ

20 августта булып узган әлеге пленумда Татарстан Югары Советының ачылачак икенче сессиясе турында сүз барды. Чөнки сессия мөстәкыйльлек, суверенлык мәсьәләсен дә карарга тиеш иде.

Татарстан күпме мөстәкыйльрәк, бәйсезрәк булса, анда яшәүче татарлар белән беррәттән урыслар, еврейлар, чувашлар һәм башка халыклар да шулкадәр бәйсезрәк һәм әйбәтрәк яшәячәк.

Иҗатчылар җыенында төп фикер булып әнә шул әйтелде. Чыгыш ясаучылардан РСФСР халык депутаты Ринат Мөхәммәдиев, галим Әбрар Кәримуллин, философия фәннәре кандидаты Рафаэль Хәкимов, язучы Роберт Батулланың һ. б. ның фикере бер иде: Татарстан бернигә карамастан мөстәкыйль дәүләт булырга һәм аның дәүләтчелеге субъектларга бүленмәскә тиеш. Ахырдан пленум резолюция кабул итте һәм ул Татарстан Югары Советына тапшырылды.

## ХАЛЫК ЫШАНЫЧЫН АКЛАДЫЛАР

Татарстанның суверенлык алуын һәм союздаш республикага әверелүен тәэмин иткән Татарстан Югары Советының чираттан тыш икенче сессиясе эшендә язучы-депутатлар да актив катнашты. РСФСР халык депутаты Р. Мөхәммәдиев, Татарстан халык депутатлары Р. Фәйзуллин, Р. Миңнуллин, Ф. Бәйрәмова, Разил Вәлиев үз чыгышларында Татарстанга суверенлык кирәклеген кире кага алмаслык дәлилләр белән раcладылар.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕНДӘ

16 августта Татарстан республикасы Язучылар берлеге идарәсе утырышында шагыйрь Зиннур Мансуров бертавыштан язучылар берлеге рәисенең урынбасары итеп сайланды.

## ҖЫЛЫ ӘҢГӘМӘ

23 августта Әдәбиятчылар йортында АКШның СССРдагы илчелеге икенче со-

ветнигы Майкл Морроу һәм илчелекнең атташесы Томас Ратбурн белән татар әдипләренең очрашуы булды. Әлеге әңгәмәдә илләребез тормышындагы, дөнья халыклары яшәешендәге бик күп мәсьәләләр турында җанлы сөйләшү булды.

Очрашуда Татарстан республикасы Язучылар берлеге рәисе Р. Мөхәммәдиев, идарә рәисе урынбасары З. Мансуров, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Р. Фәйзуллин, күренекле галим Ә. Кәримуллин, язучы Р. Батулла катнашты.

## КАЗАНДА — КЫТАЙ КУНАКЛАРЫ

Татарлар Кытайда 5 меңләп исәпләнә. Ләкин ике ил арасындагы мөнәсәбәтләр киеренкеләнгән чорда Кытайдагы милләттәшләр турында берни дә белми яшәдек. Менә Кытай Халык Республикасында яшәүче бер төркем милләттәшләребез Казанга килеп чыкты. Алар 22 августта татарларның «Ватан» җәмгыяте җитәкчеләре белән очраштылар. Фикер алышу бик файдалы булды.

Кунаклар, нигездә, Кытайның Синьцзян провинциясеннән иде. Андагы татар җәмгыяте рәисе, Синьцзян университетының Үзәк Азия халыклары мәдәниятен өйрәнү институты директоры Зариф Дулатов Кытай Халык Республикасында татарларның тормышы турында сөйләде. Очрашуда катнашучылар һәр ике яктан да эшлекле хезмәттәшлекне, татар халкының тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүне дәвам итәргә теләк белдерделәр.

## ИТАЛИЯ АЛКЫШЛЫЙ

Чаллының «Айгөл» балалар җыр ансамбле, Италиядә фольклор коллективлары фестивалендә катнашып, бу ил тамашачысының олы хөрмәтен яулап кайтты.

Ансамбль Совет тынычлыкны яклау комитеты каршындагы иҗади инициатива үзәге чакыруы буенча барган иде. Ул Италиядә ике атна буе чыгышлар ясады. Программага татар композиторлары җырлары һәм биюләре кертелгән иде. «Әпипә», «Бәбиләр» биюен тамашачы аягүрә басып алкышлады.

## УТЫЗ ДҮРТ ЕЛДАН СОҢ...

РСФСР Халык мәгарифе министрлыгы быелдан Башкортстанның Кушнаренко каласында татар педагогия училищесы ачу турында карар чыгарды. Училище Башкортстанда яшәүче милләттәшләрнең телен саклауга, мәдәниятен үстерүгә, рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә булышлык итәчәк. Утыз дүрт ел элек «кирәге юк» дигән әмер белән ябылган училище икенче тормышын башлый.

## СӨЕМБИКӘДӘ — ЯРЫМАЙ

Казандагы Сөембикә манарасына ярымай кую-куймау турындагы бәхәсләр, нихаять, уңай хәл ителде. Изге манара башына ярымай урнаштырылды. Әлегә ул төзүчеләрнең агач корылмалары эчендә. Тиздән мәгърур ярымай алардан арынып һәм бөтен Казан өстендә нур чәчеп балкый башлар.

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЯҢА ГАЗЕТАЛАР

### «ШӘҺРИ КАЗАН»

Халык депутатларының Казан шәһәр Советы һәм шәһәр партия комитеты газетасы «Шәһри Казан»ның беренче саннарын казанлылар гына түгел, бөтен республика халкы шатланып каршылады.

### «ТАТАРСТАН ХӘБӘРЛӘРЕ»

Яңа елдан Татарстан республикасында тагын ике газета дөнья күрәчәк. Татарстан Республикасы Югары Советы татар һәм урыс телләрендә чыгарачак әлеге басмалар «Татарстан хәбәрләре» һәм «Известия Татарстана» дип исемләнә.

### «ӨМЕТ»

Тобольск шәһәрендә Себердә яшәүче милләттәшләребез өчен «Өмет» газетасы нәшер ителә башлады.

### «ЧУЛМАН-ИДЕЛ»

Чаллының «Таң йолдызы», «Нур» газеталары янына тагын бер татарча басма өстәлде. Ул — халык депутатлары шәһәр Советының «Чулман-Идел» газетасы. Әлеге басма җомга көннәрендә чыга.

### «ТУГАН ЯК»

Нижний Новгород өлкәсендә яшәүче милләттәшләребез дә үзләрен сиздерә башлады. Татарлар яшәгән авылларда бер-бер артлы мәчетләр калка, милли мәктәп һәм балалар бакчалары ачыла. Шушы көннәрдә өлкә татарлары өчен тагын бер күренекле вакыйга булды: Сергач шәһәрендә «Туган як» исемле татар газетасы чыга башлады.

### «ИДЕЛ»

Әстерхан өлкәсендә яшәгән милләттәшләребезне берләштергән «Дуслык» татар мәдәни җәмгыяте «Идел» дигән газета чыгара башлады. Газета әлегә рус телендә чыга. Якын араларда газета татар телендә чыга башлаячак.

## УКРАИН СҮЗЛЕГЕНДӘ — ТАТАРСТАН

«Украиньска Радяньска Энциклопэдия» нәшрияты өч томда «Украин совет энциклопедик сүзлеге»н бастырып чыгарды.

Яңа сүзлекнең Татарстанга багышланган бүлеге украин укучыларын бу административ төбәкнең оешуы тарихы, аның халык хуҗалыгы тармакларының үсеше, социаль өлкәдәге казанышлары, Татарстан белән бәйләнгән атаклы шәхесләре турында җентекләп таныштыра.

### «БОЛГАР» БИЮ АНСАМБЛЕ

Чаллыда яңа оешкан «Болгар» бию ансамбле эшли башлады. Аңа Чаллы сәнгать училищесының хореография бүлеге мөдире булып эшләгән белгеч Мөхәммәт Мортазин җитәкчелек итә.

Ансамбльгә училищены тәмамлаган сәләтле яшьләр чакырылды, Мәскәү, Свердловск, Ижевск, Йошкар-Ола дәүләт ансамбльләрендә эшләгән оста биючеләр дә килде.

Сентябрьдә ансамбль оркестрында дәресләр башланды. Музыкантлар белән сәнгать училищесының элеккеге укытучысы Фәрит Закиров җитәкчелек итә.

### МӘДРӘСӘ АЧЫЛДЫ

Түбән Кама шәһәрендә мәдрәсә ачылды. Анда ир-атлар һәм хатын-кызлар класслары булачак. Инде 30 кешелек төркем тупланды. Дәресләрне Түбән Каманың имам-хатибы А. Вәлиев һәм Татар иҗтимагый үзәге активистлары алып барачак.

### САБАДА — БӘЙРӘМ

8 сентябрьдә Саба район мәдәният йортында районның оешуына 60 ел тулуга багышланган тантаналы җыелыш үткәрелде. Халык депутатларының район Советы рәисе Ф. Гыйльмиев докладыннан соң, КПСС райкомының беренче секретаре М. Газизов районда туып-үскән, әлеге тантанага кунак булып кайткан әдәбият-сәнгать әһелләренә сүз бирде. Язучылардан — ТССР халык депутаты Фәүзия Бәйрәмова, филология фәннәре докторлары Азат Әхмәдуллин һәм Әбрар Кәримуллин, «Казан утлары» журналының баш редактор урынбасары Рашат Низамиев, музыка өлкәсендә күренекле белгеч Мәхмүт Нигъмәтҗанов һ. б. үзләренең якташларын район юбилее һәм Татарстанның суверенлык алуы белән котладылар, үзләрен борчыган мәсьәләләр хакында фикер уртаклаштылар.

Тантана әдәби-музыкаль кичә белән тәмамланды.

### ТЕЛӘКТӘШЛЕК ӨЧЕН РӘХМӘТ

Татарстан Югары Советы сессиясе республика мөстәкыйльлеге мәсьәләсен караган һәм суверенлык турында Декларация кабул иткән көннәрдә Татар иҗтимагый үзәгенә меңнәрчә теләктәшлек һәм котлау телеграммалары килде. Татар иҗтимагый үзәге идарәсе телеграммалар җибәргән Әзербәйҗан, Литва, Латвия, Эстония халык фронтларына; Үзбәкстанның «Берлек», Кырым татар халык хәрәкәтләре идарәләренә; Татар иҗтимагый үзәгенең Татарстан, Башкортстан, Казахстан, Үзбәкстан, Төрекмәнстан, Украина, Белоруссия, Латвия, Литва, Эстониядәге; РСФСРның Оренбург, Пермь, Свердловск, Әстерхан, Пенза, Саратов, Куйбышев, Тольятти, Төмән, Тобол, Омск, Новосибирск, Воркута, Чиләбе, Мәскәү, Ижевск, Воткинск, Чайковский, Березники, Кунгар, Златауст, Богырыслан һ. б. шәһәрләрдәге бүлек һәм теләктәшлек төркемнәренә рәхмәт белдерә.

**Татар иҗтимагый үзәге идарәсе.**

## *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** 1977 елда СССРдагы дүрт Диния нәзарәте өчен нәшер ителгән Корьәннән фотокүчермә. Сүрәтүл-Фатиха.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган әдип, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Хисам Камалов.

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотолары.

### АЧЫКЛЫК КЕРТӘБЕЗ...

Журналыбызның быелгы 8 санында өлкән шагыйребез Нури ага Арслановның Салих Баттал турында язмасы басылган иде. Анда төгәлсезлек киткән. Ватан сугышы елларында Нури Арслан редакциягә эшкә керми, ә госпитальдә ятып сәламәтләнеп чыккач, болай гына — хәл белергә генә керә. Сугыш беткәнче Н. Арслан армиядә була, 1946 елда гына демобилизацияләнә.

*Редакция.*

*«Казан утлары» 1991 елда*

**Батулла**

# СӨЕН БИКӘ КЫЙССАСЫ

Сөен бикә (Сөембикә) манарасы, Сөен бикә бәете, Сөен бикә риваяте, Сөен бикә тәкъдире, дибез. Үзен татар санаган һәр адәм бу сүзләрне күп мәртәбәләр ишеткән, бәетен укыган, җырын җырлаган. Телдән телгә күчеп йөри торган бу канатлы тәгъбирләр, дүрт йөз кырык еллап вакыт узса да, онытылмый. Татар яшәгәндә онытылмаячак та. «Кем соң ул шундый мәшһүрә Сөен бикә?» — дигәнгә әбкәйләр, бабакайлар: «Ханбикә булган ул, углым, Казанны кансыз, рәхимсез, дәһшәтле Явыз Иванга бирмәскә тырышкан батыр, акыллы, чибәр ханбикә», диярләр. Сөен бикәнең гүзәллеге хакында сүзләр китапларда да, телдә дә бик күп. Ә менә татар әдәбиятында Сөен бикәнең балачагы, кияүгә чыгуы, Казан азатлыгы өчен ниләр кылганлыгы турында моңарчы бер генә әсәр дә язылмады. Бу кыйсса — Казан ханлыгына караган беренче әдәби-тарихи әсәр. Бу — Сөен бикәне күзаллау, җанландыру өлкәсендә беренче тәҗрибә.


Халык сөйли: имеш, Сөен бикә урысларга әсир төшәргә теләмәгән, углы Үтәмеш белән Кызыл манарадан сикереп төшеп, вафат булган, ди. Шуңа күрә әлеге Кызыл манара «Сөембикә манарасы» дип атала, янәсе.

Тарихчылар яза: имеш, Сөен бикә әсир төшкән, Мәскәүгә озатылган. Имеш, Сөен бикә үз үлеме белән коллыкта үлгән. Улы Үтәмеш Гәрәй хан чукындырылып, Александр исеме алып, егерме яшендә Мәскәүдә үлгән. Шундый сүзләр дә бар: имеш, Сөен бикәнең колак-борыннарын кисеп, чибәр йөзен ямьсезләп, каты җәзалап үтергеннәр икән, икенчеләре, шул золымга түзәр хәле калмагач, ул үзенә-үзе кул салган икән, дип тә әйтәләр.

Кайсысы соң боларның хакыйкатькә туры килә? Кем соң ул Сөен бикә ханбикә? Ул яшәгән заманда татар халкының мәшһүр адәмнәреннән тагын кемнәр булган? Нинди шартларда Казан мәмләкәте харап ителгән, яшәүдән туктаган? Менә шулар белән кызыксынган кеше Батулланың безнең журналга тәкъдим иткән кыйссасында үзенә җавап табачак.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



**КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)**

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРСТАНА